АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
имени ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

Из сокровищницы научных экспедиций

# НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Астраханские татары*

КАЗАНЬ · 2017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ

*Әстерхан татарлары*

КАЗАН • 2017

УДК 39(470.41)+008(470.41)
ББК 70(2Р354)
М48

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

**Редколлегия:**

***К.М. Миңнуллин** (рәис), **Д.Б. Рамазанова, М.Х. Вәлиев***

**Төзүче һәм фәнни мөхәррир**
***М.Р. Булатова***

**М48** **Милли-мәдәни мирасыбыз: Әстерхан татарлары.** – Казан, 2017. – 420 б. – (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән; унберенче китап).

ISBN 978-5-93091-210-4

«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядә дөнья күргән чираттагы бу китап Әстерхан өлкәсенең Идел буе районында яшәүче милләттәшләребез, аларның гореф-гадәтләре, тел үзенчәлекләре турында бай мәгълүмат бирә. Бу җыентыкта борынгы ташбилгеләр, шәҗәрәләр, тарихи шәхесләргә багышланган язмалар урын алды. Шулай ук анда җирле халыкның авыз иҗаты, җыр-моңнары, осталарның кул эшләре, авыллар тарихы белән дә танышырга мөмкин. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең тикшеренү-эзләнүләрен туплаган әлеге басма үз укучыларын табар һәм андагы язмалар һәркемдә зур кызыксыну уятыр, дип ышанабыз.

**ISBN 978-5-93091-210-4**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2017

## СҮЗ БАШЫ

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, татарларның телен, әдәбиятын, халык иҗатын, музыкаль һәм тасвирый сәнгатен югары фән дәрәҗәсендә өйрәнә торган гыйльми-тикшеренү үзәге буларак, 2009 елдан башлап һәр елны милләттәшләребез яшәгән 2–3 төбәккә комплекслы экспедицияләр оештыра. Актаныш (2009), Түбән Новгород, Курган, Апас, Эстәрлебаш (Башкортстан), Оренбург (2010 ел), Кукмара, Бәрәңге (Мари Эл, 2011), Чүпрәле, Удмуртия Республикасы (2012), Мамадыш, Барда (Пермь крае) (2013), Омск (Себер) һәм Самара (2014) тарафларына оештырылган гыйльми сәфәр материалларының байтагы «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» исемле сериядә аерым китаплар булып басылып чыкты.

Әлеге китап Институттан бер төркем галимнәрнең, аспирантларның 2013 елның июнь аенда Әстерхан өлкәсендә (Идел буе районындагы Киләче (Килинчи), Җәмәле (Три Протока), Ярлы Түбә (Осыпной Бугор), Кызан (Татарская Башмаковка), Мәйле Күл (Яксатово), Каргалык (Карагали) һәм Нариман районындагы Каңга (Кучергановка) авылларында) булып, анда яшәүче милләттәшләребезнең сөйләш үзенчәлекләрен, тормышкөнкүрешен, мәдәниятен, сәнгатен, халык авыз иҗатын, кульъязма һәм ташъязма текстларын барлау, аларны фәнни эшкәртү, тикшерүләренә багышланган хезмәтләрен колачлый.

Тарихи чыганаклардан мәгълүм булганча, Әстерхан өлкәсе – төрки халыклар яшәгән мөһим төбәкләрнең берсе. Ул – заманында Төрки һәм Хәзәр каганлыклары, Алтын Урда, Нугай Урдасы, Әстерхан ханлыгы составларында булган. Әстерхан өлкәсе татарлары әлеге төбәктә яшәп килгән төрле этник төркемнәр (кундра татарлары, юрт татарлары, карагашлар, мишәрләр, казан татарлары һәм нугайлар) катнашында, аларның аралашуы нәтиҗәсендә формалашкан.

Әстерхан өлкәсе татарлары Идел елгасының түбән агымында урнашкан Әстерхан шәһәрендә һәм аның тирә-ягындагы районнарда аерым авыллар булып яшиләр, милләтебезнең аерылгысыз бер өлешен тәшкил итәләр.

Түбән Идел буенда элек-электән төрки халыклар яшәгән һәм Алтын Урда таркалудан барлыкка килгән Әстерхан ханлыгында әстерхан сөйләшенең нигезен тәшкил итүче юрт урынчылыгы вәкилләренең бабалары гомер иткән.

Алтын Урда җимерелгәннән соң, аның территориясендә барлыкка килгән татар ханлыклары бер-бер артлы рус дәүләте тарафыннан яулап алына. Ул чор тарихчылары, дәүләт эшлеклеләре, административ органнар һәм башка түрәләр Әстерхан ханлыгы халкы, аларның кем булуы, килеп чыгышы, теле, дине турында төрлечә язып калдырганнар. Әмма, яңа кушылган территориядәге хәлне, тарихны, тормыш-көнкүрешне начар белгәнгә күрә, бу язмаларга буталчыклыклар, ялгышлар да шактый кергән.

Әстерхан татарлары сөйләше узган гасырның 70–90 елларында Л.Ш. Арсланов тарафыннан өйрәнелгән. Татар халык сөйләшләре атласын төзү өчен материаллар җыйнау программасы кысаларында эзләнгән галим бай материал туплый алган. Ул Түбән Идел буе сөйләшләренең Атласын, һәртөрле сүзлекләрен төзегән һәм аларны бастырып чыгаруга да ирешкән.

Институтыбыз галимәсе, филология фәннәре докторы Ф.С. Баязитова да Әстерхан татарларының гореф-гадәтен, йолаларын, сөйләш үзенчәлекләрен өйрәнә. 2002 елда аның «Әстерхан татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор» исемле китабы дөнья күргән иде. Әлеге басмага кертелгән мәкаләсендә исә әстерхан сөйләше үзенчәлекләрен җирле мисаллар ярдәмендә тасвирлый.

2013 елда Әстерхан өлкәсенә оештырылган экспедициядә археограф М.И. Әхмәтҗанов, диалектологлар Д.Б. Рамазанова,

М.Р. Булатова, фольклорчы И.Г. Закирова, тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать төрләре белгечләре Д.И. Әхмәтова белән А.Р. Исимбитьева катнашты. Комплекслы экспедициянең максаты милләттәшләребезнең көнкүреш йолаларын, җирле сөйләш һ.б. үзенчәлекләрен өйрәнеп, анализлау иде. Эш нәтиҗәләре Әстерхан җирендә көн күрүче милләттәшләребезнең рухи-мәдәни һәм матди мирасы турындагы мәкаләләр, һәр юнәлешкә багышланган аерым язмалар рәвешендә, әлеге китапка урнаштырылды.

Танылган галим, филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов тапкан һәм өйрәнгән ташъязма истәлекләрдә, кульъязмаларда җирле халык тарихы белән бәйле яңа мәгълүматлар китерелә.

Филология фәннәре докторы, профессор Дария Рамазанова һәм яшь галимә, филология фәннәре кандидаты Миңнира Булатова Әстерхан өлкәсенең әйтеп үтелгән авылларында җыелган материаллардан сөйләш үзенчәлекләре, халыкның көнкүреше, авыллар тарихы, гореф-гадәтләр, йолалар, мәкаль-әйтемнәр, шигырь үрнәкләрен һ.б. тәкъдим итә.

Халык авыз иҗаты филология фәннәре докторы Илсөяр Закирова тарафыннан тупланды. Шушы төбәккә генә хас булган тарихи һәм мифологик риваятьләр, бәетләр, мөнәҗәтләр, җырлар, йола фольклорына һәм төрле ышануларга бәйле булган текстларның һәркайсы фольклор фәненә тиңсез хәзинә буларак өстәләчәк.

Тасвирый, декоратив-гамәли сәнгать һәм матди мәдәният өлкәсендәге тикшеренүләрне Динә Әхмәтова белән Альбина Исимбитьева башкарды. Төрле чигүле сөлгеләр, милли киемнәр, агачка чокып ясалган бизәкләр, мәчет һәм йортларның тышкы һәм эчке бизәлеш үзенчәлекләре, шәмаил үрнәкләре аларның мәкалә һәм фотосурәтләрендә чагылыш таба.

Әлеге экспедиция материалларыннан тыш, бу китапта Әстерхан каласындагы «Сөембикә» исемле төрки-татар оешмасын җитәкләүче Наилә ханым Потеева-Фатыйхованың әстерхан татарлары тормышын сурәтләгән мәкаләсе, Әстерхан өлкәсе Идел буе районы, Киләче авылы мәктәбе укытучысы Наилә Есенбаеваның әстерхан татарлары сөйләшенә караган сүзлекчәсе дә урын алды.

Әстерхан татарларының милләтебезгә хас булган мөлаемлыгы, тыйнаклыгы, кунакчыллыгы, якты йөз белән каршы алуы экспедициядә катнашучы Институт галимнәренең күңелендә якты

тәэсирләр уяткан. Безнең гыйльми хезмәткәрләребез сәфәрен нәтиҗәле оештыруда, аларга яшәү өчен уңайлы шартлар тудыруда турыдан-туры катнашканнары өчен өлкәнең Идел буе районы хакимияте башлыгы Ринат Ибраһим улы Үтәлиевка, «Әстерхан татарларының мәдәниятен үстерү һәм саклау ассоциациясе» җитәкчесе Ильмира Мөхлис кызы Үтәлиевага, Әстерхан татарлары язмышы, яшәеше, мәдәнияте турында киңкырлы мәгълүмат биргән Наилә Шакирҗан кызы Потеева-Фатыйховага һәм авыллардагы информантларга чиксез рәхмәтлебез.

Әстерхан татарларының олысы-кечесе халкыбыз традицияләрен ихтирам итеп, аларны саклап яшәтүгә лаеклы өлешен кертә. Телебезгә, милли йөзебез, рухи-мәдәни хәзинәләребезгә, «тел җәүһәрләре», ягъни әби-бабалар тапшырып калдырган йолалар, гореф-гадәтләргә караш киләчәктә дә сүрелмәсен иде.

Халыктан җыелган һәм галимнәр тарафыннан фәнни эшкәртелеп, шушы төбәктәге татарларның тарихилыкны саклап яшәүләрен, җирле осталарның, талантлы милләттәшләребезнең рухи һәм мәдәни мирас үрнәкләрен үзенә туплаган әлеге китап укучылар күңеленә хуш килер, дип ышанабыз.

***Ким Миңнуллин,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм*
*сәнгать институты директоры*

# ӘСТЕРХАН ӨЛКӘСЕ ТАТАР ЗИРАТЛАРЫ ҺӘМ АЛАРДАГЫ КАБЕР ӨСТЕ КУЛЬТУРАСЫ

*Марсель Әхмәтҗанов*

Әстерхан өлкәсенең татар зиратлары һәм алардагы ташбилгеләр фәнни яктан әлегә хәтле бер мәртәбә дә өйрәнелмәгән иде.

Әстерхан өлкәсендәге татар авыллары зиратлары үзләренең тәртипле тотылуы белән аерылып торалар. Аларда, беренчедән, зиратны чүпләп утыручы сәрби, канәфер кебек әрсез агачлар утыртылмаган.

Зиратларда икенче бер күңелсез күренеш – чардуганнарны арасыннан кеше йөрергә уңайсыз итеп урнаштыру. Мондый хәл беркадәр Әстерхан зиратларында да күзәтелә. Ләкин анда каберләр арасында сукмак калдырыла, һәркемнең мәңгелек йорты янына килеп дога кылырга, кабер өстен тәртипкә китерергә мөмкин.

Әстерхан өлкәсендәге Кызан авылы зиратының капка төбендә кызыл кирпечтән җыйнак кына, матур итеп, тәһарәт алу урыны ясалган. Аның эченә утыргыч, зур гына су савыты, комган һ.б. әсбаплар куелган. Мондый яхшы әдәпне әлегәчә башка татар каберлекләрендә күргәнем булмады.

Бу якларда, агач күп булмагач, кабер өсләренә агач материалларыннан эшләнгән чардуганнар сирәк куелган. Ләкин менә арматурадан ясалып, матур итеп зәңгәр, яшел төсләргә буялган чардуганнар хәзер бик күп. Аларның металл читәннәренә татар орнаменты мотивларыннан матур конструкцияләр эшләнеп, чардуган челтәрләрен милли сәнгатебезнең әлегәчә тормышыбызда чагылмаган жанры, дип кабул итәргә мөмкин. Мондый сәнгать мотивлары хәзерге көндә татар хуҗалыгындагы урам капкаларында, коймаларында, йортларның бизәлешендә дә киң җәелә бара.

Ләкин шуның белән бергә бу матур күренешнең татар зиратларында ямьсез яклары да күтәрелә башлады. Бу ямьсезлек варислары калмаган мәрхүмнәр каберләре өсләрендәге материалы күгәреп, кәкрәеп беткән чардуганнардан гыйбарәт.

Моны булдырмас өчен һәр авылда зират турында кайгыртучы аксакаллар төркемен тупларга кирәктер. Алар мәңгелек йортларыбызда кирәкле тәртипне оештыру вәкаләтләренә ия булырга тиештер.

Әстерхан якларында кабер өсте корылмаларыннан биек баш казыклары утырту традициясе нык саклана. Баш казыклары – юанлыгы (диаметры) 12–15 см булган түгәрәк очлы башлы баганалар мәрхүмнең баш ягына яки аяк очларына утыртыла. Алар гадәттә чардуган эчендә кала. Ул баш казыкларының җирдән бер 120 см югарылыкта бер ягын киртекләп, ул киртеккә җайлап такта кадаклана. Тактада мәрхүмнең исем-фамилиясе һәм башка мәгълүматлар язылган. Әстерхан ягындагы зиратларның баш казыклары белән күңелсез хәлләр дә килеп чыккалаган. Җәйге эссе көннәрдә, үләннәр саргаеп кипкәч, янгын чыгып зиратлардагы баш казыкларының янып бетү очраклар да булган икән. Шунлыктан хәзер баш казыкларын, очына 20–25 см диаметрлы металл айлар беркетелгән трубалардан да ясап утырту йоласы таралган. Шулай ук Әстерхан якларында нечкәрәк бүрәнәләрдән, киртәлек агачтан башларын очлайтып ясалган баш казыклары күп күренә. Аның очына, кошлар килеп утырмасын өчен, кадаклар да каккалап куйганнар.

Баш казыклар кую культурасы татар халкында киң таралган милли күренеш. Аны Рязань якларында да, Татарстанда да, Пенза һәм Нократ якларында да куялар. Ләкин Әстерханнныкылар үзләренчә, аерылып торалар.

## Әстерхан өлкәсенең Идел буе районы татар авыллары зиратларындагы ташбилгеләр

Әстерхан өлкәсе, Идел буе районы татар авыллары зиратларының ташбилгеләр кую традициясе Урта Идел буендагыга караганда бераз соңрак, аеруча XX йөзнең башларыннан җанланып китә. Дөрес, кайбер зиратларда сирәк кенә 1880 елларда куелган ташбилгеләр дә күренә. Ләкин алар сәнгатьлелек ягыннан бик камилләшмәгәннәр. Татарстан һәм Оренбург якларындагы ташбилгеләр кую традициясе XVII гасырның икенче XVIII гасырның урталарыннан күтәрелеш кичерә башлый.

Әстерхан төбәге татарларының зират традицияләре ныгып китү өчен XVIII йөздә мөмкинлек булмый. Әстерхан шәһәрендә татар халкы яшәве хакында XVII гасырдан ук мәгълүматлар булса да, аларның мазарлары сакланышы һич канәгатьләндерерлек түгел.

Татарлар монда бүгенге Киләчи, Кызан, Тияк кебек авылларда, Әстерханның үзендә Касыйм, Казан, Пенза кебек яклардан күчеп килгән татарлар белән аралашып, беркадәр үзләренең тел-фольклор йола традицияләрен саклап, өлкәдәге татар үзенчәлекләрен кабул итеп, әлегәчә сакланырга тырышып яшиләр.

Шушы процессларның барышын аңлар өчен халыкның күңелен көзгедәй чагылдырган милли зират традицияләрен өйрәнү зур әһәмияткә ия.

### *Киләче авылы зираты*

Киләче авылының исеме борынгы татар ыруы атамасыннан килгән дип санала. Әстерхан ягы Киләче авылының адашы – Клачы, Татарстандагы Арча төбәгендә дә бар.

Төрки халыкларның этнонимнары исемлегендә *Килеҗи* исемле этноним[1] белән бүгенге Әстерхан төбәгендәге Киләче авылы атамасы бер чыганакка барып тоташа. Бу чыганак атамасы «киләчи»нең ыру-кабилә этнонимы икәнлеккә ишарә ясый.

Әлеге авылның тарихын ачыклауда аның зиратындагы эпитафик язмалар текстлары да ярдәм итә. Бу яктагы ландшафтларны борынгы традиция буенча түбәләргә бүлеп тәгаенлиләр. Киләче зираты берничә түбә дип аталган калкулыклар өстендә урнашкан.

Әлеге зират иң борынгы кабер – җирле халыкта иң танылган «Нур Ата һәм Йегет әүлия (Җайдак әүлия)» төрбәсе буларак мәгълүм. Алар изгеләр дип саклаaналар, халык аларны борынгыдан бирле танып килгән. Ләкин, кызганычка каршы, бу изгеләр тарихыннан риваятьләр сөйләүчеләр бик сирәк булды. Без бу зиратны 2013 елның 12 июнендә зиярәт кылдык.

Соңгы елларда бу ике әүлия кабере өстенә зурлыгы 25×30×60 см булган таш плитәләрдән төрбә салынган. Аның озынлыгы 11 метр, иңе 4,2 метр, биеклеге 2,4 метр. Бер як диварында 80×120 см үлчәмдәге ике тәрәзәсе бар. Аларга дүрткә бүленгән агач рамнар утыртылган. Төрбәнең иң түрендәге кабер Нур Атага

[1] Материалы по истории кыргызов и Кыргызстана (второе издание). Бишкек, 2002. С. 229.



Нур Ата һәм Йегет әүлия дөрбәсе. Киләче авылы зираты

нисбәтләнә, бер як стенадагы ишектән кергәч тә булганы Йегет әүлиянеке дип санала.

Төрбәнең эчендә дә, тышында да аларга мөнәсәбәтле ташбилгеләр куелмаган. Төрбәнең түр ягындагы кыска иңле диварның тышкы ягында аңа терәлеп торган унбер тимер торбаны әләмнәр элү өчен җайлап урнаштырганнар. Аларда ак материядән ясалган ак әләмнәр җилфердәп тора. Тузгач, 1939 елда туган бер ханым аларны яңартып тора икән. Төрбәнең түбәсе горизонталь рәвештә (төз түбә) ябылган.

Бу якларда Киләче зиратының Бабай түбәсендә Гайшә әүлия, Фатыйма әүлия каберләре барлыгын да сөйлиләр. Ләкин безгә ул урынны күрсәтүче булмады.

Киләче зираты, бу төбәк каберлекләренә хас булганча, биек баш казыклары күплеге белән күзгә бәрелеп тора.

Баш казыклары күп очракта кабернең баш ягына яки аяк очларына утыртыла. Аларның башлары очлы итеп ясала һәм, кош килеп кунмасын өчен, иң очка кадак та кагылган. Баш казыкларының диаметры 13–14 см алып 6–7 см калынлыгындагылар да бар. Баш казыкларына мәрхүмнең исем фамилияләрен, туган-үлгән елларын язган дүртпочмаклы такталар кадаклап кую очраклары сирәк күренә.

XX гасырның беренче яртысына кадәр чардуган кую гадәте булмаганга охшый. Әстерхан ягы татарларының татар милләте вәкилләренә хас милли зират атрибутлары булган чардуганнар бу дәвернең икенче яртысында киң таралыш алганнар. Баш казыклары чардуган эчендә калганнар. Баш казыкларының очларына 20 см чамасы диаметрлы металлдан кисеп ясалган ярымай сыннары кую йоласы нык таралган. Әстерхан татарларының күп зиратларындагы кебек, Киләче зиратында да зур агачлар утыртылмаган.

Өйрәнелә торган зиратта төбәкнең башка каберлекләрендә сирәгрәк күренгән гарәп язулы ташбилгеләр шактый гына сакланганнар. Ул ташбилгеләр янында чардуганнар юк һәм ташларның авып төшкән очраклары да күп.

Бу заманда Әстерхан якларында традицион татар ташбилгеләре тибы өстенлек алган. Түбәндә аларның кайбер үрнәкләре бирелә.

***1 нче ташбилге.***

Ташбилгенең йөзлегендә татарның гарәп нигезендәге тәгъликъ ысулында, ташка уеп язылган текст күренә:



«Һазә әл-мәркаде
мәрхүм
Ураз –
мәнбит
Мират
углы дарел-
фанадин
дарел-бакайа
рихләт әйләде».

Ташбилгенең арткы стенасында:

«1920
нче йылда
87 йәшендә.
Аллаһ рәхмәт әйләсен».
Ташның бер кырында:
«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун».

Искәрмә: ташның үлчәмнәре – 15×18×59 см, известьташтан кисеп ясалган, язмалар уеп язылган. Билге 10 см калынлыгындагы дүртпочмаклы, таштан эшләнгән нигез басма өстендә куелган.



***2 нче ташбилге.***

«Һазә мәркадә
Казан губерна
-сы Мамадыш
өйәзе Саба карийә-
сенең Мөхәммәд Әмин
Садыйк углы вафат
улды Мәүлид нәбинең
3 нче көнендә 72 йәшендә.
1910 сәнә. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун».

Искәрмә: ташның үлчәмнәре – 17×35×100 см. Текст татар тәгъликы ысулында язылган.

***3 нче ташбилге.***

«Һазә әл-мәркад
Мәрхүм Госман
у....
..........
рәхмәт әйләсүн».

Икенче ягында:

«1920
нче йылда
24 нче
рамазанда».

Искәрмә: ташның үлчәмнәре – 15×19×52 см. Известьташтан ясалган басмага куелган. Язмалар уеп, тәгъликъ ысулында язылганнар.

***4 нче ташбилге.***

«Әлмәрхүм Мәүләм бирде
Корбанкай углы 1907 нче
йылда рәбигыль-әүвәл айында
алтмыш йәшендә рихләт әйләде».

Искәрмә: ташның үлчәмнәре – 14×36×68,5 см. Язмалар уеп тәгъликъ ысулында язылганнар.

***5 нче ташбилге.***

«Урусова
Кальбибе
Тлекмамбет
кызы
1883–1957».

Искәрмә: ташның үлчәмнәре – 20×34×116 см, татар телендәге язма кириллицада теркәлгән.

***6 нчы ташбилге.***

«Телякманбетов
Гафур
Нугман улы
Туды 1932.29.XII.
Вафат булды 1985.12.VII».

Искәрмә: известьташтан эшләнгән, үлчәмнәре –13×47,5×117 см.

Алда китерелгән 5 нче, 6 нчы ташбилгеләр Идегәй би нәселеннән булган Урусовларның токымнарыннан икәнлеге Киләче авылыннан Зөлхәбирә Ишбирде-Урусованың «Нәселем эзләреннән» дигән 2005 елда Әстерханда басылган китабында күрсәтелгән.

***7 нче ташбилге.***

«....
Маһикамал
........
10 нчы йанварда
дүшәмбе көн
49 йәшендә
1912 нче сәнәдә».

Искәрмә: ташбилге тексты татарның тәгъликъ ысулындагы язмасында теркәлгән, уеп язылган, үлчәмнәре – 14×32×71 см. Ватылып, җиргә ауган.

***8 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Акчурина
Харис кызы Мәфтүха. 1924–2011».

Искәрмә: чардуган эчендә, кабер өстендә ике баш казыгы. Чардуган тышында кара мәрмәр ташбилге.

Киләче зиратының бер почмагы казак каберлегенә әйләнеп килә. Анда казакъларның дистәләрчә төрбәләре тезелеп киткән. Ул каберләр куелу тарихлары 2003–2012 елларга туры килә. Казакъ төрбәләренә беркетелгән элмә такталарда аларның **Агатай бериш, ТНС бериш, Бескаска бериш, Кызыл курт, Кыла каска шеркеш** ыруларыннан чыкканнары язылган.

***Кызан (Башмаковка) зираты һәм Мансур әүлия кабере***

Әстерхан өлкәсенә оештырылган археографик экспедиция вакытында Кызан (Башмаковка) авылында булырга туры килде. Бу бик зур татар авылы. Авылның мактаулы аксакаллары Әхмәтов Габбас (1928 елда туган) белән Шәфигуллин Шамил (1939 елда туган) безне авылның зур тарихлы зираты белән таныштырып йөрделәр.

Аларның сөйләве буенча Кызан авылы зиратында Күгәнә һәм Мансур әүлияләрнең каберләре, төрбәсе саклана икән. Габбас

ага сүзләренә караганда (ул борынгы риваятьләргә таянып сөйли. – *М.Ә.),* Мансур әүлиянең Кызанда күмелү тарихы түбәндәгечә була: Мансур әүлиянең мәете Идел елгасында салга куелган килеш агып килгән. Килгән чакта ул салга төреп салынган була, халык аны танып, изге дип олылап, Кызан зиратында күмгән. Күрәсең, мәетнең янында аның кем икәнлеген язган язма булган, бәлки Мансур әүлия Әстерханда бик мәгълүм изге зат булгандыр. Мансур әүлия җирләнгән урын Куштүбә дип йөртелә икән. Мансур әүлиянең бу якларда – «Мансур йерик» дигән елга буенда авылы да бар, диләр. Бу факт та аның үз чорында атаклы кеше булганлыгына дәлил булып тора.

Минемчә, Мансур әүлия Әстерхан ханлыгыннан Сафа Гәрәй хан белән 1546 елда Казанга килеп, шул ук елда Сафа Гәрәй хан белән кире Әстерхан ягына берлектә чыгып киткән Мансур сәет – мәшһүр Кол Шәриф Мөхәммәд сәетнең атасы булса кирәк. Кол Шәрифнең 1550 елда «Зафәрнамә-и вилаяте Казан» әсәрендә язылганча, Мансур Ата турында аның вафат булуы хәбәре генә теркәлгән[1]. Күрәсең, Мансур сәет Әстерханга кайтканда юлда үлеп, Сафа Гәрәй хан һәм аның юлдашлары мәрхүмнең гәүдәсен ватанына салга салып озатканнар дип фаразларга нигез бар.

Мондый очраклар байтак тарихи риваятьләрдә дә сөйләнә. Мәсәлән безне озатып йөргән агалар, Казан шәһәренә бәла килгәндә, аның халкы, салларга утырып, Әстерхан якларына күчеп килүчеләр булганлыгы хакында да риваять сөйләп алдылар. Әстерханнан атаклы «Гайсә углы Амәт» дастанының төп каһарманы Амәт хәзерге Татарстанның Олы Тархан авылы тирәләреннән салга утырып ватанына кайткан. Аның җырында:

Ак Сарайда балчымын,
Ана Иделдә салчымын.
Әстерханда тучымын,
Кыр-далада уенчымын[2].

Казан якларында 1623–1624 еллардагы ачлык вакытында 40 гаиләнең сал белән юлга чыгуы, агып барганда, үзара ызгышып ике төркемгә бүленүе, шуңа күрә ике авылга урнашып төпләнүләре ха-

---

[1] Мәңгелеккә аяк басканда: Сәйед Кол Шәриф. Казан: Идел-Пресс, 2006. 18 б.

[2] Гайса углы Амәт // Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. 180 б.

кында да бер риваять ишеттек. Кызан авылында шул вакытларда тукталып яшәп калучылар күп булган.

Кызан авылының салынуы турында да бер кызыклы риваятькә тап булдык: «Борынгы заманда берәүнең бик матур кызы булып, аның сөйгән, вәгъдәләшкән егете була. Бу кызга аны сорап икенче бай егеттән яучы килә. Ата-ана байга кызын бирергә риза була, ләкин кыз риза булмый.

Кыз бай кияүгә чыкмаска сәбәп итеп, минем йөргән егетемнән йөгем бар, дип сөйли. Шуннан мондый хәлдән соң ул кызны авылдан куалар. Ул кыз шушы Кызан авылы урынына килеп, чокыр казып, шунда тора башлый. Шунда торганда бала таба. Шунлыктан никахсыз бала тапкан кыз истәлеге буларак авылга Кыз+ана (Кызана) исеме кушылып калган».

Кызан авылы бүгенге көндә дүрт җәмгыятьтән гыйбарәт икән. Алар түбәндәге исемнәр белән мәгълүм:

1. Базар авыл
2. Кинәгәс авыл
3. Кужа авыл
4. Түбә өсте.

Бу атамаларның берсе – Кинәгәс борынгы татар кабиләсе һәм ыруының атамасы («Кенегесъ») буларак яхшы мәгълүм[1].

Кужа атамасы Алтын Урда дәүләтендәге социаль яктан югары катлау татар термины. Ихтимал, бу җирдә хакимият ияләреннән берәрсе яшәгәнлекне аңлатадыр.

Түбә өсте – бу татар дәүләтләрендә административ бүленешне аңлаткан термин булган, шуннан татар телендә төбәк мәгънәсендәге сүз дә саклана.

Авылның бу атамалары Кызан авылының шактый борынгыдан барлыкка килүенә дәлил булып торалар. Аларның Әстерхан ханлыгы, Нугай Урдасы, Әстерхан (Хаҗи-Тархан) тарихлары белән бәйле булуы бәхәссез хакыйкать.

Алда искә алынганча, Кызан авылының зур зиратына Күгәнә һәм Мансур әүлияләрнең күмелүе хәбәре дә зиратка, ким дигәндә, XV–XVI йөзләр нигез салынганлыгына дәлил булып тора.

---

[1] Бравин Н. И Беляев И. Указатель племенных имен к статьи Н.И. Аристова «Заметки об этническом составе тюркских племен и сведения о их численности». СПб.: Типо-литография «Герольд», 1903.

Зират материалын өйрәнү нәтиҗәләре күрсәткәнчә, Кызанда XIX йөзнең икенче яртысына кадәр сакланган кабер өсте культурасы эзләре сакланмаган.

XIX гасырның икенче яртысыннан Әстерхан татарларының бердәм татар милләте оешу процессында ныклы катнашуы Кызан зиратындагы кабер өсте культурасы белән раслана. Болар, барыннан да элек, кабер өсләренә куела торган ташбилгеләр, төрбәләр, баш казыклары, чардуганнар һәм ташбилгеләрдә сакланган эпитафик язмалар текстларыннан гыйбарәт.

Әстерхан якларындагы татар ташбилгеләре үрнәкләренең башка төбәкләрдәге белән уртаклык билгеләреннән түбәндәгеләрне атап китәргә була:

1. Ташлар, нигездә, известьташ плитәләрдән кисеп, уеп ясалганнар. Тик ул материалны табу кыенрак, диләр. Тарихи ташбилгеләрнең аз булуына да төп сәбәп шушыдыр мөгаен.

2. Сакланган ташбилгеләрнең үлчәмнәре башка төбәкләрдәге һәйкәлләрдән нык аерылмыйлар.

3. Таш өслекләргә төшерелгән язмаларның, бизәкләрнең уеп һәм күпертеп эшләнешләре буенча да башка татар регионнары белән уртаклык бар.

4. Ташлардагы текстлар да, нигездә, гарәп, гарәп-татар, татар телләрендә язылулары белән милли мәдәният хәзинәсе ягыннан уртаклык күрсәтәләр.

5. Ташбилгеләр күпчелек очракта мәетнең баш очына, чардуган булса тышкы ягына куелалар, кабер өстенә утыртылмыйлар.

6. Ташбилге текстларындагы куелу даталары миләди, яки миләди-һиҗри тафталогик ысул белән язылганнар.

7. Ташбилгеләр барысы да, гомуммилли традиция буенча, вертикаль хәлдә, кендек ясалып, нигез-плитә өстенә утыртылалар.

8. Ташбилгеләрнең иң очында яки түбәсендә, сирәгрәк булса да, мифологик җан саналган кош, үзенең гәүдәсе күмелгән кабергә килгәндә, сусавын бассын өчен яңгыр суы җыела торган сай гына итеп уелган чокыр үрнәкләре очрый. Мондый очракларны Казан артындагы җирле осталар тарафыннан эшләнгән ташбилгеләрдә еш күрергә туры килә.

9. Ташбилге йөзлегенең иң өске өлешен фәндә *тимпан* дигән термин белән атыйлар. Татар ташбилгеләрендә күпчелек очракта тимпанда каллиграфик осталык белән эшләнгән гарәп графикасын-

да язылган ләүхәләр эшләнә. Шулай ук, инде XX гасырга кергәч, тимпаннарда күпчелек очракта ярымай силуэте һәм сирәгрәк очракта ярымай куенына керергә торган йолдыз сурәте төшерелә. Бу күренештә ташбилге бизәлешенең гомуммилли контекст эчендә барганлыгы чагыла.

10. Шулай ук Әстерхан регионы татар-мөселман ташбилгеләрендә мәрхүмнәрнең фотопортретлары күчермәләрен урнаштыру очраклары күбәя баруы күзәтелә. Бу инде ислам кануннары белән һич кенә дә ярашмый.

11. Әстерхан туфрагындагы ташбилгеләрдә гомуммилли эчтәлеккә туры килгән трафарет текстлары сакланышы күзәтелә:

Йөзлек ягында:

1. Аллаһ каршына баручы догасы.
2. Мәрхүмнең исеме, үлем датасы.
3. Даталарда миләди яки миләди-һиҗри елларның катнаш язылуы да очрый.
4. Мәрхүмнең яше.
5. Ходадан аның өчен дога-үтенеч.
6. Сирәк кенә шигъри юллар бирелә.

Кырларында:

1. Догалар.
2. Канатлы сүзләр.

Мәрхүмнең яше хакында мәгълүмат булуы мөмкин.

Әстерхан ташбилгеләрендәге уң һәм сул кырларда текст язу күренеше сирәгрәк.

Арткы стенага сирәк очракта гына догалар языла һәм ләүхәнең кем тарафыннан куелуы күрсәтелә. Бик сирәк кенә ташбилгене ясаучының исеме күрсәтелергә мөмкин. Әстерхан татар зиратларында кабернең баш һәм аяк очларына баш казыклары утыртылуы хакында әйтелде инде. Аларның очына металлдан эшләнеп, диаметры 20 см чамасындагы ярымай беркетелә.

Әстерхан баш казыклары үзләренең зурлыклары, куелу ешлыклары белән аерылып торалар. Аларны металлдан куюның сәбәбен болай аңлаталар: Ватан сугышы вакытында Кызан зираты почмагына зенит туплары утыртылып, аларга хезмәт күрсәтүче солдатлар агачтан эшләнгән баш казыкларын ягып, җылыну һәм аш әзерләү өчен файдаланалар.

Икенче вакытта Кызан зиратында җәйге корылык вакытында коры үләннәргә ут кабып баш казыклары да янып бетәләр. Мондый хәлләр башка зиратларда да кабатлангач, өлкәдә баш казыкларын металлдан куя башлау гадәткә кереп китә.

Кызан зиратының бер үзенчәлеге Әстерхан ягы каберлекләрендә таралмаган, кечкенә күләмле ташбилгеләргә тамгалар уеп ясап, эпитафик плитә итеп утырту очракларында күренә.

***1 нче ташбилге.***

Дүрт кырлы эшкәртелгән таш плитәгә төшерелгән тамга. Плитәнең үлчәмнәре 12×22×24 см. Тамганың сурәте:



Тамганың өстәге сызыкчасының буе 7 см, ташка уелу тирәнлеге 1,5–2 см. Аскы өлештәге сурәтнең бер чаты 16 см, икенче чаты 9 см. Аның атамасын ачыклыйсы бар.

***2 нче ташбилге.***

Дүрт кырлап эшкәртелгән известьташ, үлчәмнәре – 10×22,5× 30 см. Тамганың рәвеше:



Моңа охшаш тамгалар, минемчә, «әвернә тамга» дип атала. Аның биеклеге – 20 см. Өске ыргагының буе 5 см. Урталыктагы ике якка сузылган сызыкның буе 12 см. Аскы як сызыгының озынлыгы 6 см. Сызыкларның ташка уелу тирәнлеге 7 мм.

***3 нче ташбилге.***

Өстә дугаланып, калган өч ягы туры почмаклык итеп эшләнгән ташбилге, үлчәмнәре – 10×20×35 см. Таш йөзлегенә төшерелгән тамга «кош каурые»:



Китерелгән ике сызыкның буйлары 8 әр см. Ике арадагы бушлыкның киңлеге 6 см. Уелу тирәнлеге 0,5 см.

***4 нче ташбилге.***

Дүрт кырлы туры почмаклы ташбилге. Үлчәмнәре – 11×22× 24 см. Сызыклары, уеп, 0,6 см тирәнлектә итеп башкарылган.

Тамганың сурәте:



Дагасыман сызыклар тамгасы, даганың диаметры 6 см. Ике дага арасы – 2 см.

***5 нче ташбилге.***

Шундый ук тамга, тик даганың диаметры зуррак – 8 см, сызыкларның тирәнлеге 1,0 см.

***6 нчы ташбилге.***

Тамга өсте дугаланып торган ташбилгенең иң аскы өлешенә уелган. Тамганың сурәте:



Аның өске сызыгы буе 10 см. Астагы кендеге 6 см. Сызыкларның тирәнлеге 1,5 см.

***7 нче ташбилге.***

Зурлык үлчәмнәре – 10×22×28 см. Аңа уеп төшерелгән тамга сурәте:



Тамганың буе 8 см. Ыргагының буе 3 см. Сызыкның киңлеге 1 см. Сызыкның тирәнлеге 0,8 см.

***8 нче ташбилге.***

Уеп ясалган ай тамга. Сурәте:



Үлчәмнәре алынмады.

***9 нчы ташбилге.***

Формасы бозылган ташбилгедәге көянтә сыман тамга:



Бу төр тамга берничә ташта очрады.

***10 нчы ташбилге.***

Дүрткырлы ташбилге плитә, үлчәмнәре – 12×22×24 см.



Тамга уеп ясалган.

***11 нче ташбилге.***

Дүрткырлы ташбилге плитә тамгасы:



Уеп ясалган тамга.

Ташбилгеләргә төшерелгән тамгаларга килгәндә, алар борынгы «ташка тамга салу» традициясенең билгеләре дип санала. Мондый тамга салынган плитә, риваятьләргә караганда, Сарайчык шәһәренең үзәк мәйданында да җирдә яткан.

Матбугаттан мәгълүм булганча, ислам диненнән аерылып, язусыз калган керәшен татарлары зиратларындагы агач ташбилгеләргә тамгалар төшерә торган булганнар[1].

Кызан авылы зиратындагы халык тарафыннан сакланып калган ташбилгеләр арасында аларның борынгы бабалары язган үрнәкләр дә саклана.

Һәм бу мисаллар Кызан татарларының башка төбәкләрдәге милләттәшләре белән уртак казанышлары булганлыгын раслыйлар.

Кызан зиратында гарәп һәм татар телләрендә катнаштырып язылган ташбилгеләр Әстерхан өлкәсендәге башка татар зиратларындагыга караганда күбрәк очрый.

***1 нче ташбилге.***

«Лә иләһә иллә Аллаһы Мөхәммәд рәсүллаһ
әл-мәрхүм әл мәгъфүр
Бикгали бине Кулдас
гафар Аллаһ
вафат ... сәнәи
1898»

Искәрмә: ташбилге известьташтан эшләнгән, үлчәмнәре – 20×38×100 см. Язмалар калкытып эшләнгән һәм тәгъликъ ысулында башкарылган.

***2 нче ташбилге.***

«Әгузе билләһи минәш-шәйтанир-раҗим
бисмиллаһир-рәхман әл-рахим

[1] Макаров Г. Ыру тамгасы, баш казыгы һәм ташбилге – борынгыдан килгән тарихи хәтер билгеләре // Проблемы изучения истории заселения и образования населенных пунктов Альметьевского региона. Казань, 2000. Б. 143–156.

әл-мәгъфүр
әл-мәрхүм бу...
Мостафа...
-колый гаффар Аллаһ
1315».

Искәрмә: ташбилге известьташтан эшләнгән, язмалар гарәп телендә һәм тәгъликъ ысулында ташка уеп язылган, үлү вакыты һиҗри 1315 (милади белән 1897/1898 ел дип күрсәтелгән).

Ташның үлчәмнәре – 20×36×90см.

***3 нче ташбилге.***

«Төрекмән халкы
Абдел ругы
Дауд Салахан Тукырҗан...
вафат әйләди
Аллаһ әл-гали әл....»

Искәрмә: ташбилге известьташтан бизәкләп эшләнгән, язмалар күпертеп язылган, таш авып, ватылып ята.

***4 нче ташбилге.***

«Лә иләһә иллә Аллаһы Мөхәммәд рәсүлуллаһ
Көлли мән галәйһа фан...»

Искәрмә: начар укылышлы, җимерек ташбилге, язулары уеп язылган, тәгъликъ ысулында булган.

***5 нче ташбилге.***

«Һазә әл-мәркади
әл-кәрим әл-мәгъфүр
Җанибәк бине Карт....»

Искәрмә: известьташ, язмалары уеп, тәгъликъ ысулында эшләнгән.

***6 нчы ташбилге.***

«Бисмиллаһи әр-рахмани әр-рахим
әгузе билләһи минәш-шәйтанир-раҗим
лә иләһә иллә Аллаһы һу-Аллаһы
әл-кайум лә тахмә сәнә-и вә лә
Нух лә Малих әс-сәмавәт вә шафи лә әрыз...»

***7 нче ташбилге.***

«Бисмиллаһ әр рәхман әр-рәхим
Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Мәрхүм Рахматулла углы
Айбулатов
Рөстәм
туды 1958.7.II.
вафат булды 2007.7.VII
Алланың рәхмәтендә булсын Әмин».

Искәрмә: ташбилге мәрмәр ватыкларыннан традицион формада коеп эшләнгән. Тимпанда ярымай силуэты ясалган. Аның астында сыгылмалы стильдә ике Коръән аяте уеп язылган.

Эпитафик текстның калган өлеше татар телендә кирилл әлифендә язылган. Ташбилге ике баскычлы басма өстендә, чардуганның тышкы ягында утыра.

***8 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Бикбулатов
Абдулхамит
Абдулвахид улы
туды 1969.14.XII
вафат булды
2009.7.VIII.
Алланың рәхмәтендә
булсын (Амин)».

Искәрмә: ташбилге турыпочмаклык рәвешендә мәрмәр ватыкларыннан коеп эшләнгән, тимпанында, уеп, ярымай силуэты төшерелгән. Аннан түбәндә тәгъликъ ысулында Коръәннән бер аять уеп язылган. Калган өлештәге текст, уеп, кирилл алфавитында язылган.

Ташбилге ике баскычлы басма өстендә, агач рәшәткәле чардуганның тышкы ягында, мәрхүмнең баш очына утыртылган.

***9 нчы ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Нургалиева
Индира
Кадыр кызы
туды 20.II/1986 ел

вафат булды
4.X.2002 ел.
Бәгырь балам
газиз балам
ике күземә бер кара
синең ялкыныңнан янам
сабырлык бирче
бер Аллам».

Искәрмә: ташбилге агач рәшәткәләрдән яшел төскә буяп эшләнгән чардуганның тышкы ягына, мәрхүмнең баш очына, бер катлы басмага утыртылган. Һәйкәл үзе мәрмәр ватыкларыннан коеп, туры почмаклык итеп ясалган.

Тимпан очында ярымай силуэты уеп ясалган, аннан түбәндә, дулкынсыман итеп, Коръән аяте уеп язылган.

Ташбилгенең татар телендәге текстына Әстерхан өлкәсенең Идел буе төбәге татар зиратларында бик сирәк очрый торган эпитафик поэзия үрнәге китерелгән. Бу кабер өстендә баш казыклары куелмаган. Чардуганның почмакларындагы терәк баганалары, җиргә күмелгән өлешендә, металл торбага утыртылган.

Язмалар уеп эшләнгән.

***10 нчы ташбилге.***

«...Мөхәммәд Аллаһ
көлли нәфсен заикател-мәвәте
Гайазулла бинте Мәстүрә
сәнәи 1905 4 ийүл
25 йәшендә....»

Искәрмә: ватылган ташбилге җир өстендә ята. Текст, уеп, тәгъликъ ысулында гарәп һәм татар телләрендә язылган. Эпитафия өчен начар эшкәртелгән известьташ файдаланылган. Ташбилге янында баш казыгы да, чардуган да сакланмаган.

***11 нче ташбилге.***

«Һазә әл-мәркад
әл-кәрим әл-мәрхүм
Җанбәк бине Карт».

Искәрмә: известьташтан эшләнгән ташбилге, эпитафик текст гарәп телендә, күпертеп язылган. Язма нәстәгъликъ ысулында.

***12 нче ташбилге.***

«Төрекман халкы
Абдәлругы
Даудсала хан тукызна
вафат әйләде әл-хөкем
Аллаһ әл-гали әллидә...».

Искәрмә: ташбилге тексты сөлес стилендә язылган. Ташбилге Кызан авылында катнашкан төрекмәннәрнең Абдал ругы вәкиле икән. Текст татар телендә язылган. Ләкин аның сөлес стилендә язылуы һәм тимпандагы йолдыз-ай композициясенең тискәре якка каратып ясалуы, башка татар телендәге эпитафик текстлардан аерыла. Ташбилгенең түбәнге ягы ватылган, бәлкем анда куелу вакыты да күрсәтелгән булгандыр.

***13 нче ташбилге.***

«Һазә әл-мәркаде мәрхүм
Фәхретдин
Максуд хаҗи
углы дарел-фана
дин дарел-бакайа
рихләт әйләде 1921
нче йылда шәвәл...».

Искәрмә: ташбилге известьташка уеп ясалган. Ярымай астында беренче язу гарәп телендә, тәгъликъ ысулында башкарылган, калган юллар татар телендә, тәгъликъ язуында теркәлгән. Ташбилге беркадәр авып, җиргә баткан, аның арткы стенасын әйләндереп карау мөмкин булмады.

***14 нче ташбилге.***

«Лә иләһә иллә Аллаһ
Мөхәммәд рәсүл Аллаһ
...................»

Искәрмә: ташбилгенең язу тексты өлеше нык җимерелгән, тик беренче юлы гына укылырлык. Бу һәйкәлнең тимпанындагы текст күпертеп язылган булган. Ташбилге известьташтан ясалган.

***15 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһивә иннә иләйһи раҗигун
Бердеева
Ажархан
Дамир кызы
туды 1972.28.IV –

вафат булды
2009.10.XI
Алланың рәхмәтендә
булсын (Амин)»

Искәрмә: ташбилге кара гранит плитәдән гыйбарәт. Үлчәмнәре – 8×40×8 см. Ул турыпочмаклы итеп ясалган. Аның тимпаннында ярымай һәм мәрхүмәнең зур портреты төшерелгән. Әстерхан якларында әле кабер ташларына портрет ясату кебек ширеклек бик таралып җитмәгән, шулай да, ул инде керә бара.

Коръән аяте язмасы тәгъликъ ысулында башкарылган, текстның калган өлеше саф татар телендә язылган (кирилл язуы белән). Ташбилге ике катлы басмага утыртылган, чардуганның тышкы ягына. Чардуган эчендә трубадан ясап куелган баш казыгы бар.

***16 нчы ташбилге.***

«Мархом
Бекбулатов
Яппар
Каримович
1917–1985».

Искәрмә: ташбилге мәрмәр плитәдән эшләнгән, чардуганга тышкы яктан терәтеп куелгган. Чардуган эчендә металл баш казыгы куелган. Аның очына ярымай беркетелгән.

***17 нче ташбилге.***

«Мархом Асаков Равил Шаукарбек улы, ыругы “Тома”.
1965–2005».

Искәрмә: ташбилге мәрмәр кисәкләреннән ясалган, чардуган тышына урнаштырылган. Үлчәмнәре – 8×40×65 см.

***18 нче ташбилге.***

«Әлхәмдул-иллаллаһ
көлли нәфсин
даикате әл-мәват:
Нигъмәт.... бинте
Фәйзулла 1905 йылда
14 нче ийүл 2 йәшендә».

Искәрмә: текст уеп язылган. Баштагы өч юл – гарәп телендәге аять өзеге, калган өлеше татар телендә тәгъликъ ысулындагы әлиф белән язылган. Ташбилгенең үлчәмнәре – 20×43×71 см.



Кызан авылы зиратындагы каберташлары

## *Идел буе (Приволжское) районының*
## *Каргалык авылы зираты ташбилгеләре*

Бу авылда безне үзешчән сәнгать түгәрәге артистлары җырлар, сый-хөрмәт белән каршы алдылар. Анда түгәрәк өстәл янында чәйләр эчеп, мәдәни язмыш турында фикер алыштык. Очрашуга шәһәрдән телевидение хезмәткәрләре дә чакырылып, бездән чыгышлар ясауны үтенделәр. Бик кирәкле, мәгънәле очрашу булды. Аннан соң без тау битенә салынган мәчет белән танышып чыгып, зиратка киттек. Зиратта кабер казырга килүчеләр күренә иде. Тауда – Баяз түбәсе, өстәрәк беседка шикелле түгәрәк түбәле итеп, стеналары фәкать баганалардан гыйбарәт булган төрбә күренә. Ул төрбәдә Сары хуҗа әүлия күмелгән. Иске төрбәдән бераз гына читтәрәк кирпечләрдән матур итеп төзелә башлап та, тәмамланмаган, яңа төрбә күтәрелгән.



Каргалык авылы зиратында Сары хуҗа әүлиягә салынып бетмәгән төрбә

Каргалык зиратында, бу якның башка каберлекләрендәге кебек, агачтан яки тимердән эшләнгән баш казыклары күп күренә. Аларның очына металлдан ясалган ярымайлар беркетелгән. Баш казыкларының биеклеге 180–200 см чамасы. Чардуганнарның күпчелеге арматурадан, агач рәшәткәлеләре сирәк. Чардуганнар араларында сукмакларга урын калып, тыгызлык сизелми.

Каберлектә сирәк кенә булса да XX йөз башларында куелган ташбилгеләр күренә, аларда гарәп язуының тәгъликъ ысулында, татар телендә язылган эпитафик текстларны очратасың, ләкин аларның саны бик аз, 10–15 ләп кенә күренә. Эпитафик текстлар ташларга уеп язылганнар. Күпчелек ташбилгеләрнең эпитафик текстлары тулы сакланмаган, ватылган.

Эпитафик текстлардан өлгеләр:

***1 нче ташбилге.***

«Мәрхүм
Тәчүлбибә
Кадерле кызы
вафат булды
1923 йылда
20 йәшендә»

Искәрмә: ташбилгенең үлчәмнәре – 12×35×88 см. Язмалар уеп татар тәгъликы ысулында теркәлгән. Тимпанда ярымай белән янәшә йолдыз сурәте төшерелгән.

***2 нче ташбилге.***

Ташбилгенең бер ягында:

«Йа вакыйга
Йа кабре».

Икенче ягында:

«Бисмилла әр-рәхман әр-рәхим
......әл-мөхәррәм
гаффар Аллаһ».

Искәрмә: язмалар уеп язылган булган, ләкин күпчелек урыннары кыйпылып җиргә коелган.

Гел гарәби җөмләләрдән гыйбарәт, язулары бозылган. Аларның күбесе ташбилгеләрдән кыйпылып, җиргә коелганнар, һәм бу XIX йөз ташлары юкка чыгу алдында торалар. Ташбилгенең үлчәмнәре – 17×45×95 см. Язмалары уеп язылган.

Бу югарыда санап үтелгән каберташлар янында чардуган эзләре юк. Ташларның кайберләре басып тора, җиргә ауганнары да җитәрлек. Аларның каберләре дә инде җир белән тигезләнеп беткән, билгеләү бик кыен.

### *Тияк бистәсе зираты*

Тияк бистәсе зиратын өйрәнеп бетерә алмадым. Шулай да кайбер ташбилге текстларын теркәргә өлгердем.

Каберлектә чардуган стеналарына ябыштырылган кара мәрмәр плитәләргә кириллица алфавитында татарча язылган исем-фамилияләр күренә.

***1 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун (бу язма гарәп графикасында. – *М.Ә.*).

«Салихов
Равиль
Файзрахман улы
Туды – 1937, 17.XII.
вафат булды – 2011.02.VI».

Искәрмә: ташбилгенең башына ярымай куелган. Плитәнең үлчәмнәре – 2,5×42×62 см, ул чардуган стенасына беркетелгән.

***2 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи
әл-мәрхүм
Абдуллаев
Растям
Фардин улы
Туды: 1967.16.IV.
вафат булды: 2003.17.XI.
Алланың рәхмәтендә
булсын. Амин.
Соңгы бүләгебез, син
Мәңге исебездә булырсың».

***3 нче ташбилге.***

«Байрамгазиев Ризабек Измаил улы. Туды 29.III.1955. – вафат булды. 4 апрель. 2006 ел. Рухы шат булсын».

Искәрмә: эпитафик текст кара мәрмәр плитәгә язылып, ул исә мәрмәр ватыкларыннан ясалган ташбилгегә беркетелгән. Плитәгә ярымай һәм мәрхүмнең портреты төшерелгән. Ташбилге чардуган тышына, мәрхүмнең баш очына утыртылган. Чардуган металл арматурадан эшләнеп, күгәргән хәлдә тора. Чардуган стенасына зәңгәр тасмалар бәйләнгән.

***4 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Шахмамедов Рашид Юнусович
1925.8.XI–1999.30.IV».

Искәрмә: кара мәрмәр плитәгә эпитафик текст язылган. Тимпанга гарәп әлифендә дога һәм ярымай сурәте төшерелгән. Ташбилге чардуган эченә, мәрхүмнең баш турысына куелган. Тәбәнәк арматура чардуган, буялмаган, күгәрмәгән. Язма һәм бизәкләр мәрмәр плитә йөзлегенә уеп төшерелгән.

***5 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Будинов Ринат Марат улы
1963.17.III – 2002.19.VIII».

Искәрмә: мәрмәр ватыкларыннан коеп эшләнгән ташбилге, тимпанына ярымай сурәте төшерелгән һәм аның астына гарәп телендә классик дога үрнәге уеп язылган, өстеннән кара буяу йөгертелгән. Ташбилге чардуганның тышкы ягында ике баскычлы басмага куелган. Чардуган эченә баш казыгы утыртылган.

***6 нчы ташбилге.***

«Абубикеров Гафур улы Рифгат
туган елы: 1936.13.09.
вафат булды: 2010.25.02».

Искәрмә: металл кисәкләреннән эшләнгән эпитафик билге. Очына ай куелган. Чардуганның тышкы ягына, баш очына утыртылган. Чардуганның биеклеге 60 см чамасы. Чардуган эчендә, мәрхүмнең баш очында бүрәнәдән баш казыгы ясап, аңа тактага язылган эпитафик текст беркетелгән булган. Очлы башлы итеп юынылган баш казыгы башына кошлар утырмаска кадак кагып куелган.

***7 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Еферов Равиль Газиз улы

туды: 1953.28.05.
вафат булды: 2012.22.02».

Искәрмә: металл пластинкадан буяп эшләнгән эпитафик билге. Тимпанда ай һәм йолдыз символы. Алар астына «Коръән» кәлимәсе һәм мәрхүм турында кыскача мәгълүмат язылган. Ташбилге чардуган тышына куелган.

Тияк бистәсе зиратында Үмәр Гашун исемле изгенең кабере барлыгын сөйләгәннәр иде. Ләкин без аның урынын таба алмадык. Бу каберлекне махсус өйрәнеп чыгасы бар, чөнки анда XX йөзнең беренче яртысында Әстерханда яшәгән һәм эшләгән татар зыялыларының мәңгелек йортлары ачыклануы мөмкин.

### *Каңга (рәсми Кочергановка, Ново Кочерга) авылы зираты*

Зират озын булып сузылып бара, уртасыннан юл белән бүленә. Юлның (барганда) сул ягында каберләр урнашкан мәйдан таррак, уң ягында киңрәк. Бу зираттагы ташбилгеләр яңалар, аларның эпитафик текстлары тагын да кызыклырак, чөнки анда Пенза, Рязань ягы татарлары фамилияләре күп очрый.

***1 нче ташбилге.***

«**Бадамшин** Рашит Рафик улы. 1955–2010».

Искәрмә: кара мәрмәрдән эшләнгән ташбилге. Йөзлегендә ярымай һәм мәрхүмнең портреты урнаштырылган.

***2 нче ташбилге.***

«**Бадамшина** Фирдаускай Константиновна. Туды 1958 (елда), вафат булды 1998 (елда)».

Искәрмә: кара мәрмәрдән эшләнгән ташбилге. Йөзлектә ярымай һәм мәрхүмнең сурәтләре урнаштырылган. Агач баш казыгы бар.

***3 нче ташбилге.***

«**Бадамшина** Ензиря Шамшетдин кызы.
тудэ 1.01.1924
вафат булдэ 26.01.2003».

Искәрмә: йөзлектә ярымай һәм мәрхүмнең портреты урнаштырылган. Агач баш казыгы бар.

***4 нчеташбилге.***

«**Бадамшин** Константин Яковлевич
тудэ 5.05.1925
вафат булдэ 30.04.2006».

Искәрмә: ташбилге кара мәрмәр плитәдән эшләнгән, йөзлегенә ярымай, аерым йолдыз һәм мәрхүмнең сурәте төшерелгән. Агач баш казыгы куелган.

Портреттан күренгәнчә бу зат гаскәри булып, үзенең мулла кушкан исемнәрен бөтенләй онытканга ошый.

***5 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Горелова Гузяльхан Ибрагим кызы
туды 2.04.1929
вафат булды 21.11.2012.
Рухы шат булсын».

Искәрмә: ташбилгенең очына (тимпанга) ярымай һәм аннан түбәнрәк портреты төшерелгән.

***6 нчы ташбилге.***

«Курмакаева Әминә Хәйрулла кызы
туды 1903
вафат булды 30.VIII.1989».

Искәрмә: ташбилгенең тимпанында ярымай сурәте бар.

***7 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Ишеева Гафира Каюм кызы
туды 15.VI.1925
вафат булды 8.X.2003.
Рухы шат булсын».

Искәрмә: тимпанда ярымай сурәте ясалган. Ташбилге аксыл мәрмәр ватыкларыннан коеп эшләнгән.

***8 нче ташбилге.***

«Мархум
Равиль Һидиятулла улы Ишеев

туды 8 март 1935 елда
вафат булды 25 апрельдә 2003 елда».

Искәрмә: ташбилгенең тимпанына ярымай сурәте төшерелгән. Һәйкәл үзе мәрмәр ватыкларыннан коелган.

***9 нчы ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Алюшев Марат Фахретдин улы
1939. 10.III–2002.19.VII».

Искәрмә: ташбилгенең тимпанына ярымай сурәте төшерелгән. Һәйкәл үзе мәрмәрдән эшләнгән.

***10 нчы ташбилге.***

«Такташева Гульферде Хайбула кызы
туды 1914.10.VI
в-т б-ды 2004.2.X.
Рухы шат булсын».

Искәрмә: тимпанга ярымай сурәте төшерелгән.

***11 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Мархум Такташев Усман Раҗаб улы
1906.24.IV–1984.03.XII
Билге куйды балалары».

Искәрмә: тимпанында ярымай сурәте төшерелгән.

***12 нче ташбилге.***

«Мустафин Хамит Хамзя улы
1969.27.X–2007.20.III».

Искәрмә: тимпанда ярымай һәм аннан түбәндә мәрхүмнең портреты урнаштырылган. Ташбилге кара мәрмәрдән эшләнгән.

***13 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Алкина Халися Вильдан кызы
туды 1935.8.V
в-т б-ды 2011.13.XII».

Искәрмә: ташбилге мәрмәр ватыкларыннан коелган, тимпанында ярымай сурәте ясалган.

***14 нче ташбилге.***

«Измаилов Шамил Гемран улы
т-ды 1936.27.07.
в-т б-ды 2012.07.03».

Искәрмә: ташбилге кара мәрмәрдән эшләнгән, тимпанына ярымай сурәте төшерелгән.

***15 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Мулеев Хайрулла Гатаулла улы
т-ды 1909
в-т б-ды 1996
Рухы шат булсын».

Искәрмә: тимпанына ярымай сурәте ясалган.

***16 нчы ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Мулеева Фокигя Гатаулла кызы
1910–1994».

Искәрмә: тимпанына ярымай сурәте ясалган.

***17 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Туктаров Сафар Растям улы
1975–2005
Сафару от мамы и братьев».

Искәрмә: ташбилгенең тимпанына ярымай сурәте һәм аннан астарак мәрхүмнең портреты урнаштырылган.

***18 нче ташбилге.***

«Кандидат биологических наук Абляев Муниф Мингажетдинович
1928–1973»

***19 нчы ташбилге.***

«Карапаева Гульбибя Мухамадрахимовна
1929–1993»

***20 нче ташбилге.***

«Карапаева Хуршитбану Кадыровна
1965–1985».

Искәрмә: ташбилгенең тимпанына ярымай сурәте ясалган.

***21 нче ташбилге.***

«Абушаев Ахмади Сафа углы
1912–1972».

Искәрмә: ташбилге тимпанында ярымай сурәте бар.

***№ 22 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Агишев Рафкат Шакир улы
1940–2011».

Искәрмә: ташбилге тимпанына ярымай сурәте ясалган.

***23 нче ташбилге.***

«Акчурина Раиса Халиловна
1927–1988».

Искәрмә: ташбилге тимпанында ярымай сурәте һәм аннан түбәндәрәк мәрхүмнең портреты бирелгән.

Канга авылындагы җирле совет администрациясе рәисе Рамил Каһарманов мәгълүматларына караганда, авыл халкы Казан һәм Касыйм якларыннан күчеп килүчеләрнең нәселләрен тәшкил итә. Бу авылга 1920 нче елларда Һади Такташ килгәнлекне дә сөйлиләр, монда аның туганнары яшәгән. Шагыйрь бу авылда кемнәр беләндер фоторәсемгә дә төшкән булган, фотоның табылу өмете юк түгел. Р. Каһармановның авыл тарихы буенча әйткән сүзләренә, зират ташбилгеләрендә сакланган Абушаев, Абляев, Агишев, Акчурин, Алкина, Алюшев, Бадамшин, Горелова, Измайлов, Ишеев, Карапаева, Курмакаева, Мустафин, Такташев, Туктаров кебек фамилияләрнең булуы да дәлил булып тора.

### *Майлы Күл (Яксатово) авылы зираты*

2013 елның 16 июнендә археографик экспедициянең эшчәнлеген Майлы Күл авылында башлап җибәрдек.

Авылның зираты бу яктагы татар авылларыныкыннан шактый кечерәк. Ләкин анда бер тарихи кабер – Хыдыр (Хызыр) баба ка-

бере мәгълүм икән. Ул кабергә халыкның ихтирамын искә алып, аны 2007 елда җәмәгатьчелек көче белән тәртипкә китергәннәр. Үлчәме 6,1×6,8 м төрбә-йортка өстәп, 3,0× 6,1 м зурлыкта веранда эшләнгән. Төрбә территориясе 19× 18 м зурлыктагы мәйданны били.



Хыдыр баба кабере янында. М. Әхмәтҗанов белән озатып йөрүче Рәшит Мохтаров (1954). Майлы Күл (Яксатово) авылы

Татарстанда Яңа Бистә зиратындагы Габдулла Тукай каберенә дә мондый хөрмәт күрсәтелмәгән. Хәтта ки бөек шагыйребез һәм галимебез Габдерәхим Утыз Имәни хатирәсе дә болай зурланмый.

Андагы йөзләгән каберләр арасыннан кайбер үрнәкләргә тукталып үтик.

***1 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Бабаев Зәкрья
Касыйм улы
вафат булды 2005 ел 6.IX
Алланың рәхмәтендә булсын».

Искәрмә: кабер өстендә баш казыклары ясалып куелган (агач һәм металлдан), мәрмәр ватыкларыннан коелган ташбилге эшләнгән. Чардуганнары рәшәткәдән эшләнгән.

***2 нче ташбилге.***

«Һазә мәркаде мәрхүм
Фәхретдин
Максуд хаҗи
углы дарел-фана-
дин дарел-бакайа
рихләт әйләде 1921
нче йылда шәүвәл
аеның 15ндә
сишәмбе көн».

Искәрмә: ташбилгенең үлчәмнәре – 25×36×70 см. Текст ташбилгенең йөзлегенә уеп язылган. Ул тулаем тәгъликъ ысулында татарча һәм бер юлы гына гарәп телендә язылган.

***3 нче ташбилге.***

«Әл-мәрхүм әл мәгъфүр
Габдессаттар
хаҗи Гайсә углы
4 нче рамазанда
дүшәнбе көн
вафат 43 йәшендә
милади 1919».

Искәрмә: ташбилге известьташтан эшләнгән, язмалар аның йөзлегенә тәгъликъ ысулында татар телендә язылганнар. Кырларында дога үрнәкләре бирелгән. Ташбилгенең үлчәмнәре – 17×37×68 см. Очында 4×4×6 см зурлыкта, «җан кошы» өчен су эчү урыны бар. Бу гадәт борынгы чорларда Татарстанда да киң таралып, Әстерханда ул фәкать Майлы Күл авылы ташбилгеләрендә генә очрады. Әлеге ташбилгенең арткы стенасына тәгъликъ ысулында *«Йазды Мөхәммәд-Хәсән»* дигән имза теркәлгән. Стенасындагы «...рәсүл Аллаһ» сүзе сакланган.

***4 нче т ашбилге.***

«Хаҗел харәмин
Гайсә Гомәр углы
1925 нче йылда
80 йәшендә
кабергә дәфен кылынды
гаффар... Аллаһ».

Искәрмә: ташбилгенең үлчәмнәре – 12×34×100 см.

Майлы Күл авылы зираты тимер сетка белән уратып алынган. Сеткалар тимер баганаларга эретеп ябыштырылганнар. Зиратта агач баганалардан һәм тимер трубалардан эшләнгән баш казыклары күп күренә.

### *Ярлы Түбә авылы зиратында табылган тарихи мәгълүматлар*

Без анда 2013 елның 14 июнь көнендә булып, зиратның тарихи һәйкәлләрен өйрәндек. Авылның музеенда булдык, эшчән, тырыш халкы вәкилләре, күренекле кешеләре белән очрашып аралаш-

тык. Бу эшләрне оештыруда Әстерхандагы татарларның «Дуслык» җәмгыяте рәисе Наилә ханым Потеева-Фатыйхова зур тырышлык күрсәтте.

Соңыннан мин үзем татар мәдәниятенең традицияләре сакланган зиратта булдым.

Зиратның уртасындагы үзенчәлекле төрбә игътибарны үзенә тартты. Аның үзенчәлекле архитектурасы, кабатланмас бизәкләре халкыбызның борынгыдан килгән гүзәл мәдәниятенең бер чагылышы булып тора иде.

Төрбәнең буе – 7,15 м, иңе – 5,2 м, биеклеге – 3,5 м чамасы. Безгә анда күмелгән әүлиянең исеме билгесез дигәннәр иде, ләкин Әстерхан укымышлысы Зөлхәбирә ханым китабыннан, анда күмелгән әүлиянең Кендек баба газиз дип йөртелгәне мәгълүм булды.

Ярлы Түбәнең зират ташбилгеләре авыл тарихының ышанычлы чыганаклары булып торалар. Дөресен әйткәндә, Әстерханда татар зиратлары белән танышканда аның халкының коточкыч кырыла баруына йөрәк янды. Монда хәзер борынгы каберләр күренми диярлгә була, мәрхүмнәрнең абсолют күпчелеге XX гасырның икенче яртысында туган адәм балалары. Әстерхан ташбилгеләреннән аңлашылганча, андагы фамилияләр ерак һәм якын тарихлар күрсәткече булып торалар.

***1 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Хәйруллин Ильмат Марат улы
вафат булды 2.II.2005».

Искәрмә: ташбилгенең тимпанындагы кәлимәләр гарәп язуында башкарылган. Тимпанда иң өстә ярымай силуэты төшерелгән. Ташбилгедәге язмалар уеп һәм язманың эзләре буенча буяп, укырлык хәлгә җиткерелгән. Ташбилгенең үлчәмнәре – 6,5х50х100 см, ул чардуганның тышкы ягында, ташбасма өстенә утыртылган, баш казыклары юк.

***2 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Хәйруллин Дамир Ильмат улы
Вафат булды – 10.01.2009».

Искәрмә: ташбилгенең тимпанында Коръәннән бер аять китерелгән, ул гарәп хәрефләре белән уеп язылган. Тимпанда дога өстендә ярымай

силуэты да бар. Ташбилгенең үлчәмнәре – 6,5×50×100 см, ул чардуганның тышкы ягында дүрткырлы ташбасмага бастырылып куелган, баш казыклары юк.

***3 нче ташбилге.***

«Бисмилла әр-рахман әр-рәхим
Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Ишмухамедов Анварбек Хисматулла
улы. Вафат булды 26.XII.1994.
От жены».

Искәрмә: тимпандагы Коръән аяте гарәп хәрефләрендә башкарылган. Ташка уеп язылган. Мәрмәр ватыкларыннан хәзерге коелган ташбилге, үлчәмнәре – 14×49×120 см. Тимпанда ярымай силуэты төшерелгән.

Ташбилге чардуганның тышында тора, баш казыклары юк.

***4 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
әл-мәрхүм
Ибраһим Хөсәйен
углы Акъҗигитов
туган 1921 нче йылда
вафат 1973 нче йылда
2 нче дикәбердә
Алланың рәхмәтендә булсын».

Искәрмә: ташбилге тулысынча татарның тәгъликъ ысулында язылган, үлчәмнәре – 10×40×65 см, металл табагыннан кисеп, ябыштырып, өске өлешенең бер почмагын биек, икенче почмагын тәбәнәк итеп, байрак рәвешендә эшләнгән һәйкәл. Аның өстәге тимпан ягы киңрәк (65 см), аскы нигез ягы таррак (40 см), биеклеге 65 см, калынлыгы 10 см итеп, пластинканы бөгеп куеп эшләнгән. Тимпанның уң яктагы очына ай-йолдыз композициясе төшерелгән. Ташбилге чардуганның тышкы ягында, баш казыклары да юк.

***5 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
мархума
Сягдят
Якубовна
туган 29.XII.1939
вафат 7.IX.1998».

Искәрмә: тимпанда иң өстә ярымай сурәте төшерелгән. Аннан астарак портрет урыны контурлары билгеләнгән. Портрет астында гарәп имлясындагы дога урнаштырылган. Дога һәм эпитафик текстлар ак мәрмәр плитәгә язылып, мәрмәр ватыкларыннан коеп эшләнгән ташбилге йөзлегенә урнаштырылган. Ташбилге чардуган эчендә мәрхүмнең баш очына куелган. Баш казыклары юк.

***6 нчы ташбилге.***

«Бисмилла әр-рахман әр-рәхим
әл мәрхүм
Зиннур Мохтәр
углы Каралашев
туган 1891 йылда
1967 йылда үктәбер
22 ндә вафат
Каралашев Зиннур».

Искәрмә: эпитафик текст тәгъликъ ысулында бирелеп, соңгы юл гына кирилл язуында эшләнгән.

Ташбилгенең тимпанында ай-йолдыз композициясе ясалган. Текст уеп язылган һәм кара төскә буялган. Ташбилге җирле останың хезмәте буларак таныла, ул чардуган эченә урнаштырылган, баш казыклары юк.

***7 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Нугаев
Рашид
Гали улы
1.1.1939–5.VIII.1994».

Искәрмә: ташбилге зәңгәрсу төстәге дүртпочмаклап эшләнгән мәрмәр плитәдән гыйбарәт булып, аңа кирилл алфавитында татар телендә язылган. Ул чардуганның тышкы ягында мәрхүмнең баш очында ике баскычлы таш мәрмәр басмада тора. Тимпанда ярымай сурәте һәм гарәп язуындагы Коръән кәлимәсе китерелгән. Баш казыклары куелмаган.

***8 нче ташбилге.***

«Бисмилла әр-рахман әр-рәхим
Нугаев
Сагид
Гали улы
1942.2.IV–2011.4.III».

Искәрмә: ташбилгенең тимпанына ярымай силуэты уеп ясалган. Куелган истәлек үзенең төзелеше белән башкалардан аерылып тора. Баш казыклары куелмаган.

***9 нчы ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Бикмаев
Аделша
Махмуд улы
1927.12.IV–2012.5.XII».

Искәрмә: ташбилгенең тимпанына ярымай силуэты төшерелгән. Коръән кәлимәсе гарәп әлифендә бирелә, калган текст кирилл графикасында. Ташбилге чардуганның тышкы ягына урнаштырылган, баш казыклары куелмаган.

***10 нчы ташбилге.***

«Курмаев
Ильхам
Умерович
туган жылы
1942.12.II.
Вопат болды
15.X.2008».

Искәрмә: дүрткырлы итеп мәрмәрдән эшләнгән ташбилге. Тампанына ай-йолдыз композициясе ясалган, эпитафия язмасы телендә нугай фонетик эзләре күренә. Ташбилге чардуган эчендәге мәрмәр басмада утыра, баш казыклары юк.

***11 нче ташбилге.***

«Бисмилла әр-рахман әр-рәхим
әл-мәрхүм
Мөхәммәд-Кәрим
Алим углы
Кантимуллин
Уз авылы Пинза ублысты
туган 1885 йылда 13 нче үктәбердә
вафат булды 1966 нчы
йылда 23 синтәбердә

---

Кантимулин
Карим
Алимович
13.X.1885–23. IX.1966».

Искәрмә: ташбилге кара мәрмәр ташка, уеп, алтын төсендәге, татар тәгъликъ ысулындагы әлифтә язылган, соңыннан кирилл әлифендә русча да исем-фамилиясе теркәлгән. Эпитафик истәлекнең тимпанында уелма ярымай-йолдыз композициясе урнаштырылган. Ташбилге чардуган эчендә мәрхүмнең баш очына куелган. Баш казыклары юк.

Ярлы Түбә зиратында мондый затлы, бай эчтәлекле эпитафик язмалар сирәк.

***12 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи ражигун
мәрхүмә
Газизә
Әхмәджан кызы
Тинчурина

---

Тенчурина
Азизя
Ахмеджановна
1900 $\frac{23}{XII}$ –1973 $\frac{8}{VIII}$»

Искәрмә: ташбилге кара, шомартылган мәрмәр плитәдән эшләнгән. Үлчәмнәре – 8×48×95 см, ул чардуган эчендә, мәрхүмнең баш очына утыртылган. Тимпанга, уеп, алтын төсендәге ай-йолдыз композициясе төшерелгән. Коръән аяте һәм татарча текст тәгъликъ ысулында, алтын төсендә язылган. Аннан түбәндә текст рус телендә бирелә. Баш казыклары юк.

***13 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи ражигун
мәрхүм
Сәлахетдин Гали углы
Тинчурин

---

Тенчурин
Салах
Алиевич

1894 $\frac{3}{V}$ – 1973 $\frac{13}{V}$».

Искәрмә: ташбилге кара төстәге, шомартылган мәрмәр таштан эшләнгән, чардуган эчендә, мәрхүмнең баш очына утыртылган. Кабер өстенә баш казыклары куелмаган. Ташбилгенең тимпанында, уеп, алтын төсендә ай-йолдыз композициясе эшләнгән. Коръән аяте һәм татарча текст тәгъликъ ысулындагы әлифтә язылган.

Мәрхүмнең исем-фамилиясе аска уеп, алтын төсендәге хәрефләр белән рус телендә язылган.

***14 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Мәрхүм
Сәлахетдин Гали углы
Равил
Тинчурин

---

Тенчурин
Равиль
Салахович
1927 $\frac{29}{I}$ –1994 $\frac{29}{XI}$ ».

Искәрмә: ташбилге кара төстәге, шомартылган мәрмәр таштан эшләнгән, чардуган эчендә, мәрхүмнең баш очына утыртылган. Кабер өстенә баш казыклары куелмаган. Тимпанына, уеп, алтын төсенә буяп, ай-йолдыз композициясе төшерелгән. Коръән аяте һәм татарча текстлар тәгъликъ ысулында язылганнар.

***15 нче ташбилге.***

«Акчурин Касьян Касьянович
1920 $\frac{20}{I}$ –1968 $\frac{2}{V}$ ».

Искәрмә: эпитафик текст 20×30 см зурлыктагы плитәгә рус телендә генә язылып, металлдан эшләнгән ромб рәвешендәге стендка шөрепләр белән ныгытылып куелган. Ташбилге чардуган эчендә тора, баш казыклары юк.

***16 нчы ташбилге.***

«Бисмилла әр-рахман әр-рахим
мәрхүмә

Биби [хан]
Хәбибулла кызы
вафат булды
31.V.1972 йылда
79 йәшендә
―――――
Дасаева».

Искәрмә: ташбилге вак һөнәрчелек мастерскоенда эшләнгән, тексты татар телендә тәгъликъ ысулында язылган. Тимпанда ай-йолдыз композициясе бирелә. Ташбилгенең сул ягында, кысалар эчендә русча стильдә, басма хәрефләр белән мәрхүмнең фамилиясе теркәлгән. Һәйкәл өч катлы басмада, чардуган тышында, мәрхүмнең баш очында тора.

Моннан тыш, чардуган аратасындагы 20×30 см үлчәмле плитәгә русча язылган әүвәлге текст та сакланган.

***17 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Мамлеева Сагадат
Г... кызы
1930....II.–1991....II».

Искәрмә: ташбилге мәрмәр ватыкларыннан коеп, традицион формада эшләнгән. Чардуганның эчендә, мәрхүмнең баш очына ике катлы басмада утыртылган. Баш казыклары юк.

Тимпанга ярымай силуэты уеп төшерелгән. Аның астына тәгъликъ ысулында гарәпчә Коръән аяте язылган.

***18 нче ташбилге.***

«Бирдиева
Райса
Гиният кызы
тудә 12.X.1929
вафат булдә 23.XII.1975
Кызларыннан».

Искәрмә: ташбилге мәрмәр ватыкларыннан традицион стильдә коелган. Тимпанга ярымай силуэты уеп ясалган.

Эпитафик текст ак мәрмәр плитәгә язылып, ташбилгенең йөзлегенә беркетелгән, ул кирилл әлифендә, җирле фонетик сөйләш үзенчәлекләрен саклап язылган. Ташбилге чардуган тышында, бер катлы басма өстенә куелган.

***19 нчы ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Абаева
Зухра
Хусаин кызы
1919.18.I–1999.3.I».

Искәрмә: ташбилге мәрмәр ватыкларыннан традицион формада коелган. Тимпанга ярымай сурәте төшерелгән һәм тәгъликъ ысулында Коръән аяте язылган. Текст ак мәрмәрдән ясалган плитәгә язылып, ташбилгенең йөзлегенә беркетелгән. Ташбилге чардуган эчендә, бер катлы басма өстендә, мәрхүмнең баш очында тора, баш казыклары юк.

Әлеге зиратта Касыйм һәм Пенза якларыннан килеп вафат булган кешеләрнең каберләре күп күренә. Бу зират бик зур һәм кабер ташларының күплеге белән аерылып тора. Андагы ташбилгеләрдә традицион татар фамилияләре – Акчуриннар, Хәйруллиннар, Тинчуриннар, Мәмлиевләр, Ишмөхәммәтевләр, Абаевлар, Акҗегетовлар, Инакиева (Еникиева) һ.б. сакланалар.

Бу мәгълүматлар бүгенге Әстерхан татарларының борынгы бабалары кемнәр булуын дәлиллиләр.

## *Җәмәле (Три Протока) авылы зираты*

Җәмәле авылында мәет озату процессы белән танышырга туры килде. Ул көнне анда 84 яшенә җитеп үлгән укытучы ханымны соңгы юлга озаттылар.

Берничә йөзләп кеше җыелган. Килүчеләр барысы да ир затыннан, башларында кәләпүшләр.

Менә мәетне өйдән ишек алдына алып чыгып куйдылар, җеназалар укып җеназа тактасын (яшел табут) күтәреп капкага таба аяк атлауга, йорт эчендә һәм ишек төбендәге хатын-кызлар кычкырып елый башладылар.

Җеназаны күтәреп баручылар, аны югары тотып ашыга-ашыга җәяүләп машиналарга таба киттеләр. Зират авылдан шактый ерак, тау битендә икән. Анда юл ике чакрым чамасы булыр. Зират капкасына җиткәч ирләр җеназаны югары күтәреп тауга күтәрелделәр. Монда мин хатын-кыз күрмәдем. Мәетне кабергә индерүдә, Татарстандагыга караганда, беркадәр аерымлыклар бар иде, аларга тәфсилләп тукталмыйм инде.

Зират эчендә калкулык буенча эчкәрәк күтәрелә башладым. Монда да, башка Әстерхан авылларындагы шикелле, арматурадан ясалган, буяп эшләнгән бизәкле чардуганнар, биек баш казыклары тезмәләре күренә. Болардан соң зиратның иске өлеше башланып, анда кабер ташбилгеләре сирәк күренә. Еракта бер әүлиянең агачтан эшләнгән төрбәсе бар.



«Бикәш әүлия» төрбәсе күренеше. Җәмәле авылы зираты

Күренгән ташбилгеләрнең күбесе җимерек, язулары начар сакланышлы, булган эпитафик текстлар XIX йөз ахырына һәм XX гасыр башына карыйлар. Үземне озатып йөрүчеләр белән төрбә янына килеп җиттек. Ул агачтан эшләнгән, мәйданыы 5,2×6,6 м, биеклеге 2,05 м. Түбәсе юк, моннан берничә ел элек зиратта коры үләннәргә ут кабып, шул чакта төрбә дә яна башлаган булган, аны сүндергәннәр, шуннан бирле төрбә түбәсез тора икән. Әлеге төрбәдә җирле халык телендә «Бикәш» һәм «Баксаис» әүлияләр күмелгән дип сөйлиләр. Киләчедә яшәүче Зөлхәбирә Ишбирде-Урусованың китабында алар «Бикәч әүлия» һәм «Каракаш ханым-әүлия» дип аталганнар[1]. Җәмәленең аргы (4 нче һәм 5 нче түбәләрендә дә изгеләр каберләре булып, информантлар аларның исемнәрен белмибез дип әйттеләр. Зөлхәбирә ханым язмаларында аларның «Галиханым әүлия» һәм «Бакчаяз газиз» икәнлекләре язылган[2].

***1 нче ташбилге.***

«Әл-мәркаде Һазә

Әлмәрхүм Әбүбәкер морза бине Гали морза гаффар (кичерүче. – *М.Ә.*) Аллаһа мәтүфи

1906 сәнәтә ....фи Бәхтийар (?) Җ.... 78 .......».

Искәрмә: Әбүбәкер морза 1906 елны 78 (?) яшендә вафат булган. Таш җиргә авып төшкән, язуның бер өлеше юкка чыккан. Ташбилге известьташтан эшләнгән булган, язмалар күпертеп, татар тәгъликы ысулында

[1] Зөлхәбирә Ишбирде-Урусова. Нәселем эзләреннән. Әстерхан, 2005. 109 б.

[2] Шунда ук.

язылганнар. Җәмәле зиратында моны эшләгән останың тагын бер эше саклана Ул (2 нче) ташбилге ватылмаган. Аны монда укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.

***2 нче ташбилге.***

«Мәркаде Һазә
Әлмәрхүмә Биби Гөлбахар әл-хаҗи
Әбүталиб кызы вафат булды
14 йәшендә август
1907 нче йылда. Бихөкем Аллаһ».

Искәрмә: ташбилге известьташтан эшләнгән. Тимпанга ярымай силуэты төшерелгән. Хәрефләр калкытып язылган. Ул җиргә авып төшкән, урныныннан кубарылган.

***3 нче ташбилге.***

«Һазә мәркаде
Лә Илаһи иллаллаһи
Мөхәммәд рәсүл Аллаһи
Хаҗи Тархан гу-
Бирнасы Җәмил карийә-
синең Гобәйдулла
Әбүбәкер углы вафат
улды 1904 сәнәдә».

Искәрмә: бу ташбилге каллиграфик осталык һәм төгәллек белән, уеп эшләнгән. Бизәүче орнаментлары да Казан осталары эшләре белән тиңләшә. Мондый ташбилгеләр Әстерхан якларында сирәк сакланган.

***4 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Мархум Хаджаева Гафифя Мингаж кызы, туды 22.08.1929. вафат булды 15.01.2011.
Кабере нурлы булсын, Амин!»

Искәрмә: текст ак мәрмәр плитәгә уеп язылган һәм мәрмәр ватыкларыннан эшләнгән ташбилгенең йөзлегенә беркетелгән. Ташбилге ике баскычлы басма өстендә тора. Тимпанга ярымай силуэты ясалган.

***5 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Туктаров Равиль Маннаф улы
туды: 1944.3.IX, вафат булды: 2011.6.02».

Искәрмә: мәрмәр плитәгә текстны язып, мәрмәр ватыкларыннан эшләнгән ташбилгенең йөзлегенә беркеткәннәр. Тимпанга ярымай силуэты төшерелгән. Ташбилге ике катлы басма өстендә тора.

***6 нчы ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи ражигун
Хаджаева
Гафифя
Мингаж кызы
туды 22.08.1929
вафат булды
15.01.2011.
Кабере нурлы
булсын Амин».

Искәрмә: ташбилге мәрмәр ватыкларыннан коеп ясалган, торышы борынгы һәйкәлләр кебек, тимпанында – ярымай, ул уеп ясалган. Коръән аяте тәгъликъ ысулында язылып, ташбилге йөзлегенә, ярымай астына урнаштырылган.

Төп эпитафик текст ак плитәгә кирилл алфавитында язылып, койган вакытта ук ташбилгенең йөзлегенә ябыштырып куелган. Ташбилге чардуганның тышында, мәрхүмнең баш очына куелган. Чардуган эчендә бүрәнәдән ясалган очлы башлы баш казыгы да утыртылган.

***7 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи ражигун
Туктаров
Равиль
Маннаф улы
туды 1944.3.IX
вафат булды 2011.6.II».

Искәрмә: ташбилге мәрмәр ватыкларыннан коеп ясалган, ак мәрмәр плитәгә ярымай эшләнгән, эпитафик текст һәм Коръән аяте тәгъликъ ысулында язылган. Калган текст кирилл әлифендә теркәлгән.

Ташбилге такта рәшәткәдән ясалган чардуган тышында ике катлы басма өстенә урнаштырылган. Чардуган эчендә агачтан эшләнгән баш казыгы утыртылган, аның бер ягына шулай ук эпитафик текст язылган.

***8 нче ташбилге.***

«Бисмил-ләэһир
рахмәнир-рахиим

Туктаров
Халиль
Халит углы
туды 1961 $\frac{30}{X}$
вафат булды 2007 $\frac{24}{V}$
Кабере нурлы
булсын
урыны җәннәттә
булсын».

Искәрмә: ташбилге мәрмәрдән традицион арка стилендә эшләнгән. Тимпанга ярымай силуэты уелган. Эпитафик язмалар барысы да кирилл әлифендә башкарылган. Ташбилге чардуганның тышында, мәрхүмнең баш очында ике катлы басма өстенә утыртылган. Чардуган такта рәшәткәләрдән эшләнеп, зәңгәр төскә буялган. Чардуган эчендә баш казыгы күренә.

***9 нчы ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Арстанова
Фируза
Рауф кызы
тудә 1931.27.VI
вафат булды 2007.19.XII.
Рухы шат булсын».

Искәрмә: ташбилге мәрмәр ватыкларыннан традицион арка стилендә коелган. Тимпанда ярымай силуэты бирелгән. Аның астына ташбилге йөзлегенә тәгъликъ ысулында Коръән аяте язылган. Төп эпитафик текст ак мәрмәр пластинкага кирилл әлифендә язылып, ташбилгенең йөзлегенә беркетелгән. Ташбилге агач рәшәткәле чардуган тышында, мәрхүмнең баш очында ике баскычлы басмага утыртылган. Чардуган эченә бүрәнәдән эшләнгән баш казыгы утыртылган.

***10 нчы ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Сагаитдин кызы
Амина
Калиева
туды 01.07.1919
вафат булды 10.01.2013

Кабере нурлы булсын
Амин».

Искәрмә: ташбилге шомартылган кара мәрмәрдән эшләнгән. Тимпанына ярымай сурәте уелган. Ай астына тәгъликъ ысулында Коръән аяте язылган.

Калган текст кирилл әлифендә. Ул уеп язылган һәм ак төскә буялган. Ташбилге ике баскычлы басма өстенә, агач рәшәткәле чардуганның тышкы ягына, мәрхүмнең баш очына утыртылган.

Чардуган эчендә тактага язылган эпитафик текст беркетелгән баш казыгы күренә.

***11 нче ташбилге.***

«Мархом
Аханым
Мустафа кызы
туган жылы 1922
вафат булды 1999.5.XII
руе Жайек бериш
белги койган
кызы Көнслу».

Искәрмә: ташбилге татарның традицион аркалы ядкаренә охшаган. Тимпан астына ярымай силуэты уелган. Калган язмалар кирилл әлифендә язылганнар. Ташбилге чардуган тышында, мәрхүмнең баш очына куелган, ул мәрмәр ватыкларыннан ясалган.

***12 нче ташбилге.***

«Кадырбердиев
Корбангали
Гумар углы
1931.18.IV–2006.30.X
Алланың рахмәтендә
булсын Амин».

Искәрмә: ак мәрмәр ватыкларыннан коеп традицион арка стилендә эшләнгән ташбилге, бер кат басма өстенә, агач рәшәткәле чардуган тышына утыртылган. Тимпанда ай сурәте уеп ясалган.

***13 нче ташбилге.***

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
Исамулла улы

Мухамедгали
Калиев
туды 09.05.1919
вафат булды 25.05.2010
Кабере нурлы булсын
Амин».

Искәрмә: ташбилге кара тоташ мәрмәрдән турыпочмаклык формасында ясалган. Тимпанына, уеп, ярымай сурәте төшерелгән. Аның астына тәгъликъ ысулында Коръән аяте язылган. Калган текст материалы кирилл әлифендә уелып, ак төскә буялган. Ташбилге ике баскычлы (ак, кара) басмага бастырылган, агач рәшәткәләрдән ясалган чардуганның тышкы ягына, мәрхүмнең баш очына утыртылган.

***14 нче ташбилге.***

«Мулляминов
Абубакер
Абдулла улы
туды 1933
вафат булды 2009.10.XI
Кәберендә нур булсын».

Искәрмә: ташбилге традицион арка стилендә эшләнеп, тимпанына ярымай сурәте уелган. Эпитафик текст ак плитәгә уеп язылган һәм ташбилгенең йөзлегенә ныгытылган. Ул агач рәшәткәдән ясалган чардуганның тышкы ягына, мәрхүмнең баш очына, ике катлы басма өстенә утыртылган.

## Йомгак

Әстерхан өлкәсенең Идел буе төбәгендәге татар авылларының зиратлары фәнни күзлектән 2013 елда беренче тапкыр өйрәнелде. Әлбәттә, бу эш тәмам төгәлләнде, дип әйтеп булмый әле. Ләкин шунысы ачык, мондагы татар зиратлары гомум милли традицияләрне (аеруча тел өлкәсендә) тырышып саклыйлар, ташбилгеләрдә татар теле өстенлек итә.

Зиратларда ташбилгеләр бик күп, гаҗәпкә калырлык. Алардан күренгәнчә, Әстерхан татарларының күбесе 40–50 яшькә дә җитми кара җир астына керәләр икән. Димәк, Түбән Иделдә экологик катастрофа хакимлек итә. Шул ук вакытта Төньяк Кавказ халкы арта, алар инде Әстерхан каласына да Дагыстанның бер районы итеп карыйлар.

# ӘСТЕРХАН СӨЙЛӘШЕНЕҢ ЮРТ УРЫНЧЫЛЫГЫ

*Дария Рамазанова*

Әстерхан сөйләше дигәндә Идел елгасының түбән агымында, нигездә, Әстерхан шәһәре һәм аның тирә-ягында таралган татар авылларының сөйләше күздә тотыла. Бу тасвирлама Әстерхан өлкәсенең Идел буе районы Җәмәле (Три Протока), Кызан (Татар Башмаковка), Каргалык (Карагали), Ярлы Түбә (Осыпной Бугор), Майлы күл (Яксатово), Киләче (Килинчи) авылларында тупланган материалларга нигезләнеп языла. Әлеге авыллар төрле өлкәләрдән (аеруча Югары һәм Урта Идел бассейнына караган өлкәләр күздә тотыла) төрле юллар (ирекле күчеп утыру, патша хөкүмәте карарлары нигезендә килеп урнашу һ.б.) белән барлыкка килгәннәр.

Тик шунысын ассызыклап күрсәтергә кирәк, Түбән Идел буенда элек-электән төркиләр яшәгән һәм Алтын Урда җимерелгәндә шушы тирәдәге төрки халык нигезендә Әстерхан ханлыгы оешкан да. Алар – Әстерхан сөйләшенең нигезен тәшкил итә торган юрт урынчылыгы вәкилләренең бабалары. Рус чыганакларыннан, галимнәрнең хезмәтләреннән аңлашылганча, тарих дәвамында аларны төрлечә атау очраклары булган. Юрт татарлары үзләрен татар дип саныйлар. Соңгы еллардагы милли хәрәкәтнең тәэсире аларга да кагыла һәм аларны нугайлар дип атау да күзәтелә. Ләкин юрт татарларын татар дип атау ешрак күзәтелә һәм аларны хәзерге этник нугайлар белән кушып карау дөреслеккә туры килеп бетми.

Л.Ш. Арсланов, юрт татарларының бабалары Көнбатыш Казакъстан далаларында да күчеп йөргәннәр һәм нугай дип аталмаганнар, дип яза. Автор күрсәтүенчә, «нугай», «ногайская орда» атамалары XIX йөзнең 20 нче елларында барлыкка килгән (Л.Ш. Арсланов. О взаимодействии языков карагашей и юртовских татар

(ногайцев) с казахским языком // Советская тюркология. 1986, № 5. с. 11). Л.Ш. Арсланов үзенең русча язылган хезмәтләрендә «юртовские татары (ногайцы)» дигән тезмә атама куллана.

Минемчә, юрт татарларын Әстерхан ханлыгына берләшкән төп кабиләнең дәвамчылары итеп күздә тотарга кирәк. Тел материаллары да шуны раслый: юрт татарларында, казан татарларындагы кебек, сузыкларның Идел – Урал яңгырашы яши; төп фигыль формалары ягыннан татар әдәби теле белән уртаклык көчле чагыла; лексика өлкәсендәге үзенчәлекләрдә уртак географик һәм климатик шартлар белән бәйлелек күзәтелә һ.б.

Кыскасы, әстерхан сөйләшенең юрт урынчылыгы вәкилләре катлаулы тарихи формалашу юлы үткәннәр. Юрт урынчылыгындагы гореф-гадәтләр, матур җирле йолалар, көньяктагы далада тырыш хезмәт белән тормыш алып бара торган мөлаем, ачык йөзле халык бездә һәрьяклап уңай тәэсир калдырды. Аларның тормыш-көнкүрешендә җирле сәнгать үрнәкләре, бай рухи чагылышлар аеруча зур кызыксыну уятты.

Юрт урынчылыгы әстерхан сөйләшендә үзәк урынны тота. Бу урынчылык күчеп килгән татарларның тормышына, сөйләшенә зур йогынты ясаган. Үзенчәлекле җирле йолалар, уртак географик шартларда тормыш алып бару һ.б. юрт татарлары белән күчеп килгән татарларның сөйләшендә, аларның рухи һәм матди тормышында күп кенә уртаклыклар формалашуга китергән.

*Юрт урынчылыгын өйрәнү тарихына карата берничә сүз.* Алтын Урда җимерелгәннән соң аның территориясендә барлыкка килгән ханлыкларны патша хөкүмәте әкренләп яулап ала. Рус дәүләте эшлеклеләре, административ органнар һәм төрле башка чиновниклар Әстерхан ханлыгының халкы, аларның кем булуы, килеп чыгышы, теле, дине турында язып калдырганнар. Әмма, яңа кушылган территориядәге хәл-әхвәлләрне, тарихны, тормыш-көнкүрешне начар белгәнгә күрә, бу язмаларда күп кенә буталчыклыклар, ялгышлар да шактый киткән.

Татар тел белемендә әстерхан сөйләшен төпле өйрәнүгә Л.Ш. Арсланов гаять күп көч куйган. Ул әлеге төбәктәге татар авылларын җентекләп өйрәнеп чыккан. Атлас программасы нигезендә өйрәнгәнгә күрә, галим бай материал туплый алган, Түбән Идел буе сөйләшләренең Атласын төзегән, күп санлы мәкаләләр, китаплар язган, сүзлекләр төзегән һәм аларны бастырып чыгаруга

да ирешкән. Сүз уңаенда тагын шуны да күрсәтеп үтәргә кирәк, татар халык сөйләшләренең 3 томлык атласын төзегәндә, «Татар халык сөйләшләре» исемле (2008, 2 китапта) хезмәтнең әстерхан (урта диалект) һәм волгоград (көнбатыш диалект) сөйләшләрен тасвирлаганда Л.Ш. Арсланов материаллары төп чыганак булып хезмәт итте.

Л.Ш. Арсланов та юрт урынчылыгын әстерхан сөйләшенең үзәк урынчылыгы дип саный, аларның башка урынчылыкларга йогынтысын өйрәнүгә зур урын бирә (Арсланов Л.Ш. Язык юртовских татар // материалы по татарской диалектологии. Казань, 1976; Аныкы ук: О влиянии языка юртовских татар (ногайцев) на язык татар Наримановского района Астраханской области // Вопросы татарского языкознания. Казань, 1978. 107–119 битләр һ.б.).

Әстерхан сөйләшенең гореф-гадәт, йолалары чагылышы Ф.С. Баязитова тарафыннан да өйрәнелә («Әстерхан татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш һәм йола терминологиясе». Казан, 2002; төрле басмаларда дөнья күргән күп санлы мәкаләләре). «Татар халык сөйләшләре» дигән хезмәттә дә (Казан, 2008) әлеге сөйләшне Ф.С. Баязитова тасвирлады.

Институт тарафыннан 2013 елда оештырылган комплекслы экспедиция материаллары юрт татарларының милләтебезнең бер өлеше икәнен тагын бер кабат раслады.

## Фонетик үзенчәлекләр

*Сузыклар*. Борынгылыкны үзендә нык саклап килә торган һәм формалашулары буенча Казан ханлыгы чорларыннан алда булган дип санала торган касыйм, пермь, нократ, керәшен сөйләшләрендәге кебек үк, юрт сөйләшендә дә *а* авазы ачык, иренләшү төсмере булмаган сузык итеп әйтелә. Кайбер очракларда тагын да арткырак позициядә ясалган ачык *а* авазын әйтү дә күзәтелә.

*Ә* авазының әйтелеше белән әстерхан сөйләше әдәби телдән аерылмый. Сүзнең тамырында *и, э, ө* авазлары булса, алардан соң килә торган *ә* авазы таррак вариантта (аны э дип билгелибез) әйтелә: *өстендэ* – өстендә, *җиргэ* – җиргә, *белэзек* – беләзек, *шикэр* – шикәр, *пешерэ* – пешерә һ.б. Күзәтүләргә караганда, бу борынгы күренешнең кулланылышы шактый чикле. Биредә әдәби телнең һәм Казан ягыннан һаман да өстәлә барган казан татарлары сөйләү теленең йогынтысы зур роль уйнаган булса кирәк.

Сөйләшкә хас күренешләрнең берсе – киң әйтелешле борынгы **о*, **ө* авазлары сакланып килү. Әмма бу күренеш тә сирәк күзәтелә: *орта* – әд. урта, *той* – туй, *орлый* – урлый, *ол/ул* – ул (бала), *йоқа* – юка, *өлкүн* – өлкән, *көл* – күл, *көңөл* – күңел, *бөгөн* / *бүген* // *беген* – бүген.

Хәзерге татар теленә хас *о, ө* авазларының иренләшү элементы кимегән: *то*$^{ы}$*рмыш* – тормыш, *то*$^{ы}$*лым* – толым, *бо*$^{ы}$*рыңғы* – борынгы, *кө*$^{е}$*леп* – көлеп, *сө*$^{е}$*т* – сөт. Еш кына *о, ө* авазлары иренсезләшкән вариантта күзәтелә: *бырыңғы* – борынгы, *ызын* – озын, *эстәл* – өстәл, *телке* – төлке, *кен* – көн, *бөгәт* / *бегәт* – арыктан кергән суны түтәл башында тоткарлап тора торган балчык өеме.

Сузыклар өлкәсендәге сөйләшкә хас башка үзенчәлекләр төрле аваз тәңгәллекләренә, авазларның позицион үзгәрешләренә кайтып кала:

**и ~ ә**: *тәмике* – тәмәке, *кипен* – кәфен, *тәрит җаулық* (диал. тәрәт яулык) – сөлге, *бәлин-төгән* – фәлән-төгән, *кизәнкә* (диал. *кәзәнкә*) – чолан, *җитем* < *йәтим* – ятим, *Әмил бәйрәме* (< диал. *әмәл*) – Сабан туе, *пирдә* – пәрдә, *тирәзә* – тәрәзә, *синәк* – сәнәк, *пике* – пәке (шулай ук касыйм сөйләшендә), *тигәршек* – тәгәрмәч.

**и ~ ү**: *чибәк* – чүәк,

**и ~ у**: *чиқан* – чуан, *бийақ* – бу як,

**ә ~ ө**: *кәчек* – көчек,

**е ~ и**: *печә* – бичә,

**и ~ ы**: *буси* < *бусы* – муенса,

**ы ~ у**: *йықа* – юка, *партык* – фартук, *мыйа* // *муйа* – рус. солодковый корень, *былмаған* – булмаган,

**ы ~ а**: *арғылдақ* – (< аркалык) – матча; фигыль кушымчаларында: *барғыла* – баргала, *салғыла* – куйгала; сорау кушымчасында: *барама* – барамы,

**а ~ ы**, **ә ~ е**: фигыль кушымчаларында: *қайтармыз* – кайтырбыз, *китерәрсен* – китерерсең, *булар* – булыр, *барар* – барыр һ.б. Чагыштыр: шулай ук бараба диалектында да.

**ө ~ ү**: *бөгәт* /*бүгәт*/ *бегәт* (алу) – бакчага кергән су түтәл арасына керсен өчен туфрак өеменнән 1-2 көрәк җир алып, суга юл ачу.

Башка сөйләшләрдә теркәлмәгән **о ~ а, ы** күренеше: *кәмпит* / *қомпит* (диал. канфит) – конфет, *кыйммәт* / *қомбат* / *қыйбат* – кыйбат.

Сузыклар өстәлү: **ә**: *пәрәмәчә* – пәрәмәч, *мәчә* (рус. мяч) – туп, *қуша* –куш (тигезлек белән) қартайығыз.

Сузыклар төшү: **ы**: *бармыз ды* – бырыбыз да, **а**: *машин* – машина, **е**: *ик қолағым* – ике..., *кешләр* – кешеләр.

Әстерхан сөйләшенең юрт урынчылыгында да арткы рәт сузыклары урынына алгы рәт сузыкларын һәм, киресенчә, алгы рәт сузыклары урынына арткы рәт сузыкларын куллану күренеше бар.

Мәсәлән, нечкәртү түбәндәге сүзләргә хас: *тәтле* – татлы, *әрүwем* – аруым (каенсеңелгә эндәшү сүзе), *әкиләде* – алып килә, *кәймә* – кайма, *йәүче* – яучы, *сәрек* – сары (авыру), *зәр булу* – зар булу, *әчек* – ачык, *әчек зат* – ачык кеше, *ат йәрешләре* (ярышлары), *сөргән* – сырган (*сөргән пубайқа*), *тәнә* – тана.

Кеше исемнәрендә: *Әсийә*, *Өрхийә*.

Бу күренеш алынмаларда актив: *түтник* – тут, *мәркү* (рус. морковь) – кишер, *пишәткә* – перчатка, *кәртүп* – бәрәңге, *пирүк* – пирог, *ширтә* (рус. черта) – сызыклы (уен исеме).

Калынайту: *капыста* – кәбестә, *такле* – тикле, *шал* – шәл.

Мисаллардан күренгәнчә, бу үзенчәлекне чагылдыра торган юрт урынчылыгы татар теленең башка сөйләшләреннән аерыла.

*Дифтонглар*. 1. Юрт урынчылыгында *өй* кушык авазы үзе әйтелә: *өйләнү, сөйәк, көйәнтә, төйәп* һ.б. *Өй* дифтонгының иренсезләшү очраклары да бар: *сийәл* – сөял, *сийәрем* – сөярем (каенсеңелгә эндәшү сүзе).

2. Фигыльләрдә, аеруча юклык кушымчасында, *-ай*/*-әй* дифтонгы әдәби вариант белән параллель кулланыла: *йарый* / *йарай*, *бармай* / *бармый*, *ақлайдылар* (агарталар), *йөрәйбез* / *йөрибез*.

Бу дифтонг кайбер исемнәрдә һәм туганлык атамаларында да күзәтелә: *әнәй* – әни, *әпәй* – ипи, *түтәй* / *түти* – өлкән хатын-кыз туган, *атай* – әти, *җизнәй* – җизни.

3. Ачык иҗектә яисә сүз азагында әдәби *-и* сузыгына *-ей* кушыгы тәңгәл килә: *кейенәде* – киенә.

4. Шундый ук позициядә *-еү* ~ *ү* күренеше дә очрый: *эүземес* – үзебез.

5. о$^{у}$, ө$^{ү}$ дифтонгоидлары әйтелү очраклары бар: *со$^{у}$қ, ө$^{ү}$лкүн* / *өлкө$^{ү}$н* – өлкән (әд. зур).

6. *Өрәнү* – әд. өйрәнү.

*Тартык авазлар*. Тартыкларның әйтелеше белән әстерхан сөйләше һәм аның юрт урынчылыгы татар әдәби теленнән аерылмый.

Үзенчәлекләр, нигездә, төрле аваз тәңгәллекләренә һәм позицион үзгәрешләргә генә кайтып кала.

Урынчылыкта *җ* һәм *й* авазларының кулланылышлары әдәби телгә якын. Әдәби телдә *җ* белән әйтелә торган сүзләр монда да шулай: *җиде*, *җәйәү, җир* / *йер, җәйәде* – җәя һ.б.

Бер төркем сүзләрдә этимологик *п*/*б* авазы саклана: *тупрақ*, *йапрақ* – яфрак, *кипен* – кәфен, *йебәк* – ефәк һ.б. Бу күренеш кеше исемнәрендә дә очрый: *Пәризә* – Фәризә.

Башка алынмалардагы *ф* авазы да *п* га күчә, кайбер очракларда ф > п > б. Мәсәлән: *байтун* – фаэтон, *тупли* – туфля, *бәлин-төгән* (п > б) – фәлән-төгән, *кәмпит* – конфет, *пылак* – флаг, *партык* – фартук, *пубайка* – фуфайка, *Бәрит* – Фәрит, *Баузия* – Фәүзия.

**Н ~ ң** тәңгәллегенең түбәндәге очраклары күзәтелә:

I зат берлек сандагы хикәя һәм шарт фигыль кушымчаларында: *китерәсен* – китерәсең, *бирәсен* – бирәсең, *барсан* – барсаң, *күрсән* – күрсәң, *эшләмәсән* – эшләмәсәң.

Иялек килеш кушымчасында: *йаулықнын* – яулыкның, *синен* – синең, *үземеснен* – үзебезнең, *кийәwемезден* – киявебезнең һ.б.

II зат тартым кушымчасында: *күләгенде* – күлмәгеңне, *битенде* – битеңне.

Бертөркем сүзләрдә: *тан* – таң, *унай* – уңай, *мен* – мең, *сон* – соң, *сонға таман* – соңа табан, *тин* – тиң (*үземезнен тиннәр*), *ун айағы* – уң аягы, *җин* – җиң, *туну* – туңу. Бу үзенчәлеге белән юрт сөйләше касыйм, мордва-каратай, бәрәңге кебек сөйләшләр белән зур уртаклык күрсәтә.

**б ~ м** тәңгәллеге төрле грамматик күрсәткечләрнең башында күзәтелә: *килбәгә* – килмәгә, *салбадық* – салмадык, *лақсалба* (лаксалма) – токмач рәвешле киселгән камырны майда пешереп баллаган камыр ашы, чәкчәк, *җитписен* – җитмисең (*б* авазының саңгырау пары), *ишпиде* (*ик қолағым да ишпиде*) – ишетми, чәй дә *эчпиде* (эчми), *бөрбәләп теккән* (бөрмәләп).

Киресенчә, **м ~ б** тәңгәллеге дә күзәтелә. Аерым сүзләрдә: *нәлмәк* – диал. нәлбәк – тәлинкә, *менән* / *мән* / *бән* / *бан* – белән, *мәлеш* – бәлеш, *таман* – табан, *пинҗара* / *минҗара* (п > б > м), грамматик күрсәткечләрдә: *үземез* / *үсмес* / *үзмес* – үзебез.

Биредә шуны күрсәтеп үтәргә кирәк, *б* авазы исем һәм сыйфат ясагыч -ма/-мә кушымчасындагы *м* авазына туры килә: *лақсалба* < *лаксалба* (< салма), *кызба* (< кызма) – малярия, *бөрбә* < бөрмә,

*ишпә* < шимә – крендель, сушки, *табайаппа* – бәрәңге белән кабакны чабып табада майда кыздырган ашамлык, *белгезби* – белдерми.

Чагыштыр: *кисмә* – лапша, *киртмә* – груша, *қызма* – бизгәк, *табайаппа* (– йапма).

Иялек, төшем килешләрендә, тартым белән төрләнештә кушымчаларның охшашлану күренеше бар. Мәсәлән: *қаздын* – казның, *картуптын* – бәрәңгенең, *қуйдын* – сарыкның, *сыйырды* – сыерны, *намаздын* – намазның, *қызымдын* – кызымның, *қызынды* – кызыңны.

*Х* авазы, нигездә, билгеле бертөркем сүзләрдә күзәтелә: *қаха* – абый, *төким* // *тыхым* – көнбагыш, *хаза* – каза (бәла-каза), *тактамбит* // *тахәпамбит* – сәке, *бахча* – бакча, *Өрхийә* – Оркыя, *хур булу* – җәфа чигү, азаплану, *хәбер* – кабер, *арқалық* / *архалық* – матча, *чахан* // *чақан* – камыш.

Әдәби телдә *х* белән әйтелә торган сүзләрдә *х* урынына тирән тел арты тартыгы *қ* әйтелә: *қужҗалық* – хуҗалык, *қатыннар* – хатыннар, *қабар* – хәбәр, *қырма* – хөрмә.

Фарингаль *һ* авазы сирәк очрый: *һәр*, *Аллаһы*. Күпчелек очракта *һ* авазы әйтелми: *аман* – һаман, *awa* – һава, *әрwақытта* – һәрвакытта, *Әҗҗәр* – Һәҗәр, *зинар* – зинһар, *әргем* – һәркем, *айлақ* – (< һәлак; чагыштыр: Урал төбәге сөйләшләрендә *һәләк* / *һайлак* – бик ) – бик.

Кеше исемнәрендә, гарәп-фарсы алынмаларында ике сузык арасындагы *һ* еш кына төшә, янәшәдәге сузыклар бер төрле күтәрелештә булсалар, кушылып, озын сузык барлыкка китерәләр (*шәәр* – шәһәр, *зәәр* – зәһәр) яисә әлеге озын сузык тагын да кыскарырга мөмкин: *зәр* – зәһәр, ә күтәрелешләре төрле булган очракта *һ* урынына *й* соноры әйтелә (*Шийап* – Шиһап, *Мәйсәрә* – Маһисара).

*Ч* тартык авазы урынына *ш* авазы әйтелү күзәтелә, ул сүз башында да, сүз уртасында да булырга мөмкин. Әмма бу күренеш системалы түгел: *шақыр туй* / *чақыр туй* (туй йолаларының берсе). *Татарша* (уқыдым), *ошон* – очын, *шатыр* – чатыр, *килен ашқан йаулық* (битен ачкан), *чупыр* / *шупыр* – шадра, *тигәршек* – тәгәрмәч, *шық* – чык, *пышқы* – пычкы.

Юрт сөйләшендә *ч* авазы куллануның, *ш* авазы белән чагыштырганда, активрак булуын Л.Ш. Арсланов татар әдәби теле йогынтысы белән бәйләп аңлата. Әлбәттә, юрт сөйләшенә казан татарларының йогынтысы, һичшиксез, электән үк булган. Әмма биредә

борынгы тарихи уртаклыкны да истән чыгарырга ярамый. Минемчә, бу очракта да Алтын Урда чорындагы тарихи уртаклыкның роле зур булган, юрт сөйләшенең оригиналь үзенчәлекләре (*пике, синәк* һ.б.) буенча касыйм сөйләшенә якынаюы да шушы ук тарихи вакыйгалар белән бәйле. Биредә, күрше нугай, казакъ, каракалпак телләрендә *ч* авазының әйтелмәве дә игътибарны җәлеп итә. Ә казан татарларына гына түгел, Кырым ханлыгы халыкларына да *ч* авазын әйтү характерлы.

**с** ~ **ш** (бу күренеш төрле очракларда, ләкин сирәк очрый): *кесе* – кеше, *аштан сесенү* – ачтан шешенү, *мийес* / *мийеш* – почмак, *биспәт* – бишмәт һ.б.

Аерым сүзләрдә генә күзәтелә торган тәңгәллекләр.

**й** ~ **н**: *майит* – диал. манит – тәңкә,

**н** ~ **л**: *ванник* < валенок; *маймун* – маймыл,

**в** ~ **г**: *дува* – дога,

**w** ~ **г**: *шуwыш* – сугыш,

**ң** ~ **н**: *теңләр* (буе) – төннәр (буе), *теңнә* – төнлә,

**н** ~ **д**: *ине* – иде (сирәк).

Яңгыраулаштыру: *дамады* – тамада, *зәләмә йупка* (бәеттән) – сәләмә, *байтун* < *пайтун* < фаэтон, *бәлин-төгән* < *пәлән-төгән* – фәлән-төгән, *дәтле* < диал. *тәтле* – әд. татлы, *аргылдаҡ* (< аркалык) – матча, *палаз* – палас, *бурчын* // *пуршын* (рус. поршня) – тиредән теккән аяк киеме.

Ике сүз арасындагы позициядә саңгырауларга тәмамланган беренче сүздән соң икенче сүз башындагы *ҡ/к* авазлары яңгыраулашу очраклары бар: *ын гуна* – он кунасы, *сыйыр гура* – сыер абзары, *бал гырты* – бал корты һ.б.

Яңгыраулашу күренеше ике сүз арасында сузыклардан соң да булырга мөмкин: *Майлы гүл* – Майлы күл, *безгә гил* – безгә кил.

Саңгыраулаштыру. Сүз башындагы *җ* авазын саңгыраулаштыру очраклары теркәлгән: *чирендә* – җирендә.

**д** > **т**: *тутый* (< рус. дутый) беләзекнең бер төре, *печә* – бичә, *пизәнә* – бизәнә, *чымылтыҡ* – чымылдык, *тәwә* – дөя,

**г** > **к**: *чикә* – чигә, *кәрәбдәй* сары – гәрәбдәй сары, *патраш* (диал. батрач) – бөтнек, *көбе* – гөбе.

**б** > **п**: *печә* – бичә, *пизәнәде* – бизәнә.

Авазларның охшашлануы: *ҡычҡыч* – кыскыч, *шугыш* // *шуwыш* – сугыш.

Аваз төшү очраклары; **м**: *куләк* – күлмәк; **н**: *мыдый* – мондый, *ниди* – нинди, *майит* < рус. монета – акча санау берәмлеге; **л**: *апару* – алып бару; **д**: *алнда* – алдында; **р**: *пишәткә* – перчатка.

Тулы иҗекләр дә төшәргә мөмкин: *тәсхан* – тәстерхан (скатерть), *кишәк* – киленчәк, *йаси* – ястү (намазы), *мән* – белән, *бийтеп* – болай итеп, *шийтеп* / *сийтеп* – шулай / сулай итеп.

Аваз өстәлү: **б**: *җомбат* – кыйбат; **п**: *ыштампел* – штапель; **г**: *җиңгел* – җиңел, *йаңгы* – яңа; **гесе**: *индегесе* – инде; **к**: *сәрек* – сары авыруы (чагыштыр: себ. сарық – шул ук мәгънәдә).

Метатеза: *нихак* – никах.

Күргәнебезчә хәзерге юрт сөйләшенең фонетик системасы да татар теленә якын.

Алынмаларны үзләштерүдәге кайбер фонетик үзенчәлекләрне карап үтик: *мадур* – помидор, *мәркү* < рус. морковь – кишер, *мәчә* < рус. мяч – туп, *байтун* – фаэтон, *мата* < материал – тукыма, *бәрек* < рус. варига, вареги – бияләй, *бәрек туку* – бияләй бәйләү, *күсәнкә* / *күчәркә* – кочерга, *кәртү* / *кәртүк* / *картуф* / *картуп* < картофель – бәрәңге, *кәтәйкә агач* – сырлы бәләк, *бурчын* – поршня (чи тиредән теккән аяк киеме), *җомбат* – кыйбат, *ванник* < валенок – киез итек, *майит* < монета – тәңкә, *буси* < бусы – муенса, *орих* – гомумән чикләвек һ.б.

## Грамматик үзенчәлекләр

*Исемнәр*. Иркәләү-кечерәйтү мәгънәсе *-җай*/*-кәй* кушымчасы ярдәмендә белдерелә: *чәчәкәй* – чәчәккәй, *тустаҗай* – кечкенә чүмеч, *иркәк* / *иркәккәй* – ир (*ике иркәккәй туганым бар*).

Урта диалектның күпчелек сөйләшләренә хас *-кәч* кушымчасы да күзәтелә: *бәбкәчләрем, безнен туйларны йызасыспа?*

Компонентларны үзара нисбәтлек мөнәсәбәтендә булган исем-исем сүзтезмәләрнең кушымчасыз формасы әстерхан сөйләшендә дә күзәтелә: *нугай мәлеш* – нугай бәлеше, *җыз биттә* – кыз ягында, *үземес тел* – үзебезнең тел.

Мондый характердагы сүзтезмәләр кушма сүзләргә дә әвереләләр: *бәйрәмаш* (бәйрәм ашы) *пешерәсен*. *Җузбүрәкне* (чикләвек пирогын) мин *сирәк пешерәмен, суwагаш* – көянтә, *атарба* – арба, *кийәүсый* – кыз ягындагы туй мәҗлесе.

Сүз уңаенда ассызыклап күрсәтеп үтәргә кирәк, әстерхан сөйләшендә исем һәм башка сүз төркемнәре (аеруча фигыльләр)

ярдәмендә дә кушма сүзләр (бигрәк тә йола атамалары) ясала: *атқушар* – исем кушу туе, *көнбағар* – көнбагыш, *биткүрем* / *бит күргән* – киленнең битен ачу йоласы, *илашар* – ачкыч.

I зат тартымлы исемнәрнең иялек килеше, мордва-каратай, темников, ләмбрә сөйләшләрендәге кебек, инструменталь килеш кушымчасы ярдәмендә ясала: *Әтийемен* (әтиемнең) *сеңнесе қалада торады. Әбийемен* (әбиемнең) *қодашасында торды уқығанда. Үсмесен телчә* (үзебезнең телдәгечә).

*Алмашлыклар*. Зат алмашлыклары: мин, син, ул / *у,* без / *мез* / *мес* / *безләр,* сез, алар. Мәсәлән: *Безләр ақ түпли кийәмез.*

Күрсәтү алмашлыклары: ул / *у,* бу / *бы* / *ме,* шул / (сирәк: *сул*), *монау* / *мынау* – бу, *мәди* / *мона ди* / *мыдый, анау, менә* / *мә ундый* / *мондый* / *монаудий* – мондый. Мәсәлән: *Ме йерләре* (бу җирләре) *абуркалы күләкләрем әл дә торады. Мә* (менә) *монда бөргән күләк кейдем. Мәди* (мондый) *қалпақ салғаннар* (куйганнар) *баш түбәләренә. Мыдый* (мондый) *сырғалар тағып чыға булған әмил бәйрәмендә* (сабан туенда). *Монаудый итек айақта, соуқ* (суык). *Ул wахытта тырактырлар өсте ачық. Монауда* (монда) *бер ыстул кирәк.*

Сорау алмашлыклары, нигездә, татар әдәби телендәгечә: *ни дәт теләсән, шул була. У нигә күренеп тора?, ниди* / *нинди* – *нинди, қалай* – ничек, *қай* / *қа* – кайсы, *нидәт* – нәрсә, *қайсындықы* – кайсыныкы, *нигә, ничә, ни* / *ни зат* / *ни зәт* – нәрсә, кем.

Билгеләү алмашлыклары: *һәр, бөтен, барысы, әргем, әрқайсы* һ.б.

Юклык алмашлыклары: *ни дә* – берни дә, *кем дә, беркем дә.*

Гомумән, алмашлыкларның составы һәм әйтелеше ягыннан әстерхан сөйләше татар әдәби теленнән аз аерыла.

Килешләр белән төрләнеш тә шулай ук әдәби телдәгечә. Тик юнәлеш килешендә генә зат һәм күрсәтү алмашлыкларының күп төрле вариантлары күзәтелә. Мин: *миған* / *мага* / *маған* / *миңә* / *миңан* – миңа. Син: *сиған* / *саған* / *саға* / *сиңә* / *сиңан* – сиңа. Мәсәлән: *Миңә придан итеп шифанир, камод, кырawат, йастық* (меңдәр) *дүртне бирделәр. Маах-мах саған* (сиңа) *дип кукиш күрсәтәсен* (арпа имләү йоласыннан). *Миған* (миңа) *мишәйт итмиде* (комачауламый). *Қазаннан маған сәләм китермәдеңесме? Саған күрсәтәйем әле бит ашқан йаулықты.*

III зат һәм күрсәтү алмашлыгының да юнәлеш килешендә берничә төрле вариант күзәтелә: *уға* / *уғай* / *унаған* / *аунағар* һ.б.

*Бу* күрсәтү алмашлыгының юнәлеш килешендә *буға, быға, бығай* формалары теркәлде. *Шул* күрсәтү алмашлыгының юнәлеш килеше дә шушы типтагы формаларда ясала: *шуғай* / *шуға* һ.б. *Монау*: юнәлеш килешендә: *мынаға, мынағай* һ.б. Мәсәлән: *Угар алтмыш та йуғ әле. Бығай пинесийә әстәделәр. Мынағай барсаңыз йырақ.*

Алмашлыкларның иялек килешендә кушымча бөтенләй әйтелмәскә мөмкин: *Қайнанам, қайнатам да үзем* (үземнең) *қулымнан китте. Менә бу үзем* (үземнең) *сүзләрем. Үземез телне онытпаға йарамайды. Үспесен* (үзебезнең) *телчә йаға булады речка.*

*Саннар.* Әстерхан сөйләшенең юрт урынчылыгында чама саны *-лаған/-ләгән* кушымчалары белән ясала. Мәсәлән: *Туйда бит күргән* (туй йолаларының берсе: яшь киленнең битен берничә яулык белән каплыйлар һәм якын туганнар киленнең битен ачалар, бер яулыкны алып китәләр, ул «килен ашқан яулык» дип атала) *бар иде, унаулаған, унбишәүләгән йаулық, килен ашқан* (киленнең битен ачкан) *йаулық бу. Нуғай мәлешен кийәүсыйда өләшәләр, унаулаған, уникәүләгән нуғай мәлеше барады. Ике йөзләгән ат китте шуғышқа.*

Әдәби төп сан функциясендә *-ау/-әү* кушымчалы формалар кулланыла: *өш* (өч) *иркәк* (ир) *балам бар, берәwе* (берсе) *өйләнгән йоқ. Берәwе* (берсе) *1922 нче йылғы.*

Югарыда күрсәтеп үткәнчә, чама саны да шушы ук формага нигезләнә: *бишәүләп-алтаулап* – 5–6 чамасы (бала).

Тартым белән төрләнгәндә дә шундый ук хәл: *Икәүмез* (икебез) *бергә бер җома* (атна) *торырбыз.*

Сөйләшкә хас санау сүзләре*: кәрәм / карам* – тапкыр, мәртәбә. *Дүрт кәрәм төйәп алып китте. Атларны өлкән* (зур) *парум белән алып киттеләр ике қарам*); *йул* – тапкыр (*қышта ике йул қайтты*).

Сонор авазларга беткән сыйфатлар һәм рәвешләрнең чагыштыру дәрәҗәсе *-дырақ/-дерәк* кушымчасы белән ясалу очраклары теркәлде: *Нәлбәктән* (тәлинкәдән) *кәндерәк* (зуррак) *итеп бороп-бороп чығасын қамырын. Тирәндерәк нәлбәккә* (тирәнрәк тәлинкәгә) *йасаң салатын.*

*Вакыт* рәвешләре: *әүвәл, көзнең көне, көн буйы, төннең буйына, электә, быйыл, иртәдә* – элек, *иртән* – иртәгә, *иртән йуқ* – берсе көнгә, *ике дә бер*, *ике-бер* – кайвакыт, *йаз* – җәй, *йаз башы* – яз, *элем-алан* – эңгер-меңгер, *иртеңмен* – иртә белән, *йаңғары* – узган ел, *әзил заманда* – борынгы заманда, элек, *қай заман* – кайвакыт,

*әлегечкә хәтле* – әлегә хәтле (*әлегечкә хәтле белмәйде*). *Памидур* > – сезон мәгънәсендә: *Бер памидурдан икенче памидурға хәтле эшли, йал күрми. Баш көн* – дүшәмбе, *кече йома* – атнакич. Мисаллар: *Балыққа барады ике-бер. Электә күб йуғ иде. Йаңғарыма, бийылма. Ике дә бер ызбанит итә ынығым. Қай заман тиз бетәде қыш.*

Башка рәвешләр: *дүрткел* – дүрт почмаклы (чагышт.: эчкен сөйләшендә *дүрткил* – шул ук мәгънәдә), *қартлау* – картайган, олыгайган (*әнийем бераз қартлау иде, апам да өлкүн иде*), *тиген* – бушка, бушлай.

Вакыт рәвешләре семантик ысул (*көз* – көзен, *қыш* – кышын), урын-вакыт килеше кушымчасы (*көздә* – көзен, *қышта* – кышын һ.б.), иялек килеше кушымчасы һәм бәйлекләр (*көзнең көнендә, көннөн буйына, көннәр буйы*) ярдәмендә ясалалар.

Сөйләштә *-лат*/*-ләтә, -лый*/*-лий* рәвешьясагыч кушымчалар да күзәтелә: *Көзнең салқын көнендә салқын тийеп, йәшлий үлеп китте. Севижлата сата сөтне.*

Чагыштыру рәвешләрен *-дый*/*-дий* кушымчасы белән ясау актив: *Миндий қарт кем дә йуқ. Синдий булсын, аман-исән йөрсен.*

*Фигыльләр*. Хәзерге заман хикәя фигыльнең I зат күплек сан формасы *-мыс*/*-мес*/*-мыз*/*-мез* варианттагы кушымча ярдәмендә ясала. Мәсәлән: *барамыз* – әд. барабыз. *Ут* (үлән) *чабамыз*, *капыста үстерәмез*.

Бу күренеш тартым кушымчасында да күзәтелә: *икәүмес* – икәүбез, *йурғанымыз* – юрганыбыз, *үземезнен* – үзебезнең.

III зат берлек сандагы фигыльләргә *-ды*/*-де, -ты*/*-те* кушымчасы ялганып килә. Ул борынгы төрки телдәге *торур* фигыленә туры килә: *Нигә қайтмайды* – Нигә кайтмый? *Балалар эшләйде* (эшли), *уқыйды* (укый). *Тан атқанчы утырады* (утыра). *Тахтан* (кияү белән кәләшнең зөфаф кичәсенә әзерләнгән урыны) *чыққан кийәү, күрешеләргә кереп, қул алып* (күрешеп) *чығады* (чыга).

Әстерхан сөйләшенең юрт урынчылыгында хәзерге заман хикәя фигыльнең аналитик төрләре дә кулланыла: *Хөкүмәтемез пинсе биреп йатыр* (бирә). *Суған үстереб атырлар* (үстерәләр). *Пучтаға бара йатыр идем* (бара идем).

Нәтиҗәле үткән заманның II зат берлек һәм күплек формаларында билгесезлек кушымчасы (*-дыр*/*-дер*) зат кушымчаларыннан алда ялгана: *Йәмәледә* (авыл исеме) *күп торғандырсыз*

(әд. торгансыздыр). *Қара турғайны* (сыерчыкны) *беләдерсез* (беләсездер). *Йағадан* (елгадан) *су ташығандырсыз* (ташыгансыздыр).

Әстерхан сөйләше өчен характерлы үзенчәлекле күренешләрнең берсе итеп *-ып/-еп* кушымчалы нәтиҗәле үткән заман формасының I, II затта билгеле үткән заман (*-дым, -дык*) кушымчалары белән төрләнүен күрсәтергә кирәк. Мәсәлән: *Кесәсенә дува* (дога) *йазып қуйыптым* (куйдым), *кийеп йөри. Кукук килгән, кукук қычқырыптыр, йаз* (җәй) *килә. Бер сәүдәгәр қыз булыпты* (булган). *Қалада аданашлар йәшәпте* (туганнан туганнар яши). *Мартта йаучы килепте* (килде).

Юклык формасы: *Бәйеттән туймаптық* – Бәеттән туймыйбыз.

Сөйләштә нәтиҗәле үткән заманның угыз телләренә хас *-мыш/-меш* формасын куллану очраклары да теркәлгән: *Син алып йөрмешме боларны?*

Кабатлаулы үткән заман *-а/-ә/-й* кушымчалы хәл фигыль һәм *торган иде* төзелмәсе белән белдерелә. Ләкин бу әдәби вариант сирәк күзәтелә, әстерхан сөйләше өчен аның *даган / таган / дәгән / тәгән* вариантлары хас һәм ул актив кулланыла. Билгеле булганча, бу төзелмә һәм аның кыска вариантлары себер диалектларында актив. Мисаллар: *Қышқа йағарға қамыш ура даған идек* (ура торган идек). *Шул қатын йағада* (елгада) *балық тотадаған иде. Мин түбәтәй чигә дәгән идем мулине менән* (чигә торған идем мулине белән). *Аwылларға йөрә дәгән иде, аwыштырып* (алыштырып) *ашамаға апқайтады. Тәрит җаулықлар* (сөлгеләр) *чигә тәгән идек. Йаңғы өйгә Қоран* (Коръән) *уқыта торган иделәр, өстәлгә нугай мәлеш бирә торған иделәр.*

Бу форманың тагын да кыскарган варианты да күзәтелә: *Уйнап җерәтән* (йөри торган) *идек. Безнең зийарәттә ыруwын күмәдән* (< күмә торган) *бер урынға, хәзер урам-урам* (рәт-рәт) *инде.*

Дәвамлы үткән заманнар. Әстерхан сөйләшендә *-а иде* иң актив кулланылышлы форма.

Характерлы күренешләрнең берсе – әлеге форманың юклыгында *иде* ярдәмче фигылен кушып әйтү: *Бар балықны да ашап белмидек* (белми идек).

Юрт урынчылыгында дәвамлы үткән заманның *-а/-ә/-ый/-ий + булған* формасы да шактый актив кулланыла: *Мыдый* (мондый) *сырғалар тағып чыға булған* (чыга торган булган), *әмил бәйрәмендә*

(сабан туенда). *Зур абый суғышқа китте, тамақ* (ашарга) *ничек таба булғаннардыр.*

Үткән заман юрт сөйләшендә *-а/-ә/-и + даған/дәгән иде* төзелмәсе белән белдерелә.

Киләчәк заман хикәя фигыльләрдә зат кушымчасының башында киң вариант сузыклар әйтелә һәм бу үзенчәлек юрт урынчылыгына үзенчәлеклелек өсти. Икенчедән, мондый форма татар теленең бараба диалекты, тубыл-иртыш диалектының тара, тевриз һәм башка сөйләшләрендә дә күзәтелә: *Исемә төшерәрем* (төшерермен) *микән. Белгәнемезне сөйләштерәрмез* (сөйләштерербез). *Күрсәтәрем* (күрсәтермен) *дә әле.*

Билгеле киләчәк заман әдәби телдәге *-ачак/-әчәк* кушымчаның *-айақ/-әйәк* варианты ярдәмендә ясала. Мәсәлән: *Мин иртәгә қалаға барайақман* (барачакмын). *Инде монда торайақсын, диделәр. Сәлим иртән* (иртәгә) *китәйәк. Баласы исән қалайақ тиб әйттеләр.*

Билгеле киләчәк заманның үткән заманы *иде* ярдәмче фигыле белән ясала: *Түбәгә күптән эримут йасайақ идем. Мин туйға бармайақ идем.* Шушындый ук төзелмә себер татарларының бараба диалектына хас һәм ул ниятне, ниятле теләкне белдерә.

Исемләшеп урын-вакыт килеше кушымчасын алганда, әлеге форма шул нигездән аңлашылган эшнең вакытын белдерә: *Әрмийәгә китәйәктә қазанөй* (җәйге кухня) *эшләтеп китте.*

Боерык фигыльнең II зат күплек саны *-ың/-ең/-еңез* кушымчасы ярдәмендә ясала: *Хушығыз, йақшы йулға барың* (барыгыз). *Өрәтеңез мине...*

Сөйләштә эчке теләк *-кы/-ке/-гы/-ге + кил-* төзелмәсе белән белдерелә (чагыштыр: көнбатыш диалектта *-ак/-әк/-к + кел-* – әд. *-асы/-әсе килә*). *Ашағым да килмиде мадурын* (помидорын). *Уқығым килеп торады* (укыйсым килеп тора). *Күргегез килсә, ул рамнар бар. Үземез телне онытқымыз килмәйде* (онытасыбыз килми).

*-гыр* кушымчалы борынгы теләк формасы да теркәлде: *Бөтен аwылларға йөрәсез икән, сау булғырлары.*

Кабатлаулы эш-хәлләрне белдерә торган форма, әдәби телдәге кебек, *-ғыла/-геләә, -кыла/-келә* кушымчалары белән ясала: *Өлкөн* (зур) *шәлне дүрткел итеп дүрткә кискеләдек.*

Шушы ук функциядәге *-штыр/-штер* формасы юрт урынчылыгында сирәк очрый: *Белгәнемезне сөйләштерәрмез.*

Юнәлешләр. Йөкләтү юнәлешен көнбатыш диалектка хас кушымчалар белән ясау, әдәби тел белән чагыштырганда, актив: *әкрен йөргезеп* (әд. һәм урта диалектта: йөртеп). *Йазын* (җәен) *соу үткәзәбез* (әд. үткәрәбез). *Қызны атарбаға утырғызып озатқан. Қаwғалды* (уен коралы) *қағадылар, кийәүне күтәреп кергезәделәр. Миған* (миңа) *лампы тотқыздылар* (тоттырдылар), *шуны күтәреп алып бардым.*

Кайбер фигыльләрнең төп юнәлеш формасы сакланып килә: *Чәйең суwыйды* (суына). Бу форма Урал һәм Себер ареалларындагы татар сөйләшләре өчен хас.

*Кирәк* модаль сүзенең фигыль кебек төрләнүе: *Кирәккәндә* (кирәк булганда) *мадур* (помидор) *керебал, дисә көнөләм була иде.*

*Инфинитив*. Урта диалектның борынгылыкны аеруча көчле саклап килгән касыйм, нократ, пермь, бәрәңге, керәшен сөйләшләрендәге кебек, юрт урынчылыгында да инфинитивның *-маға/-мәгә,* саңгыраулардан соң *-паға/-пәгә* формалары кулланыла: *Кеймәгә* (кияргә) *кейемебез булмады у чақта. Ашамаға* (ашарга) *апқайтады. Уқыдым да эшләмәгә* (эшли) *тотындым. Ирнен туғаннарына исеме белән әйтпәгә* (әйтергә) *йарамаған. Киспәгә бирмәдем. Суға төшпәгә* (төшәргә – коенырга) *барсан, сыу анасы айақтан тартады. Ақ тәтәне* (әнисенең бертуган апасы) *чақырмаға кирәк.*

Күрсәтеп үткән сөйләшләрдәге кебек үк, юрт урынчылыгында да әлеге форманың кыскартылган варианты күзәтелә: *Күләкләр сатыб алма* (алырга) *кирәк. Башым аwыртма тотынды. Мин книгалар уқыма* (укырга) *йаратам.*

Сирәк кенә *-галы* кушымчалы инфинитивны куллану очраклары теркәлде: *Без балалар икәүмес, ашағалы телимез* (ашарга телибез).

Бу инфинитив формасы Себердә таралган татар сөйләшләре өчен характерлы.

Сыйфат фигыльләр. *-а торган* формасы юрт урынчылыгында *-а даган/-ә дәгән* вариантында кулланыла: *Туқайны белә дәгән* (белә торган) *Мәйсәрә исемне қатын бар. Қамыш үсә дәгән битләрдә* (якларда, җирләрдә) *дөге чәчәделәр.*

*-ган/-гән* кушымчалы сыйфат фигыльнең мәгънә функцияләре, нигездә, әдәби телдәгечә.

*-ғанда/-гәндә* кушымчалы сыйфат фигыльләр эш яки хәлләрнең бер вакытта башкарылуын белдерәләр: *Җитәкләшеп бийү бар иде без үскәндә. Үтеп барғанда сөйләшеп торды, қул алышты да*

(күреште дә). *Ускәндә урамда саз* (гармонь) *тартып йөрү бар иде, саратыский саз. Йарлы Түбә* (ярлары, сыртлары булган тау) *аwылына барғанда, безне адаштырды, озақ эзләп йөрәдек, бисмилланы әйтеп йөрәсен инде.*

*-ганда/-гәндә* формасында *-да/-дә* кушымчасы алдында *-ын/-ен,* I затта *-ым/-ем* формантын өстәп куллану күзәтелә: *Уны* (мәчетне) *совет выласте килгәнендә wаттылар. Мин күргәнемдә ақ жәйәделәр, киленне бастырадылар биткүремдә. Қызға сөт эчерәделәр кергәнендә* (кияү өенә). *Шуwыш беткәне белән* (беткәч) *мануфактур чықты.*

*-айақ/-әйәк* кушымчалы сыйфат фигыль шактый актив күзәтелә: *барайақ* (барачак) *кешеләр*; *кийәүгә китәйәк* (китәчәк) *қыз*; *сорайақ* (сорыйсы) *сүзләр бар.*

Бу форма урын-вакыт килешендә килгәндә вакыт мәгънәсен белдерә: *Китәйәктә* (китәр чакта, китәр алдыннан) *қыз идән уртасына утырады.*

Төшем килешендә: *Үләйәген белгән ул.*

*Бул* ярдәмче фигыле белән килгәндә *-айақ* формасы ният-теләкне белдерә: *Түбә сырлайақ булып* (буямакчы булып) *йөрде.* Чагыштыр: шулай ук татар теленең бараба диалектында да.

*-ғач/-гәч* кушымчалы хәл фигыль сөйләштә сирәк кулланыла. Бу аның синонимы булган *-ғаннан соң* төзелмәсенең активлыгы белән дә бәйле булса кирәк: *Өч энем бар иде, алар үлгәннән сун, мин бер үзем қалдым. Өйен салғана сын* (салганнан соң) *аурады, айақлары қыйшық булды. Қарт мамам үлгәннә сун* (үлгәннән соң), *монда қайттық.*

*-кандый/-кәндий булу*: *Киткәндий булсам арғы* (теге) *дөнйаға, wасийат итәм, татар қызына өйлән. Шуwыш wахытта туйғандый ашарға да булмаған.*

Хәл фигыльләр. Әдәби телдәге кебек үк, юрт урынчылыгында да *-ып/-еп*, *-ғанчы/-гәнче*, *-ғач/-гәч* һ.б. формалар актив.

*-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыльләрнең *-а/-ә/-ый/-ий* формалы хәл фигыльләр функциясендә кулланылу очраклары бар, бу бигрәк тә *башлау*, *белү* фигыльләре алдында килгәндә күзәтелә: *Үзем жырлап белмидем, саз тарттым* (жырлый белми идем, гармун уйнадым). *Жыллар үтә-үтә аwылны Жәмәле диб әйтеп башлыйлар. Кийет* (бүләк) *биреп булғаннан сун ақча чәчәделәр, элек қыз бит* (як) *чәчәде. Кеше белән сөйләшеп* (сөйләшә) *тә белми. Кем үзе*

*теген* (тегә) *белә, тегәләр иде. Йазып беләм, уқып белмим* – (яза беләм, укый белмим).

*-ганчы/-гәнче* формасының вариантлары һәм синонимнары. *-ғанча/-гәнчә*: *Әтийем, туwыштан килгәнчә, пастух булыб эшләдем.*

*Теркәгечләр*. Әдәби телгә хас теркәгечләрдән тыш, тагын түбәндәгеләрне күрсәтергә кирәк.

*Әмән* – гүя: *Шырық-шырық таwыш килә, йорт ийәсе ишеттерәде әмән.*

*Исә* теркәгече билгеле үткән замандагы фигыльгә кушылып килә һәм эш яки хәлләр арасындагы вакыт, шарт яки сәбәп бәйләнешләрен белдерә: *Түпли кимәдисә* (туфли кимәгәч), *кечкенә булып торады қызым. Китаб уқыб утыра бирәм, уқыды исәм* (укысам) *йақшы була.*

*Бәйлекләр*. Урынчылыкта түбәндәге бәйлекләр актив: *Күбек / күwек кебек, таман* (таба), *менән/мән/белән/бан, төсле, такле / тикле / тикем, қәдәр* (кадәр).

Мәсәлән: *Тән төсле чирәбәк* (< рус. черевики) *була даған иде, анда шырқылдаwық* (шыгырдавык) *йуқ. Иртә мәнгә* (беләнгә) *қәдәр. Өч көнгә қәдәр сөйләмәдем* – өч көн тел яшердем. *Шуның бан* (белән) *алтмыш йыл йәшәдем. Эшкә тикем* (тикле) *килә алмайдылар. Тәтле* (татлы) *тамыр чахын* (камыш) *күбек* (кебек) *үсә иде.*

*-мы/-ме...* сорау кисәкчәсе, татар теленең мордва-каратай, дөбъяз, бәрәңге, себер татарлары сөйләшләрендәге кебек, киң вариантта да кулланыла: *Орқыйа, дусын барма? Ундүрт йәшпә* (яшьме) *индегесе* (инде)?

Сорау кисәкчәсе әстерхан сөйләшенең юрт урынчылыгында йомык тартыклардан соң *-па/-пә/-пе*, яңгырау һәм саңгырау авазлардан соң *-бы/-бе, -ба/-бә* вариантларында күзәтелә. *Үземеспе?* – Үзебезме?

Өлкән кешеләр телендә *қуй/ғуй/ғу* (әд. бит, ич) раслау кисәкчәсен куллану күзәтелә: *Гурт қуй* (шәһәр бит) *инде монда. Үтерек* (ялган) *сөйләп булмый ғуй инде белмәгәнне.*

Үтенүне, ипләп кушуны белдерә торган *-чы/-че* кисәкчәсе кулланыла: *Қойчы чәй.*

Әстерхан сөйләшенә хас фразеологизмнар: *қуwанычы қултығына сыймау; хур булу* – газап чигү; *су ату* – елгадан бакчаларга мотор белән су сиптерү; *кул алу* – күрешү; *аwызберлек табу* – уртак тел табу; *тәм иту* – авыз итү; *арғы дөнйа* – теге дөнья; *төрекмән*

*түрен бирмәс, ди; Батагадан* (ватага, эшчеләр артеле) *тоз алма, Қазаннардан қыз алма; күмәг итү* – ярдәм итү; *йөз йәшә, йөзем аша; илче илчегә ызық* (каршы килү, бәхәсләшү) *йуқ* һ.б.

## Лексик үзенчәлекләр

Әстерхан татарларының килеп чыгышы һәм формалашу тарихы мәсьәләләрен хәл иткәндә аларның тарихында, иҗтимагый-мәдәни үсеш барышында формалашкан сүзлек фондына да игътибар итәргә кирәк. Биредә түбәндәге төп моментларны яктырту күздә тотыла: сөйләшнең лексик составын әдәби телгә мөнәсәбәтле күзәтү, татар теленең башка сөйләшләре белән чагыштыру һәм сөйләшнең үзенчәлекле лексикасын ачыклау.

Әстерхан сөйләшен проф. Л.Ш. Арсланов лингвогеографик планда тикшергән галим. Шунда ук ул аларның сүзлек фондын да өйрәнә. Сүзлекләрендә, монографияләренә кушымта итеп бирелгән сүзлекчәләрендә бай материал чагылыш таба (1972, 1973, 1974, 1976, 1977, 1978, 1979, 1980, 1981, 1982, 1983, 1986, 1989, 1990, 1992, 1994, 1995, 1997, 1998, 2010). Сөйләшнең лексик составы турындагы мәгълүматлар Ф.С. Баязитова хезмәтләрендә дә китерелә (1992, 1995, 2002, 2006, 2008).

Л.Ш. Арслановның Программа нигезендә Әстерхан, Волгоград өлкәләре һәм Ставрополь крае татар авылларында (31 авыл) тупланган материаллары 3 томлы «Татар халык сөйләшләре атласы»нда да (III томда) нигез материал булып санала (Атласның электрон версиясен кара: http://atlas. antat.ru).

***Туганлык атамалары***. Әстерхан татарларының үзенчәлекле атамалар системасы формалашкан. Билгеле булганча, һәр этнографик төркемнең үзенчәлекле билгеләре табыла, туганлык атамаларында да аларның формалашу тарихы чагылмый калмаган. Кантуганлык атамаларында борынгы катлам белән соңгы чорда, мәсәлән, казан татарлары алып килгән атамалар бергә кушылып киткән.

*Әйем, ана, анам, әнием* эндәшү формасы да шулай ук: *әйем:* 1) әнием, 2) кайнанага эндәшү сүзе, *әйең* – әниең (*әйең ничә йәшендә?*); *дусым әни:* 1) әниемнең дусты, 2) әтинең хатыны – әстерхан татарларының борынгы катламыннан килә булса кирәк. Тарихи яктан ул *әни* сүзенең варианты булырга да мөмкин, әмма *н* авазы төшкән вариант Түбән Идел регионында юрт татарлары һәм алабугатлар телендә генә күзәтелә. Аның янәшәлекләрен тагын корея

теленнән китерергә мөмкин: *ẹі, еńі* формасына кайтып кала дип санала (Э.В. Севортян, 1974, 281 б.).

Л.Ш. Арсланов материалларында *әйем* – анам (зензели авылы сөйл.), әти ягыннан булган *әди* (юрт урынчылыгында), *әйім* – ана ягыннан булган туган тиешле хатын-кыз яки теләсә нинди хатын-кыз (карагашлар сөйләшендә), ягъни төрле мәгънә белдерә дип күрсәтелә. Бу хәл дә аның борынгы кабиләчелек, аналар һәм өлкән яшьтәге хатын-кызлар әле индивидуальләшмәгән чорга барып тоташуын, *әйе* атамасының кайчандыр классификацион характерда булуын раслый.

*Ата* (эндәшү формасы: *атам, атийым, әтием*) – әдәби телдәгечә. Бу атаманың да кулланылышында үзенчәлекләр күзәтелә. Мәсәлән: *аданаш атам* – туганнан туганымның әтисе; *дус әтисе* – әтисенең дусты; *дус атам* – атамның дусты; *дусым әти* – әтинең дусты; *атайбикә* – әтисенең апасы; *зур әти* – әтинең абыйсы; *ата* / *атам* – әтинең әтисе.

*Тәтә* – бертуган апа. Санскрит теленнән үк билгеле булган бу атама татар диалектларында киң таралган һәм төрле мәгънәләрдә (*апа, ата, баба*) кулланыла (Д.Б. Рамазанова. Термины родства и свойства в татарских говорах. Казань, 1991). *Аķ тәтә* – әнисенең апасы.

*Апа* атамасы бик сирәк очрый. *Апай* варианты балалар бакчасындагы, мәктәптәге тәрбиячеләргә һәм укытучыларга карата кулланыла: *16 йәшемнән дитсатта апай булыб эшләдем.*

*Әптә* < *абызтәтә* – 1) бертуган апа, 2) әти яки әнисенең кыз туганнары, 3) олы яшьтәге хатын-кыз һ.б. Бу атама Тау ягында таралган тархан, кама-тамагы, норлат сөйләшләрендә дә билгеле. Сүз уңаенда шуны искәртеп үтәргә кирәк, юрт сөйләше вәкилләре арасында күрсәтелгән төбәктән килгән нәселләр еш очрый. *Әптә* атамасының нугай, казакъ телләрендә дә кулланылуы билгеле.

*Ķаха* (эндәшү формасы *ķахам* / *ķаķай* / *ķахай*) – абый: *Султанғали ķахай* һ.б., шулай ук, әстерхан сөйләшенең үзенчәлекле билгеләреннән берсе. Чагыштыр: нугай теле диалектларында *калькем* – әтигә эндәшү сүзе, төрекмән телендә *кәкә* – абый, татар теленең мамадыш сөйләшендә *кәкәм* – балаларга яратып эндәшү сүзе.

*Бибә* // *эне* – эне (чагышт.: нугай телендә, шулай ук, *бебе*): *Бибәләре китәйәк ķыз ман саубуллашадылар.*

*Мама* – әби, *мамам* / *маман* // *әйем* – әбием, баба – 1) бабай, 2) әтинең абыйсы, *бабам* – бабайга үз итеп, яратып эндәшү сүзе,

*қарт мамам* – әби яки бабайның әнисе, *мамай* – кендек әби (*мамайлар таптырғаннар баланы*), *ата, атам* – әтинең әтисе.

*Қайтим* / *қатин* – әнисенең (сирәк очракта әтисенең) апасы, кыз туганы (аңа *сәүлим, җиңгәм, өлкүн тәтәм, бал тәтәм* дип эндәшкәннәр): *Халида қайтиң мән йырлаб утырдылар.*

*Ол* – ул: *Биш олы бар; кинҗә* – 1) төпчек бала; 2) иренең иң кече энесе.

*Биби әйем* – әнисенең кече килендәшенә эндәшү сүзе.

*Ақ мамам, ақ бабам, аданаш ани, аданаш әтийем* – туганнан туганнарның әти-әниләренә эндәшү сүзе.

*Аданашлар* – 1) туганнан туганнар, 2) бер елда туганнар; *ике аданаштан туган* – туганнан туган.

*Аданаш әнийем, аданаш әтием* дип үз нәселеннән булган теләсә нинди өлкән туганнарны атыйлар.

*Қуншайым* (*қунчайым, күршәйем*) – күрше хатын-кызга эндәшү сүзе, *кунш атам* – күршедәге ир кешеләргә эндәшү сүзе.

*Зур абый* – әтисенең абыйсы.

*Бала: Балалар уйнайдылар. Бала-шаға* (әд. бала-чаға). Аларга иркәләп эндәшү сүзләре: *бәбекәчкәйем, алтынымнын бер кисәге, кечки бала, кечкентәй, яшь бала, кичәгем* (әд. җаныем). *И балам, қырағым, ди икән кечки баласына.*

*Сиқа* – бик сорап, бик теләп алган бала: *Аның сиқасы бар, анарға* (аны) *йарамый азарларға* (ачуланырга).

Гомуми туганлык: *хәрдәш* / *қәрдәш, туған, зат – нәсел, туғанқәрдәш* – туганнар, *ыру* һ.б. Мисаллар: *Бабамның заты* (туган тиешлесе) *бар иде, қахам, шул чықты әйттерергә* (яучы булып). *Ир кеше туғаны бар иде, суғышта йуғалды. Биткүрем* (туй йоласы) *йасадылар, туған қәрдәшләрне җийа. Туй йасыйлар, қыз биттә* (ягында) *кийәү сый була, туғаннары килә.*

***Никах туганлыгы атамалары*** системасы кыпчак телләре, татар теленең көнбатыш һәм себер татар диалектлары (тубыл-иртыш, бараба, том) өчен уртак: *қайната, қайнана, қайнага, қайымбикә // қәйембикә, қайниш, кайын эне, қайынсеңел, бийаға* (иренең абыйсы) һ.б. Шулай ук *бажқа, килендәш* / *апсын, балдыз, кеншек* / *киленчәк* (сөйләм.) / *кешәк* / *кишәк* – килен: *печә* / *пичә* – хатын, хатын-кыз.

Сөйләш өчен эндәшү формаларына аерымлыклар хас: *әйем* – каенанага, *атам* – каенатага эндәшү сүзләре. Көнбатыш диалекттагы

кебек үк, әстерхан сөйләшендә дә иренең эне-сеңелләренә исеме белән эндәшү тыелган. Аларга *аппағым, туғаным, сәүлим* (нурым, яктым), *эрүwем* (< ару – чиста, яхшы), *гүзәлем, сөйеклем, сийәрем* – сөярем (каенсеңелгә), *ақмуллам, мырзам* // *моллам* (каен энегә), *суқташ* (иренең абыена), *қайнағам* (иренең абыйсына), *абсын, чичи* (килендәшләргә), *апа*(*й*) *туғаным, сөйеклем* һ.б. сүзләр белән мөрәҗәгать итә торган булганнар.

Гомумән, туганнарга эндәшү формасы, борынгы төрки телдәге һәм иске татар язма әдәби телендәге кебек, беренче зат тартым кушымчасы белән ясалган: *қахам* // *абийым, җиңгәм, чичи* / *чичийем* – җиңгигә эндәшү сүзе (*Пәризә чичи, Халидә чичи әйтәсен*). Килендәшләр үзара бер-берсенә *татуwым* дип эндәшәләр. *Бикәм* – ир ягыннан булган өлкән хатын-кыз туганнар, аларга эндәшү сүзе.

Сөйләштә җенесне белдергәндә *иркәк* сүзе кулланыла. Мәсәлән: *Өш* (өч) *иркәк балам бар. Ире* мәгънәсендә *байы, байың, байым* сүзләре кулланыла: *Анын байы җуқ, йалғыз.*

Туй йолалары белән бәйле лексикада да үзенчәлекле күренешләр шактый табыла. Татар теле белән уртак *яучы, кыз әйттерү* кебек сүзләр, сүз тезмәләр белән беррәттән, җирле атамалар, әстерхан сөйләшенә генә хас йола исемнәре сөйләшкә карата зур кызыксыну уята.

*Тахтан чыққан кийәү* – яшьләр кушылганнан соң икенче көнне иртә белән башкарыла торган йола: *Тахтан чыққан кийәү күршеләргә кереп қул алып* (күрешеп) *чыға. Тақ* (кызның бирнәсе) сүзеннән. *Тақтамбит* / *тахтамбит* – сәке, *тақта* – түтәл.

*Шақыр туй* – кызга никах укыр алдыннан туган тиешле кызларны, дус кызларын чакырып уздырыла торган кичә.

Туй йолаларының эчтәлеге белән дә, атамалары белән дә юрт (утар) татарлары үзенә бер специфик төркем тәшкил итәләр. Болар турында сөйләү үрнәкләрендә бирелгән «Туй йолалары» дигән бүлекчәдә киңрәк яктыртыла.

Биредә туй йолаларының исемнәре генә теркәлә: *бит күргән* – киленнең битен ачу, *килен ашқан йаулық* – «бит күргән» йоласы башкарылган чакта алган яулык, *сөйләмәү* – тел йәшерү (*Өч көнгә хәдәр сөйләмәдем, аннан бийағам миңан әйтте: «Қызым, битенде аш, шәленне чиш, бит ачуға ислемай әкиләде Мортаза бийағам»*), *өндәүче* – туйга чакыручы итеп махсус билгеләнгән кеше, *көн кисү* – туй көнен билгеләү, *йәүче* – яучы.

*Туғыз туй* – егет ягыннан ярәшелгән кызга җибәрелгән бүләкләр, алар тугыз исемдә булган.

*Канфит туй* – кыз ягында зур подноста конфет тарату.

*Сөт хақы:* Сөт хақы дип қызның әниенә ақча бирелә.

*Кийәү арақысы* һ.б. (сөйләү үрнәкләреннән кара).

*Түркеннәп бару* – килен төшкәч һәм кызның ата-аналары чакыргач, яшьләрнең кыз ягына кунакка баруы.

*Нағажы* – ана ягыннан булган өлкән туганнар, бу атама татар телендә XVIII гасырда кулланылышта булган әле (С. Хәлфин сүзлегендә теркәлгән).

Сөйләш вәкилләренең сөйләшендә, рухи-мәдәни лексикасында да үзенчәлекле моментлар байтак: *саз* – гармун, *саратыски саз* – рус. саратский гармонь, *саз тарту* – гармун уйнау, *аwызда саз тарту* – эттэгидер... дип әйтеп көйләп тору, *этнәгә бийәү* – бию исеменең бер төре, *сазчы* – гармунчы.

*Муйтомар / буйтомар* – муенга асып йөртелә торган догалык.

*Өй ийәсе* – йорт иясе.

*Аш қайтару* – ашагач дога кылу.

*Аwыз бөрлеген бирсен* – гомерегез озын булсын.

*Хатем қоран* – Коръән ашы; *қан қойу* – кан чыгару.

*Кийит / кийет* – бүләк, хәергә таратылган әйбер.

Бәйрәмнәр: *әмил бәйрәме* – сабан туе; *утырыш* – кунак, мәҗлес (*Керимтишин күләк утырышқа барырға әзерләп қуйдым*).

*Җыйын* – аулак өй.

*Қул йудырып керту* – туйга килгән кунакларны кулларын юдырып кертү. Бу йола кайбер керәшен сөйләшләрендә һәм нократ сөйләшендә күзәтелә.

Кешене тасвирлый торган сүзләр: *маштақ* // *тәбән* – тәбәнәк буйлы; *маштақлар бассын, озыннар утырсын* (карточкага төшкәндә); *бийек* – озын буйлы; *шупыр* – шадра; *қычқырық* – җәнҗалчы, тавыш чыгаручы; *ардақлы* (чагышт. татар телендә: *йақлы*) – кыланчык, шулай ук – мактанчык, кыланчык, ягъни юрт сөйләшендә мишәр сөйләшләренә хас *ардаклы – кадерле*, *якын* сүзенең мәгънә төсмере үзгәргән; *дуwадақ* – 1) эшләмичә, киләп сарып йөрүче; 2) дүдәк (дрофа). Татар сөйләшләрендә ул башка мәгънәләрдә дә билгеле:1) бала чыгармаған каз, 2) дүдәк, 3) чүл кошы, 4) ялгыз кеше, бала-чагасыз кеше һ.б.; *атақ* – кушамат, *арық* – ябык, *қул алу* – көрешү; *тезә* – тез (шулай ук бараба диалектында

да), *әрү* – матур, яхшы; *чигү* / *тигү* – тәмәке тарту, *тәмбәл* – ялкау һ.б.

Авыру исемнәре: *сәрек* – сары авыруы (чагыштыр: себер татарлары сөйләшләрендә *сарық*); *қызба* – бизгәк; *чиқан* – чуан, *қызылча* – кызамык; *тирескән* – арпа (күздә): *Тирескән – кәчекнен* (көчекнең, этнең) *сигәненә қарасаң була; сыңғылдау* – очкылык тоту (шулай ук нугай телендә дә); *мараз* – авыру (исем).

Хуҗалык эшләрен белдерә торган лексик-семантик төркемдә дә төрле характердагы сүзләрне бүлеп чыгарырга мөмкин. Алар арасында җирле климат һәм табигать шартлары белән бәйле булган хуҗалык эшләрен белдерә торган тәгъбирләр һәм лексемалар аеруча әһәмиятле: *қадау* – утырту (*қапыста қадау*), *тақта* – яшелчә һ.б. үстерү өчен әзерләнгән участок (*ике тақта җир монда, ун-унике гр'адка*); *қатлық* – терлек ашаганнан калган кура, печән, салам калдыклары (*Қатлықны йағабыз*); *печән чалу* – чабу (*Қазан биттә дә чалалар печәнне чалғы белән*); *өкө* – бәке (*Өкө уймаға кирәк атларға, ирләр йуқ, менә ничек хур булдык, җәфаландык*); *арбачы* – арба белән йөк ташучы, *хәйер қуйу* – өстәү, бирү (*кем үзе теген белә, тегәләр иде, хәйер өстәп саталар иде*); *балчы* – квас кайнатучы, *утлык* – көтүлек.

***Бакча сугару белән бәйле сүзләр:*** *бегәт алу* – арыктан килә торган суны бакчага бору өчен бер-ике көрәк җир алу, юл ачу; *сыу җибәрү* – сугару (*Анан эстенә* (бәрәңгегә) *сыу җибәрдем, үсә төшкәч өйә башлыйсын*)*; күсәм* / *күчәм* – сугару каналы (*Үзебезнен күсәмгә килеп төшә су водогонны ача да, күчәмен ачыб-ачып су ачабыз, бүгәтләрен атамыз да су керә шилгә* (түтәлгә)); *чил*/*шил* – сугару өчен җайланган түтәлләр; чик: 1) *чик йасап, чик-чик йасап су салалар* – сугарыла торган түтәлләрнең читләрен биегрәк итеп ясау (түтәлдә су бераз җыелып торып торсын өчен шулай эшләнә); 2) *чик* – дөге түтәле (*Чикларда үсәде дөге*); *кирпән чабу* – җирне китмән белән йомшарту; *тере* – тимер көрәк; *тырнаwыч* – 1) кул тырмасы, 2) җир тырмалый торган тырма; *арыш*/*арыс* – тәртә (себер диалектларында да шулай ук), *боғыл* – печән кибәне; *чил* – сугарырлык итеп әзерләнгән түтәл, *эчәү*/*эшәү* – бакчада су сибү, сугару.

***Каралты-кура, йорт-җир төзелеше белән бәйле лексика*** халык яши торган җирле шартларны яхшы чагылдыра. Шулай ук аның составында көньяк халыкларына хас сүзләр дә табыла: *әүлә* –

ишек алды; *мал әүләсе* – мал абзары; *таш өй* – кирпеч өй; *таш пич* – кирпеч мич; *ч*(*ш*)*арлаҡ* – чорма; *түбә* – 1) түбә, 2) түшәм; *ҡазан өй* – җәйге кухня (ишегалдында): *Казан өйнен түбәләрен йуwам; пластинчатый өй* – калын тактадан (пластиннан) эшләнгән өй; *аҡ таш* – ак кирпеч; *әк* – акбур; *әкләү* – агарту (*Өйне әклиләр иде әк белән*).

Этимологияләре ачык булмаган сүзләрне ассызыклап үтәргә кирәк: *пинҗара* / *минҗара* – өй алды; *мансарда* – өй түбәсеннән чыгып торган балкон; *чарлаҡ* / *бала чарлаҡ* – шул ук мансарда (*Таҡтадан чарлаҡ йасалған*); *эргә суғу* – нигез салу (*Соуҡ көрмәсен өчен эргә суҡтыҡ*); *өй торғызу* – өй күтәрү; өй салу; *мийеш*/*мийес* – почмак; *айат* – өйнең (кергәч тә) ишек каты, өй алды; *бихыт* – подвал, *элдерек* – савыт-саба киштәсе, *эргә* – өйнең тышкы нигезе, *чапраш* – баскыч (басып менү өчен), *ыры*/*оры* – баз.

Көнкүреш лексикасында җирле шартларда иҗат ителгән диалектизмнар бар: *суwағач* / *суwағаш* – көянтә, *шайтан лампы* – сукыр лампа; *селпек* – тирес, *хезмәт* – эш (*Арбаны сөйрәп китәдем хезмәткә* (эшкә); *чикке* – үлчәү; *айаҡ орчыҡ* – җепне аяк белән әйләндереп эрләү коралы; *пийала* – көзге; *арғылдаҡ* – матча; *ашар* / *илашар* – ачкыч; *сырдаҡ* – сырылган әйберләр (түр киезе, урындык киезе һ.б.); *җир түшәге* – җиргә салып утыра торган сырма киез; *баҗаклы* – алтын тәңкәләр; *ҡәлбәй ҡашыҡ* – бал ҡашыҡ; *керт* – йозак; *ҡыпыл* – ачкыч (*Ҡыпынны ҡайа ҡуйдың?*); *ҡалбыр* – эре тишекле дуршлаг, *шешә* – пыяла; *сыйа* – кара (чернила), *элдерек* – киштә, шүрлек. Болардан тыш борынгы төрки (*айаҡ-саwыт* – савыт-саба, *айаҡ-касә*, *йастыҡ-мендәр*) һәм күрше төрки (казакъ, нугай) телләр белән уртак (*шара табак* – зур табак, *тәсхан* / *тәсторхан* – скатерть, *ҡуншы* – күрше), сүзләрне аерып күрсәтергә мөмкин. Алынма сүзләр дә күп: *бидрә* – чиләк; *кәтәйкә ағачы* – сырлы бәләк; *эспичәк* – шырпы; *манит* – акча санау берәмлеге, сум, тәңкә: *Йалғыз кишәкләр* (киленчәкләр) *биш йөз манит ташлыйды туйда* һ.б.

***Аш-су атамалары:*** *аш эчү* – аш ашау, *тамаҡ* – ашамлык, ризык.

Юрт татарларына үзенчәлекле камыр ашлары хас: *ҡатланчыҡ* – юка итеп җәелгән камырларны 3 катлы итеп бөклиләр дә рулет кебек итеп урыйлар, аннан соң кисәләр; кисеп ясалган йомры камырларны җәеп, уртасына *эч* салына һәм бөкләп куеп пешерелә.

*Питер* – табада өстен каплап пешерелә торган камыр ашы (чагышт.: себ. *пәтер* – табада, мичтә пешерелә торган ритуаль камыр ашы – төче күмәч).

*Қузбүрәк* – эченә ит салынган пәрәмәч.

*Лақсалба* – камыры токмач кебек кисеп катырылган чәкчәк.

*Пахлава* – чикләвекне бал, он һәм ак май белән болгатып пешерелгән татлы ашамлык.

*Нуғай мәлеш* – дөге һ.б. өстенә 1 кат ит куеп пешерелгән бәлеш (җирле халыкның милли һәм ритуаль ашамлыкларыннан берсе): *Кийәү сыйда унаулаган, умбишәүләгән нуғай мәлеше бароды.*

*Баздамгөл* – татлы камыр ашы, кекс.

*Пирүкләр* – пироглар, *баwырсақ* – әдәби телдәгечә.

*Бадамгөл* – йорт шартларында әзерләнеп пешерелгән, прәннек тибындагы татлы ашамлык.

*Картуф қалач* – ваклап туралган, майлы табада мичтә пешерелгән бәрәңге (*Қартуф қалач пешерә идек табада салып, май салып, пичтә пешә*);

*Турамжа* / *турамша* / *турамча* – итле, камырлы ашамлык (бишбармакка якын): *Турамша бездә бер шара табақ* (зур табак). *Турамчаны нәлбәкләргә* (тәлинкәләргә) *салып бергә ашыйлар.*

*Шикәр чүрәк* – рус. песочное печенье

*Тилди* / *картуп тилди* – чапкы белән чабылган (*тапалган*) бәрәңгене, он кушып, табада майда пешергән ризык.

*Қайнарый* – әд. пәрәмәч.

Қайнарый, қайнарый,
Ашый Казан байларый.
Ашамас ийе қайнарый,
Тамып тора майларый.

*Күк чәй* / *самовар чәй* – чәй, кара чәй; *қара чәй* – қалмык чәе.

*Әнкәл салма* / *өнкәл* – бишбармак (һинд, санскрит телләреннән үк килә торган сүз).

*Таба йаппа* – бәрәңге һәм кабак турап, табада майда кыздырып әзерләгән ашамлык.

*Туғаш* / *туғач* – крендель, бублик (себер татарлары диалектларында да шулай әйтелә).

*Күмәч* – төче күмәч, *мерәппе* – варенье, *шүлә* – ботка, *қамыр аш* – токмач.

***Кием-салым атамалары.*** Аларның зур күпчелеген хәзерге заман өчен хас булган киемнәрне белдерә торган алынмалар тәшкил итә: *куртка, пал'то, шапка, сапук, пиршәтке* – перчатка, *бәрек* < вареги – бияләй, *ванйек* – валенок, *төпли* – туфли, носки, *фартык* – фартук, *фуфайкы* – мамыктан сырган, уртача озынлыктагы кышкы кием, *чиребәк* < рус. черевики – юка күн итек (сапожок), *бурчын* (рус. порошня) – тиредән тегелгән аяк киеме, *биспәт* – бишмәт, *қаптал* – өс киеменең бер төре, *китән* – тукыма, *арқалық* – камзул.

Күлмәкнең фасонын һәм өстәмә бизәкләрен белдерә торган рус алынмалары татар теленең башка сөйләшләре белән уртак: *татйанка*, *кәкиткә* (кыска кыса), *абуркы* – балаитәкле кием, *йазғы күләк* – җәйге күлмәк (*йазғы күләккә йақа салынмый*).

Күлмәк һәм аның төп өлешләре гомумтөрки сүзләр белән белдерелә: *итәк, җиң, озын җиң, кыска җиң, йаға* – яка, *күкрәкчә* – 1) эчке күкрәк, 2) изү (бизәнү әйбере);

Диалектизмнардан тагын түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин: *күләк* – күлмәк; *чөлкә* – оек; *нәзек чөлкә* – базар оегы; *җыйылған* – бөрелгән; *сенәпит* / *сөнәпит* – арка-күкрәк өчен җиңсез кийем; *пәрәзә* (< ? пәрәнҗә): *Пәрәзәләре булған, битне күрсәтмәгәннәр*; *тун* // *өлкүн тун* – толып; *тақыйа* – башлык; *чибәк* – чүәк; *балтыр* – куныч; *ату* – читек.

*Шәл* / *шал* – шәл; *пинзел шәл* – кабарынкы бизәкләр белән бәйләнгән, озын чуклы ефәк шәл; *өлкөн шәл* – зур шәл, чана шәле; *пупсик шәл* – юка шәл; *эрислы* (*?*) *шәлләр* – мамык шәл; (наски) *туқу* – (...) бәйләү; *түбәтәй; йатақ* – бүрек; *паутинка печү* – кисү (*Үзе печеп, үзе тегә ике-бер* (кайбер) *кеше*); *кәпәш* – бала башлыгы (*Кәпәшкә томар тегеп қуйа даған, күз тимәсен дип*)*; төлке тамақ тун* – төлке тамагы тиресеннән тегелгән тун; *мата* – мануфактура.

***Бизәнү әйберләре:*** *буси* – муенса; *сырға* – алка; *тутый* (< рус. дутый) *беләзек; қалпақ* – калфак; *қазан қалфақ*; *тәңкә* – чәчкә тага торган бизәнү әйбере (*Чәчләренә тәңкә тағып йөрегәннәр*)*; санҗақ* – брошка; *бажақлы* – алтын тәңкә; *дутый беләзек* – гади пыяла белән бизәлгән беләзек.

Сөйләштә чулпыны белмиләр.

***Үсемлек атамалары:*** *көзлөк* – курпы, *бөлдергән* – ежевика, *ийер* – аир болотный, *ашыбуйақ* – гусиные лапки, *севәтә* – рус. солодовник, *қызыл ут* – алабута (ширица), *чәнчәкәйле* – шайтан таягы. *Түбәсендә* (очында, башында) *сиреневый гөле үсәде; ут* – үлән,

чүп үләне, печән; *чигү* – (тәмәке) тарту; *нубыйа* – фасоль. *Аш* (ач) *wақытта тәтле тамыр ашадық, тамырны йықалыйбыз* (?), *чемәтәйләрен* (кечкенә ботакчыкларын) *киптереп ашап йөрәймез кесәдән; муйа* / *мыйа* – солодковый корень. *Тирәк* – агач, *чақан* – 1) камышның бер төре (чагышт.: тепекәй сөйләшендә *җикән* – камыш), 2) кипкән камыштан үргән маты; *җикән* – рус. рогоза, *байтирәк* – тополь, *қызыл гөл* – рус. шиповник, *қуз тирәге* – чикләвек агачы.

Чыгышлары ачык булмаган сүзләр теркәлгән: *батраш* / *патраш* – бөтнек, бөтнектән ясалган аш тәмләткеч, *шыбыт* – укроп, *көзлек* – курпы, *бөлдергән* (< бөрлегән) – кара кура җиләге, *қыйақ* – күрән, кыяк (рус. осока), *чормаwық* – эт эчәгесе, *қурай чәй* – чәй үләне (*Қурай чәй маштақ* (тәбәнәк) *қына булыб үсә*).

Яшелчә атамалары, нигездә, рус алынмаларыннан тора: *қапыста* – кәбестә, *мәркү* – кишер, *севикла* – чөгендер, *мадур* – помидор, *карту* (к, п, ф) – бәрәңге, *түтник* – тут, *арих* – чикләwек, *қабақ* – кавын, *киртмә* – кыргый груша.

***Хайван атамалары:*** *тәwә* – дөя, *йолдыз* – кашка (маңгайдагы), *қуй* – сарык, *иркәк қуй* – тәкә, *орғачы қуй* – ана сарык, *боға* – үгез, *кукук* – кәкүк (*Кукук қычқырыпты, йаз* (җәй) *килә*)*; кәчек* / *кәшек* – көчек, *семә* – көя, *су күсесе* – ондатра, *мышық* – песи, *қачар* – тана, *бура* – ата дөя, *тана* / *тәнә* / *тәнәкәй* – тана.

*Турғай* – чыпчык (бу үзенчәлек белән сөйләш Себердә һәм Урал төбәгендә таралган сөйләшләр белән уртаклык күрсәтә: *қара тургай* – сыерчык); *баллы гүбән* – сагызак, *қутан* – челән (рус. цапля), *аққу* – аккош, шийре шыбын // шийре чыбын – озынборын, *суна* – кигәвеннең бер төре, *шәwел* – күсе, *лақ* – кәҗә бәтие, *қураз* – әтәч, *қузы* – сарык бәрәне, *ичке* – кәҗә (шулай ук себер татар диалектларында да) һ.б.

***Терек булмаган табигать белән бәйле сүзләр:*** *ақырған суwық* – чатлама суык; *күк көлтөрәү* – күк күкрәү; *йерик* – ерым, ерганак, елга тармагы; *түбә* – тау, *Йарлы Түбә* – ярлары булган тау түбәсе; *йаға* – елга буе; *үр* – Иделнең (Волганың) югары агымы күздә тотыла (*Безнең бабалар үрдән килгәннәр*)*; сәрен* – җиләс, *Хәсән-Хөсәйен җәйәсе* – салават күпере.

Юрт татарлары сөйләше өчен үзенчәлекле булган сүзләр: *машиқ* – шамаиль, *саз* – гармун, *саз тарту* – гармунда уйнау, *сенәпит* – җиңсез, камзул, *бадымҗан* – баклажан, *қызба* – бизгәк, *нубыйа* – фасоль, *сөргән* – фуфайка, *қайры* – песок, *тил* – тимер

чыбык, *кылау* – ширпы (рус. заноза), *утлыҡ* – көтү йөри торган җир, *эке* – бәке, *кыба* – чабулык?

Сөйләштә әдәби телдән мәгънәләре белән аерылып торган сүзләр дә бар: *кирәмәт* – әкәмәт, могҗиза; *дуwадак* – эшлексез, эшләмичә килеп сарып йөргән кеше турында.

**Нәтиҗәләр**

Шулай итеп, юрт урынчылыгы татар диалектлары системасында үзенчәлекле берәмлекне тәшкил итә. Төп сыйфатлары белән ул урта диалектка карый. Алай гына да түгел, әлеге диалектның борынгылыкны аеруча нык саклап килә торган реликт характердагы нократ, пермь, касыйм, керәшен, бәрәңге сөйләшләре белән уртаклык күрсәтә: инфинитивның *-мага*/*-мәгә, -ма*/*-мә* формасы, тартым кушымчасыннан башка ясалган исем-исем сүзтезмәләре (*кийәү сый, ҡыз биттә* – кыз ягында), боерык фигыльнең *-ң*/*-ең* формасы (*борың* – борыгыз).

Күрсәтелгән сөйләшләр белән уртаклык булу әлеге сөйләшләрнең бер вакытта формалаша башлаулары, кайчандыр бербөтенне тәшкил иткән булулары турында сөйли. Минемчә, хәзерге юрт татарлары чыгышлары белән Әстерхан ханлыгын тәшкил иткән төрки халыкка барып тоташалар. Билгеле булганча, әле ул вакытта нугай дигән исем астында берләшкән халык булмаган.

Бер төркем үзенчәлекләре белән юрт урынчылыгы себер татар диалектлары белән уртаклык күрсәтә. Биредә шуларның кайберләрен күрсәтеп үтү урынлы булыр.

III зат хәзерге заман хикәя фигыльнең өстәмә *-ды*/*-де*/*-ты*/*-те* кушымчасы белән әйтелүе. Билгеле булганча, әлеге элемент борынгы төрки телнең хәбәрлеге *тор-* фигыленә кайтып кала һәм татар теленең көнбатыш диалектында *-дыр*/*-дер* (*ул кайтадыр да...; бу хат миңадыр*), мордва-каратай сөйләшендә – *т* (*баратлар* – баралар, *күрәтләр* – күрәләр), себер диалектларында *-ды*/*-де*/-/*ты*/*-те* (*бараты, киләте* һ.б.) вариантларында сакланып килә.

Шулай ук *-а даган*/*-ә дәгән*, яки тагын да кыскартып *-а тан*/ *-ә тән* дип әйтелүе ягыннан да юрт һәм себер татарларының сөйләшләре үзара уртаклык күрсәтәләр.

Тубыл-иртыш диалекты сөйләшләрендә катлаулы *-ганда* формасының уртасында тартым кушымчалары кулланыла (*барганымда очраттым* – барганда очраттым һ.б.). Юрт урынчылыгында да

шундый ук үзенчәлек күзәтелә: *Бусаға атлап кергәнемдә* (кергәндә) *ақ җәйәделәр.*

Әстерхан татарлары сөйләшендәге эчке теләкне (әд. барасы килә) белдерә торган *-гы килә* формасы да татар теленең себер диалектларында күзәтелә, шулай ук ул көнбатыш диалектка (*-гы келә*/ *-ге кели*) да хас.

Өйрәнелә торган сөйләшнең себер татар сөйләшләре белән уртаклыгы лексика өлкәсендә дә күзәтелә. Мәсәлән: *питер* – кабартма, себер диалектларында *пәтер* – төче күмәч; *туғач* / *туғаш* (юрт урынчылыгында) – 1) кабартма, 2) төче күмәч; тобол һәм саз ягы сөйләшләрендә: уртасы тишек итеп пешерелгән камыр ашы (баранка); *арыш* – юрт сөйләшендә дә, себер татар диалектларында да тәртә мәгънәсендә; *қойын* – өермә (сөйләшләрнең икесендә дә шул ук мәгънәдә), юрт урынчылыгында бу мәгънәдә тагын *шайтан уйыны* тәгъбире дә кулланыла (чагыштыр: әдәби пәри туе – 1) буран, 2) өермә).

Себер диалектлары белән уртаклыкларны дәвам итәргә мөмкин. Мондый хәлнең нигезендә борынгы заманнарда булып узган тарихи бергәлек, уртак кыпчак нигезе ятуы мөмкин. Себер татарлары диалектлары белән охшашлык казакъ теле аша да барлыкка килгән булуы ихтимал. Юрт урынчылыгы фонетик системасы белән дә татар теленә якын тора. Моны да татар теле йогынтысы дип кенә аңлату дөреслеккә туры килеп бетмәстер. Чөнки Идел буе татарларының авазлар системасы мең еллар буе үзгәрә килгән, ә сөйләшләрдә борынгы вокализм хәзер дә әдәби тел белән тәңгәл килеп бетә алмый. Мәсәлән, нократ сөйләше моңа ачык мисал булып тора. Шулай итеп, юрт урынчылыгы авазлар системасының үсеш-үзгәреше көнбатыш диалектлар белән борынгы чорда ук бер дәрәҗәдә булганнар. Нократ сөйләшендә борынгы төрки вокализмның тоткарлануы сөйләшнең изоляцияләнгән булуы (һәм бәлки борынгы бичырманнарның да катнашлыгы) белән бәйле булса кирәк. Ә юрт татарларына казан татарларының көчле йогынтысы Казан ханлыгы җимерелгәннән соң ук башлана, аларның юрт татарларының формалашуында зур роль уйнавы, халык арасында сөйләнә торган риваятьләрдә генә түгел, кабер ташларында да чагылган.

Юрт татарлары сөйләшенең формалашуында әһәмиятле моментларның тагын берсе – аларның казакълар белән бәйле багланышлары. Бу багланыш уртак географик даирәдә бик борынгы чорлардан

килгән, аларның уртак чыгышлары белән бәйле, тарихта Әстерхан ханлыгының көнчыгыш чикләре турында мәгълүматлар бик үк ачык булмаса да, Әстерхан ханлыгында билгеле бер төркем ыру-кабиләләр калгандыр, дип фараз ителә, чөнки экспедиция дәвамындагы күзәтүләр буенча юрт татарлары белән казакъларның антропологик яктан аерылып торулары турында фикер йөртеп була.

Югарыда күрсәтелгән себер татарлары диалектлары белән юрт урынчылыгы арасындагы параллельләр барысы да казакъ телендә табылалар, ягъни аларның икесенә дә казакъларның йогынтысы тәэсир иткән, әмма ул бертигез дәрәҗәдә булмаган. Әдәбиятта юрт татарлары белән казакъларның (көнбатыш казакъларның) бәйләнешләре чиктәшлек шартларында гына булган. Мәсәлән, андый бәйләнеш турында сүз йөрткәндә Володарский районындагы Тулугановка, Идел буе районындагы Киләче (Килинчи) авылларын мисал итеп китерәләр (Л.Ш. Арсланов. О взаимодействии языков карагашей и юртовских татар (ногайцев) с казахским языком // Советская тюркология. 1986. № 5. 11–15 битләр). Тагын шунысы әһәмиятле, үзенең хезмәтләрендә автор юрт татарларын «Юртовские татары (ногайцы)» дип күрсәтеп бара (тагын кара: Арсланов Л.Ш. О влиянии языка юртовских татар (ногайцев) на язык татар Наримановского района Астраханской области // Вопросы татарского языкознания. Казань, 1978. – 107–119 б.) һ.б. Ә юрт урынчылыгы вәкилләре үзләрен без элек татар идек, хәзер нугай инде дип атыйлар. Әлбәттә, соңгы еллардагы милли көрәш юрт татарларының үзаңына көчле тәэсир иткән.

## Авыллар тарихыннан

Бу аwылға 1690–1700 йылларда нигез салынган. Бимәскән булған йырақ (*борынгы*) исеме, билдән өскән дигән сүз. Монда Шайтан таwы, Урта аwыл диләр. Җәмәл йерик (*ерык, су яки елганың тармагы*) белән ике арасында. Без, қартлар, нуғай дибез үзебезне, татарлар без, хәзер нуғай диләр. Без йүкәйақлар, қазан татарларын шулай атыйлар, аларның айақларында чабата булған. Қырығашар (*үлән исеме*) – қырығачар – қырық төрле аwырудан дәва, җиде көн буйы эчергәннәр.

Әвәл энҗе қалфақ булған, қазан қалфағы. Бездә киит бирәделәр, килгән қунақларға бүләк булады ул. Өндәүче байанды (*килиннең аяк астына җәелә торган ак яулык*) бастыра. Киит бирер алдыннан

байанды бастырып чығалар. Киит бирерлек булғач ақча чәчелә. Халыққа чәчәләр, халық аны җийып тора. Безгә дә шундый туйлар насыйп булсын, дигән сүз инде у, диб әйтә тәгән иде Сәйрән әби.

Сәйрән әби китабын да уқый иде. Тарихчылар беләдер инде аwылның тарихларын, үрдән (Иделнең югары агымыннан) килгәннәр дип сөйләйләр иде.

Бу бүрек, йорт татарлары без, бу безнең бүрек. Җәмил диб әйтелә. Безнең аwыл, ин беренче Җәмил килгән. Җыллар үтә-үтә Җәмәле диб әйтеп башлыйлар.

XVI ғасырда сәйәхәтче Кристофер Берроу аwылның йануын күргән. (Шуннан чыгып) аwылга 500 еллар дип саныйлар. Алабуғат татарларының Сүләңкә аwылы Нуғай ханның ыставкасы булган, шунда қала чатыры булған, мишәрләр диб әйтәбез без аны.

Кендекле дигән күлебез бар. Шул Кендекле күленнән кен аша Ғаптулла Туқайға қымыз ташып эчерәделәр.

*Сөйләүче: Гомәрова Мәйсәрә*
*Хәким кызы (1936 елгы).*
*Җәмәле авылы*

Татар Башмакуфка әтәләр, үземесчә Қызана диләр. Бер ананын қызы қашып киткән. Кемдер утырғызып озатқан. Анасы эзләп килгән, киттек дип. Бу китмәгән. Кем дәт (*нәрсә*) белә шуны сөйли. Қыз көйе баласы туған аның, түбәдә йәшәгән ул.

*Сөйләүче: Бикбулатова Мәгърифә*
*Сәйфулла кызы (1939 елгы).*
*Кызан авылы*

Йарлы Түбә бедный дигән сүз түгел, ә йарлар бар дигән сүз. Йар сүзеннән ул Йарлы Түбә. Бездә тағы Ашантау Түбә дигән йир бар.

*Сөйләүче: Ильясова Халидә*
*Фәрит кызы (1938 елгы).*
*Кызан авылы*

Қартузан аwылы бар, қарт узған дигән сүз ул. Қарағалық – қара халық дигән сүздән. Қызан – өлкүн (*зур*) түбә (*калкулык, тау*). Хан түбәдә ханнар торған, сал белән йөри торған булғаннар. Қызан қызана у, қызлый ана булып қалған. Өйеннән чығып китеп, қайыққа утырып Қызанға чыға.

Кушаматлар: Қуқанай, Сыры Бука(н), Тычқаннар, Аққалле, Бибжорнай, Бабаларымыздын тамғалары балта булған. Урамны

(зиратта кабер рәтләре арасындагы юл) қалдыралар халыққа йөрү өчен, белә торғандырсыз. Қарағалык аwылы урамнары: Кирийет, Қымшақ, Қарағалық.

*Сөйләүче: Бирдиева Рухия Хөсәен кызы (1928 елгы). Каргалык авылы*

Шушы урамда ана у өйдә үстем мин. Өйөбез зур инде. Қуша бирдек, ақчаға қарап әкрен қуша бирдек. Балалар үсә бирде, кийем кимәдек, өйөбез булсын, өйөбез булсын, қаңғып йөрмийек андамонда дип.

Бабайым үлде, пинсийәгә дә чықмады ул, илле туғызда үлде. Соңға таман аwыр эш йарамады. Беригадта эшләдек, ут (*печән*) чабамыз, суған үстерәмез, мадур (*помидор*) үстерәмез, қыйар үстерәмез. Суғыш заманда йәш қызлар булып эшләдек. Оркыйа тәтә, мин, Әминә, Хәйәт, без алты-җиде қыз бергә эшләдек. Мондый тәкле эсвикла үстерәмез, шуны күтәреп қайтамыз өйгә, айва белән қушып пешерәмез, варинйы кебег үк булады.

Суғыш wахытта wайынныйлар капыста төйәп китәделәр машин-машин, қартуп қазып йәрдәм итеп тордоқ шулай. Аннан болай табак үстердек, тәмике. Тәмикеләрде арба белән эпкилеп саладылар өйгә, менә шуны киптереп, таwып, тәмәг итеп заттық (озаттык).

Әрбер өйгә кереп першәткәләр туқытамыз (*бәйләтәбез*) салдатларға. Шуларны җыйып чығамыз без. Силсәwиттә дижурыт итәмез ике қыз, бер бала (малай).

Суғыш wақытта чиләк-чиләк тутник җыйып, йәшел алма белән қайнатып қалачны манып ашаймыз. Аузыбыз-мырнымыз қап-қара.

Балық ашадық. Ул заманда балық күб иде, хәзер йуқ. Әле дә тотамыз йағада (*елга буенда*). Биш бала, бер қыз үстердем. Алланың биргәненә шөкөр, пинсийә биреп йатырлар. Ашағаны алдында, ашамағаны артында, ит ашыйсын да май ашыйсын, Алланың биргәненә шөкөр. Қаймағ ашыйсынма, сөт ашыйсынма, теләгәнен ашыйсын, таwығ ашыйсынма, қаз ашыйсынма. Түлке қызыл балықлар ашый алмыйсын, қара икралар да йуқ хәзер, төшкә дә инмиләр (*кермиләр*). Миган (*миңа*) икәү-өчәү йибәрәдер әнә у Исхақ. Айағым аwырмаса йағада үзем дә тотар ыйым. Тездән айақларым йөрми. Өйдә йөрәм қыбырдап, тиз утырам. Мадур қәзер әүләдә (*ишек алдында*) үсә үземездә. Беригат йуқ қәзер, әркем үзенә эшлиде, суған үстереб атырлар (үстерәләр). Ат үстереб йатырлар

үзләренә, сийыр үстереп, қалқуз да йуқ, фирме дә таралды. Йәшләр бөтенесе қалаға киттеләр эшләмәгә.

*Сөйләүче: Нурмөхәмәдова Сафура*
*Абдулгазиз кызы (1927 елгы).*
*Киләче авылы*

Йоқла, балам, йал ит бераз,
Рәхәт үтәр көннәрең.
Зур да булыб үсәрсең,
Илгә файда итәрсең.
Илгә файда китергән баладан
Мин дә рәхәт күрермен.

Безнен әбиләр балаларын шулай уқ қараған wахытында әйтәләр иде.

Зур үс, балам, зур үс, зур үскәч сиңа
Туйлар йасарбыз.

Дүрткел чатыр қордырып
Түгәрәк қазан қаздырып.

Җиргә қазан қазыганнар, ике қазан, өч қазан, бик күп кешеләр җийганнар. Менә шулай иттереп туйлар йасарбыз, дип балаға. Кечкенәдән қолақларына керә торған булған. Алар инде қачан булса да үзләренә тормыш қорыр өчөн әзер.

Җирле халық мона без, нугайлар. Йуртовски татарлар, татар булғамыз инде.

Қала татарлары күбесе мишәрләр, Идел буйыннан килгәннәр.

Ғаптулла Туқайға шунда, Сүләнке аwылына барып Кендекле күленнән көн аша қымыз ташып эчерәләр. Матурайып, битләре нурланып қайтып китә Қазанға.

Безнең мамалар әйтә иде, кеше килсә – ит пешә, ит пешмәсә – бит пешә. Ашыңны бирмә, қашықны бир, диләр, йезеңне аш (*ач*) дигән сүз.

Мамабыз бик ғайрәтле кеше булған, өйдә кийезләр йәйә торған булған, идәнгә дә, сәкеләргә дә йылылығ өчөн. Пажарда түбә башына шул кийезләрне йаптырғаннар. Әтийем сүләде, шул кийезне йаwып пажардан алып қалғаннар. Әтийем ул wақытта бала wақты була.

*Сөйләүче: Ибәтуллаева Шәһәрбану*
*Хөсәен кызы (1923 елгы).*
*Җәмәле авылы*

Қартузан дигән аwыл қайан килгән? Ул wахытта бөтен аwыл қатыш булған, торорға жир булмаған, аwыр тормыш инде. Патшалар заманында инде. Әтийем сөйләгәне буйынча, бер ыру Қазан йақтан инде, йөри-йөри шушы Қартузан биткә килеп чығалар. Утын йуқ, қамыштан башқа зат йуғ иде. Бер қарт әйтә, мин китийем, барған йиремдә қамышны бәйләп китәрем. Бер көн торалармы, күп көн торалармы? Қартны эзләп китәләр болар. Килеп чығалар, йаға монда. Су. Сунын йанына килеп чығалар. Шунда қамыш бәйләнгән бетә. Бабай йуқ. Қар тузған жиргә килеп чығалар, аwыл булып қала шуннан. Без – татарлар, ыруыбызны белмим инде мин, татарлар без. Без ыруларны белмибез. Безгә ыру билге сорнай. Ыру бәлки булған дадыр. Шунда тордык, өч абийым бар иде.

Қарағалықмы, қара халықмы, белмим. Қарағали аwылы қайдан килеп чыққандыр. Алар қап-қара, чын нуғай инде. Ә Қызанны ишеткәнем бар. Қызанда түбәләр күп. Мин үзем Қызанда туwыб үскән. Минем әни күчеп килгәндә утыз бишенче йылны, Қызаннарның теленә төшөнми иде. Нуғайлар күчмә булғаннар инде. Қазақларда да ыру булған. Безнең қайнатам әйтә йе, балта тамғалы без дип, аларны қарағашлар дигәннәр. Қәберләренә дә тамға салғаннар. Шул тамға белән белгәннәр, ә-ә бу безнен ыру икән, дип.

Қызанның түбәсе бөткән. Анда һәркем ыруы белән күмә торған булғаннар. Хәзер урам-урам (*рәт-рәт*) инде қәберләр.

Қарагач дигән аwыл бар. Қайнанам әйтә иде: «Қазаныдан қыз алдык, Батағадан тыз алдық». *Батаға* русча ватага дигән сүздән, балық тотқаннар алар инде. Әнийем тик қарап уқый иде, йазып белми иде. Алар тере ди тимер көрәкне.

*Сөйләүче: Бирдиева Рухия*
*Хөсәен кызы (1928 елгы).*
*Каргалык авылы*

Элег анда қаннар (*ханнар*) торғаннар. Түбәнең берсендә – бер қан, берсендә бер қан торған. Берсенен олы булған, берсенен қызы булған. Қызан булмаған ул wахытта. Болар инде бер-берен йараталар. Шуннан, ничектер, суғыш башлана. Әстерхан биттәме, анысын белмим, суғыш башлана. Қызан булмаған әле ул wақытта. Салдан күпер йасап чыға торған булғаннар. Шунан суғыш башланғанда қызның иркәсе– йегет суғышқа китә. Суғышқа киткән wахытта қыз буйында булып қала. Ул инде анда торырға ойала, этиләре-әниләре

алнда (*алдында*), һәрwакыт йылап бу йаққа килә, шушы судан чығып иптәше суғышырға китә, и қыз да һәрwақыт шушы суға йылап килә инде. Монда сал белән генә йөри торғаннар булып тора.

Бер көннәрне үзенең салашын йасый бу қыз. Шунда бәбәйли. Ә йегет суғышта үлә, қайтмый. Шунда әйтәләр, қызлый ана булып қалған. Шуннан қызана, қыз ана дип қалған. Шуннан Қызан аwылы булып қала.

Әле дә бар әле ул Хан Түбә. Маниталар, тағы ни затлар табадылар.

*Сөйләүче: Бирдиева Рухия*
*Хөсәен кызы (1928 елгы).*
*Каргалык авылы*

**Йорт-җир, хуҗалык эшләре**

Алар күчмә халық булған. Иртә торғач менә болай қарыйсың, әйеме, агач та йуқ. Менә монда бер нинди ағач та йуқ. Бернинди йорт та булырға тийеш түгел. Шуның өчөн төп нуғай аwылларында бернинди ағач та йуқ. Нуғай халығы шуның хәтле эшчән халық. Аларның түтәлләре шул хәтле тигез эшләнә. Йоморқа тәгәрәтеп қарағаннар, хәтта биш тийеннек ақча тәгәрәтәләр, ул туктамыйча барырға тийеш булган. Шунда ғына түтәл йақшы эшләнгән.

Су бер җирдә күбрәк булып, икенче җирдә су бармый, җире йуғары булып қалса, иген уңмый. Өйөлгән җирдә дә булмый, сулы җирдә дә уңыш булмый. Шуның өчөн ул тигез барырға тийеш.

Менә монысы бу баштан теге башына хәтле такта була, ә монысы күсәм диб атала. Йул – ағадан, су – сағадан, диләр. Тегендә сага ачыла, су килә. Менә бу каналлардан су йөри, ышлангы белән су сипмиләр. Бер җирдән ачалар, икенче җирдән йабалар. Менә болары чик диб әйтелә. Башта берсен ача да су тула. Ябалар, аннан сун икенчесен ача, су тула. Менә қызым ике тактасына су бирде. Шундый урындық бу, утырыб ут утыйбыз, утырғыч.

*Сөйләүче: Гомәрова Мәйсәрә*
*Хәким кызы (1936 елгы).*
*Җәмәле авылы*

Әүләдә (ишегалды) сәрен (җиләс) булды.
Шайтан лампы – сукыр лампа.
Кәтәйкә ағач – сырлы бәләк

Қазан өй – ишек алдында җәйге кухня.

Қызнын затлары күп булады: йастық, түшәк, тастымал, тәрит йаулық (*сөлге*), сандықта. Җир түшәге (*җиргә җәя торган қиез*), сырдақ (*сырылган вак-төяк киез һ.б.*), тәсхан // тәсторхан (*скатерть*). Чигү чиккәннәр қызлар. Йөзләренә йаулық кебек йапқаннар, тәрәзәләре булган, битне күрсәтмәгәннәр.

Картун чәчәмез, анан эстенә сыу җибәрдем. Үсә төшкәч өйә башлыйсын. Үзебезнен күсәмгә (*бакчага су кертү өчен махсус әзерләнгән канау, су юлы*) килеп төшә су, вадагунны ачасын, күчәмен ачыб-ачып, сыу ачабыз, әйтәбез. Бүгәтләрен (*түтәл арасына су керүне туктатып тора торган балчык өеме*) ачамыз да – речка ул, йагада балық тотам дип сөйлисен. Үсемесен телчә йаға, колодец булса қыйы дибез. Йирне чик-чик (*сугарыла торган җирнең биегрәк итеп өеп ясалган читләре*) итеп йасап су салалар.

*Сөйләүче: Бикбулатова Асия*
*Абдразак кызы (1937 елгы).*
*Ярлы Түбә авылы*

Саман (өйне) дүрткел кирпечләрдән йасыйлар, сәке, ничек тора булганнардыр. Читән диләр, йатқызып үргән, җикән қамышыннан үргәннәр. Өйне дә қамыштан салғаннар. Қамышны нәзек көлтә итеп бәйләгәннәр, аларны тезеп қуйып ике йақтан рейка белән қысабыз, аннары ике йақтан да сылыймыз. Шул өйне тақта белән, таш (*кирпеч*) белән апшивайт итү дә бар. Мона шул өйнө боздық, монда китереп салдық.

Дусым әти, дусым әни бар иде. Өйләренең ыстиналары да қыйшық иде. Бу борынғы пластин (*бүрәнәне калын итеп ярып ясалган такта*) өй. Қайсы қамыш маты кебекне ике йақтан шул пластин менән қысып тыштан сылый. Бер-берләп тараттық ул өйне. Күргегез килсә, тактамбитләр (*сәкеләр*) бар. Стенаны әклиләр (*агарталар*) иде әк (*акбур*) белән. Түбәдәге балкун бит инде мансарда, тақтадан чарлақ йасалған, қалада мансарда, безчә, үсемесчә чарлақ, бала (*кечкенә*) чарлақ. Қура – абзар.

*Сөйләүче: Бирдиева Гөлфәридә*
*Дуллаян кызы (1939 елгы).*
*Ярлы Түбә авылы*

Өйне торғызу (*өй күтәрү*) аwыр эш. Соуқ кермәсен өчен эргә сұқтық. Йаңы өйгә Қоран уқыта торған ийек. Өстәлгә нуғай мәлеш

бирә торғаннар иде. Нуғай мәлешнен итен салалар тозлыққа, суған салалар, пешерәләр. Нуғай бәлешне пешерә белмәгә кирәк. Анын оста пешерүчеләре бар.

*Сөйләүче: Абрахманова Зәйнәп*
*Шабан кызы (1926 елгы).*
*Майлы күл (Мәйле күл) авылы*

Әүwәл җиделек лампы, сәке diләр сездә, без тақтамбит, қуншыларға (*күршеләргә*) барып торамыз. Лампа шешәләре (*пыялалары*) булды.

Ағач сабан иде. Җирне тырнаwыч белән бороновайт иттек. Кирпән (*китмән*) белән эшлибез, тере (*тимер көрәк*) мән (*белән*) қазый идек.

Бағанаға (*матчага*), арқалыққа нық ағач кирәк, пыластиннан (*калын итеп ярылган такта*) қуйғаннар. Май қарағайдан (*сагызлы нараттан*) салғаннар, арқалыққа (*матчага*) пластиннар салғаннар. Өйләре ике йақлы иде, кылидурда чапрач (*баскыч*) бар иде йуғарыға менмәгә. Бала чарлақлы өй (түбәдән чыгып торган чарлак, мансарда).

Қартузан – авыл исеме, карт узған дигән сүз. Қарағалық (*авыл исеме*) – кара халык, Қызан – Өлкән Түбә // Хан Түбә (?), кыз ана – кызлый ана булып қалған.

*Сөйләүче: Бирдиева Рухия*
*Хөсәен кызы (1928 елгы).*
*Каргалык авылы*

## Тормыш-көнкүреш турында

Уналтыда эшләмәгә тотындым, пинсийәгә чыққанчы эшләдем. Севикла үстерәмез, қапыста үстерәмез. Төйәб алып китәделәр машин-машин. Өлкән-өлкән тәмикеләрне киптереп, шаwып (*чабып*) әпкитәделәр. Төн буйына пишәткәләр туқыдық. Тамақ (*ризык*) йуқ ашамаға. Түтник ашамаға китәмез, аwызымыз, морнымыз қап-қара түтник ашап. Түтникне төйөп қалачқа йағып ашыйбыз. 5 бала: 4 малай, 1 қыз үстек. Балық тотпаға йаратам, төшкә дә инмиләр инде қара икралар. Мадур қәзер үземездә үсә. Қәзер әүләдә мадур үсә, суған үсә.

*Сөйләүче: Курманова Нәсимә*
*Насыйр кызы (1939 елгы).*
*Киләче авылы*

Сонға таман эшләп башладым: ут чабамыз, қапыста үстерәмез. Шулай эшләмәгә тотындым. Орхийә тәтәң (*апаң*) мондый такле (*хәтле*) эсвикла үстерде, кәртүк қазып утыртамыз. Тәмике үстерәмез, анамыз чаwып торады.

Төн буйына дижурит итәмез, пишәткә (*рус. перчатка*) туқытамыз (*бәйләтәбез*). Атамаға йуқ суғыш бит, түтник (*тут җимеше*) ашап аwызлар қап-қара булады. Әле қалачқа йағып ашиймыз түтникне.

Дөге урамыз көзнең көне. Тамақ пешерәде, барады ике-бер балыққа. Қамыш үсәтәгән битләрдә (*җирдә, якта*) дөгө чәчәләр.

Әүләләрдә қул белә эшлиләр, әкушит итә (*төбенә өя*). (Улым) сүләмит тә (*сөйләшми, киңәшми*), нитмит тә, өч кәрәм (*тапкыр, мәртәбә*) алып китте мадурны (*помидор*). Киткем килмиде, ди. Миған (*миңа*) мишәйт итмиде, әүләгә ике-өч шатыр йасапты (*өсте ябулы урын, помидор, кыяр үстерү өчен*). Қызына күмәг итмәйде (*ярдәм итми*). Ике тақта (*полоса*), эчендә 10–12 грядка. Йафрақларын мал ашайды, қатлықны (*терлек ашаганнан калганын*) йағабыз. Чалғы белән чалабыз (*чабабыз*) утны (*үләнне*), урақ мән дә урғаннар. Қазанда да чалалар печәнне чалғы белән. У заманда мынди плитәләр йуқ, қычқыч (*кыскыч*), күсәнкә (*кисәү агачы*), таш (*кирпеч*) пич. Ырисур арбада йерәмез эшкә. Тарантас қалада була, читләре, тәгәршекләре (*тәгәрмәчләр*) нәзек.

Атларда пастук булыб эшләдем, өч йөз атқа. Йануwарда ақырған (*ыжҗгырган*) суwық, әтийемне (*сугышка*) алып киттеләр, әтийем килгәнчә пастуқ булыб эшләдем. Әнийем бераз қартлау (*өлкән, карт*) иде, апам үлкүн (*зур*) иде. Табун қарадым, өйрәтеп йөргездем. Ике йөзләгән ат китте шуғышқа. Өлкән (*зур*) парум белән алып киттеләр ике қарам (*мәртәбә*). Өкө (*бәке*) уймаға кирәк атларға, ирләр йуқ, менә ничек хур булдық (*җәфа чиктек*).

Шуғыш шақта аштин (*ачтан*) сесенеб үлде халык, тормышлар аwыр булған. Дус әтисе (*әтисенең дусты*) булған, күмәг иткән (*булышкан*). Йаңга үлде, туқсан бер йәштә.

Мен туғыз йөз қырық сигезенче йыл тормышқа чықтым. Әйттерде (*сорап килде*) қарт әнисе, баласы шуwыштан қайтқан. Намаз уқый тоған иде.

*Сөйләүчеләр: Курманова Нәсимә Насыйр кызы (1939 елгы),*
*Юнысова Зөбәрҗәт Нургали кызы (1927 елгы).*
*Киләче авылы*

Тийешле (*туган*) кешесе килде йаучы булып. Сыйырлар, қуйлар (*сарыклар*) бар иде. Сөтен, гурыт йақын бит инде, сата идек. Кирәккәндә суйа идек, унға тикем була иде қуйларыбыз. Йерләрне беләә торған идем. Иркәк (*тәкә*) қуй, орғачы (*ана*) сарық тип әйтә торған идек.

Мин бала заманда су буйында тордық. Су боғасы (*су үгезе*) дә иркәк була, орғачысы булады.

Ат шул йылқы. Тимәбер кеше (*теләсә кем*) атны өйрәтә белми. Қымыз йасыйсын. Әкитәсен дә сатасын да қайтасын, эшкә тикем киләсен.

Пешән чаwып әзерлисен, шарлаққа өйәсен, қамышны да саласын, уралар да. Гөлләрем бердийләр икәwесе, су қойам, селпек (*тирес*) салмаға кирәк.

Туйға бардым. Айақларым қыйшық, 90 йәш ғуй, вағзалға әкитеп салдылар (*алып китеп куйдылар*). Йулаучы йулда қалмас, ти, вагунға меңгезделәр.

*Сөйләүче: Ибәтуллаева Шәһәрбану*
*Хөсәен кызы (1923 елгы).*
*Җәмәле авылы*

Ситкә (*җәтмә, сетка*) қоратаған идек, сазан, судак, қызылқанат бар. Өлкән (*зур*) су йуқ бездә. Кем ни зат таба, шуны сатып торды. Тамыр қаздық, қышта қата, қазып булмый, ун манит ыстаканы, киптергәч ашап җөриләр, жарит итеп ашыйсын инде. Картуф та чәчәсен, мадур утыртасын. Базарға барасын зилинен (рус. *зелень*) бәйләп, сатасын, ни кирәгене аласын.

*Сөйләүче: Ибәтуллаева Шәһәрбану*
*Хөсәен кызы (1923 елгы).*
*Җәмәле авылы*

Кукук килгән, кукук қычқырыптыр, йаз (*җәй*) килә.

Кайтим (*әнисенең апасы*) сүли дәгән иде. Сәрек (*сары авыруы*) менә аwыртым дип. Қызба (*бизгәк*) менән аурағаннар, хәзер бетте инде, хина таблиткасын биргәннәр. Қызылчаны (*кызамык*) да сүләмиделәр. Қызыл чәчәк диләр, кем су чәчәге ди, урыслар оспа ди. Қызыл чәчәк белән аwырғаннар, биттә чупыр-чупыр (*шадра*) булып қалады. Чиқан (*чуан*) суwық тисә чығады.

Тирескәнне дә күргәнем бар. Тирескән кәчекнен (*этнең*) сигәненә қарасан була. Әүвәле имнәгәннәр аны.

*Сөйләүче: Ибләминова Әҗәр*
*Идрис кызы (1952 елгы).*
*Кызан авылы*

Қышта туқтаусыз йағам. Қамыш урып китерәләр, йылғын (*куак, чыбык-чабык*) да жыйып китерәмез. Мындый қазан белән аш пешерәбез. Килен қулланған кебек тип карасинкаға қуwандық. Алла мәдәт бирсен боларға, хәзер плитәдә пешерәбез.

Арбачы булған әтийем, арба менән әйбер ташыған. Сыйырыбыз да булды, бер чирек (*3 л. сыешлы шешә*) сет өч йөз манит, сатса, куwанычы қултығына сыймый (*эченә сыймый*). Хур булып (*җәфа чигеп*) үлде, тиген (*бушлай*) эшләп.

Әүвәле бездә дөге чәчә торған иделәр. Хәзер күбесе йәшләр эшләеш, чикларда (*махсус әзерләнгән түтәл, чокырсыман була*) үсәде дөге. Қышта катын-қызлар чигә торғаннар иде.

Бездә хатыннарға да эш күп. Бер памидурдан икенче памидурға хәтле эшлиләр. Машиннар килә, төйәп җибәрәсен.

Җир тырнап йәшиделәр. Бер сыйыр, дүрт қуй, кәзә бар. Печән йуқ, күр нинди жар, печән қыйбат. Су ата (*су сиптерә*) торған машиналар эшләп җиткерә алмыйды. Бар балықны да ашап (*ашый*) белмәделәр шуғыш чақта.

*Сөйләүче: Абдрахманова Зәйнәп*
*Шабан кызы (1926 елгы).*
*Майлы Күл (Мәйле Күл) авылы*

Әбисе тоташ йатып тора. Қызым җийыштыра икән. Әбисе, әллә берәр бәйрәмме, ди. Йуқ, һәр көннө шулай жыйып торырға кирәк, ди. Қызым ундүрт йәштә индегесе.

Үзең телеңне онытпаға йарамайды. Үземез телне онытқымыз килмәйде.

Эш күп, қапыста қадыйсын, мадур (*помидор*) қадыйсын. Анда кызыл ут (*песи алабутасы*), йусан (*әрем*) үсәде, чәнчәкәйле үлән (*шайтан таяк*), унын түбәсендә (*очында*) сиреневый гөлө (*чәчәге*) үсәде. Чормаwық (*эт эчәгесе*) һаман ут, бетми ул.

*Сөйләүче: Мөхтәрова Разия*
*Хәмит кызы (1928 елгы).*
*Майлы Күл (Мәйле Күл) авылы*

Бала wақытта без йәш тә алты айлык қалғамбыз, әтийем суғышқа киткәндә. Әнийем қалған өч бала белән. Ашлық (*ачлык*) та күрдек, тундық та. Ул шақта ашарға тамақ та йуқ, зат та йуқ. Шулайтеп қур булып (*җәфа чигеп*) үстек. Әтием қорқ бишенче йылны суwық заманда, боз заманда қайтып килде қаладан. Ул қайтқан wақытта күзәйен дигән зат бар иде.

Ул wақытта күзәйен дигән зат бар иде. Берәү эрмийәдән қайтса, күзәйен дип барамыз. Барамыз. Шунда бер кисәк әпәйме, йарты кисәк әпәйме ашап, күзәйен булып қайтамыз. Мин йылыйм әнийемә. Ээ дип йылыйм әнийемә, қалықның әтиләре қайтып йатыр, йабынмага йурганымыз йук, ашамаға тамақ йуқ. Минем әтийем нигә қайтмый, дип. Шул wақытта минең әтийем дә қайтып килде, безгә дә қалық җыйылды. Әтийем қара әпәй алып қайтқан. Қара әпәй инде ул заманда да қәдерле инде. Шуны кисеп-кисеп ушақ өстөнә қуйғаннар инде, қалық килгәндә бирмәгә, ыстулға салмағачын. Ә без, минең абийын белә икәүмез, миш арт йақта орлаб ашағыбыз киләде, әпәйне ашағыбыз киләде. Абийым мине бераз күтәргән иде, қулым җитеп бер кисәк булса да алғамдырмын инде, бер кисәкне икебезгә бүлек ашадық. Әнийемез бар кийемен алып китеп, қазақ аwылларға барып, шуны алыштырып йөрәдегән иде. Кийемен алып барадырыйы, пасудасы булса, тарилкамы, табақмы, каструлме алып китеп, аwыштырып, безгә бодай алып қайтады, дөгө бер зат, аңан балығ алып киләде. Қайчан җәйәү барады, җәйәү қайтып, арып-талып төннө қайтқаннан сун, ану бодайны табаға болай куурып қына безгә ашатады. Шуны ашап без йатамыз. Тәwә (*дөя*) җөнөннән йурғанымыз бар иде.

Шуннан уқу бахыты җитте. Укуға барғанда трапышный сумкә белә йөрдек. Кимәгә киймебез йуқ, шалбар йуқ, йарлы заман. Кала җирендә матур кийем кирәк.

*Сөйләүче: Курманова Нәсимә*
*Насыйр кызы (1939 елгы).*
*Киләче авылы*

Мона бер йыр йырлағым килә, башлый алмыйм.

Ничек килдегез сез безгә,
Батмайынчы диңгезгә.
Қәдерле қунақ сез безгә,
Ни хөрмәт итим сезгә.

Тегендә бер өй бар иде, хуҗасы қалмаған. Шунда уйнап қайта торған идек.

Минем йанымда вынучкам торды. Ақсубайда тора хәзер. Мөн манит йулға кирәк барырға. Үзебезчә бирдек қызыбызны. Өч кеше килде сорарға. Қышта килделәр, әнисе, тәтәсе, тағын бер тийешлесе.

Сийырларыбыз, қуйларыбыз бар иде. Сыйырны саwып, иртүк қалаға барып, сөт сата торған идем. Қуйлар унға тикем була иде, кирәккәндә суйасын. Иркәк қуй, орғашы қуй. Безне йанымыздан көтү җийылып китә торған иде. Без су буйында тордоқ, қазлар, үрдәкләр бар иде. Бозауны орғачы бозау, иркәк бозау булса боға була. Қышта өкө (*бәке*) қазып эчерә иде ирләребез. Һәркем аты, арбасы бар иде. Ат шул йылқы була. Имезгәндә була. Йылқы. Әкитәсен дә сатасын, қала йақын. Килеп китеп йөрәләр иде, туған булып қаласын, қәрдәше булып. Без йақын қалаға, Киләчләр (*авыл исеме*) кебек түгел. Пешән шаwып әзерлисен, әзерли алмасан сатып аласын. Шарлаққа өйәсен пешәнне йақшы торсын дип. Ағач булмағанда өйне қамыштан салалар, бәйлиләр дә сылыйлар.

Кийәwебез йақшы, рәхимне, йараттық. Йулаучы йулда қалмас, ди, бардым қышта, айақларым қыйшық булса да. Багунға ике йегет күтәреб алды, рәхмәт әйттем, күтәрелеп қарарға ойалдым. Туқсан йәштә бит инде. Утыр, әни, дигән кешеләрем йуқ өйдә, бер үзем торам.

Безчә эргә була, нигез бездә йуқ. Йазу йазып бирәм дә, (өй салганда) түр биткә сала аны. Әрмийәгә китәйәктә әйтә икән, син нинди йөзек телисен. Исләмәгәннән туй йасадық, туй да булды, перидан да булды.

Ақчамны алдым да кылидур йасаттым. Өйөмнең тышын ақ таштан (*кирпечтән*) йасатырым дим. Қазан өй (*җәйге кухня*) белән өйне қушайақ идем. Мин үлгәч рәхәтләнеп йөрсеннәр өйөмдә дим. Вынучкам бар, Зөлфийә исемне, тап этисе, шуны бик йаратам, ул Йарлы Түбәдә тора. Ул инде ничәмә йыллар мине йуwындырады, керләремне йуwады. Йақшы, әйем (*әбием*), үзем китерәм, дип кенә торады. Мийа җитеп бара, ақчам җийыла тора. Шушында тора, Чәмәлнеке. Ай бер замат үтеп китәт тә.

Йорт ийәсе дип әйтәләр бездә. Хәзер ышанмыйлар да. Йорт ийәсе йаратмый, бимазалый дип ишеткәнем бар. Йорт ийәсе йаратмаган булады. Бала заманда атның йалларын үрә дип ишеткәнем бар.

Йарлы Түбәгә барғанда, икәү қыз барабыз инде, безне адаштырды. Йөрә бирдек, йөрә бирдек, табалмадық Йарлы Түбәне. Өйгә қайттық. Бисмилланы әйтеп йөрергә қушалар.

Йаға (*елгага*) барабыз суға. Қойо суы чичта дип қойодан алабыз. Су анасы дип сөйлиләр. Шәшен салтыратыб утыра дип сөйлиләр. Бездә өлкән (*зур*) су да йуқ. Бездә кечкенә су, анда су анасы була микән.

Қайзаман қыш тиз китәде. Йылына қүрә инде. Тирәг (*агач*) үстермийделәр, мадур үстерәләр, машин килеп тезелде. Мадурны алып китәделәр. Алар хур булып (*җәфаланып*) эшлиде, қыштан эшли башлыйлар бақчаны.

*Сөйләүче: Ибәтуллаева Шәһәрбану*
*Хөсәен кызы (1923 елгы).*
*Җәмәле авылы*

**Кием-салым турында**

Кәкитке күләкләр булған, монда ике кесәсе бар. Итәгенә фартук, эшләгәндә. Итәгенә текмәгәннәр. Бездә нуғайлар инде, перәмуй итәк кийә, абурка салмыйдылар бездә. Татарлар инде, татар аулы без. Нәселебез нуғай. Нуғай дип йөрткәннәр безне. Тийәктә қала татарлары, без аwыл татарлары. аwылларда ничә төрле халықлар бар, татарлар да бар, нуғайлар да бар, урыслар да бар, мишәрләр дә бар, бар да бар ғуй инде. Тәңкәләр тезгән күләкләр, байларда элек булған, без кигәнебез йуқ. Бархыт халатлар булған. Чәч очларына ақшалар тағып бай қызлары. Қолағында мондой сырға, очонда калакулчиклар бар, бармақларында йөзөк, қулында тутый беләзек. Үзе сазчы иде ул Сәхипҗамал. Муйынында энҗе, wақ энҗеләр, қомбатлы (*кыйбатлы*) энҗе. Бездә бер ат (*зат*) та йуқ, ул заманда әнийемнәр тақты буйтомар. Күләкнең эчендә буйтомар, эчендә ақча, бархатлардан тегеп. Менә йефәк шәл бу. Бу шәлне әйтәләр бездә уймақ күпертмә дип, уймаққа шаған бу. Моно қуз күпертмә диләр, қузғамы шаған ул. Рисле (*мамык*) шәлләр. Қаптал булғач қаплану сүзеннән инде ул. Айақларына бийек үкчәле түфли кийәде, аннар сун ақ тапычка кийәбез, аннан бер баулы чирәбәк. Чирәбәкне қулдан тегәделәр заказ белән, эченә балык шартлаwығ салады. Бийегән сайын шарт-шорт, шарт-шорт итеп торады. Бер баулы чирәбәк, димез, аның бер баwы бар. Анан сун тән төслө чирәбәк була торған иде. Аппақ чирәбәк, уны магазиннан аласын, унда

тырқылдаwық йуқ. Әниемнәр мәдәй (*мондый*) қалфақ салғаннар, йаулық салалар, битләрен йаwып йөргәннәр, әнийем сөйли торған иде, битләрен ирләргә күрсәтмиләр, йефәк шәл бәйләдек, әл дә бар сандықта. Кийәwем йибәргән йефәк шәл, түфли, бер джимпер, кийәүгә әйттергәндә.

*Сөйләүче: Нурмөхәмәдова Сафура*
*Абдулгазиз кызы (1927 елгы).*
*Киләче авылы*

Сөнәпитнен җине булмай, фуфайкы сөргән мамықтан.

Күләк мә (*менә*) монда бөргән (*билдә*), мә монда (*күкрәк турысында*) бөргән булады. Кәкиткә (*кыска кысалы*) күләкләр дә кидек. Ме (*бу*) йерләре абурка (*балайтәк*) була, берме, икеме, таррақ булса, өш (*өч*) тә булады. Җин очына уқалар салып тегәделәр күләкләрне.

Тағып чыға булған мыдый (*мондый*) сырға (*алка*), тутый беләзек, үзе сазчы. Қомбатлы энҗе иде бусилары (*муенса*).

Күләкнен эчендә буйтомар (*догалык*), бархыт, эчендә ақча. Алтыннарды тағып бара қунаққа.

Бийек үкчәле түпли, безләр ақ түпли кийәбез. Әле бер баулы чирәбәк тектердек, тән төсле чирәбәк була торған иде. Анда шырқылдаwық (*шыгырдаwық*) йуқ.

Мәди (*менә мондый*) қалпақ салғаннар башқа.

Ақ партық бәйләгәннәр, читләренә кәрзинкәләр, гөлләр чигеп. Матаға (*тукымага*) чигеп, тәрит жаулық (*сөлге*) чигәтәгән идек. Пыйаланын (*көзге*) ике читенә чигеп қуйа торған идек.

Үземез туқыймыз бәрик (*бияләй*), пишәткә. Орчық белән эрлидек. Белгән кешеләр айақ белән эрли, айақ орчық әйтәмез.

Ана (ул) wахытларда ундый (*андый*) күләкләр йуқ иде.

Ыштампел күләкләр, йефәк шәлләр бәйлидек, чачақлары бар. Рислы (*мамыклы*) шәлләр, уймақ (*бизәге уймак-уймак кабарынкы булган*) шәлләр, йефәк шәлләр қунаққа бармаға. Өлкүн (*зур*) шәлләр була иде тәwә (*дөя*) йонынннан.

*Сөйләүчеләр: Курманова Нәсимә Насыйр кызы (1939 елгы);*
*Нурмөхәмәдова Сафура Абдулгазиз кызы (1927 елгы).*
*Киләче авылы*

Мамық – йон: қуй мамық, дөйә мамық. Мамық шәлләр дә туқығаннар. Йефәк шәлләр була: уймақ шәл, күпертмә шәл, күз шәл (*озын чуклы ефәк шәлнең төрләре*).

Күкрәкчә (*изү*) диделәр, алдында була, уқалы, тәңкәле.

Қапталның затлысын байлар ғына кийепте. Энҗеләр тезеп, кәймә (*кайма*) салып та тектерәләр. Сәнәбәт җиңсез, хәзер дә кийәмез.

Минем белгәнемчә, кин әбүркәне күрмәгән. Қазан қалпақ, Әстерхан қалпақ була. Батағадан қаз алма, Казаннардан қыз алма, дигәннәр, мадур эше бик аwыр, Казан қызлар эшли алмый аны.

*Сөйләүче: Гомәрова Мәйсәрә*
*Хәким кызы (1936 елгы).*
*Җәмәле авылы*

Әлегечкә хәтле ислим, тиредән теккән бурчын (рус. *поршни*), йон наски, ванник (*киез итек*)*,* уйулы (*каеган*) читекләр була иде, чигүле. Чигүсезе қара читек эрләрнеке. Без чақта чибәкләр кидек.

*Сөйләүче: Бирдиева Гөлфәридә*
*Дуллаян кызы (1939 елгы).*
*Ярлы Түбә авылы*

Ийоқ кигән қодағыйны ничек түремә чығарыйм микән, дип қайғыра икән. Нәзек чөлкә кийәләр бит инде қунаққа барғанда.

Үкчәле атуны (*читекне*) кийеп, әмил бәйрәмендә (*сабан туенда*) арбаға утырып барғаннар. Намаз уқығанда чигүе йуқны кигәннәр.

Суғыш беткәне белән мануфактура чықты, кем үзе тегеп белә, тегәләр иде, тегә дә хәйер қуйып (*өстәү белән*) сата.

*Сөйләүче: Абдрахманова Зәйнәп*
*Шабан кызы (1926 елгы).*
*Майлы Күл (Мәйле Күл) авылы*

Кәкиткәле (*кыска кысалы*) күләк, йақалы күләк, йазғы (*җәйге*) күләккә йақа салынмый. Айақта базар ойоғы, қышта – wалник, тишелсә уға табан тартадылар иске wалник қунычтан.

Бездә төлке тамақ тун булған байырақларда, тағы өлкүн тун (*толып*) бар алыс (*ерак*) йергә барғанда. Шақмақлы өлкән (*зур*) шәл, эрисле шәл, җиңгел, бизәкләп, қулдан туқылған.

Мәрҗән тақтық, санҗақ (*брошка*) қададық. Байларнын энҗеләре дә булған. Бажақлы таққан қолағына, диләр, кечкенә генә, алтыннан ғына түгәрәк алқа тақса. Нуғай қатыннаары да чәчкә бажақлы таққаннар. Беләзекләр төрле-төрле, дутый беләзекләр була иде. Йөзекләрне бөтен бармақларға да кийәләр қунаққа чақырсалар, қашы йуқ йөзекне балдақ димез.

Чулпы бездә йуқ, тилебизырдан қарыймыз.

*Сөйләүче: Бирдиева Рухия*
*Хөсәен кызы (1928 елгы).*
*Каргалык авылы*

Йаулық, күпертмәле ақ шәлләр, йефәк ақ шәл йабыналар да қунаққа китәләр. Қалфатан йөриләр, очында маниталар, әнийемдә алтын бик күп булқан, паранжасы бар иде.

Чабатадан да йерегәннәр, чүwәк күwек бер затлар бар иде.

*Сөйләүче: Булатова Флера*
*Касыйм кызы (1940 елгы).*
*Нариман районы, Каңга авылы*

21 йыл йәшәдем, өч бала таптым. Қайнатам, қайнана белән ғөмере йәшәдем. Кийәwем аварийаға чорады эштән қайтып килгәндә, бер айақсыз қалды. Биш йыл торды, инфарк булып үлде. Мин утыссигез йәшемдә идем, ирем қырық йәшендә үлде. Иремнен қорқы узды, қайнанам үлде. Бер Қоран (Коръән) уқытам, икенчесе килеп житә. Бер йыл узғач, қайнатам үлде. Иремнен дусы бар иде, йәрдәм итеп торды, ташламады, қайда ит китерде, қайда балық китерде. Үзенен туған қатыны суға батыб үлгән иде. Мин чигеп тә белмим, тегеп тә белмим. Бездә мал асрағаннар, иген иккәннәр. Әркем өйендә асырый торған, қуй, сыйыр.

Пешәнне басуда уралар иде, урақ белән, мал қура өстөнә өйәләр. У заманда сөтне эчкәндермез инде, брынзаны да белмәдек. Сыйырны берәүдән, икәүдән тоталар иде. Безнен нуғайда қаз йуқ, таwық тоталар. Сарықлар йонынннан бәрек (*бияләй*), наски туқыйлар иде. Хәзер инде сарық жөннәрен ыздабайт итәләр. Озын наски, қысқа наски туқыйлар иде. Мамықтан сырған сенәпит, жине булмый, арқаға, күкрәгенә жылы булсын дип.

Безнен заманда ситец, ыштампел, учыртқа тора торған идек ыштампелгә. Итәкләр жийалған, йә келин итәктә абурки, бер қат, ике қат. У заманда халык тәртипле, муйыннар йабық, озын жиңне. Шәшкә дә таққаннар, қолаққа сырга, муйынға бусилар таққаннар. Муйтомарлар хәзер дә тағалар, доғалық. Қалада да саталар муйтомарны.

*Сөйләүче: Курманова Нәсимә*
*Насыйр кызы (1939 елгы).*
*Киләче авылы*

Башларында өйдә булса – прастой йаулық, қунаққа барса – ыспайы йаулық. Йақалы күләк, бөргән бу йирләре кәкиткәле күләкнен. Айақларында чөлкә. Кемнен қуйы бар, үзебез туқый (*бәйли*) идек, кәлүш, наскилар, валник (*киез итек*) кийәдер идек. Чичелсә (*тишелсә*) төбөнә сала, күн кебек зат белән, табан тартма кирәк. Валник суға торған мастерской бар иде.

Байларнын төлкө тамақ тун, төлкенен қойроқлары чығып тора торған. Тун тура (*туры*) иде. Қала сәүдәгәр байлары ғына кигәннәр. Алыс йиргә барғанда тулып тектергәннәр. Қатыннар пухыбый шәлләр йабынып, шақмақлы қалын зур шәлләр булған, қаладан қалаға йөргәндә, шақмақлы димәгәннәр, эрисле шәлләр дигәннәр. Кәзәнеке пыхларыннан инде ул эрисле шәлләр.

Байлар муйыннарына ничә төрле мәрҗәннәр таққаннар, санҗақлар тағарға, бырушка дийәрләр иде. Алтыннан энҗеләре дә булған. Бажақлы қызларына чәч очларына алтын тағып қуйғаннар, алтын бажақ дигәннәр.

Қәлбәй қашық нуғайларныкы, безчә бал қашык. Беләзекләр ничә төрле, рисункалысы бар иде. Аны инде дутый беләзек бар иде. Йөзекләр ничә төрле. Қашы йуқ йөзөкне балдақ дийәләр иде. Йақут қашлы йөзөкләр. Чулпыны белмим, андый сүз ишеткәнем йуқ.

Нуғай халкында қушамат күп булған: Қуқанай, Қырмысқа, Аққале, Әкәмнәр, Миллион Фәрит, Тычқаннар ыруwы, Сарбүкә / Шарбүкә дип әйткәннәр инде. Салдат дип әйткәннәр. Күчмә булганнар.

*Сөйләүче: Бирдиева Рухия*
*Хөсәен кызы (1928 елгы).*
*Каргалык авылы*

Чөлкә кигәннәр, шәл йапқаннар, озон жиңне күләкләр, керимтишин күләкләр кигәннәр. У күләкне утырышқа (*аш мәҗлесенә*) барырга әзерләп қуйдым. Қышта пуфайка қысқа, сөргән (*сырган*), пал'то, бесмет хәзер йуқ. Үлкүн (*зур*) шәлне сатыб алалар, наски, бәрекләрне үзләре туқыған, тақыйа (*башлык*) кигәннәр. Түбәтәйләр булган, йатақ (*бүрек*) йөреткәннәр, ике-бер (*кайбер*) кеше үзе печеп (*кисеп*), үзе тегә.

*Сөйләүче: Бикбулатова Асия*
*Абдразак кызы (1937 елгы).*
*Ярлы Түбә авылы*

## Аш-су турында

Қоран (*Коръән*) булса да туғаннарымы җыйа идем. Пылау да пешерәм, қабақ белән пешерәбез без, аны пысы (*пары*) шықмасын дийеп қамырын қаплыйсың. Қатланчық пешерәсең, қамырны йуқа итеп җәйәде, өч қат итеп бүкләйде, түгәрәклиде рулет кебек, кисеп-кисеп шығады, анан томалақлыйды (*йомры итеп әвәләү*) кисәкләрен, җәйәде, уртасына начинкы бүкләп салады.

Қузбүрәкнең қамыры шундый уқ, қамырның уртасына қуз (*чикләвек*) шикәр белән салады. Пәрәмәчә дә шул ук ачы қамыр, эченә ит саладылар. Пирүкләр төрле-төрле, бәлешләр инде. Бездә тагын лақсалба пешерәләр туйларда. Сездә чәкчәк инде ул. Лақсалбаны м'асорубкадан шығарып камырны шикәр белән қатырады, сездә қамыры түгәрәк булады.

Пахлава йасыйды бездә. Қамырын макарун кебек, қуз (*чикләвек*) белән, бал белән, ақ май белән қушып йасыйды.

*Сөйләүче: Курманова Нәсимә*
*Насыйр кызы (1939 елгы).*
*Киләче авылы*

Энкәлсалма (*бишбармак*) йасыйды қунақ килсә.

Туқмач диләр, қамырны қул белән өзеп-өзеп салады.

Бездә нуғай мәлеше әзерлиләр, озак пешәде ул. Итен айырым пешерәләр, қамыр эченә дөге белән итне салалар. Қарап қына, оста кеше генә пешерә аны. Кийәү сыйда өләшәләр. Унаулаған, умбишәүләгән нуғай мәлеше бара, туйға.

Баwырсақ шул уқ инде, сездәге кебек.

Бадамгөл – йорт шартларында пешерелгән пряник.

Аш қайтару – (ашагач) доға кылу. Қайнарый пәрәмәчә (әд. *пәрәмәч*).

*Сөйләүче: Юнысова Зөбәрҗәт*
*Нургали кызы (1927 елгы).*
*Киләче авылы*

Картуп қалачны табаға салып, май салып, пичтә пешерәсен.

Турамжа – туралған итле-камырлы ризык (*бишбармак тибында*). Турамжа бездә бер шара табақ (*зур агач табак*). Тасламсуқ сурпа – ашның бер төре.

*Сөйләүче: Сафура Абдулгазиз*
*кызы Нурмөхәмәдова (1927 елгы).*
*Киләче авылы*

Қатланчық пәрәмәчне тәм итегез (*авыз итегез*). Қатланчығын (*юка итеп җәелгән камырны кат-кат бөкләп пешерелә*), пахлавасын, луқымын (*майда пешерелгән вак кабартма*) да пешерә, туйда ни зат қына йуқ анда. Шикәр чүрәк әйтәмез, русча песочное печенье була. Әпәй үзем пешерәм. Бал кыwac қайнаталар иде. Қомбатлы балықлар сатадылар, бер манит киласы. Чиккеләре (*үлчәү*) бар, сары-сары табақлары.

Ашны тустақай (*аш чүмече*) мән қутарыб алабыз. Әүвәл өлкүн шара (*зур табак, чара табак*) белән иде аш өстәлдә.

Тилди пешерәбез, картуфны чапқыман чабалар, табада пешерәделәр, запеканка кебек була. Кәртүп қалач (рус. *запеканка*).

Қоранда қабақсыз пылау пешми, қабақны дубыйа (*фасоль*) белән болғыйлар, бал қабақ (*кабак*), урыс қабақ (рус. *кабачок*) булады. Мәркү (*кишер*) қуwырыб алалар, айырым суғанны қуwырыб алалар. Бер қалбыр (*иләк, дуршлаг*) дөгене йуwалар, әwәлдә қуй (*сарык*) ит иде. Хәзер инде төрле ит, бөтенесен болғап, йабып ташлыйлар (*куялар*).

*Сөйләүче: Бирдиева Рухия*
*Хөсәен кызы 1928 елгы.*
*Каргалык авылы*

## Туйлар, туйлар

Әйттермәгә (*кыз сорарга, ярәшергә*) айнанам килде, қәйенбикәм килде, тәтәсе кийәwемнең. Өлкән шал (*зур шәл*) йаптылар. Қапқамның алдында ут йағып, әкрен йөргезеп алып бардылар. Қамыш йанады, без сикердек. Қайнанамнын әнийесе ишағалдында тора, ун айағын белән кер, дип. Бер нәлмек перәнник, бер нәлмек пылау, анда балалар талаққа дип ашап утыра (*талашып ашый*). Кийәү бер өйдә мақпырда, аны минең ике җиңгәм сақлаб утырадылар. Тақ җиңгә, ин дәү җиңгә, эзләп парады кийәүне. Безнең айғырыбыз җуйылған. Сездә йуқма? Нинди ат, ақмы, қарамы? диде, қайсы йаққа йығылған йалы дип. Эй сары ат, йалы ун йаққа йығылған, дип ике җиңгә. Әтү, без тағы да китәбез эзләп, ди. Ағалары, затлары җегетте алып киләделәр қызның йанына, бүлмәгә кергезәделәр. Түрдә тәмике, җиңгәләр тәмике салады. Шул тәмикене чигеп (*тартып*), шығып китәделәр ағалары. Қызықлы инде туйлар. Әнийемнәр заманда кийәүгә күрми барғаннар, безнең

заманда бар да күреп бардылар. Минең йандағы қызлар минең йанда утырадылар. Чай қайнатадылар. Икенче көннө әбиләр килеп, биткүргән булады, қыздың битен күрсәтәделәр. Мине уртаға салып (*куеп*) ике йақта ике қыз тора, берәү килә дә «Әби, битне ач кызның», әби ача да теге кеше йаулықны ала да китә. Шулай итеп падарка бер пудры, бер ислемай, ун йаулықмы, алып бетерәделәр. Аннан қызға фартык кигезәделәр, менә инде қамытны ки, дип, мона муйнына инде қамытны киден, дип. Самуwар салмаға өйрәтә, ашсу, тоз-моз, барын да өйрәтеп шыгып китәделәр.

Өч көн сүләмәдем, қайнатам белән сүләмәдем. Пүпсик (*юка*) шәлне бәйләп йөрисен, өлкүннәр белә сүләшмисен, сәүлим, морза (*каенсеңлем, каенем*) белән сүләшәсен. Бийаға белән дә өч көн сүләшмисен. Бийағам «Шәлне чич, сүләшсән дә була» диде. Кийәү туғаннарны чақырады. Гаптеразақ бийағаң, Мәрҗән чичийең, дип әйтәделәр. Чичиләрем (*җиңгәләрем*) күб иде минем. Татуым дип эндәшәсен килендәшкә. Мулла бабай килә дә азан чақыра (*кычкыра*), ат қуша. Йаңғарыма, бийылма? Элгәре қарый торған мамайлар (*әбиләр*) бар иде. Әтисе азарланыб алады, сийыр қайтмады, дип. Китаптан қараб әйтмәде. Қартмамаң (*әнисенең әнисе*) бар ийе. Қайтып киләр, диде, китаптан қарады да әйем булса әтисенең әнисе булады.

Йәчмин булса, мә саған дип күкиш күрсәтәсен ғуй инде. Син дә ғайт, мин дә китәм дисен. Шуннан, ийалып, қачып китәр икән, күкиш күрсәткәннән сун, җирәнеп.

*Сөйләүче: Нурмөхәмәдова Сафура*
*Абдулгазиз кызы (1927 елгы).*
*Киләче авылы*

Қала чирендә (*җирендә*) үстем, татарша уқыдым. Миңа уналты йәш, дип сатта апай булыб эшләдем. Бездә әwәл әйттерәләр, әйттереп бирәләр қызны кийәүгә. Мартта әйттерделәр. Кийәүнен қәрдәшләре ике қәрдәш, туғаннары килделәр. Безнең атабыз жуқ иде. Әйем шақыр туй йасады: «Син, туғаным, сандық бирәсең, син, туғаным, фәлән зат бирәсең», – дип бүлеп чықты. Кийәүгә барайақ қызға, китәйәк қызға ни зат кирәк, барын да тутырдылар.

Китәйәктә қыз идән уртасына утырады, өстенә зур йаулықмы, шәлме йабалар, йаулықның ошон төйнәп, идәнгә қамыш йағып, шатыр эчтә килен таң атқанчы утырады. Тахтан чыққан кийәү күршеләргә кереп қул алып чығады.

Йаучы булып ике хатын киләде. Хәбип маман йаучыбикәм булды. Гөлезби маман йаучыбикәм булды, ике йаучы бикәм булды. Уларны тағырдайтеп утырадылар һәр бәйрәмдә бер тәтле бәйрәмаш пешерәделәр. Шақыр туйны қызлар өченрәк йасыйлар.

*Сөйләүче: Курманова Нәсимә*
*Насыйр кызы (1939 елгы).*
*Киләче авылы*

Бит күргән. Бит күргән бар иде. Унаулаған, умбишәүләгән йаулық булады. Киленне күрергә килгәннәр берәр йаулықны ала бара. Килен ашқан (*ачкан*) йаулық бу, диләр.

Төшкән киленгә эспис (рус. *специальный*) фартык бирәләр иде. Уйнаб үскән урамнан қайнана белән қайембикә (*иренең апасы*), кийәwемнен тәтәсе өлкән (*зур*) шәл йаптылар, әкрен йергездереп апардылар. Шалнын эчендә көн буйына, төн буйына буласын, ақ йаулық астан бәйлисен әле.

Ун айақ менән кер, диделәр. Нәлмәк (*тәлинкә*) менән перәнник қуйдылар. Иртә мәнгә (*беләнгә*) қәдәр кийәүне сақлаб (*көтеп*) утырадылар. Минем ике җиңгәм бардылар. Таң алында әбиләр бит күргән йасыйды. Қызнын битендә йаулықлар, өлкән (*зур*) йаулықтарды аладылар. Торайақсын, күләгенде кийәсен. Бибәләре (*энеләре*) саубуллашадылар (*күрешәләр*). Тәтәм, қахам (*абыем*) дисен. Қахам мән (*белән*) өч көнгә қәдәр сөйләмәдем. Пужик шәл (*юка шәлъяулык*) миңан (*миңа*) әйтте, өлкөн (*зур*) шәл. Бийағам дисен өч көн.

Йәрәшсәләр, туй көнен кисәделәр, көн кисү әйтәделәр. Туғыз туй (*билгелиләр*). Ул туғызға кийәү биттән қызға бирелә торған әйберләр: ақча, алтын, кийем, барысы туғыз төрле була.

Конфит туй қыз йағында, қызға үлкүн (*зур*) патнуста камфитлар китерәләр, туйдағы халыққа таратып шығалар хәзер.

Сөт хақы бирәләр қызнықы әнийенә, ақча белә була ул.

Кийәү арақысы бар, ул унике бутылка, йаландырталар, маймун (*маймыл шикелле*) булаты бөтене, бииләр, җырлыйлар.

Кийәү сый. Кийәү сыйга килгәндә кийәүне эзләтәләр, эзләтәләр аны, шатырға (*ишегалдында туй уздыру өчен махсус ясалган, зур «дүрткел» чатыр*) кергенчә басып торалар, йул ашпаға (*ачарга*) кирәк. Әнисе чақырыб ала да, киитли (*бүләкли*) дә, йул ашылды, диләр. Кийәүгә дә хәзер туғыз биреләде, бийем-бикәме (*кийәүнең ата-анасы һәм туганнары*), қайтиме (*әнисенең өлкән хатын-*

*кыз туганнары*), өлкән тәтәменә, мырзаларга (*кияүнең энеләренә*), сәүлим-җиңгәләренә (*каенсеңелләргә, җиңгәләргә*). Батракка кенәз дигәннәр.

Бит күрем йасадылар, қыз битнеке (*кыз ягыныкы*) ақ шәл йабындырып бит күрем йасадылар, туған-қәрдәшләрне җийа.

Җибәрәләр йәүче, үзенен туғанынннан қатын кеше барады әйттерергә. (Туйның) қачан булайағын көнен кисәләр (*билгелиләр*). Йәүчегә материал биреп йебәрә, йәүчегә, қачан туй йасарға.

Туй йасыйдылар. Қыз биттә (*якта*) кийәү сый була, туғаннары килә. Кийәү сый була туй беткәннән сун, нихак уқытып йегет биткә (якка) килен төшә. Машин белән, пинзел (*челтәрле ак ефәк*) шәлләр белән килен төшә. Атарба менән апкиләләр, друшкаға ике кеше утыра, кал'усасы җиңгел була, тарантас белән җиңгәләре килә, ақча чәчәләр, сет эчерәләр. Байан (*ак тукыма яки яулык*) җәйеп, шунын эстенә бастыралар, «Бәхетле айағың белән кил, килен», дип. Қайнанасы «Хуш килдең, киленем, төкле айағың белән кил, бәхетле бул!» ди.

Кийәү сыйда кертми торалар кийәүне. Қызны күрсәтмиләр.

Пинзел шәлләр булған, қайнанамнын пинзел шәле әл дә бар.

Қуйнымнан чығарып
Қызымны бирдем.
Эриза бул, қодағый.
Бәхетең булсын, қызым.
Тигез ғөмөр итегез,

дип озата инде қызнықы әнисе.

Алып қачу иде ул wахытта, йыллар аwыр булды. Барасы кийәwем белән, иптәш қызларны, туғаннары чақыртыб алалар.

Йәрәшебалса, әйттереп килә ике қатын-қыз, кийәүнен тийешлеләре. Кенне (*туй көнен*) кичәделәр (*кисәләр – билгелиләр*). Чатыр қорадылар. Йегет биттә (*якта*) туғыз туй. Чатырда йеп (*бау*) сузалар. Кем кийәүгә ни зат бирә, элеп қуйыла.

Қодалар киләләр, кийет (*бүләк*) бирәләр. Җыйыб алалар, туғыз туй бетте.

Қыз биттә (*якта*) кийәү сый. Қодалар килә қаwал (*уен коралы*) белә, саз (*гармун*) белә. Кийәү арақысы була. Кийәү арақысын йәшереп қуйалар. Аны эзләп алалар. Кийәү арақысын эчеп қарыймыз дип шунда...

Нихаӄ (*никах*) була. Нихаӄтан сун кийәүне китерәләр. Кийәүнен ике йағында ике кеше килә арбада. Кийәү сый була, икенче кенне биткүрем.

*Сөйләүче: Бирдиева Гөлфәридә*
*Дуллаян кызы (1939 елгы).*
*Ярлы Түбә авылы*

Бусаға атлап кергәнемдә аӄ җәйәделәр. Ӄул алмаға (*күрешергә*) киләделәр, ӄыз ӄул алып чығады ӄатыннарға. Ӄыз биттә кийәү сий. Йалғыз кишәкләр (*киленчәкләр*) бишәр йөз манит ташлыйдыр (*кияү сыенда*). Әттереп барганда тел бүләге бирәделәр, белә торғандырсыз. Ӄоры шыӄма дип материал бирәде.

Ӄыз биттә хатыннар туйы булады, ӄодағыйларны аладылар, байанды бастырады. Шикәр өләштерә йегет биттән, зур патнус шикәр. Шикәрде халыӄӄа бүләделәр. Аннары кийет бирәде ӄыз битнен (*якның*) туғаннары. Бүләк биреп булғаннан сун аӄча чәчәделәр. Элек ӄыз бит чәчәде.

Пылау бастырадылар. Кийәү сый бер-ике сәғәттән сун ӄыз биттә. Кийәүне кертми торадылар, җырлар йырлыйдылар, ӄаwалды ӄағадылар. Аннан сун кийәү керәде, күтәреп кертәделәр. Уға (*кызга*) туғыз бирәделәр, бийемәгә шыӄтылар.

Нихаӄ булады ӄыз биттә (*ягында*). Никә табаӄ белән баwырсаӄ, ул булады ӄызға. Ике wәкил аларға булады, аларға кийет (*бүләк*) бирәде. Баwырсаӄны бер ӄатын әкиләде (*алып килә*). Ӄайсындыӄы (*кайсыныкы*) ике ӄатын әкиләде.

Кергәнемнән сөт эчерәделәр, аӄча чәчәделәр бары да. Ӄызны ӄул алдырадылар (*күрештерәләр*) туғаннарыннан, кийет (*бүләк*) бирәделәр.

Әwәлдә (*башта*) ӄатыннар китәде, аннары, кичкә йәшләрден туйы, анда кишәк (*киленчәк*) тә булады. Бөтен халыӄ йыйылғаннан сун туй башлана. Атам, анам, ыриза бул, тиб әйтәтеләр. Бите бирәзә аста, асубый тегелгән булады, затты (*затлы*), йалтырап торады. Ӄуша (*тигез, бергә*) ӄартайығыз, дип йылыйлар.

Аӄӄаным, адаш тәтәм,
Ӄарасам – ӄара булыр,
Баӄсам – баӄыр булыр,

Күрсәм – күмер булыр,
Алсам – алтын булыр.

*Сөйләделәр: Бикбулатова Мәгърифә Сәйфулла кызы (1939 елгы),*
*Ибләминова Әҗәр Идрис кызы (1952 елгы).*
*Кызан авылы*

Бу печәләр (*хатын-кызлар*) туйы, ирләр туйы да бар, алар айырым утырады. Күрсәтәйенбә? Кичкә йәшләр туйы була.

Айақчы (*туйда аш-су әзерләп, өстәлгә ашамлыклар ташып торучы, айак савыт дигән сүздән*) пешәләргә (*хатыннарга*), өндәүчеләргә (*килennнең яки кияүнең махсус билгеләнеп куелган*) қунаққа чақыручылары әйбер бирәләр, табан йалы, диләр аны.

Байанды бастыру әтәләр. Аны үзенә бер ақ, қызыл читле йаулықны идәнгә җәйәделәр (килен төшкәндә). Ул йаулықны кишәк (*киленчәк*) үбеп, маңғайын тийереп алады.

Аннары қул алу булады, кишәк қәрдәшләре белән қулалыша (*күрешә*). Аннан сун ақча чәчәләр, ана сөте өчен дип. Кийәү битләр бүләк өләшә, кампит. Қыз битләр қодағыйларға кийет (*бүләк*) бирә. Йегет бит ақча чәчеп чыға.

*Сөйләүчеләр: Ильясова Халидә Фәрит кызы (1938 елгы),*
*Бикбулатова Хәлимә Маулитгали кызы (1936 елгы),*
*Бикбулатова Хәдичә Дайыр кызы (1942 елгы).*
*Кызан авылы*

Өндәүчеләр йөреп қайталар, туғаннарны, қунақларны туйға чақырып қайталар. Туйға килгәннәрнен барысын да қулларын йудырып кертәделәр.

Қалада аданашлар (*бертуганнар*) йәшәпте. Йаучы килепте. Аданашымнын килене әчек зат икән. Тақтамбитнең (*сәкенең*) йөзе кәрәбәдәй сап-сары. Өстәл җәйеп, самаwыр салып (*куеп*), қунақ итте. Алдымыздан чықты, артымыздан чықты, дәсторханны (*табын*) қорыпты. Артыбыздан чығып, алдымыздан чығып озатып қалды.

Сәләм қылып, қулымыздан алып, аданашым ақча чәчте. Чәчү ақчаларын «йәшә, йәшә, шоколат аша, рәхәт йәшә» дип бәбкәчләремә өләштем.

*Сөйләүчеләр: Бирдиева Рухия*
*Хөсәен кызы (1928 елгы).*
*Каргалык авылы*

Киләләр қыз артыннан, сүз қатып китәләр. Ниқах уздыралар, аннан қыз йылату да бар иде. Миңа лампы тотқыздылар, шуны күтәреп алып бардым. Булачақ қайнана, тәтле су эчереп, байинды (*аклы яулыкка*) бастырып кертте, тормышығыз бу су кебек тәтле булсын, дип. Кергәч wақ ақча сибәләр. Җегетнен җиңәсе була.

Икенче кенне биткүрем (*яшь киленнең битен ачу*) була, әбиләрнен қулын алып (*күрешеп*) чыға килен.

Берәр җомадан сун әниләре чақырыб ала. Йәрәшү белән үк йәрәшелгән қызны һәр туғаны чақырыб ала, қунаг итеп.

Кийет җегет җағы қыз җағына, қыз җағы җегет җағына бирә.

Ниқахқа килә паднус, анда була сөт хақы була, алтыннары була. Шунда әти-әнисенә дә бүләкләр була. Бирнә дигән зат (*әйбер*) йуқ бездә. Кийәү сый бар, кийәүгә падаркы бирәләр, қыз йағы чығара. Кийәүләр йалындырып киләләр. Кийәү арақысы була.

*Сөйләүчеләр: Булатова Флера Касыйм кызы (1940 елгы),*
*Хасьянова Сания Абдулкаюм кызы (1942 елгы).*
*Нариман районы, Каңга авылы*

Туйны сүлим инде. Кийәүгә киткән шағымда, ул wахытта әйттерәләр. Мине март айында әйттерделәр, нүйәбер айында туйым булды. Йегет йағыннан қызны әйттерделәр. Нүйәбердә туй. Нигә дисәң, әнийемнең хәле йуқ перидан йасарға. Занабиска кирәк, шифанир кирәк, камод кирәк, өстәл кирәк, хәл йуқ. Ул заманда қызы кийәүгә барған кеше қәрдәшләрен шақырып әйтеп шыға, туғаным, син шифанир алып бир, син, туғаным, фәрдәсенә қушыл, син ыстуллар алып бир, дип әйтеп шығар иде. Әйтеп шыға бирсен, халық йарлы, бирәсе йуқ. Өйөнә шақырып қунағ итәде, или қулйаулық, или өч митерме, ике митерме мата (*тукыма*) бирә. Индегесен әнийем нүйәбер айына тикле перидан җийды. Шунан туй булды.

Бездә, ғәдәттә, шақыр туй була элек. Тик қызлар ғына җийып, ул қызларның туйында бер тарилкадан аш бирә, чәй бирә дә, и бөтөн килгән қызларға қулйаулық биреп шыға бүләг итеп. Аннан суң шақыр туй беткәч, кийәүгә барайақ қызны шақырып, өйөн күрсәтеп, өйөнә шақырып қунағ итәде. Тужы ашатады, эчертәде бер қулйаулықмы, өч митерне матамы (*тукыма*) бирә.

Аннан суң ир йағы көтөп тора, қыз йағында туй була. Алып китәйәктә қызды идән уртасына утырталар, зур шәлне йабады қызның башына. Дүрт йағынан дүрт дус кызымны тоттырдылар. Йаңынан бер дус қызымны кертәде. Пирwый әнийем кереп

йылыйды. Ни қызым китеп барады, дип әнийем йылыйды. Әнийем йылап шыға шәл астыннан, тәтәләре керә, анда абыйларыма инде. Анда қәрдәшләр, күршеләр кереп-кереп қызны қошақлап йылашып, саубуллашадылар.

Инде шыққаннан суң, шул туйның бер дамадасы (*туй башлыгы*) булады. Миндә Эрәшит абийым бар иде. Шул Эрәшит абый байағы қызны шул шәл астынан шығармыйдылар. Шәлнен астынан дүрт йақтан дүрт кеше тотып, қызның өйөнән йегетнең өйөнә хәтле әкрен генә йергезеп урам буйыннан алып барады. Артыннан инде туй халқы барады. Инде җегетнең қапқасына ғына җиткәндә, бер бау (*көлтә*) қамыш йағып торадылар. Бер әби керәде қулйаулык белә башында. Кийәүгә чыққан қыз йанып торған қамышның өстеннән сикермәгә тийеш. Мин сикереп чыққач, бер әби тора, зур қарт әби, йаулық белән, ул йаулықның ошон утқа йаға да, мине болай түгәрәк әйләндереп ошоқлый, ошоқлап кергезә. Шулай итеп өйгә керәсен.

Өйгә кергәченнән, түр йақта шатыр булады, шатырда тик ирләр утыралар, қунақ булалар, ашыйлар-эчәләр, қатыннар бер йақта торадылар. Ә киленнең ике йағында ике йақ җиңгәсе белән йегетнең бүлмәсенә кергезәде дә, төнө буйы шунда утырады килен. Туйға шықмый сафсым, шатырға да шықмый. Тан атқанчы киләттә қыз, утыра шунда. Икенче көн иртә белән кийәү керәде йанына. Кийәү кереп исәннәшәде дә, аннан ул кийәү шул көнне үк күршеләргә керәде кийәү. Күршеләргә кереп күрешеп чығады. Тахтан чыққан кийәү диб әйтәделәр, күршеләргә кереп кул алып (*күрешеп*) чығады. Аннан сың кире өйгә қайтады.

Әйттергәндә йегет йағыннан киләде йегетнең радн'асе. Миңә килде ике хатын, ике йақшы булады, мийа ике мамам килде, йаушы бикәм дип әйтәмез. Алар өлкән инде, шуңа күрә мамам була инде. Аларны «йаучы киләде» дип хәбәр итәләр элек. Қызның өйө белеп тора йаучы килә икәнен. Киләйәген белеп, аш пешереп, чәй қайнатып, көтөп торады инде.

Килеп керәләр, тағырдаб (*сөйләшеп*) утыралар. Аннан суң «Менә қызыгыз белән алар бер-берсен йарата икән, мона без сезнең қызны әйттереп килдек» – дип әйтәделәр алар.

Миңа болай әйтеп чығарды әнийем: «Қызым, синңа йаучы килгән. Рәүптән, диде, – Кийәүгә барасынмы?» – диде. Мин әнә у йақтан тороб әйтәм: «Әнийем, мин йаратам уны», – дийәм.

Ул заманда әнә шул әйттергән қызға туй булғанчыға қәдәр бәйрәм булса, чиклек йибәрәде. Һәр бәйрәмдә. Чиклектә бер патнус тутырып тамақ (*ризык*), бәйрәмаш и киленгә күлмәкмә, шәлмә, йаулықма. Шундый бер зат йибәрәләр. Мона миндә ураза бәйрәм дә, қорбан бәйрәм дә булды. Ике мәртәбә чиклек килде миндә. Чиклек дигән зат хәзер йуқ, мин борынғы заманны сүләдем.

Рәүпнең атасына «атам» дидем, анасына «әйем» дидем. Ул заманда қәйем – бикәләрем булса да, қайын сеңелләрем булса да, атларын әйтәргә йарамый дыған иде. Ике тәтәсе бар иде, тәтәләренә «тәтәм» дийә идем. Ике сеңлесе бар иде, берсенә – сәүлим, икенчесенә эрүwем дийә идем. Тәтәләренең балаларына «морзам», «сәүлим» дийә идем. Абыйсына – абыйым, җиңгәм, диләр. Бар бездә нуғайлар, қахам дийәләр. Әниде апам дийәләр нуғайлар, нәнәм, атам диләр. Хәзер бары да әтийем, әнием дийә.

Байағы килен аш пешерәде, айақ (*савыт-саба*) йуwады, әүлә сеперәде, бөтөн эшне эшли.

Туйда пылау туй ашы инде. Итен айырым пешерәделәр. Пылаудың дөгөсен әwәле күп суға салып, бүртеп, пешереп чығарадылар да өстәл өстенә җәйеп қуйалар. Ике кила микән майға суғанны салып қуwарады. Аннан суң қазанны бушатадылар да төбенә қабақ җәйәделәр. Қабак өстөнә байағы дөгөне җәйәделәр, байағы қуwырған суған белән майны төйәделәр. Йә йақшы итеп йабады пары шықмасын дийеп қаты қағаз (*фольга*) белән. Аннан суң йомошақтан йабады, иске куфайкымы. Ысланып, әкрен пылау пешәде. Итне wақ-wақ итеп кисеп айырым пешерәде. Анан суң пылауды салып, аңа итне салып бирәде. Пылауны пылау пешерүчегә бирәләр. Туйғама, қоранғама пешереп алып килә пылаучы, ә ите өйдә пешә.

Тарилкаға салған заманда тарилкаға пылау салады, бер кисәк қабақ салады, и бер қашық ит салады, шулай бирә. Ит салып торушы булады, қабақ салып торушы булады, дөгөсен салып торушы булады.

Бәйрәмашлар ничә табақ: қатланчық, кузбүрәк, итле пәрәмәчә.

Қатланчықты қамырны нәзек итеп җәйәләр дә бер эрәтенә май салып, икенче җәймәне салалар да тағын май салып, өчөнче җәймә салалар да болай итеп, болай итеп болғыйлар да, бөкли-бөкли томалақлыйды (*йомры кисәкләр ясау*) қатлы қамыр була. Қатлы қамырды җәйәләр дә болай-болай кисәләр дә уртасына зат (*эчлек*) салады: күрәгә һ.б. Шул қатланчық булады. Қузбүрәккә шундый уқ қамыр, уртасына төйөлгән қуз (*чикләвек*) салады.

Пәрәмәчә – пәрәмәч, қамыры да шул уқ. Болар бары да ачы қамырдан була.

Лаксалба (әд. *чәкчәк*) – бирмишел кебек кисәләр. Пахлава қуз һәм бал белән, май белән. Қамраш (рус. рожки). Эңкәл, салма – тукмач. Туқмач (әд. чумар).

Тәмне, тәтле әйберләр шул лаксалба, нуғай бәлеш – төчегә. Бездә инде шул қәдерле ашамлық.

Киленгә қалым бирәләр. Икенче көн биткүргән бар иде. Килеп монда торады, аның алдында унаулаған-умбишәүләгән йаулық тотып торалар пәрдә кебек. «Килен, бәхетле бул!» – диләр дә бер йаулыкны алып китәләр. Йаулықны алып бетергәч, «киленнең бите ачылды», – диләр. Һәркем ачқанда йаулықны үзенә алады. Кадерле бүләк була ул, киленне ашқан йаулық диләр.

Мона минем онығым өйләнергә тора, әйттереп қуйдық қызны. Икенче көнне бит ачуны чығарыйм әле дип торам.

Перидан керткәндә өйнең башына менеп он чәчәләр. Перидан он бар дип, онға буйалалар. Кызның периданын орлау дигән бар иде. Қызның периданын тезәделәр дә шатырға кергезәделәр. Шунда берәү қарап йөреп бер әйберне орлап китәде, бер чашкама анда, бер тарилкама. Икенче көнне «Ва, мона у зат йуқ, мона у зат йуқ» дип йуқлайлар (*юк икәнен ачыклыйлар*), Қайда ул зат? Әә, сатыб алма кирәк. Ақча бирәде. Менә шундый бер қызықлы ғәдәтләр бар бездә, хәзер инде ул ғәдәтләр йуқ.

Уйым бар әле шулай үзем киленемә бит ачтырырға, бездә қалған зат инде ул. Ә бездә борынғы заманда минем өч киленем бар, биш онығым, өч правнугым бар. Оныкларны инде өйләндерәбез.

Килен тегендә қамышны сикергәннән сун, ишектән инде керәсен. Ну перидан килгәндә, кызның периданы булады бит, анда абыйлары, ағайлары кертеп таратқанда затнын (*өйнең*) башына менеп, түбә башына менеп он чәчәләр. Онға буйалып шулай. Инде өйгә, ишектән кереп киткәндә, ышкап сыймый тора, диван өйгә сыймый тора дип әйтәләр, ыштубы болар бер зат (*әйбер*) бирсен, ақча бирсен. Анан сун йөз маниттанмы ақча бирәде. Анан сыйады, апкереп урнына салады (*куя*) анан сун диванны. Анан сун менә қызнын периданын орлау дигән нәрсә бар иде. Қызнын периданын тезәделәр дә шатырға кереп китәләр. Периданны қарап қалучы кеше булады, қарап торады. Шунда да бит берәүләр қарап орлап китәде, бер чашкамы анда, бер тарилочкамы. Шуны ана сун икенче

көнне, бай-бай мона у зат йуқ, мона у зат йуқ тип, йуқлайдылар (*юк икәненә төшенәләр).* Қайда ул зат, ни, сатыб алмаға кирәк. Бирәде, зат ақча биреп алмаға кирәк. Менә шундый, борында бездә шундый бер қызықлы ғәдәтләр бар иде. Хәзер ул ғәдәтләр йуқ. Бездә мылтықтан ату йуқ, менә шул теге ут арқылы сикерткәннәр. Ут арқылы сикерәсен, анда шул қамыш, бер бау қамыш салалар, ут йанып тора. Килен йакынайа, анда аны сақлап торалар, шул ут өстеннән килен атлап чыға. Ник атлап чыға ут өстеннән, ни сәбәпле ул, ни зат аннатқан инде ул, белмим. Ут өстеннән сикерткәннәр қызны. Бер әби кеше йаулықны қызнын түгәрәгеннән әйләндереп ышықлаған, менә аурушы булмасын дигәнме инде ул, бәхете қотлы булсын дигәнме ул, шундый бер зат. Менә безнен чыққан заманда шундый иде. Ә хәзер күзебез қыза, безне, мин әйтәм, урам әйләндереп, машин қышқыртып йөремәделәр, шәлне ачып бардық хур булып (*җәфаланып*)*,* җәйү барабыз, мин торамын аwыл очында, ирем монда. Ана шул озын йулны, найабер айы, суwық, әкерен йөретәде. Тизрәк барсан да тунмас иден. Әнә у чебеч йөргән кебек әкитәде (*алып бара*) шулай.

*Сөйләүче: Курманова Нәсимә*
*Насыйр кызы (1939 елгы).*
*Киләче авылы*

## Туганлык атамалары

Бездә қайынанаға «әйем» диләр, қайнатаға «атам» дисең. Иремнеке апасы тәтәм, минең тәтәм иремә қәйенбикәм була, балаларына «мырзам» дисең. қайынсеңелгә «әрүwем», «сәүлим», «сөйәрем» диләр, йаратып.

Үзенекеләргә «қахам» дип әйтәсең, абыйым дийүчеләр дә бар. Җиңғәм сездә дә шулаймы?

Баланы азарлаған (*ачуланган*) таң алнда (*алдында*) қарт мамам (*әби*). Килә, диде маман (*әби*). Әйем этисенең әнисен унча (*ничек*) дийә?

Үлкөн баламдықы баласы унөчкә йетепте. Өч иркәк (*ир*) балам, берәwе өйләнгән йоқ.

Тәтәм (*апам*) килде ике вынучкасы, килене белән.

Тәтәңне күрдем, сиған (*сиңа*) сәләм күб әйтте.

*Сөйләүче: Юнысова Зөбәрҗәт*
*Нургали кызы (1927 елгы).*
*Киләче авылы*

Әбийем бар иде, ислэп (*искә төшереп*) сағынып торам. Кешелекле, намаз ийәсе иде. У заманнар халық кешелекле иде. Минән қарт кеше йуқ, өш улым бар иде, өшәwе дә үлделәр инде. Қырық йыл пинсе алам. Уртанчы улымнын қызы бар, йуwа, ул күмәг итә (*булыша*).

Әтийем, әбийем, қахам (*абыем*), әйтәмез. «Әйем» әйтә идек әбигә, этийем – әнисенә, йомшақ сүз сөйләп үстем мин. Суғышқа киткесе килде, алып қалдылар. Йырақ җирләребез бар. Көзнең салқын көнендә салқын тийеп үлде, йәшлий үлеп китте.

Энем бар иде, алар үлгәннән сун, мин бер үзем қалдым. Қоран (*Қоръән*) уқып йөрим мин, чақырсалар.

Бөтен зат йақшы, өйем дә йақшы.

*Сөйләүче: Ибәтуллаева Шәһәрбану*
*Хөсәен кызы (1923 елгы).*
*Җәмәле авылы*

Қызым битенде (*битеңне*) ач, шәлне чиш, диде. Бит ачуға (*тел ячереп йөргәннән соң, сөйләшә башлаганда*) ислемай әкиләде (*алып килә*) Мортаза бийағам.

Қайынсеңелемне «сәүлим» (*нурлым*) дийәсен, «әрүwем», «сийәрем» дийәсен. Энеләренә «мырзам» дийәсен, атын әйтмим.

Чичиләр – җиңгиләр алар. Пәризә чичи булады, дүртәү алар, дүртәwе дә миңан «килен» диделәр. Килендәшләр булса, бер-берсен «татуwым» диделәр.

Бала булса, башына Қоран (*Қоръән*), пышақ салып партық (*бардык*) эшләмәгә.

*Сөйләүче: Курманова Нәсимә*
*Насыйр кызы (1939 елгы).*
*Киләче авылы*

Вынукам (*оныгым*) тап (*нәкъ*) этисе, җиңгел. Әйем (*әбием*), мин киләм, диде дә, берзаман үтеп китәде, вынукам киләде дә. Қайенемнен олы. Иремнен тәтәсенен олынын олы. Мөгөлсөм тәтәм суғышта қалды. Әтийемен сеңнесе.

Бабамнын заты (*нәсел*) бар иде, қахам.

Әнисенен ағасына чықтым.

Әбийемен тәтәсе. Қодаша да, қайнанам-қайнатам да үзем қулымнан китте.

Қайнанамнын ир кешесенең (*иренең*) туғаны бар иде.

Дусым эти, дусым әни бар иде. Атайбикә (*әтисенең бертуган апасы*) мән кинәштем. Әтинең абыйын «баба» диләр, «зур эти» диләр. Әнинең әтисенең – «бабам», әтинең әтисенә «атам» диләр.

Эр кешемен ағасы қайнағам, қатыны – абсын, йә чичи үлкөнрәк булса. Эр кешемен сеңлесенә сәүләм, сөйеклем, гүзәлем, туғаным дисен, энесенә – морзам.

*Сөйләүче: Бирдиева Гөлфәридә*
*Дуллаян кызы 1939 елгы.*
*Ярлы Түбә авылы*

Ақ тәтәне (*әнинең апасы*) чақырма кирәк. Зур симийәгә төшсән апсыннар (*килендәшләр*) булады, қәйнеш, балдыз булады. Иренен тәтәсе – қәйембикәләре булған, иренен сеңлесенә кишәк (*киленчәк*) сәүлим дийешәләр, аппағым, сәүлим, әрүwем диләр. Иренен абийын «қайнаға» диләр, «суқтам» ди қасы, иренен энесен «морзам», «ақмоллай», қасы «акмуллам» ди.

Кишәк (*киленчәк, яшь килен*) тел йәшерә, иренен абийы да, қайната да йат була бит. Ике килендәш бер өйдә булсалар чичи дийешәләр, өлкүнрәгенә жиңгәм дисен. Әтинен, әнинен бертуған тәтәсенә «қайтим» дип эндәшәләр, қайнананың, қайнатанын тәтәләренә «бикәм» дисен. Биби әйем – олы килен балалары, әниләренең кече килендәшенә шулай эндәшәләр. Аданаш(лар) – 1) туганнан туганнар; 2) бер елда туган бертуганнар; 3) туганнан туганнарның балалары бер-берсенә карата. Ике аданаштан туғаннар – туганнан туганнар. Өлкәннәр жиңгә булған, өлкәннәрнең апсыннары (*яшьрәк килендәш*) булған. Қайнешләре булғаннар, ireңнең энесе қайнеш булған, сеңнесе булса, қәйенсеңне булған. Иренә хатынның сеңнесе балдыз була. Тәтәләре қәйембикәләре булған. Иренең сеңнесенә сәүлим була, әрүwем, аппағым. Иренең исемен әйтмәгәннәр, ойат булған. «Аппағым» дигәннәр, «қәйнесеңнем» дигәннәр, «әрүwем» дигәннәр. Қарт мамам әрүwем ди торған иде искечә. Хатынның тәтәсен дә «қәйембикә» дигәннәр.

Ул заманда қайнатасындан, қайнағасындан бит йәшерә торған булғаннар. Қайнаға ireңнең абийсы инде. Қайнағасы белән сүләшергә дә ойат булған. Энесе булса, «қайнем» дигәннәр, «морзам», «ақ малай» дигәннәр, сапсим кечкенә булса, «ак муллам» диб әйткәннәр, ирнең ағасына «суқтам» дигәннәр. Ике килендәш бер өйдә булса, исемнәрен әйтмәгән, чичи дигәннәр бер-беренә.

Әтиенен тәтәсен «қәйтим» дигәннәр, «бикәм» дигән. Әнисенен тәтәсенә дә «қәйтим» диб әйткәннәр. Ә килен аларға «бикәм» дигән. Биби әйем, биби әнийем диб әйткәннәр, олы килендәшнең баласы кече килендәшкә шулай әйтә. Зур әнием, зур әйем – әнинең олы килендәшенә әйтә. Ақмамам, аданаш. Аданаш әнийем, аданаш этийем дигәннәр, бер-берсенә дыбайуродной булғаннар, биби мамам, биби этийем дигәннәр. Бер ырудан булсалар аданаш әйтәләр. Ике аданаштан туған булғаннар, аданаш этийем, аданаш әнийем диләр, йәштән қәрдәш булсалар, бер ырудан булсалар – аданаш әнийем, аданаш этийем дигәннәр.

Күршәбине күршәйем (< күрше әйем), қуншайым (< қуншы – күрше + айым – әйем) әйтәләр. Шул әдәтне этче уларға йазып алырлар. Жиңги, қахай (*сабый*) сурады тахтамбит (*сәке*) астында балға, дип әйтә, ә без аны чүкеч дидер ийек.

Бер ырудан булған туғаннан туғаннар бер-берсенә аданаш этием, аданаш әнием дип эндәшәләр (*әлеге модель башка очракларда да күзәтелә: күршәйем / қунчайым атам – күршеләргә эндәшү сүзе*).

Житем (*ятим*) бит инде ул қыз. Мине этийем азарлағаны йуқ. Мин сиқа қыз. Сиқа булғач сораб алған бала була, аңа тийәргә йарамаған. Аның сиқасы бар, анарға йарамый азарларға (*ачуланырга*).

Әнийем қахасына (*абыйсына*) қырық йыл булады үлгәненә.

*Сөйләүче: Бирдиева Рухия*
*Хөсәен кызы (1928 елгы).*
*Каргалык авылы*

Жиңгигә қадерлем, сөйеклем этәбез, аты белән йарамый. Йөрәкәм, дисен, исемесе белән йарамый.

Зур абыйым көрәшче, этийемнен зур абыйы безнең Каңгага (*авыл исеме*) көрәшергә килә иде.

Электә сабан туйлар булмаған. Сабан туйда ат йәрешләре көңелле.

*Сөйләүче: Хасьянова Сания*
*Абдулкаюм кызы (1942 елгы).*
*Нариман районы, Каңга авылы*

Жинағасы < жыен агасы – авылда жәмәгатьчелек оештыра торган жыелышларда, бәйрәмнәрдә һ.б. башлап йөрүче.

Алты йартыда – алтынчы яртыда.

Атқушар – исем кушу мәҗлесе.

Бишектуй;

Ақча чәчү – мәетне озатканда акча чәчү йоласы.

Әмил бәйрәме – яз башында (*мартта*) була торган йола.

*Сөйләүче: Бикбулатова Әсия*
*Абдразак кызы (1937 елгы).*
*Ярлы Түбә авылы*

**Мәзәк.** Берәү өйләнгән. Ни хәл йаңгы (*яшь*) қатын белән, дип сурағаннар. Ни хәл булсын, бидрә иде, силәк булды, картуф иде, бәрәңге булды, суағаш иде, көйәнтә булды, дигән.

**Бишек туйы**. Бишек туй, бәби туй була. Қырқы тулсын дийергә бишек туйда. Қызнын әтисе китермәгә тийеш бүләкләр.

Бер йәш тулғанында қунақ җыйалар. Бала қурқынмасын өчен астына йақшы довалар йазып салалар.

Мәйет булса, қыблаға қаратып йатқызалар, тағын ни, белмим. Төнәтергә туры килсә, күкрәк өстенә тоз, қайчы қуйалар.

*Сөйләүче: Бирдиева Гөлфәридә*
*Дуллаян кызы (1939 елгы).*
*Ярлы Түбә авылы*

## Мәетне озату

Илтәйенне чақырабыз. Кичкедән (*кичен*) үлсә, қатынннар төнәтәдер (*төнлә мәет саклау*) теңләр (*төн*) буйы, ирләр үлсә, ирләр төнәтәдер. Икенче көн қәрдәшләр жыйыла, илтәйен (*остабикә*). Кәфенне ирләрнекен ирләр печә, қатыннарнықын қатыннар печә. Йуwындырамыз биш-җиде кеше. Кергән кешеләр йуwындырмаға башлыйлар. Кәфен унтуғыз митер, биткә йәшел йабалар. Табыт белән әкитәделәр (*алып китәләр*)*,* баш биттә (*ягында*) шәл йабадылар. Чымылдық (*мәет өстен, көймә кебек ясап, каплау*) әүвәл булған.

Әүвәл ырыwын күмәде бер урынға, хәзер урам-урам (*рәт-рәт*) инде хәберләр.

## Уйыннар, җырлы биюләр

Аулағыйны хәзер тилебизырдан қарыймыз. Әүвәл йыйыладылар буш өйгә. Уйныйдылар, римин суға, бутылка тәгәрәтә.

Йәш шақта паромға чықтық. Паромға ақ қулйаулықлар ташлап суға, кеңелле булады ул.

Аулағөйләр бездә дә булды, бичыр йасый ыйық шулай. Саз (*гармун*), гармонис, бийүләр, җырлап. Ничә төрле уйыннар була торған иде, саратыский саз. Аулақ өй. Бер өйгә җыйылалар, гарманис қызлар үзләре бар иде. Нишә төрле қызлар бар иде, атларын да онытып бетердем инде. Йегетләр, қызлар җыйылалар, ә өйнең ийәләре өйне бирәде дә китә туғаннарына. И шунда жырлыйдылар, бииделәр, уйын уйнайдылар ничә төрле: бутилка белән тәгәрәтеп, йөзек ушлайлар (*учка салалар*). Ничә төр уйыннар бар иде инде. У заманда тилебизыр йуқ, радийу йуқ, клуб йуқ. Күңел ашқаннар. Безнең заманда шулай иде инде. Мин үзем җырлап белмидем, җырлап белүчеләр бар иде, көйләре йақши иде аларнын. Сазны қызлар тарта иде. Саз тартучылар үлеп беттеләр инде. Андый затларны белмим.

*Сөйләүче: Курманова Нәсимә*
*Насыйр кызы (1939 елгы).*
*Киләче авылы*

Йәшермәк – качышлы (*уены*).

Қапқачар уйныймыз, мәчте (*тупны*) суғып.

Ширтә (рус. *черта, сызыклы*) уйнадык.

Буймәчә/биймәчә (рус. *бей мяч*); тупны бәрә, икенчесе ағач белән бәрә, икенче команда тотып ала.

Барымыз да урамға барамыз, третий лишний уйныймыз. Аwызымызда саз тарту бар иде, аwыз белән көй әйтәмез дә этнәгә (*бию исеме*) бийеп китәбез.

Үсемезнен тиннәр кыруг уйныймыз, бер кесе (*кеше*) уртада торады. Төрлесен уйнап җерәтән (*йөри торган*) идек.

### Хатем Қоран

Хатем Қоран – Аллаһы тәғәләдан сорыймыз: печән булсын, иген булсын. Бөтен аwылдан ике мең акча җийамыз, сыйыр суйамыз, қан қойамыз. Бер мен сөйлимен. Әнисе имкәқләп йөреп җыйа.

*Сөйләүчеләр: Нурмөхәмәдова Сафура Абдулгазиз кызы (1927 елгы),*
*Юнысова Зөбәрҗәт Нургали кызы (1927 елгы).*
*Киләче авылы*

Җитәкләшеп бийү бар иде. Үскәндә урамда саз тартып (*гармун уйнап*) йөрү бар иде, саратский саз. Бер йыр йырлағым килә.

Йәшереп сала торған (*йөзек салыш*) уйын бар, шуны салып уйныймыз. Мин йырламый таған идем. Бала чағыбызда уйнағанбыз.

Қайнарый, қайнарый,
Ашый Қазан байларый.
Ашамас ийе қайнарый,
Тамып тора майларый.

*Сөйләүче: Ибәтуллаева Шәһәрбану*
*Хөсәен кызы (1923 елгы).*
*Җәмәле авылы*

**Өй иясе**

Җыйын дип йәшләр җыйылышып утыра таганнар, йырлашалар, анан бийешәләр. Бутылка әйләндерәләр, туракай килсә, үзенә сән йырлайсын Хушығыз! Йақшы йулға барын. Киткәндий булсам арғы (*тегe*) дөнйаға васыйат итәм, татар қызына өйлән дип...

*Сөйләүче: Мөхтәрова Разия*
*Хәмит кызы (1928 елгы).*
*Майлы Күл (Мәйле Күл) авылы*

Менә йаңғыр йаумый. Аwыл қартлары җийылышып қорбан чалалар иде. Ағач пийалалар (*савытлар*) белән киләбез, утырып ашыйбыз, балалар қычқырышалар:

Йаңғыр йау, йаңғыр йау,
Иләкләп тә чиләкләп.

Йәшүсмер кыз wақытымда римен уйный идек, римен кемгә ләгә, шунысына наказанийе ләгә, йырлый, бии шунда.

Урам мәч (рус. *мяч, волейбол*) уйный идек. Тәтәбез орышмасын дип алдан сөйләшеп қуйабыз.

*Сөйләүче: Булатова Флера*
*Касыйм кызы (1940 елгы).*
*Нариман районы, Каңга авылы*

Без ул wақытта йәшермәк уйнай даған идек, қапқашар уйнадық, анна сун чирта (*сызыклы*) уйнадық, чиртә диб әйтәмез дә. Болейбол без уйнамадық, қапқалар уйнадық, болибол зурлар уйнай даған идек. Қапқашар буймәчә була инде, бимәчә (рус. *бей в мяч*). Мәчне берәү подавать итәде, ә икенчесе болай суғады. Суғасын да

қашасын анна сун. Артында торған кеше тағын суғады. Ә бу кеше йөгөрәде теге йаққа. Қызықлы уйын ул заманда. Қәзер тилевизыр да компийутыр.

Йәшермәкне урычча пр'атки диләр.

Эштән қайтамыз да урамға шығамыз. Урамга җыйылабыз бөтенемез, третий лишний уйныймыз балалар белән, ана сун аwызымызда саз тартып биимез. Уннан сәғәт унике булдымы, ахыраннар безде қуwалар, қайтығыз өйегезгә, дип. Қайтып китәмез өйемезгә.

Саз тартамыз аwызымызда, көй әйтәмез.

Әттә генә генәме?
Гармунчығыз өйдәме?
Өйдә булса, килсен әле,
Бийетеп китсен әле.

Үпкәлибез, үпкәлибез,
Үпкәлимез килмәсә.
Гармун күтәб йөрмәсен,
Бийү көйен белмәсә.

Менә шулай тартып, әкрен генә бийеп китәбез.

*Сөйләүче: Курманова Нәсимә*
*Насыйр кызы (1939 елгы).*
*Киләче авылы*

Йәшермәк, қапқашар уйнадық, былибул (рус. *волейбол*) шул қапқашар инде. Чиртә уйнадык (рус. *классики*). Қапқашар буймәчә (рус. бей в мяч) дип тә әйтәмез. Йәшермәк – русча прятки.

Эштән қайтамыс та урамға чығамыз, жыйылабыз бөтөнебез, теритий лишний уйныйбыз, бар көй уйныймыз, аузымыздан уйнап саз тартамыз (*авыздан көй чыгару*).

Менә шулай итеп әтнәгә бийеп китәмез, қайсы нуғайча, әтнә көйләре димез. Қыруг уйнисын, уртада бер кеше, йырлыймыз, анан сун ул кеше берәүне барыб алады, йырламағамы, теге кеше кыруққа басады. Йырламаға беләмә?

Кисәң дә, кимәсәң дә.
Син минеке, мин синеке
Сийсәң дә, сиймәсән дә,

дип йырлый тыған идек.

Китә қазлар көзлектә.
Шәшәк кебек йәш ғөмөребез
Үтте бәхетсезлектә.

*Сөйләүче: Нурмөхәмәдова Сафура*
*Абдулгазиз кызы (1927 елгы).*
*Киләче авылы*

Элкедән бездә булган әмил, йазда. Иген басайақ заманда (*иген чәчәр алдыннан*) булган, көрәш булған.

Игенне айның башында чәчкәндә қорый диләр, айнын азағында чәчсән, су була. Әwәлдә көнгә қарап иген эшләгәннәр. Әнә салаwат күпере чықты, көн айаза диләр. Анан инде Қәсән-Қөсәйен җәйәсе дип әйтә торғаннар ийе, дуға кебек булып, җәйә дип әйтә торғаннар ийе.

Томана кешене арда диләр бездә, невежда булса. Май қарағайдан өй салғаннар. Ағачын кисеп булмый, чәйер генә, май қарағай (*сагызлы нарат*) диләр. Wақтында (бу өй) бик (*биек*) булған, менәргә бийек чапраш (*баскыч*) бар иде, бала чарлақлы (*балконлы*) йы, ике йөз йыл утыра бу өй, бер қадақсыз. Халық бик оста булған. Байның қызлары бала чарлақта утыра булғаннар, саз тартып.

Байның қызы чарлақта,
Ике күзе йан-йақта.
Байның қызын бай алмаған,
Илтеп биргән бурлаққа.

Йалчылары хезмәт итә инде, қызлары шунда чарлақта йегетләрен сақлаб утырғаннар. Қаwал тартып утырғаннар. Әwәле һәрбер аwылда эскерипкәчесе бар иде, қаwалчысы, сазчысы бар иде.

Бара идем күпердән
Йығлып төштем күпердән.
Бер йегетне сөйгән идем,
Кәзә сөзөб үтергән.

Бер йегетне сөйгән идем
Исеме иде Ғафур.
Йөрәкләремне йандырды
Қарғалықта (*авыл исеме*) бер матур.

Йәш wақытта парум өстендә бии торған идек. Анда эримин уйный торған идеғ инде.

Йегетләр эриминнәрен шишеб алалар да шарт итеп суғалар, арқаң ийоп қала инде суққан wақытта. Анда теге ачуланышқан қызларға шатырдатып суға торғаннар ийе эримин белән.

Аннан инде мал салыб уйный торған идек. Инде жийылып утырабыз да. Қыш көнендә барырға суқыр лампа суқырайып тора. Мал салғанда тезелеп утырабыз да кемнең қулына төшә, шул чығып йырлый йә бии инде. Теге бис канса дигәнне.

Өч иркәк малай артыннан бер қыз булып үсте. Аның сийқасы бар, анарға йарамый азарларға дийә иде атасы. Берәрсе абижайт итсә аңа зарары тийә.

*Сөйләүче: Бирдиева Рухия*
*Хөсәен кызы (1928 елгы).*
*Каргалык авылы*

Су анасы бар, өй ийәсе бар. Шайтаннар биләб утырады. Ничә қарам (*мәртәбә*) уқыса да тынычланмый. Йатпаға (*ятарга*) бирмиде, бастырыласын тоссос баwырсақ пешерәсен дә чарлаққа (*чормага*) қуйасын. Тоссоз, майсыз пешерәсен аны.

Су анасы, суға төшпәгә (*төшәргә – коенырга*) барсан, айақны тартады, мин бармаға қурқам.

*Сөйләүче: Бикбулатова Мәгърифә*
*Сәйфулла кызы (1939 елгы).*
*Кызан авылы*

## Ырымнар, авырулар

Тирескән чықса мах-мах саған (*сиңа*) дип, кукиш күрсәтәсен.

Қыйарақ чықты қултығымда, урыслар сучье вымя диме. Бырачлар кисәмез диләр, киспәгә (*кисәргә*) бирмәдем.

Балаға күз тийәде, пышақ беләкурқытасын, дува (*дога*) йазып саласын йантығына.

*Сөйләүче: Нурмөхәмәдова Сафура*
*Абдулгазиз кызы (1927 елгы).*
*Киләче авылы*

Эргә йасыйлар, дүрт зат (*биредә: бүрәнә, ниргә*) салалар да йасыйлар, доғалық йазып саласын, зат арасына, түр битенә (*ягына*) салынады доғалықны, бағанны (*матчаны*) иркәкләр (*ирләр*) меңгезәте.

Йорт ийәсе ишеттерә әмән. Адаштыра да ул. Йарлы Түбә аwылына барғанда безне адаштырды. Барғанда Йарлы Түбәне (*авыл*

*исеме*) эзләп йөрдек. Ике қыз ийек. Қурықсаң да бисмилланы әйтеп йөрәсен.

Су анасы дип сөйлиләр ийе, чәчен үрә дип, атнықын.

*Сөйләүче: Ибәтуллаева Шәһәрбану*
*Хөсәен кызы (1923 елгы).*
*Җәмәле авылы*

Қызылча үзенең wахыты җитми бетми диләр.

Қызамық белән аwырды, чәчәк чығарды.

Кәпәшкә (*түбәтәйгә*) буйтомар (*догалык*) тегеп куйа торған булғаннар күз тимәсен дип. Кечке (*кечкенә*) балаға күз тимәсен дип.

Чәчләренә тәңкә тағып йөрегәннәр.

*Сөйләүче: Бикбулатова Асия*
*Абдразак кызы (1937 елгы).*
*Ярлы Түбә авылы*

Өй ийәсе диләр, йырт ийәсе. Бу урынны алғач күчендек. Тақтадан чарлақ йасалған. Күчкән идем, йоқы бирми. Йырт ийәсе йаратмаса қамышаулый (*комачаулый*) кешегә. Мөйескә дувалық қуймаға қушалар. Күченгәндә арбаға күсәркә (*кисәү агачы*) қуйып, йорт ийәсен үзен мән бергә шақырадылар икән.

*Сөйләүче: Бирдиева Гөлфәридә*
*Дуллаян кызы (1939 елгы).*
*Ярлы Түбә авылы*

Күз тисә пычақ белә қурқыта торған булғаннар. Белмәгән кешеләрнең күздән чечеп (*шешеп*) китәде. Доға йазабыз, башнын чепчик асынан тегеп қуйа торғаннар ийе.

Қызба була, урысча малярий.

Мата (*тукыма*) алабыз, тәрит җаулык // бит җаулык тегәмез, пыйалаға (*көзгегә*) элеп қуйамыз. Қызым кийәwе эшләп китте түбәне (*түшәмне*), арғылдақ күренми қәзер. Өч кәрәм (*мәртәбә*) сылыйсын өйне, йылы булсын дип.

Аман қороға китсә, мал суйып Қоран уқыйдылар, қан шәшәделәр, теләк телиделәр. Бер ике-өч көннән йаwады йаңғыр, теләк телиделәр дә.

Суғанны күб иккәннәр, 2 тақта. Тақта зур, эчендә 20 грәдка. Ашақ буйақ (*үлән исеме*) күб үсәде, бөлдөргән (*кара кура*

*җиләге*) булады бездә. Көзлөк булады, көзлөк пешәнне шаwыб аласын.

*Сөйләүче: Нурмөхәмәдова Сафура*
*Абдулгазиз кызы (1927 елгы).*
*Киләче авылы*

Қушаматлар бар халықта, исемә төшөрә алырым микән. Шәһәрбану мамай дисәләр мин булам инде.

Перепис wақытында нуғай йазылмыйды, татар дип йазылабыз без.

Син алтыннын бер кисәге, кечкенә булсан да, дим кийәүгә. Алтын кечкенә булады. Тәмәке чикмей, аракы эчми. Олы (*ир баласы*) туды. Қайнатасы зур, олым да қайнатам күк булса иде, ди. Тәртипле, йомшақ қына сүләшә кийәwем.

Доға йазып җибәрәсен, буйтомарға йақшы доға йазып саласын, бәлә-қазадан сақла дип.

Көнө буйы бер үзем утырдым. Китап уқыйм, теләп уқыйм шуны. Минем әйем Қазанда туыб үскән. Әтисе булмаған. Әнисе бергә мәчеткә йөргән кешегә биргән дә йебәргән. Қала қызы нуғайға аwылға чыққан. Ул қала қызы бөтен аwылда кендек кискән. Күлмәк тегеп кийезәде, балаға тақыйа тегеп кийезәде.

Ибраһим қағам (*абый*) бар иде. Қарт мамам қатыннарны қарыйды, бөтенесен белә иде. Бабамны төрмәгә салдылар уқымаған дип. Шунда төрмәдә үлде.

Менә мийә күз тигән балаларны алып киләләр, өшкөрәм. Қурққан кешеләргә қурғашин қойам. Шуға күңел салып киләделәр дә сауайып китәделәр. Эретеп қурғашин қойам, қурқулық қойам, шул инде. Қурғайшинны эретеп, баш түбәсенә табаққа суақ суға қойасын.

Күз тисә дә киләләр, өшкөрәм уқыйм да. Тирескән (*арпа*) чыққанын беләм. Хәзер берәү дә белми. Әзил заманда (*элекке заманда, бик борынгы заманда*) була иде, хиналар йотқызып. Шупыр чыққан Асийә апаға, өлкән уқытучы ийе ул, ураза тотады, йәшереп аwыз ачтырады. Йақшы уқытучы иде.

*Сөйләүче: Ибәтуллаева Шәһәрбану*
*Хөсәен кызы, (1923 елгы).*
*Җәмәле авылы*

# ТАМЫРЛАРЫ ТАРИХКА ТОТАШКАН

*Флера Баязитова*

Идел елгасының түбәнге агымында урнашкан Әстерхан шәһәрендә һәм аның тирә-ягындагы районнарның аерым авылларында яшәүчеләр татар халкының бер өлешен тәшкил итәләр.

Тарихи материаллар күрсәткәнчә, Әстерхан өлкәсе татарлары әлеге төбәктә элек-электән гомер иткән төрле этник төркемнәр (кундрау татарлары, юрт татарлары, карагатлар, мишәрләр, казан татарлары һәм нугайлар) катнашында, аларның аралашуы нәтиҗәсендә формалашкан. Ул төркемнәрдә тел ягыннан кайбер үзенчәлекләр бүгенге көннәргә кадәр сакланса да, алар бер-берсенә бик нык тәэсир итешкән, берсен-берсе баеткан.

Әстерхан сөйләше Л.Ш. Арсланов тарафыннан өйрәнелгән, бу хакта аның күп санлы мәкаләләре җыентыгы (1976) һәм монографиясе (1995) дөнья күргән. Соңгырак елларда минем үземә дә Әстерхан өлкәсе татарларының сөйләшләрен, рухи культурасын, йола сүзләрен, терминологияне өйрәнү максаты белән күп кенә авылларда экспедицияләрдә булырга туры килде. Анда тупланган этнолингвистик, диалектологик материаллар нигезендә язылган мәкаләләрем (1992) һәм монографиям (2002) басылып чыкты.

Әстерхан сөйләше вәкилләрен фәнни хезмәтләрдә юрт татарлары дип атау гадәткә кергән, алар җирле халыкны тәшкил итә. Тарихи язмалар күрсәткәнчә, алар Алтын Урда чорларында ук шул төбәктә яшәгәннәр, юрт татарлары турында Әстерхан шәһәренә нигез салган халык дигән фикер дә бар. Юрт татарлары Әстерхан өлкәсенең Идел буе районы Киләче (Килинчи), Кызан (Тат. Башмаковка), Җәмәле (Три Протока), Сүләнкә (Солянка), Карагалык (Каргалы), Майлы Күл (Яксатово), Ярлы Түбә (Осыпной Бугор),

Казавыл (Мышаяк) авылларында һәм Әстерхан шәһәренең Аргы Тияк, Бирге Тияк дип аталып йөртелгән төбәкләрендә яшиләр, аларның сөйләшен шартлы рәвештә **юрт урынчылыгы** дип атыйбыз. Әстерхан өлкәсендә төрле районнарда төп үзенчәлекләре белән әстерхан сөйләшенә карый торган аерым-аерым авыллар бар. Тарихи сәбәпләр нәтиҗәсендә аларның сөйләшендә кайбер үзенчәлекле күренешләр яшәп килә. Шуңа бәйле рәвештә әстерхан сөйләшендә тагын **җидәле, кундрау, линейное, картузан** урынчылыклары аерылып чыга.

**Юрт урынчылыгы** әстерхан сөйләшенең төп үзенчәлекләрен үзендә бөтен тулылыгы белән чагылдыра.

## Фонетик үзенчәлекләр

Сузыклар: *а* – иренләшмәгән ачык аваз: *ал, алма, асау* (ат).

**Ә** авазы үзенең әйтелеше һәм ясалышы ягыннан татар әдәби телендәге *ә* авазыннан аерылмый. Ул сүздә төрле позициядә килә ала: *тәрәзә, иләк, әрү* (яхшы), *әмәм* (әни).

Кайбер очракларда, сүзнең алдагы иҗегендә тар *и* сузыгы булганда, аннан соңгы иҗектәге *ә* авазы чагыштырмача таррак *ә̂* булып әйтелә: *шикә̂р* – шикәр, *ирка̂к* – ир кеше, *кирә̂к* – кирәк һ. б.

Киң әйтелешле *о* ирен авазы өлкән буын вәкилләре сөйләшендә аерым сүзләрдә генә кулланыла: *той* – туй, *қол* – кул, *орта* – урта.

Кыска әйтелешле *о* ирен авазы сөйләштә берникадәр иренсезләшеп *ы$^о$* кебек булып әйтелә: *ы$^о$н* – он, *ты$^о$з* – тоз, *ты$^о$лым* – толым, *қы$^о$лақ* – колак.

Өлкән буын вәкилләре сөйләшендә (татар теленең мишәр диалектындагы, нугай, казакъ, каракалпак һ.б. телләрдәге кебек) киң әйтелешле *ү$^ө$* дифтонгын куллану еш очрый: *кү$^ө$л* – күл, *сү$^ө$з* – сүз, *өлкү$^ө$н* – өлкән, *ү$^ө$рнәк* – үрнәк.

Әдәби телдәге *ө* сузыгы берникадәр иренсезләшеп *е$^ө$* кебек әйтелә: *те$^ө$тен* – төтен, *те$^ө$н* – төн, *те$^ө$лке* – төлке, *се$^ө$т* – сөт.

Дифтонглар. Әстерхан сөйләшендә фигыльләрдә, нигездә, *-ый/-ий* һәм *-ай/-әй* дифтонглары параллель кулланыла: *бармайды//бармыйды, ашайды//ашыйды. -ай/-әй* дифтонглары ешрак өлкән буын хатын-кызлар сөйләмендә очрый.

Туганлык терминнарында һәм кайбер исемнәрдә дә *-ай/-әй* дифтонгы кулланыла: *җизнәй* – җизни, *түтәй* – түти, *атай-анай* – ата-ана, *қодағай* – кодагый, *әпәй* – ипи.

Аваз тәңгәллекләре. **И ~ ә:** *тирәзә* – тәрәзә, *пирдә* – пәрдә, *тигәршек* – тәгәрмәч, *синәк* – сәнәк, *пике* – пәке, *бишмит* – бишмәт, *мичет* – мәчет.

**Э (е) ~ ү:** *беген* – бүген, *тегел* – түгел.

**А ~ ы:** *булар* – булыр, *барар* – барыр, *барама* – барамы?

Алгы һәм арткы рәт сузыкларын берсе урынына икенчесен куллану: *әрү* – ару (әйбәт, яхшы), *әрзән* – арзан, *тәнәкәй* – тана, танакай, *бедәй, бидай* – бодай, *тәтлем* – татлым, *сәwәп* – савап, *шашбау* – чәчбау.

Иҗекләр төшү һәм ике сүзнең бергә кушылып әйтелү очраклары: *әкил//акил* – алып кил, *бийтеп* – болай итеп.

Тартыклар. *К, ғ* – тирән тел арты тартыклары, татар әдәби теле белән чагыштырганда, тагын да арткырак артикуляциядә ясалалар: *қарға, мағa//миға* – миңа, *саға//сиға* – сиңа, *қабақ, қыдыру* – чабып йөрү.

Тирән тел арты *ғ* тартыгы сүз башында, нигездә, кеше исемнәрендә генә кулланыла: *Ғәли, Ғазиз, Ғалимә.* Гарәп-фарсы телләреннән кергән сүзләрдә күпчелек очракта ул төшә: *адат* – гадәт, *айып* – гаеп, *әҗеп* – гаҗәп, *аскәр* – гаскәр.

Ике сүз янәшә килгәндә, алдагы сүз *л, н* авазларына беткән очракта, сүз башындагы *к* тартыгы ассимиляцияләнергә мөмкин: *мал ғура* – мал кура (абзар), *ын ғуна* – он куна (он кунасы, куна тактасы), *бал ғырты* – бал корты.

Алдагы сүз сузык яки яңгырау авазларга беткән очракта, сүз башындагы *к* авазы яңгыраулашырга мөмкин: *безгә гилде* – безгә килде, *сине гүрепте* – сине күргән, *бер ген* – бер көн, *Майлы гүл* – Майлы күл (ав. ис). Кайбер очракларда, киресенчә, тел арты *г* тартыгы саңгыраулаша, ягъни **к ~ г:** *көбе* – гөбе, *чикә* – чигә.

*Х* – тирән тел арты тартыгы, берничә сүздә генә очрый: *хыйлы* – күп, *қахам* – абый, *тыхым* – көнбагыш, *ахтара* – ыргыта, *бахча* – бакча, *хәберлек* – каберлек, *хаза* – каза. Калган очракларда тирән тел арты *х* тартыгына *к* туры килә, ягъни **қ ~ х:** *қуҗалық* – хуҗалык, *қәл* – хәл, *қатын* – хатын, *қабар* – хәбәр, *қур булу* – хур булу, *Қапиз* – Хафиз. Ләкин бу күренеш күбрәк өлкән буын кешеләре сөйләшенә хас, урта һәм яшь буын сөйләшендә *хәл, хатын, хәбәр* һ. б. кулланыла.

**П ~ ф.** Ирен-ирен *ф* тартыгы сөйләштә сирәк кулланыла, күпчелек очракта ул ирен-ирен *п* яки *б* тартыгы белән алмашына:

*тупрақ* – туфрак, *керпек* – керфек, *йапрақ* – яфрак, *йебәк* – ефәк, *кипен* – кәфен.

**Б ~ п.** Ирен-ирен саңгырау *п* тартыгы аерым сүзләрдә яңгырау *б* белән алмашына: *билмән* – пилмән, *былау* – пылау; шулай ук **б ~ ф:** *Әлбийә* – Әлфия.

**Ш ~ ч** кайбер сүзләрдә генә очрый: *пышқы* – пычкы, *шабақ* – чабак, *шық* – чык, *шатырлы туй* – чатырлы туй, *шашбау* – чәчбау.

Әстерхан сөйләшенә *җ*-ләштерү һәм *й*-ләштерү хас. **Й ~ җ** сүз башында ешрак күзәтелә: *йибәрү* – җибәрү, *йаратам* – яратам, *йусан* – әрем, *йаулық*– яулык, *йақшылық* – яхшылык; *җил, җәйәү*– җәяү, *мәрҗән, җаwап, бажҗа, әҗеп* – яхшы.

**Н ~ ң** аерым сүзләрдә күзәтелә: *тунам* – туңам, *унай* – уңай, *тыннаусыз* – тыңлаусыз, *ун* – уң, *мен* – мең. Кушымчаларда (фигыль һәм алмашлыкларда): *синен* – синең, *безнен* – безнең, *барасын* – барасың, *мынын* – моның, *қыздын* – кызның һ. б. Ләкин түбәндәге сүзләрдә тел арты *ң* саклана: *йаңғыр* – яңгыр, *йаңғыз* – ялгыз, *чыңқыр* – чокыр.

**М ~ б:** *чымылдық* – чыбылдык, *мәлеш* – бәлеш, *ман/менән* – белән, *билмау* – билбау, *мырын* – борын, *мере* – бөре; **м ~ б** күренеше беренче зат хәзерге заман хикәя фигыльләрдә, тартым кушымчаларында да очрый: *қайтамыз* – кайтабыз, *китәмез* – китәбез; *китабымыз* – китабыбыз, *ийләремез* – өйләребез. Мәсәлән: *Бер сыйырымыз* (сыерыбыз), *бер атымыз* (атыбыз) *бар. Атамыз* (атабыз) *суғыштан килгән. Икемез* (икебез) *ике йаққа йөри бирәмез* (бирәбез) *туйларға.*

**Д ~ н.** *Й, м, л, р, з* тартыкларына беткән сүзләрнең иялек һәм төшем килешләрендә, шулай ук тартым кушымчаларында әдәби телдәге *-ны, -не, -ның, -нең* урынына *-ды/-де, -дын/-ден* кушымчалары ялгана: *әти-йемде* – әтиемне, *әнийемде* – әниемне, *сыйырды* – сыерны, *сыйыр-дын* – сыерның, *қуйдың* – куйның, *қаздын баласы* – казның баласы, *қыздын анасы* – кызның анасы.

Авазлар һәм иҗекләр төшү: *әр* – һәр, *аман* – һаман, *аwа* – һава, *әкитә* – алып китә, *қәртәсе*– карт этисе, *ман* – белән, *қалқ* – халык.

## Грамматик үзенчәлекләр

**Исемнәр.** Исем-исем сүз тезмәләрен кушымчасыз гына кулланy очраклары бар: *кизәк ут* – кизәк уты, *килен чәй* – килен чәе, *қуз*

*бәлеш* – чикләвек бәлеше һ.б. Мисаллар: *Қыз биттән* (кыз ягыннан) *бирәләр нуғай мәлеш* (ит бәлеше). *Нике табаққа* (никах табагына) *бер табақ итеп баwырсақ пешереп сала, нике баwырсақ* (никах бавырсагы) *була. Қыз йағында барған туй – кийәү сый* (кияү сые) *әйтелә.*

Тартым кушымчалары алган исемнәрнең зат белән төрләнүендә түбәндәге үзенчәлек күзәтелә: II зат берлек санда *ң* авазы урынына *н* авазы кулланыла, күплек санда исә I затта *-мыз*/*-мез* (-быз/-без), II затта *-ныз*/*-нез* (-гыз/-гез) кушымчалары ялгана: Мәсәлән: *бабам, бабамыз* – бабам, бабабыз; *бабан, бабаныз* – бабаң, бабагыз; *бабасы, бабалары.*

*-нықы*/*-неке* тартым кушымчаларының *-дықы*/*-деке* вариантлары да кулланыла: *атнықы, минеке, аwылдықы* – авылныкы, *бездеке* – безнеке, *сездеке* – сезнеке.

Килеш белән төрләнгән исемнәрнең иялек һәм төшем килеш кушымчалары үзенчәлекле. Нигезе *с, ш, т, к, п* тартыкларына беткән сүзләргә иялек һәм төшем килешендә *-ты*/*-те, -тын*/*тен* кушымчалары ялгана, ә нигезе *й, л, м, р, з* тартыкларына беткән сүзләргә *-ды*/*-де, -дын*/*-ден* кушымчалары ялгана. Мәсәлән: *қардын* – карның, *қарды* – карны; *картуп* (бәрәңге), *картуптын, картупты; қаздын* – казның, *қазды* – казны.

Тартымлы исемнәр килеш белән төрләнгәндә дә шундый ук үзенчәлек күзәтелә: *Қыз wақытта, ускәндә башымдан* (башымнан) *чишеп, билемдән* (билемнән) *билмауны чишеп, айақтан атуны салып утырғанда ағаларым килеп қалса: «Тиз билеңде* (биленне) *бу, айағыңа ки», – ди.*

II заттагы тартым кушымчалы исемнәргә юнәлеш килешенең әдәби телдәге *-га*/*-гә* кушымчалары урынына *-а*/*-ә* ялгану очраклары бар. Мәсәлән: *Қызымыза* (кызыбызга) *атқушар мәҗлескә* (исем кушу мәҗлесенә) *чақырам. Өйөмезә* (өебезгә) *кереп бадамгел* (өйдә пешерелгән перәннек) *белән чәй эчеп киттеләр. Безнең улымыза* (улыбызга), *қызымыза* (кызыбызга) *қузқолак булырсың, берәр йаман* (начарлык) *ишетсәң, безгә хәбәр итәрсең.*

**Алмашлыклар.** Юнәлеш килешендәге I һәм II зат алмашлыклары берничә вариантта кулланыла: *маға, маған, миған* – миңа, *саға, саған, сиған* – сиңа. Мисаллар: *Маға* (миңа) *күзен қысып айтады ғу, йаман булмайым ғу. Маған* (миңа) *балалар анам*

*дип айтадылар. Миған* (миңа) *әйткән кеше йук. Сиган* (сиңа) *Алла саулық бирсен. Саға* (сиңа) *рәхмәт.*

III зат алмашлыгы ул юнәлеш килешендә берничә фонетик вариантта килә ала: *аға, уға, уған, уғар, анаға, унаған* – аңа. Мисаллар: *Уға* (аңа) *да хат килде. Мин бирдем уған* (аңа) *өч манит. Уғар* (аңа) *қайық кирәк арғы йаққа чықпаға. Сүзләр анаға* (аңа) *кирәк. Қода төшер туйда қыздын әти-әниләренә җимеш бирәде, йақын ағасы булса, җиңгәсе булса уған* (аңа) *бирәде. Хатын-қыз җиргә җалан айақ басса, аға* (аңа) *иблис бит диде.*

Күрсәтү алмашлыкларының төрләнешендә дә кайбер үзенчәлекләр бар: *бу, мынын* – моның, *быға, буға, бығай* – моңа, *мыны, мыннан, мында; сул//шул, сунын//шунын, суға//суғай//шуға// шуған* – шуңа, *суны//шуны, суннан//шуннан, сунда//шунда; мынау// монау* – бу, *мынаунын* – моның, *мынаға* – моңа, *мыны, мынауны* – моны, *мыннан, мынауда* – монда. Мәсәлән: *Уны бығай бирәде* (аны моңа бирә). *Бир шуға, шуға бирче* (бир шуңа, шуңа бирче). *Быға* (моңа) *сет тә қайнатмадық.*

Сөйләштә еш кына *анау, монау, монади* алмашлыклары да кулланыла: *Раwил анауда* (анда) *утырды. Анаwы* (ансы) *да қартайды, монаwы* (монсы) *да қартайды. Монауға* (моңа) *да бирәбез, анауға* (аңа) *да бирәбез кийет* (бүләк). *Монауларны* (боларны) *буйады. Монади* (мондый) *йефәк.*

Сирәк очракларда *қалай* (ничек) сорау алмашлыгының кулланылуы да күзәтелә: *Қалай булады ул* (ничек була ул)?

**Рәвешләр**. Сөйләштә рәвешләрнең *-лай/-ләй, -лата/-ләтә* кушымчалары белән ясалган формалары кулланыла: *Суғанды йәшелләтә сатпаға йақшы. Анау йақлардан мадур* (помидор) *йәшелләй* (яшел көенчә) *барады. Пылауны қайнарлай* (кайнар көе) *ашамаға тәмле.*

*-дай/-дәй, -дый/-ди* кушымчалары белән ясалган рәвешләр дә сөйләштә актив кулланыла: *Қунақларны йаратмағандый булып* (яратмаган кебек) *йеремез. Қураздый* (әтәч кебек) *булып йерәсен. Кеше сөймәгәнди* (яратмаган сыман) *булып утырма, кешегә ашыңды бирмәсәң дә қашыңды бир, диләр бездә. Қуйы қаймақтай булып торды дәwә сөте. Сөттәй ап-ақ йул булсын дип, қызга сөт эчертәләр. Бутлақ* (су чикләвеге) *ул картуптай була иде, суда пешереп ашый торган идек.*

**Фигыльләр**. Затланышлы фигыль формалары. Хәзерге заман хикәя фигыльләрнең зат кушымчалары алып

төрләнүендә үзенчәлекләр күзәтелә. Мәсәлән: *бара-ман, бара-мыз* – барам, барамын, барабыз, *бара-сын, бара-сыз* – барасың, барасыз, *барады, барадылар* – бара, баралар. Юклык формалары: *бармаймын / бармыймын, бармайбыз / бармыйбыз.*

Кайбер очракларда *-ды/-де* кушымчасы саңгырау *т* булып әйтелә һәм соңгы *ы, е* сузыклары төшә: *Синди қартлар килеп тырат* (тора), *дит* (ди). *Кешеләр әрмийәдән өлкун булып кайтат* (кайта). *Қазах атқа менсә, дынйасын ынытат* (онытa). *Қодаға йағалы кийем йабат* (бирә), *кийет әзерләп торат* (тора). *Өй ийәсе сәғәт булып суғат* (суга), *чикерткә булып қычқырат* (кычкыра), *тургай булып сайрат* (сайрый) *диде.*

Фигыльләрдә *-ды, -де (т)* кушымчалары ялгану күренеше себер диалектлары өчен дә хас.

Сөйләштә юклык формасының әдәби варианты ешрак очрый. *-ай/-әй* варианты исә нигездә олы кешеләр сөйләменә хас.

Хәзерге заман хикәя фигыльләрнең *-а/-ә, -й, -ып/-еп йата, утыра, тора* конструкцияләре белән ясалган төре дә кулланыла. Ул эш-хәлләрнең нәкъ сөйләү моментында башкарылуын белдерә, зат кушымчалары ярдәмче фигыльгә ялгана: *бара йатырмын, бара йатырмыз; бара йатырсын, бара йатырсыныз; бара йатыр, бара йатырлар;* юклык формасы: *бармай йатырым//бармай йатырмын, бармай йатырмыз; бармай йатырсын, бармай йатырсыныз//бармай йатырсыз; бармай йатыр, бармай йатырлар.*

Үткән заман. Категорик үткән заман формасының II зат төрләнеше әдәби телдәгечә: *бардым, бардық; бардын, бардыныз* – бардың, бардыгыз; *барды, бардылар;* юклык формасы: *бармадым, бармадың; бармадын, бармадыныз* – бармадың, бармадыгыз; *бармады, бармадылар.*

Нәтиҗәле үткән заман *-ып/-еп* формалы хәл фигыльләргә зат кушымчалары ялганып ясала: *барыптым, барыптық* – барганмын, барганбыз; *барыпсың, барыпсыз* – баргансың, баргансыз; *барыпты, барыптылар* – барган, барганнар; юклык формасы: *бармаптым, бармаптық* – бармаганмын, бармаганбыз; *бармапсын, бармапсыз* – бармагансың, бармагансыз; *бармапты, бармаптылар* – бармаган, бармаганнар. Мисаллар: *Сусыз қалдырыпсыз* (калдыргансыз) *мине, чайға су йуқ булып қалыпты* (калмаган). *Алма тирәк утыртыпсыз* (утырткансыз), *төбе чайырлы булсын.*

*Матур қызлар туwыптылар* (туганнар),
*Ал күлмәкләрен җуwыптылар* (юганнар).
*Узып барған wахытта байның улы күрепте* (күргән),
*Башын чайқап китепте* (киткән).

Күптән үткән заман *-ып/-еп иде* конструкциясенә зат кушымчалары ялганып ясала: *барып идем, барып идек* – барган идем, барган идек; *барып иден, барып иденез* – барган идең, барган идегез; *барып иде, барып иделәр* – барган иде, барган иделәр, барганнар иде; юклык формасы: *бармап идем, бармап идек* – бармаган идем, бармаган идек; *бармап иден, бармап иденез* – бармаган идең, бармаган идегез; *бармап иде, бармап иделәр* – бармаган иде, бармаганнар иде, бармаган иделәр. Мисаллар: *Бер маман әүләсендә* (ишек алдында) *су эчте, картуп утыртып иде* (утырткан иде). *Мин бераз латинча уқып идем* (укыган идем).

Сөйләштә аерым очракларда *-ған/-гән* кушымчалы фигыльләргә *-да/-дә* урын-вакыт килеше кушымчалары ялганып ясалган *-ғанда* формасы кулланыла. Ул әдәби телдә вакыт хәлен белдерә, ә әстерхан сөйләшендә, урта диалектның нократ сөйләшендәге кебек, җөмләнең хәбәре булып килә. Мисаллар: *Башына тастар төшкәндә* (төшкән) *диде қыз бала кийәүгә киткәч, тастарлы була, тастар – сылаwыч белән йөриде. Чарылдап җиргә төшкәндә* (төшкән), *кендегеңде кискәндә* (кискән), *диде.*

Кабатлаулы үткән заман *-а, -ә, -й* формалы хәл фигыль *даған/тоған/торған иде* конструкциясе һәм зат кушымчалары ярдәмендә ясала: *барадаган идем / баратоган идем, барадаган идек / баратоган идек* – бара торган идем, бара торган идек; *барадаған иден / бара тоған иден, барадаған иденез / баратоған иденез* – бара торган идең, бара торган идегез, *барадаған иде / бара тоған иде, барадаған иделәр / бара тоған иделәр* – бара торган иде, бара торган иделәр; юклык формасы: *бармайдаған идем / бармай тоған идем, бармайдаған идек / бармай тоған идек* – бармый торган идем, бармый торган идек; *бармайдаған иден / бармай тоған иден, бармайдаған идегез / бармай тоған идегез* – бармый торган идең, бармый торган идегез; *бармайдаған иде / бармай тоған иде, бармайдаған иделәр / бармай тоған иделәр* – бармый торган иде, бармый торган иделәр. Мисаллар: *Без мадур* (помидор) *арасында йатадаған идек* (ята торган идек). *Безем қалқ иген игәдәгән иде* (игә торган иде). *Ул мында килеп сәүдә итәдәгән иде* (итә торган иде).

*Йегетнең өйөндә җиңгәләр була тоғаныйы* (була торган иде). *Йегетнең қапысы ачык, қапы алдына қамыштан ут йағадылар, ут алдыннан керә доғаныйы* (керә торган иде) қ*ыз.*

Дәвамлы үткән заманың *-а/-ә, -й булған* формасы да сөйләштә шактый актив: *Бала йуwындырған суны чоқыр қазып күмә булғаннар* (күмә торган булганнар). *Зират бәйрәмендә теләк йасый булғаннар* (ясый торган булганнар), *су сибешкәннәр*.

Киләчәк заман. Билгесез киләчәк заман *-ыр/-ер, -ар/әр* формалы сыйфат фигыльгә зат кушымчалары ялганып ясала: *барармын, барармыз* – барырмын, барырбыз; *барарсын, барарсыз // барарсыныз* – барырсың, барырсыз; *барар, барарлар* – барыр, барырлар; юклык формасы: *бармам, бармастык // бармамыз* – бармам, бармабыз; *бармассың, бармассыз // бармассыныз* – бармассың, бармассыз; бармас, бармаслар. Мисаллар: *Кахам қайтқанда син дә қайтарсын. Әтиләр, без тырмастық* (тормабыз).

Билгеле киләчәк заман формасы *-айак/-әйәк* формалы сыйфат фигыльләргә зат кушымчалары ялганып ясала: *барайақпан // барайақман, барайақпыз // барайақмыз* – барачакмын, барачакбыз; *барайақсын, барайақсыз // барайақсыныз* – барачаксың, барачаксыз; *барайақ, барайақлар* – барачак, барачаклар; юклык формасы: *бармайақпан // бармайақман, бармайақпыз // бармайақмыз* – бармаячакмын, бармаячакбыз; *бармайақсын, бармайақсыз // бармайақсыныз* – бармаячаксың, бармаячаксыз; *бармайақ, бармайақлар*– бармаячак, бармаячаклар.

Үткән киләчәк заман *-айак, -әйәк* формалы сыйфат фигыль һәм *иде* ярдәмче фигыленә зат кушымчалары ялганып ясала: *барайақ идем, барайақ идек* – барачак идем, барачак идегез; *барайақ иден, барайақ иденез* – барачак идең, барачак идегез; *барайақ иде, барайақ иделәр* – барачак иде, барачак иделәр; юклык формасы: *бармайақ идем // барайақ тегел идем, бармайақ идек // барайақ тегел идек* – бармаячак идем // барачак түгел идем, бармаячак идек // барачак түгел идек; *бармайақ иден // барайақ тегел иден, барайақ тегел иденез // бармайақ иденез* – барачак түгел идегез, бармаячак идегез; *бармайақ иде // барайақ тегел иде, бармайақ иделәр // барайақ тегел иделәр* – бармаячак иде // барачак түгел иде, бармаячак иделәр // барачак түгел иделәр.

Боерык фигыль кушымчаларында фонетик яктан кайбер аерымлыклар күзәтелә: *бар, барың // барыныз // барыңыз* – бар,

барыгыз; *барма, бармаң // барманыз // бармаңыз* – барма, бармагыз. Мисаллар: *Ике кәрәм бармаңыз, кичкә таман йатайақта барарсыз* (ике тапкыр бармагыз, кичкә таба ятар алдыннан барырсыз). *Килен килде – күрегез, күремлеген биреңез* (бирегез). *Син тынна, қызым. Аман булыңыз* (булыгыз). *Айағын йәрәшсен, бәхетле булыңыз* (булыгыз), *дип әйтәде киленгә. Қараңғыда тирәзәдән қарамаң* (карамагыз), *йалан баш далаға чықмаң* (чыкмагыз), *башығызға бәйләп чығың* (чыгыгыз) *диләр бездә. Ак күңел белән кереңез* (керегез), *бәхетегез белән кереңез* (керегез).

Теләк фигыль. Беренче зат берлек һәм күплек сандагы теләк фигыльләрнең кушымчасы әдәби һәм диалекталь вариантта кулланыла: *-ыйм/-им, -ыйк/-ик* һәм *-айым/-әйем, -айык/-әйек.* Мисаллар: *Мин қардәшләрем белән киңәшәйем* (киңәшим), *мин йаңғыз туй итә алмайым* (алмыйм), *йаңғыз қыз бирә алмайым* (алмыйм), *хәзер шуның өчен җаулық бирмийем* (бирмим), *дип әйтәделәр. Баласы қыз алып килгәндә килен сандығына сикереп менде қайнана: Сандығыңа қунайым* (куныйм), *қайын анаң булайым* (булыйм). *Қунағ итәйем* (итим), *аш қуйайым* (куйыйм), *дип йөреп йатам.*

Сөйләштә теләк фигыльләрнең *-ғай/-гәй, -қай/-кәй* формалы сыйфат фигыль һәм *иде* ярдәмче фигыле белән ясалган формалары да еш кулланыла: *барғай идем, барғай идек* – барыр идем, барыр идек; *барғай иден, баргай иденез* – барыр идең, барыр идегез; *барғай иде, барғай иделәр* – барырга иде, барырга иделәр. Мисаллар: *Син йырлағай иден* (җырлар идең). *Чай салғай иден* (ясар идең). *Эчкәй иденез* (эчәр идегез) *чәй. Син безгә килеп қунғай иден* (кунар идең) *бер көн.*

*-айақ/-әйәк* зат кушымчалары алган *иде* яки *булу* ярдәмче фигыльләре белән дә теләк-ният мәгънәсе белдерелә: *Қалаға бармаға машина сырайақ идек* (шәһәргә барырга машина сорамакчы идек). *Мадур сатпаға барайақ идем* (помидор сатарга бармакчы идем).

Сөйләштә теләк фигыльләрнең *-ғы/-ге, -қы/-ке киләде / киләт* формалары да актив кулланыла: *ашағым киләде/киләт, ашағымыз киләде / киләт* – ашыйсым килә, ашыйсыбыз килә; *ашағын киләде / киләт, ашағыныз киләде/киләт* – ашыйсың килә, ашыйсыгыз килә; *ашағы киләде, ашағылары киләде / киләт* – ашыйсы килә, ашыйсылары килә. Мисаллар: *Никах сазын уйнағанда йылағың килмәсә* (елыйсың килмәсә) *дә йылай идек. Әргем үз телен йуғатқысы килмит* (югалтасы килми). *Қызды күргем кели* (күрәсем килә)

*дип өлкүн йаучы кереп йатады. Сезден лақсалбаны ашағым килә* (чәкчәкне ашыйсым килә).

Шарт фигыль әдәби телдәгечә: *барсам, барсақ; барсан, барсаныз* – барсаң, барсагыз; *барса, барсалар;* юклык формасы: *бармасам, бармасақ; бармасан, бармасаныз* – бармасаң, бармасагыз; *бармаса, бармасалар.* Димәк, үзенчәлекләр II зат берлек һәм күплек, санда гына күзәтелә*:* **н~ң, н~г.** Мисаллар: *Йахшы булсаныз* (булсагыз), *кеше дә йаратады. Битачар булмаса* (ягъни киленнең йөзен ачып күрсәтү йоласы үтәлмәсә), *килен урамға чығып кешене күрә алмый, йарамый чықмаға. Қызды қачырып акилсә* (урлап алып килсә), *йегет анасы кучтәнәч камфит урап хәбәргә барады.*

Фигыль юнәлешләре. Сөйләштә фигыль юнәлешләрен белдерә торган кушымчаларның кайбер архаик формалары да кулланыла. Мәсәлән, йөкләтү юнәлешен *-ғыз/-гез, -қыз/-кез* кушымчалары белән ясау күренеше актив: *Унда иркәкләрне кергезбиде* (кертмиләр). *Әйдә арбага йатқызам* (яткырам), *башын ырма затқа. Йаңы төшкән киленгә тастар кигезгән* (кидергән) *җиңгәсе. Қуйны суйғызды* (суйдырды). *Тамада уртада тороп, туй қунақларын ашатып, эчкезеп* (эчертеп) *йөри. Ишектән кергезми* (кертми) *торалар җиңгәләр кийәуне. Килен күргәзә* (күрсәтә) *қайнана. Өстенә күләгеи кигезә* (кидерә). *Қайнанасымы, тәтәсеме, шул очықлап* (ут белән ырымлап) *кергезәде* (кертә) *киленне. Қызды шәл астында әкерен генә җөргезеп* (йөртеп), *ике йақтан ике дус қызы тотып, кийәү җортына китерәләр.*

Затланышсыз фигыль формалары. Инфинитив. Инфинитивның *-ма/-мә, -маға/-мәгә* (аның фонетик варианты *-паға/-пәгә*) формалары актив кулланыла. Мисаллар: *Мин битемне йабып йөрмә* (йөрергә) *тийеш идем. Қыйар җыймаға* (җыярга), *тут җыймаға* (җыярга) *китә идек бақчаларға. Кийәүләр қыз алмаға* (алырга) *килгәндә, қызның ике йагында ике дусы утырады шәл йабындырып. Тегеләр шулай йаулық алмаға* (алырга) *киләләр, без менә сүләшмәгә* (сөйләшергә) *килдек, диләр. Суға тешпәгә* (су коенырга) *барамыз. Улар қазанча сүләшпәгә* (сөйләшергә) *тырышады. Безгә қода килмәгә* (килергә) *тийеш, ди. Риза булсалар кызны бирмәгә* (бирергә), *бар тағамын салады да утырып сүләшәделәр.*

Татар әдәби телендәге *барасым* бар конструкциясе түбәндәге формалар белән белдерелә ала: *-маға кирәк*: *Мағa уқымаға кирәк* (укыйсым бар). *Қоръән тастарханга халwа пешермәгә кирәк*

(пешерәсе бар). *Қыйарны җыймаға кирәк* (җыясы бар). *Қапыны сырламаға кирәк* (буйыйсы бар).

*-айақ/-әйәк бар, йук, бул: Минем уқыйағым бар* (укыйсым бар). *Әле сигез йыл эшләйәгем бар* (эшлисем бар). *Уның киләйәге* (киләсе) *йуқ. Минем саға әйтәйәгем* (әйтәсем) *бар. Йегетнең өйөнә керәйәк булғанда* (керәсе булганда) *өлкүн итеп ут йаққаннар, қыз уттан сикереп чығады. Болар әүлийә өйөннән чығып китәйәк* (китәсе) *булғаннар. Балалар әрмийәгә китәйәк* (китәсе) *булғанда әпәй тешләтеп қалалар.*

*-маға/мәгә* (*-паға/-пәгә*): *Уғай бер йыл служит итпәгә* (хезмәт итәсе бар). *Өйгә керәмез, казан аспаға* (асасы бар).

Х ә л  ф и г ы л ь л ә р . *-ып/-еп* формалы хәл фигыльләр *белү, башлау* фигыльләре янәшәлегендә килеп, әдәби телдәге *-а/-ә, -ый/-и* формалы хәл фигыльләр мәгънәсендә кулланылу очраклары бар. Мисаллар: *Ул да саз тартып беләде* (уйный белә). *Мин үпкәләп* (үпкәли) *белмим. Хәзер йәшләр йырлап* (җырлый) *та белмиде.*

Хәл фигыльләрнең юклык формасы *-май/-мәй, -мый/-ми* (яңгырау авазлар һәм сузыклардан соң), *-бай/-бәй, -бый/-би* (*з* тартыгыннан соң), *-пай/-пәй/-пый/-пи* (саңгырау тартыклардан соң) кушымчалары ялганып ясала. Мисаллар: *Иртә мән чығалмыйсын кийенми* (киенмичә). *Асықпай* (ашыкмыйча) *сүләнез. Мин уны күрәлмәй* (күрә алмыйча) *ғалыптым. Сыйырым быйыл тумай* (бозауламыйча) *ғалды. Чақырып алмый тороп* (алмыйча), *килен аларның өйенә керми.*

*-май/-мәй + -чы/-че* формасы да сөйләштә еш очрый: *Чақырмайчы* (чакырмыйча) *киләләр үле қоранына. Сезде күрмәйче* (күрмичә) *қалдық.*

Сөйләштә хәл фигыльләрнең *-ғанча/-гәнчә, -ғанчы/-гәнче, -ғынчы/-генче* формалары параллель кулланыла: *Син барғанчы иртәнге сөт ыйыр. Битачар булғанча* (булганчы) *күренмәгән килен, иртәрәк барған суға. Өй эчендә кеше үлсә, бер йыл тулғанча* (тулганчы) *туйға да бармый, җыйылышқа да бармый, халығ арасына чықмый, намус сақлый. Йыл қораны көнне қоранға хәтле иртә белән йаулығын чишеп ақлық йаулығы бәйләтәләр халык җыйылғынчы.*

*-ған/-гән* формасы чыгыш килешен белдерә торган *-нан/-нән* кушымчасы алырга һәм *-ғанчы/-гәнче* формалы хәл фигыль мәгънәсендә кулланылырга мөмкин: *Унда барғаннан* (барганчы) *ийдә утырасын. Сезгә барғаннан* (барганчы) *өйдә утыра бирәм.*

Хәл фигыльләрнең әдәби телдәге *-гач/-гәч* кушымчасы урынына *-гачын/-гәчен* формасы кулланыла: *Ике-өч көн җыйып алгачын* (алгач), *қаймақны май итеп атлап аласын. Тыварукны, сөтне қазанга салып қайната, аны қуйыргачын* (куергач), *қулың белән қысып-қысып кибәргә қуйады, ул қорт булады.*

*-гачтан/-гәчтән* формалы хәл фигыльләр сөйләштә сирәгрәк: *Йылын уқытқачтан* (укыткач) *инде ул кердән чыга дип әйтәләр, ақлық бирәләр. Кеше үлгәчтән* (үлгәч) *тақмақлап йылау бар.*

Сөйләштә *-гач/-гәч* формалы хәл фигыль урынына аның түбәндәге мәгънәдәш конструкцияләре дә кулланыла:

а) *-ган/-гән сон//сын//сун*: *Күренмәгән сын* (күренмәгәч) *қайдан белик. Ул килгән сын* (килгәч) *бер гыз табыпты. Суга төшкән сун* (су коенгач) *ашагысы киләт. Кино қарап булган сун* (карагач) *ашарлар.*

ә) *-ганнан/-гәннән сон//сын//сун*: *Шул сүзләрне әйткәннән сон* (әйткәч), *арты менән чыгарды өйдән қызды да, кийәүде дә. Баш қодагый көмеш ақча чәчә туйда, қартлар туйы бетә баш қодагый ақча чәчкәннән сун* (чәчкәч). *Қунақлар килгәннән сын* (килгәч) *қуанып киттем. Туй узганнан сон* (узгач) *қорән уқытабыз.*

б) *-ып/-еп булгач*: *Ашап булгач байанды җәйәде* (ашагач ак яулык җәя). *Ақча чәчеп булгач* (чәчкәч) *кийетләр булады. Ашап булгач* (ашагач) *тагын да сурайт.*

С ы й ф а т ф и г ы л ь. Сөйләштә *-айаң/-әйәк* кушымчалы сыйфат фигыль актив кулланыла, мәгънәсе белән ул әдәби телдәге *-ачак/-әчәк, -ыр/-ер, -асы/-әсе* формалы сыйфат фигыльләргә туры килә: *Барысы да ил сақлайақ* (саклаячак) *балалар. Бирәйәген* (бирәсен) *биреп, алайагын* (аласын) *алган сун туй башланып китә. Апкитәйәк* (алып китәсе) *қызны сыйлап җыйылабыз, җырлыйбыз, биийбез, саз тартабыз. Сабанга чыгайақ* (чыгасы) *көндә ботқа пешерәләр, қабақ бурәк пешерәләр. Кийәйәк* (кияр) *кийемең, ашайақ* (ашар) *тәгамың бар.*

Сөйләштә *-у/-ү* формалы исем фигыльгә *-лы/-ле* кушымчалары ялганып ясалган сыйфат фигыльләр дә кулланыла. Мәсәлән: *Уртада озатулы қыз утырады. Алдында йаулық йабулы булады. Йаучы бикәмә ошаулы қыз киләде.*

**Ярдәмлек сүз төркемнәре. Бәйлекләр.** Алар, нигездә, әдәби телдәгечә. Мисал итеп китерелгән бәйлекләрнең әйтелеше түбәндәгечә: *ман/мән/мынан/менән* (белән): *Балгасық мән эченез* (бал

кашыгы белән эчегез). *Сезде күрү мән* (белән) *таныдым. Сезде пахлаwа мынан* (белән) *қунақ итәмез; тике/тикем* (хәтле, кадәр): *Мынадыйына тикем* (хәтле) *җыйған қыйарды. Қазан өйгә тике* (кадәр) *артымдан керде қуншым; тийен/чийен* (хәтле, кадәр): *Қырқына чийен* (хәтле) *сақламаға қуша баланы, җен алыштырмасын. Қырқына тийен* (хәтле) *бала йуwындырған суны да үсеп торған тирәк төпләренә түгә булғаннар; бит* (як): *Туй булғанда қыз биттә* (кыз ягында) *булады туй, кийәү сый дип әйтеләде йегет биттәге туй. Кийәүне сайлай инде қыз бит* (кыз ягы). *Безем биттә* (безнең янда) *үлән юк; тик* (*кебек*): *Ышанма йәшлегеңә, тайанма саулығыңа, йәшлегең җил тик* (кебек) *үтәр, қарыйлық ни хәл итәр; таман* (таба): *Йағаға таман* (таба) *китте.*

**Кисәкчәләр.** Әстерхан сөйләшенең аерым кешеләр сөйләмендә *ғуй* (ич, бит) раслау кисәкчәсе кулланыла: *Кеше үлгәч қычқырып йылайды ғуй, йыламасаң аwыру буласың, йөрәгең тотады, қаның күтәреләде. Қычқырып-кычкырып йылады, йыламаса эчендә қалады ғуй. Үлгән кешенең рухы килеп торат, диде ғуй. Бу өйдә кеше торғызмыйды ғуй, өй ийәсе кертми, ди.*

## Лексик үзенчәлекләр

Әстерхан сөйләшендәге диалекталь сүзләрнең кайбер тематик төркемнәрен карап үтик. Алар арасында нугай теле белән уртак сүзләр дә булу күзгә ташлана.

Й о л а  а т а м а л а р ы: *кечкентәй йаучы* – беренче мәртәбә кыз ярәшергә килгән кеше, *өлкүн йаучы* – кызны ярәшкәч туй һ.б. турында сөйләшергә килгән кеше, *шикәр сындыру* – кызны ярәшү, *туй көнен кисү* – туй көнен билгеләү, *нике баwырсақ* – никах бавырсагы, *тақ ағасы* – туй башлыгы, *байанды* – туйда киленнең аяк астына җәелә торган яулык, *күмәкче* – туйда булышучы, *кийет* – бүләк, *туғыз* – туйда кияү ягыннан бирелә торган акча, кием-салымнар һәм аш-сулар; *түркеннәп бару* – кияү өенә килен булып төшкәннән соң, кызның үз эти-әнисе йортына кунакка килүе, йола буенча ул үзенең туган йортына ана ягы чакыргач кына килергә тиеш.

Е л  ф а с ы л л а р ы  һ ә м  к ө н  и с е м н ә р е: *йаз башы* – яз, *йаз* – җәй (шулай ук мишәр диалекты сөйләшләрендә дә), *йыма* – атна, җомга, *кече йыма* – пәнҗешәмбе, *йыма суны* – шимбә.

Т у г а н л ы к  т е р м и н н а р ы: *мийәм, әмә* – әни, әнигә эндәшү сүзе; *қахам* – абый, абыем; *тәтәм* – апам; *бибәм* – эне яки сеңел;

*әйем* – әтисенең әнисе, әби; *мамам* – әнисенең әнисе, әби; *ақмуллам* – хатыны иренең иң олысыннан икенче булган абыйсына шулай эндәшә, *бийаға* – иренең олы абыйсы, *иркәк* – ир кеше; *нағашым* – әнисенең туганы, *қысқайақ* – хатын-кыз һ. б.

Ашамлыклар: *қатланчық* – катлы бәлеш, бәлеш, *кузбәлеш* – чикләвекле бәлеш, *нугай милеш* – ит белән дөге бәлеше, *бурәк* – бөккән, *җимеш бурәк* – җимешле бөккән, *бадамгел* – өйдә пешерелгән перәннек, *лақсалба* – чәкчәк, *тақыйа баwырсақ* – түгәрәкләп, түбәтәй формалы итеп никах мәҗлесенә пешерелгән бавырсак, *пахлаwа* – бал һәм чикләвек белән пешерелә торган күп катлы бәлеш, *нан* – төче күмәч, *туғач* – клиндер, *қул ылақса* – токмач, *кисмә* – ит һәм эре итеп киселгән токмач белән пешерелгән ашамлык, *балқуwас* – өйдә әзерләнгән эчемлек, *қалмық чәй* – яшел чәй.

Йорт-җир һәм көнкүреш белән бәйле сүзләр: *пинжара//мижара* – өйалды, *кизәңке* – чолан, *арқалық* – матча, *элдерек* – савыт-саба шүрлеге, *қазан өй* – ишек алдындагы җәйге кухня, кечкенә өй, *малғура* – абзар, *пыйала* – көзге, *тигәршек* – тәгәрмәч, *шуwал* – морҗа, мич торбасы, *әүлә* – ишек алды, *қулҗуар* – кечкенә таз, ләгән, *кипкер*– тишекле чүмеч.

Кием-салым һәм бизәнү әйберләре атамалары: *ату* – читек, *биспәт* – бишмәт, *қаптал* – бишмәт, *йатақ* – бүрек, *китән* – тукыма, *тақыйа* – түбәтәй, *сырға* – алка, *арқалық* – камзул, *тастар: баштастар, буйтастар, қыйық тастар* – башка бәйли торган урамалар, *җағалык*– муенса, *бурчын* – тиредән тегелгән аяк киеме.

Җир эшкәртү атамалары: *тақтарланған җир* – эшкәртелгән җир, *тақта* – түтәл, *кул* – иңкү урын, сугарыла торган урын, *күлче* – игенче.

Хайваннар һәм кош-кортлар: *быға* – үгез, *башмақ* – тана, *қонаҗын* – өч яшьлек тана, *қунан* – колын, *көчек* – эт, *мышық* – песи, *қуй* – сарык, *ичке* – кәҗә, *қураз* – әтәч, *лақ* – кәҗә яки сарык бәтие.

Үсемлек атамалары: *тирәк* – агач, *армыт* – груша, *байтирәк* – тополь, *қызыл гел* – гөлҗимеш, *дубийа* – фасоль, *картуп* – бәрәңге, *шыбыт* – укроп, *ут* – чүп үләне, *йусан* – әрем, *бадымҗан* – баклажан, *мадур* – помидор, *чақын* – җикән, *қомаршық* – кыргый рәвештә үскән ниндидер бөртекле ашлык, бик борынгы заманнардан билгеле булган дип санала, *чилем* – су чикләвеге.

***Әстерхан сөйләшенә мисаллар***

## ӨЙЛӘНЕШҮ, ТУЙ ИТҮ

### Яучы килү

**Йаучы, җаучы** – кыз димләргә, кыз сорарга килүче кеше. Яучы вазыйфасын үтәргә килүне Әстерхан татарлары **әйттереп килү** дип сөйлиләр.

– Йегетнең анасы килде, йаучы килде әйттереп, дип әйтә торганнарыйы:

«Алтын бусагагызны басып,
Көмеш ишегегезне ачып,
Сезнең кызны әйттереп киләм,
Сорап киләм балама», – диләр.

– Кыз әйтә, миңа йаучы җибәр, качып чыкмыйм, ди. Йаучы килә. Мин шулай кызыгызны йәрәшмәгә килдем, ди. Кыз күренми. Килешәләр, кул бирешәләр.

«Амансызмы?»– дип керәде йаучы. «Хуш килдең», – дип каршы алабыз, бар тагамыбызны салабыз, сыйлык күрсәтәбез (*Киләче*).

– Без кечкентәй булдык инде ул wахытта. Катын кеше, кыскайаклар киләде җаучы булып, иркәк кеше килмиде җаучы булып (*Кундрау*).

### Әйттереп килү

– Йаучы әйттереп килә. Сөйләшийек, мамасы (*әбисе*), бабасы белән сөйләшийек тиләр. Йаучы белән килешми торып чәй эчмиләр.

«Бусагаңа басам,
Ачмаган ишегеңне ачып киләм», –

дип әйтеп килгән йаучы мийәмнәр заманында (*Кызан*).

Пирбуй сүз салырга килгәндә бер кашык су да, бер айак чәй дә эчмәгән йаучы.

– Кызга йаучы ике кәрәм (*тапкыр*) киләде. Беренче килгәндә кызны бирмиләр әле. Кызны сорый әти-әнисеннән. Кызны бирмәгә ыриза булсалар, кәнфит сындырып, башын бәйләп (*ярәшеп*) китәде. Артык **ул** башка берәү белән дә бәйләнеш тотмиды.

– Минем үземне әйттереп килде йаучы йәрәшмәгә. Баклажаннан чүлә (*ботка*) йасады әйем, самаwыр кайнатты.

– Йаучы ишекне ачып кергәндә әйтәде:

«Мин алтын ишегегезне ачып кердем, мине көмеш ишектән чыгармагыз», – дип керәде. Анан инде кереп утырып сөйләшәде туган-кардәшләре белән. Менә мин шундый йомыш белән килдем, шулай-шулай буламын дип (*Җәмәле*).

– Кызлар булгач йаучылар килә. Беренче килгән кешегә бирмәгә кирәк икән диләр, икенче килгән кеше шайтан ишек ачканда килә икән, диләр.

– Йаучы килеп йәрәшкәннән соң кыз бала анасы күзенә күренми иде, йат эш дип бара иде (*Кәменни*).

– Миңа йаучыга минем иремнең нәгаше килде. Кызыңны әйттереп киләм дип килеп керде. Нәгаше инде ул минем иремнең әнисенең энесе. Ул миңа нәгаш бийага була. Әтинең биргесе килмәде. Шуннан бу йаучыга башка кешене, үзенең этисенең энесен җибәрде. Зур кешеләр булалар инде болар. Ул кеше килгәндә инде атам куып чыккан йук. Ул кеше минем атамнан өлкәнрәк кеше иде, тегесе йәшрәк кеше иде атамнан. Сөйләштеләр, анда да йаулык бирмәде эти. «Минем йаңгыз энем бар. Шул энем, кызның агасы диңгездән кайтмый тороп мин сезгә җаwап бирмим», – диде. Әwәлдә шулай булган. Абыйым кайткач бу кеше тагын барды, эти тагын кайтарып җибәрде (*Киләче*).

## Кечкентәй йаучы, сүз салучы

**Кечкентәй йаучы, сүз салучы** – беренче башлап кызны сорарга килгән кеше, ул әлеге гаиләнең нийәтен, кызны бирергә ризамы, түгелме икәнлеген белеп китә.

– Йаучыдән элек сүз салучы килә. Ул белеп китә боларның нийәтен, ризалыгын. Йаучы синең ризалыгыңны белеп әзерләнеп киләде, канфит-шикәр әкиләде.

– Кечкентәй йаучы пирбуй килеп сүз алады синнән, барамы, йукмы. Сөйләшмәгә, белмәгә киләде кечкентәй йаучы. Кечкентәй йаучы кечкенә кәнфит (*яучының беренче килгәндә алып килгән күчтәнәче*) апкиләде. Шулай килешкәндәй, сүләшкәндәй булалар ике кодагый.

Кечкентәй йаучыга «чәй бирмиләр, чәй эчми йаучы, килешми торып чәй эчмәгә йарамый», – диделәр.

Иң әwәл кечкентәй йаучылар килеп сүз салып китәде, кызны сорый килдек дип. Әз генәкәй шикәр әкиләде йаучы, кечкенә шикәре дип. Уны йакын-йулыкка (*туган-тумачасына*) өләшәде (*Киләче*).

## Өлкүн йаучы

**Өлкүн йаучы** – икенче тапкыр килгән яучы.

– Бер йомадан сун өлкүн йаучы киләде. Өлкүн йаучы патнус белән кәнфит, шикәр апкиләде, йегерме киладан артык булады.

«Шикәрдәй, кәнфиттәй тәтле булып торсоннар», –

дип апкилделәр (*Җәмәле*).

– Икенчедә өлкүн йаучы килеп туйның көнен кискән. Кыз анасы кийем сорай доган булган: башына шәл, өстенә күләк, айагына ату (читек) сораган (*Каргалык*).

## Билге, билге йаулык

Кызны ярәшкәч, вәгъдә билгесе итеп, кыз ягыннан **билге** – сөлге яки яулык биреп җибәрәләр, ул – **билге йаулык** дип тә атала. Кыз ягыннан бирелә торган вәгъдә бүләген **билге** дип әйтү мишәр диалектында һәм ногай телендә бар.

– Бер кеше, җаучы булып килеп, йаулык алаты. Кыз йагы бер йаулык бирә йаучыга, билге йаулык була (*Сәетләр*).

– Кызны әйттереп килгәндә, кызның анасы йаулык биреп җибәргән, кызның билгесе, дип бер матур йаулык бирә булган. Баш-йаулыкның йакшысын биргән. Шуны әкитеп түргә элә торган булган (*Кундрау*).

«Менә мин балама кыз әйттереп куйдым, менә бу кыз әнисенең биреп җибәргән билгесе», – дип түргә элеп куйа торган булган. Шунда җегет җакның җакын-җуwыгы:

«Хәйерле булсын», – әйткән. Шул җаулыкка барып, кызның билгесенә барып әйткән.

– Сөйләшәләр: «Без җаулык алып китәр идек», – диделәр. Ике йак сөйләшәде. Ни зат бирәйәк, ни зат алайак, ни зат бирмәгә тийеш. Хәле тартамы, йукмы? Хәле тартмаса кичерә иделәр. «Йәшләрнең бәхете булсын инде», – дип. Җаулыкны биреп җибәрәделәр әгәр дә риза булсалар.

Ыриза булмасалар: «Тукта минем туганнарым бар, хәрдәшләрем бар, мин шулар белән киңәшәйем, мин йаңгыз туй итә алмайым, йаңгыз кыз бирә алмайым, хәзер шуның өчен җаулык бирмийем» – дип әйтәделәр, җаулык бирмийенче җибәрәде. «Фәлән көнне килерсегез», – дип.

– Беренче көнне килгәндә йаучыга билге йаулыкны бирмиләр. Туганнары белән киңәшкәннән соң көн билгелиләр, тагын килә. Анда инде җизнәсе килә, абыйсы-җиңгәсе килә, биш парга хәтле килә. Билге йаулык алмага килгәндә коры чыгармый, кийетләп (*бүләкләп*) чыгара. Тегеләр шулай йаулык алмага киләләр. Бадымҗан калҗа (*пешкән баклажан*) пешерә, чәй эчертә (*Кундрау*).

**Ишек ачып килү** – беренче тапкыр кызны сорарга килү.

– Ишек ачып килү диде иң әwәле. Агасы белән җиңгәсе киләде йегетнең, йә йегетнең атасы-анасы киләде. Ике йак та хәл-әхwәлен сурайды бер-беренең, ни хәлләре бар. Ике йак килешкәннәр икән, без менә сүләшмәгә килдек диләр. Риза булсалар кызны бирмәгә бар тагамын салады да утырып сүләшәделәр (*Кызан*).

**Кода килү** – кыз сорарга килү.

– Минем кызым кийәүгә чыгайак булса, җиңгәсенә әйтәде. «Минем йегетем бар», – диде, – безгә кода килмәгә тийеш», – диде. Җиңгәсе анасына, кайнанасына әйтәде, әзерләнәделәр, кийет (*бүләк, гадәттә нинди дә булса тукыма*) әзерлиләр (*Сәетләр*).

## Башын бәйләү, шикәр сындыру

**Башын бәйләү** – ярәшеп кую.

– Йегет биттән кызга йаучы килгәндә кечкенә шикәрен китерә шулай итеп башын бәйләр өчен инде. Анда канфит, шикәр инде. Пирбуй баш бәйләwе кечкенә шикәр әйтелә. Кыз инде малайга йәрәшелеп кала.

– Билге йаулык алсалар, баш бәйләнгән була инде бу кызның (*Кызан*).

**Шикәр сындыру, канфит сындыру** – кызны бирергә килешкәннән соң ике кодагыйның егет ягыннан җибәрелгән канфит-шикәрен бүлеп кабу йоласы.

– Өлкүн канфит, кечкенә канфит диделәр. Кәнфит сындырады ике кодагый, канфитмы, шикәрме сындырады.

«Бераwыз булып йәшәйек,
бераwыз булып торайык» – дип,
«бер-берсенә тәтле булсыннар» – дип.

Кәнфит йә шикәрне сындырып икесенә бүлеп ашыйлар ике кодагый. Сындырган дигән сүз шул инде (*Җәмәле*).

**Әйттерелгән кыз** – ярәшелгән кыз.

– Мин сигез ай тордым әйттерелеп, әйттерелгән кыз булып. Шул сигез ай эчендә ураза бәйрәм, корбан бәйрәм булды. Шул көннәрдә әйттерелгән кызларга бәйрәм бүләге җибәрәләр икән. Бәйрәмдә миңа бәйрәмчәйгә дип бер паднус бәйрәмашлар пешереп җибәрәләр иде (*Киләче*).

## Киңәш

Туй алдыннан һәр ике як катнашында **киңәш** мәҗлесе үткәрелә.

– Туйны ничек йасама, күпме кийем бирмәгә – киңәшү булады. Элек кадерле иде кыз бала. Туй башларга килегез дип чакырады бөтен йакын туганнарын. Киңәшкә чакыралар.

– Йаучы килгәннән соң инде туйга ни хәтле кеше китерергә, кайчан утбасар (*егет ягыннан бирелгән калым*) китерергә, кайчан туй йасарга, ни хәтле анда кода-кодагыйлар килә, машинаны йегет йагы җибәрәме, кыз йагымы, шулай киңәшеп китәләр. Анысы киңәш була. Кемне-кемне чакырмага киңәш булады (*Картузан*).

## Туй көнен кисү

**Туй көнен кисү** – туйның көнен билгеләп кую.

– Туй көннәрен кисә. Чәршәмбе көнне киләләр. Көннең сәтле көне (*уңайлы көн*) дип әйтәләр, җомга көнне туй башламыйлар.

– Туйның көнен кисәделәр, кайсы көнне, кайсы айда туй була торганын әйтәделәр.

– Кода төшер туйда туйның көнен кисәделәр. Фәлән сәгәткә кийәүләр киләде, фәлән сәгәткә кодалар киләде. Кыз йак та, ул йак та туйга әзерләнә. Әле иген (*бакчадагы яшелчәләр*) пешкәнен көтәме, әле салкын төшкәнен көтәме, шуннан суң туй башланады (*Сәетләр*).

## Кызны урлап алу

**Качырып акилү** – ата-анасы белән алдан килешмичә генә кызны алып кайту:

– Качырып әкитсә кызны, барган җирен йаратмаса, бик каты кәйенә (*кайгыра*) кыз анасы. Менә мин үзем бик кәйендем, бер дә йаратмадым, менә шуңа күрә тора алмадылар (*Янга-Әскәр*).

**Хәбәргә бару** – малай кызның атасы-анасы белән сөйләшмичә, аларның ризалыгыннан башка гына кыз алып кайтса, малай әнисе кыз өенә «хәбәргә бара».

– Кызны касырып акилсә, йегет әнийе иртә белән күчтинәч камфит урап:

«Кәйенмә, кайгырма, кызыгыз бездә», – дип хәбәргә баралар. Туган-тохомын җыйа, аш-су әзерли башлыйлар. Хәбәргә барган кешеләргә кийет бирелә.

– Мине качырып алды ирем. Бу йактан барып әйттеләр: «Кызыгыз бездә», – дийеп. Кыз килгән көнне үк никах укытмыйлар, иҗап кабул укыттылар монда.

**Кул алырга килү** – кыз әнисенең ризалыгын алырга килү.

– Кызны касырып акилсә, хәбәр белән барганнан сун йегет йагыннан кул алырга килә башлыйлар. Кул алырга килү инде кызның әнисенең ыризалыгын алырга килү була. Кыз анасы белән килешәсең (*Картузан*).

## Дини йоланы үтәү, никах уку
## Никах, нике

Әстерхан татарларында гарәп теленнән кергән **никах** сүзе белән бергә, Урта Азия халыкларындагы кебек **нике, нике койдору** сүзләре дә кулланылышта йөри.

– Никах укыганда мулла сорый, нинди ыру, нинди тамга. Ыру тамгасы бертөсле булса, мулла никах укымый. Мулла өч мәртәбә сорый, ризамы дип. Йегет бер бүлмәдә, кыз бер бүлмәдә (*Лапас*).

– Өстенә кигән күләге белән яулыгын чыгарып муллалар алдына куйалар, менә шул күләккә, йаулыкка никах укый (*Урта Аwыл*).

– Кызның өйендә никах була. Йегет пирут бара. Йегет йагыннан wәкил килә, шаһит. Муллалар сорау алалар. Йегет биттән бер wәкил, кыз биттән бер wәкил була (*Кызан*).

**Хөтбә уку** – никах уку.

– Кыз биткә йегет биттән килгән әйберен, тарагын, ислемайын, йаулыгын, сабынын мулланың алдына саладылар, аңа хөтбә укый дип әйтеләде (*Җәмәле*).

**Л'оком** – никах көнендә егет өennән кыз өенә җибәрелгән күчтәнәч канфит-шикәрләр.

– Л'оком дип ол бит йибәрә кыз биткә. Аны ир йагыннан wәкил алып килә, ул йегет битнең бүләге булады, канфит-шикәр, такта чәй баwырсак. Л'окомны өлкүн табакка салып җибәрәделәр, табакны тутырып. Ул л'окомны бүләделәр, өләшәделәр никахка килгәннәргә.

«Синең улыңа да йуш булсын,
синең кызыңа да йуш булсын», – дип (*Кызан*).

**Нике, никә** – никах.

**Нике койдору, никә укыту, никах уку:**

– Кыз кийәүгә китәр булса кыздың анасы никене койдорып җибәрәде. Улымыз кызды качырып акилсә, киленгә никене кайнана койдорады (*Каргалы*).

– Ике йомадан сун ир биттә туй булады. Ир биттә туй булганда, шул көнне кыз биттә йакын-йуwыкларын, туган-кәрдәшләрен чакырып никә укытадылар.

Әйттереп барсалар никә кыз биттә булады, качып барса йегет биттә никә булады. Кыз китәйәк көнне (*Җәмәле*).

**Никә йарагы, нике йарак** – никах укыганда егет өеннән кыз өенә бирелә торган әйберләр.

– Никегә ир йагыннән килә бер хатын. Аның канфит-шикәре, көзгесе, тарагы булады, кызга шәле, битенә йагарга кершәне, йуwынырга сабыны, ислемайы киләде, башын тарарга тарагы киләде. Никә йарак дип әйтәделәр аны. Шул ислемайны ире белән бергә йагынмага тийеш, сабыны белән йуынмага тийеш, тарагы белән тарамага тийеш. Шәлен үзе йабына, күлмәген тектереп кийә иде (*Кызан*).

**Нике баwырсак** – никах көнендә егет өеннән кыз өенә җибәрелә торган бавырсаклар.

– Нике баwырсагын тишәргә йарамый, уртасын тишмиләр. Нике баwырсагын йаучы алып бара табакка салып.

Нике баwырсагын бүлешәләр.

«Игелекләр булсын, игелегегез үзегезгә кайтсын» – дип (*Картузан*).

**Нике табак** – никах көненнә егет өеннән кыз өенә җибәрелгән табак.

– Нике табакка бер табак итеп баwырсак пешереп сала, нике баwырсак була. Аның өстенә шәл саламы, йаулык саламы. Тарак сала, нике тарагы. Өстенә ни зат йаба да алып бара. Тахтамбиткә тастырхан җәйә, баwырсакны куйа. Баwырсакны өләшәләр (*Киләче*).

**Нике тарак** – никах көненә егет өеннән кыз өенә җибәрелгән тарак.

**Нике җаулык** – никах көненә егет өеннән кызга җибәрелгән яулык.

– Җегет җак чара табак (*зур агач табак*) җибәрде, нике табак, нике тарак җибәрде, башына бәйләмәгә нике җаулык җибәрде, нике баwырсак җибәрде. Кыз нике табакка битен жуwады, нике тарак белән чәчен тарайды, нике җаулыкны тузгинча башына бәйләп җерде (*Кызан*).

**Никах уку, никах койдору:**

– Йаучы килмәсә, кызны качырып акилсә, никах йегет йагында укылады. Йаучы килсә, никах кыз йагында укылады. Никахта паднуска куйып шәл, тарак китерәләр, мулла укыгач шул паднусны алып китәләр. Кыз китәйәк көнне никах укыталар.

– Никахның нийазын (*сәдәкә акчасы*) ир йак биреп җибәрә. Ике кеше кыз биткә барып муллага никах койдорып килә (*Җәмәле*).

**Никах табагы:**

– Никах табагында йакшы кәнфитлар, җимешләр, уруклар була, бер табак такийа баwырсак була. Тарак, дүрткел шакмаклы шәл киләде. Никах табагын алдына салып никах укытады (*Каргалык*).

**Никах шәле, никах тарагы** – егет өеннән кызга никах көнендә җибәрелә торган шәл һәм тарак.

Никах шәле дип килен үзе йабынады, кешегә бирмиде. Бирсә – никахы бозыла дип әйтәде. Шул никахка салган шәлне башына йапса, баш аwыруы бетәде, саклап куйасың аны. Кайа да булса чыкса гына бәйли аны, болай бәйләмисең.

Никах тарагы белән чәчен тараса да баш аwыруы бетәде (*Җәмәле*).

**Никах башйаулыгы:**

– Никахка бер башйаулык сала, бер тарак сала йегет биттән (*Кәменни*).

**Такийа баwырсак:**

– Никахка бер табак такийа баwырсак китерәләр, йегет биттән. Баwырсак эченә бер шикәр йә канфит салып куйалар. Йаучы әкиләде.

**Wәкил, шәһит** – никах укыганда кыз ягыннан килгән кешеләр.

– Никах укыганда кыз биттән ике кеше утырады. Берәwе wәкил, берәwе шәһит булады. «Бирдеңме ыриза булып, алдыңмы ыриза бу-

лып». Әзилдә шулай иде. Хәзер кыз белән йегетнең үзеннән сорый (*Җәмәле*).

### Туйда катнашучылар, туйны оештыручылар

**Өндәүче** – туйга чакырып йөрүче.

– Туган-кардәшне чакыра. Акча бирәләр чакыручыга. «Табан йалы» дип.

– Мин үзем өч туйга өндәүче булдым. Өйенә барып: «Безгә туйга килегез», – дип чакырып йөрисең. Туйда сиңа йаулыкка акча салып бирәләр. «Бу синең сибәрлегең», – диләр. Өндәүчегә «сибәрлегең, чәчәрлегең, – дип акча бирәләр. Туй башлангач өндәүче килгән кунакларны утырта, урнаштыра, туйда акча чәчә (*Кызан*).

**Җинагасы, җыйын агасы** – туй башлыгы. Аны кияү һәм кыз ягы үзара киңәшеп, алдан ук билгеләп куялар.

– Җинагасы – туйның хәзәине, ул кийәүнең агасы була. Җинагасы кызга йакын җибәрми туйда. Ул рөхсәт бирсә генә торып бийиләр, ә рөхсәт бирмәсә, берәү дә бийеми. «Кызлар, торыгыз, бийибез», – дисә, шул wакытта торып бийиләр.

– Җыйын, агасы туйны башкарады, туйны күтәреп торады. Җыйын агасы итеп алдан әйтеп куйадлар. Менә син җыйын агасы буласын, туйны башлап җересен дип тапшырып куйады. Кайа утыртмага, бийетмәгә беләде җыйын агасы, тәртипләп алып барады туйны. Җыйын агасы булмаса, туй таркау булады (*Киләче*).

**Тархан** – туй башлыгы.

– Тархан дип тә әйтәделәр җыйын агасын. Кемгә җырлауга, кемгә бийүгә кушады. Ул өстәлне карап, кунакларны сыйлап йөриде (*Картузан*).

**Тамада** – туйны алып баручы.

– Туйларда тамада булады. Әйтеп куйасың, син менә килгән кода белән кодагыйга сүз биресең. Йакынына, дусларына сүз бирә. Шул кеше уртада торып, ашатып-эчкезеп йөри. Тамада булады.

Агиделнең уртасыннан
Чириз парум кичәбез.
Кодагыйым җырлап бирә
Без дә җырлап бирәбез.

Алма тирәк утыртыпсыз
Төбе чайырлы булсын.
Хуш килдегез, кодаларым,
Урын хәйерле булсын

(*Картузан*).

**Кода:**

«Әссәләмәгәләйкем» – дип кода керә.

«Хуш килдегез кадерле кодалар», – дип каршы алалар.

Түргә чыгарып утырталар кодаларны. Бу йакның кодалары кул алып, аманнашып (*исәнләшү*) чыгалар, күрешеп. Куллашу, каршы алу, хуш килдеңез, дип, ул бер тәртип инде (*Сәетләр*).

**Башкода, кода башчы** – кәләшнең яки кияүнең әтисе яки кодалар башлыгы итеп куелган кеше.

– Кода башчыга зур табак әкиләт (*алып килә*), коданың алдына табакны салат (*сала, куя*).

– Башкодаңыз кем дип сурайдылар. Шул башкода алып килгән кешеләрнең тәртибен көзәтмәгә тийеш, җибәргән коданың сәләмен дөрес әйтмәгә тийеш, бөтен кушканын үтәмәгә тийеш. Башкодадан сорыйлар ни зат эшләсәләр дә.

Башкода үзен караган, үзенә хезмәт иткән кешеләрне ыризаламага тийеш, акча бирәме (*Сәетләр*).

**Кодагый, кодагай** – кәләшнең яки кияүнең әнисе.

– Кодагыйларны каршы алалар капка төбендә. Аларны җимешләр белән каршы алалар, нәлбәккә җимеш салып, җимешләр каптырып каршы алалар. Алар чатырга кереп утыралар (*Картузан*).

Кодагыйларны тастарханда да, җыр белән дә хөрмәтлиләр:

Кодагый, хуш килдеңез туйымызга,
Сезде алып утыра идек уйымызга...

Кодагыйым матур икән
Чатырак шәле башында
Ничек кенә җырлар җырлыйм
Кодагыйым каршында.

Хуш килдеңез безләргә
Рәхмәт йаусын сезләргә.
Килмәсәгез сез безләргә
Бара идек эзләргә.

Сез бит минем кодагыйлар
Алтын баганаларым.
Сезнең белән үтсә иде
Калган заманаларым.

Әй кодалар, кодагыйлар,
Утыргансыз әрәтләп.
Чакырганны кабул итеп
Килүегезгә эрәхмәт

Әй, кодалар, кодалар,
Кодалар, кодачалар.
Сездә ничек бездә шулай
Җырлап күңел ачалар

(*Урта Авыл*).

**Баш кодагый** – кызның һәм егетнең әнисе.

– Баш кодагый көмеш акча чәчә туйда.

Менә мин баш кодагый, йегет анасы, мин дә җырладым туйда. Башта җырлыйсың инде шушы чатырны көттем инде күп йыллар дигән кебек.

Бүген бездә туй көне дип
Бәйлим матур фартукны.
Ничә йыллар көтеп алдым
Мин бүгенге шатлыкны.

Вазаларга алма салдым
Әй, балам, сайлап аша.
Балам миннән сиңа теләк
Бәхетле булып йәшә.

Алай димәсен кеше,
Бодай димәсен кеше.
Бу шатлыкны күрми калмас
Баласы булган кеше.

Көн өстенә барыр идем
Москва каласына.
Кем бәхет теләми икән
Үзенең баласына.

Бу җырларны мин үземнең улыма җырлаган идем туйда (*Картузан*).

**Кийәү һәм кийәү йегетләр**

**Кийәүләр** – кияүнең үзе һәм аның белән бергә кияү егете булып килүчеләрнең барысын да кийәүләр дип атыйлар.

– Кийәүләр килә, кийәүләрне утыртады, аннан сун үзенең чакырган туганнары утырады (*Кундрау*).

– Сәгәт дүрттә-биштә иртә белән кызга киләделәр кийәүләр, кыз алмага киләләр.

**Кийәү җегет**: – Кийәү җегет дип кийәүнең үзен әйтәделәр (*Кундрау*).

**Уң кийәү, сул кийәү** – кияүнең ике ягында утыручы кияү егетләрен шулай атыйлар.

– Кийәү җегет килә, аның ике йагында кийәү утыра, уң кийәү, сул кийәү булады. Өчесенә дә аш тартыла.

– Туйда уң йак кийәү бар, сул йак кийәү бар. Уң йак кийәү өлкәнрәк була, аның сүзе өстенрәк була.

– Уң йак кийәү йегет йагыннан бер туганы, сул йак кийәү кыз йагыннан булды, ике кийәү булады. Алар кийәү йегет белән бергә йөриләр. Уң кийәү дә, сул кийәү дә (*Сәетләр*).

**Дусы, йулдашы** – кияү егете.

– Йегетнең дусы, йулдашы була. Кийәү йулдашы ике җиңгәгә кәде (*бүләк яки акча, хезмәте өчен түләү*) биреп кереп китә торганыйы. Кийәү белән бергә дусы килә, дус йегет. Уң кийәү, сул кийәү килә (*Җәмәле*).

**Кийәү кушчы** – кияү егете.

– Кийәү җегетнең ике дусы булады, кийәү кушчы дип әйтәде. Кийәү кушчыга үзалдына аш тартады (*кемгә дә булса багышлап пешерелгән ашамлыкларны табынга куялар*), йаучыларга үзалдына тартады, кийәүгә аш тартады (*Лапас*).

**Кызны алмага килгән җегетләр** – кыз алырга килгән егетләр.

– Кызны алмага килгән җегетләр җырлый:

Кара сирның кабыргасын
Кайырырга киләбез.
Әнекәсенең бер бәпкәсен
Айырырга киләбез (*Каргалык*).

**Кийәү җегетләр** – кияү ягыннан килгән егетләр.

– Туй булганда кийәү җегетләргә кулҗаулык чигәде кызлар, мулинә бар иде гуй. Шул җеп белән чигеп умбиш-йегерме кулҗаулыгы өләштерәделәр. Кызның дуслары чигеп әзерли иде, кийәүнең җиңгәсе өләштереп чыгады кийәүнең дусларына (*Сәетләр*).

## Кәләш һәм аның янында йөрүчеләр, кыз җиңгәләре

**Килен** сүзен бу сөйләштә **кин**, **кинчәк**, **йәш килен** формаларында кулланыла.

– Кин дүрт-биш күрпә (көрпә) бирә мамыктан йасаган, махмал (*хәтфә*) тышлаган, кайнатасының астына җәйеп утырта (*Лапас*).

**Кыз озатып баручылар**:

– Кызды чыгарып, озатып барады утыз-кырык кеше, кыз йагының үзенең туганнары барады, агалары, җиңгәләре киләде кыз затып. Кыз затып килүчеләр чәй эчә (*Кундрау*).

**Җиңгә, кыз җиңгәсе**:

– Ике җиңгә идән җуwа, кайнари (*пәрәмәч*) пешерә, пәрәмәчә инде, кийәүне чәй эчерә, ике җиңгә өстәлгә җаулык җәйә. Кийәү акча ташлый җаулыкка.

– Йегермешәр кила кәнфит әкитәләр туйга, чатырдагы халыкка күрсәтәләр, җиңгәләргә өлеш салалар. Туй ийәсенә калмый да ул. Җиңгәләр аны күтәреп кертә, чатырдагыларга әммесенә бүләләр.

– Без җиңгә булдык туйда. Кийәүне керттек кыз йанына, икебез ишек йанында утырдык, икебез ике йакта, ишек төбендә. Таң

атканнан соң боларны торгыздык. Без кердек, кийәү чыгып китте. Киленнең җәймәсен җыйып алдык, төреп аны кызның әнисенә алып килдек. Ул күреп, куанып безне сыйлап, бүләкләр биреп, рәхмәтләр әйтеп, теләкләр теләп каршы алды (*Киләче*).

**Дус кызы, дусы:**

– Минем тәтәм кийәүгә чыкты. Ике йагында ике дус кызы утыра. Тәтәм бирәзә (*бөркәнчек*) эчендә утыра.

– Әwәл заманда кызны озатып барганда уртада кыз барады, ике йагында ике дусы. Йаулыкны өстән тотып бардылар ике дус кызы, саз тартып барадылар йегетнен өйенә барганда.

– Кийәүләр кыз алмага килгәндә кызның ике йагында ике дусы утырады шәл йабындырып. Бу йагында бер дусы, икенче йагында икенче дусы, кыз уртада утырады. Саз (*гармун*) тартадылар (*Кызан*).

**Баш җиңгә** – кыз йагыннан аны озатып килүче хатын-кыз. Ул кияү белән кызга түшәк-урын сала.

– Баш җиңгә дип әйтәделәр, баш җиңгә түшәк салады. Иртә менән тороп, җиңгәләре боларны торгызып, ике кулларын йугызып урыннарын җыйадылар. Җыйганда шул җиңгәләргә акча салмага тийеш кийәү йегет. Баш җиңгә сурайды: «Канәгатьсеңме, ыризасыңмы? Дөресме кыз?» – дип. Йегет әйтәде. Ул хәбәрне җиңгәсе кызның анасына әйтеп, сөйенче алып киләде (*Киләч*е).

**Баш кодача** – туйга килгән яшь хатын-кызлар арасында өлкәне.

– Баш кодача булып бардым туйга, йоклап калганмын. Миңа кийет салганнар туйда. Шул кийетне тектереп кидем (*Кызан*).

**Так агасы** – туй башлыгы.

– Так агасы туйны алып баручы, бөтен тәртипне алып барады, бөтен эшне башкарады. Аны сайлап куйалар так агасын.

– Так агасын йегет йагыннан куйа, ул кийәүнең агасымы, җизнәсеме. Ул инде бөтен туйны алып бара, сөйләшә, мәҗлесне оештыра. Күпме эчемлек, күпме тамак куйарга.

– Так агасы утыра. Синең урыннан кузгаласың килә икән, так агасы, өрөхсәтме?– дисең. Ул өрөхсәт, дисә, син чыгып китәсең. Кергәндә: «Әссәламәгаләйкем, так агасы», – дисең. Ул: «Wәгаләйкем әссәлам», – дисә, урыныңа барып утырасың (*Киләч*е).

**Так саклаучы** – кызның алып килгән өй әйберләрен саклаучы.

– Ике кортка (*карчык*) такны саклап каладылар. Пыридан саклыйбыз, ырламасыннар», – дип йәшерәләр иде такны, шайан кешеләр була иде. Түләмәгә туры килә иде. Сүтеп ырлилар такны. Так саклаучы дип калдыралар иде пыридан йанында, манит йә бутилкә бирәде ырлатса.

**Такчы** – кызның әйберләрен алып килүче.

– Иртәгә туй дигән көнне так китә, такчы йаллыйлар. Такчы ресур арбада утырып бара, такны саклап бара. Кызның җиңгәләре такны төйәп җибәрәләр, акча чәчеп җибәрәләр такны. Кыз биттән так алып килгән җиңгәләрне кийәү биттә сыйлыйлар (*Киләче*).

**Байанды йөртүче** – туйда киленне ак яулыкка бастырып каршы алып, ул яулыкны барлык туй кунакларына тоттырып йөрүче кеше.

– Киленне байан җәйеп шунда бастырып кертәләр. Шул байанны бер җиңгә барлык кунакларга да тоттырып чыга. Менә шулай әйләндереп чыккан кешегә шул йаулыкны бирәделәр, ул байанды йөртүче кеше була инде. Аны тырышалар иде анда:

«Мин бәйән (*байанды, ак яулык*) җәйдерәм, мин бәйән җәйдерәм»– дип. Ул бәйәннең очына акча бәйлиләр тийешле кешегә. Ул инде кыдыртып (*әйләндереп*) чыга чатыр әйләнәсендә, алар битен сыпырып бәйән белән:

«Минем балама да йуш булсын,
Минем кызыма да йуш булсын», – дип.

Шулай кыдыртып чыккач ул йаулыкны шул байанды йөртүченең кулына бирәләр (*Каргалык*).

### Аш-су әзерләүчеләр

**Аш-ашчы** – туйда аш-су хуҗасы.

– Аш-ашчы бөтен мәҗлесне кулда тота. Эчемлекне чоланга салып бикләп куйалар. Кем генә килсә дә бирми ул. Так агасы әйтә: «Теге эрәткә эчемлек бир». Ашашчы бирә (*Киләче*).

**Пылаучы, пылау бастыручы** – пылау пешерүче.

– Ике казан пылау бастыралар пылаучылар.

– Туйда пылау бастыручы үзенә айырым кеше була. Туйда йөреп остарган, рәтен белгән кешене куйалар пылау бастыручы итеп (*Кызан*).

**Айак өстән йөрүчеләр** – туйда кунакларга хезмәт күрсәтүчеләр.

– Айак өстен йөрүчеләр йегет йагыннан да, кыз йагыннан да була, үзенең йакын туганнары йөри. Кунакларын каршы алып, эрәтләп сыйлап, матур йырлар йырлап сыйлыйлар (*Кәменни*).

**Айак өсте йасау** – туйда булышучыларны сыйлау.

– Туй беткәндә туйда йөргән бөтен туган-токомнарыңны җыйып айаг өсте йасый идең инде, сыйлый идең ашлар пешергән халыкларны, чатыр йасаган халыкларны сыйлый идең (*Картузан*).

**Күмәкче –** туйда булышучылар.

– Күмәкчеләр күп була туйда.

– Күмәкче йегетләр пылауга мәркү йуналар, күмәк итәләр.

– Туган-током күмәкче була, күмәкләшеп ашлар пешереп китерәләр. Бик күп кеше күмәкләшә.

– Күмәкчеләр кирәк пешермәгә. Әйтеп куйа, менә син катланчык йасарсың, син кузбурәк, син лаксалба, син пылау бастырмага килерсең ди (*Канга*).

### Думбырачы, каwалчы, сазчы

**Думбырачы, җырчы, бийүче**:

– Думбырачы, җырчы, бийүче үз аwылында булмаса башка аwыллардан атаклап чакырып әкиләде. Думбырачы думбырасын тартады, күп wакыт утырады. Кемгә җырлауга, кемгә бийүгә җыйын агасы кушады. Эскерипкә, саз, каwал белән сорнай уйнайды (*Каргалы*).

**Каwалчы –** каwалда уйнаучы.

– Менә без малның карыныңдан йасаган каwал, мин үзем каwалчы, хәзер каwалчылар бетте. Менә умбиш йыл уйныйм бу каwалда. Сазда да уйныйм мин. Туйларга чакыралар (*Сәетләр*).

**Сазчы –** гармунчы.

– Борын заманда сазчы, эскерипкәче, каwалчы дип атлар белән аwыллардан барып алалар иде, кала йактан йаллыйлар иде, хәзер инде дымбыл-дымбыл (*Сәетләр*).

**Саратский саз** – саратов гармуны, аны кызлары кияүгә киткәндә бирнә итеп атасы йортыннан биргәннәр.

– Кызды кийәүгә биргәндә кызга саз салганнар, саратский саз. Шуның өчен барлык хатыннар да саз тарта, саз – кыздың приданы була.

– Кызлар утырышында, баштанарларда (*аулак өйдә*) да саз уйнаганнар кызлар. Сазда уйнап кемне йаратканлыгын белгезгәннәр, шулай саз белән сөйләшкәннәр, телдән әйтү йук, саздан гына белгәннәр. Йегет шуны төшенәде. Саз белән орышышканнар.

– Каwалым да бар, саратский сазым да бар, туйларга йөрим. Чакырып машина белән килеп алып китәләр. Туй аткызалар (*үткәрәләр*). Бу киленем дә каwалчы, сазчы, икемез ике йакка йөри бирәмез туйларга.

«Туган аwылым», «Кама буйы», «Айырылмагыз», «Ай, былбылым» көйләрен уйныйм. Мин барлык көйләрне дә уйныйм.

Кәйен сеңлем каwал суга, мин сазда уйныйм. Картлар да бийеп йатыр мин уйнаганда (*Сәетләр*).

**Балкуwас көйе**:

– Балкуwас көйөнә җырлаганнар туйда. Балкуwас эчәләр и җырлыйлар шул көйгә. Халык туйга җыйылганда балкуwас көйөн уйнап балкуwас бирәләр:

Бийек тауның башларында
Алма ничек тәгәри.
Айның уны, оҗмах нуры
Булмас сезнең кәдәрли.

– Балкуwас белән туй йасаганнар, бучкы-бучкы балкуwас булган. Балкуwас көйе дип җырлаганнар. Без кинчәк булып йөргәндә дә аракка аwыз тигән йук (*Кызан*).

**Хушаwаз** – туй җырлары.

– Туйда хушаwаз әйткәннәр картлар, йар-йар әйткәннәр. Хушаwазлары булган бороңгыларның. Ак чәчәк, кызыл чәчәк дийеп әйткәннәр.

**Җыр**:

– Азаматларның җыры үзалдына, кызларның җыры үзалдына. Азаматлар утырган җиргә кинчәкләр килми.

**Үләң:** – Бороңгыча үләң әйтештеләр.

**Әwи:** – Әwине туйда җырлат. Кыскайаклар җырлат. Аннан кодасы, моннан кодагыйсы җырлайды (*Лапас*).

**Йар-йар:** – Йар-йар, хуш килдеңез кодалар туйымызга (*Лапас*).

## Туйда үзара бүләкләшү

[Кызның кияү йортына алып бару өчен әзерләнгән урын-җир әйберләре, киемнәре һәм бүләкләре рус теленнән кергән **придан** (приданое) сүзе белән аталып йөртелә, шул ук вакытта **так** дип, **заты** дип тә әйтәләр].

– Кызның затын төзиде, сандыгын, йастыгын, кашмасын. Кайнанасына, кайнатасына намазлык, тәсбих әпкиләте, тәрәт (*таһарәт*) җаулык әзерлиде. Кыз кийезләрен, күрпә, мендәрләрен бирәде йегет анасына. Бийем диде бездә. Йегет анасы алырга үзенең тийешле кешеләрен утыртады (*Сәетләр*).

## Придан

**Придан** – кызның кияү йортына алып килә торган әйберләре.

– Кыз да килә пыридан белән. Ана килен ызбаны тутырып куйды пырдан белән. Ызба эчендә ни зат кирәк, бар да бар.

Түр йастыклары, палазлар алып килә килен. Сүләп бетергесез.

– Менә кырык йыл килгәнемә. Менә минем приданым: менә сәгәтем, менә камутым, менә сандыгым.

– Кыз алып бара намазлык, коран, тәсбих кайнанасына. Ул затлар искедән калган гадәтләр бар да. Корән кабы була, намазлыкка ай салалар башына.

Кызның лампысы була. Кызның лампасын алып барган кеше корән кабын да алып бара. Тегәсең корән кабын матурлап, затлар салып. Аны караwатның башына элеп куйалар. Ак зәһәннән (*ефәктән*), махмалдан, матур затлы шыттан (*тукымадан*) тегәләр корән кабын корән салырга кызга. Придан белән бергә алып бара.

Кызның лампысын өйгә кергәч тә кайнана йандырып пич алдына куйа.

«Утың йакты булсын, көнеңне күр», – дип (*Җәмәле*).

– Кыз килгәндә мендәр алып килә, түшәмә алып килә. Менә шушы мендәрне кайнатасының, кайнанасының астына салырга, шундый йакын кешеләренең астына салырга унлаган мендәр киләде. Куй җоны, дәwә җоно салады эченә. Мендәрен салып кайнатасын утыртабыз килennнең, кайнагасы бармы, утыртабыз. Ун, унике мендәр киләде, йомшак итеп тегеп киләде, шуны бирәделәр.

– Кызның алып килгән мендәрләрен «Менә бу киленемнең алып килгән мендәрләре» дип, кадерләп кулланмага тийеш кайнатасы, кайнагасы.

«Киленнең мендәрен әкил, ә киленнең мендәре кайда» дип эзләйделәр. Ул бик матур булмага тийеш. Ул шундый хәтердә калгандый булсын.

Көрпәсен, мендәрен салады, картларны утыртады. Ә инде барлык кардашлары булмаса:

«Менә шундый урынлы кешеләрегезгә син үзең бирерсең» диде, мендәрләрен дә, кийетләрен дә бирәде. Икенче көнне килен чәйе эчергәндә җиңгәләр өләшәде, бүлеп бирәде. Анда үпкәлиде, «маган (*миңа*) бирмәделәр» дип (*Сәетләр*).

**Придан әкитү** – кызның әйберләрен кияү йортына алып китү:

– Приданны ат-арба белән әкиткәннәр, саратский сазда уйнап.

– Придан җибәрү инде арбалар белән. Әзилдә урам буйы придан йөртү бар иде. Өч-дүрт пар йөртеп бара иде шул приданны. Йегет йагында өстәл әзерлиләр. Кыз йагында приданны төйиләр, ул приданны төйиләр, ул приданны төйәгән кешеләргә йорт ийәсе тийешле бүләген кийет дип бирә инде. Селгеләр булса да, ни зат булса да, кулын буш итми иде.

– Приданда инде кызына дип әзерләгән йорт җиһазлары, айаксаwыты (*савыт-сабасы*), урын-җире, өсте-башы, ике йурган, бер йастык, бер түшәк булган.

Приданны кампит чәчеп кертә, әзилдә он чәчәләр иде (*Киләче*).

**Придан кертү** – кызның әйберләрен өйгә кертү:

– Приданны китерәләр, кычкыралар: «Ишектән сыймай йатыр». Приданга пийала була, былкамут була, пәрдә, палас, фартыклар була, ышкаф, караwат, түшәмә була. Йоннан баскан кийезе дә була.

– Кайнанасына намазлык, кайнатасына тәрәтҗаулык салалар киленнәр.

– Приданны китергәндә кызның шәме, лампасы була иде, кирасин лампысы. Ул лампыны, шәмне кайнанасы пич кырына йандырып куйа.

«Көнен күрсен, ут йаксын,
Йакты көне күп булсын», – ди.

– Кызга бирәләр иде мендәр. Ул мендәр алты митыр озынлыкта, тахтамбит өстенә ике кеше ике баштан тотып сузып салалар иде.

– Кыз биттән килгән приданга йегет бите кул тигезми, кыз битнең халкы бушата. Кыз бит үзе дүрт тәгәрчәкле арбага тийи, үзе китереп бушата, йегет битнең берәүсе дә кулын да тигезми, йарамый бездә.

– Придан киләде кыз биттән. Кыз приданы килеп йатканда йегет кардәшләре он чәчәделәр, акча чәчәделәр, кыз битнең кардәшләре онга буйалып кerәделәр.

«Ак нийәт белән килсен,
Ашлы-сулы булып килсен», – ди.

**Приданны элеп куйу** – кызның бирнәләрен һәм киемнәрен кияү өендә бауга элеп кую халыкка күрсәтү.

– Кыз биттән килгән приданны җепкә эләләр иде борынгы заманда. Тәрәт җаулыкны, күләкләрен, аркалыкларын (*камзул*) элеп куйадылар (*Кундрау*).

## Так

**Придан килү, так килү** – кыз ягыннан өй әйберләрен китерү.

– «Бүген так киләде икән инде» дип торалар. Шул такны, приданны ишектән кергезми торалар җиңгәләр.

«Ишектән сыймай йатыр, сыймай йатыр», – диләр, кәде (*түләү, акча*) сорыйлар кызык өчен. Капкадан кергәндә он чәчәләр.

«Ак йуллы булсын, азыклы булсын», – дип.

**Так караwаты** диләр. Шуның өстенә йастык ташлайлар җиңгәләр талашып. Так дип әйткәннәр агач караwатны. Так китә, караwат китә. Тактамбит өстенә так салганнар, ул такта йастык, дүрт мендәр булган.

– Так инде ул придан. «Так җибәрдем», – дип әйтәделәр. «Так әкитеп барабыз», – дип әйтәделәр. Кызның җиңгәләре барады.

**Так:**

– Так дип әйтәләр. Так – придан килү. Кыз биттән килгән приданны он чәчеп кергезәләр. Йегет йагында так була, кызны төшерәләр. Аш-су, йыр, гармуннар, балкуwас (*өйдә ясалган эчемлек*) (*Җәмәле*).

**Килен сандыгы** – яшь киленнең бирнәләре һәм киемнәре салынган сандык, аны һәрвакыт кайнана кабул итеп ала.

– Баласы кыз алып килгәндә килен сандыгына сикереп менде кайнана:

«Сандыгыңа кунайым,
Кайың анаң булайым», –

дип, киленнең сандыгына утырып әйтәде (*Лапас*).

– Кызның үзенең туганнары ачады сандыкны. Әкилгән бүләкләрне бирә. Барына да мата (*тукыма*) бирә, намазлык белән тәсбих бирә кайнанага.

– Сандык белән килмәгә тийеш кыз килгәндә. Сандыгына салып алып килгән сулыклар, күлмәкләрен. Сулыгы уннан ким килмәгән. Мата салады сандыгына. Сине берәү чакырып алса үзе алып бара, кайнанасыннан сорап йөрми. Сулыкларын да үзенекен тота.

Кәйембикәләре утырган кызның сандыгына.

«Сандыгыңа кунайым
Саттың кызды, алайым», – диделәр.

Киленнең сулыгын чиккәннәр, ак җептән кружива тукыганнар. Ак җептән тукыган йастык бит, прастина итәген тукыган (*Сәетләр*).

**Элү** – килен бүләге.

– Кайнатасына, кайнанасына килен килгәндә элү дип бирәде мата, кийез әкиләде. Килен бүленеп чыкса да ул әкилгән әйбер элү булып кайнанада калады, әкитми килен (*Кызан*).

**Өй бизәү, өй төзү** – килен әйберләре белән өй киендерү.

– Кыз приданнары килгәннән сун өйне төзәделәр. Кыз җиңгәләре, тәтәләре пәрдәләр корады, йегетнең туганнары акча бирәде. Приданны китерә җиңгәләр, шул җиңгәләр бизәп чыга өйне (*Картузан*).

**Йастык талаш** – кызның әйберләре белән өй киендергән вакытта кызның һәм егет якның җиңгәләре мендәрне кем беренче куя дип шаярып көрәшәләр.

– Придан тезәделәр җиңгәләр. Придан тезгән waхытта караwатка йегет биттән бер җиңгә, кыз биттән бер җиңгә йастык талаш башлайлар. Кем җиңә. Йегет җиңәме, кыз җиңәме. Кайсысы караwатка пирwай ташлайлар «менә без җиңдек, без җиңдек», – дип шапанай кагадылар (*кул чабалар*), шул йастык белән талашадылар. Йегет бит җиңмәгә тийеш шул waхытта.

– Придан китергәндә кыз йагыннан так китерәләр. Так – кызның караwаты. Аны зур тахтамбит өстенә куйалар. Шул такка җиңгәләр бер-берсеннән йәшереп мендәр алып кереп ташлыйлар. «Кем алдан ташлый, шул йак җиңгән була диде. Кычкыру булады, талашу булады. «Минеке җиңде, минеке җиңде» дип. Шундый кызыклы булады туйлар. Берәwе кыз җиңгәсе, берәwе йегет җиңгәсе. Шулай талашалар иде (*Киләче*).

## Кийет

**Кийет** – бүләк, **кийетләү** – бүләкләү:

– Кийәү йагында барын да кийетләгән, әwәл-әwәлдән килгән гадәт ул бездә.

– Әммесенә дә кийетләр, бирнәләр, падаркылар бирәләр. Ирләргә күлмәк өләшә, хатыннарга кийет, чатырда утырган кардәшләренә, килгән дусларына маты бирә, анда өчәр митерме, дүртәр митерме кисеп өләшә булганнар (*Кызан*).

– Туйга килгәндә бирәсен мата, менә шулар кийет әйтелә.

– Туйга килгән мамайларга, кызларга барына да кийет бирәтләр, мата бирәтләр. Туй булайакта әзерләп куйа кийетләрне. Читтән чакырган халыкка барына да бердәйне бирә, инде кодагыйларга башка төрлене бирә. Әзилдә кодагыйларга шатланкә бирәйделәр, ә болай халыкка ыштапел бирәделәр.

– Минем әйем туй йасады чатыр корып, чатырлы туй диде. Туйда бер кодачага ыштапел салганнар. Ул өлкән кийет көтеп утырган, үпкәләгән. Аңа алмаштырып шатланкә салдылар.

Туйдан кайтканда урам буйы кычкырыклап үпкәсен әйтеп килде. «Маңа шыт салдылар, шатланкә салмадылар», – дип. Кем булса да үпкәли туйда.

– Йакын кардәшенә йакшы кийет бирәләр, берсенә башйаулык эләгә. Кайсы кеше үпкәле була, кайтып китә туйны ташлап: «Карамагыз аларга»– диләр.

«Туй үпкәсез булмый
Үле – йылаусыз булмый», дип.

«Мин сиңа йакшыны салган ыйым, син миңа йаманны салгансың», – дип үпкәлиләр (*Кызан*).

– Туйга салган кийетләрне барлык кешегә күрсәтеп салалар, бөтенесе дә белеп торалар кемгә нәрсә салганны. Акча чәчәләр кийет салгач.

– Кийет салалар килгән кунакларга. Бөтен чатырга күрсәтеп чыгалар бүләкләрне. Бөтен чакырган кешеләргә мата биреп чыгалар. Бүләкләр биреп чыккач:

«Бүләкләрегез хәйерле булсын,
кийетләрегез хәйерле булсын», –

дип, килгән кодагыйлар акча чәчәләр.

– Әзилдә көндезге туйга да, кичке туйга да кийет биреләде. Хәзер йук. Мата биреләде. Туй булайакта әзерләнә.

Аннан соң инде без менә кодалар килгәндә кийетләдек бит, инде йегет йагы минем туганнарымны чакыралар. Шунда минем туганнарымны кийетләп җибәрә йегет бит, агам-җиңгәмне.

– Туйда кийет бирер алдыннан байандыны тоттырып чыгаралар иде. Туй ийәсе үзенең әзерләгән тийешле кийетен бирә инде. Кийет дигәне инде үзенең әзерләгән шыт бүләкләре инде. Кийетне зур паднус белән апчыгалар иде дә пирбуй шул кодагыйларга биреп, анда йазып-йазып салган инде, кулларына бирәләр иде. Аны инде туй буйы кулларына тотып утырмыйлар иде, аннан кешеләргә кире бирәләр дә, киткәндә паднусы белән биреп җибәрәләр икән.

– Хәзер инде алай түгел. Хәзер инде кызны йәрәшкәндә үк ата-анасы барып сүләшә. Йатка ди эчемдәге серемне сүләгәнче ди барып үзем сүләшәм ди. Алай ди, кодагый ди, чатыр буйы кийет бирергә сөйләшмим, өй эчендә генә бирийек, ди.

– Кийет чыкмагангамы, хәзер инде байандыны да чыгармыйлар, киткәндә генә биреп җибәрәләр. Йорт эчендәге халыкларга гына бирә дә җибәрә, үзенең өй эченә генә, чатырга чыгарып кийет бирү йук (*Каргалык*).

## Калым, туй малы

**Калын, калым** – кияү ягыннан кыз өенә бирелә торган әйберләр: тере хайваннар, кием салым һәм ашау әйберләре, акчалар.

– Калын белән барган, бер тана, бер конаҗын (*ике яшьлек сыер* ) биргән, кызга тастар-сылаwыч (*баш киеме*), тийен тун, йакшы укалы капталлар (*өске киемнәр*), атулы калушлар салганнар.

– Кийәү биттән бер куй бирә тогон ыйы, дөге бирә тоган ыйы, калым итеп бирә (*Кундрау*).

– Йегет биттән калын әкиләләр туйга. Йегет йак бирәйәген бирде. Туй малы бирәде, менә ит. Сөт акы бирәде, анасының күкрәк сөте акы киләде, ишег ачар киләде, акча инде. Дүрт канвирт булады, акчалата киләде, үзегез алырсыз дип (*Картузан*).

## Тугыз

**Тугыз җибәрү** – егет ягыннан кызга әйберләр җибәрү.

– Йәрәшеп китә булганнар кызны ыризалашып. Тугыз җибәрә булганнар. Йегет җибәрә өсте-баш, куйлар. Кыз бит сорый, йегет

бит җибәрә. Куй, дөге, чәй, кийем-тотым, махмал күлмәк; ак йефәк шәлләр, йакшы йаулыклар, баҗаклы (*муенга тагыла торган алтын тәңкә*), энҗе, бурса (*йон*) йаулык (*Җәмәле*).

– Туй йасаганда ол биттән тугыз киләде. Кийемнәр, калын акча, мәлешләр, камфит киләде.

– Әйттереп алган кыз булса тугыз китерә. Тугызны кыз бит сорый, башына, айагына, өстенә. Хәлле кеше әйтә: «Мин үзем тугызны тутырып бирәм», – ди. Минем мамам менә тугызны тутырганны ике йыл көтеп утырган, бабам ике йыл эшләгән. Пәлтә, шәл, туфли, ату сорый. Минем ату бар иде, аркалык бар иде. Шулай кийем-китә, калын акча, кийетләр китерәләр.

– Тугызда тийешле калым акчаны, дөге, куй, такта чәй, май бирәләр. Бер куй, алты-җиде кила май, йегерме килә дөге киләде. Эле дә килә кийәү биттән. Кызга йаучы килгәч йаучы үзе китерә. Бер малай ат әйдәп килә. Ул йаучыга да, ат әйдәүчегә дә мата бирәләр, кийетлиләр (*Кызан*).

– Тугыз киләде туйның алдыннан. Тугыз китерде, җиңгәсе, тагын берничә кеше. Кызга кийемнәр китерәде, сыргасын, йөзеген, атусын, өс кийемнәрен, аркалыгын, шундый затлар китерәделәр.

«Тугыз килде, бик бай тугыз килде» дип дусым менә тугыз килгәнгә чакырып китте (*Картузан*).

– Менә тугызда барын да шулай биреп җибәрә. Калын акчасын да, кийемнәрен, шәлен, йаулыгын, атуын, капталын, барын да сала. Тугыз дип шуны әйтә (*Каргалык*).

**Тугыз табак** – туй алдыннан егет ягыннан кыз өенә бирелгән әйберләр.

– Бер-ике йома алдан тугыз табак илтеп килделәр, ашлар-сулар, кийемнәр илттеләр. Дүрт кеше илтеп барды. Йөзекләр, затлар, катланчык, өчпочмак, канфитләр, җимешләр, оны, куйы, заты (*Кимәнни*).

Тугыз табак килә кийәү биттән кыз биткә. Кийәү сыйга китерәләр бадамгел, лаксалба, катланчык, җиләк-җимешләр. Зур паднуслар белән китерәләр (*Урта Авыл*).

**Тугызны ачу**:

– Тугызны ачады туй ийәсе билгеләп куйган кеше. Ачкан кешегә өстә бүләк була, тийешле кешесе ача, мамасы, әйесе, тәтәсе, җиңгәсе була. Ачкан кеше бүләкне ала да башына сала.

«Бүләк ул туйымлык түгел, күңеллелек өчен».
«Бүләк килде, әләк килде», – дигәннәр әwәлгеләр.

– Кийәү биттән килгән тугызны кыз битнең халкы ачмага тийеш. Иң өстә кийет булмага тийеш, ачучыларга бүләк. Ачучыларга кулларына айаклар бирәделәр, алар бөтен чатырдагы кунакларга шул айаклардагы җимешләрне, канфитларны өләшеп чыгадылар.

«Сезнең балаларга да йуш булсын», –

дип китергән кийетләрне җиңгәләре чатыр буйы. Йөреп күрсәтеп чыгадылар сыргаларын, йөзекләрен (*Сәетләр*).

## Сөт аклыгы, ана хакы

**Сөт аклыгы** – егет ягыннан кыз өенә бирелә торган әйберләр.

– Сөт аклыгына кийем бирәде, кодагиларына кийет салады, камфитлар табак-табак, катланчыклар, шәкәр-чүрәк салдылар. Ул табакларның өстенә йаулык салады. Өлкән тәтәләре, өлкән әбиләре бул-са, ул йаулыкларны алады.

«Әбийем, син шиш бу табакны», – диде кыз йак. Шул әбисенә бирәде. Икенче табакты тәтәсенә шиштерәде, йаулыкны ага бирәде. Йакын туганнары табакны шишеп алады.

**Сөт аклары:** Икенче атнага килгәндә тийешле җимешләрен, сөт акларын тийешле затлары белән алып киләләр.

**Ана хакы:** – Ана хакы да бирәләр әwәлгечә. Йегет кеше кызны икешәр кабат кийендерә. Ана хакына куй бирәләр, акча бирәләр, аш-сулар зур табак белән.

Ана хакына салалар төрле йакшы канфитлар, күрәгә, җимеш, пәрәмәч, шикәр-чүрәк. Тегеннән дә табакны буш җибәрмиләр.

**Сөт акчасы, имезгән сөт хакы, сөт акы**:

– Сөт акчасы диләр, кыз анасы сорый, йегет анасы ыриза була. Әйттерелгән кыз булса сөт хакы алып бара: бер такта чәй, пот дөге, куй, кийетләр алып бара (*Картузан*).

## Утбасар

– Йәрәшкәченнән туй алдыннан утбасар дип йегет анасы китерә кийәү биттән. Сөт хакы дип тә әйтәләр аны. Тәмле-татлыларны ак затлар белән урап, тырантаска куйып китерәләр, барын да

өләштерәләр туган-тохомнарга. Калганын өлеш итеп йегет өйенә дә җибәрәләр, «өләшсен туганнарына», – дип.

– Утбасар диләр безнең картузанда. Кийәү биттән килә куй, дөге. Менә мин малайымны өйләндергәндә кыз йагына бирәм он капчыклап, шикәр–чәйен, майын, җимеш-җиләген бирәбез, йакшы күлмәкләрен бирәбез, затларын бирәбез. Менә шул була утбасар. Аны паднусларга салып илтәбез.

Паднусларда кузбурәк, катланчык, шәкәр-чүрәк, бадамгел, канфитлар, арихлар, җимеш-җиләк.

Паднус өстенә кызның хакын саласың әле, күпмедер акча. Хәлеңнән күпме килә.

– Йаучы килә, йаучы артыннан утбасар килә. Утбасар дигәне кызның хакын китерә. Йегет йагыннан кыз хакын бирә. Менә мин малайымны өйләндерсәм куй бирәбез, он бирәбез, кәнфит-шикәрен, җимеш-җиләген бирәбез, акча бирәбез. Утбасарны безнең аwылда йегет йагыннан бер туганы китерә.

– Ата-анасы сөт хакына утбасар китерәләр, кызга кийемнәр, капчыклы он, куй бөкеле, дөге, җиләк-җимешләр. Бөкеле куй (*тере куй*) дигән сүз инде бөтен көйенә куй дигән сүз. Ул куйны инде кыз йагында никах булса, никахка суйалар. Кыз йагында никах булмаса кийәү сыйга суйалар. Кайсылары инде йаулыклар бәйләп китерәләр ул куйга.

Ананың үстергән хакы инде шул утбасар. Кызга сыргалар, берлиант йөзекләр бирәләр.

– Кийәүгә йәрәшәләр кызны, утбасар килә, паднус килә, бадамгелләр килә. Менә мин үзем өч кызымны озаттым, зур паднусларда аш-су килә, сөт хакы килә, ана хакы инде (*Картузан*).

**Кийәүне ат меңгезү** – кыз ягыннан кияүгә ат бүләк итү.

– Йегеткә дә сорый кыз биттән. Йегеткә кызның атасыннан ат меңгезергә куша.

– Кийәүгә ат меңгезә булган кызның атасы. Бизәлгән атны меңгезеп кийәүне урам әйләндерә булганнар. Кийәүне ат меңгезеп урамнан кыдырта булганнар. Кийәү ат менеп урам кыдырта булган (*Кызан*).

## Күремлек

**Күремлек** – килен белән беренче мәртәбә күрешкәндә кияү ягының туганнары тарафыннан бирелә торган бүләк яки тере хайван.

– Килен килгәчен күремлек сорайлар:

Килен килде – күреңез,
Күремлеген биреңез.
Ала – кола димәңез,
Атын әйтеп куйыңыз, – ди.

Ал киленем, дөнйа бирәм, мал бирәм, ди. Бер атасы әйтәт, мин сыйыр бирәм ди, бер агасы төйә бирәм, берәүсе басмак (*башмак тана*) бирәм, берәү куй кирә, берәү ишке (*кәҗә*) бирә, күремнекте килен килгән wахытта бирәте (*Сәетләр*).

**Күремнек атау**:

– Күремнек атау диделәр бездә. Мине әкилделәр, кундык. Минем кәйен сеңнем кул алдырып мине күремнек әйттерәйәк булды. Минем кийетем бар иде.

Килен килде күреңез,
Күремнеген биреңез.
Ала-кола димәңез,
Атын атап куйыңыз, диде.

Кәйен агасына бер сәләм диде. Камчыны кагалар, мин барып сәләм бирәм. Шул заманда маган шул нәгыш бийагам башмак атады, күремнек диде.

Шуннан соң икенче кәйен агама сәләм бирәм, ул ичке атады, ул маңа бер мал атап куйды.

Кәйенбикәмә сәләм бирәм. Иремнең ике апасы бар, апаларына сәләм бирәм. Минем җиңгәм әйтеп торады. «Килен килде күреңез», – дип. Шулай тезелеп утырган халыкка сәләм бирәм. Миңа унтугыз җәш иде (*Сәетләр*).

## Акча чәчү

**Акча чәчү** – туй мәҗлесендә тәңкәле акчалар чәчү йоласы.

– Туйда акча чәчәләр. Иң әзил кийәү бит чәчә, аннан тороп кыз биттән барганнар чәчә.

– Капкадан кергәндә акча чәчеп кергеләделәр.

– Акча чәчәделәр бөтен йакын-җулык. Ул акчаны туйдагы халык та җыйады, җиргә төшкәнен балалар да җыйады (*Урта Аwыл*).

– Башйаулыкка бәйли иде акчаларны туй ийәсе, аны кулына эләде. Шуннан йаулыктагы акчаларны бөтен чатырга чәчеп йөри иде. Кулйаулыкта гына түгел, башйаулыкка бәйләп чәчәделәр

акчаларны. Мин үзем дә чәчеп йөрдем туйда акчаларны, чатырлар корып туйлар йасадым, төне буйы утырдылар (*Кәменни*).

– Кыз йагындагылар акча чәчкәннең соң, теге йактан килгән кодалар да торып акча чәчәделәр. Аннан суң инде тәстерхан әзер, пылау киләде, бөтен чатырга кийет биреп чыгады туй итәсе (*Кызан*).

### Кияү килү, кызны кияү йортына озату

**Кийәү килү:**

– Кыз алырга килгәндә йегетне йегет биттән йеңгәләр кийендерә. Күләген кийертәләр, ислемай сибәләр, акча чәчеп анасы йегетне чыгарып җибәрә.

– Кийәү кызны алырга килгәндә үзенең дусларын алып килә. Гармун, эскерипкә, каwал уйнап киләләр, йырлап киләләр урамнан (*Каргалы*).

**Кийәүне ут аша сикертү:**

– Кийәү кызны алырга килгәндә капка алдына ут йакканнар. Шул уттан кийәү сикереп чыга (*Җәмәле*).

### Ишек кәдиле

**Кәдә сорау** – акча сорау.

– Йегет бара. Кызның бөтен җирен, өйен, капкасын бигетәләр (*биклиләр*), йакын да җибәрмиләр. Ул wата, җимерә дигәндә генә кертеп җибәрәләр. Һәрбер ишектән кәдә сорыйлар, һәрберсенә ыргыта килә акчаны (*Җәмәле*).

**Ишек кәдиле** – ишек бавы, кийәү кергәндә акча сорау.

– Кызны кергезеп салалар бүлмәгә. Кийәүләрне җибәрми иделәр җиңгәләр. Шул заманда җиңгә кычкырады бу йактан торып:

«Ишек кәдиле», – дип.

Ике җиңгә сорады:

«Безнең айгырыбыз жугалды, шул айгырды эзләп килдек».

«Шул айгырның җалы кай җакка төшкән, уң җаккамы, сул җаккамы?» диделәр.

Бер җиңгә әйтәде уң җакка җыгылган, кайсыныкы сул җакка диде.

«Йарар табарбыз, сез сәләм кылыңыз безгә», – диде.

«Безгә бер ыстакан балкуwас эчерегез», – диде.

Бер ыстакан балкуwас эчерделәр, сәләм кыладылар болай иттереп чүгәделәр, иркәкләргә сәләм бирделәр.

«Без әкитеп барабыз айгырны», – диделәр. Өч дүрт йегет кийәүне әкиләде кергезмәгә кызга. Шунда җиңгәләр ишекне ачмиды. Йегетләр әйтәде:

«Ачыңыз, без айгырны таптык».

Җиңгәләр әйтәде:

«Ишек кәдиле», – диде.

«Кәдисенә ни зат», – диде.

«Кәдисенә колынлы бийә, боталы бийә, – диде. Акча сорыйлар йегетне кергезмәгә. Акча бирәләр, җиңгәләр ишекне ачып кергезәде. Кыз белән йегетне калдыралар да үзләре чыгып китәләр (*Киләче*).

**Сорау алу, кийәүне кертү:**

– Кийәү йегет кыздан сорап килгәндә үзенең сорый торган табышмаклары булган. Кийәү йегет ишеккә киләде икән, кыздан сорый икән, җиңгәсе тороп әйтәде икән: «Атың кем?– Атым йурга. «Ийәре нинди? Йүгәне нинди?» Шунда сун йегетне өйгә кергезә (*Киләче*).

**Кызның эти-әнисе йортында саубуллашуы:**

– Кызны кийәү өйенә озатканда атасы-анасы керә, кардәшләре керә. Атай керә саубуллашырга. Атай пустуй керми, атайның кулында акчасы булады, биш манитмы, ун манитмы. Кыз биттән килгән агасы, йакыннары бөтенесе дә акча тотып керәләр, хатын-кызлар акча тотып керми (*Кызан*).

## Никах сазы, озату сазы

**Нике сазы, никах сазы, озату сазы уйнау** – никах сазы, ягъни көе, кызны озату көен уйнау:

– Кызны өйдән чыгарганда саратский гармунда саз уйный, зату көйе, нике сазы диләр. Шул сазны уйнаганда кыз инде бөтенесе белән күрешеп йылап чыга. Кыз чыгып киткәндә анайлары бузлап (*елап*) калады.

– Кыз уртада бирәзә бөркәнеп тора, ике дус кызы ике кабыргасында тора. Нике сазы уйнады – кыз саубуллашмага тийешле ата-анасы, туган-хәрдәшләре белән. Сазыңны алып кил дип чакыра туйга чакырганда.

– Никах сазын тартып уйнатасың. Өч кыз бирәзәнең эчендә тора. Ата-анай кыз белән саубуллашырга керә. Кыз биттән кергән агасы, атасы акча белән кергән.

– Кыз арбага утырып киткәндә озату сазы уйныйлар иде кызлар, бөтен кеше йылаган.

– Кызны таң алдыннан алып килгән дуслары белән, саратский саз белән. Йылата торган саз бар иде. Ул сазны уйнаганда йыламас җиреңнән дә йылайсың (*Кызан*).

– Кыз җылату булган, җиңгәләре кызны кийендергәчтен йылату көйенә саз тарткан, йылату сазын уйнаган, шунарга кыз җылаган йылау сазын уйнаганда. Никах сазын тартып җылатасың, никах сазын тарткан wахытта йылагың килмәсә дә йылисың, йылаш-сыкташ китә. Җиңгәләр җырлый булган:

Әй, сеңелем, китәсең,
Китеп кайа җитәсең.
Ташкүкерәк кайнанага
Ничек хезмәт итәрсең.

Кайын ата, кайын ана
Кайын агач күмере.
Кыз баланың әти-әнидә
Кыска була гомере.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Әбҗәлим.
Әткәм ничек бирер икән
Йат кулына жәлләми.

Аклы ситса күлмәгемнең
Буй-буйы тузар инде.
Айга карап йолдыз санап
Гомерем узар инде.

Бара торгач мин утырдым
Бадийан төпләренә.
Газиз әнекәм ыриза бул
Имезгән сөтләреңә (*Каргалык*).

### Кызны өйдән чыгару. Кызны әти-әнисе өйеннән чыгаргандагы серле йолалар, ырымнар

**Сөт эчертү**:

– Кызды өйдән чыгарганда сөт эчерәт, сөт уртлай (*каба*).
«Сөттәй ап-ак йул булсын».

**Кызны өйдән чыгару:**

– Кызны өйдән чыгарганда арты мән чыгара. «Өйен онытмасын», – дип.

– Кыз алмага җегет киләде. Кызның җиңгәсе кызны җәшереп куйады. Җегетнең җиңгәсе белән җегет киләде, кызны сурайды. Җегет җитәкләп апчыкканда анайлары бузлап калады.

– Ике йагында ике дус кызы. Кыз аркалыкны кийеп утыра. Уртада озатулы кыз. Алдында йаулык йабулы булады болай. Йаулыкның артында кыз, ата-анайы саубуллашып калады, кызны алып китәделәр, кырага (*кырыйга*) утырып саубуллашып, бузлап каладылар (*Кызан*).

– Кызды өйдән чыгарганда кашмага салады, дүрт мийесеннән дүрт кеше тотады, кызды бирмәйбез, ди. Кыз йагының йегетләре болай тарткалайды, йегет йагыннан килгән йегетләр болай тарткалай–ды, алып китәбез, дип. Бераз wакыт мәшәкатьләнәләр дә кызды озаталар (*Җәмәле*).

**Кыз белән кияүгә теләк бирү**

– Кыз белән кийәүгә кызның анасы әйтәде:

«Балаларым, ике йакның да ата-анасын сыйлагыз,
Сөйкемле булыгыз,
Мәхәббәтегез тигез булсын,
Бер-берегезне кичерә белегез,
Берегез сөйләгәндә берегез өндәмәгез» –

дип әйтелә.

«Әйтүчедә бер зат тә калмый, тыңлаучыда колак булса» (*Сәетләр*).

**Кызга теләк бирү**

– Кыз өйеннән китәйәктә кыз йагының туганнары кереп утыралар өйгә. Шунда кийәү дә кыз йагы туганнарының кулын алып китәде. Кыз йагының туганнары кийәүгә кул алдыра, кыз да кул ала, саубуллаша ата-анасы белән. Шуннан уртага утырталар кызны да, кийәүне дә. Шунда кызның анасы әйтәде:

«Әй, кызым, бәхетле бул барган җирендә, диде,
Син инде минем өйемнән йаңа ойага керәсең, диде,
Кайната-кайнананаңны сыйла (*хөрмәтлә*), диде,
Иртә тор, кич йат, зурларны сыйла,
Өлкүннәрне безнең йакта да,
кийәү йакта да сыйла», – диде,

шулай мәслихәт әйтәде (*Сәетләр*).

**Кияүгә теләк бирү**

Шуннан соң кийәүгә әйтәде:

«Әй, балам, кызымны алган баламсың, диде. Борынгылар әйткән, диде, кийәүне пәйгамбәр сыйлаган, диде.

Кийәүнең, диде, туганда маңлайына йазылган өч йорты була икән, – диде. Берсе – ата-ана йорты, туып-үскән йорты, диде, Икенчесе – нәгыше йорты, диде (әнисенең энесе йорты).

Өченчесе – кәйен йорты, диде. Менә бу өченчесе кәйен йорты безнең өй булды инде, диде. Шул өйгә, диде, борыңгылар әйтепте:

«Ары-бире йөргәндә атыңның башын бора йөр, камчыңны кагып кәйен йортына керә йөр», – диде. «Шул сүзләр исеңдә калсын, балам», – диде.

«Бар булса йыйшып китәрсең, йук булса безнең саулыгыбызны белеп китәрсең», – диде. Шуның өчен урамыбыздан үткәндә безгә керми китмә, диде. Шул сүзләрне әйткәннән соң арты белән чыгарады кызны да, кийәүне дә. Айак белән сөт эчерәде. Тустакай белән сөт бирәде, алдан әзерләп куйады.

«Ак йөзле бул,

Өйгә битең белән килеп кер», дип арты менән чыгарады кыз белән кийәүне (*Сәетләр*).

**Озату сазы** – озату көе.

– Кыз биттән ир биткә таң атканда алып китә. Кызның ике йагында ике кыз, бите каплы булады. Эскерипкә, каwал, сорнай уйнайды туйда, саратский гармунда озату сазын уйнайдылар (*Киләче*).

## Туй атлары, туй көймәсе

**Дөйә, нар** (бер өркәчле дөя): – Нарды көймәгә йиккән, әйләнәсенә кийез тотып, кызларны утыртып алып киткәннәр. Нар җигеп көймә меңгергән (*Лапас*).

**Көймә белән китү**: – Көймә дигән озын арба булады, кызды шунда утыртады, кыздың йулдашлары булады.

**Арба белән китү:** – Кыз таң алдыннан китә, дүрт тәгәрчәкле арбалар белән. Йулда ут йана, утның өстеннән узып алып китә кызны.

**Фаэтон белән китү**: – Кызны төшереп алалар фаэтоннар белән, калакуллар белән. Бик әйбәтләп, матурлап кызны алырга бара булганнар.

**Ат әйдәүче** – ат тотучы, кучер.

– Ат әйдәүчегә мата бирәләр, кийетлиләр инде. Йакшы зат бирмәгә тийеш.

– Дусымы, агайымы ат әйдәүче була. Бер атка ат әйдәүче, кыз белән җегет утыра, анда башка кеше сыймый. Икенче атка ике җиңгә утыра. Урамны кыдыртып бис инде җериләр иде (*Кызан*).

**Атларны бизәү:**

– Атларның дугасына сөлге бәйлиләр иде, йыланбашлар (*кечкенә кабырчык, ракушкалар*) бәйлиләр иде күз тимәскә (*Җәмәле*).

## Кияү йортына килгәндәге йолалар, ут белән ырымлау

**Атны уң йактан әйләндереп кертү**: – Ат, арба, көймә киләт, ун йактан әйләнәт. Атның башын борып, кыйблага таба каратып төшерәде киленне (*Каргалы*).

**Капка алдына ут йагу:** – Йегетнең капкасы ачык, капка алдына ут йага камыштан, ут алдыннан керә кыз.

– Капкадан керәм дигән җирдә ут җагалар, ат шул уттан сикереп чыгарга тийеш икән, кийәү белән кыз утырган ат уттан сикереп чыга.

– Кызны әкилгәндә капканың алдында корткалар ут йагадлар. Шуны иснәтәләр, киленгә әкилеп иснәтә.

– Кызны китергәндә җәйәү китерәләр саз белән. Ике йакта ике дус кызы бара, калын шәлне шулайга йабынган. Ике йагыннан ике кыз тота шәлне, син уртасында буласың. Җәйәү алып киләләр, әкерен җөргөзәләр.

Ир биттә, йегет биттә камыш йагып торалар капкадан кергәндә. Сине шуннан атлатып чыгаралар. Бер бау камыш йагып торадылар корткалар.

– Йегет өйенең капка алдына, йегетнең өйенә керәйәк булганда, өлкүн итеп ут йакканнар, камыш йакканнар. Кыз уттан сикереп чыгады (*Кундрау*).

## Киленне ырымлау

**Киленне ычыклау** (имләү, ырымлау):

– Килен төшә, бер йиңгә килә дә ычыклый киленне, җаулык мийесен җандырып баш очыннан әйләндереп иснәтә киленгә «ычык, ычык», – дип әйтәде.

– Йаулыкның читенә ут йагады бер кимпер. Иснәтә-иснәтә дә «чык, чык», – ди. Эспичкәгә ут йагады, иснәтәде кызга. «Чык, чык» дип чыклый (*имли, ырымлый*) да үзе алады ул йаулыкны. Ул йаулык үзенә булады ул әбинең. Аwыру зат, сырхау китсен дигән сүз була.

– Йаулыкны очыклый, уттан атландырып кергезә. Бу инде бөтен бәлә-хаза арткы биттә калсын дигән сүз булады. Аwыру-сырхау калсын дигән сүз булады (*Җәмәле*).

– Бер кортка очыклый киленне. Уттан чыгарады да йаулыкның почмагын йандырып, йанган уты быраз басылгач шуның белән очыклап кергезәде. «Бисмилла, бисмилла» дип. Бер карт мамай була инде.

– Бер кимпер килен, йаулык мийешен йандырып кызны ошыклайды. Башйаулыкны йанып торган утка тидерәйде дә кызның баш әйләнәсендә йөртеп ошыклайды.

– Кызны шәл астында әкерен генә җөргезеп, ике йактан ике дус кызы тотып кийәү җортына китерәләр. Капка алдына камыш йакканнар, ут йана, килгән килен шул камыш өстеннән, ут өстеннән сикереп чыгарга тийеш икән мин. Мин сикереп чыктым, ә бер мамай йаулык тотып, шырпы тотып тора. Бу нишли икән? дим. Йаулыкның почмагын шыр–пы сызып йандырып минем башымнан әйләндереп ышыклап-ышыклап мине өйгә керетте.

«Бәхетле булсын, йаман затлар ийәреп килмәсен» дигән сүз инде бу.

– Киленне уттан атлатып чыгарып очыклыйдылар, йаулыкның читен йагып «шайтан-майтаннар булмасын» дип инде, башыннан-күзеннән әйләндереп, иснәтеп очыклыйлар да алып кереп китәләр.

Кайнанасымы, тәтәсеме, шул очыклап кергезәде киленне.

«Шайтаннар аралашып кермәсен», – дигән булып. Шундый кызыклы иде ул wакытта (*Киләче*).

### Киленне кияү өендә каршы алу
### Ак йаулык, байан, байанды

**Ак йаулыкка бастыру:**

– Йегет йакта киленне өйгә керткәндә ак йаулык җәйәләр. Килен ак йаулыкка басып, сәләм короп керә, акша чәчеп кергезәләр. Кыз беркәнчектә керә, ике йагында ике дус кызы керә.

– Пирбуй башлап кергәндә ак җаулык җәйәде, бусагадан кергәндә ак җаулыктан атлап керәде килен.

«Ак җуллы булсын», – диләр (*Каргалык*).

**Байан, байанды, бәйән** – киленнең аяк астына җәелә торган ак яулыкны кайсыбер авылларда шулай дип атыйлар.

– Йаулыкны инде ишек төбенә җәйәләр, ул – байанды. Шуңар уң айагың белән басып керәсең.

«Ак йуллы булсын», – диләр.

«Айагың йәрәшсен, бәхетле булыңыз», – дип әйтәләр. Байан җәйеп кергездем киленемне, байанга басып рәхмәт әйтте, килеп кулымды алды, үпте киленем (*Кундрау*).

– Байанды инде менә кызны алып килешли йегетнең анасы баш йаулыгы җәйеп, шуңар бастырып кертә. Менә шул инде байанды җәйү була. Кыз беренче кат йегет өйенә кергәндә байанды җәйә. Тышкы йакка җәйми, өй эченә кергәч, эчке йакка җәйә.

«Хуш киләсең балам,
шушы өйләрдә тату тәмле торып,
инсафлы балалар үстер,
шушы йортларда йәшәргә насиб итсен,
олыларны олы дип күрергә насиб итсен»

дип тәмле йагымлы сүзләр сөйләп кертәләр. Электә ул байандыны тоттырып чыгаралар иде кийет бирер алдыннан. Шуны инде пирбуй кода-кодагыйга тоттырып, шуның уң йагыннан китәләр, айак өсте йөрүчеләргә барысына да тоттырып чыгаралар иде.

– Байандыны җәйеп каршы ала килен килгәндә. Бусагага җәйеп байандыга бастыралар. Әти-әни хуш күреп каршы ала.

«Хәйерле айагың белән бас,
Хәйерле айагың белән кер», –

дип каршы алып торалар (*Кәменни*).

– Туйда байан бастыру бар. Ак башйаулыкка кызыл шыт тегәләр. Шуны өйнең ийәсе үзенең бер йакын кешесенә тапшыра. Апасы буламы, кәйенбикәсе буламы. Ул байанны бөтен килгән кунакларга бастырып чыга. Аларга әйтә:

«Сезгә дә йуш булсын, сезнең балаларга да йуш булсын», – дип.

Кайсы кеше тик кенә кулын тигезә.

«Безнең балаларга да шулай туй күрегә йазсын», – ди.

– Туй башланайакта байанды бастыралар. Ул ак йаулык, уртасына кызыл тегәләр, кызыл зәһәннән. Кунаклар җыйылганнан соң ул байандыны кунакларга тоттырып чыгалар. Алар тоталар да:

«Безгә дә йуш булсын» дип, маңгайларын сыйпап алалар, баш әйләнәсен сыпырып алалар.

– Кыз кеше кийәүгә чыга, үзенең йакын кардәшенә беренче мәртәбә килә. Аны байан җәйеп кергезәләр. Кайнанасы киленнең айаг астына байан җәйеп каршы ала, сөт эчертә бер айак:

«Ак күңелең белән кил,
бәхетле булып тор», – дип, акча чәчәләр.
«Хәйерле булсынга» (*Кызан*).

– Байан җәйәделәр. Бусаганың бу йагында, өй эчендә байан җәйеп кергезәләр:

«Ак күңел белән кереңез,
Бәхетегез белән кереңез».

Чатырда утыралар бит туйда, байан җәйәләр. Шул байанны бер җиңгә барлык кунакларга да тоттырып чыга. Алар тотып, башларын сыйпап алалар:

«Сезнең балаларга, Сезнең кызларга да йуш булсын, шулай туй күрмәгә булсын».

Болар әйтә: «Рәхмәт, рәхмәт, сау булыңыз».

«Минем балама да йуш булсын
Минем кызыма да йуш булсын», – дип әйтәделәр (*Киләче*).

Менә шулай әйләндереп чыккан кешегә шул йаулыкны бирәделәр.

– Кызны китергәндә ишек йанында байанды җәйеп торасың. Пирбуй йегетне кертәсең. «Уң айагыңны бас», – дип. Кыз керә, байандыга баса. Алар керә. Тиз генә байандыны аласың да башларыннан селкеп, акчаны сибеп кертәсең. Хәзер дә шулай, әwәле дә шулай иде (*Кәменни*).

– Килен бусагадан атлап кергәндә өй эченә байанды җәйеп, байанды бастырып, айагының астына байанды салып кертәләр, сөт эчертәләр бер айак.

«Хәйерең белән килгән бул, ак йуллы бул,
Сөт кебек ак бул, тәмле телле бул,
Тигез гомер итегез», – дип,

шул сүзләрне әйтеп кертәләр. Байандыны тотабыз да башларыбызга сыйпайбыз:

«Балаларга да, оныкларга да йуш булсын», – дип (*Картузан*).

**Кодагый байандысы:**

– Акча чәчәләр шул байандының өстенә, «кодагый байандысы» дип. Кодагый муйындагы калтасыннан алып акча чәчә (*Киләче*).

**Килен байандысы:**

– Килен айак басканнан соң килен байандысы була инде, һәр кеше тотып-тотып карый.

«Минем улыма, минем кызыма да йуш булсын»;
«Безгә дә шундый йакшылык булсын»;
«Миңа да шундый килен килсен»;
«Кызым кийәүгә барсын», – дип.

Кечкентәй балалар булса, аларга да сыйпаталар:

«Менә сезгә дә йуш булсын, сез дә шундый көннәрне күрегез», – дип.

«Сезгә дә шундый йакшылыклар булсын», – дип.

Ул байандыны кадерләп салып куйалар.

– Өйгә кергәндә йегетнең әнисе тора. Йаулык җәйә йегет белән кыз кергәндә. Анда бер карт әби бармы, кеме бар – байанды җәйә. Шул байандыга йегет тә, кыз да басып керә (*Каңга*).

**Байанды йөртү** – килен аяк басып кергән ак яулыкны туй мәҗлесендә кулдан-кулга йөртү. Ул яулык изге, тылсымлы әйбер дип исәпләнә.

– Киленне байандыга бастырып кертәләр, ул байандыны бөтен халыкка тоттырып чыгаралар, чатыр буйы йөри ул байанды. Байандысыз туй башланмый, туйның башы – шул байанды.

– Кыз кергәндә айак астына байанды җәйеп, байандыга бастырып сөт эчерәләр, баш җаулыгы җәйәләр. Байанды дип әйтәләр ак җаулыкны. Ул байандыны чатырда бөтен халыкка тоттырып чыга йегет анасы.

«Сиңа да, синең кызыңа да йуш булсын», – дип тоттыралар. Кыз әнисендә туй булса, кыз кардәшләре йөртә. Йегет әнисендә туй булса, йегет кардәше йөртә. Байандысыз туй булмый.

«Синең малайыңа йуш булсын,
Синең кызыңа йуш булсын,
Синең оныкаңа йуш булсын», – ди.

Йакын кешесе йөртә байандыны. Йакын кешесенә бирмәсәң, ул үпкәләргә мөмкин. Кыз җиңгәсе дә җәйә байанды (*Каргалык*).

## Аwызландыру

**Кызга сөт эчертү, аwызландыру:**

– Кыз кергәндә җегет анасы байандыга бастырып сөт эчертә, аwызландыра.

Ак йуллы бул,
Ак күңелле бул,
Бәхетле бул, сөттәй татлы булыгыз.

Аwызың белән аш килсен,
Айагың белән ырыс (бәхет) килсен», –

дип шундый-шундый сүзләрне әйтеп аwызландыра, сөт бирә (*Кундрау*).

Он чәчеп кергезә: «Ашлы-сулы булсын».

– Килен кергәндә кайнанасы айак белән сөт тотып торады, шул сөтне килененә эчерәде.

«Килен ак күңелле булсын,
ак нийәтле булсын,
кайнана белән килен арасы да ак булсын,
тату йәшәсеннәр», –

дип бирелгән зат инде ул (*Сәетләр*).

## Кыз белән егетне кавыштыру, такка салу

**Таң алды, такка салу** – егет белән кызның беренче мәртәбә кавышулары, беренче кичләре.

– Таң алды була. Таң алды булгач йегет белән кызды салалар такка. Элек җиңгәләр тыштан караwыллап җөргән. Кыз булып чыкса, йегет йагы җиңгәсе кыз йагы җиңгәсенә бүләк бирә, әниләренә бүләк бирә.

– Йегет йанында кунып чыккан сун, җиңгәләр киленне җуындыралар. Ике җиңгә, берсе кыз җагыннан, берсе җегет җагыннан. Таза-чиста булган кызларга тактан чыкканнан сун акча салайдылар. Кыз җиңгәләре дә хәде (*түләү*) сораганнар. Кызның җәйгән җәймәсен икенче көнне кайнаталарына, кайнаналарына күрсәтә булганнар. Җиңгәләр җаулыклар җәйеп утыра булганнар. Шуларга бөтен хәрдәшләре акча ташлый булганнар җаулыкларга (*Киләче*).

– Кызның җиңгәләре биткүремдә кызның астына җәйгән җәймәне күрсәтәләр биткүремдә (*Каргалык*).

**Тактан чыгу:**

– Килен тактан чыга. Ике җиңгә өстәлгә җаулык җәйәләр. Әгәр кыз дөрес булып чыкса кийәү ике җиңгәгә акча ташлый шул җаулыкка. Әле дә шулай бездә, борынгы гадәт.

– Киленгә кайнанасы җуwынма куша. Килен җуwынмаса атай-анай чәйне үзе кайната. Килен җуwынса инде пич тутырып калач сала (*Кундрау*).

## Киленгә теләк бирү

– Бөтен туганнары теләк бирәде килен килгәндә:

«Киленең хәйерле булсын,
Киленегез кулыгыздан алсын».

«Киленеңнең аwызы белән аш керсен,
Айагы белән ырыс керсен
Бусагасы бийерек (*биек*) булсын,
Чагарагы (*чыга торган җире*) бийек булсын», – диде.

Анның җыры да бар:

«Бәхетле кайнана булып,
Киленең кулында калсын», – дигән.

Хәзер кулына күп калмый бит, айырым торалар. Шуның өчен җырлыйлар:

Туганнарым ал булсын,
Ал булсын да гөл булсын.
Бәхетле кайнана булып
Киленең баwырында калсын.

Алма тирәк утыртыпсыз
Төбе чайырлы (*уңдырышлы*) булсын.
Безгә килен, сезгә кийәү
Мәңге хәйерле булсын.

Шундый мәслихәтле җырлар җырлап теләк әйтәләр килен килгәндә (*Сәетләр*).

## Битачар, биткүрем

**Битачар, биткүрем** – яшь киленнең йөзен ачып халыкка күрендерү. Шул уңайдан мәҗлес була, кунаклар чакырыла.

– Таң алдында киләде кыз, икенче көнне биткүрем булады. Ике җиңгәсе ике җагында торады, бите каплы торады. Биткүрем булганчы битен кешегә күрсәтмиде.

– Килен төшкәч биткүрем күрсәткәннәр, киленнең ике җагында ике җиңгәсе торады, бите каплы булады болай. Ак җаулыкны тотоп торалар ике җиңгәсе, алар сәләм кылалар халыкка, айакларын бөгөп сәләм кылалар. Берничә җаулык булады. Бер йаулыкны иң йакын утырган кимпер ача, ул тагын икенче мамайны чакырады, син бит ач. Соңгы йаулыкны ачканда киленнең бите ачылады. Килен йакын кайын апаларының кулын алып күрешеп чыгады, үбә аларны. Ул битачар булады (*Киләче*).

– Битачар булганча күренмәгән килен, иртәрәк барган суга. Кайсылары бер атнадан йасаган битачарны, кайсылары бер айдан (*Кундрау*).

– Биткүремдә өч җаулык тотады кыз җиңгәләре, җакын туганнары килеп җаулыкны алады, җакын туганнары күп булса үпкәләп калыр дип уйлап биш җаулык та тотады. ике җиңгә тотады җаулыкны. Җаулыкны килеп алады да килен беләп күрешәде. Килен сәләм кылады тезен бөгеп, кул алып чыгады (*Киләче*).

– Биткүремдә кардәшләр, дус-ишләр чакырыла, былау бешә, төрле бәлешләр бешә. Өстенә аркалык йабынып, алдына пәрдә короп кыз чыга.

– Ике җиңгә килеп битачар йасыйлар. Бите ачылмаган килеш сөйләшми, битачар була, шунда гына сөйләшә, башлый. Ике җиңгә йаулык тота, киленне халыг алдына чыгаралар да килен инде сәләм бирә, кайнанасы килеп җиңгәләрнең кулыннан йаулык ала.

– Битен ачкан кеше җәш киленгә акыл биреп утырады:

йакшы бул,
кайнанаңны тыңла,
агар сәләм әйтеп тор,
айагың бөгөп сәләм әйт,
кайнатаңа каршы сүләмә,
кайнанаңның телен ал,
кайнанаңның кулын ал,
каты сүләмә, телен кайырма,
суwын биреп, ашын биреп тор, ди (*Сәетләр*).

– Тастар, сылаwыч, мизбек инде, бер-ике йыл йөри, бит ачмайды. Кай заман кешеләр чакырып килендең битен ачтырайды ул заманда. Бит ачтырганчыга хәтлек мизбек, сылаwыч, тастар кийәде килен, җегетнең җиңгәсе килендең битен ачады, утырган халыктың, кайната, кайнаналарының кулын алып, кийетте бирәде (*Лапас*).

– Биткүрем булады, җиңгәләр йаулыкны дүрт почмагыннан тотып торадылар, йаулыкны бер йегермене тотып торадылар.

Киленнең мамасы айагына басып:

«Хәйерле булсын, җаным», – дип, киленнең битен ачады.

«Кәйтисе (*әнисеннән яки әтисеннән олы туганы*), киленнең битен ач», – диде. Кәйтисе килеп, киленгә сәләм биреп, бер йаулыкны алып китәде. Шул көннән башлап килен урамга чыгады, йылгага суга барады. Бите ачылмаса, ул урамга чыгып кешене күрә алмый, йарамый чыкмага (*Киләче*).

– Биткүремдә ике җиңгәсе ике җактан киленне акиләде. Килен битен күрсәтми, сәләм кылады. Өч-дүрт йаулык саладылар.

Тәтәм, «киленнең битен ач», – диде. Бер йаулыкны алып, киленне кочаклап күрешәсең.

«Кәртәсе (*әтисеннән олы ир туганы*), киленнең битен ач» – диде. Битен ача, өйдә утырган кимперләрнең, өлкүнләрнең кулын ала (*Кызан*).

– Биткүремгә туган-кәрдәшләрне чакыра. Йаңа килгән киленне кыз җиңгәсе алып чыга, кул алдырып чыга. Туй узды, киленне күрсәтәләр. Ашыйлар, эчәләр, күршеләр, туган-кәрдәш керә, күрештереп чыгалар. Иренең кардәшләре белән күрешә, кулларын үбә.

– Кәйнәнәм бит йаптырайак булды. Мин битемне йабып йөрмәгә тийеш идем. Кайнагам әйтте:

«Тутам, син дөрес сөйләшмисең, ничек бит йаптырмага кирәк, киленең укытучы», – диде. Мин бераз wакыт йабып йөрдем. Энесе ачуланды: «Нинди бит йабу хәзерге заманда. Ач, килен», – дип утыртып, битемне ачтырды. Мин кийетемне бирдем (*Сәетләр*).

## Кул алдыру

**Кул алдыру** – килен кешенең үзеннән олыларның алдына килеп, тез чүгеп, кулларын үбү йоласы.

– Биткүремдә килен белән малайны чыгарып кул алдырып йөриләр. Ә кайнана инде киленгә биткүремгә үзе теләгән затны бирә.

– Күршеләрне чакырып кайнанам биткүрдем йасады. Җиңгә сине чыгарып күрсәтә, шунда утырган халыкка кул алдыра.

– Биткүрем икенче көнне була. Биткүремдә тирә-күршеләр керә, кыз җиңгәләре тирә-кырукны утырта, киленнән кул алдырып чыга. Утырган халыкның барсының кулын алып чыга килен. Шуннан килен алҗапма бәйләп чыга, чәйне килен койа, шуннан эшләп китә. Килен айак-саwытлар, сөлгеләрен йуwып элә алҗапма бәйләгәннән сун (*Картузан*).

– Туй булганда ике җиңгә киленнән кул алдырып чыгадылар. Бер җиңгә йегет биттән, бер җиңгә кыз биттән булады. Киленне алып чыгалар. Алдан беренче җиңгәсе йөриде, кыз уртада, аннан икенче җиңгәсе йөриде. Бөтен халыкның кулын алып чыгалар. Әле дә бер ул. Шунда туганнары белән, туйга җыйылган халык белән таныштыралар (*Кызан*).

**Килен булгач кул алу:**

– Иртә белән торгач кайнананың кулын алырга тийеш булган килен.

«Нихәл әмәм (*әнием*), нихәл этийем», – дип.

«Рәхмәт, кызым», – дип тордылар кайнаналары (*Сәетләр*).

## Кинчәкләү, җиңгәләү

**Кичикләү, кинчәкләү, кичикләмә –** битен ачкан вакытта яшь киленнең кунакларны сәләмләве.

– Киленнең бите күренми торган ыйы. Икенче көнне кызлар барып, дуслар барып, кичикләмә дип әйтә торганнар ыйы. Ике йагында ике җиңгә торады йаулык тотып, чапанын бөркәнеп. Кәйен сеңлесе килеб инде битен ача, йаулыгын. Әбиләргә дә кичикли кыз, тез бөгә, сәләм бирә. Кичикләмәгә кызлар киләләр, җиңгәләр дә була тоган ыйы. Кыз кичикләгәндә, биткүремдә тастар бәйләде башына (*Сәетләр*).

– Кыз кинчәкли диләр, анда кызлар гына була. Берәүнең кызы кечкентәй булса да, шул өйнең зур кызы булып саналса, алты-җиде йәшләрендә булса да, шуны чакыра иде, шул өйнең зур кызы дип. Җиңгәләре килә, кызга чәй койдоралар. Ул wахытта арак йук, чәй генә эчәләр. Тагамнар була пахлаwа, лаксалба, пәрәмәчә, пылау. һәркем үзенең хәленә карый. Килен үз кулы белән чәй бирә (*Сәетләр*).

– Кызның үзенең тиңнәрен чакыра, өлкүннәрне чакыра. Сазын тартып, бийем бийеп, чәйен эчеп кызлар утырады, кыз кинчәклибез дип. Арак коймыйды ул заманда.

– Кинчәкләп алган сун башына җаулыгын бәйлиде, алына фартыгын тотады, җаламбаш җөрү җук ул заманда.

– Килен килгәч кәйенсеңелләре килә, мамайлар килә. Килен кичикли диләр. Мамайлар йаулыклар тотып торалар. Шул тотып торган йаулык өстенә ничә башйаулык эләде. Син туган тийешле ачасың да бу йаулыкны аласың. Битачар дип әйтәләр, кичәкләп йөри килен булып. Таң алдыннан кыз килә дә иркәкләр утыра тастырханда, алар таралганнан суң икенче көнне кичәкләү була. Килен чәйне эчерә килен кичәкләгәндә, кул алып чыга (*Киләче*).

– Кичәкләү көнендә кыз биттән, ул биттән кимперләр чакыралар. Шул кичәкләгәндә баштаргычны (*башка бәйли торган ураманы*) йабып чыга килен. Шул хатын кайнанасы ачмага тийеш. Җиңгә белән килен икесе мамайларга тез чүгәләр, кул алалар (*Кундрау*).

**Җиңгәләү** – кыз кияү йортына килен булып төшкәч, аның битен ачып халыкка күрендерү.

– Кыз килгәннән соң икенче көнне йегет өйендә киленне чыгаралар. Анын бите йабык була. «Җиңгәнең битен ачабыз, җиңгәли», – диделәр кызны. Җиңгә була инде, кинчәк була битен ачканнан суң.

## Килен җулы

Киленне кийәү йагының туганнары белән таныштыру: – Җәш киленне кайнанасы йакын туганнарына кыдыртып әкиләде. «Килен килде, сезнең ишегегезне күрсен», – дип. Бөтен җакын туганнарына кийетләп әкитәде, күләген салып, җаулыгын салып (*Сәетләр*).

– Килен җулы дип киленне үзенең туган-кәрдәшләренә йөртә кайнанасы. Үзе алып йөри. Өй хуҗасы киленне байан җәйеп каршы ала, киленгә падаркалар, мата сала.

– Уң йак кунчы (*күрше*), сун йак кунчы дип күршегә кергезәте кайнана киленне. Килен күргәзә кайнана, чәй эчәләр (*Киләче*).

– Кайнанасы белән киленне чакырып аладылар. Минем ике ак йефәк шәлем, йефәк күлмәкләрем бар иде. Менә иремнең кайын агасы чакырып алды. Чакырганда кийет алып барырга тийеш, буш кул белән бармыйлар. Кимперенә йаулык алып кердем, болар чакырып алдылар мине. Шулай йаңа төшкән киленне йегетнең туганнары чакырып ала. Чакырып алмый торып, килен аларның өйенә керми.

Мине менә чакырып алган йук. Кайнанам әйтә: «Син ди фәлән кешеләргә бармый тор, алар чакырып алган йук әле», – ди. Чакырып алмага тийешләр йаңы төшкән киленне. Кайнанасы белән чакыра, ире белән түгел. Тамагын пешерә, чәй кайната. Аракы эчү йук. Йакшы сүзләрен әйтәләр. «Без менә туганнар, килен, шулай булыйк, болай булыйк», – ди (*Сәетләр*).

## Кийем китерү

**Кийем китерү** – туй алдыннан егет ягының кызга баштан аяк кием алып китерү йоласы.

– Баштан-айак кийем сорый кыз анасы, кийемнән пәлтә, шәл, ату (*читек*) сорай кызга. Бөтен затны биргәннәр йегет йактан, аркалык, кулына йөзек биргәннәр.

Туйга йегерме көнме, бер аймы кала кызга кийем китерәделәр, җыраг аwыллардан ат белән арбага салып китерәделәр.

– Җаулыгын, чөлкәсен, пәлтәсен, тастарын җибәрде җегет бит, мага җаучы җибәргәндә тастар да җибәргән. Кызга бөтен кийемен кийәү җагы бирәде, тастарын да, пәлтәсен дә (*Кундрау*).

– Кийәү биттән йибәрәләр ылба (*ефәк*) күләк, ылба аркалык, бурса йаулык, тастар. Туй көнне йегет биттән кыз биткә киләде. Өлкән патнуска салалар, дастархан белән бәйлиләр, сырга-йөзөкләр куйадылар. Бу кийемнәрне туй көнне акитә. Чатырда чыгарып күрсәтәләр. «Кийәү алып килгән әйбер», – дип (*Кызан*).

**Кийем печү** – никах алдыннан кыз өйенә барып, никахның һәм бирнә китерүләрнең көнен билгеләү. Элек ырымлап кызның никахка бирелгән күлмәклегенең бер почмагын әз генә кисеп алып кайта торган булганнар.

– Кызга киләсең кийәү биттән. Кызга бирелгән бүләкне, күлмәген печәсең инде. Мин үзем кийем печмәгә бардым. Миңә мийәм (*әнием*) әйтте, син кийем печмәгә беләмесин, диде, кайчы белән бер мийешен генә кисеп алың диде. Никах алдында була ул кийем печү. Көнне билгели, бу көнне никах, бу көнне так ди (*Җәмәле*).

## Тугыз

**Тугыз** – туй алдыннан кызга киемнәр һәм бүләкләр китерү көне. Элекке вакытларда тугыз төрле әйбер китерә торган булганнар.

– Тугызны тутырып бирәсез, диләр. Шәл киләде, күлмәк киләде. Йаучы әкиләде арбага салып. Кызга тастар-сылаwыч, тийен тун, йакшы укалы капталлар, атулы калушлар (*Кызан*).

– Мине баштан айак кийендерделәр болар, туфли, аркалык, шәл, ату алып бирделәр. Әйттеләр, инде туйга wахыт җитте. Шул затны тугыз итеп бөтенесен тастарханга урап туйга китерделәр.

Бер тийен (*төен, төенчек*) генә түгел, биш тийен иде кийемнәрем (*Кызан*).

**Кодаларга кийем бирү:**

– Йегет йак кыз йакны чакырады, анда йегет йак кийетли, йагалы кийем бирә анасына-атасына. Кодага йагалы кийем йабат, тун йабат.

«Тун биреп алган киленем», – дип әйттеләр (*Кундрау*).

## Күлмәк, күләк

**Күләк. күлдәк, күлмәк:**

– Килен озон гына күләк кигән, озын җиңле. Айаг очы да күренмәсен, озын җиңле күләк.

**Абурткалы күләк, күлмәк** – бала итәкле күлмәк.

– Күлмәкнең итәгендә абуртка. Абурткага ак зәһәннән (*ефәк*) куржива теккән.

– Затлыйак кыздар бармы, күлдәгенең итәге бармы, йаулыгының итәге бармы, чигү чигәде узырлап. Текмәгә булдырдылар (*Сәетләр*).

**Махмал күләк** – бәрхет күлмәк.

Махмал күләк киделәр киленнәр, күләкнең итәгендә өчәр кат абуртка.

Байларның кызлары махмалдан күлмәк кигән, энҗе белән турылаган (*чигелгән*) күлмәкне, уртасына алтын баҗаклы (*каптырма*) тагалар. Ике кахам (*абыем*) бар иде, ике җиңгәм бар иде, махмал күлмәк кийеп йөрделәр (*Кызан*).

**Кийемнәрне элеп куйу:**

– Кызның күлмәкләрен өйдә җепкә элеп куйа торган булган. Нинди кийем бар, элеп куйа торган ыйы бер җепкә. Бер йома эленеп тора кийемнәре.

– Киленнең күлмәкләрен, аркалыкларын элеп куйалар халык күрсенгә, йугарырак элеп куйалар сандыктан чыгарып. Күлмәкләре күб икән дип санап утыралар. Киленнең кийемнәрен килеп карыйлар, кандый кийемнәре бар икән дип. Җиңгәләр элеп куйалар киленнең кийемнәрен (*Кундрау*).

## Аркалык

**Аркалык** – өстән киелә торган җилән.

**Чал аркалык** – йон материядән тегелгән җилән.

**Махмал аркалык** – бәрхеттән тегелгән җилән.

– Аркалыкның итәге киң, җиңе киң, укалы була, төймәләре көмеш була. Аркалыкның билләре бөрелеп тора, парчалардан тегелгән. Бар да махмал, бар да укалы, бар да ука ман теккән. Йулак-йулак (*юллы-юллы*) йефәктән астарлыклы аркалык була. Аркалыктан күлмәге чыгып торган (*Сәетләр*).

– Аркалыгы, капталы бар иде әйемнең. Үлгәндә өстемә йабарсыз дип саклап торды.

– Парча дигән заттан тегәләр аркалыкны (*Каргалык*).

**Ылба аркалык**: Монади гөлле-гөлле йефәк аркалык (*Лапас*).

## Каптал, чапан

**Каптал, хаптал** – өске кием.

– Махмал каптал, укалы каптал булаты. Махмал капталны кайнанама бирдем, күлмәгем үземә тора. Капталларга ука койган айланасына (*Кызан*).

– Икөн (*өлкән*) агалар озон хаптал киделәр.

– Кыскайакларга (*хатын-кызларга*) каптал биргәннәр, ике чите алтын җеп белән чигелгән каптал булган. Макмал каптал киде киленнәр (*Сәетләр*).

**Чапан** – өске кийем.

– Кызыл махмал чапан булган. Кадерле кунакка, кадерле кода-кодагыйга чапан кигезгәннәр бүләккә.

Безнең кызыл махмалдан теккән чапан булган. Шуны минем иремә кигезгәннәр.

Ирем туйга куй эзләп йөргән. Берсе бирмәгән. Икенчесе акыллы кимпер булган.

«Ана, куйның эченнән сайлап биреңез бер куйны», – дигән. Шул куйны әкилеп, туй малы итеп биргән кыз биткә.

Атам биргән кийетне, шул кызыл махмал чапанны шул куй биргән кимпергә «хәйерле булсын»га биргән, шуган биргән чапанын. Тегеләр кимперләр җыйып, куанып кунак җыйып күрсәткәннәр шул кызыл махмал чапанны. Аны күрмәгән булганнар андай чапанны (*Сәетләр*).

**Пәлтә, бызау җалаган пәлтә:**

– Бызау җалаган пәлтә кигән, махмал пәлтә кигәннәр киленнәр. Киң генә пәлтә, үзеннән йакасы булган (*Кызан*).

**Күкрәкчә** – күлмәк эченнән киелә.

– Эчтән күкрәкчә кидек, агалар бар, әти бар. Күкрәк беленмәсен дип күкрәкчә кидек (*Кундрау*).

**Фартык** (< *рус*. фартук) – алъяпкыч. **Чигүле_фартык** – чиккән алъяпкыч. **Җиңле фартык** – җиңле алъяпкыч.

– Фартыклар китәннән (*киндердән*) бүздән теккән, арттан да, алдан да йабык фартыклар кигән (*Картузан*).

**Зыпын** (< *рус*. зипун) – алъяпкыч.

– Зыпын тегәмез, кулыннан теккән узыр салып, озон зыпын кигән кинчәкләр (*Лапас*).

## Аяк киемнәре

**Ату** – читек.

– Айагына ату кигезделәр, чигүле ату булды, үкчәле ату булады, мачтак табанлы (*үкчәсез, тоташ табанлы*) ату булады (*Кызан*).

**Чолка** – оек.

– Айактан чолка чишелми, йалан айак җөрми, ойат була (*Кундрау*).

## Баш сару

**Тастар** – башка бәйли торган урама. Ул сөлге кебек озын, баш-башлары чигелгән яки бизәкләп кулдан сугылган булган.

– Кинчәктән алып кортка булганчы баш сарган. Минем абам (*әни*) тастар сарган, кындыз йакалы пәлтә, башына бүрек кигән. Абамның тастарын мин гомер буйы саклыйм. Өч канатлы тастар булды (*Сәетләр*).

Тастар йабынып йөргәннәр киленнәр. «Башына тастар төшкәндә» дигәннәр, килен булган инде. «Тастар төшкәндә» дигән сүз тормышка чыккан дигән сүз.

– Йәш киленчәк, тастар төшкән киленчәк. Киленчәкләр тастар кигән, мизбек кигән, кимперләр дә тастар кигән. Киленчәк төшкәндә тастар белән төшкән. Тастарлары төрле җеп белән чигелгән. Ул заманның кызлары (*Сәетләр*).

**Баштастар:**

– Йефәк шәл, баштастар кигән кыз.

**Буйтастар** – баштан алып аяк йөзенә кадәр асылынып тора торган тастар.

– Буйтастарның эчендә сылаwыч дигән зат бар иде.

**Кыйык тастар** – олы хатын-кызлар бәйли торган тастар: – Кыйык тастарны сарынган өч-дүрт бала анасы булганда, өлкән хатын булганда.

**Башсаргыч, баштарткыч, тастаргыч** – тастар астыннан бәйләнә торган баш киеме.

– Әбиләр шәл урынына тастаргыч кийеп йөргәннәр.

– Баштарткычны астан бәйләп, өстән тастар бөркәнә.

– Баштарткыч, тастаргыч, арты озын, ике йагы да озын, бу төшен бәйлисең дә аның баwын бәйлисең. Аны олы кешеләр бәйләгән. Баштарткыч ылбадан булды (*Кундрау*).

**Сылаwыч** – чәч үремнәрен каплап куела торган бизәнү әйбере.

– Тастар, сылаwыч эчендә чачы торган, чачларын күрсәтми, битен күрсәтми (*Сәетләр*).

**Сулык** – сөлгесыман яулык.

– Кинчәкнең сулыгы башында булаты, сулыктың (*сөлгенең*) чите чиккән узырлап (*Кундрау*).

**Мизбек** – (кундрау татарлары төркемендә) яшь киленнең баш киеме. Миз > мийез > мөгез, бек > баг > бау, ягъни мөгезбау булырга мөмкин. Маңгайны һәм чәчне күрсәтми торган баш киеме.

– Кызды йаулыгы белән әкитәләр, аwылга бер-ике чакырым калганда кийендерәләр, мизбек кийертә җиңгә.

– Мизбекнең алды бите тимер, арт бите куймалак тиде төймәләр белән. Тастар сарады, кыздың битен йабады.

– Җиңгәләре кийендерген, шашын үргән, мизбекен, тастарын кигән.

– Йаңы төшкән килендә мизбек кигезгән. Кинчек бер җомамы, эки җомамы кийеп җөргән әле. Төнгә җатканда шишеп йатады, иртә белән торганда кийеп алады. Сыйыр саwа, зат итә (*нидер эшли*), шишмиги булмый (*Лапас*).

– Йегетнең өйенә баргачын мизбек кигән, мизбекнең аwырлыгы җарты пот, сигез килаграм. Мин күрдем гуй.

– Төшкән җирендә мизбек белән, манитлы каптал белән җөрделәр киленнәр.

«Мизбексез килен булмас,
Косаксыз (*билбаусыз*) кыз булмас», –

диде. Кадерле кийемнәр булмага тийеш алар.

– Җиңгәсе белән китеп мизбекләрен салып йөргән далада гына. Өйдә кийеп йөргән сыйыр сауса да, кизәккә барса да (*Кундрау*).

– Мизбекне туйга, кунакка барганда кигәннәр. «Мизбекле ул, бай», – дип мактап сөйләгәннәр. Мин сирәк күрдем ул мизбекне.

Җиңгәм майым икүмез
Без барабыз кизәккә.
Җалкындай кара чачымыз
Кур булдыңыз мизбекте.

Без икемез тиң идек
Куйдан чыккан бөйөрөктөй.
Инде айырылып барамыз
Аwада очкан йөрөктөй (*Лапас*).

**Шәл**: – кыз зур шәлен йабынып килде, биткүрем булады, шунда гына битен ачады.

**Билмау** – билбау, **косак** – билбау.

– Көмеш билбау булган. Озын, ука мынан койган косак булган. Мизбек таккан дип косакларына да теккәннәр.

– Кызларда биленде косак булган манитлы.

«Косак биреп, тун биреп алган киленем», – диде.

Сарыдин самар (*самовар*) җайлаган
Эремчек корты кайнаган.
Кызлары бик матур икән
Билләренә билмау байлаган.

– Айаг очы да күренмәсен, кул очы да күренмәсен. Озын итеп күлмәк кийәбез, аркалык кийәмез, билмау буwабыз билгә. Тастар саралар башка. Айактан чолка чишелми, йалан айак җерми, ойат була. Йазда йазча, кышта кышча кигән (*Кундрау*).

**Ыштан** – штан, **ычкыр** – иштан бауы.

– Ыштанны ычкыр салып тегеп кийә, балагын чолка эченә тыга ыштанның (*Кызан*).

### Бизәнү әйберләре, сырга, беләзек

**Шашбау, чәчбау** – чәчүргеч.

– Кинчәк чәчләрен икедән үргән, чәчбау таккан очона.

– Шашбау салган кызлар шашның очона. Шаш төбөндә төплекле шашбау булган (*Сәетләр*).

**Санҗак, баҗаклы** – брошка, кадавыч.

– Алтын баҗаклы, санҗак таккан килен (*Җәмәле*).

**Сырга** – алка, **җөзөк** – йөзек.

– Сырганы, җөзөкне йегет бит алат, йегет бит кигезәт (*Каргалык*).

**Җагалык** – муенса.

– Җагалык кийә, тастар сарына өлкөн хатын, кышын тастар сарына.

**Алка:**

– Кызларның борынында уң канатында алка булган (*Лапас*).

**Беләзек: йазулы беләзек** – бизәкле беләзек.

**Кулбау** – беләзек.

**Үсмер кызларның киеменә карата теләкләр:**

Кызwакытта, үскәндә башымдан чишеп, билемдән билмауны чишеп, айактан атуны салып утырганда агаларым килеп калса, «тиз биленде бу, айагыңа ки», – ди. Кыз wакытта билен будыра, айагынан салгызми (*Кундрау*).

– Айакларына казан читекләре кигәннәр, кайсылары, чүәк кигән күпертмәле ак йефәк шәлләр, монда бажаклылар кигән, энжеләр, беләзекләр. Шәлсез йөрмиләр, барысында да шәл була иде (*Җәмәле*).

## Кияүнең киемнәре

– Эшләпә, кәпәч (*түбәтәй*), йатак (*бүрек*) кигән кийәү, куй йоныннан вал’ник бастырган, кара ату, камзул кигән, кыш көне түгәрәк бүрек кигән (*Картузан*).

**Бурчын** – тиредән тегелгән аяк киеме.

– Айакларына бурчын киделәр малдың тиресеннән, кара малдың (*сыерның*) тиресеннән. Куйныкыннан тун йасаган, бүрек йасаган. Сыйыр тиресеннән, кара малдың тиресеннән бурчын теккән.

– Бурчын инде мал тиресеннән була. Менә малның тиресен тезеннән салдырып тегә дә менә болай тишеп бау тага. Мал тиресеннән шул бурчын дигән зат кигән, айак кийеме итеп. Йагада аны күрмәгән халыклар тамаша итә булганнар. Йаз да, кыш та кигән. Йомшак булган ул, эченә печән сала, йомошак чүперәк сала табанына, җылы булсын дип. Аны кичтән сала да эссе урынга куйсаң ул кәүрәп (*бөрешеп*) кала, кичкелеккә бер җылырак урынга күтәреп куйып калдыра. Көне буйы карда, йаңгырда йөрсә лычтый булып йүwешләнә. Ирләр киде бурчынны, картрак иркәкләр да киде (*Картузан*).

## Туй мәҗлесләре һәм туй ашамлыклары
## Чакырту

**Чакырту** – туй алдыннан ярәшелгән кызны кунакка чакырып сыйлау. Ул үзенең иптәш кызлары белән бергәләп чәйгә, кызлар утырышына йөри.

– Кызга чакырту бирә торган булганнар. Такка берәр йома, ун көн калганда көн дә шул берәр кеше өйенә чакыртуга барганнар. Чакырып чәй, аш-су куйганнар кызларга. Кахасы-җиңгәсе, тәтәсе-җизнәсе кызны чакырып кунак иткәннәр. Кыз бара үзенең дуслары белән. Тийешле кешеләре кызга бүләк биргәннәр. Кызлар йанына кызлар чакырганнар, саз белән утырганнар кызлар.

– Кызны әйттерәләр, чакырту бирәләр. Кызларны җыйалар. Уйын-келке, җырлау кыз биттә була. Әтрафтан халык килә, бакыр чәчәләр (*Кызан*).

– Чакыруга барабыз, апкитәйәк кызны сыйлап җыйылабыз, җырлыйбыз, бийибез, саз тартабыз. Мин күп йөрдем чакыртуга, күп кызларны озаттым алысларга, Кундрауларга.

– Чакырту бирәләр кызга әйттерелгәч. Ул аркалыкны йабынып, ике йагына ике кызны алып чакыртуга йөри башлый. Кыз озату була инде, кәрдәшләре чакырту бирә инде, күрә калдык без (*Җәмәле*).

## Туй күтәрү, туй малы

Туйга йегет йагы йибәрә:

– Туйдан пирут ике хатын бара. Куйларны, дөгеләрне итеп кайталар. Аларга кийетләр, күлмәкләр бирәп йибәрәләр. Кыз бит сорый, йегет бит җибәрә. Куй, дөге, чәй, шикәр.

**Туй күтәрү** – туй үткәрергә акчалата яки әйберләтә булышу.

– Йегет биттә туй булганда бер агасыннан йөз сум, бер куй, кайнагасыннан кәҗә, бер агасыннан ике йөз манит акча, биш йөз манит акча, шулай акча салалар, йегетнең туйын күтәрәләр (*Картузан*).

**Туй малы** – егет ягыннан кыз ягына бирелә торган хайван.

– Туй малы дип йегет йактан ике куй киләде, йә булмаса бер зур карамал суйып, йарты йагын үзенә алып калады, йарты йагын бу йакка бирәде.

– Йегет биттән куй, дөге җибәрәләр, уналты кила дөге була. Аны иртәгә туй дигән көнне йегет биттән йаучы алып килә кыз биткә. Куйның буйнына матур йаулык бәйләгән була. Аны кыз биттә кемгә әйтәләр, син чишеп ал дип, шул чишеп ала. Икенче көнне пылауга шул куйны суйалар.

Шул суйган куйның башын, сыйрагын айакларын куйның тиресенә төреп, йегет биттән килгән йаучыга җибәрәләр. Ә хәзер инде куй җибәреп тормыйлар, аның суйуwы бар, эше бар, акча гына бирәләр, ит җибәрәләр. Йә әйтә: «Минем үземнең малым бар әүләмдә (*ишегалдында*), итнең акчасын гына бирегез», – дийә (*Кызан*).

**Туй көне**: – Кече йомада була туйлар (*Җәмәле*).

## Туйга чакыру

– Йегет йактан йегетнең җиңгәләре чыгады өндәүче булып. Күп халык чакырса бу урамга ике кеше, теге урамга ике кеше чыгарады, килендәшләрен чыгарады. «Туйга чакырабыз, йегет йагына», ди. Сәгәтен әйтәделәр. Өндәүчеләр ак йаулык тотып йөри, төйнәмәгә.

Аларга бер манитмы, бер кечерәк йаулыкмы бирә. «Сезнең балаларыгызга да йуш булсын, туй күрегез шулай», – дип бирәде, буш җибәрмиде. «Йакшы, барабыз иртәгә», – дип әйтәделәр.

– Аwыл кечкенә иде, туйга бер өйне дә калдырмый чакыра торган иде. Менә өйнең чыгып торган трубасы бездә шуwал дип әйтеләде.

«Шуwал сайын чакыр, берәү дә калмасын», – диләр иде.

Өндәүче чыгып килгәндә йаулыкка биш манитмы, ун манитмы салып бирәсең, «туй ийәсенә» дип, үзенә «табан йулың, айак йулы», дип биш манит бирәсең. Ул өндәүче үзенекен айырым, туйныкын айырым җыйады. Туйныкын әкитеп бирәде туй ийәсенә. Өндәүчегә бирәләр иде «бу синең сибәрлегең» дип. Туйда шул акчаны сибә, чәчә.

– Кызның жиңгәсе чакырып чыгады туйга. «Менә бу йакны син чакырасың, бу йакны син», – дип ике җиңгәсенә әйтәде. Кызның туйына чакыручы кешеләр кийенмәгә тийешләр, йакшы кийемен кимәгә тийеш.

«Бу җиңгә үзенең кәйенсеңлесенең туйына чакырып йөрүче» дип белеп тормага тийешләр. Чакырган тумалары шатланырга тийеш.

«И, шундый әрү итеп кийенгән, безне туйга чакырып китте», – дип (*Сәетләр*).

Әwәле бөтен аwылны тоташ чакырады туйга.

– Әзилдә туйга чакырып йөргәннәр. Әрбер өйгә кереп саратский саз белән чакырып йөргәннәр. «Әзерләнеп торыгыз, без килеп алабыз сезне», – дип урам буйы җыйып китәде чакырган кызларны. Бик күңелле булган ул wакытта. Ул wакытта саз белән азарланалар (*маташалар*) иде. Мин үзем дә уйныйм саратский сазда (*Кызан*).

## Туй циклы

**Билге туй** – кызның өендә, кияүгә чыгарга ризалык билгесе итеп бүләк бирелгән көнне үткәрелә торган мәҗлес.

– Билге туйында бер җаулык бирәләр, ул җаулык кийәүнең анасына була (*Кундрау*).

**Икөн туй** – өлкән туй, кыз йортында үткәрелә торган мәҗлес, элек туй көнне ат чабышлары, көрәшләр оештырганнар.

– Бер йома элекке (*алдан*) чит аwылга хәбәр әйтәде, менә шундый туй була, көрәш була, ат йарыш була, икөн туйга чакырам (*Киләче*).

**Кыз туй, өлкөн шикәре**:

– Кызды әкиткәндә кыз туй булады (*Кызан*).

**Кечки туй, кечкентәй туй** – кызны ярәшү хөрмәтенә аның әти-әниләре йортында үткәрелә торган мәҗлес.

**Җыйын**:

– Кечки туйда җыйын диде. Җыйынга җыйадырыйы. Картлар түр биттә, ирләр урта биттә, йәшләр айак биттә. Йегет йакның җыйыны, кыз йакның җыйыны диләр. Хәзер туй диләр инде (*Сәетләр*).

**Кичке туй, азаматлар туйы**:

– Җәш киленнәрне алып кайнаналары көндез бара туйга, кичке туйга ирләр бара, ирләргә балкуwас куйа. Азаматлар туйы диделәр (*Кызан*).

**Нике туй** – никах туе.

– Нике туй булады кыз биттә (*Кәменни*).

**Чатырлы туй** – чатыр корып, күп итеп кунаклар чакырып уздырылган туй.

– Чатырда йасыйлар туйны. Әүләгә чатыр коралар, пылау бастыралар зур казаннарда. Суны алдан җылытып куйалар айак-саwытлар жумага.

– Туй өйләргә сыймый. Әүләгә чатыр бастыралар.

– Йегет биттә чатырлы туй дип әйтәделәр, чатырлы туй булады йегет биттә. Кичтән булады иртә белән таң атканчы (*Картузан*).

– Чатыр корып бер туй да йасаганы йук диләр, ул нинди кеше диләр. Чатыр корып туй йасау ул минем кийәзем (*бурычым*), дидер, туйны аткарырга (*уздырырга*) кирәк диләр.

– Әүләдә чатыр корганнар, бөтен туган-кәрдәшләр чатырда утыра. Чатырда ирләр-катыннар бергә утыру йук (*Кызан*).

– Чатырда җиргә турлык (*камыштан сугылган палас*) җәйгәннәр дә айакларын бекләп утырганнар. Чакыннан, җикәннән суккан турлыкны җәйеп утыра торган булганнар. Өстәл булмаган, идәндә утырганнар (*Кәменни*).

**Көндезге туй:**

– Көндезге туйга баралар киленнәр, бирәзәләрен йабынып баралар. Кайнаналары аркалык кийеп бирә, шулай туйга барып кайталар. Хатыннарга балкуwас куймыйлар, эчке йук көндезге туйда (*Кызан*).

– Көндезге туйга киленне кайнана алып бара. Алдан кайнана бара капталны кийеп, арттан килен бара. Килендә дә каптал. Киленнең бите каплы булмага тийеш. Шулай туйга алып барган киленне. Элек кайнана күрешә, арттан килен күрешә. Киленне йегет битнең җиңгәсе чыгара, килен тез чүгә.

– Көндезге туйда кодагыйлар алабыз. Ике йактан сиксәнгә йакын кодагый алабыз. Шул туйдагы кунакларның барысына да кийет бирәбез. Кызның анасына, йакындагыларына кийет бирелә. Утыралар тезелеп, алларына кийет салабыз.

«Хәйерле булсын, хәйерле булсын», – дип (*Сәетләр*).

**Картлар туйы** – көндезге туй.

– Баш кодагый көмеш акча чәчә туйда. Картлар туйы бетә баш кодагый акча чәчкәннән суң. Картлар туйы көндез булады. Чәй эчерәләр, бәлеш өләштерәдәләр, килгән кийемнәрдән тугызны күрсәтәделәр (*Каргалык*).

**Кода төшөр туй** – кыз өендә кияүнең ата-аналарын чакырып үткәрелә торган мәҗлес.

– Йаулыг алмага килгәннән суң кода төшер туй булады. Кода төшөргә бер мал суйады, туйның көнен кисәде.

– Икенче көнне кодалар килә. Кода төшөр туй диде. Менә ун кода-кодача киләме, биш киләме. Кода төшөр туйга кызның йакыннары гына чакырыла…

Сыйлык, җимешләр куйыла, кешмиш, арих, кызның әйберләре – бар да шул кода төшөр туйда алып киләделәр.

Кода төшөр туйда кызның эти-эниләренә җимеш бирәде, йакын агасы булса, җиңгәсе булса уган бирәде (*Кундрау*).

**Кыз туй, көрәш туй** – кызны кияүгә биргәндә атлар чабыштырып, кешеләрне көрәштереп зур туй ясау.

– Туй йасарга торады. Менә мин ди көрәш туй йасыйм, ат йарыш була, ди. Бер йома элеке чит аwылга хәбәр әйтәде, менә шундый туй була, ди. Урамга далага чыгарады, көрәшләр, бийү, җырлау.

– Кызын кийәүгә бирсә, көрәш туй йасаганнар, атлар чаптырганнар (*Киләче*).

**Пәти туй** (**пәти** – гарәп теленнән кергән сүз-фатиха) – кияү өенә килен төшкәннән соң уздырыла торган мәҗлес.

– Килен кайнатасының астына кийез җәеп утыртады, дастархан җәйәде, туй кунаклары киләде пәти туйга. Кайнатасы килен белән малайга пәтисен бирәде (*Кундрау*).

– Дүрт-биш күрпә бирә мамыктан йасаган, махмал тыстаган. Биш-алты кешене чакырып пәтисен (*фатихасын*) бирәде кайната. Пәти биргәннән сун кәйерле булсын әйтәде гуй инде. Чәй эчәләр.

– Без кыз алып килгәндә кәйен йортына килен мендәр алып киләде, мендәр аталады, алтау, сигез, унау. Мендәр матур матадан, дәwә йоны салган эченә. Без кодагыйлар кердек, утырдык, пәтийебезне бирдек, «хәйерле булсын» әйттек. Шуннан соң кызның җиңгәләре әйтәде: «Рөхсәт итсәңез безнең кодаларга алып килгән бер кечкентәй сәләмәбез бар иде, шуны тараткыбыз киләде», – диде.

Йегетнең анасы утырады, өлкүн абасы (*әбисе*) утырады, карт әбиләре утырады, өлкүн кайнатасы, агасы-җиңгәсе утырады. Ирләрдән бер биш-алты кеше, кимперләрдән бер биш-алты кеше утырады. Кызның җиңгәләре әлеге коданың астына кийезен түшиде, мендәрен салады коданың астына, утырады. Коданың каршында энесеме, җизнәсеме утырады. Хәле килгән кеше аларга берәр күләк, берәр сулык (*сөлге*) бирәде. Кызның анасы йаулыкка бәйләп кийет алып киләде. Шул кийетне өлкән кешеләргә өләшәде, калганын йегетнең анасына бирәде. «Ал диде, үзең тапшырырсың урынлы кешеләргә», – диде (*Сәетләр*).

– Пәти туйга кода киләйәктә, кунак киләйәктә әйләндереп мендәр салып чыгадылар түргә. Бирәйәген биреп, алайагын алганнан суң киленнең кайнатасы пәти бирәде, «хәйерле булсын» әйтәде. Җиңгәләр утырган кунакларның кулларын чайкатады утырган җирдән. Бер җиңгә сулык тотып йөриде. Тагам бирәделәр.

– Чәй бирәделәр, пирбуй сөтле чәй бирәделәр, шуннан суң ашлар бирәделәр, кайнари-пәрәмәчә, бурәкләр бирәделәр. Шулпага пешергән итле бурәк бирәделәр. Бишбармак бирәделәр (*Кундрау*).

**Так туй, такка салу** – егет белән кызның беренче кавышу кичләре хөрмәтенә үткәрелә торган мәҗлес.

– Йегет йагында так туй була. Кызны ничек кийәү йанына йаткызу, беренче кичләре, такка салу диләр. Аш-су, гармуннар, йыр, балкуwас була. Кыз йегетнең өенә килгәндә так туй дип әйтелә. Кыз килә, придан килә, он чәчеп кергезәләр (*Кызан*).

**Биткүрем туй** – яшь киленнең бөркәнчеген ачу хөрмәтенә уздырыла торган мәҗлес.

– Җегет җак калыкка биткүрем күрсәтәде, җакын туганнарнн чакырады, битләрен җаулык белән бәйләп, тез бөгеп сәләм бирәде килен, биткүрем туй булады (*Киләче*).

**Тугыз туй, кыз туйы** – кияү өеннән туй алды бүләкләре килгәннән соң, кыз өендә үткәрелә торган мәҗлес.

– Тугыз туйда йегет әнисеннән кызга кийетләр, кодагыйга да бүләкләр килә, кийет бирелә. Чатыр эчендәге бөтен халыкка кийет бирелеп чыга (*Картузан*).

– Тугыз туй дип чакыра булганнар, кыз туйы инде ул. Тугыз туйында йаучылар кийем китерә, кәнфитләр китерә, калымын китерә. Кызның сыргаларын, баҗакларын, беләзекләрен, муйынга тага торган энҗеләрен халыкка күрсәтеп йөриләр.

– Тугыз туй булганда кызга күп затлар киләде. Алтын йөзек, сыргасы, бажаклы киләдә. Өй эченә дип мата киләде (*Җәмәле*).

– Тугыз туй булады. Тугыз туйда тугыз киләде кызга. Башына, айагына барын да сорый бирәләр иде. Кыз анасы сорый. Бер айданмы, ике айданмы туй булады. Катланчык, пәрәмәчә, җимеш бурәк, куз бурәк пешерәделәр тугыз туйга.

– Тугыз туй йасый кыз йакта, кийәү сыйлый. Кийәү алып бара йегетләрне, йакын кардәшләрен (*Кәменни*).

**Җимес туй** – кыз өендә туй алды мәҗлесе.

– Җимес туйда туйның көнен кискәннәр (*Кундрау*).

**Өндәү алды** – кыз ягында туй мәҗлесе булыр алдыннан уздырыла торган киңәш мәҗлес.

– Кыз туйы булыр алдыннан кыз биттә өндәү алды була. Корән укый әwәл, туйның көнен кисәләр. Ул биттән куй, дөге килә өндәү алды көнендә, такта чәй, җимешләр килә. Куй, дөге китереп биргәнгә үзенең кийетен бирә кыз бит (*Җәмәле*).

**Кодалык** – кодалар-кодачалар мәҗлесе.

– Кыз битнең йагында кодалык дип әйтелә, кода-кодачаларны сыйлыйлар (*Сәетләр*).

**Кийәү сый** – кыз ягына кияү килгәч үткәрелә торган мәҗлес.

– Кыз йагында барган туй – кийәү сый дип әйтелә. Кийәү сый булганда калага барып бойортып ашлар китергәннәр. Кийәү сыйда

мәлбәккә (*тәлинкәгә*) дүрт кызыл алма салады, ак көлләр кадилар. «Ак йуллы булсын», – дип (*Киләче*).

– Кыз бит кийәү сыйлыйды. Кийәү киләде дуслары ман. Уң кийәү, сул кийәү (*уң, сул якта йөрүче кияү егетләре*) киләйде. Йакшы ашлар тартады кийәүләргә. Кийәү сыйга кәбестә пилмән, мәлешләр, лаксалба (*чәкчәк*), туртлар, пәрәмәчләр, паштикләр. Ул әзилдәге туй ашларын әйтерлек түгел инде Кийәү сыйга менә ундүрт нугай мәлеш алып бардык (*Кызан*).

– Туй булганда кыз биттә булады пирбуй, кийәү сый дип әйтеләде кыз биттәге туй. Кийәүне сыйлый инде кыз бит. Кийәү сыйга өлкән паднуста ун-унбиш кила канфит киләде, умбишләп бәлеш киләде, нугай мәлеш.

Ул мәлешләрне кисеп-кисеп, туйга килгән канфитларны салып, туйга килгән халыкларның барына да өләштереп чыгады. Илле кеше киләме туйга, йөз кеше киләме, туйга килгән кешеләрнең барына да биреп чыгады туй ийәсе. Өйләренә алып китәделәр киткәндә (*Каргалык*).

– Кийәү сыйга кийәү килә. Кийәү йанында уң кийәү, сул кийәү була, ике кийәү ике йагында була. Ике йаучы килә. Кечкентәй йаучы, өлкүн йаучы. Биш кеше була. Аларга биш табак аш тартыла. Менә бу кийәүгә, бу кийәүнең ике йагына дип күрсәтеп йөриләр ашны (*Киләче*).

**Кодагый сыйы** – туй вакытында кодагыйларның бер-берсен чакырышып сыйлаулары.

– Кийезне түшәде, мендәрне салды, безгә дастархан җәйде, кодагыйлар утырдык. Ике чара (*агач табак*) белән ак бүрәген салды безгә. Кикча (*кош теле формасында итеп, майда пешерелгән камыр ашы*) әкилде бер чара, куйдың түwешен салды.

«Саган (*сиңа*) бирәм, киленгә җуш булсын», – дип.

– Икенче көнне кодагый сыйы булады. Кода да барады, кодагай да барады. Без кодалар-кодачалар ашап-эчеп, сыйлыгын күреп кайтып китәмез. Җәшләр калады (*Кундрау*).

– Менә иртәгә көндез кодагый сыйы. Кодагыйлар алдына зур тәмле ашлар куйалар, сыйлыйлар кодагыйларны.

**Йәшләр сыйы** – кичке туй мәҗлес.

– Менә кичкегә йәш кодалар килә, бертуган тәтәләре, сеңелләре килә, йәшләр сыйы диләр.

## Сыйлык күрсәтү

**Сыйлык** – кунаклар өчен, туй мәҗлесе өчен әзерләнгән ашамлыклар.

**Сыйлык күрсәтү** – туй ашамлыкларын кунаклар алдына кую.

– «Менә безнең сыйлыгыбыз, күрегез», – дип кисеп-кисеп, турап-турап дастарханга сала иде. Бу – сыйлык күрсәтү иде.

«Хәйерле булсын ашыгыз», – ди, туйга килгән кунаклар әйтә (*Кундрау*).

**Зур сыйлык күрсәтү** – иң зур сый-хөрмәт билгесе итеп, кодалар алдына сарыкның башын пешереп кую. Аны – баш тарту дип тә атыйлар.

– Килгән кодаларга бездә зур сыйлык күрсәтәләр, баш тарталар. Баш тартырга куй йук этийемдә. «Мин бер лак (*кәҗә бәрәне*) булса да алыйым», – ди (лак – кәҗә баласы). Йегетем белән күрешәбез. Әтийең йаучыны кайтарып җибәргән, куй йук, лак булса да табыйм дип әйткән, ди. Әтийең йаулык бирсен инде, куй булыр, дигән йегетем (*Сәетләр*).

– Баш тартады, кодаларын, кодагыйларын чакырганда. Мәлбәккә салып, куйның башын кодага тартады. Ул – зур сыйлык күрсәтү булады кодага баш тарту. Рәхмәт әйтәде кода өй хуҗасына. Тагын кода балаларга да бирә баш итен.

«Менә минем кебек карт булыгыз,
Сез дә шулай сыйлык күрегез», – дип бирәде.

– Кода бастың йартысын җийды, йартысын кире кайтарып бирде. Бастың колагын балаларга бирәт: «Колак салып тыңлап торсон», –дип. Күзен хатынга бирәт: «Күз булырга», – дип. Таңлайын (*аңкавын*) киленгә бирәт: «Сак-сак итеп тор, сөйли тор», – дип чибәр бул, сылу бул», – дип. Бастың мыйын ачып, шорпага изеп, кашык белән өләштереп чыга.

– Куй башын баш кодага бирәт. Чикәсен, җагын (*яртысын*) кодагыйга бирәт. Табакка салып бирәт. Баш кода башның күзен алат, кыздың җиңгәсенә бирәт:

«Җакшы карашырсың», – дип
Телен – кодагыйга бирәт.
Таңлайды – кызга бирәт:
«Чибер бул, сылу бул», – дип.
Колагын – кечкенә балага бирәт (*Сәетләр*).

**Кодагай чабагачы** – кызны алып килгәннән соң егет өеннән кыз анасына җибәрелгән күчтәнәчләр.

– Кодагай чыбагачы дип бер кила канфит белән шикәр бирәде. Кызның анасына бирәделәр (*Кундрау*).

**Нәлбәк бирү** – кыз анасының кияү ягыннан килгән җиңгәләргә биргән күчтәнәче.

– Кызның анасы җиңгиләргә нәлбәк бирәде. Ул нәлбәкнең эченә шәкәр-чүрәк, канфит салады да аwызын бәйләп ун җиңгәсе булса ун нәлбәк бирәде, җегерме җиңгәсе булса җегерме нәлбәк бирәде (*Сәетләр*).

### Килен чәйе, килен җуар

**Килен чәйе** – килен төшкәннән соң кияү өендә уздырыла торган чәй мәҗлесе. Анда хатын-кызлар гына була.

– Килен чәйе дип чәй эчәләр. Азаматлар бармый, кыскайаклар гына бара. Ак тутам килен чәйенә чакырма килгән мине (*Киләче*).

– Килен чәйе эчерәделәр. Килен чәйенә бурәкпешерәделәр. Әченә кешмиш салып майга пешерәбез. Шул килен чәйенә бүрәк, канфитлар булады, эченә кешмиш салган бурәк. Өлкүн паднус белән килен чәйенең азыгын алып киләделәр.

Иртә менән торганнан сун ике җингә чакырады килен чәйгә. Килен инде кул алып чыгады, кийәү җегет белән икесе. Өлкүн кимперләр җыйылады килен чәйенә. Килен чәйгә әзерләнеп җатырлар. Җиңгәләр әйтәде:

«Хуш килдеңез, кодагайлар, без кызымызның килен чәйен эчерәйек», – диделәр.

Кызның ике җиңгәсе шул килен чәйен таратады. Азыгын салады өстәлгә (*Сәетләр*).

**Килен җуар** – килен төшкәннән соң уткәреләторган мәҗлес.

– Килен җуар булады бу килен чәйе. Шунда ана туй аткарып йөргән бөтен халыкны чакырадылар. Ире бармы, кыскайаклысы бармы, барын да килен җуарга чакырадылар. Ин алдан килен чәйе эчерәделәр, аннан сун килен җуар дип сыйланып утырадылар, шуннан таралып китәделәр (*Киләче*).

Кийәү үзе ике җиңгәме, өч җиңгәме, кызның җиңгәләрен әкилеп тапшырады.

– Туйның икенче көнендә айак өсте йөргәннәр керәде, кәрдәшләре керәде. Кызның ике җиңгәсе булады, җиңгәләр нәлбәккә

сигарит саладылар, ирләр аны чигәделәр (*тарталар*), нәлбәкке акча саладылар (*Киләче*).

**Кыз артыннан бару** – кызны төшергәннән соң кыз ягыннан кардәшләре, кода-кодагыйларның кийәү йортына мәҗлескә килүе.

– Куй суйалар. Зур кешегә баш куйарга кирәк. Куй суйганда менә кайнагамның кимпере, ул инде кайнатамның энесенең кимпере минем артымнан чакырайакта аш пешерешеп, күмәк итеп, минем йактан килгән кодагыйларны сыйлап йөрде. Ул инде затылган кызның артыннан бару дип әйтеләде (*Сәетләр*).

**Хәйерле булсынга керү** – кызның бирнәләрен, өй әйберләрен китергәч, кыз ягыннан килүчеләрнең егет өенә чәйгә кереп кунак булуларын шулай әйтәләр.

– Кыз йагыннан килгән кодалар придан әкилеп тезәләр дә йегет йагына «хәйерле булсын»га керәләр. Агалары-җиңгәләре керә, анда ике-өч кеше керә, күп кеше керми. Монда туй бара йата бирәде чатырда, кода белән кодагый «хәйерле булсын»га кертеп чәй бирәделәр, чәй тартадылар өйнең эчендә. Кыз төшкән өйгә керәделәр, кызның атасы кермиде, кызның атасы өйдә калады. Бу инде кызның төшкән җиренә «хәйерле булсын» әйтү булады.

«Кодалар хәйерле булсынга кермиме икән, wакыт аз калып барадыр», – дип, без кодагыйлар көтеп утырабыз.

Болар кузгала башлагач әйтәбез:

«Керсәңез кереңез, кичкә каласыз», – дип (*Сәетләр*).

## Сыйлык өләшү

**Сыйлык өләшү** – туйдан соң туй өчен әзерләнгән ашамлыкларны туганнарына һәм күршеләренә өләшеп ашату.

– Икенче көнне кодагый чәй кайнатып чәйгә чакыра иде кардәшләрен. «Менә мага тарткан аштан аwыз итегез», – ди. Ул сыйлыкны, килгән ашны туган-тохомына кисәк-кисәк бүлеп салып өләшәләр. Ул ашны бирмәсәң – үпкәли. Өлеш бирсәләр – санга санау була. Ул сыйлыкны, ашны биргәндә әйтәләр:

«Синең малайыңа да җуш булсын,
Синең кызыңа да җуш булсын», – дип.

Аны бирмәсәң, сыйлыкны бирмәсәң, үпкә була.
«Мине санга санамады», – дип (*Кундрау*).

## Табак йасау, табак кайтару

**Артык табак** – туй мәҗлесендә бер савытка артык өлеш салып куялар, аның иясе булмый.

– Туйда бер табак ашны артык бирәде. Килгән кода-кодагыйларга бер табак ашны артык бирәде. Артык табак дигән зат булады, артык табак дип аталады. Менә шул артык табакны кодагыйлар килен булып, айак өсте йөргән кешегә бирмәгә тийешле. Артык табак ийәсе шул кеше булмага тийешле. Туй ийәсе артык табакны тапшырады тийешле кешегә (*Сәетләр*).

**Табак йасау** – итне кунакның дәрәҗәсенә карап өлешләп бүлү.

– Табак йасый белгән кеше. Кандай кешегә кандай сөйекте бирмәгә тийеш, белә инде. Басы, йанбашы, урта йелек тийешле кешеләргә биреләде: картларга бас, җанбас салына, калакбас салына, муйын йарамый, сенерле сөйәк йарамый, сыйлы (*итле*) сөйәк салмага кирәк. Җелекле сөйәкте өлкән кодага, җамбасты кодагыйга салат.

**Куй башы** – кодага биреләде.

**Чагы** – кодагыйга биреләде.

**Күкерәк түше, куйнын түсе** – кийәүгә биреләде, кийәүнең алдына куйадылар.

**Куйымчак** (*кисеп алынган ит*) салды арттан гына – кызга биреләде.

**Җанбасы, себәсе** – кунакларга бирәде.

Ит салганда сыйлы сөйәкне салмага белгән кешеләргә тапшыра. «Син беләсең бит кемгә нинди сөйәк салмага, син сал», – ди. Калакбаш, түш, йанбаш, муйын, кабырга – шуның кайсын кемгә салмага белгән кешеләр бетеп китте (*Кундрау*).

– Куйның башын нәлбәккә салып бирә башкодага. Башның йарты йагын кисә башкода, уң колагын, күзен бер йакын кешесенә бирә.

«Безнең кызымыза күз-колак булырсың, берәр йаман ишетсәң безгә хәбәр итәрсең, карый торырсың», – ди.

Үзе кыйкасын (*баш ите*) турап табаклыкта (*мәҗлестә*) өләштерә: «Аwыз итеңез» – дип. Сыйлык шул инде.

Башын кодага бирәде, куйның йагын, йакын кисеп кодагыйга бирәде. Нәлбәккә салып кыскайаклыга ике йагын бирә, кодага башны бирә. Кода кисеп башны үзе өләшәде (*Сәетләр*).

**Табак кайтару** – егет ягыннан туй ашлары килгәннән соң, савыт-сабаларын һәм берникадәр туй күчтәнәчләрен егет өенә илтеп бирү.

– Табага аш түгәләр бездә (аш салуны әйтәбез инде). Анда була бер таба пахлаwа, бер таба нугай бәлеше, катмар пәрәмәчәсе, лаксалбасы, бадамгеле, шәкәр-чүрәге. Шуны икенче көнне табак кайтарып бара йакын кешесе.

– Тугызны салган, канфитлар салган зур биркәч була. Ул биркәчне дә икенче көнне кайтарып баралар. Ул гадәт әле дә бар бездә. Биркәч ул агач табак, миндә бар.

Анда шулай ук ашын-суын пешереп, туган-токомны чакырып ашын-суын биреп җибәрә, кийет биреп җибәрә (*Җәмәле*).

**Мөчәләү** – итнең сөйәкләрен дөрес итеп чабу.

– Туйда да, мәҗлестә дә ит куйды, дөрес мөчәләмәгә тийеш. Мөчәләү дигән сүз итнең сөйәкләрен дөрес салыгыз дигән сүз, кирәкле сөйәкләрне дөрес чабып тийешле кешесенә бирелсен, дип. Итне мөчәләгез, ди. Малны суйып мал мөчәли иде белгән кеше, калакбашын, җанбашын, түшен. Түшне кыз балага бирмәгә тийешле (*Сәетләр*).

**Көймә төп** – кыз килгәннән соң егет өеннән кыз анасына җибәрелгән ашамлыклар.

– Көймә төп дип кызның аналарына бер чара кыйгача (*кыеклап пешерелгән бавырсак*), бер чара бурәк, бер түш ит җибәрәделәр кийәү биттән (*Сәетләр*).

### Аш, аш тарту

**Аш тарту** – туй вакытында һәр ике якның бер-берсенә туй күчтәнәчләре бирешү.

– Йегет анасына кыздың анасы, кыздан анасына йегет анасы аш тарта. Патнус белән тастархан эстенә куйадлар, менә кодагыйга тарткан аш, дип. Җәмәгәтләр бар да карый, йакшы аш, дип.

– Әwәле аш тартады кызның анасына йегет анасы. Сигез патнус аш тартады: кузбурәк, катланчык, пахлаwа. Шундый ашлар тартады (*Каргалык*).

– Туй булады. Йегетнең анасына җиде табак аш, атасына җиде табак аш, ике йак кийәүгә җиде табак аш, кайнагасына, җаучыга җиде табак аш. Һәрберәүсенә җиде табак аш тарта торганыйы ул заманда. Туган-тохомына әйтәде:

«Менә син кузбурәк йасап апкил, лаксалба йасап апкил, пахлаwа йасап апкил, шикәр-чүрәк йасап апкил». Шуны самый комбатлы (*дәрәҗәле*) кешеләргә аш тартады. Икенче көнне шул ашларны өйләренә илтеп бирәде, ул ашларны бөтен халык күрәде (*Киләче*).

**Аш тарту** – ике йаклы:

– Йегет анасына кыздың анасы, кыздың анасына йегет анасы аш тарта. Кыз анасы кийәү анасына аш тарта. Алты патнусмы, сигез патнусмы. Аны ике йаучының алдына салалар. Аны күрә бөтен җәмәгәт. Бер патнуста катланчык: бер патнуста кузбурәк, бер патнуста лаксалба, бадамгел, шәкәр-чүрәк була. Кыз йагының ашларын йегет йагына бер туган-тохомы икенче көнне алып бара эскәтергә түнәп. Умбишләп нугай мәлеш, ун патнус йимеш: шәкәр-чүрәк, камфитлар әкитәде (*Кызан*).

**Кийәүгә аш тарту:**

– Кыз бит кийәү сыйлаганда кийәү сыйга аш тарта торган ыйы. Кыз бит тартады кийәүгә. Ике чит кийәүгә, ике дусына, кийәүнең агасына тартадылар аш. Җиде табак аш тартыла: кузбурәк, катланчык, пахлаwа, пылау, бадамгел (*Каңга*).

**Кийәү аш** – кияүне сыйлау өчен әзерләнгән ашлар.

– Кийәү ашка җиде табак аш тарта иде әwәле. Бер паднус лаксалба, пәрәмәчә бер паднус, бер паднус җимеш бурәк, катланчык, бер паднус. Үзенең йакын туганнарына куша пешермәгә кийәү ашка. Йакын туганнар һәрберсе бер паднус аш бирә. Хәзер инде күмәкләшәләр шулай (*Җәмәле*).

– Аш тарту диләр, кем ничек хәле бар. Барысының да тарткан ашын күрсәтәләр. Менә бу кийәүгә, менә бу кийәүнең ике йагына (*Кызан*).

– Кийәүгә аш тартады кыз җагы, биш табакмы, җиде табакмы. Шикәр-чүрәк, лаксалба, катланчык. Кийәүнең алдына аш саладылар. Ул паднустагы ашларны җиңгәләр өйенә илтеп бирәделәр икенче көнне, җакын-җуwыгын чакырып сыйлыйды, өләштерәде җакын-җуwыгына (*Сәетләр*).

**Кодаларга аш тарту:**

– Тәмле сыйлы аш тарткан кодаларга. Кәбестә калҗа, пылау, тарткан.

– Кодагыйлар үзләренә тарткан ашны өйләренә алып китеп туганнары белән ашыйлар иде. Мага биш табак аш тартсалар арба

белән җибәрәләр иде өйгә. «Менә кодагыйның ашы», – дип. Бичтә пешерәләр иде. Кодагыйга, кодачаларга бәлеш, бәрәмәч, катланчык.

Кодагыйларга җиде табак аш тарталар. Баш кодагый утыра. Кизәңкедән (*кухнядан*) ашларын китереп-китереп кодагый алдына куйалар. Катланчык-пәрәмәчәләр, кузбүрәк, лаксалба, пахлаwа. Менә бу кодагыйга тарткан аш диләр. Кодагый әйтә: «Менә минем шундый-шундый кардәшемә аш тартырсың. Мин инде чатырга чыгарып күрсәтәм ул ашларны. Кире кергезеп куйам. Икенче көнне ул ашларны кодагыйга илтеп куйалар, ул кодагый өстәл төзеп көтеп утыра. Ул тарткан ашларны туганнарына-токомнарына өләштерә (*Сәетләр*).

**Кийәүгә аш бойорту** – кияү өчен ашлар әзерләү.

– Кыз йагы аш бойортады кийәүгә: куй бойортады, пахлаwа бойортады, алма бойортады, кыз йагы бойортады (*Киләче*).

**Бәйрәм ашы** – туйга пешерелә торган камыр ашлары.

– Туйга бәйрәм ашлар пешә кыз биттә да, йегет биттә дә. Аш тарта бәйрәм ашлар пешереп.

**Утбасар аш** – егет ягыннан туй үткәрер өчен кыз ягына бирелә торган ашамлыклар.

– Утбасар аш, сөт хакы килә йегет йактан: ит, сөт, шикәр килә, дөге, бер патнус чәй – шикәр, җимеш килә. Ак затлар белән урап тарантаста китерәләр. Утбасарда тугыз-ун табаклап аш җыйыла (*Картузан*).

### Шикәр, башшикәр, җимеш

**Шикәр:**

**Башшикәр** – очлы формалы итеп койдырылган шикәр, аны кийәү ягы кыз өенә туй алдыннан китерә.

– Башшикәр койдордылар туйга дип, монди шикәр болай торады. Шикәргә гөлләр кадилар, ак гөлләр.

– Кисмәкле баллар, башшикәрләр бара торган булган. Башшикәрне катыра торган булганнар. Ул башшикәргә йаулыклар бәйләп, ак гөлләр кадап җибәрә торган булганнар:

«Ак йуллы булсын», – дип (*Киләче*).

**Шикәр сындыру** – кызны бирергә ризалык бирү. Бу көнне кияү ягыннан бирелгән шикәрне ватып, ваклап куялар.

– Килешәдләр, йома көнне шикәр сындыра торган булганнар.

– Туй йасилар. Шикәр әкиләде. Монда озын башлы башшикәр булган. Шуны әкитеп бара доган булган. Аны әйттергәндә бирәде, шикәр әкилмәгә әйтәде. Кийәүнең этисеңме хәрендәше, әнисенеңме хәрендәше шикәр әкитеп барады. Шикәрне сындырып, wатып куйалар.

«Әйдә, малайыбызга шикәр сындырыйык», – диләр. Анда шикәр сындырыга алтаумы, җидәүме кодагыйлар килә инде паднусны күтәреп (*Каргалык*).

**Кечкенә шикәре, кечкенә канфиты** – кызны ярәшү көненә килү ягыннан кыз өенә китерелә торган шикәр-канфитлар.

– Йаучы булып килгәндә камфит-шикәрне апкилә торганыйы. Туган-кардәшләрен чакыра торганнар ыйы, шикәр-камфитны бүлешә торганнар ыйы. Йыракта торган туганнарына җибәрә торган ыйы беткәнчә, аны инде кечкенә шикәре дип әйтә торганнарыйы.

– Кечкенә канфитын беренче килгәндә китерә. Туганнарыңа бирәсен, өләшәсең.

– Йегет биттән кызга йаучы килгәндә кечкенә шикәрен китерә шулай итеп башын бәйләр өчен инде. Анда канфит, шикәр инде (*Киләче*).

**Өлкән шикәре, зур шикәре, зур канфиты** – кияү өеннән кыз өенә туй көненә дип җибәрелә торган шикәр.

– Өлкән шикәрендә зур патнус белән тутырып әкилә йаучы, шикәр-җимешләр килә.

Зур шикәрендә инде паднус белән зур итеп шикәр-канфит китерә. Пирбуй баш бәйләwе кечкенә шикәре әйтелә. Зур шикәрендә кодагыйларга кийет бирәләр, мата бирәләр, акча чәчәләр.

– Зур канфитында йегерме кила канфит-шикәр китерәләр, бәлешләр китерәләр, җимешләр китерәләр.

– Өлкән шикәрендә зур паднуслар белән канфит-шикәр килә. Ул паднуста канфитлар гына түгел, шикалатлар, шикәр була, кийетләр була. Ике кеше ача ул паднусны, берсе кызның этисе йагыннан, берсе әнисе йагыннан. Аларга кийетләр була. Аны шул туйда күпме кеше бар, өләштереп бетерәләр (*Җәмәле*).

**Җимеш, зимес, зимеслек** – кияү ягыннан кыз өенә туй алдыннан китерергә тәм-томнар, чикләвекләр.

– Боронда җимеш әкиләде биттән, камфит, кузы затлары. Кыз йагындагы җиңгәләре ул җимешне барлыгына да бүлеп-бүлеп бирәде «туй ашы» дип, аwыз тигезе барына да.

– Тугыз туйда зур патнус белән камфит-шикәр китерә, аны әйтәләр җимеш дип. Ике җиңгә ике патнуска салып китерә, йегетнең күчтәнәче җимеш дип әйтелә, җиңгәләргә җимеш әйтелә.

– Шул йодалар ишек ачып килгәндә сөйләшәделәр:

«Кемнәргә җимеш аласың, кемнәрең бар, ничә җимеш аласың?» Ун кила, унике кила җимеш киләде йегет биттән. Анау җимешләрнең сумкаларын буш җибәрмиде, барысына да бүләкләр салады. Бер күләк, мата, сатин, ыштапел. Шулай итеп кийетләп җибәрәде кыз бит.

## Тел бүләге

**Тел бүләге, зимеслек** – кызның ризалыгын алганнан соң, ярәшкәннән соң егет ягыннан кыз өенә китерелә торган тәм-томнар.

– Тел бүләге итеп камфит китергәннәр. Ул камфитны туган-тохомны җыйып бүлешәсең, кардәшләребез ашый. Кызны йәрәшкәч йегет анасы тел бүләге китерә, камфит. Кыз анасы үзенең кардәшләрен җыйа. Ул камфитны бүлешәбез, туган-кардәш бүлешә, кыз анасы туган-тохомга бирә.

– Тел бүләге китергәндә бер кеше генә килгән. Аны ирнең әнисе йагыннан бер йакыны китергән.

– Йаучы килгәч туган-токымны җыйабыз, йаучы алып килгән канфитны өләштерәбез. Беренче килгәндә әз генә алып килә йаучы канфит-шикәрне. «Тел бүләге», – дип. Тел бүләге кийәү йагыннан килгәч йаучыга кийет салганнар. Тел бүләге килгәнче бер айак чәй дә эчмәгән йаучы (*Җәмәле*).

## Бәлеш

**Кузбәлеш** – эченә ваклап төелгән чикләвек салып пешерелгән бәлеш.

– Кузны шикәр белән бутыйлар; камырга җәйәләр, өстенә камыр йабалар, пичтә табада пешерәләр. Кузбәлеш була (*Кундрау*).

**Чийә бәлеше, корт бәлеше, җимеш бәлеше, арих бәлеше**:

– Туйларда чийәдән, корттан, җимештән бәлеш пешерәләр, киленем менә төне буйы бәлешләр пешерде (*Киләче*).

**Мәлеш, бәлеш, нугай мәлеш** – итле дөге бәлеше.

– Кызны төшереп алганда йегет биттән кыз биткә бирәләр нугай мәлеш, йаучы бирә бер мәлеш, туй ийәсе бирә бер мәлеш, өчәүме, бишәүме мәлеш килә.

«Кызларың бик күп, мәлеш күп ашарсың», – диләр. Ул мәлешләрне туйдан суң пичкә тыгып җылытады, туган-тохомны чәйгә чакырады (*Каргалык*).

– Зур табага камырыңды җәйәсең, өстенә дөге, суган, кичтән тозлап куйган куй итен саласың, өстен каплыйсың камыр белән, кара борыч та саласың, тозлык (*тозлы-борычлы, майлы шулпа*) саласың. Ике сагат торып пешмә тийеш нугай бәлеш.

Нугай бәлешен үле кораннарына, туйларга пешерәләр. Ит, дөге, суганын салалар. Ни зат булса, туй булса, кодагыйлар булса, шунда пешереп ашыйлар. Бәлеш капкачын кисеп-кисеп ашыйлар (*Кызан*).

– Нугай бәлешнең камырына дураж салмыйсың, камыры майлы була, майны күп саласың. Итне кискәләп тозлап куйа, суганын күп саласың, дөге саласың, эченә май сала бирәсең. Өстен капкачлап аwызын калдырасың. Бер айак тутырмыйча шүле дип тозлык саласың, борычын салып шүлене эченә саласың. Ул ике сагат тора пичтә. Шүлене артык күп койсаң дөгесе изелә, артык пешә. Бер айак шүле җитә (*Киләче*).

– Кийәү сыйга менә ундүрт нугай мәлеш килде. Ул мәлешне кисеп-кисеп чатырдагы мамайларга (*карчыкларга*) өләштердек.

– Киленнең әтисенә дип атап зур мәлеш пешерәләр. Туй узганнан соң корән укыталар, шул мәлешне җылытып ашыйлар (*Картузан*).

**Кыз бәлеше** – егет өеннән кыз ягына җибәрелгән бәлеш.

– Кыз бәлешен йегет биттән китерәләр, итле дөге бәлеше була.

«Кара, кара кызыңны, бәлеш ашарсың», – дигәннәр әзилдә.

– Мәлеш пешереп әкиләделәр. Симез итне wak-wak итеп турап дөге белән мәлеш итәде. Кызның артыннан килгәндә мәлеш пешереп әкиләде, итле мәлеш. Шул кызның артыннан килгән мәлешне өлеш итеп бүлеп-бүлеп бирәде.

«Кызыбызга килгән мәлеш, аwыз итең», – диде (*Каргалык*).

**Кыз бәлеше ашау** – туйдан соң кыз өендә үткәрелә торган мәҗлес.

– Туй беткәчтен туган-тохомны җыйасын, нугай бәлешләрне пичкә салып җылытасың, кайнар килеш тастарханга куйасын, чәй куйасың. Бу инде туйның икенче көнендә була, кор’ән укытып бәлеш ашата. Кыз бәлеше ашау дип әйтелә. Туган-тохомга бүлеп бирә бәлешләрне, берәрсе онытылып калса – ул инде үпкәли (*Каргалык*).

## Бурәк

**Бурәк** – бөккән.

**Кабак бурәк** – кабак бөккәне.

**Казан бурәк** – казанда майда пешерелгән бөккән.

**Ай бурәк** – итле бөккән.

**Куз бурәк** – чикләвекле бөккән.

**Касык бурәк** – пилмән.

**Җимеш бурәк** – камырның өстенә павидла йагып, бөреп-бөреп майга салып пешерәләр.

– Җимеш бурәк эченә кешмиш салалар, павидла салалар. Өлкөн-өлкөн итеп бурәк пешерәде (*Кундрау*).

**Кабак бурәк** – кабакны wак-wак итеп чабып, дөге салып мичтә пешерелә.

– Бурәк пешерә бездә туйга. Камырды түгәрәкләй, куйдың итен балта белән чаwып, шуны казанда кайнатып пешерә. Шара-шара бурәк пешерә (*Сәетләр*).

– Куз бурәк затлы камырдан була, аның эченә күз саласың, арих. Кузды шикәр белән төйөп сала. Камырны йазып, эченә куз салып бөгә.

**Йатарлык, җатырлык, җатырас** дип әйтәдләр бүрәкне.

– Җатырас дип кодагыйларга касык бурәк пешерәт.

– Кодагый сыйы бурәк – йатарлык дип сөйли иде, кич йатканда ашайлар. Чәй, май, эремчек, корт, касык бурәк (*пилмән*) була кодагыйлар килгәндә (*Лапас*).

## Бадамгел, шәкәр-чүрәк, лаксалба

**Бадамгел** – өйдә пешерелгән перәннекләр.

– Йомырка белән шикәрдән атлыйсың, табага салып пешерәсең.

– Бадамгелгә мин дүрт йомырка, ике пачка маргарин салдым, анан сун ике айак шикәр салдым, бер кыружка, кечкентәй кыружка белән бер кыружка сөт салдым. Болгыйсың бутап-бутап, шәкәре изелгәннән соң он саласың да басасың, фурмыларга салып пешерәсең. Бу бадамгел озакка тартыла, искерми. Кибетнеке тәтле түгел, тиз искерә. Ун көннән артык инде пешергәнемә. Алты таба, җиде таба пешерәм, әллә нихәдәргә җитә бирә. Кибет пичинйәсен йаратмыйм савсим. Тик акча аладылар (*Киләче*).

**Шәкәр-чүрәк** – перәннек.

– Комшикәр белән майга камыр басады, шәкәр-чүрәк күп итеп пешерәде.

Шәкәр-чүрәк – йарты кила майга йарты кила шикәр, өчәүме-дүртәүме йомырка салына, ул күпертелә. Он белән бутыйлар, аның агач формасы бар, шуның белән өстенә басалар. Ул шәкәр-чүрәк әйтелә. Әнә килен пешерә бирә шәкәр-чүрәк (*Җәмәле*).

**Катланчык** – катлы пирог.

– Катланчыкны туйларга пешерәде, каты итеп басады камырны, җәйәде зур кунага, өстенә май йагып, урап-урап, арасына җимеш салып пешерәде. Катланчык ул катланып–катланып тора инде. Урап-урап арасына курага, җимеш сала.

– Камырны җәйәсең нәзек кенә иттереп. Җәеп читкә куйып торасың. Әрбер җәймәгә сары майны сөртәсең. Тагын өченче җәймәне куйып анарга да сөртәсең май. Аны шулай урап-урап кисәсең дә, кискәч аны түгәрәкләп куйасың. Эченә күрәгә саласың. Камырына йоморка, шикәр сала.

Катланчык ул калмык чәйенә куйарга бик йакшы инде (*Кызан*).

– Камырны нәзек кенә итеп җәйә. Беренче җәймә өстенә сары май эретеп сала, аның өстенә икенче, өченче җәймәләрне сала, майлап-майлап сала. Каты итеп төрә, түгәрәкли. Аны кечкенә кисәкләргә кисеп җәйә, катлы-катлы булсын. Эченә куз салып пешерәләр. Менә шул катланчык. Сары май, куз күренеп тора. Кем куз сала, кем павидла (*Кәменни*).

**Лаксалба** – чәк-чәк кебек әзерләнә торган ашамлык.

– Йомыркага басасың камырны. Җәймә итеп кисәсең. Лакша (*токмач*) кебек итеп кисәсең. Майга салып калкытып аласың да бер затка салып торасың. Монда шәкәрең, балың кайнап тора, шул лакша эстенә аударасың. Әйләндереп-әйләндереп торасың. Эстенә разни каш-кашлар (*төрле төстәге вак конфетлар*) сибәләр. Лакшаны майдан кипкер белән сөзеп аласың.

Лаксалбаны ничек пешерә? Ун йомыркадан ун җәймә чыга. Шуны камырашка кискән кебек кисәсең, майга салып калкытып чыгарасың да шикәр белән белән кайнатып болгаталар, катыралар басып-басып, ландрин канфитләр йабыштырып чыгалар, күркәм була.

– Лаксалwаны җоморткага тугып-тугып аласың, он сибәсең, җәйәсең кунага. Wak-wak итеп кисеп майга гына пешерәм. Пешереп

куйганнан соң комшикәрне тагы да кайнатасың, комшикәргә болгап-болгап бал кайнатып койасың (*Каргалы*).

### Баwырсак

– Баwырсак камырына майын сала, онын сала, аз гына шикәрен сала. Табага майны койалар да шунарга салып пешереп алалар, астын-өстен кызартып алалар.

– Килгән кешегә майын күп итеп койып баwырсак пешерәде. Дыружын сала, сөтен сала, йомыркасын сала, майда пешерә. Табагы белән алып килә, тастарханга чәчеп сала баwырсакны. Тастархан әйләнәсенә көрпәсен сала, кийезен сала, мендәрен сала, камфит-пичинйе чәчә. Уртада утырган кеше чәчәде, чәйен бирәде. Корәндә нәлбәк салмадылар, тастарханга чәчәделәр. Җакын-җуwыгына бирәде баwырсакны.

– Безнең заманда туйның иң зур ашы баwырсак иде гуй (*Кундрау*).

– Баwырсакка шикәр салмыйлар. Йомырка салып, камыр итеп, йасап, аны җәйәләр. Җәйгәннән соң дүрткел-дүрткел итеп кисәләр, табада майда пешерәләр (*Сәетләр*).

**Такийа баwырсак** – никах өстәленә пешерелә торган бавырсак.

– Такийа баwырсак дип аны такыйа формалы итеп йасайлар. Ул башка кигән кәләпүш-такыйа кебек була. Камырны җәйәләр дә өчтән бер өлешен кисеп алалар. Камырны кушып бөргәч ул такыйа кебек булып кала, эшләпә кебек булып чыга. Майга кайнатып пешергәндә ул такыйа кебек була. Баwырсак йанына канфитын да алып баралар (*Кызан*).

– Туйларга баwырсакны дүрткел-дүрткел итеп майда куырып пешерәләр (*Янга-Әскәр*).

### Пахлаwа, кайнари

**Пахлаwа** – бал һәм чикләвекләр белән пешерелә торган күп катлы пирог.

– Пахлаwага бал, май, куз кирәк, кыркбер белен йасыйбыз пахлаwага, кыркбер кат була, йегерме биштән дә йасыйбыз. Пешкән камырга балды кайнатып койабыз, калган балды өстенә койабыз, калган балды өстенә койабыз (*Канга*).

– Пахлаwаны мин үзем пешерәм, куншылар, туган-тохомнар да бойорталар үземә. Чәй эчә торган айаклар белән бер айак сөт, 250 г май, бераз гына чәйни суды камырына, камырны басам, кагаз кебек

җәйәсең уклау белән. Ул бер табада утыз биш тә, кырык та була, нәзек итеп җәйелә. Ул катлау-катлау була, һәрбер катлаwына май койола. Шикәр белән кузны болгап, wак кына итеп төйеп, майны койоп саласың. Ул пахлаwа пешеп чыкканда аны кискәлисен кыйыкча итеп. Һәр кискән арасына кайнатып бал койасың. Бер кила бал койола. Җәйгән камырына ике йөз илле гырам май салына. Кисәсең табада. Ул шунда тора. Аны тагын да wак кына итеп кисеп өстәлгә нәлбәккә салалар. Туйларга, кодагыйлар алганда, үле коранына, җидесе, кырыгына, йылына пешерәбез.

– Кыз бит йегет биткә пахлаwа алып бара, пахлаwаңды тотып барасың кийәү биткә барганда. Атланмай, шәкәр, йомыркага камыр баса, кәгазь калынлыгында җәйә, кырык кат йасый, кайнатып бал сибә, бер таба пахлаwа була (*Кызан*).

**Турт: –** Туртны бахча итеп, куй итеп койады, өләштерәде кийәү туртны (*Киләче*).

**Кайнари, пәрәмәчә** – пәрәмәч.

– Кайнари булады, пәрәмәчә. Килен кергәч ике җиңгә кайнари пешереп чәй әзерлиләр (*Кундрау*).

### Нан, тугач, калач

**Нан** – табада юка итеп пешерелгән төче күмәч.

– Нан пешерә булганнар һәркайсына берне. Эченә пылауны салып һәркайсына чорнап-чорнап биреп йибәрә булганнар туйда.

– Нан дигәннәр. Йөзләгән нан бара торган булган йегет биттән, чүрәк инде булган. Шул нанды, чүрәкне йегет бит жибәрә торган булган.

Шул нанды инде туйда бөтен халыкка өләшә торган булганнар. Менә минем мийәм wакытында нан, капыста пилмән диде. Капыста пилмәнне туйда ашыйлар да бер нәлбәк пылауны теге нанга салып өйгә алып кайта торган булганнар (*Җәмәле*).

**Табанан** – табада пешерелгән төче күмәч.

– Төтеннек сала малга, наwыз сала, көл түгә, күмер төшә. Шул төтеннек эченә ике таба уртасына нан сала. Табанан дибез. Ачыган сөткә или бирәсең камырны (*Кундрау*).

**Казан күмпәч** – казанда майда пешерелгән күмәчләр.

– Сыйырны саwады, чәйни суды салады, май салады, камыр баса. Шуны уклау белән җәйә дә казанда майда пешерә, казан күмпәч була (*Кундрау*).

**Тугач** – клиндер.

– Әзилдә калада да мал тотканнар. Ала таңнан иртүк торып. печәнне илтеп сатып, тугач, булки каладан экилгән. «Базарлык экилгән» диделәр. Шул тугач белән чәй эчмәгә кунчыларын чакырадылар.

Кечкентәй балалары булганда үзләре дә тугач пешерәделәр (*Сәетләр*).

**Тогырчык** – уртасы тишек кабартма.

– Тогырчык-түгәрәк итеп пешергән камыр. Ун тогырчык, умбиш тогырчык кызның артыннан экиләде. Түгәрәкләйде, уртасын тишәде, майга дулкынландырып пешерәде тогырчыкны. Кызны озата килгәндә тумалары пешерәде, бер куймалак (*кечкенә агач чиләк*) тутырып экиләделәр (*Сәетләр*).

**Кыйгача** – бавырсакның бер төре, кыеклап кисеп пешерелә.

– Бер кыз затып киләбез гуй. Без кыз затып килгәндә җегет бит бер чара кыйгача әзерли иде, бер чара бурәк әзерли иде, шуның өстенә өлкүн түш салады, кара малныкын булса да, куйныкын булса да, пешкән ит инде. Шуны алып киләделәр, кодалар бер чара бүрәген экиләде, өстендә түше бар, такта экиләде, пычак экиләде. Без кыз затып килгән кодачалар шул бер чара кыйгачны, бер чара тастарханга салып экитәдек.

Кыйгача баwырсактан эре булады, бер чара кыйгача пешерәде, уртасы тишеләде. Бер чара кыйгача, бер чара бурәк ир бит бирәде кыз алып килгәндә. Әрү оннан кешмиш салып пешерәде бурәкне (*Кундрау*).

**Кал′акай** – күмәч.

– Курада учак сылайды, әүләдә. Кизәк утта пешкән кал′акай диде. Йазның көне ике таба арасына салып учакта пешерәде, кызу көлдә. Ике табаның арасында ул иң тәмлесе булады. Агач уты кызу булады, көйдерәде.

Сөтнең сары суын салып ачытады кал′акайны. Ачыган кал′акай, сөткә, сары суга иләгән кал′акай тәмле булады, кетердәwек булады (*Лапас*).

**Калач** – күмәч.

– Казан өйдә учак сылап калач пешерәбез, йазның көне өлкән өйебездә йоклайбыз. Калач пешермәгә җайланган була казан өйнең учагы (*Урта Аwыл*).

**Күмпәч, көлчә:**

– Күмпәч дип әйтәде, көлчә пешерәде нугай мичтә (*Кундрау*).

**Үтпүк, үтпәк** – икмәк.

– Үтпәкне үзебез пешердек. Әүләдә учак сылыйды, шунда пешерәде үтпәкне. Кизәк йагады, кизәк утында үтпәк тәмле пешәде.

**Туй эпәйе, туй үтпәге** – туйга пешерелгән икмәк.

– Нугай мич булады, камыр басабыз, агач табакка салабыз эпәй итеп, кабара. Пичкә куйып пешерәбез. Пичнең калагын йабады йугарыдан. Туй үтпәге зур-зур, түгәрәк кенә булады, эпәйләр пешереп чыкканнан сун тастымаллар белән томалап куйады. Капкачын ачып-ачып карыйсын пичнен, үтпәк пешеп чыгады (*Кундрау*).

**Питер** – төче күмәч.

– Питерне дуражсыз пешерәсен. Питер дип әйтелә. Сөткәме басасын, бер кисәк май саласын да. Илисен, илисен дә уклау белән җәйәсен дә пешерәсен (*Киләче*).

– Ике таба була. Берсенә камыр саласың сөткә баскан камырны, икенче табаны өстенә йабасың. Кизәкне тартып пичкә куйасың, кып-кызыл булып пешеп чыга. Менә сага питер була (*Кундрау*).

– Питер ачытмайчы пешереләде. Таба белән нугай мичкә куйады. Өстенә таба каплайды. Питерне учакка да күмәде таба белән (*Кундрау*).

– Арыш камырын, йә бодай камырын сөткә баса сирлы кеше, йә сары суга баса. Май да сала, питер итеп пешерә. Ашап та туйып булмый.

– Питерне он, сөт, май, тоз сала, камыр баса. Кайсы кеше әчегән катыкка баса. Алай тәмнерәк була. Түгәрәк-түгәрәк итеп пешерә (*Кызан*).

## Салма, кисмә

**Салма** – токмач камырын эре итеп кисеп шулпада пешерелгән ашамлык.

– Кул ылакша камырын кыйыклап кисеп шулпада пешерәләр дә итнең шулпасын койоп бирәләр (*Кәменни*).

**Камыр аш** – токмач.

– Йомырка сытасың, камыр йазасың, кулдан кисәсең дә саласың. Итеңе саласың куй суйсаң күп итеп. Кызыл балыгыңды саласың балыгың булса (*Кундрау*).

**Кул ылакса** – токмач.

– Кул ылакса пешерә бишбармакка, сөзге белән сөзә шорпадан. Ит белән табакка куйып бирәт (*Сәетләр*).

**Ашымал:**

– Айран белән пешерган дөге, азаматлар ашый (*Лапас*).

**Кисмә** – ит һәм эре итеп туралган токмач камыры белән пешерелгән ашамлык.

– Куйны суйганнан соң башын туныйлар, җуwасың да пешерәсең. Итен турап аласың wак кына итеп. Камыр басасың юка гына итеп, йомыркага гына. Токмач камыры кебек җәйәсең дә кыйыклап кисеп, баш итен пешергән шулпада пешереп аласың, суганнарын саласың, суганны каты пешермә, үтереп кенә сал, алай тәмле була. Баш итен, суганнарын салып, токмачын салып болгатасың. Кисмә дип әйтелә, куй суйгач пешерәбез (*Кәменни*).

## Турамчы, бишбармак

**Турамчы, турамшы** – туралган ит белән токмач.

– Турамчы булады. Эре мал суйылады кыш көне. Зур агач табакка салады, турамчыны турайды, өстенә тозлыкны койайды. Агач мәлбәкләргә салып бирәйде. Ит белән картубын сала.

Турамша пешерәм дип итне зур-зур кисәкләр белән пешереп чыгарады, аны суытып, wак-wак итеп турыйды. Камырдан өңкәл (*җәймә*) җәйеп аны шулпага салып пешереп алады. Өңкәлне wаг итеп турыйлар. Аннаң сон шулпага итне дә, өңкәлне дә салады. Итнең шулпасыннан майны җыйып алып суганны пешерәләр, суганны wак-wак итеп турыйлар. Аны пешергәндә белергә кирәк, ул бөтенләй пешеп китмәсен, тереләй булсын суган. Шул турамшаның эченә салып болгыйлар.

Турамшага итне озак кына итеп пешерәсең, баш, сыйрак та салып пешерәсең. Аларны айырып пешереп, йартысына ит кушасың, конаҗын (*тана сыер*) ите пешерәсең. Менә без ике йәшәрлек конаҗынны суйдык, шуның йартысын үзебезгә алып калдык, йартысын саттык. Итне зур кисәкләргә турап пешерәсең, аннары wак кисәкләргә турайсаң. Йомырка салып камыр басасың. Камырны нәзек итеп йазып кисәкләп кисәсең. Итне турагач суган пешермәгә кирәк. Суган саласың. Камырны пешереп теге тураган итне салып, тозлык-шулпа салып, суган салып бирәсен нәлбәкләргә. Пешкән итнең шулпасына салып пешерәбез камырашны.

– Турамша йылкы итеннән. Телемләп турап шулпа белән бирәләр (*Кундрау*).

**Ит гептәсе** – фрикадельки.

– Ит гептәсе дип әйтәләр. Йомарлыйсың итне машинадан чыгарып. Шулпага салып гептә пешереп бирәсең картларга, йомышак була (*Сәетләр*).

**Йомарлам** – фрикадельки.

– Йомарлам итеп пешереп салам туй ашларда.

– Кайсы кеше итне машинадан тарттырып йомарлам пешерә картлар туйына (*Янга Әскәр*).

**Бишбармак** – ит белән токмач.

– Бишбармакка җокалак камыр, ит сала, тозлык койа. Тустакай белән шорпа бирәләр бишбармак биргәч. Бишбармакка алпама (*юка камыр*) өңкәле җокалак камыр сала. Бишбармакны кыдаларга пешерәтләр. Бишбармакка кайсы кеше өңкәл сала, кайсы дөге сала. Ашап китәләр. Ит күп хәзер.

– Бишбармакка итне пешерәделәр, алпамасын җәйеп алады, кисеп пешереп алады. Шуны чилтәккә салып сөзеп, салкын суга салып алады. Шулпаның майын җыйып алып чи суган турайды, кискән алпаманың өстенә тозлыгын койады. Суганны аз гына пешерәде, чи калсын, исе чыгып, тәме чыгып торсын диде. Эре итеп кисәде алпаманы, сөзгедән салып алады кигача итеп (*Сәетләр*).

**Куwырдак** – кыздырган ит.

**Ак** – катык.

– Ит шорпасын ак катып эчкәннәр (*Кундрау*).

### Туй эчемлекләре

**Туй эчемлекләре:** кымыз, балкуwас, ширбәт, чәй.

**Кымыз:**

– Кымыз эчкәннәр аталарымыз туйларда.

– Кымыз булган. Бийә сауган. Аны ачыткан. Шуның белән туй йасаган. Каси белән биргән болгап-болгап. Кымыз белән туй йасап кыз озаткан.

– Кымыз йасайды. Бийәне саwайды, шуны ачытады. Минем атам кымызсыз торган кеше түгел. Ике-өч бийә саwып кымыз йасап утырды гуй. Өйләренә ике бийә китереп саwып, җулдашы-кимпере

шуны кымыз итеп йасап торды. Туксанга тиңен торды. Җир бай, ашайды бийәләр. Аны белмәгә кирәк. Колынын бәйләмәгә кирәк. Колынсыз бийә булмага тийеш (*Кундрау*).

**Шыбат** – дөя сөтеннән ясалган эчемлек.

– Куйы каймактай булып торды. Шыбат диде, дәwәне саwайды да агач бучкыга салады, аны болгап-болгап ачытады (*Кундрау*).

**Ширбәт** – баллы су. Кодагыйлар килгәндә ширбәттән эчерәләр, җимеш тоталар (*Кәменни*).

**Балкуwас** – өй сырасы.

– Туйларда балкуwас булган, шәкәр белән кайната булганнар, колмак сала булганнар. Бер җома тора кадушкада. Туй ийәсе үзе кайната балкуwасын. Халык туйга җийылганда, балкуwас көйен уйнап балкуwас эчәләр (*Кызан*).

**Чәй: тук чәй, калмык чәй, кара чәй, татар чәй.**

– Куйның койрык майын эретеп калмык чәйгә саладлар, тоз саладлар.

– Такта чәй, кара чәй дип әйтәбез, кара чәй парлыйбыз дип әйтәбез.

– Айакка салып кара чәй биргән, татар чәй.

– Кызга кийәү биттән калмыкчәй, башшикәр бирделәр.

– Безнең аwыл халкы иртә белән калмык чәйен эчә. Су кайнатасың, чәйен саласың wатып, сөт саласың, тоз саласың, май саласың, куйның койрык майын саласың, кара казанда (*зур казанда*) пешерәләр чәйне, сөтен бергә салып (*Җәмәле*).

## Туй табыны

– Электә өстәл салмыйлар иде, чатырның идәненә кийезме бар җәйә, тастархан җәйә, шундый наннар пешереп салып чыгалар, бәлешләр алмадан, айвадан. Әркайсының алдына бер нан салып чыга булганнар, чүрәк инде. Менә шулай пылау чыгарганнар, кара чәй, калмык чәй салып чыкканнар (*Киләче*).

– Зур гына тахтамбит инде, балас җәйеләде, түфәкләр түши, тастархан җәйеләде. Агач мәлбәк, агач айак, агач табак булады. Җалпак кына өйемөз зур иде, түгәрәкләнеп утыралар. Пылау куйалар, мәлбәк белән пылауны кулың белән ашыйсың, баwырсак салады, чәй, чәйдән сун ит. Балкуwас эчәсең.

– Эргә буйлап түшәйбез мендәрне. Балаз эстенә утырмый. Йастык – зур мендәр. Ырыслы кунакка түфәк саладылар, түфәк салсаң сыйлык булады.

– Кийез өстенә тезелеп утырады. Тастарханны әкилеп җәйәде. Баwырсак салады, бурәк салады, шай, шайдан сун ит бирәде (*Кундрау*).

– Итне зур табаклар белән әкилеп салады, итне туриды. Шуны ашайды бишбармак белән.

## Туй саркыты

**Туй саркыты, картларның саркыты** – туйда картлардан соң мәҗлестә калган ашамлыклар.

– Йакын кешегә туйга килә. «Саркыт бир», – ди. «Картларның саркыты», – ди, «картларның җәшен бирсен, сага да җуш булсын», – дип, туйдан калган саркытны табынга куйаты, картларның саркыты дип картлардан калганны бирә (*Кундрау*).

– Туйга йегерме киладан да, утыз киладан да пылау пешерәде. Саркыт дип биреп тә җибәрәде туй пылаwын. Картлар бар, балачага бар. Күп итеп кечкентәй наннар пешереп куйадылар, шунда пылау салып, өстенә бәлешләр салып, киткәндә балаларга, мамайларга дип биреп җибәрәде. Кем килми калган, шуларга дип саркыт биреп җибәрәләр (*Киләче*).

## Туйны тәмамлау

– Туй беткәч теләк бирәләр, аш кайтаралар, дога кылалар.

Туй ийәсенең салган ашын тамамладык, инде җәмәгәт ихтыйар, кайтырга өрөхсәт. Берәү әйтер, йук без туй ийәсенең салган ашын ашап таркалып китмибез, туйды без дәwам итәргә тийешбез. Туйды йасаган агайның күңелен күтәрмәгә тийешбез, ди. Җаулык җәйәде, берәү илле сум, берәү йөз сум салады. Җыйын агасы санайды (*Җәмәле*).

## Туйда хезмәт күрсәтүчеләр

**Айакчы** – туйда өстәл әзерләү һәм туй кунакларына хезмәт күрсәтү өчен чакырылган хатын-кыз.

– Ничә кешегә әйтәде айаг өсте йөрмәгә, айакчыларга. айаг өстән йөргән җиңгәләр була. Айакчылар койа эчемлекне (*Картузан*).

**Аш-ашчы, аш-бапчы, пылаучы** – аш пешерүче, туй өстәле өчен җаваплы кеше.

– Аш-ашчы аш әзерли, аш-суны барлый, сыйлык төзи, аш тарата. Аш-ашчы ашны пешерәде, пылауны пешерәде, чәйне кайнатып торады. Бер пылаучы айаг өстен җөриде.

**Күмәкче, күмәк итүче** – булышучы.

– Пылауга мәркү йуналар йегетләр, күмәк итәләр.

– Туйдан бер көн алда кара малны суйып итен пешерәләр кара казанда.

«Ит турамага кил» диде, күмәкчеләрне чакыра, үзләренең йакыннарын ит турамага чакыра. Аны wаклап турап йазның көне ачымасын дип киптерәләр, икенче көнне шулпага шуны җибәрәләр, шуны табак белән бирәләр кодаларга (*Кундрау*).

**Кул биргән** – нәрсә дә булса эшләгән, булышкан, пешергән һ.б.

– Килен чәйенә туй аткызып йөргән бөтен халыкны чакырадылар, күмәкчеләрне, кул биргәннәрне, кулы белән эшләгәннәрне барын да килен чәйгә чакырадылар (*Кызан*).

## Тел йәшерү

– Кайнатасыннан, кайнанасыннан тел йәшерә, гомер буйына йәшерә. Кайнатадан ойаласың, алдыннан үтмисең (*Янга Әскәр*).

– Битне ачмаган килennәр, сүләмәгән кайната, кайнана алдында. Битен ачса да сүләмәгән, тел йәшергән.

Аwылда бит йабып йөрү иде. Менә минем үземнең җиңгәм этийемнән бит йапты. Минем атам мулла кеше иде, аракы эчми, тәмәке чикми (*тартмый*) торган. Гумер буйына битен йапты җиңгәм, ачкан йук.

Кәйен ата белән сөйләшми. Кәйен сеңлесе, кәйен агасы аркылы әйттерә. Әтийем әйтә: «Килен, болай итсәң әрү булыр ыйы», – ди. Ә килен өндәми генә эшли бирә, битен ачмый, сөйләшми. Минем этийемнән менә шулай җиңгәм битен йапты. Зур әнийем ачтырмады (*Сәетләр*).

– Менә минем нәнәм (*әнием*) тел йәшергән кайнатадан. Мин туwарга (*бала тудырырга*) барам арба өстендә ди, сүләргә йарами ди. Тырантас белән калага алып китәләр бәбәйләргә ди. Атасы белән генә сүли булган, үзенең атасы белән генә сүләшкән. Йалан айак йөргән йук, йалан өс йөргән йук.

– Тел йәшерә булган килен. Кайната үзе ыриза булып әйтсә, килен, сүли бир», – дип, килен сүләшкән (*Картузан*).

## Суга бару

– Бөтен җакын туганнарын күреп бетергәннән сун суга бармага була иде. Пирбуй барганда җиңгәсе әкилеп күрсәтәде, суагач (*көянтә*) белән әкиләде суны. Суы түгелмәсә, килен абруйлы, салмаклы була. Түгелсә инде, бераз кызу холыклы була, дип әйтәделәр. Йалгыз йөргезмәгәннәр киленне, кайынсеңнеләре белән йөргән (*Кундрау*).

**Килен җөргезү:** – Килен җөргөзү диләр, килен җөргөзә алып килгән җиңгәсе. Суга алып бара. Килен агар табакмы, нәлбәкме бирә. «Җөргөзгән айагы», – дип (*Каргалык*).

## Түркеннәп чакыру, түркеннәп бару

**Түркеннәп чакыру** – кыз белән кияүне кызның әти-әнисе йортына чакырып алу. **Түркен йагы** – кызның туган ягы. Бу сүз башкорт, ногай, якут, чуваш, монгол телләрендә дә төрле фонетик вариантларда шул ук мәгънәдә кулланыла (*Каргалы*).

**Түркеннәп бару** – туйдан соң киленнең үз әти-әнисе йортына кунакка баруы.

– Кыз белән кийәүне чакырадлар, бер җома узамы, ике-өч көннәнме ике җиңгәсе бара, кызды чакыра килдем ди. Кыз бән кийәү кайын сеңелләрен алады, киләт өйгә, ике арада килеп-китеп йөрмәгә була түркеннәп барганнан соң. Ике җиңгә чакырат, кыз белән йегет барат. Чакырмый килми иде кыз өйенә, чакырма тийеш ана йагы, чакырганнан соң киләт, кызды да, йегетте дә кийетли, барын да кийетли.

– Ничә кардәше бар, атасының биш кардәшеме бар, шулар бар да түркеннәп чакырады, барына да бурәк песереп барады, бурәк, кийет белән барады кыз. Кажни кардәшенә түркеннәп барып, бер ай торамы атасының өйендә, йарты аймы, атасы арбаның артында сыйыр бирәме, конаҗын бирәме, артына байлап җибәргән. Кызды кайтарып җибәргәндә өйенә, түркеннәре бар да куй атаганнар. Мал бирәде бездә ул заманда, инче (*кияүгә киткән кызга атасы йортыннан бирелгән җанлы мал*) дип биргән. Кыз түркеннәп килгәндә шундый булган (*Сәетләр*).

– Кардәшләренә барына барган, түркеннәренә ни зат әкилгән кыдырып, иркеннәп кайтады. Бер йылдан сун түркеннәп килгән.

– Кодагай үзе әйтәде бераз wакыт үткәннән соң. «Киленемне түркеннәп әкиткем киләде» дип кабар бирәде кызның анасына. Әзер

булса кызның анасы каршы алып кабул итәде. Әкилмәгә тийешләр куй суйып, бер чара бурәк пешереп. Инде кызның анасы әкилгән куйның итен чи килеш өләштерәде җакын кешеләренә, чи килеш булмаса «кызымны түркеннәп әкилделәр, кунакка килеңез» дип чакырады. Ә бер чара бурәкне өләштерәде күршеләренә, йакыннарына.

Түркеннәп килгәндә кызның атасы мал теркәп җибәрмәгә тийеш, куймы, кара мал сыйырмы, конаҗынмы. Әwәл заманда бездә шулай иде. Түркеннәп барганда биргән заты диделәр. Хәле тарткан кеше әwәлге гадәт буенча мал бирмәгә тийеш кызды түркеннәп әкилгәндә (*Картузан*).

Ә йегет анасы кызды түркеннәтеп әкилгәндә әрү ит бирәде, йә мал бирәде. Кыз калады кийәү менән, ике-өч көн торады үзенең түркен йортында. Ә кайнаналары кайтып китмәгә тийеш үзенең өйенә. Хәзер инде түркеннәтеп әкилми, ул гадәт калды (*Сәетләр*).

**Түркен чәйе** – кияүгә киткән кыз үзенең туып-үскән өенә килгәч оештырылган чәй мәҗлесе.

– Түркен чәйе дип, кийәү битен күрәбез дип әwәле кыз белән кийәүне чакырып алады ана йагы. Монда кунаклар булады. Кийәүнең йакын туганнары киләде, кыз белән кийәү киләде, кийет бирәде ана йагы. Түркен чәйенә пешерәде лаксалба, бәлеш, пәрәмәчә, турамша.

– Түркенгә килгән кызына кыз йагы мал бирә, сыйыр малы бирә, кара мал дип, туwайагын бирә. Кызның ата-аналарының малы булса, ул гадәт әле дә бар (*Кундрау*).

## ХУҖАЛЫК, КӨНКҮРЕШ ЭШЛӘРЕ

### Килен хезмәте

– Килен өй эчендә саwыт-сабаларны җуwып җөрәде, җыйыштырады. Әүләгә (*ишек алдына*) чыкса җакын туганнарына сәләм бирәде.

– Киленгә кайнана тапшырган:

«Менә балам, элеке оло кешеләргә салырсың ашны, анда сун үзебезгә салырсың», – дип (*Картузан*).

– Кайнанасы булса ул инде эш куша. Өлкән киленгә, урта киленгә, кечкәй киленгә. «Син шаны эшлә, син шаны эшлә». Әркем үз эшен эшләп торады. Кайнанасыннан өрөхсәтсез эшләми.

– Килен төскәндә абасы (*анасы*):

«Кара казаным, учагым, бар да киленемә» – дигән, кортка булып утыра биргән үзе. Улы туса – улын караган, кыз туса – кызын караган. Өй эшен барын да килен караган.

– Киленнәр кийез басты, кийездең читен койдолар, кулдан ишеп кыйу койдолар, айланасын тектеләр.

– Зыпын тегәмез, кулынан теккән узыр салып, озон зыпын кигән кинчәкләр.

– Иң беренче килен суга барады. Аны затып килгән җиңгәләре алып барады суга. Иң беренче эше киленнең су әкилү. Чиләк белән торады суwы, шуннан алып аш кешерәде, чәй кайнатады. Анан сун тастархан җәйү, ыризык пешерү, зат итү (*Кундрау*).

– Тахтамбиттә он гунага салып килен токмач кискән, аш та пешергән. Ирләр, кайнаталар кырда эшләгән, хатын-кызны кырга әкитмәгәннәр. Әкитеп күрсәтә булганнар арба өстенә утыртып кына, арбадан төшәргә йарамаган. Кайнанасы булса да, килен булса ла арбадан төшәргә, игенлек өстенә басарга йарамаган, «хатын-кыз игенгә басса йарами, иген корый», – дигәннәр. Ирләр генә эшли, күрсәтергә генә әкиткәннәр күргесе келәсә, игеннәр, карбыз, каwыннар пешкәндә генә. Бирәзә-бөркәнчек йабынып кына барганнар, арбадан төшәргә йарамаган. Хатын-кыз ирләр арасында эшләмәгән (*Киләче*).

– Мийәм сөйли иде. Биш кыз үстек. Чәршәмбе көн кер йуwа идек, кече йома көнне өй җыйыштыра идек, ди. Йома көнне атайлар да, кахамнар (*абыйлар*) да йома нийазына китәләр иде, ди. Шуларның йомадан кайтканын көтеп, тәмле-тәмле ашлар пешереп ашамыймы көтеп утыра идек, ди. Шул йомадан кайткан атай, агай, энеләр белән ашаганнар. Шундый тәртип булган (*Җәмәле*).

Хатын-кызларның айагы у (*авыр*), җирне корыта, игенне корыта дип җиргә кертмәгәннәр.

Башка көннәрне чигу чигә идек, канwа белән зат төшерә идек, лакмы белән утыра идек, ди. Энҗе турлый (*энҗе белән чигә*) торган идек күлмәкләргә, йаулыкларга ди, йома суны көнне ди (*Җәмәле*).

Мин үзем турлык тугыдым. Биш-алты митр турлык була. Чакыннан турлык тугыдым. Дүрт җирдән бәйләнә, бик тиз эшләнә ул. Турлыкны идәнгә җәйеп, анын өстенә тастархан җәйеп ашап утырдык (*Каргалык*).

– Пич җагып, пич тутырып калач салган.

Казаннан чарага кутарып (*бушатып*) алган килен ашны, камыш урып китергәннәр әтиләр, казанда аш пешерәбез.

– Өч-дүрт килен бер өйдә торган, эшне бүлеп эшләгәннәр, син идән йу, син калач сал. Аwызберлек булган, татуwым дигән киленнәр бер-беренә.

– Килен чәй таратады тастархан җәйеп, сулыкты тотып, ике җиңгә су койады кулларына, чәй бирәде, кимперләр утырабыз тезелеп. Киленнең кийетен бирәде, берәр кисәк маты. Килен кул алышады, килен кул алып чыксын, сулыклар өләштерәт килен (*Сәетләр*).

## Каралды-кура, мал-туарлар

– Утын сарай, таwыг өйе, сыйыр курасы, бәрән курасы, куй курасы булады. Килен сыйыр саwады, куйларга ашарга бирәде, бозауны карайды. Сыйырым быйыл тумай (*бозауламыйча*) калды. Әле киленем өйдә йук, картуф утларын чаба.

– Азбарда тора маллар кичен, көндез курага чыгарып ашатасың. Куйыбыз да, сыйырыбыз да бар. Куйлар йаwын-чәчен булмаганда куралган җирдә торалар. Таwыклар кетәкләрдә торалар (*Картузан*).

– Сыйыр, куй, кәҗә, ат, дәwә тотканнар. Дәwә бар иде безнең, күп тоттык дәwәне.

– Аwылда жигә торган дәwә бар иде. Чыгыр әйләндереп ат белән су эчәләр, бала чагымда күреп калдым. Атның күзен бәйләп әйләндерәләр. Чыгыр чиләк суны ала бирә, суны җулапка койа бирәләр. Шуннан су эчәләр.

– Калага ат белән барганнар, кузалаг арбага (*дүрт тәгәрмәчле арбага*) утырганнар, ресур арбалар (*ике кешелек үреп ясалган арбалар*) да булган.

– Сабан сөргәннәр ат белән, ат белән тырнаганнар (*Кызан*).

## Сөт ашамлыклары, сыер бозаулау, зәңки бабага хәйер бирү

– Күршеләргә, туганнарга сөт өләшә сыйыр бозаулагач, уызы беткәч. Әwәл туганнарга өләшә, аннары калага илтә сатмага.

– «Сыйыр ике ай суалып торса сагына иделәр сөтне. Суалу диләр, сөттән калып тора. Кайбер сыйырлар бер ай йөри дә бозау туа, кайбер сыйырлар ике ай суалып тора.

– Май айында сыйырың туса, май айының майы тәмле булады. Чәчәкләр ашый гуй мал. Ул нинди аwыруга да им булады.

Чәчәк майы (*май ае сөтеннән атлаган май*) дин имгә йарады. Менә чәчәк белән аураса, башы аураса, май чәчәкләренең майы дип бирәделәр. Бутилкәгә салып куйдылар. Им булады чәчәк майы (*Кундрау*).

– Сыйыры туса, әйтә иде күрше мамай: «Зөбәйдә тәтәм, Зөбәйдә тәтәм, сыйырым туды бит, каплы он керде, бакчалы чәй керде».

– Сыйыры туса инде сөт була, сөтне катык итә, катыктан эремчек була. Сары суын эчә, эремчеген ашый. Сыйыр асырый белгән кеше шулай сөт белән тукланды.

– Сөт күп булады, катык ойоткың киләде. Ул сөтеңне казанда пешерәсең. Балык булса да казанда пешерәсең. Казанны җуwасың җакшы итеп, таза көл белән ышкып җуwабыз. Камыр ашы пешерсәң дә кара казанда пешерәбез.

– Сыйыр бозаулаганнан соң беренче сауган сөтен уз диләр. Аны инде бик көтеп торабыз, зарыгып көтәйең инде, уз ашыйбыз дип. Хәзер дә уз пешерәбез сыйыр бозаулагач. Узыңнан да, сауган сөтеннән дә күршеләргә бирәбез (*Картузан*).

– Каймак, тыварук, корт йасайды сөттән. Тыварукны, сөтне казанга салып кайната ди, тоз салып тора. Аны куйыргачын кулың белән кысып-кысып кибәргә куйады. Ул корт булады, йакшы тәмле булады, чәй белән эчмәгә дә булады.

– Эремчекне кызартып кайнатасың сөт белән, казанда кайнап утыра. Ул кызыл эремчек булады.

– Кортны түгәрәкләп йасайды, салкынга салып киптерәде. Койашта эреп китәде гуй.

– Көбе пешкәннәр. Каймакны көбегә салып көбе пешкәннәр. Тайак белән тугиды. Каймак май була, тугыган май була.

Шул тугыган майны малның карынына салып саклайды. Токчуп (*малның аш казаны*) буламы малның. Токчупны йуwады, шуны киптерәде, майны шул карынга салып саклайды. Карын май дип аталады. Йазлай җыйады, кышлай ашиды шуны. Шуны кунак килгәндә салма пешереп, сары май белән суганны куырып салып ашайдылар (*Сәетләр*).

– Менә пышлакны (*сырны*) шулай йасыйбыз. Бер кила тыварукны бер литыр сөткә салып кайнатабыз. Ике йомырка, ике йөз грам май, бер кечкенә кашык чәйни суды, бер кашык тоз салып, 15–20 минут пешерәсең, кайнатасың. Аннан суң бер табакка кыйасың. Ул ката, пышлак була (*Картузан*).

**Зәңки баба, мал сәдәкәсе**:

– Зәңки бабага хәйер бирәбез сыйырың туса, малларның ийәсе дибез бит инде аны. Малың аураса, төрле казалар килсә, сыйыр туса (*сыер бозауласа*), мал сәдәкәсе дип Зәңки баба рухына хәйер бирәбез (*Картузан*).

## Камыш, җикән, чакын эшкәртү, алардан файдалану

**Чакын** – камышның бер төре, җикән.

– Чакыннан турлыклар, җәймәләр суктык. Чакынны суга манып тоталар, йомшара инде ул, аннан соң аны сугалар, суккан турлыкны идәнгә җәйәләр, сәкегә-тахтамбиткә җәйәләр.

– Кәрзиннәр, зимбелләр (*сумкалар*) бәйлиләр чакыннан. Чакыннан йасаган затны сумка димиләр, зимбел дип сөйлиләр (*Кәменни*).

– Чакын үзенә айырым, камыш үзенә айырым. Коры чакынның үзен генә урып алалар. Чакын үсә торган күлләр була.

– Чакынның орлыгын куырып ашыйсың, булымчык (*камыш орлыгы*) дип әйтәбез (*Кәменни*).

– Чакын саргайып төшә көзен, шунда урып алалар иде аны. Чакынны җыйып китерә дә аны баwыктыра (*бүрттерә*) суга салып. Аны тукып палаз итеп җәйә. Аны эшли белгән кеше генә эшли.

– Чакынның үзәгеннән корады ыстанукка. Өлкән ыстанук, йөгерме дүртлек зимбел, уникелек зимбел туги идек (*Янга-Әскәр*).

– Җикәннән турлык тугилар. Ике митырлык, өч митырлык ыстанук, турлыкны туги барасың. Күп тугыдык турлыкны.

– Әтийем урып китерә иде камышлар, йакшысын гына. Турлык итеп туги идек. Өй түбәсенә сала идек турлыкны, өстен балчык белән сылый идек (*Каргалык*).

– Камыштан бучок бәйләп өй саладылар. Сагыз балчык белән сылап чыгады өйне. Менә минем өйем дә, мунчам да камыштан салган, күрсәтәм хәзер. Әwәле өйләр камыштан иде.

– Коймалар да камыштан булган. Кайсы үреп йасаган, кайсы пучоклаган. Җир җире белән камыш була монда. Кулыңа бийәли кийәсең, камышларны чабасың. Әзилдә урак бар иде, камыш урак дип әйтәләр иде.

– Камыш өй булды. Агачтан каркас йасап, камышны пучоклап бәйлиде дә каркасына кагады (*Сәетләр*).

## Мичкә камыш йагу, кизәй йагу

**Камыш йагу:**

– Камышка барып камыш алып киләбез. Аны чабабыз өчкә бүлеп, ул бик озын була. Мичкә йагабыз. Кышка чана белән алып киләбез камышны. Аны кар булмастан алда кисеп, бәйләп-бәйләп куйабыз. Кар булса ала алмыйбыз гуй инде (*Кундрау*).

– Аwыл йанында камыш күп үсә. Кышлый камыш йага идек. Ул үзе саргайып кибә. Кыш барасың да урасың, алып кайтып йагасың (*Җәмәле*).

**Кизәк йагу:**

– Менә киленнең кәйенсеңлесе, күрше киленнәре булады. Алар бергәләп далага кизәккә барадылар. Ике-өч капчык кизәкне аркалап алып киләбез, әкилеп өйәбез киптереп. Кизәкне шулай аркалап алып кайтабыз. Кизәкне далада да өйеп куйабыз, коп-коргак булып тора. Кизәк утында пешкән үтпәк (*икмәк*) тә, питер (*төче күмәч*) дә, көлчә дә тәмле була, көйми генә пешә.

– Аннан сун агачка барабыз. Агач белән кизәкне алып килеп, киптереп, курага кергезеп куйабыз, су булып куймасын дип. Агач белән кизәкне кушып казан астына йагабыз.

– Кизәк җагабыз, камыш җагабыз, чакын җагабыз, урып әкилеп салабыз (*Кундрау*).

## Ит, балык һ.б. ашамлыклар турында

– Куйны суйасың да, тозлайсың да йазның көне эссе бит, нугай мичне ачып, нугай мичнең эченә тыгып куйады. Анда сәрән (*салкынча*) торады (*Кундрау*).

– Самуwарга күмер саласың, сөтен агызасың, чәйен койасың, суwын агызасың, айакка салып бирәсен (*Кундрау*).

– Ит чабар балта була. Куйның итен wак кына итеп чабып, суганлап, шуны бурәк итеп пешерәде, шуны шулпалап ашады. Бишбармагын да пешерәде, ул да кадерле тамак (*Сәетләр*).

– Каклаган балык, пыслак, эремчек ашадык, картук ашадык, мадур, кабыста, кабак, карбыз ашадык. Какбалыкны үзем әле дә йаратып ашыйм (*Сәетләр*).

– Камыр баса торган шара булган, шунда эпәй басканнар. Атнасына бер шара дийә торган иде. Нугай пичтә пешергән эпәйен.

Ничә әпәй чыккандыр инде. Тигәнәләре (*тагараклары*) дә агачтан иде әпәй пешергәндә (*Сәетләр*).

## Кавын-карбыз, яшелчәләр, җиләк-җимешләр

– Әүләдә игеннәрем йакшы. Мадур да, кыйар да күп. Әнә ничә такта (*түтәл*) суган, мәркү үсеп утыра (*Кызан*).

– Кирпән чапканнар борон, бакчаларда тирәк үстергәннәр. Суган, кабак, картук, мадур, дубыйа (*фасоль*), слива, армыт тирәк (*груша агачы*) үстергәннәр, каwын-карбыз иккәнләр (*Картузан*).

– Әwәл фивыралнең йегермесендә ридискә чәчәләр иде. Ридискәне җыйып алгач ул урынга кайсы кеше мадур, кайсы кыйар, кайсы мәркү, кайсы кеше дубийа утырта, чебет (*укроп*) чәчә. Безнең әүләдә шул затлар үсә инде, ни зат кирәк, урын бар. Башта үстергән хаклы була. Күз тиде быйыл курага, персик сынды, кыйар үлде.

– Курага күз тимәсен өчен кызыл йаулык элеп куйа әүләгә, үтпек сораганы йук, тора бирсен, ди (*Сәетләр*).

– Далада карбыз, каwын үстердек. Без менә быригатта карбыз үстердек, җыйып та бетерерлек булмады карбызны. Әзилдә менә хатын-кыз керсә игенне корыта дип хатын-кызны җибәрмәгәннәр, кертмәгәннәр. Хатын-кыз җиргә җалан айак басса, ага «иблис бит», – диде (*Җәмәле*).

– Слива тирәге бар, ике чийә тирәге бар, армыт тирәге бар, тут тирәге бар, ботаклары сыгылып торады. Әүләдә үсәләр. Варинийәләр бер йылдан бер йылга җитә. Аджика кайнатам памидур пешкәч. Моңа әйтәләр: «Мамам, син быйыл варинйә кайнатам дип әwәрә булып йөрмә, үзебез кайнатырбыз», – ди (*Сәетләр*).

– Кыйар җыймага, тут җыймага китә идек бакчаларга. Тирәкләрдән бидерә-бидерә тут җыйабыз, шуны әкитеп сатабыз калага. Аннан калач, чәй, шикәр-кәнфит алып кайтабыз (*Киләче*).

– Әзилдә безнең аталарыбыз әүлә тутырып кабак үстергән. Шул кабакны көзлектә кырауга суктырып аладылар. Кырауга суктырган кабак тәтле булады. Ун митырга хәтле үрмәләп үсә кабак.

«Кабак ашаган нугай», – дип көлделәр бездән.

«Йазның бер көне кышның бер йылын ашатыр», – дигәннәр (*Кундрау*).

– Әзилдә далада иккәннәр, әүләдә ни зат та икмәгәннәр. Чыгыр әйләндереп, су китереп далада иккәннәр. Әүләдә мал булган.

– Далада иген иккәннәр. Монда бодай, арыш зат чәчмәгәннәр, суган, кәбестә, мәркү, кабак, каwын иккәннәр. Игеннәр әйбәт була бездә. Хатын-кызны иген кырына җибәрмәгәннәр, иген корый дигәннәр.

– Карамалга ашату өчен лүцирна игәләр хәзер (*Кызан*).

**Ашарга яраклы үләннәрдән файдалану**

– **Тузганбаш** дигән тамыр күл йагаларында үсә. Шуны җыйып, пичкә салып киптереп китән (*киндер*) капчыкларда сакладылар. Шуны ашадылар, шуның белән көн күрделәр (*Кәменни*).

– **Җилемчәү** дигән бер йомшак кына тамырлар бар иде. Менә мәркәү кызыл була, җилемчәү аксыл-сары була. Шул җилемчәүне ашыйлар иде. Күл йагаларында бар иде. Безнең картузан аwылында шул тамырлар, балык, сөт саклады аwыр йылларда (*Картузан*).

– **Чилем** су өстендә үсә. Эчендә картушка кебек ак затлары булды, ашадык. Ул өч йәпле чәнечке кебек. Ул әwәле су өстендә үсә дә үсеп җиткәч су төбенә төшә икән. Суга чумып алып чыгалар икән. Үзе эре була. Пешерәсең, кисәсең. Мәмәйе бик тәмле (*Кәменни*).

– **Җикән тамыры, җир тамыры** диделәр, шуны ашадык. Аны киптереп пичтә табада кыздыра, уалар, ап-ак булып кала. Шуны төйә, он кебек булып кала. Аны базарда да саттылар. Тамыр ашап йан саклаучылар күп булды (*Сәетләр*).

– **Карга җиләге** ашадык, куырып ашадык. Мәштәк (*тәбәнәк*) кенә булып үсә, кып-кызыл җиләк була.

– **Булымчык** – ашый торган үлән, орлыгын ашыйбыз, пичинен (*куырган орлыгын*) ашыйбыз, пичтә пешә. Булымчык эре чакынның орлыгы, wак чакыннан булмый. Орлыгын куырып ашыйсың (*Янга-Әскәр*).

– **Бытлак – бутлак** – төбендә wак кына суганы бар, шуны пешереп ашадык. Бутлак ул картуптай була торган иде, суда пешереп ашый торган идек (*Сәетләр*).

– **Батрач** – сары чәчәк ата торган. Аны пичкә салып киптерәләр, орлыгыннан питир пешерәләр (*Кундрау*).

– **Чакын тамыры** ашадык. Аны суырып-суырып ашыйсың. Чакынның төбендә ак тамыры бар.

Мин җәйәү каладан килеп шул чакынга барам, тамырга. Ул ап-ак, шуны казамыз, әкилеп йуwабыз, шуннан соң турайбыз, казанда куырабыз. Арихтай булады. Шуны ашадык, су йагасында үсә, түбә башында үсми, ди.

– **Чакын тамырын** суырып утырабыз, үзе төче, тәмле, суырасың килеп тора. Бөтен җирдә йук ул. Пич йагып пичтә куратып ашый идек. Су йагаларында, тоба җирләрдә була торган иде. Менә шул чакынның тамырын тамак итеп ашадык ашарга булмаган заманда, үлмийек ачтан дип инде (*Сәетләр*).

– **Комаршык** кырда үсә. «Комаршык какмага китте» диделәр. Ул бик сыйлы, бик тәмле. Шуны суырабыз. Шуны тайаклап сугып-сугып капчыклап әкиләделәр. Әкилеп куырып ашадык. Тирмәндә тартып он итеп, сөт койып ашасаң телеңне йотарсың. Җуып корытып талкан итеп ашадык (*Сәетләр*).

– **Мыйа** тамырын ашадык, дәрман булган.

– **Йылгын, себерке тәрәш** – аңардан себерке йасыйлар. Шуның башында орлыгы була иде. Тирмәнгә салып он итеп ашый идек. Шул себерке тарысын ашадык корытып, төйеп (*Каргалык*).

– **Ашык буйак,** менә шуны йуwып сәрен җирдә киптерәм, шуны эчәм йүткергәнгә. Йаңгыр йаугач үзеннән-үзе чыга, тамыры да йук (*Урта Авыл*).

– **Әлчукай** ул кара тамыр, аны җуып киптереп икалап-икалап (*юка итеп*) төйеп ашадык (*Картузан*).

# БАЙ ТАРИХЛЫ, ҖЫРЛЫ ТӨБӘК

*Миңнира Булатова*

Әстерханда Идел суы
Мул да икән, татлы да.
Кыпчак канлы тамырлары,
Бай мираслы халкы да.

Халкыбыз төрле җирләргә сибелеп утырган. Бер милләттән булсак та, таралу урынына карап, телдә һәм гореф-гадәтләрдә, йолаларда аерымлыклар да шактый. Халыкның теле, аның җирле үзенчәлекләре сакланган төбәкләрдә гореф-гадәт һәм башка күренешләрнең дә борынгы үрнәкләренә тап буласың.

Әстерхан өлкәсе – төрки халыклар яшәгән шундый төбәкләрнең берсе. Ул заманында Төрки һәм Хәзәр каганлыкларына, Алтын Урдага, Нугай Урдасына, Әстерхан ханлыгына кергән. Шәһәр үзе 11 утрауда урнашкан. Төп өлеше – Иделнең сул ярында, уң якта халыкның биштән бере генә яши. Идел аша 2 күпер салынган. Әстерхан Идел буйлап 45 чакрымга сузыла. Татар Базарына килгән сәүдәгәрләр Хаҗитарханга Татар капкасы аша уза торган булганнар. Әстерханда халкының күпчелеген урыслар, татарлар тәшкил итә, казакълар һ.б. милләт вәкилләре дә шактый. Шәһәрдә озак еллар татар иҗтимагый үзәге – «Дуслык», төрки-татар «Сөембикә» оешмасы эшли. 2010 елда татар телен саклау фонды оештырылган.

Әстерхан шәһәрендә безне «Әстерхан татарларының мәдәниятен үстерү һәм саклау ассоциациясе» җитәкчесе Үтәлиева Ильмира Мөхлис кызы каршы алды. Ул үзе Майлы Күл авылында туып-үскән. Үз авылының Әстерхан татарларына хас булган сөйләшендә ул безне андагы гореф-гадәтләр, йолалар белән таныштырды.

Шәһәрнең истәлекле һәм матур урыннарын күрсәтте. Ильмира ханым экспедициягә килүчеләргә максатларын үтәүдә дә зур ярдәм күрсәтте.

Татарстаннан бу якка килен булып төшкән, Киләче авылы мәктәбенең татар теле укытучысы Есенбаева Наилә Ислам кызы авылдашларының дуслыгы, бер-берсенә «күмәг (*ярдәм*) итешеп» яшәүләре турында сокланып, горурланып сөйләде. Аның, бу төбәк халкы әйтмешли, «Әстерханға килеп, сазан башы ашасаң, монда қаласың, диләр» дигән сүзләре дә, балыкка гына бәйле түгелдер, ә андагы татар балаларына әдәби телебезне, милләтебезнең бай сәнгате, рухи мәдәнияте, шәхесләре турында киң мәгълүмат җиткерү, әдәбиятыбызны өйрәтү теләге сәбәпче булгандыр. Берничә ел эчендә ул инде әстерхан татарларының үзенчәлекләрен, халыкның, авылның формалашу тарихларын, риваятьләрен, йола-бәйрәмнәрен, аш-су серләрен өйрәнеп өлгергән һәм аларның кайберләрен безгә дә җиткерде.

Әстерхандагы төрки-татар «Сөембикә» оешмасын җитәкләүче, татарлар дип янып-көеп яшәүче милләтпәрвар кешеләрдән Наилә Шакирҗан кызы Фатыйхова-Потеева да Татарстанда туып-үскән зат. Әстерханда инде 15 елга якын яши ул. Әстерханның тарихын өйрәнә. 5–6 ел Ак мәчеттә үзе төзегән, төрки-татар дөньясына багышланган программа белән шәкертләрне укыта. Ул программа Идел Болгарстаны, Алтын Урда тарихы, Кырым, Әстерхан, Себер ханлыклары тарихы, татар әдипләре, милли хәрәкәт, бигрәк тә хатын-кызларның милли хәрәкәте мәсьәләләрен үз эченә ала. Наилә ханым үзе дә шул мәчеттә укыган. 3 ел дәвамында дин нигезләрен үзләштерүен, намаз укырга өйрәнгән вакытларын, үзенең шактый табибларны, шәфкать туташларын мәчеткә алып килә алуын иң бәхетле еллары дип саный. Ул Коръәнгә бәйле төрле чаралар уздыруда катнаша. «Мин беренче урынга тарихны өйрәнү, милли аңны һәм телне үстерүне куям. Мәчетләребез дә матур, әмма татарлар күбрәк йөрсеннәр иде», ди ул.

Урам буйлап барганда Наилә ханымның анда күргәннәрне аңлатып-таныштырып баруы да үзенә бер экскурсия булды. Татар бистәсенең үзәге Тияк-Царевоның кыскача тарихын сөйләп алды. Менжинский урамы буйлап элек трамвайлар йөрүен дә белдек. Татар дөньясыннан кем генә Тиятктә булмаган. Заманында кирпечтән эшләнгән Кызыл шәрекь клубында күренекле язучыбыз Һади

Такташ кичке 9 дан төнге сәгать 2 гә хәтле, баскан хәлдә, шигырьләрен укыган булган. Риза Фәхретдин, Фатих Кәрими, Галимҗан Ибраһимов, Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, шулай ук татарның башка бөек шәхесләре, ислам дөньясының олы-олы укымышлылары, галимнәре монда булган.

Наилә ханым Печән кибете, Татар Капкасы һәм мәчетләр (Кара мәчет, Яшел мәчет, Ак мәчет, Нугай мәчет, Кызыл (үзәк) мәчет, Камышлы һәм Сары мәчетләре) турында сөйләде, кайберләрен таныштырып-күрсәтеп йөрде. Ак мәчеттә җомга намазларында урын җитми икән, халык урамга чыга, ә Корбан һәм Ураза гаетләрендә урамда да урын булмый икән. Татарлар башка авыллардан да, каладан да киләләр. Кремльдәге чиркәүләр урынында да элек мәчетләр булган. Мәчетләрнең үз әүлияләре (Урак, Кайтармыш әүлия, Үтәмеш бабай, Фатыйма әүлияләр һ.б.) бар.

Яшел мәчет тә киң танулы. Ул Шиһабетдин Мәрҗанинең яраткан укучыларыннан берсе Габдрахман Гомәри (1867–1933) исеме белән бәйле. Г. Гомәри, Казаннан кайткач, 1892 елда «Низамия» мәдрәсәсен ача һәм ярлыларга булышу фондын оештыра. Әстерханның Бирге Тияк дигән бистәсендә татар нәшрият компаниясен ачып җибәрә: 6 елда төрле телдә 60–70 ләп исемдәге китап басыла. 1907 елдан 1914 елга кадәр чыккан «Идел» газетасы редакциясен дә ул җитәкли. Тиздән әлеге газета бөтен Россияда (кайбер елларда чит илләрдә дә) тарала. Газетаның Төркиядәге хәбәрчесе сөргендә яшәүче Гаяз Исхакый була. 1910 елдан 1914 елгача «Идел»нең әдәби бүлеген Сәгыйть Рәмиев җитәкли. Гомумән, биредә тормыш кайнап тора: клублар эшли, кинолар күрсәтәләр, дин әһелләре, Казан, Мәскәү кунаклары да еш була. 1936–37 еллардан башлап татар балалары өчен мәктәпләр эшли башлый.

Габдулла Тукай яшәп киткән урында да булдык. Мәгълүм булганча, 1911 елда ул, Сәгыйть Рәмиев киңәше белән, Әстерханга килеп, өч атна дәваланып китә.

Җәмәле авылы зыялыларының берсе – күп еллар дәвамында Әстерхан якларында халык иҗатын, гореф-гадәтләрен, йолаларын туплауда һәм популярлаштыруда зур эш башкарган Гомәрова (Умәрова) Мәйсәрә Хәким кызы. Аның «Тиңсез Ватаным» дип аталган китабында милләткә мәхәббәт, халыкка хөрмәт белән сугарылган шигырьләре күңелләрдә соклану хисе уята. Татар тормышы, татар дөньясы аның канына кечкенәдән сеңгән. Авыл халкының

көнкүреш әйберләрен, савыт-сабаларын, милли киемнәрен туплап, 1991 елда өендә музей-күргәзмә ача.

Ханбикә Сөембикәне дөньяга бүләк иткән Әстерхан һәм Нугай ханлыгы далаларыннан күтәрелгән аксөяк Урусовлар нәселенең бер вәкиле – Ижбирдиева Зөлхәбирә Фәрит кызы (1929–2011 елларда Киләче авылында яшәгән) туган авылына һәм нәсел-ыруына багышланган язмалары, шигырьләре, мәкальләре, татар йолалары, халык риваятьләре тупланган «Киләчем минем» дигән китап чыгарган булган. Ул яшь вакытыннан ук мәкальләр, әйтемнәр, халык җырлары белән кызыксынган, аларны җыйган. «Дуслык» җәмгыятенә нигез салуда, аның уставын төзүдә актив катнашкан. Җыелышларда рәислек иткән, туган тел, гореф-гадәтләргә багышланган кичәләр уздырган. Озак еллар балалар укыткан.

Әстерхан ягы көй-моңнары белән ямьләндереп торучы җырчыларга да бик бай. Казан кунаклары килүен ишетүгә, Кызан авылының актив апалары бик тиз арада җыелыштылар. Кызан авылының «илтәйесе», ягъни остабикәсе Бикбулатова Мәгърифә Сәйфулла кызы кешене соңгы юлга озатуда һәрвакыт моңлы һәм кайгылы итеп яңгыраган «Якты дөньяны күреп туймадым» мөнәҗәтен, «Ана васыяте» бәетен һ.б.ны җырлап күрсәтте.

Яхшы хәтерле Ильясова Халидә Фәрит кызы «Тәскирә», «Гомәр», «Мөршидә», «Картка бирелгән кыз» бәетләрен һәм кыска җырларны башкарды. Татар шагыйрьләренең шигырьләре, бигрәк тә Һ. Такташның, Г. Тукайның күп шигырләре әле дә аның хәтерендә яхшы сакланган. «Мәктәптә татар язучыларының әсәрләрен яратып укый идек», – ди шат йөзле Халидә әби.

Бикбулатова Камилә Мәүлетгали кызы, Бикбулатова Хәдичә Даир кызы, Ибләминова Әҗәр Идрис кызы да аларга кушылып, бергәләп борынгы җырларны, совет заманындагы җырларны да ишеттерделәр. «Түгәрәк өстәлебез» тирәсендә Кызан апалары «Монда сез бездийләр менән утырсаңыз, иртәнгә дә қалырсыз» дип, җыр-моңнарыннан тыш, Әстерхан татарларына хас булган гореф-гадәт, адәм баласы туганнан алып, аны соңгы юлга озатканчыга кадәр булган йолаларны, авыл, тормыш-көнкүреш хәлләрен, гаҗәеп вакыйгаларны сөйләп уздылар.

Ярлы Түбә авылыннан кечкенәдән ятим калган, бик күпне күргән Бикбулатова Асия Абдразак кызы «Әниемнең җылы кочагы» җырын җырлап күрсәтте, үзе шигырьләр дә яза икән. Яшь вакыт-

лардагы эш, кием-салым, гадәт-йолалар һ.б. турында йомшак тавышы белән сөйләп бирде.

Каргалык авылыннан Асхаров Шамилбек Маликаджар улы исә, милләтебезгә, туган ягына, туганнарына багышлап, үгет-нәсыйхәтле шигырьләр яза икән.

Әстерхан авылларында милли азыклардан бадамгел, шәкәрчүрәк (өйдә пешкән перәннекләр), кабак бүрәк (эченә кабат салынган бөккән), казан бүрәк (казанда майда пешерелгән бөккән), куз бүрәк (эченә әстерхан чикләвеге төше салып пешерелә торган бөккән), катланчык (катлы бәлеш), лаксалба (баллы бавырсак, чәкчәк), нугай бәлеш (ит белән дөге бәлеше), пахлава (баллы, чикләвекле бөккән), тилди, пәрәмәчә/кайнарый (пәрәмәч), өчпочмак һәм пылау пешерүнең борынгы үрнәкләре сакланган.

Аларны пешерү осталары да бар. Мәсәлән, Киләче авылының оста пылаучылары – Мулләминова Гөлҗиһан Харис кызы һәм Ажмөхәммәтова Роза Мирзаһит кызы. Пылау күп төрки халыкларның яраткан азыгы, әмма киләчелеләрнеке башка милләтләр пешерә торган пылаудан күпкә аерыла. Күрше-тирә авыллар да Киләче пылаучыларыннан пешертәләр. Мулләминова Гөлҗиһан апа безгә дә үзенең пылау пешерү серләрен ачып бирде. Гомумән, Әстерхан татарлары башка милли азыкларны да бик оста пешерәләр. Картуп пилмәне ясаучылар – Аккалиева Тәскирә Фәрит кызы, Каргалык авылыннан Асхарова Зәйтүнә Мөэмин кызы. Коръән ашларына, туйга һәм башка бәйрәмнәргә алардан пешерттерәләр.

Кызан авылында яшьләр туе үзенчәлеген әби-бабайлар сөйләвеннән ишетеп кенә түгел, ике туйның кайбер өлешләрендә катнашып, үз күзебез белән дә күрергә насыйп булды. Ярлы Түбә авылында Коръән ашына да туры килдек әле.

Әстерхан татарларыннан мәгълүмат алган вакытта җирле сөйләш үзенчәлекләре ачылды. Шуларның иң аерылып торганнарына аерым тукталып китү урынлы булыр.

Төп ф о н е т и к үзенчәлекләргә мисал итеп түбәндәгеләрне әйтеп китү мөһим: ***а*** – иренләшмәгән ачык аваз: *канат* – әд. ка$^{о}$нат; авазлар тәңгәллеге: кайбер сүзләрдә [ә] сузыгы әдәби телдәге [а] авазы урынына әйтелә ***(ә ~ а):*** *әрзән* – әд. арзан, *йәүче* – йаучы; ***и ~ ә***: *тирәзә* – тәрәзә, *йөрә* – йөри; ***әй//ай~ и//ый:*** *әпәй* – ипи, *атай* – эти, *бармай* – бармый; ***ый~и:*** *мый* – ми (баш мие);

***о~у:*** *олы* – улы, *орлый* – урлый; ***ү ~ ө:*** *үлкүн / өлкүн* – өлкән, *сүлим* – сөйлим; ***ы ~ о:*** *мырын* – борын; ***й ~ җ:*** *йете* – җиде, *йебәр* – җибәр; ***ш ~ ч:*** *шитән* – читән, *шығару* – чыгару, *ошут* (рус. очередь) – чират; ***п ~ б:*** *йапалақ* – ябалак; ***м~б:*** *мәлеш* – бәлеш, *киләмез* – киләбез һ.б.

Грамматик аерымлыклардан *й, м, л, р, з* тартыкларына тәмамланган сүзләрнең иялек, төшем килешләрендәге, тартым кушымчаларындагы үзенчәлекләрен күрсәтеп үтәргә була. Мәсәлән, *-ды/-де ~ -ны/-не* (*өйемде* – әд. өйемне), *-дын /-ден ~ -ның /-нең* (*қыздын* – кызның), *-дан/-дән ~ -нан/-нән* (*қахамдан* – кахамнан); *с, ш, т, к, п* тартыкларына беткән сүзләргә - *тын /-тен, -тан/-тән, -ты/-те* (*қабақты* – кабакны) кушымчалары ялгана.

Җыю саннарында *-ны/-не* кушымчасы төшеп калу очраклары: *Икәү* (икене) *эчәргә кирәк чәйде, улым берәү* (берне) *эчте*.

*-нчы/-нче* кушымчаларының кайбер сүзләрдә әйтелмәве*: Сәгәт алты* (алтынчы) *йарты, бер йарты* (беренче ярты).

*-дый/-дий* кушымчалы чагыштыру рәвешләре очрый: *Монда сез бездийләр* (безнең кебекләр) *белән утырсағыз, иртәнгә дә қалырсыз.*

Сөйләштә *-лай/-ләй, -лый/-лий* кушымчалары ярдәмендә ясалган рәвешләр дә бик актив: *Эсселәй* (<эссе көе – әд. кайнар көе) *чәй эчеңез. Эссе көе* мәгънәсендә куллану Башкортстан һәм Себер ягы татар сөйләшләренә дә хас.

Сөйләмдә *зат* сүзе еш кулланыла: *Ни зат ул?* – әд. Нәрсә йә кем ул? *Ни зат итә? Ни зәт итәде?* – Нәрсә эшли? *Уға бер зат* (кеше) *килә. Халаттай булған зат* (кием) *ул. Әтисе бикләп қуйған бер затқа* (урынга). *Затларын* (әйберләрен) *салып йибәрткән ағызып. Йортларда бер зат* (нәрсә) *та йуғ иде, сәке, булса инде, әзерәк түшәкләр.*

Хәзерге заман хикәя фигыльнең I зат күплек сан формасы *-мес/-мыз* варианттагы кушымча ярдәмендә ясала: *Қоранға* (Коръән ашына) *барамызмы* (әд. барабызмы)*? Бәйетләр сөйләймес* (сөйлибез).

III зат берлек сандагы фигыльләргә *-ды/-де, -ты/-те* кушымчасы ялгану очраклары күп: *Внучқамыз йома көнне последний экзамен бирәде* (бирә), *юридическийда уқыйды* (укый), *кийәүгә шықты, уқуwын да бетерәде* (бетерә), *Алла бирса. Аурады* (авырый), *йөрә бирде* (йөри бирә) *ақсап.*

Боерык фигыльнең II зат күплек саны *-ң//-ныз//-ңыз* (әд. *-гыз*) кушымчалары ярдәмендә ясала: *Кеше йазғанда туқтап торыныз* (торыгыз), *сүли бирмәнез* (сөйләмәгез). *Ойалып утырмаңыз. Сөйләң* (сөйләгез).

Хикәя һәм теләк фигыльләрдә *-ай/-әй* кушымчасы әдәби вариант белән параллель кулланыла: *-ай//-әй ~ -ый//-и/ий, -айым//-әйем ~ -ыйм//-им: Башын савуға бару йоласында ақчаны қағызға салалар да өстәлгә қуйалар, қулға бирергә йарамай* (ярамый). *Бер зат* (беркем) *та қалмай* (калмый). *Нәсел ағачларын сөйләйем* (сөйлим әле). *Қунсымды* (күршемне) *кереп күрәйем* (күрим).

Фигыльләрдә *-ай//-әй* аффиксы урта диалектның касыйм, нократ, эчкен, минзәлә сөйләшләрендә, бигрәк тә Башкортстандагы бәләбәй урынчылыгында, кормантау, тепекәй, златоуст, бөре һәм учалы сөйләшләрендә киң таралган. Билгеле булганча, ул шулай ук көнчыгыш диалектка да хас күренеш.

Инфинитивның *-ма/-мә, -мага/-мәгә* формалары кулланыла: *Қоран* (Коръән) *ашынын ризығын көттермә* (көттерергә) *йарамыйды. Йыл да уқымаға* (укырга) *ақча бирә торған идек.*

Тезмә сыйфат фигыльләрдә (*-а, -ә* кушымчалы хәл фигыльгә *торган* ярдәмче фигыле кушылып ясалу) кыскартылган вариант куллану үзенчәлеге: *Қойынадан* (әд. коена<юына торган) *җирем* (урыным) *бар.*

Сирәк булса да *қу//қуй* (әд. ич, бит) кисәкчәләре очрый*: йуқ қу* – юк бит.

Кайбер л е к с и к үзенчәлекләр. Т о р м ы ш - к ө н к ү р е ш б е л ә н б ә й л е с ү з л ә р: *ағач* – әд. утын, койма, *тирәк* – агач, *спичкә* – шырпы, *суwағаш* – көйәнтә, *тақтамбит* – сәке, *ишек* һәм *тәрәзә йөзлөкләре* – тәрәзә пәрдәләре һәм ишек чаршаулары, *чапрач* – баскыч, *әүлә* – ишек алды, *ушақ* – кечкенә мич, *тәрәтқанә* – бәдрәф, *бабай түбә* – зират, *йағлау* – чүмеч, *бирчәчкә* – агач тәлинкә, *чилтәк* – тишекле чүмеч, сөзгеч, *дура(ж)ш* (<дрожжи) – чүпрә, *тастархан* – ашъяулык, *ширәкә* – чынаяк, *ләлмик //ләлм(б)әк* – чынаяк тәлинкәсе, *типкер//кипкер* – тишекле кашык, *нәлмәк* – тәлинкә, *чүмеч//тустақай* – чүмеч, *зыпын//запун* – алъяпкыч, *бидрә* – чиләк, *қуймалақ* – кечкенә бидрә, бидон, *әпәй* – икмәк, *балға* – чүкеч, *матқап* – каргаборын (рус. плоскогубцы), *дәрмән* – дару, *қайық* – көймә, *шиққарын* – мал эчендәге қарынны әйтәләр, *қырққабат* – кырыққарта, *йастық* – мендәр,

*сырдаҡ* – урындык өстенә ққуйа торган җәймә, *сырға* – алка, *сенәпит* – җиңсез җылы сырган кофта (рус. душегрейка), *төнәген* – кичә, *үлкүн // өлкөн* – зур, *көйәз // кийәз* – сый, сыйлы, *кийет* – бүләк, *ҡамыраш* – токмач, *ҡыйҡым* – чүп, *суй* – нәсел, *ҡанжҫаға* – ат ияре.

Эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр: *имбәкләү* – мүкәләү, *утны йағу* – утны кабызу, *утны тымызу* – сүндерү, (*телевизор) салу* – карау, кабызу, *чәпәнәй ҡағу* – эд. кул чабу, *ҡул алу* – күрешү, *ҡыйрау* – җимерелү, сыну, *күмәг итү* – ярдәмләшү, *үтерек сөйләү* – ялган, алдап сөйләү, *сукешү* – әрләшү, *анап утыру* – саклап утыру, *азарлау* – тиргәп сөйләү, *суға төшү* – су коену, *мучаға төшү* – мунча керү.

Затларны белдерә торган сүзләр: Әстерхан татарларында гадәттә үзеннән бер яшькә зур булган апа, абыйга үз исемен әйтергә ярамый. Ир белән хатын да бер-берсенә исемнәре белән түгел, ә *этисе*, *энисе* дип кенә эндәшкәннәр.

Әтисенең энисенә – *әйем*, этисенең этисенә – *атам*, этисенең агасына – *муллам*, этисенең апасына – *атайбикәм*, этисенең сеңлесенә – *апаҡтәтәм* дип әйтәләр.

Әнисенең этисенә – *бабам*, энисенең энисенә – *мамам*, энисенең энесенә – *кахам*, энисенең сеңлесенә – *тәтәм*, энисенең апасына – *ҡайтим* дип эндәшәләр. Алар икәү булсалар *өлкән*, *кечкенә* сүзе кушыла. Аларның дусларына *дус* сүзе өстәп әйтелә: *дус әйем*, *дус атам*, *дус ҡахам*, *дус тәтәм*. Әнисенең ике-өч абыйсы булса: *өлкән ҡахам, кечкенә ҡахам, биби ҡахам* дияләр.

Ир кешесенең абыйсы – *ҡайнаға*, хатыны – *абсын*, килене – *кешәк / кишәк.*

Әгәр гаиләдә балалар күп булса, *ак, бал, шикәр, өлкән, кечкенә, биби* сүзләре кушыла: *актәтәм, балтәтәм* һ.б.

Килен кеше иренең туганнарына ире ничек эндәшсә, шулай эндәшергә тиеш. Зурлар үзеннән бер яшькә генә кечкенә булса да, сеңлесенә *сәүлим*, энесенә *мырзам* дип дәшә. Өйдә ике килен булса, кечкенәсе зурысын *тәтәм* дип йөртә; икесе бер яшьтә булсалар – *ахирәт, сөйәрем, сөйеклем, ҡадерлем, гүзәлем, аппағым*. Мондый сүзләр белән эндәшкәндә беркайчан да талашырга ярамаган.

Күршеләргә дә исемен әйтмиләр: *ҡунсы // күрше // ҡуншы*. Балалар өчен алар – *ҡуншы атам, ҡуншы әйем, ҡуншы тәтәм* һ.б.

Әгәр капкалары кара-каршы булса, *қап-қалач* дип әйтелә. Ә балалар *қапқалач* сүзен кушып эндәшкән.

Туганнарга, күршеләргә исеме белән әйтү әдәпсезлек саналган.

Үзеңнән бер яшькә олырак кешегә исемен әйтеп җибәрсәң, ул «тәрбиясез, син туганда мин куанган идем, ә син исемне әйтәсең», – дип кисәтү ясаган.

Дус кызлар бер-берсенә *айырылмас, былбылым, туғаным, қардәшем, дусым, күбәләгем, күгәрченем, сандуғачым, алтыным, ахирәт* дип дәшкәннәр һәм чәнти бармакларын бөгеп чалмаштырып ахирәт дуслыгына кушылганнар. Элек, хәтта XX гасыр башында да дус туен ясап «дус кушылдырганнар». Бер-берсенә истәлеккә зур затлы әйберләр бүләк иткәннәр. Дус, ахирәт булып кушылганнар, алар ахирәткәчә аерылырга тиеш булмаганнар.

Кешене тасвирлый торган сүзләр: *исле* – карт, *спайы*// *күркәм* – матур, *үтерекче* – ялганчы, *қыйшық* – кыек*, маштақ*// *упақ* – бик кыска, бәләкәй, *җисер* – тол хатын*, асау* – усал һ.б.

Әстерхан татарларының фонетик, грамматик, лексик үзенчәлекләре һәм аларга хас булган гореф-гадәт, йола һ.б.лар алга таба биреләчәк сөйләү үрнәкләрендә аеруча тәэсирле яңгырый. Текстларда сүзләрнең әйтелеше транскрипциядә бирелә. *Я, ю, е* хәрефләре урынына [йа], [йә], [йу], [йы], [йы], [йе] авазлары, өстәмә билгеләрдән [w] – ирен-ирен өрелмәле тартык аваз һәм [қ], [ғ] – тирән тел арты тартык авазлары кулланылды. Кыскартылмалар: *әд.* – әдәби, *рус.* – русча, һ.б. – һәм башкалар.

## Авыллар тарихыннан

Киленчи дип аталса, электә монда бер зат та булмаған. Шуннан бер зат (*кеше*) күчеп килә. Шул күчеп килгәндә кемдер сорыйдыр, менә, например, мин барам, син сорыйсын: «Анда ничек, хәлләр ничек, аwылда ничек?», – дип сорыйсын. Шунда ул әйтәде: «Йақшы». «Ату бармаға кирәк икән», – дип әйтә ди инде анау. Анау бабай әйтәде: «Киләче, киләче». Менә шуннан Киләнче булған да киткән ул. Син киләсен мийаға (*миңа*): «Анда ничек сездә аwылда?» дип сорыйсын да, «Әй, мин дә барым күрсәм икән», – дисен. Шунан мин сиған (*сиңа*) әйтәм: «Киләче, киләче, кил, күрерсен, нинди икәнен».

*Сөйләүче: Мавшиева Мөгөлсем*
*Газиз кызы (1936 елгы).*
*Киләче авылы*

Бу аwылға күчеп килгән булғаннар ике партия кеше. Ул икән бер милләт – татарлар. Улар бүленгән, берсе киткән урманға, берсе менә шундый ачық җирдә қалған. Ачық җирдә қалған кешеләр бақша (*бакча*) эшләгәннәр, урманға киткән кешеләр мал қарағаннар. Ул кешеләрне қарағач дип әйткәннәр. Монда иген мән (*белән*) шөғөлләнгән кешеләрне нуғай дип әйткәннәр. Шуның өчен берәз генә аларнын телләре безгә қарағанда башқарырақ, өч аwылнын – Қызан, Киләче, Солянка – теле бер, йақаш килә (*туры килә*). Без таш дибез, алар тас диләр. Без эт дибез, алар кәчек дийәделәр. Қатырақ сөйләшәләр. Менә шул урманға киткән кешене қарағач дип қуйғаннар. Минем әтийем шул урмандағы кеше булып чықты инде, ә әнийем Қазаннан, әтийем аны суғыштан қайтканда алып кайтқан.

*Сөйләүче: Бирдиева Гөлфәридә*
*Дуллаян кызы (1939 елгы).*
*Ярлы Түбә авылы*

Мин үзем шушы аwылда туып үстем. 6 йыл эчендә мең кешегә артты аwылда, мин килгәндә 2800 иде, хәзер өч мең йарым. 900 артық йорт, қалаға йақын. Йәшләр китми. Бездә иске аэрадром бар. 1932 йылны анда ангар йасалған иде, самолетный стояк. 1998 йылны балалар уйнап-уйнап, пожар булып, эчендә 14 самолет йанды. Монда элек көн дә прыжоклар, полетлар иде. Мин үзем дә шунда очтым бит. Монда ул как аwылның үзәге, визитная карточкасы кебек. 1979 йылда монда «Старшина» дигән фильм төшерәделәр. Анда безнен аэродромды төшерәләр, ангар күренә. Бер эпизодта «Победа, победа!» дип безнен аwыл халқы йөгөрәде. Анда иске Әстерхан эләкте, Татар-Базарын да төшөрделәр. Татар-Базарында революциягә қәдәр булган киноларны да төшерәләр иде. Кечки wақытта әнийем белән барғанда хатыннар йөрәде иде дореволюцион күлмәкләрдә, эшләпә, собачкалар белән. Шулайтеп монда әwәл wақытлар турында кино төшөрделәр.

*Сөйләүче: Бирдиев Фаил*
*Йосып улы (1968 елгы).*
*Ярлы Түбә авылы*

Киләче аwылы 1787 йылны төзөлгән аwыл, Әстерхан губернийәсендә. Беренче легенда әнә ул Екатерина II – әби патша wақытында. Әби патша ниндидер утырыш җыйған була. Мон-

да Әстерханда татарларның җәмгыйәтеннән җибәрәләр мурза Йамгурчиев дигән кешене дилировайтәләр. Ул аннан қайтқаннан сон, дварйан собранийесе була инде, шуннан қайтқанда, монда әле Киләче булмаган, Әстерханның Мошайық дигән козачий шул тирәдә урнашқан була, менә шушы Киләче татарларының бороңго бабалары, Мошайық Әстерхан тирәсендә моннан йырақ ул, қалага йақын. Шуннан килгән халыққа «Безгә нинди йаңалык китердегез?» – дип сорыйлар инде, «Сезне Екатерина II миңа крепостнойлар буласыз», –диде. Йасақ түләмәгә бит инде. Шунан ачуыннан халық шушы абыз мурзаны суга батырып үтерәләр. Шуннан қурқалар да халық, чөнки аларның атлар, сарықлары күп була, ә моны дворйаннар килеп-килеп ала. Җирле халық булган бит инде гөмер-гөмергә. Шуннан халық әкрен генә урын эзли башлый. Атқа атланалар да, бер-ике кешене җибәрәләр шул йақларга. Килә-килә, шушы йылганың бу йагына килеп җитәләр. Баллы йылгасы, русча – Балда. Йылганың теге йагына башта урнашмақчы булалар, аннан уйлыйлар: без бу йылга читенә урнашсақ, безне барыбер килеп табырлар, дип, чөнки Киләче аwылы ул утрауда тора, чөнки сез килгән күперне төзеделәр генә, сез килдегез бит күпер арқылы. Әгәр су басса, баса да қала инде, иң түбәндә без. Каспий йылганың түбәнендә. Халық йөзеп чыгып шушында урнаша и бераз-бераз бар халықны килегез, «Килче, килче»,– дип чақыра. Килче сүзенннән Киләче аwылы. Шулайттереп халық йылганың бу йагына урнаша. Ә инде қалага чыгар өчен, теге йаққа китәр өчен, қайықларда (*кечкенә көймәләрдә*) чыгарга кирәк. Бик күп йыллар, менә 2000 нче йылларга хәтле шушы аwылдан халық паром белән теге йаққа шыга (*чыга*). Паром бар иде, туры йул йуқ иде. Күперне ике мең ничәнче йылларда гына ачтылар.

Монда бер аwылда 14 милләт кешесе йәши. 80 проценты татарлар, аннан соң қазақлар, иң основной – урыслар, аннан сон цыганнар, үзбәкләр. Күп кенә Әстерхандагы татарлар үзләрен, мин әстерхан татары, ди, ә қайберләре, мин нугай, ди. Нугайның кем икәнен дә белмиләр. Татар ул татар, татарның җире бар, дәүләте бар, ә кем нугай. Ә монда алар Әстерхан татары дип, ә чөнки халық санын алу булганда Әстерхан татарлары барысы да татарлар дип йаздырдылар. Шушы урамда торган нибар халық, ничә милләт бар, күбесе аларның татарча төшенә (*аңлый*). Урыслар да. Қазаннан килгән халықны әйтәләр *җүкә айақлар* дип.

XVII ғасырдан ук монда татарлар булған. Пенза, Татарстаннан күп килгәннәр.

*Сөйләүче: Есенбаева Наилә*
*Ислам кызы (1974 елгы).*
*Киләче авылы*

Безнен аwыл Шайтан аwылдан башланған. Күп йыллар элек аwыл бөтөнләй йанған булған. Шул уқ урында Шайтан аwылы йаңадан төзөлгән. Иң бороңго аwылларның берсеннән санала.

Күчмә тормыштан утрақ тормошқа күчкәннәр. Аwылыбыз арқылы 3 йылға аға, шуңа – *Три Протока*, татарча *Җәмәле* дип атала. Аwылыбыз қаладан 5 кенә чақрым. Идел тармағы қала йағыннан *Кутум* йылғасы дип атала, безненчә *Билгәскән* йылғасы. Күп йыллар элек шушы су йулы белән йырақ аwыллар қала белән бәйләнештә булғаннар. Йырақ аwыллар малчылық, балықчылык белән кәсеп иткәннәр.

Билгәскән йылғасының көнйағында зур түбә (*тау*) бар, аны *Аға* түбәсе (*тауларның агасы*) дип атаганнар. Ага түбәсенен астында көнйағында *Қар күл* бар, анда бик озон, қуйы қамышлар үскән. Әле аwыл булмаған чақта шул қамышлықта қачқынчылар йәшәгәннәр, алар су йулы белән қалага баручы қайықчыларны (*көймәчеләрне*) талағаннар, бик қаты суғышлар була торған булған. *Билгәскән* суы алсу төскә кергән, бил кискәнче қаты суғышлар булған. Шуннан бу йылғаға *Билгәскән* (<Бил кискән) дип әйткәннәр. Талаучылар, қарақлар түбә астыннан, қамышлықтан начар қийәфәттә, йәмсез, қоточқоч таwышлар чығарып көймәчеләрне талағаннар, аларны шайтаннар дип әйткәннәр. Қамышлықны *Қарақ күл* дигәннәр. Соңрақ Аға түбәсеннән аwыл башланған. Хәзерге көндә дә Билгәскән йылғасы Аға түбәсе Қара күл дип әйтелә. Шайтан аwыл диләр.

Икенче йылға Шайтан аwыл йылғасы дип атала, бу йылға аwылны бүлеп тора, аwылның икенче өлеше Қазақ аwылы һәм йылғасы да Қазақ аwыл йағасы, дип әйтелә иде.

Бик бороңғо заманда солдатқа күп йылларға ала торған булғаннар, солдатқа қазақларны алмағаннар, солдатқа бармас өчен берничә симйа (*семья*) қазақлар торған йақта берәз йәшәп, хәтта қазақ булып йазылып қайтқаннар. Аларға өй салған wақытта чарлақсыз салырға қушқаннар. Шуға аwылда йылға да қазақ исемен алған. Икесе бергә хәзерге көндә *Җәмәле* дип әйтелә. Электә

*Җәмиле* дийәләр иде. Җәмил исемле кеше башлап йәшәгән булырга тиеш.

Башта халыкъ малчылыкъ, балыкъчылык, соңракъ йөзөм (рус. *виноград*) менән шөғөлләнгән. Күп йыллар инде қала йақын булғанға – игенчелек (*бакчачылык*). Аwылыбызда милләтләр саны 25 тән артықъ. Зур аwыл тыныч, рәхәт йәшәйбез, җир барчабызға да җитә. Безнең аwыл иң боронғы аwыллардан санала. Әтийем әйткән 500 йыллар чамасы булырга тийеш безнең аwылға дип.

*Сөйләүче: Гомәрова Мәйсәрә*
*Хәким кызы (1936 елгы).*
*Җәмәле авылы*

***Кызана** (легенда).* Қазанда бер патшамы булған, шунын булған биш қызы. Кечкенәсе иң матуры, йаратқаны була. Бу қыз пастухты йаратқан. Унан бергә қашып киткән. Малайлары туа. Әтисе боларды эзләтеп табып, алып қайта. Ә қыздын ире өйдә булмаған була ул wақытта. Әтисе йибәрми қызын: «Күрше кнәзден олы (*улы*) үсеп килә, шуңа бирергә сөйләштек, ул синен өчөн йахшы қалым бирә», – ди. Әтисе бикләп қуйған бер затқа (*урынга*). Кичкә әнәсе (*әнисе*) қызын шығартып, сал торғозып, бөтөн приданнарын, затларын (*әйберләрен*) салып йибәрткән ағызып, озатқан. Әстерхандағы бер йарға килеп туқтағаннар. Шунда: «Алла безгә Қыз-ана җибәргән», дип, халық қаршы алып уны, бер өй салғаннар уға. Ире берничә йылдан сон эзләп таwып, өчәүләп бәхетле йәшәй башлайлар. Аwыл халқы мән дус-тату булалар. Әтисе қызынын қайдалығын белепте, эзләп килгән безнен аwылға (күп затлар менән әнисен генә җибәргәннәр дип тә әйтелә). Унан күп кешеләр килгәннәр корабл'ләр менән. Аны апкитәрәк булған, мин китмим, дигән. И шуннан монда тороп қалған. Шунан Қыз-анадан *Қызан* булып қалған аwыл. Башмашниклар күп була, шуңа күрә Башмаковка әйтеләде. Потом, улар татарлар күп булғанға, *Татарская Башмаковка* дигәннәр.

*Сөйләүче: Мәхмүдов Наил*
*Гали улы (1988 елгы).*
*Кызан авылы*

***Тийәк.*** Монда Төйәк суwы булған. Пароходлар, баржалар йөргән, товарны шунан те йаққа чығарғаннар. Тийәк сүзенен килеп чығышын шуннан киткән дигән сүз бар. Ул суның икенчесе русча

Царево дип атала, йәғний 1454 йылны Әстерханны алғанда Йанғурчи хан моннан Дағестанға қача. Әстерханға ничә йыл дигәнгә җаwап биргәндә, 1554 нче йылны, ике йылдан соң Қазанны алғанның Иван Грозныйның ғаскәрләре монда төшәләр Идел буйынча. Әстерханға 1554–1558 йыллар да нигез салынған дип йазыла төрле җирдә. Халық қуыла қамыш арасына. Әлбәттә, урыс йазмаларында йазылса да 450 йыллар дип, Әстерханға бик күп йыллар.

Монда булған урыс эче, анда урыслар йәшәгән. Қазан эче – Қазан йағыннан килгән халық булған, қарағачлар һәм башқа җидесигез қәбилә дә. Төрле эш башқарғаннар. Габдрахман Гомәри Қазаннан қайткач, «Низамия» мәдрәсәсен ача, Ш. Мәрҗанинең уқучысы ул. Йаңа җәдидчелек белән уқытуға нигез сала. Габдрахман Гомәри музейы бар.

Тийәк икегә бүленә. Бер йағында ғына да җиде-сигез мәчет булған. Халықта нәзер қалған, нәрсә булса да эшлә. Җиде мәчеткә садақа күтәрәм дигән.

Мәчетләрнең исеме: Йәшел мәчет, Сары мәчет, Қамышлы мәчет ... – өчесенең оригиналлары исән әле. Татарның бөйек шәхесләре генә түгел, ислам дөнйасының олы-олы уқымышлылары, ғалимнәре монда булалар. Дағестаннан, Карачай-Черкесиядән, Төркиядән, Мәккәдән, Мәдинәдән, Уфа, Қазаннан һ.б.дан.

***Ак мәчет.*** Бу элеккеге Җәмит мәчете булған үз wақытында. Алтын Урдадан килгән бик бороңғы мәчет бу, қарый XVI ғасырға, ә болай үзенең төзелеше, ташы 1810 йылда салынған. Бу – татар мәхәлләсе районында. Wақытында ғәҗәп хәлләр дә булып алғылаған. Эшли башлыйлар төзүчеләр. Берwақыт эш бөтөнләй бармый, кемдер йығыла, айақларын сындыра. Шуннан соң әйтәләр, монда күптән намаз уқымадылар, үзәк мәчетләрнең берсе булган бит, намаз уқығыз, диләр. Намаз уқыйлар, қычқыралар азан, шунннан соң инде эшләп алып китәләр. Эшнең барышын камераға төшерәләр. Фотопаратта михраб йағында кеше йөзе күренә. Исем китте. Қызыл тап эчендә йөз. Шуңардан көчле энергетика килә, диләр халық.

Бу ғәди мәчет түгел, хикмәтле, мөғҗизәле. Исеме дә Ақ мәчет. Ул көчле энергетикаға ийә, аны сизмәү мөмкин түгел, тынычландыра. Намаз уқыйм, доға қылам, садақа салам. Бу мәчеткә төрле йақлардан киләләр. Михрабның бер йағында бер әwлийә, икенче йағында икенче әwлийә күмелгән, ди. Урақ һәм Қайтармыш әw-

лийә. Халыk әз йөри. Татар, әзербайҗан, чеченның үз мәчете бар калада. Kызғанычkа kаршы, мәчетләр дә әле татарлар kулыннан китүwен китмәде, но безнең халыk әз йөри. Киләчәктә мәчетләр безнең kулдан китергә мөмкин. Чөнки ул халыk – дағестан, чеченнәр – башта базарда иде, хәзер кибетләрне сатып ала башладылар. Депутат, собранийеләрдә kатнаша башладылар. Әстерханда 75–80 мең татар дийелә иде. Хәзер соңғы халыk исәбен алу буйынча 60–65 мең татар бирәләр.

Әле монда мөфти дә, муллалар да, мәзин дә, уkучы халыkның төп өлеше безнең халыk. Монда башkа халыk та йөри (әнә ике Дағестан кешесе утыра), әмә мәчет аларныkы түгел. Җомға намазларына монда урын җитми, урамға чығалар. Kорбан һәм Ураза ғәйетендә урамда да урын булмый. Татарлар аwыллардан да, kаладан да киләләр.

Бу мәчет Фахап хәзрәт Али үз акчасына башлап җибәрә, аның тәғдиме беләν сәүдәгәр Мөхәммәтшакир Kазаков үз исәбенә дәwам итә. 1898 йылда тәмамлый. Бу мәчеткә 102 йыл. Мөхәмәтова Алсу һәм аның ире Сәйфулла хәзрәт Бикмөхәммәтовлар 20 йылға йаkын ислам дине нигезләрен өйрәтәләр.

***Татар kапkасы.*** Kалада чиркәү йанында Татар kапkасы булған. «Татарские ворота» дип аталған. Шул kапkадан Идел платной килеп терәлгән булған. Уннан сәүдәгәрләр затлы пароходлар мән килгәнде. Шул Татар Базар kапkасы, йарлыраk халыkkа анда килергә рөхсәт булмаған. Вип салоннар кебегрәк җир булған.

***Печән кибете***. Kазанда Печән базары икән, монда Печән кибете булған. Хәзер урамнары булса да kалған. Печән кибетендә хатынkыз йөрмәгән. Бу аталған икенче төрле «ирләр кибете» дип.

*Сөйләүче: Фатыйхова-Потеева Наилә*
*Шакирҗан кызы (1957 елгы).*
*Әстерхан каласы*

## Тормыш-көнкүреш, йорт-җир турында

Доға китабы уkып утыра бирәм. Ул инде үземә бик кирәк булып kалған зат (*әйбер*). Эшем туkтадисә, уkырға тотонам. Телим шуны уkырға. Кечкенәдән күреб үстем, әтиемнен әнисе уkый торады иде. Әтийем укый иде доға. Минем әйем (*дәү әни*) kала kызы дип әйтеләде. Kазанда туыб үскән, kазанлылар алар. Ул заманда кемгә

кийәүгә бирәләр, шуға бара инде қызлар. Минем әйемнен әтисе булмаған, ағасы бергә мәчеткә йөргән кешегә Җәмәлгә (*авыл исеме*) биргән, қала қызын қалаға бирмәгән. Бергә мәчеткә йөргән кешегә тотқан да биргән. Минем қала қызы әйем нуғайға чыға инде. Мин шул әйемнен внучкасы инде. Қала қызы күркәм иде. Ап-ақ, тулы, зур иде әтиемнен әнисе. Шуны нуғайға биргәннәр дә, шунардан без кечкенә нуғайлар туғанмыз.

Әйем үзе бөтөн аwылға бала тудыртқан, кендек кискән. Хөрмәтле инде, бала туса, җиде көнгә тиклем аны җибәрмиләр, хөрмәт итеп. Анау баласын башына әйем монадый тақыйа тегеп кийезеп, ғади зат күлмәк тегеп кийезәде. Затларына (*итәкләренә*) текми иде, сәленеп торады. Шул саwап икән имештер, текми. Җиденә тиклем, җибәрмиләр инде аны. Қайзаман өйләрендә тар кешеләр була икән, «Китийем, өйемә қайтыйым», – дийәде әйем. Йуқ җибәрмиләр, өйе тар булса да. Әйем бер заман, этийем әйтә иде: «Адай, синен ақылын бармы ул тар җирдә қайда йоқлыйсың», – дигән. Әйтәде: «Миға нинди җир бар, йоқладым, миңа урын бирделәр». Йибәрмәсәләр қайда барасың, йибәрмиләр, китмисең дийәде. Хөрмәт итәләр инде, китәлмый бу, кешене санамаған бу дийәрләр дип. Ул өлкүн (*зур*), ап-ақ, қала қызы, үзе прастуй, үзе йомшақ, қулы йомшағын күрсәң, аны йаратмаған кеше йуқ. Җәмәлдә йәши. Үзе қалада туып үскән. Аның атасы брач (*табиб*) булған, ул заманда уқып түwел, уқымый болай брач булған. Атасы үлгәндә ағасы да брач булған, ул да уқымыйча. Менә иснәгәндә йат чығып китә икән, сынғанны да йасыйлар. Шуны да утыртқан бабам минем – әйемнен ағасы. Әтисе шундый булған. Анан ағасы. Ул өйләнгән җиңгәсе хатын-кыз лечит' иткән, мамам қарый, ди. Ир килсә, бабам қарыйды – иреде. Аларның леченийесе файдаға ашқан. Бөтөн районнан халық килгән, йәрдәм бирде, бөтен аwырулар килде. Сынғаннарны, чыққаннарны, бөтөн җирен урнаштырып төзәтә, ул шундый үзеннән-үзе оста кеше иде. Хатыны хатыннарны лечит' итте.

*Сөйләүче: Ибәтуллаева Шәһәрбану*
*Хөсәен кызы (1923 елгы).*
*Җәмәле авылы*

Зур йылға – Баллы (Балда). Бүзәк йылғасы, урычча Садовый дип аталады. Аннары Кафтаний йылғасы бар. Арық бар – йерик (*ерганак*). Бездә ағач йуқ. Әүәлдә монда бригадалар бар иде.

Бакчалар бар иде. Шунда искеләрен бригадир белән сөйләшеп, картайган тирәкләрне (*агачлар*) кушып (*кисеп*), утынға ала торған идек. Киләче күбрәге картуф үстерә. Картуф тик Киләчедә, шуңа картуф пилмән, картуф калач һ.б. пешерәделәр, ә Башмаковка, Кызан, Җәмәлене (*авыллар исеме*) алсан, улар – помидор, кыйар и зелен'. Бер салат пербий Җәмәлдән чыкты. Пәрәмәчә // пәләмес – пәрәмәч ул, ә кайнарый дип мондағы урыслар әйтәде. Өчпочмаклар, пироглар та пешерәмез.

*Сөйләүчеләр: Саҗидә Рәшит кызы (1937 елгы) һәм*
*Әдһәм Габдеразак улы (1935 елгы) Баубековлар.*
*Киләче авылы*

Түтәлләр шул хатле тигез итеп эшләнелә. Йоморка тәгәрәтеп карағаннар, хәтта биш тийенлек акча, ул туктамыйча барырға тийеш булған, шунда ғына түтәл йакшы эшләнгән. Сыw бер җирдә күбрәк булып, икенче җиргә сыw бармый, йуғары булып калса, анда иген бу сыw күп җийылған җирдә дә булмый, и бийегрәк җирдә дә булмый. Шуның өчөн ул тигез барырға тийеш. Мадур (*помидор*) ул халыкны монда ашату. Бакча эшләре үктәбердә бетә, и ғыйнwар ахыры – фебрал башында рассаданы чәчәләр. Аннан сон утырталар, аның эше шул кәдәр аwыр хезмәт у. Әмма халык шунын белән көн күрә. Бөтөн нәрсә парникта, парниксыз бернәрсә үсми, кыйар да, хәтта ағачлар да корой башлады, әстерхан газпромыннаннан кислаталы йамғырлар килә. Халык калхузлар, савхузлар беткәч, шуны утыртып, помидор сатарға Мәскәүләргә, Санкт-Петербургка хәтле баралар, ғәйләләр белән шөғөлләнәләр. Төп хезмәте. Мадур җыйабыз, мадур сатабыз, диләр. Баклажан, кыйар бик күп үсә, зелен', укроплар..... Ә карбыз, каwын калхуз кырларында инде алар. Моносы – такта, ә бу йул күсәм дип әйтелә. Йул ағадан сыw сағадан. Тегендә ашыла (*ачыла*) и сыw килә. Бу каналлардан сыw йөри, шланга белән сипмиләр, бер җирдән ашалар, икенче җирдән йабалар. Болар шилләр дип әйтелә, түтәл түгел, ә шил. Ә болары шик (*чик*), ыштубы сыw тегендә-монда бармасын. Матиг белән ача, тулғач, йаба да тегесен ача. Монда сыw сипмичә бер нәрсә дә үсми. Халык җәй көнө беркайа китәлмый.

*Сөйләүчеләр: Гомәрова Мәйсәрә Хәким кызы (1936 елгы).*
*Җәмәле авылы,*
*Фатыхова-Потеева Наилә Шакирҗан кызы (1957 елгы).*
*Әстерхан шәһәре*

Татар аwылы булғанға, бездә инде шунлай ук Қоран уқытамыз, бәйрәмнәр йасыймыз. Бар да бездә татарша ул. Бездә урыслар йуқ монда күбесенчә. Без қор татарша сөйлимез. Рус теле дә кереп китмәйде. Без коренной татарлар, мөселманнар. Татарлар, нуғай татарлар дип әйтәләр. Белмим қайан, безне нуғай татарлар дип сөйлиләр. Безне қазан татарлар дип әйтмиде инде, бездә нуғайлар, әстерхан татарлары дип. Без ногаецлар да түгел. Ник нуғай дип әйткәннәрдер.

*Сөйләүчеләр: Бикбулатова Хәдичә Даир кызы (1942 елгы), Ибләминова Әҗәр Идрис кызы (1952 елгы). Кызан авылы*

Элек Киләче өч аwылға бүленгән – Урта аwыл, Йуғары аwыл, Түбән аwыл. Иң зур татар аwыл бу. Татар теле Идел буйы районында ғына уқытыла. Нариман районында татар аwыллары күбрәк. Монда 1933 йылда ике атна Муса Җәлил булған. Председатель совхозанын өйөндә торған. Моннан киткәч, «Балықчы қызы» әсәрен йаза. Қызыл сорт суған иң беренче Киләчедә чыққан. «Килинчинский сорт» дип атала. Монда саратовский, килинчинский алма үстерәләр. Килинчинский – чыдамлы алма ул. Элек малчылық булған, хәзер игенчелек.

*Сөйләүче: Есенбаева Наилә Ислам кызы (1974 елгы). Киләче авылы*

## Кызыл кар яугач

Әбийем, бабам, әтийемнен әтиләре Қазаннан килгән булғаннар. Минем әбийем – апам 5 йәшендә киткән Қазанға, ә миға әйтә торған иде, мин сине қызыл қар йауғанда әкитәрмен, дип. Мин көттем ғөмер буйы қызыл қар йауғанды, ул йаумады. Бер географтан сорадым. Қызыл қар вабще йауамы, йаумаймы. Ул ничә бер мең йылғамы мужет йаумаға, мужет йаумасқа диде. Әбийем дә үлеп китте, әбийемнен сеңелләре дә үлеп китте. Нигәдер адресын да алмағанмыз йақыннарнын. Әлегә қатлем дә Қазанға баралмый қалдым. Инде быйыл хотя бы Болғарға барыйым дигән идем, шул wақытта Әстерханнан мичеттен алып барады йыл дады автобусмы, зат ман-

ме мулла алып барады бөтен хатыннарды. Анда хатыннар йөрөп уқыйдылар. Быйыл тап шул wақытта мин аwырыдым да грипп мән, баралмадым.

*Сөйләүче: Ибләминова Әҗәр*
*Идрис кызы (1952 елгы).*
*Кызан авылы*

## Йорт салу

Минем туып үскән җирем Лапас дигән аwыл. Анда монә мондый өйләр йуғ иде ул wақытта, саманнан йасалған өйләр иде. Қызыл балчықтан йасыйлар дүрткел зур-зур кирпечләр, шуннан салынған йортлар. Безнен өйөбез бик кечки иде. Әти, зур абый суғышқа китте. Әни өч бала белән қалды. Тормош бик аwыр иде, ничек бар, шулай тордоқ. Йортларда бер зат (*нәрсә*) та йуғ иде, сәке, булса инде, әзерәк түшәкләр. Ашарға да йуғ иде. Мәктәптән қайтқанда, ничек таба алғаннардыр белмим, әни бер кисәк картуп, қаwақ табып қуйса инде, безнен қорсақ туқ була иде. Бақшаларны (*бакчаларны*) қушалар да, читәннәр, талдан туқый торғаннар иде. Ш(ч)итәне тал чыбықларыннан үрәләр. Без ул аwылдан бу аwылға күчтек. Қамыш йабабыз, ағач йуқ. Җикән дигәне дә бар, ул бераз қалынрақ булса да, йомшарақ. Әнийем шунын үзәгеннән алып, матурлап, метр йарымға бер метр даружка туқый иде. Мин шуны кемгә илтеп сатарға белми идем, әпәйлек. Шул җитәнне бер сумға, кемдә дә ақча йуқ алырға. Зәйнәп апаға итә идем: «Апай, алдағын, безгә ипи алырға да акша йуқ», дип. Ала иде, бер сумнан шуны. Шулай итә-итә әкренләп, бақча эшләп, аннары сатып. Аннан үзебезгә тағын қамыштан өй салдық. Қамышны бәйлиләр, пучок дип әйтәбез. Ул қамышны тезәләр. Пучокны тезәбез, и ике йақтан рейка мән (*белән*) қысабыз, тығыз-тығыз итеп қуйабыз. Аннары аны сылыйбыз балчық мән. Менә шулай итеп өй сала идек.

Әл дә ул өйләр бик күп. Хәзер қамыштан салынған өйләр обшитый, шуңа қамыштан икәне күренми. Ул қышын йылы, йазын (*җәй көне*) сәрен (*салкынча*) була. Ул wақытта без салған өйне йылын (*ел саен*) да сылый идек. Балчық белән көздә сылыйбыз. Ул қышын қуба йаңыр белән, йазын шулай үткезәбез, көзен қупқан җирләрен сылыйбыз. Аннары халық әзерәк хәлләнә башлағач, тақта, таш белән обшивайтә башладылар. Бу өй пластин безнеке. 1966 йылларда қалада өйләр бозола башлады. Мондый өйләрне бозалар,

унын урынына йортны зур қуйалар, биш-алты этажлы. Менә шунда анын хуҗалары саттылар. Без қалада торған көйе wаттық, боздық (*сүттек*). Машинаға салып китереп, монда киредән йасадық. Бу йақ пластин бездәйе. Күп кешеләр, шулай өйләре бозолғач, қалада, алып шулайтеп салдылар.

Пластин қалын. Ул инде бороңғы менә безнен өйләрне әйттеләр байлар булған ул wақытта. Тәрәзләре кечкенә, дөрес салынмаған, стеналары да қыйшық (*кыеш*). Бу қалын борынғы пластин. Болар чын ағачтан киселгән, ағачнын хәзер бит майын (*чәерен*) алалар. Ә монын майы үзендә, и ул череми. Бер-берләп тараттық, аннан аны осталар җыйдылар. Теге йағыбызны қамыштан йасадық, йартысын – пучоктан. Анарға хәтле қамыштан түгел, саманнан салғаннар. Хәзер инде ақ таштан салалар, обшивайтәләр дә, ни заттан салынғаны беленмиде инде. Қамыштан салған өйләрне эчен дә, тышын да қайсылары әклиләр (*агартала*р) иде әк (*акбур*) мән.

*Сөйләүче: Бирдиева Гөлфәридә*
*Дуллаян кызы (1939 елгы).*
*Ярлы Түбә авылы*

Быйылны 55 йыл бергә йәшәгәнебезгә. Бу өй қамыштан төзөлгән. Қамышны күлдән алып киләбез. Аннары пучки бәйләдем, аннары каркас, каркастан сон қамыш тықтық. Туғаннар күмәк (*ярдәм*) итте сыларға балчықны өч мәртәбә. Қышта иң җылы өй, җәйдә иң сәрдә (*салкын*). Хәзер таштан сала башладылар. Минем әни Таҗмәрҗән муллабикә (*остабикә*) иде, ул килде Қөрән уқырға. Ул дуwалар (*догалар*) йаза иде. Өйнең фундаментына салды. Почмақларына ақча салды. Шушы өйдә тыныч тормаға насыйп итсен дип дуwа сала иде, үзе йаза иде матур почерк белән. Һәрбер өйдә қөрән китабы бар.

*Сөйләүчеләр: Саҗидә Рәшит кызы (1937 елгы) һәм*
*Әдһәм Габдеразак улы (1935 елгы) Баубековлар.*
*Киләче авылы*

## Гореф-гадәтләр, йолалар, бәйрәмнәр, ырымнар, ышанулар

### *Яңа туган бала белән бәйле йолалар*

Бала туғанда пирбуй балаға ата үзем ***исем атыйды***, эти-әнисе түгел, ә дедушка и бабушка атый. Исемне бабайлар кушады.

Қызның әнисе балаға ***придан*** бирә. Баланың приданы дип әйтелә. Эче тулы була. Қызың китсә, алып бирәсең кол'аска или бишек. Шул бишектә урын-түшәген салып, кийемнәрен салып, шул балаға придан әкиләсен (*алып киләсең*).

Электән инде әбиләр тудырағын булған. Ул әбиләрне ***кендек әйем, кендек мамам*** (*кендек әби*) дийә торған булғаннар.

Кемгә булса да өйөнә керсән, син ул баланын башына исле маймы, май йағасынмы мыйына (*баш миенә/түбәсенә*). Исе килсен дип түгел, қоры чығармаға йармыйды. Шул башына салып ақча бирәләр. Бу обряд ***бала башына ақча салу*** дип атала. Әгәр бала йатқан булса, мендәр астына салалар. Бишек туй, бәбәй туйға кийемдер китерәсен инде.

Урамда син күрсен (*күрсәң*) танышыңны, ***балаға бит күрем*** дип бирәсен, ақча салмаға тийешсен.

***Сау кисү***. Бала йөри башлағанда сау кисәләр. Йөрәлми торады ул. Кем тиз йөри. Қырқыннан чыққанда шул кеше чәчен дә алады. Бабасын йәшен, тормышын бирсен диде. Кем тормыш йақшы, шул кисеп қашый белән обряд йасыйлар – бала йөреп китсен, тормышта бар да йақшы булсын дип. Тиз йөрәде алмый қайсы бала. Болай-болай чайқалып торады, ә йөреп (*йөри*) белмиделәр. Имбәкли (*мүкәләү*) – дүрт айақлап йөрү. Имбәклиме дип сорыймыз. Қырығына хәтле махсус бер кеше ала. Кемнен чәче қуйы – шул кеше алмаға тийеш. Ир кеше.

*Сөйләүчеләр: Мавшиева Мөгөлсем Газиз кызы (1936 елгы),*
*Есенбаева Наилә Ислам кызы (1974 елгы).*
*Киләче авылы*

***Бишек туйы.*** Бәби туйы безнен балалар туған wақытта йуқ иде, қырқы тулдысын дигән. Хәзер бәби булдымы, қырқ көнгә хәтле килергә йарамый. Хәйере булсын да әйтергә йарамый, бүләк тә китерергә йарамый. Қырқ көн булғач, аннан сон инде бишек туй йасыйлар. Ә атын (*исемен*) қушалар сразу. Мулла килә дә азан әйтә. Ә бишек туйда қызнын әнисе китерергә тийеш анарға придан. Кол'аска китерәме, веләсәпит китерәме, әллә ни затлар-әллә ни затлар. Кийемнәр китерәме, әллә нич, ике-өчкә хәтле җиткенче. Аннан йақын туғаннары китерә. Шул инде бишек туй була. Аннан сон йасыйлар бер йәш тулғанын, зур итеп туған көн йасыйлар. Бала

қурқынмасын өчен башына түшәк, мендәр астына Қоран китап салабыз, йә булса бер доға.

*Сөйләүче: Бирдиева Гөлфәридә Дуллаян кызы (1939 елгы). Ярлы Түбә авылы*

### *Өйләнешү, туй йолалары*

***Қыз урлау.*** Йаңа йылны қаршыларға дийеп әзерләнеп торған җирдән кийәүгә шықтым (*чыктым*). Крентишен күлмәк йуwылған, үтүкләп қуйдым кийеп бармаға утырышқа (*аш мәҗлесенә*). Әбийем дә, җиңгәм дә: «Шықма (*чыкма*), қайда барасын, нәрсә бар сиға анда?» – ди. Шыккым килә бит инде, малай. Өстөдә, астыда бер күләк (*күлмәк*), башқа шәл бәйләп, пубайка (*фуфайка*) кийеп шығым киттем. Қайнесеннемнен абыйсы барып керде клупқа. Бийеп тора икән. Миға (*миңа*) йаулық бирде. Йаулық мән (*белән*) бииделәр саратский сазға. Ул миға, мин уға бирдем. Шул көнне кичкә дусларын җыйған да мине алып қашарға уйлаған. Мине алып қачтылар. Шулайтеп 17 йәштә тормышқа шықтым. Анда бер йегет Майлыкүлдән (*авыл исеме*) көтөп утырған тоже, килсәм мине апқашарға орлап (*урлап*). 31 көннө апқашачақ булып килгән, дусларын җийып. Әсийә 30 көннө қашып китте инде.

*Сөйләүче: Бикбулатова Асия Абдразак кызы (1937 елгы). Ярлы Түбә авылы*

***Ниқах туй.*** Wәкилде берәүсен ир биттән (*ягыннан*), берәүсен қыз биттән сайлыйсын. Қызны сорап килгәндә пербуй бер киломы кәмпит әпкиләде. Кечкенә кәмпит шушы. Олы кәмпит әкиләде поднос белән. Өйдәге һәрбер кешегә кийет (*бүләк*). Электе бездә салмадағы йақшы материал ирләргә, анар тағы бер йақшы күләк саладағын иде. Барсына да, менә өйдә минем ничә балам бар – қызым бар, бабама, миға. Шул кәмпитне қыз кечкенә кулокларға салып үзенең дусларына, күрше-тирәгә тарата, сезгә дә йуш булсын дип. Сезгә дә шуны телийем, уңышлы кийәүгә чықарқа (*чыгарга*) йазсын дип, өләштерәсен барына да. Шул өйдә утырқан қалыққа өләштерәсен, кәмпит, шикәр саласын, йөзөм. Шунан қыз белән йегет утырады. Кәзер шулай.

Ул wақытта, безгә ниқах уқығанда, пока син йегеттен өйөнә килми, йегетнен анасына да атасына, апаларына – берәүгә дә күренмисен. Менә әйттереп қуйады сине, пока унын өйөн килмәйсин. Мине сораштылар, ике ай тордым өйдә. Ике ай торғаннан сон мине туй йасап алдылар. Бабамнын өлкөн этисеннән апасы бар иде, шулар килеп сорады. Башта мондағы мамам үзе килде, билге килгән инде. Сөйләшмәгә киләде инде йегетнен анасы, менә фәлән көнне йаучы җибәрәм, шул көнне әзер булыныз.

***Ниқах / никә табагы, күрендек***. Унда саласы бер пыйала (*көзге*), тарақ, нике тастар йаулық. Аны қайнана сала. Әйттереп алған қызға быйақтан киләде шундый затлар. Никә таба (*никах табагы – никах көненә егет өеннән кыз өенә җибәрелгән табак*) киләде, подносмы, тарақ, йаулық булады. Кемдә хәле бар – алтын салады, сипушкәме. Күрендек дип әйтәде. Күрендек – қайнанадан киленгә бүләк.

***Кийәү сый*** – қыз бит (*ягы*) чақырып ала кийәү йағын берничә көндән. Шунда туғыз киләде. Туғыз бүләк, туғыз килгән дип әйтәделәр, туғыз төрле әйбер. Алтын сырға (*алка*) салады шунда. 17 мәлеш булады, берсе йақшы иттереп қызнын атасына дип салына. Аннан 16 мәлеште кисеп-кисеп өләштерәде барсына да. Бер зат (*беркем*) та қалмай.

***Байан***. Йаwлық, йаwлықтын өстөнә қызыл мата (*тукыма<материал*) тегәсен. И шуны җибәрәләр, болай кешегә башларын сыйпыйлар, маңғайларына тидерәләр. «Сезнен балаларығызға да йуш булсын, шундый бәхет тисен», – дип өстәл артындағыларны сыйпап-сыйпап йибәрәләр йаwлық мән.

***Ашарчы, өндәү чәй, өй хақы.*** Арақыды, затты сақлап торады. Почетный кеше. Өндәү чәй – халықты җийасын, башта чәй йасайсын. Қыз бит тә, йегет бит тә туй йасар алдынннан йасый өндәү чәй. 10–15 кеше минем туйымда йардәмләшеп йөгөреп йөри торған, шуларны чәйгә чақыра. Шунда әйтәм: «Син салатларға җавап бирәсен, син пироглар өчен...». Өндәү чәйдән сон сразу ике йә өч кеше өндәү чыға, йәғни өндәү қунақларны чақыручы кешеләр, аларға җәйәләр йаулық, утырған шунда бар халық, өйгә һәм өндәүгә ақча салалар. Өч йаулық җәйәсен дә, шул өч йаулыққа да ақча салам. Ақча тулы булсын дигән сүз инде ул, қоры чықмасын.

Син килден мине туйға чақырмаға, син ***өндәү*** булдын. Өйгә керә, сиға мата, туй қайчан була. Син өндәүчегә бирмәгә тийешсең

акча. Туй өйгә бирәсен ***өй хақы*** дип атала, хужаға. Чақырған кешенен ақчасы үзенә қала. Хәзерге wақытта ул йөз сум. Илле сум өйгә, илле сум өндәүгә. Монда өндәү булып чыға жиңгәләре, тәтәләре (*апалары*). Өч йаулық – берсе өндәү, ике – өйгә. Бу обряд – өндәү  әй.

***Килен чәй*** – килен төшкәннән сон, икенче көнне чәй. Килен чәй қайнатып, қалған халыққа, айақ өстөндәге халықны чақырасын икенче көне. Киләче татарларында килен борон-бороннан биргән қара чәй. Ул тақта чәй сөт, төз мән (*белән*). Май мән сызықны айақларға (*касә*) саласын.

*Сөйләүчеләр: Мавшиева Мөгөлсем Газиз кызы (1936 елгы),*
*Есенбаева Наилә Ислам кызы (1974 елгы).*
*Киләче авылы*

***Туғыз бирелү.*** Қашып, йабышып килгән қыз, үзен килгәнсен, ничек телисен, шулай йәшә дигән кебегрәк монда. Қайнанасы бераз әйтерәде. Қашса, туғыз бирелми, бүләк бирелми. Хәзер ике йақның килешүе буйынча. Қыз үзе йабышып чықса, қашты, диләр монда. Қашса, туғыз (*бүләк*) бирелми. Но қызның дәрәҗәсе особо булмай, қайнана-қайнатасы әйтә: «Ничек килдең, шулай йәшә», – ди. Йер безгә, йер сезгә, бүләкләр алалар. Йау килмидер, пока аны шақырып алмыйлар. Йулашу бездә туй булғандан сон, бер атна буйы қызнын өйөнә баралмыйлар. Әнисе шақырып ала да кийетләп, йулаша ди инде. Ике йақтан да туй wақытында бик бүләкләр бирелә, расходлар бик зур. Процедура бик озак ул. Бүләкләр конкретно список буйынча барырға тийеш. Хәзер инде, Аллаға шөкөр, қызымды кемдер кийәүгә ала дип, барсына да риза була – қыз бит (*ягы*) шулай. Хәзер уйлап чығардылар: кийәүгә дә кийет – туғыз – бирәделәр, баштанайақ кийендерәделәр, эчке кийемгә қәдәр. Туғыз туже. Йөзөк, балдақ... – тотош йегетте кийендерәләр. Кийәүгә туғыз биреләде, урыс әйтмешли, қалы́м инде.

***Придан килү.*** Қыз йегет өйөнә килгәч, бернәрсә дә сорамаға тийеш түгел. Придан полностью булырға тийеш, қадақны, балғаны (*чүкечне*) бөтөнөсен үзе алып килергә тийеш. Придан килү – айырым ритуал, туйға қәдәр ике-өч көн алдан придан киләде кийәүнен өйөнә. Кийәүнен өйө буш лампочкасына қадәр. Қайчан қыз бит үзләре алып киләделәр, үзләре тезәделәр анын барысын да, ә йегет битләре, йегет халығы, берәр нәрсә орлый (*урлый*) да, без са-

тып алмаға тийеш. Придан килгәч, ике әбей сақламаға қалалар ул әйберләрне, кич қуналар шунда. Керосиновый лампа булырға тийеш, ул өстәлдә йанып қалмаға тийеш. Әгәр ул булмаса, өй кирасин лампысы да йуқ икән дийәрләр.

*Сөйләүчеләр: Үтәлиева Ильмира*
*Мөхлис кызы (1976 елгы). Майлы Күл авылы.*
*Мөхәримов Рамазан Рафикъ улы.*
*Җәмәле авылы*

***Нәселгә тап төшермәү, шәҗәрә барлау.*** Қызнын ата-анасы булмаса, туғаннары, нәсел җийылышып, қызны кийәүгә бирергә тийеш, нәселгә тап төшмәсен өчөн. Алай булмый икән, қыз йабышып китә, қашмаға. Феврал'дә башлана ақча-мақша дип мадур (*помидор*) үстерү, нуйабердә бетеп, туйлар башлана. Аwыр булса да, бик қызық ул. Туйлар көз көнө уздыралар мадур үстереп сатқан ақчаларға уздыралар. Туйға җийынғанда ир-атның хақы хатынын матур итеп кийендереп китермәгә: кийенеп-йасанып, булған бөтөн алтыннарын да тағып киләләр. Хатын-қыз бер өстәлгә, ир-ат бер өстәлгә җийылып утыралар, үзләренең шәҗәрәләрен искә төшөрәләр, нәсел ағачларын сөйләйләр – онотмайлар. Бабам, қаһам, олы тәтәм... дип, бөтөнесен онытмыйча тезеп чығалар. Син қаһам, син монығ олы апасы һ.б.

*Сөйләүче: Үтәлиева Ильмира*
*Мөхлис кызы (1976 елгы).*
*Майлы Күл авылы*

***Сүз қуйышу.*** Бер-берсе белән аралашқан йәки йыраграқ туғаннарның қыз һәм ир балаларын 10–12 йәш'ләрдә сүз қуйышып (*димләп*) қуйғаннар әзилдә (*элек*). Балалар үсеп җиткәнче аларның ыруын җиде арқаға (*буынга*) хәтле тикшергәннәр. Йәш'ләре җиткәч, аларны өйләнештергәннәр һәм йәш'ләр күнгән. Аларға башқа белән очрашырға йарамаған.

***Тел бүләк.*** Қызға йаучы булып ата йақның йақын туғаны – йегетнең атайбикәсе, этисенең тәтәсе (*апасы*) барырга тийеш була. Култығына қысып кечке конфетты – *тел бүләк* дип атала (3 кг чамасы).

***Қалын.*** Қыз йағыннан да ата-ана йағыннан йақын туғаннар чақырыла, алар қалын, сөт хақы күп сорайлар. Қалын дип әйтелә, бирнәсе күп, затлы әйберләр булғанлықтан һәм сөт хақын да мул биргәннәр. Қалыны җиңел булса, бер қабатын биргәннәр, хәлләренә

қарап. Ризалық қуйышканчы чәй дә эчәрмәгә, тәғәм дә қапмаға йарамаған. Ризасызлык билгесе булып саналған туғанлашмағаннар. Қайчақларда бер атнаға тартылған. Йақын туғаннары да зур, затлы әйберләрен алып бирәм дип сүз қуйышқаннар.

***Аwыз берлек.*** Ризалашқач қына туғанлашу билгесе итеп конфетны йаwчы атайбикәсе алдына салған ул, чигеп өстенә қуйылған күлмәклек йәисә затлы йаwлықны алып, башын салып сыйпап қуйған. Минем дә балаларыма шушындый сый-хөрмәт насыйп булсын, ғайлә қорсыннар, затлы кийетләр (*бүләкләр*) өстәүле булсын дип. Бу конфеттан – тел бүләктән – йәшләргә ашарға йарамаған. Конфетны, шикәрне сындырып ике қода-қодагый ашағаннар, аwыз берлек (*уртак тел табу*) билгесе булып саналған.

***Туғыз, сөт хақы.*** Қалынны туғыз дип тә әйтәләр, затлы әйберләре туғыз булырға тийеш булған. Моңа кийем-салым, алтын, көмеш әйберләре саналған. Сөт хақы қызның әнисенә имезеп үстергән өчөн тийеш була. Қыз йағы да кийәүгә кийәү сый туйын йасарға, һәм кийәүгә йақын туған қәрдәшләргә затлы кийетләр бирергә тийеш була. Әгәр дә туғыз бирмичә қызны урлап алып қачсалар, зур кийәү сый туйын йасамағаннар. Кийәз (*сыйлы*) күршесе килсә, туғыз биреп, әйттереп алғай иде дигәннәр.

***Бит күрем.*** Сыйла мине, сыйлармын сине, дийелгән. Қызны йегет аwылыннан йәрәшеп қуйсалар, озақ wақыт үтмичә, бит күрем йасағаннар кийәүгә. Кийәүне чақырып алып қунақ иткәннәр. Ул йалғызы килмәгән, җиңгәсе һәм йақын аданашы икенче арқа (*буын*) ир туганы, бер йәки ике дус йегетләре белән қызға бүләген алып килгән. Кийәү қызның өлкән буын туғаннары белән йақыннан танышқан, моңа қәдәр урамда йә қайда булса да күрсә, тиз генә қачарға, йәшеренергә тийеш булған. Өлкән йәштәге қызның йақын туғаннарын сыйлау, тәртипле, тәрбийәле саналған. Әгәр кийәү йәшеренми икән, аны ойатсыз дип санағаннар. Туйны элек қыз йағы йасарға тийеш булған.

***Өндәү алдысы.*** Бер-ике атна элек өндәү алдысын (*туйга чакыру*) уздыралар. Өндәү алды хатыннар белән уза. Туй көнен билгеләү һәм кем чақырырға тийешлеген. Өндәүчегә өй хуҗасы матур йаwлыққа ақча салып бирә, туталарның берсе аны йаwлық очына бәйләп: «Җиңел чығып, аwыр қайт, ақчаны мул бирсеннәр», – дип өстәп қуйа. Өндәүче икенче көннән үк йазылған кешеләрне чақыра башлай.

***Ҡади аҡча.*** Туғыз туй зур ғына ҡорылған шатырда була. Шатырны күмәкләшеп ирләр йасайлар, бизиләр, шатырығыз әзер, безнең эш бетте, дип, бераз күңел ачар өчен аш әзерләүчеләрдән, өлкәннәрдән поднос тотып кади җийалар. Ҡадани хәл (*хәлеңә*) ҡарап дийүне аңлата, ҡади аҡча җийалар.

***Кийәү сый, туғыз туй.*** Туғызны, зур биркәч конфетны олы йәштәге ҡодалар, ҡодағыйлар, җиңгәләр, өйләнешкән йәштәге йаҡын туғаннар, тату күршеләр алып бара. Ҡыз йағыннан булған җиңгәгә айырым подноста конфет бирелә һәм күләклек (*күлмәклек*) бүләк салына, җиңгәлегең хәйерле булсын, диләр. Ғайләдә булған барлыҡ кешеләргә дә бүләк, затлы әйберләр, бишектәге сабый балаға, армийә сафында йәки йыраҡта йәшәүче бер туғаны булса, аларға да бүләк алып киләләр. Китергән конфетны, туғызны, аҡчаны өстәлдән-өстәлгә йөртеп күрсәтеп чығалар. Конфет табағына аш тараталар, буш җибәрергә йарамаған. 9 табак-пәхләвә, лаксалва (*чәкчәк*) нуғай бәлеш. Ҡатпар пәрәмәче (*кат-кат камырлы, мичтә пешерелә*) бадамгел, бер поднос пылау, чикәр чүрәк, бадам бүрәк, ҡатланчыҡ. Кодағый утырған өстәлгә ҡуйалар да алып китәләр. Туйның икенче көне табаҡ ҡайтарып (*китереп*) килә 2 кеше. Аларға кийет бирелә, туталар чаҡырыла. Шатырда матур ғына марш уйнап тора. Кийет (*бүләк*) бирү башлана. Туғанлыҡларына ҡарап, кийет бирәләр. Кийәүгә бирә торған бүләкне дә анасы алдына китереп салалар. Шатырда утырған ике йаҡтан да чаҡырылған җәмәғәткә кийет бирәләр. Конфетны да азазлап барлыҡ кешеләргә өләшәләр. Аҡча чәчәләр, ки(б)етләрегез хәйерле булсын дип. Башҡа балаларығызныҡын да кийегез, көйәз (*сый*) күрегез, игелекләр, муллыҡлар булсын дип.

*Сөйләүче: Гомәрова Мәйсәрә*
*Хәким кызы (1936 елгы).*
*Җәмәле авылы*

***Байанды бастыру, кийет бирү.*** Бездә бүләк бирә торған ғадәт бар, аны кийет диләр, килгән кунакларга. Бүләкне өләшер алдыннан өндәүче (*туйга чакырып йөрүче*) шушындый матур йаулыҡ белән байандыны бастырып чығаралар бөтөн килгән ҡунаҡларға барсына да. Маңғайларына тидерәләр, безнең дә балаларға шушындый туйға насыйп булсын, дип. Аннары кешеләрнең алдына аҡша

чәчәләр. Аны җийып-җийып алалар. Безнең дә балаларға шулай насыйп булсын, дип, акчаға моһтаҗлык булмасын дигәнне аңлата. Қорәнне ашып (*ачып*) уқый иде.

*Сөйләүче: Гомәрова Мәйсәрә*
*Хәким кызы (1936 елгы).*
*Җәмәле авылы*

***Туй.*** Бит күрем (*яшь киленнең битен ачып халыкка күрсәтү*). Ул қашып киткән қыздыкы, әйттерелгән қыздықы түгел. Қашып китә – қызды о(ы)рлый диләр, сагласийы була да, менә шуға бит күрем – қызды күрсәтәделәр. Ә әйттереп алғанды туй көндө күрсәтәделәр, қыз килгән көндө. Қызнын битен күрсәтәделәр, аннан әниләренә кийет бирә. Без беребез дә қашып бармадық, әйттереп бардық. Алып қачкан ул – йөрәделәр дә, сүләшәләр, туй йасасылары килмәсә, тизрәк өйләнешәселәре килсә, шул көннө үк әниләре әйтеп китәде, қода киләм диде. Утырыш йасыймыз. Несагласийы йасый инде кергәндәме. Кергәндә әлегә хәтлем дә бар обычаи кергәнемнен ишек алдына ақ йаулық җәйәделәр, эчерәделәр, тәтле булып торсын дип бал қаптырадылар, йуллары ақ булсын дип сөт эчерәделәр. Дус-ишләре мән шул көнне үк берәз ғына утырадылар, аннан инде икенче көн әниләре-әтиләре үзләре сүләшәделәр. Қул алмаға киләделәр. Йегет биттә бит күрем булады. Икенче көннө утырыш була, вечер йәшләрнен. Һәр кеше үзенен wақытына қарап әзерләнеп, бер атнадан сон, хатыннарға утырадылар. Унда қоры (*фәкать*) қатыннар – әниләре, туғаннары, дуслары. Қыз қул алып (*күрешеп*) чығады, йегет биттән бер җиңгәде, қыз биттән бер җиңгәде қатыннарның қулын алып чыға. Қызды, анын битен күрсәтәделәр. Аннан туй була йәшләрнең, аннан қыз биттә пирбым кийәү сыйлыйлар. Беген қыз қашып килде, ди, қартларнын мамай туйы була. Аннан күпмедер wақыт узғач, қул алма барып килә, аннан қыз биттә кийәү сыйлыйлар. Ул ғәдәтләр әле дә бездә бар.

***Почетный туй.*** Бер айдан сон йегет биттә почетный туй була. Қәрдәшләр ақша ташлыйлар, чыға поднос тора, анда арақы саладылар. Кем күпме ташлады. Менә фәләнчә бусы мен монет ташлады, рәхмәт изгелеге қайтсын, дип шолай әйтәде. Бер румка қойып эчертәде, шунын эченә кем ничек, кем мен, кем өч мен, йақын қәрдәшләр биш мен ташлыйлар. Йақын кешеләр об'азателно ун мен инде. Йәш, йә йалғыз кишәкләр (*киленнәр*) биш йөз таш-

лый, кесәсенә қарап инде. Шундый почетный була. 300–400 кеше шақырыла почетныйға. Чақыру қағызы йазыла шул көнгә.

***Ризалык алу, тел бүләге***. Бездә әwәлдә әйттереп барады, аннан барғанда пербуй сөйләшәде, йисли ул риза булса, чәй эчәде. Риза булмаса, чәй эчмийде. Мине әйттереп барғанда, әйем үзе барған лично. Шунда әйем әйтәде: «Қодача, чәй салым, чәй эчик». Әйем әйтәде икән: «Йуқ қода, қулынны бирсән, wәғдә бирсән, – чәй эчәм. Қулынды бирмәсә, риза булмаса – китәм». «Юк, риза», – ди икән этийем. Шуннан киредән, чәй салып, эчеп қайтқаннар. Риза булмаса әйттереп барған кешеде, ризалық итеп бернәрсә дә бирмиде. *Тел бүләге* дип берәз затмы (*әйбер*), кәмпитме (*кәнфит*) алып барадылар. Метрмы, матамы (*тукыма* < *материал*), коробка кәмпитме – ни зат булса да салына. Кәмпит болай халыққа салына. Болай хәзер инде. Безнен wақытта бераз ғына инде тел бүләге итеп. Хәзер кийет һ.б. затлар күбрәк салып барадылар, тел бүләге дип әйтәделәр.

Килгәч, башта «Хуш килденез!» – дип қаршы аладылар. Анан: «Сез белеп торғандырсыз, без нийә килгәнмез. Риза булсаныз, сезнен қызығызды әйттереп килдем», – дип әйтәмез. Шунда әнисе қыз биттен ни зат дип әйтәде.

Керәсен дә барасын да утырасын, бер зат (*беркем*) та йуқ анда. Байанды қыз кергәндә була, регистрацийәдән қайтқанда, өйгә керә дә утырадылар. Әйткән булады, улар инде әзерләнәләр, чәй қайнаталар, пешерәләр. Әйттереп килгәндә в курсе булады.

Аннан сон туй булады, әйттерде бу қызны. Аннан сон туйға мәшәқәтләнәделәр. Ризалық итеп әwәлдә метражом метр бирә торған иделәр, хәзер ике йақ әниләре энисен кем кофта, кем жемпер бирәде. Әwәлдә ундый зат йуқ иде. Бер материал бирәде и булды, қор шыкма итеп, қоры шығармыйлар иде. Бу илле йыл элек. Материал була әйттереп килүчеләргә. Ул қайтып әйтәде. Әйттердем шул қызды, ул риза булды, дип.

***Кийәү сый:***

***1. Хатыннар-қодағыйлар туйы***. Аннары әзерләнәләр кийәү сыйға. Қыз биттә (*ягында*) қодағыйлар аладылар. Хатыннар туйы булады башта. Анда қодағый бер йегерме-утыз кеше алып барады үзенен йағыннан. Кодағыйлар туйы көндез була, иртәрәк, байанды (*ак яулык, чите кызыл тасма белән сугылган*) бастырады. Аны бер туғаны зур кеше баса инде. Или ирнен тәтәсе, кийәwенен. Или үзенен тәтәсе, йә җиңгәсе. Безнен балаларымызға да йуш булсын

дип тезелеп утырған қунақлардын маңғыйларын сыйпау, тидереп алу була ул байанды бастыру. Әwәлдә кич була торған иде. Байанды бастырып булғаннан сон инде, кийет (*бүләк*) бирәде, шикәр бирәделәр айақтан (*савыт*), кешегә бүләккә китәде подноста. Қыз биттә кийәү сый булғанда подноста шикәр китәделәр. Йегет биттән зур поднос белән шикәр, кәмпит, җимешләр әкитә. Бу кодағыйлар туйы. Кийет бирәде, шушы подноста килгән шикәрде бүләделәр шатырдағы (*чатырдагы*) халыққа, айақларға бүлеп-бүлеп кечкенә пакетларға салып бирәделәр. Анары кийет бирәде – материал, тастамал, башйаwлық – кем ничек инде. Кийетне җиңгәсе, әнисе, апалары шатырдағы бөтөн халыққа бирәделәр. Аннан сон манит (*акч*а) чәчәделәр, кийетләремез хәйерле булсын дип салалар, әйтәделәр. Башта қыз бит чәчәде, шуннан сон қодағыйлар чәчәде. Хәзер инде қыз бит кийет биргәннән сон чәчәде. Анда балалар да буладылар, алар ақша җийадылар, җийып йөрәделәр. Кийәү сый бетте. Ашадылар, эчәделәр, пылау бастырадылар, пахлава, лақсалба, чәкчәк ... Әwәлдә бөтөн туғаннар җийылып шул затларны үзләре пешерә иде. Хәзер заказывайтәделәр, ризык төрләрен пешерә торған хатыннар бар. Ақшанды түлисен дә аласын.

***2. Кийәү сый.*** Бер ике-сәгәттән кийәү сый башланады. Кичке 9–10 нарда шул қыз биттә. Пирбуй кийәү килеп керәде шаторға, керми тора башта, уны күтәрәләр дә кергезәләр.

Менә шулайтеп йырлыйлар бездә, қаршы аладылар:

*Ничек килдегез сез безгә,*
*Батмайынча диңгезгә?*
*Қәдерле қунақ сез безгә,*
*Ни хөрмәт итик сезгә.*

*Ничек килдегез безләргә,*
*Рәхмәт йаусын сезләргә!*
*Тағы да бераз килмәсәгез,*
*Чығар идек эзләргә.*

*Сезнең алтын алмағыз,*
*Безнен алтын алмабыз.*
*Безен алтын алмабызны*
*Хур итәргә алмағыз.*

Аннан, йауап қайтарып, йегет бит йырлыйды:

*Сезнен алтын алмағызны*
*Хур итәргә алмабыз.*

Әwәлдә, безнен wақытта қаwаллар, саз, саратский саз, скрипка иде. Безнен аwылда да кешеләрдә бар ул. Сазды тартадылар, қабалды. Хәзер музыка.

Аннан шатырға кийәү керәде. Кийәwде күтәреп кергезәделәр. Ул wақытта қыз өйдә була. Хәзер бергә утырадылар. Ул безнен бороңғо wақытта без бергә утырмадык. Хәзер кийәү сыйда бергә утырадылар. Өстәлләр әзер, арақыды қойадылар, сыйларға тотоналар барсын да. Кийәүгә бүләк бирәләр. Безнен wақытта кастүм, брүкә (*чалбар*), соңыннан велосипит бирәделәр иде. Хәзер баштанайақ бирәделәр, кийәүнен әнисенен алдына саладылар подаркаларны. Қызға да шулай бирәделәр. Уға туғыз бирәделәр: күлмәкләр, шуба, итеге дә, пәлтәсе дә. Бар да бар. Бирәделәр дә туй башлана. Ачап-эчеп утырымыз инде.

***Кийәү арақысы***. Бераз утырғанннан сон, қызның ағалары кийәү арақысын сорый башлайлар, «кийәү арақысы тәмле була» һ.б. дип. Кийәү арақысына китәделәр. Ул арақыны иң йақын туғанына тапшыра. Кемдә икәнлеген әкренләп беләләр һәм аның қаршына поднос тотып барадылар. Кийәү белән бергә сумқаға ленталар бәйләнгән 12 бутылка салып, арақы, бер кан'йак, шомпанский, йақшы вино салып бирәделәр әнисенә, и коробка конфет. Ике жиңгәгә айырым сумқада бер канйак, конфет-мазар, хәзер кәрзинкәгә салалар.

Кийәү сыйда утырғанда шундый йырлар йырлыймыз:

*Сез икегез, икегез,*
*Икегезнен битегез.*
*Икегез дә пар килгәнсез,*
*Тигез ғөмөр итегез.*

*Мөгөлсем, Мөгөлсем,*
*Исемнәре Мөгөлсем.*
*СССР төзөлгән кебек*
*Тормышығыз төзөлсен.*

*Сезнен қызығыз алчәчәк,*
*Безнен улымыз гөлчәчәк.*
*Алчачәк белән гөлчәчәк*
*Тигез ғөмөр итәчәк.*

Шундый итеп йегет белән қызға күп итеп йырлыйсын. Ашықмаған шунда қаладылар, ашыққаннар китәделәр.

***Нихақ*** (*никах*). Нихақ булады туйда, әйттергәннән сон қодағыйларны қыз бит алады. Потом бер айданмы йегет биттә була. Борон рисур арбаға, аннары грузовой машинаға утырып киләде. Ол биттә дә шундый туй булады. Кийет бирде, ақча чәчте. Қыз биттен қодағыйлары киләдер хәзер монда. Йегет белән қыз көндез регистрациягә барып киләделәр, аннан сон көндөз қатыннар туйы булады.

Тулырақ әйткәндә, йегеткә киткәнче, ***қыз биттә*** нихақ уқылады. Нихақ кемдә ничек. Кемдә иртән сәғәт 8 дә булады. Аннан йегет киләде машина менән, қызды алып китәде йазлышмаға. Нихаққа киләде ике wәкил, берсе әни биттән, берсе әти биттән, как свидетел'ләр. Бер табақ баwырсақ пешереп алып барадылар. Малированный табаққа салып. 12 табақ алып бардық қызға. Аннан өстөнә сала бер косынка йаулық булса да баш бәйләмәгә қызға, тарак, пийала (*көзге*), қызға қарамаға. Аwылнын мулласы уқый да. Қыз қалады әзерләшергә. Wәкилләргә кийет бирәде. Ике күлмәк бирәде ике wәкилгә. Қыз әзерләнәде. Туғаннары, дуслары киләде. Йегетнен машинасы готовый булып торады. Йегет машина мән қышқыртып килеп, бераз утырадылар да, теләкләр-мазар, қызды җитәкләп алып бара йатқанда, қыздын айағынан бер туфләсен йәшерәделәр. Йегет тапмаға тийеш. Тапмаса ақша бирәде. Хәрбер басқычтан төшкән сайын, ишекне ачқан сайын выкуп. Йегетнен башын әйләндереп бетерәделәр. Шулайтеп алып китәде загска монан туры.

Аннары – ***йегет биткә,*** қаршы алалар, сөт эчерәделәр, бал қаптыралар. ақша чәчәләр кергән қызға. Ақ йаулық җәйәләр идәнгә, бастыралар уң айағы белән. Қыз битнен әниләре барадылар бүләкләр белән йегет биткә. Кийенеп чыққан килен қулларын алып чығадылар утырғаннарнын. Шатырдын эчендә әниләре, қунақлар утыра. Йегеткә кәләпүш кигезеп, қызда фатасы бар. Шуннан шықарып қул алдыралар. (Ә безнен заманда безгә шыкмаға йарамыйды, бүлмәдә утырдық, анда туй була бирде, минем йанымда дусларым утырады, кийәwем килеп, хәлемне белеп киләде). Бит күрем, кийет бирәделәр, монет (*акча*) чәчәде, ашап-эшеп қатыннар китәде. 1–2 сәғәттән сон 9–10да ***йәшләр туйы*** башланады. Бөтөн йәшләр шатырға шығадылар. Невес-

та бийергә шығады уже. Бийегәндә ақша чәчәделәр. Ашау-эчу, бийүw, йырлау.

*Сөйләүчеләр: Бикбулатова Мәгърифә Сәйфулла кызы (1939 елгы),*
*Бикбулатова Камилә Мәүлетгали кызы (1936 елгы),*
*Бикбулатова Хәдичә Даир кызы (1942 елгы),*
*Ибләминова Әҗәр Идрис кызы (1952 елгы),*
*Ильясова Халидә Фәрит кызы (1938 елгы).*
*Кызан авылы*

***Туйда ақча җыйу йоласы.*** Туйға барғанда эспей (рус. *специально*) бер кеше бар. Ул йазып утыра кем ничә сум китергәнен. Шул ақчаны мин сиңа 3 мең әкилдем. Син миға кайтарырға тийешсең. Әгәр туйға килмәсәң дә, син шул ақчаны миңа кеше аша тапшырырға тийешсең. Ул кәғәзләрне кешеләр 20 шәр йыл сақлыйлар.

*Сөйләүчеләр: Есенбаева Наилә*
*Ислам кызы (1974 елгы).*
*Киләче авылы*

***Кыз киткәндә.*** Ул wақытта әти-әниләре сөйләшеп бирә торған иде, әти-әни кемне йаратты шуға, сөйгәненә бирмийчә. Шуға риза булмаған булып қыз җырлыйды:

*Әтийем-әнийем, риза бул,*
*Бер тақтаңны җәлләдең.*
*Сөйгәнемә бирмәдең.*
*Бер тақтаңны җәлләдең.*
*Сөйгәнемә бирмәдең.*

Боронда йылап китәде торған иде қыз. Зур бирәзә (*плащ*) кийеп китә торған иде борондын, ул 50 йыллар инде. Қыз уртада тора, ике йағында ике дусы торады. Кергән кеше болайтеп күрешәде. Без барғанда шулай итеп бардық: қыз ике йағында, анау саз (*гармун*) тартады, шуға қыз йылыйды шул йыр-сүзләрне әйтеп. Қыз йанына бибәсе кереп, қошақлый да йылыйды. Саубуллашып, бәхете булсын, тигез ғөмөр итегез, куша (*бергә*) қартайығыз дип. Әти-әнисе кергәндә, сапсим да йылатады.

*Сөйләүчеләр: Ибләминова Әҗәр Идрис кызы (1952 елгы),*
*Бикбулатова Хәдичә Даир кызы (1942 елгы),*
*Ильясова Халидә Фәрит кызы (1938 елгы).*
*Кызан авылы*

***Қоран қапта*** (*Коръән китабын салып кую өчен тегеп әзерләнгән кечкенә букча*) әүәлге Қоран, һәрбер өйдә бар ул, әнийемнән қалған. Қызлар кийәүгә чыққанда шулай итеп, затлар (*әйберләр*) салып, тегеп, постел-мазарларны алып килгәндә, әбизәтелне баш битенә (*баштан югарырак стенага*) шушы Қорәнне эләләр. Сондоқ (*сандык*) та һәрбер өйдә бар. Бер йыл йөргәч, йаwчылар килде. Ике йаwчыбикә килде. Кийәүгә, туғаннарына бүләкләр аласын, поднос мән нуғай бәлеш алып барасын, ий (*өй*) эченә дигән бүләкләр алып барасын. Йаwчыларға бүләк биреп қайтаралар.

*Сөйләүче: Баубекова Сажидә*
*Рәшит кызы (1937 елгы).*
*Киләче авылы*

***Жыйын ағасы.*** Аwыл дамадасыннан башқа йәшләр арасында «жыйын ағасы» сайлағаннар. Ул кешене, «жыйын ағасы – күпер бағанасы» дип тә әйткәннәр. Жыйын ағасы булған кеше һәр йақтан да тәртипле, халық арасында абруй қазанған күренекле кеше булырға тийеш булған. Жыйын ағасы йанында 5–6 йегетләр сайланған, алар жыйынның тәртипле булуына жаwап биргәннәр. Қызларны өйләренә барып ата-анасыннан сорап, жыйынға алып килгәннәр һәм китереп тапшырғаннар.

Әгәр қыз күрше аwылға, яки башка аwылларға, читкә кийәүгә чыға икән, кийәwдән қызны йаманаттан сақлаулары өчөн кийәү арақысы алғаннар (пакьлыгы өчен).

*Сөйләүче: Гомәрова Мәйсәрә*
*Хәким кызы (1936 елгы).*
*Жәмәле авылы*

### *Үлгән кешене соңгы юлга озату һәм искә алу йолалары*

Бикбулатова Мәғрифә Сәйфулла қызы – безнен аwылнын илтәйесе (*муллабикәсе*), кораннәргә йөриде ул. Қоран (*Коръән*) уқыйды, мәйетләрне йуындырады.

Мәйет үлсә, илтәйенде шақырады. Туғаннары жийылды, утырады. Кичкедән (*кичен*) үлсә, хатыннар төнәтәделәр (*төн куналар*), уқып утыралар. Ир үлсә, ирләр зат итәде, төн буйы йанында утырады, белгәнен уқып. Икенче көн туған, қәрдәшләре жийылалар, өй тулып утыралар, хатыннар күбрәге. Шунда бу илтәйемне – Мәғрифәне – шақырталар. Илтәйем килә, доға итә. Аннан кифеннек-

ләрен пешмәгә қарый. Хатын кешенекен бу пешә (*кисә*), ир кешенекен – ир пешә. Хатын булса, бу барып кифеннекләрен пешеп (*кисеп*), әзерләп, анан сон йуwындыралар. Кечкенә кеше булса, йанында биш кеше, зур, симез булса, җиде кеше кереп йуwындыралар. Тә(һ)әрәтләнеп керергә кирәк. Кергән кешеләр чиста булмаға тийеш. Йуындырып, пешеп қуйған кәфеннәргә кәфенниләр. Биш кеше бар да йуалар: бер кеше су қойып торады, илтәйен уқып торады, башқалар йуалар төрлө затын (*төшен*), сабыннап йуwып, чайқандырып. Аннан қоротып, сөртөп, кәфен эченә урайлар мәйетне. Бер 19 метрлы ақ кәфенгә урайлар. Өстөнә йәшел йабылады. Табутқа салалар. Баба түбәгә (*зират*) әкитәләр, күмгәндә табутны күммәйләр, табут белән әкитәләр, ә салғанда җиргә болай салалар. Унда қазылган, әзер булады. Шунда салып, илтеп, монда инде мамайлар (*әбиләр*) қоран уқыйлар, шушы илтәйем. Табут өстөнә йәшел мата (*тукыма*) йабылады. Хатын кешенен баш-битенә шәл, йаwлық йабылады, хатын икәне билгеле булсын дип. Шатыр қормыйлар. Түбәдә әйтәләр шымылдық мән зат итәләр бар да. Әүәлдә шымылдық (*мәет өстенә көймә кебек ясап каплау*) салып, хатын кешеде сүтеп кергезә торған булган ләхеткә. Хәзер шымылдықсыз. Монда шушы илтәйем уқып утырады шушы мөнәҗәтләрде, қоран, тәбәрәк уқыйды. Әкиткәндән сон (*алып киткәннән соң*), әле җырлап күрсәткән «Ана wәсийәтен» уқыйды, аннан тәбәрәк уқыйды. Түбәгә инде барып җитте буғай дигәндә тәбәрәк уқымаға башлый. Бу үлемде озату булды инде.

*Сөйләүчеләр: Бикбулатова Камилә Мәүлетгали кызы (1936),*
*Бикбулатова Хәдичә Даир кызы (1942 елгы),*
*Ибләминова Әҗәр Идрис кызы (1952 елгы),*
*Ильясова Халидә Фәрит кызы (1938 елгы).*
*Кызан авылы*

Қаберчеләр билгеләйде, 7 кеше булады. Алар – иң йақын кешеләрен чақырасын. Эспис (рус. *специально*) ләхет чығарасын. Аннары алдына тақта қаплыйлар, эченә балчық кермәсен дип.

Иркәк кешедә (*ир-ат*) ирләр, хатын кешедә (*хатын-кыз*) хатыннар, әбиләр утырады, туғаннары утырады. Сақлап утырады. Пока үле йатқанда бер зат та уқылмыйды. Үлене йалғыз қалдырма йарамый дип сақлап утыралар. Мәйетне чыққанчы күтәреп апчығалар. И һәрберсе чиратлап, йөгөреп-йөгөреп барып ике адым сайын. Мәйетте узып китмәгә йарамый.

Әгәр дә қаберче или өстөндә утырған кешесе килми қалса, анарға азықны җибәрәләр өйөнә.

Йыл қораны булғанда қашығын да җибәрәләр. Йуындырмаға биш кеше кирәде. 7 кеше, шуларға нәлмәкләр (*тәлинкәләр*) әзерлисен. Нәлмәк салып апарасын.

Үле ашына махсус кеше чақырып йөри. Ә Җәмәледә (*авыл исеме*) көнө буйы, и чақырмыйча киләләр. Садақаны алып китәләр. Ә Җәмәледә алып китәргә йарамый. Аларда алып китү йуқ, ашадын и киттен. И ничә кеше килерен белмисен.

***Башын савуга бару йоласында акча***. 7 көнгә хәтле киләләр на соболебезнование. Залда халық утыра. Килгән кешеләр қулын алалар (*күрешәләр*), башың сау булсын, диләр. 5–6 кеше бара җийылып-җийылып керә на соболебезнованийы. Алып киләләр ақча, мата. Ақчаны кәғәзгә салалар да өстәлгә қуйалар, қулға бирергә йарамай. Аннары ул қәғәзләрне йағалар. Утырдың, доға уқылды, чығып китәсен. 7 көнгә хәтле. Бу и соболебезнование и матерал йәрдәм.

Монда үле ашына туқмач түгел, ә пылау пешерәләр. Ниқах туйына пешергәндә мин алйапқыч йабам алдыма, ә үлегә алйапқыч йабып пешермәгә йарамый икән шул азықны пешергәндә.

Азықларны өстәлгә тезеп салалар, ә нәлмәкләргә түгел. Өстәлнең қырыйына озон тастамал салалар. Ул тастамалны алдына салып утыралар. Тоз қуйылады. Йидесендә тозды саласын бер айаққа, йылы җиткенчен аны сақламаға тийешсен син. Қоран тастарханы була, үзеннен кәпеннегенненән кисеп алмаға. Тозды қоран уқығанда һәрберсе өч бармағы белән қаба.Үлене қоранен укытқан сайын шуны шығарасын. Йылы узғаннан сон тозға қушасын, шунын йәшен бирсен дип қарт кеше булса. Хәзер мәчетебез булғач, мәчеттән чығаралар. Қорбанғали Мохаҗимович – әлеге мәчет төзелгәч, беренче мулла.

*Сөйләүчеләр: Мавшиева Мөгөлсем Газиз кызы (1936 елгы),*
*Есенбаева Наилә Ислам кызы (1974 елгы).*
*Киләче авылы*

### *Ураза гаете, Корбан гаете*

Ураза, қорбан бәйрәмнәрендә аwылда өч көн, беренче көн өйдә пешерәләр, өйләрне җийыштырып әзерләнәсен, тазалыйсын. Аннан ашлар пешерәсен. Көнө буйы бәйрәм ашлары тезелеп тора.

Көнө буйы өстәл жәйелгән. Саwыт-сабаға түгел, ә өстәлгә жәйеп саласын, өстен жаwып, өч көн буйы тора. Бөтөн кеше бер-берсенә йөрә, ***чәй көнө*** дибез инде без аны. Конфет, чәй, йөзөм тотоп барасын. Өйдә зур кеше булса, башйаулықмы алып барасын. Мулла өлгөргенчә йөрә, үзе булмаса, йәрдәмчеләре йөрә. Әүәлдә бәйрәмгә чақырмый иделәр мулланы, ә хәзер чақырып алалар. Иртәнге 6 дан мәчеткә барабыз, ғайет қоранын уқыйлар, садақа алып киләләр. Аннары, туғаннарға барғанчы, без беренче чиратта қуншыға (*күршеләргә*) барабыз. Йәшләр қартларға керә. Күп кешеләр шул көнне бара бабай түбәгә (*зиратка*), Қөрән уқыйлар.

*Сөйләүчеләр: Сажұидә Рәшит кызы (1937 елгы) һәм*
*Әдһәм Габдеразак улы (1935 елгы) Баубековлар.*
*Киләче авылы*

### ***Коръән укыту, Корбан гаете һәм Коръән пылавы***

Қоранға алып килделәр шундыйны, и вот барысына да қабақты житкезәмез. Фасоле дә бар, кишере, суғаны. Әүwәлдә тағын тәтле изүм дә бар иде. Шуны айырым майда қуwырадылар. Бер-ике киломы аладылар. И каждый нәлмәккә (*тәлинкә*) бер қашық-бер қашық салып бирә торған иделәр. Итен, қабағын саласын. Һәрберсе айырым торады. Ите айырым пешә. 20 кило дөгөгә 18 кило сыйыр итен (қуй, кәжә итенән дә йарый) кисәк-кисәк итеп салмақ шитенә. Менә безнен Киләчедә қоранға халықты шақырамыз без, уже беләсен, ничә кеше киләде и шул расчеттан пешерәмез. Ә Киләчедән башқа жирдә шақырмыйлар. Унда төннен уртасына хатле кеше килә торған. Ә бездә Киләчедә тәртип – wақытында килеп, wақытында китәләр. Сәғәт 6 булдымы, өстәлләр, ыскамейкалар шыққан, өй жийылған, айақ-саwыт йуылған. Ә башқа аwылда эй сәғәт уника қәдәр. Өстәлдәге ризықты тилмертмәгә (*көттерергә*) йарамый. Қоран ашынын ризығын көттермәгә йарамыйды. Ә бездә монда Қоран үтте. Хатыннарға муллабикә (*остабикә*) Қоран уқыйды. Мулла иркәкләргә (*ир кешеләргә*) уқыйды. Ну әйтәделәр ирләр уқығаннан сон инде хатыннарға йарамай қоран уқымаға дип әйтәделәр. Но без өйрәнгенчә муллабикәне көтәмез. Менә шул муллабикә Қоранне уқығаннан сон, потом уже Хатыннар ашый башлай иде. Спирба (рус. *сперва*) иркәкләр уқыйды Қоран, потом плау өләштерәмез бердән-бердән, менә бер нәлмәк бирәсен, икәүде подносны әкитеп бирмәйделәр (ике

тарелка тик туйларда йарый пар булсын дип туйда бирәде). Ә монда басабыз, подносқа салмыйбыз. Берәр-берәр и по цепочке қашығын тығып бирәсен. Чәйен дә икәүне алып килергә йарамый – берәүде. Чтобы мәйет икенчегә шақырмасын. Шундый ғәдәт Киләчедә. Ирләр ашағач, тиз айақ-саwытларны йуwып, шайқап, хатыннарны утыртамыз. Өстәлде төзәтеп шығардылар йәшләр. Но ирләр укығаннан сон хатыннар сразу ашыймыз. Сразу ашағаннан сон, потом муллабикә Қоран укыйды. Хатыннар ашағаннан сон Қоран укылады.

Монда ***җидесендә*** бездә утырады туғаннар, туған кардәшләр. Иртүк киләләр, 7дән үк килеп утыралар, но сәғәт унға хатле, 10нан сон килмәй уже. Туғаннар өй тулып утырадылар. Бөтен нәрсәне шығаралар өйдән, бернәрсә булмый өйдә. Стена буйлап утыралар. Сырдақлар (*җәймә*) идәндә, ну как матрац, шунарға утырадылар. Бөтен аwыл, күпме халық бар, бар да киләде. Монда бар да аwылдашлар шақырамыз өстенә килгән кешене, менә үле йатыры шул үленен өстенә килгән туған, дус, қода, қодағыйлар кем килде – ире дә булсын, қатын-қыз да булсын – менә қоранға шулар ғына шақырылады саубуллашырға. Ә басын (*башы*) сауға иртән килгән кешеләрне берәү дә шақырылмайды. Ә башқа аwылларда улай йөрмәйде. Уларда киләт китәде. Үлеш шығарыр йақта уже кешедә булмый унда, башқа аwылда. Ә менә бездә 8–9га, и анан пока үледе әкитеп, пока анда менә мәчеткә киләделәр йаназасын уқыйды. Потом әкитәде бабай түбәгә (*зиратка*), телефоннан звонит итәт без уже алып шықтыт, шуннан мулла бикә қоран уқыйде үлгән кеше артынан. Аннан сон, уқу булғаннан сон, потом туған хардәшләр торып ақша (*акча*) өләштеләделәр. Менә шул килгән халықнын барына да кем биш, кем ике монет, кем бер, кем ун монет – туғаннар киткән кешенен садақасын өләштеләделәр. Бездә сабын өләшүw йуқ.

Потом мулла қайтады бабай түбәдән, ул килеп Қоранны уқыйды, и билгели өче шул көнгә, җидесе шул көнгә, қырқы шул көнгә дип. Менә кеше йомасын уқый торған монау уқый, қырығын менә монау уқыйды, мәсәлән. Йылына хәтле кеше йомасын укытамыз без. Әйтеп қуйалар. Муллалар шулай распределәйтәләр. Менә главный Шакиров Гарифҗан Зарипович ул. Бездә йәше-қарты, олысыкечесе – бар да озата. Бездә халық как иртәдән килде, бер сәғәт өчләрдә өйгә қайтабыз арып-талып. Қайғымы-шатлықмы халық монда бер-берсенә йәрдәм итә.

Бездә болайтәде. Бездә ***өченә*** wақ пилмән пешерәмез и қаберчеләре болай йасалған, үрмәгән, ә қолақ пилмән бөгеп-бөгеп менә болайтеп зат итәсен. Түлке (рус. *только*) өченә генә. Қаберче җиде кеше, мулла менән сигез кеше, мулла озайта киләде, ә йуындырушылар биш кеше, қатынға да биш кеше, ир кешегә дә биш кеше керәде йуындырмаға и ике килен идән-керләр йумаға. Түлке киленнәр йуа, қызлар йумайды. 14 кеше.

Аннан сон ***җидесе*** булады. Җидесендә өй тулып утырған халыққа бирәделәр мата (*тукыма* < *материал*). Шуннан муллаларға, қабер қазғаннарға ақча саладыдар, күләк (*күлмәк*) саладылар мужской и йаулыққа урап ақчасын салып, өч кисәктән аш, қатланчык пәрәмәчә, җимеш бүрәк и қуз бүрәк. Обезателне өч аш эчендә җимеш или орех. И берәүе ит менән. Қуз бүрәк ит менән. Нәқ шул өч кисәктән йуындырған кешегә, идән йуғанға – 14 кешегә уже салып әзерләп қуйамыз. Бер нәлмәккә пылау салып йибәрәсен. Ул җидесеннән алып уже. Потом җидесендә үлгән кешедән кийемнәрен туғаннарына өләштеләделәр. Элек кийем йуқ wақытта тырышалар кермәгә йуындырмаға. Қазер инде берәү дә кешенен кийемен йат итсен. Қазер чистый мата саладылар. Или йуныдырғаннарға өч метр мата салады, кемгә ночной рубашка, кемгә зат-халат, нәқ шулайтеп саладылар. Ир кешегә бар да рубашка саладылар. Бу җидесендә.

***Қырқында*** (*кырыгында*) бер зат та бирмиләр. Қаберчеләргә, йуындыручыларға әпәт плау, ашларын и нийазын қырқында.

***Йыл қоранында*** ир кешеләргә күләк, сөлгөләргә урап, ақчасын урап саладылар. Монда ақ қағызға салып. Монда садақаны әкитеп бирәсең, ә соболевознованиегә килгәндә, анда бер өстәл тора, шунда салалар. Қулға бирмиде, шунда тезә бирәде. Шул қағазне йағалар. Ул қағызны беренче көн килгән затка садақаға дип әйтеп, мунчаға әкитеп, мунчаға йағадылар. Қалдырмыйдылар иде. Қатын-қызға хуш килден дип әйтергә йарамайды, озатмаға да йарамый. Исәнләшмиләр, улар керәделәр. Ишектән кереп утырады, доға қылады. Утырған халықның қулын алып чығады. Потом киредән утырадылар, потом мулла доға уқыйды и шулайтеп шығып китәде. Исәннәшергә қышқырып йарамый. Урамдағы соболевознованийегә килгән кеше беләән дә исәнләшергә қычқырып йарамый. Шундый тәртибе.

Ә уже ***йыл қоранына*** нәлмәк алабыз и қашық, тутырып пылауны саласын. Өстенә қашығын саласын, салафанға кигезеп бәйләп,

салафанга салып өстенә өч кисәк аш и ни йаз – күләк (*күлмәк*), сөлгөгә урап акчасын – менә шулайтеп йыл корандыгын әкитеп бирәсен. Әгәр үзләре ашка килгән булсалар, казер бирәләр, әwәлдә бирмәйделәр. Катын-кызга биреп йибәрәде, катыны булса инде монда, ә болай ир кешедән кулына тоттырып җибәрмиләр. Килеп китә, аннан сон өйөнә әкитеп бирәләр җәйәү дә. Халык транспорты монда велосипет. Менә корандың заты гадәте шул. Менә шулайтеп әкитеп бирә торган иделәр.

***Пылаучы wазыйфасы, бурычы***. Пылау пешергән кеше үзе өләшә пылауды. Пылауды пешергән кеше коранга обизәтелен үзең барасын. Шакырса да шакырмаса да, җиткезмәгә тийешмен. Нәлмәккә түлке мин салам, йанымда ит салып торучылар, кабак салып торучылар, түлке карап йибәрәсең, әһә, кызлар шулай сала биреңез и йибәрә бирәделәр бер нәлмәктән. Ә потом затка салып әзерләп куйамыз каберчеләргә, йуwындыручыларга. Ул инде пылаучының об'азанносте. Җиткезмәгә тийешсең пылауынды. Кем аwыру, кем балниста – уларга да йибәрәделәр.

***Тансык аш***. Бер калага бардым. Кала катыны сорый: «Тансык аш ни зат ул?» – диде. Мин сезгә әйтәм, дим, ул аwылда тансык аш түгел дим. Нугай мәлеш мәйтәм тансык сезгә. Чөнки сездә пич йук уны пешермәгә, и пылау мәйтәм сезгә тансык. Пилмән, пәрәмәчә ит белән зат камыр. Сездә калада аwыр пылау пешермәгә, и коранга барамыз калага да газда пешерәделәр табакта да.

*Сөйләүче: Мулләминова Гөлҗиһан*
*Харис кызы (1940 елгы).*
*Киләче авылы*

### ***Егетләрне армиягә солдатка озату***

Паромнан кулйаулык ташлап, шул wакытта ундый җырлар бар иде йегетләргә җырлый дырган. Паром wакытында мез күп өлгермәдемез.

*Пароход килә, пароход китә,*
*Пароход күрми калабыз.*
*Йәш йөрәкләремезнен*
*Кәдерен белми калабыз.*

Пароходыбыз китте. Безем йегетемез киткәндә мин йоклап калдым. Карточкада мин йук. Паромда саз (*гармун*) тартып бии

торған иделәр. Қарғалықтан, Мәйлекүлдән халығ килсә, зат менән, саз менән шул паромнан шығады халық, шунда йырлашалар. Армийәғә йегет китәд. Армийәгә киткәндә шулай озатадылар, қайтқанда да шулай итәделәр саз менән, каwал (*уен коралы*) мән. Бөтөн халык жыйылып, паром өстөндә, аннан төшкәндә бийеде һ.б., хәзер йуқ. Бездә шулай булады.

*Йырақ илләрдән күренә*
*Ағыйделнен ақ ташы.*
*Йәш йөрәктән қайнап шыққан*
*Сағынышлы қат башы,*

дип башлый идек хатты.

*Сөйләүчеләр: Бикбулатова Хәдичә Даир кызы (1942 елгы),*
*Ибләминова Әҗәр Идрис кызы (1952 елгы),*
*Ильясова Халидә Фәрит кызы (1938 елгы).*
*Кызан авылы*

## Аш-сулар

### *Пылау пешерү сере*

***Пылау бастыру.*** Сәғәт дүрттән чығам, қазанға ут йағып җибәрәм. Сәғәттән артық су қайнайды. Бүwертеп аласын дөгөде, аны табақларға салып, аннан сон инде қазанды киредән йуwып, май қойоп. Бер кило дөгөгә өч йөз грамм сармай (*атланмай*) китәде. 20 кило дөғө булса, 5 кило суған – туралған, киселгән – и биш кило мәркү, ике кило дубйа (*фасоль*) саласын. Дубйаны пешерәсен, бүрткән сайын йарт кила, йарт кила саласын. Пешереп йатқан зат – дөгөнән – саласын да, шунын белән бергә зайтып аласын. Аннан сон шул 20 килога қабақ саламыз қазан эченә – қазан төбенә төзөп, саламыз. Аннан қабақты салып, өстенә биш кило бүрткән дөгөдән сала бирәсен, өстенә майын қойоп бераз болғап-болғап, потом тағын саласын, пока ана шул 18 кило саласын, бер-ике килосы инде чилтәктә (*тишекле чүмечтә*) қалады. Ул монадый да булады, ручкалы зур да булады. Шул майды қойоп-қойоп, болғап-болғап бераз зат итеп, последнийын чилтәккә бушатасын да, җәйеп-җәйеп, уқлау мынан тишеп-тишеп шығасын өстөнән. Анисы өстөнә қағыз йабасын сулап, қағыз қапчықлар бар бит, шуны сулап, бер ике қабатын алып, пылаудын өстенә йабасын. Малированный табақты

өстөнә йабасын да, өстөнә йурқанмы анда, түшәкме шуны йабасын. Үәт шул пылау бастырылған була.

***Пылауды аудару.*** Бастырылғаннан сон өч сәғәт торадын ул. Өч-өч сәғәт йарым торады. 20 килоға бер өч сәғәт торады. Потом шығам суны пылауды. Ә ул аудару була инде – өстенән жыйып аласын барын да қабақның өстенән, мәркубын, суғанын бутап бергә, табақларға салып-салып, потом қабағын шығарасын. Қабақты шығарып уны башқа табаққа саласын. Қазанды йахшы итеп йуwып, тәтле қабақтын таты-балы қазанға қара булып йабылады. Шуны қазанды йахшы ышқып йуwып, алған дөгөдө, пылауды киредән саласын қазанға. Қабағын алмыйсын, қабағы айырым торады. Ә дөгөдө киредән қазан эшенә (*эченә*) салып, асларын төзәтәсен дә инде, йуwып ташлыйсын.

***Пылау заказы өчөн кирәк-йарақ.*** Пылаудын утынын хужалар үзләре китерәләр. Кем заказыбайыт – шул китерә. Утын булмаға тийеш қаты ағач – слива, тут (*тут агачы*), алматирәк (*алмагач*). Улар көчлө. Ул қазанды суwытмаға бирмиде. Уты көчлө, ә простой, без жөнке дип әйтәбез, простой тирәкләр (*агачлар*) йылға буйында үсеп утыра, ул тепло бирмиде. Ә слива, алма, тут – улар қаты тирәкләр. Өч сәғәт тормаға тийеш. Өч сәғәт утыра бастырғаннан сон өстен йаwып (*ябып*). 8 сәғәт бара бөтөн пылау пешерү wақыты: 4 тә торасын, сәғәт 12 йартыларға әзер була ул. Қоранға 2 гә, сәғәт 4 тә йағып жибәрәсен, су қайнатасын. Қысқасы, төнө буйы йоқо йуғ инде ул пылау пешергәндә. Миға (*миңа*) алдан әйтеп қуйалар заказайтеп.

Бу ***казан өй*** (*җәйге кухня*) – көне буйы шушында, пешерәм, кеше киләде көнө буйына. ***Пылау пиче***, нугай пичем бар минем. Анау өйгә кермимез дә без. Әүләдә (*өй алдында*) өлкән өй. Ул таштан эшләнгән өй, қушып салдық инде анда зал.

***Туй пылаwы***. Әwәлдә туйлар булады бездә пылау мынән. Уwай, бөтөн аwылды чақырадық. Туже 20 килодан пешерә торған идек инде. Ул 20 кило хазерге расчет менән 200 кешедән шығып, ә безнен ашлық wақытта 200 грам кеше башына иде. 20 килам синен йөз кешегә иде. Ул заманда әниләр инде нәлмәкне (*тәлинкә*) тутырып сала торган иде. Затны – итен саласын и қабағын, икесе ике йақта була. Қабақты айырым аламыз, шул қабақтан қашық белән менә болай итеп, әwәлдә қабақнын қабағын тазалый торған идек. Потом инде модқа китте – йуwып бер қабақты сигезгә бүлеп, тезәмез,

ақ қабақ, урыс қабақ дип әйтәмез татлы қабақ булады ул, бал қабақ сулы, бал қабаққа йарамый иде, бал қабаққа салсан, қайнап шығады, қазаннан ташыйды.

*Сөйләүче: Мулләминова Гөлҗиһан Харис кызы (1940 елгы). Киләче авылы*

### *Милли ашлар*

Милли азықлардан бар нуғай бәлеш – аны туйға да, үле ашына да алып китәләр. Чөнки ул самай милли блюда. Бадамгел или шикәр чүрәк – без инде домашний прәнник дип әйтәбез. Қабақ бүрәк – ул бөккән. Җимеш бүрәк, қуз бүрәк. Һәрберсенең эчендәге начинкалары үзенчә инде. Қатланчық, лаксалба, нугай бәлеш, пәхләвә, кәртүф пилмән.

***Бадамгел.*** Бадамгелгә йарты килодан әйтиг инде. Йарты кило май саласын, йарты кило шикәр саласын. Йомырқа, бераз чемтеп соды саласын. Формалары бар. Мичләр әнә духовка.

Мичләр бар пылаучыларда. Учақ. Аwылда бар пылаучылар. Ике пылаучы: Гөлҗан апа и Роза апа. Аларга күрше-тирә аwыллардан киләләр. Пылау пешерүнең үзенең сере бар. Аларның қазаннары бер 300 кешелек инде. Ул пич тора урамда (*йорт алдында*). Пылауға қабақ, фасоль, мәркү, суған саладылар.

***Турамша***. Кәртуф пилмән, турамша йасыйлар. Турамша – элек (*башта*) итенде пешерәсен йахшы иттереп, эшенә (*эченә*) бер 3–4 суған салып пешерәсен. Аннары итте чығарып аласын, аннары өнкәлләр (*җәймә*) йасыйсын. Қазакча өнкәл, безнеңчә – җәймә. Барын да сүли бирәмез. Нуғай да түгел, татар да түгел, шундый зат мез.

***Тилдей*** – картуптан ул, кырғыч аша үткәрелеп пешерелгән табада, суған, күкәй кушып.

***Кәртүф қалач***. Кәзер без месарубкадан чығарабыз. Кәртуфты аршыймыз да, кәртуфен дә, суғанын да – барын да бергә месарубкадан чығарабыз. Элгәре карета була иде озон, ағачтан йасаған. Шул каретаға саласын кәртуфты и тәписен затты. Wақ итеп чапмаға кирәк уны. Тиз пешермә кирәк. Пырт-пырт итә. Уны чаwып булғаннан сон, инде онды үзенә қарап саласын. Он күп салсан, он татыйды ул. Мин салмыйм йомырқа, ни чаққа кирәк ул тәмен бозоп. Суған, борыч саласын, май қойасын эченә бер стакан постный (*көнбагыш мае*) май қойасын да, болгап-болгап. Табаға маргарин майзы йағасын астына ыштубы йабышмасы кәртуф қалач.

Элек тә қазақлар безгә әйтәдәген булған: нуғайлардың ашағаны үлән-чүп дип, без инде ашқа барын да саламыз бит. Йәшел суған саламыз, петрушка, укроп саламыз, кәбестә, картуф ашыймыз. Менә шуларды улар әйткән, нуғай ашағаны үлән-чүп. Үзләре дә ашыйлар инде кәзер.

*Сөйләүчеләр: Мавшиева Мөгөлсем Газиз кызы (1936 елгы),*
*Есенбаева Наилә Ислам кызы (1974 елгы).*
*Киләче авылы*

## Тамыр сатып исән калдык

Мин аwылның иң қартысы, миннән қарт кеше йуқ. Әwәле бездә қалаға йақын кем ни зат табып, шуны алып барып сатып, тирәктән (*агачтан*) йәшел ботақларны сындырып, қала безгә йақын, қалада кәҗә тоталар иде, безнең халық күтәреп барып шуны саталар иде кәҗәлеләргә, қала халқына. Аштан (*ачтан*) күп кеше үлде. Киләче аwылы қалаға йырақ, анда күп кеше үлде аштан, нигә дисән, аннан киләлмыйлар. Ә без қалаға йақын идек, бездә бик күп кеше үлмәде. Бездә ни зат бар, шуны алып барып сатып торды. Ашлық wақытында тамыр қаздық – җирдә тамыр була. Ул әйтәләр борны белән қазып шушқа (*дуңгыз*) ашый торған тамыр дип. Без қазып, шуны пич йағып, киптереп, шуны тазалап, қапчыққа салып, ышқып, уғалап шуны ыстаканға салып, саттық суғыш wақытында. Стаканға бишәү керәме инде тамыр. Шулайтеп сақландық. Тамырны ашамый идек, шушка ашый торған дип. Аны ашаса, кешене киптерә диләр, файдасыз тамыр икән. Но без саттық, йарма зат алып, бер хилы йәшәдек инде. Ашамадық, саттық қына. Безнең бәхетебезгә ул булған. Ул булмаса, қырылып үлә идек. Шуны сатыб қала халқына да ашаттық. Аны қазарға көш (*көч*) кирәк. Аны қазалмасан, үлделәр күп кешеләр. Ул далада була. Далаға барып, ул йақын җирдә булмый. Кигән кийемебез дә иске. Ни зат бар – шуны кийеп барып, шуны җирдән қазып, ул аwыр була күтәрергә. Аның аwырлығын исәпләмисен, штобы қапчық тулсын. Йырақтан күтәреп алып қайтабыз, қар эреп бетмәгән, тез белән тамыр қазыймыз. Ашамаға кирәк. Йылытқанны көтөп булмый – ашлык (*ачлык*), тезләнәсең салқын җирдә. Анау қазуы да қыйын әле, бозолып бетмәгән бит. Ни күрсәк тә, күрдек тә инде.

*Сөйләүче: Ибәтуллаева Шәһәрбану*
*Хөсәен кызы (1923 елгы).*
*Җәмәле авылы*

## Кием-салым, бизәнү әйберләре

Бездә шәл-мәл туқымағаннар. Қарағач йақлары туқыған. Безнен биттә (*якта*) сарық мамықтан наски туқығаннар айаққа кимәгә, қулға кимәгә бәрекләр (*бияләйләр*). Йәш қызларға перчатка. Шәлде, шарфны Красноярски, Нуримански битләре туқыйдылар. Сарық мамығыннан чөлкә (<*чулки*) кигәннәр, тақыйа (*башлык*) кигәннәр. Кәләпуш, йатақ (*бүрек*) мехтан тегелгән. Күләкләрде (*күлмәкләрне*) пешә (*кисеп тегә*) белгән үзе пешеп кийә бирде инде.

Борын озатқаннар, сондық, түшәк булған. Кийемнәре сондықта булған, пәрәзәләре (*битләрен каплар өчен*) булған. Приданны озын арбаларға, сиганский арбаларға салып китергәннәр. Аннары машин белән китергәннәр. Придан итеп йастық, түшәген әзерләгәннәр, башына бәйләргә йаулығын дигәндәй. Тастымал, сөлге, бит сөртә торғаны тәритйаулық (*сөлге*), аларны сандыққа салғаннар. Үлкүн (*зур*) сандықларды қалада йасағаннар.

Җир түшәге – сырдақ җиргә җәйә торған, мамықтан йасайлар утыра торған итеп озон-озон. Борын заманды йастық, түшәк булған идәнгә җәйгәннәр, и шунда утырғаннар. Тәсхан/тәстерхан (*ашъяулык*) җәйгәнннәр.

Килен булып төшкәндә қайнатам, қайнанам бар иде. Башта – шәл, айақта – чөлкә, йылы көн булса йаулық, озон җиңле күләк кийеп йөрдем.

*Сөйләүче: Бикбулатова Асия*
*Абдразак кызы (1937 елгы).*
*Ярлы Түбә авылы*

Қолаққа сырға (*алка*), муйынға мәрҗән тағабыз. Алға зыпын/запун (*алъяпкыч*), қулға беләзек таққаннар. Әниләр сөйли иде қаптал дигәнде, халаттай булған зат (*кием*) ул. Ул заманда алтын күп булған. Алтыннан төймәләрен сала торған булғаннар. Болай ырғақлы затлар булған. Қаптырып-қапып қуйа торған. Озон җиңле, бизәкле дә, бизәксез дә булған.

*Сөйләүчеләр: Мавшиева Мөгөлсем Газиз кызы (1936 елгы),*
*Баубекова Саҗидә Рәшит кызы (1937 елгы).*
*Киләче авылы*

Сәнәпәт//сәнәбәт – җиңсез кийелгән әйберне шулай диләр. Әбүркә итәк. Шәлләр чын йефәктән. Қуй, дөйә мамығы. Бу шәл

уймақ күпертмә. Бу шәл – қуз күпертмә, эрерәк булғанғамы. Болары чачақлар, чуқлар. Рислы шәлләр – мамыктан, жылы шәлләр. Монысы қаптал – ирләр кийеме, қызлар да йабынып ир кешегә күренмәс өчен қапланғаннар. Бүрекләр этийемнен, түбәтәйләр. Монысы энҗе қалфақ.

*Сөйләүче: Гомәрова Мәйсәрә*
*Хәким кызы (1936 елгы).*
*Җәмәле авылы*

### Туганлык атамалары

Мин симйада кечкенәсе, минем алда ике бертуған апам бар, һәм икетуған апам. Миндә бар өлкүн тәтәм, бал тәтәм, биби тәтәм. Бикәм – эр кеше биттән, қайтим – әни йақлап. Тәтәм, абыйым... Апалар аралары бер йәш булса да, тәтәм дип дәшә. Морзам, җиңгәм, сәүлим, җиңгәм. Қыз йағы әйтә сәүлим дип, йегет йағы җиңгәм ди атый. Сәүлим и җиңгәм – берүк сүз, абыйымнын қатыны.

*Сөйләүче: Үтәлиева Ильмира*
*Мөхлис кызы (1976 елгы).*
*Майлы Күл авылы*

Әйем – ир кешенен әнисенә онуклар әйтә, дәү әни. Биби атам, ақмуллам – килен кеше қайнатасын әйтәделәр. Атай бикәм бар. Қахам – абыйым. Қартам, муллабикәм, мулла тәтәм. Күрше – қунсы атам (*күрше ир*), қунсы әйем (*күрше хатын*).

*Сөйләүче: Мавшиева Мөгөлсем*
*Газиз кызы (1936 елгы).*
*Киләче авылы*

Эр кешемен ағасы қайнағам, қатыны – абсын, йә чичи үлкөнрәк булса. Эр кешемен сеңлесенә сәүләм, сөйеклем, гүзәлем, туғаным дисен, энесенә – морзам. Баба (*дәү әти*) дип әйтәләр оныкълары, ә бабай дип чит бабайга әйтәләр. Әнинең этисенә – бабам, этинең этисенә атам диләр. Мама – қыздықын дәү әни, ә әйе (әйем) дип этинекен сүләйләр. Дус әни, дус эти – дусларымдың эти-әнисе. Апаны тәтәм дип әйтәде.

*Сөйләүчеләр: Бирдиев Фаил Йосыф улы (1968 елгы),*
*Бирдиева Гөлфәридә Дуллаян кызы (1939 елгы).*
*Ярлы Түбә авылы*

## Кушаматлар

Бездә халыҡ күп, исемнәр күп, шунын өчөн атаҡларыннан (*кушаматыннан*) сорыйлар. Бикмуллалар күп бездә. Бар – Ҡабаҡ Бикмулла, бар – Чапай Бикмулла, Әрмәле Бикмулла. Атаҡлар мынә мездә: Капитан, Күк чүпрәк, Күкчөбәрәк, Күкүк, Куйан, Төлкө, Ҡабаҡ, Ҡырмысҡа, Бүре, Бизнесмен, Йарғаҡ. Тараканнар, Бөрчәләр дә күбәйде. Безнен атағымыз – име, атаҡлар, байымнын атағы Көркәсен. Без Йүкәайаҡлар – ҡазанлылар. Без – күпчебрәкләр. Безнен этиләремез атаҡлар булган, Көркәсен дигән менә бер кешеләргә сөйләте: «Ҡор кәсебен эшләгез, кор кәсебен эшләсәгез, бай булырсыз», – дигән. Шунан көркәсен булып киткәннәр. Ҡабаҡ – ашый дағын *(торган)* ҡабаҡ тегел, аларнын бабаларымы, затлармы әүәлдә ҡабаҡта эшләгән. Менә йаға (*елга*) буйында хәзерге кибет бармы, шул урында ҡабаҡ затлары, чәйни затлары булған. Шунардан.

*Сөйләүчеләр: Бикбулатова Хәдичә Даир кызы (1942 елгы),*
*Ибләминова Әҗәр Идрис кызы (1952 елгы),*
*Ильясова Халидә Фәрит кызы (1938 елгы).*
*Кызан авылы*

## Әүлияләр

***Үтәмеш бабай әwлийә.*** Сул йаҡҡа китә Татар-Базар, уң йаҡҡа китә Татар бистәсе – Тийәк, алда «Петро Павла» чиркәwе һәм «Храм-собор Святого князя Владимира (в честь 900-летия крещения Руси)» дийелгән чиркәү тора. Аның астында безнең әwлийәбез йата. 1930 йылларда коммунистлар бу чиркәүне шартлатырға алыналар. Ә Тийәктәге татарлар аны шартлатырға бирмиләр. Аны урыслар әйтәләр, татарлар саҡлап калды, диләр. Дөрестән дә, ә ни өчен татарлар бу чиркәүне саҡлап ҡалдылар соң? Чөнки ул татар мәхәлләсендә. Аның урынында булған мәчет, һәм мөселман әwлийәсе күмелгән. Йәгни әwлийәнең тынычлығын бозырға бирмиләр. Менә шуннан. 1554 йылны менә монда Идел платной килгән була урыс дошманы, мәчет-чиркәүләрне бөтенесен йандыралар. Бу чиркәүне салырға бер татар зур күләмдә аҡча бирә, ул әйтә: «Чиркәү булса да, Аллаһы тәгалә йортта, әwлийәне өстеннән машиналар йөремәсен, дуңғыз сарайы йасамасыннар» һ.б. тәртипсез нәрсә йасамасыннар өчен, хот'а бы ул чиркәү тора. Менә бу районда иске татар Хаҗи Тарханның үзәге шуннан узған, әwлийәләр күмелгән.

Бер әwлийә менә монда, икенче әwлийә Родина кинотеатры йанында (хәзер комплекс «Даир»), шуның йанында Үтәмеш бабай әwлийә күмелгән. Монда татарның кендек кергән җирләр. Факт моны салырға безнең татар кешесе акча бирә, төбендә безнең әүлийә.

***Тағын бер әwлийә*** элеккеге ипи кибете иде, хәзер «Русский лён» дип йазылған, шунда күмелгән. Бу үзәге, Хаҗи Тархан узған бу түбәдән. Әби-бабайлар сөйләwеннән, монда ханның нәрсәседер, мәчетеме, булған. Факт монда ханның ставкасы булған. Монда татар китапханәсе булған, коммунистлар wақытында, йуққа чыққан. Аста ***Татар-Базар***. XVI гасырда ук урыс тарихында йазылған булған.

***Урақ*** һәм ***Қайтармыш әwлийә*** бар Ақ мәчеттә.

***Фатыйма әwлийә.*** Иван Златоуст чиркәwе эчендә Фатыйма әwлийә қәбере. Анда хан мәчете, әwлийәләр қәберләре һәм башқа изгеләр қәберләре булған. Алары, шәһәр алынғач, сүтелгән, җимерелгән, чиркәүләр салынған. Безнең мөселманнар анда йөриләр хәйер күтәрергә. «Ник анда йөрисез?» – дигәч, «Безнең гомер-гомергә әби-бабайлар шунда йөргәннәр», – дип әйтәләр. Өч қабер қалған чиркәү эчендә. Берсе – Фатыйма һәм тағын икәү бар. Алар (чиркәүдәгеләр) мөселманннарны килгәч таныйлар, бер сүз дә әйтмиләр. Халық монда садақа күтәрергә йөри.

*Сөйләүче: Фатыйхова-Потеева Наилә*
*Шакирҗан кызы (1957 елгы).*
*Әстерхан каласы*

## Йорт иясе

Йорт ийәсе покой бирми. Бастырыла дип сөйләдәделәр. Шуңа күрә Айател көрсине укырға кирәкте. Йаңғы өйгә кергәндә, йаңғы өйме, кешенең өйен сатып алғандамы, бастырыласын төннә, как будто шул өйнен өйәсе бастыра тип. Без әнәү өйгә күчкәндә әйем миға бастырылғанда зат әйткән иде, мичнен аwызын ашып, «Мин дә бу өйнең кешесе, мин дә бу өйнең кешесе, мин дә бу өйнең кешесе», – дип өч кәрәм (*мәртәбә*) әйт, дип, мин шуны белештерәм. Аннары тоссыз баwырсақ шарлаққа (*чормага*) күтәрмәгә кирәк, баwырсақ пешерәсен дә тоссыз. Уқып йатсан, килмийде шайтаннар. Ошатмаған кешегә бер хил басқан хәтлем бастырыласын дип тә әйттеләр миға.

Йатқанда айақ биттән терсәгемә тайанып, «Пс, пс» итәделәр ийе. Йөрәк йарылды. Ул wақытта мин бер дат (*дога*) та укып белмимез. Ул wақытта, айақны типмәгә кирәк, сүкмәгә кирәк икән. Ундый затларны қайа инде йәш wақытта беләсен инде. Мичне қапқашын ашып (*ачып*), өч кәрем әйткезде: «Мин дә бу өй кешесе» дип, аннан, үзе бер зат уқыды да зәтләрне, әнә шул баwырсақ иттердек, пич чығарып, тоссыз, майсыз пешерәсен.

*Сөйләүчеләр: Бикбулатова Мәгърифә Сәйфулла кызы (1939 елгы),*
*Бикбулатова Хәдичә Даир кызы (1942 елгы),*
*Ибләминова Әҗәр Идрис кызы (1952 елгы),*
*Ильясова Халидә Фәрит кызы (1938 елгы).*
*Кызан авылы*

Әйтәләрде өй ийәсенә қайада торма кирәк, шуға уға шарлақ кирәк, мансарда. Монда күчәргә булғач, қайнанам мән бөтөн әйберләрне күчердек, соңғосын китәбез дигәндә күсәнкәне (*кисәү агачы*) салды идән уртасына, и әйтәде әби: «Без менә бу өйдән күчәбез. Әйдә син барсан, безнен мән утыр менә күсәнкәгә. Мин сине алып китәм». Салды, ни заттыр уқыды үзенчә. Шул күсәнкәне җилкәсенә салып аннан монда қәдәр күтәреп килде. Өй ийәсен алып қайтты. Үземез өй ийәсе болай күргәнебез йуқ. Қайсыбер кешеләр әйтәләр йокы бирми, тегендә йөри, монда йөри, төшемә инә дип. Әйтмәгәнем булсын, әстәгафирулла, алай боршылулар мин күрмәдем. Менә өйдә дөбердәү була икән, қамышаулық була (*комачаулый*) икән, сискәндерә икән, шулай әйтәләр.

Элек шарлақны былай йаба булғаннар, җылы җир йуқ, суғанны шарлақта сақлағаннар. Өйнен түбәсе, и шарлақны болай салалар, шунда суғанны саласын да, ул өй эченән йылы бирә, ә тышына йабасын нәрсә белән буса да. Шунын өчөн күберәк шарлақ тақтадан йасалған, өшеми дә, йылы була.

*Сөйләүче: Бирдиева Гөлфәридә*
*Дуллаян кызы (1939 елгы).*
*Ярлы Түбә авыл*

## Су анасы

Су анасы дип әйтәдән иде. Әнә, су төшмә (*коенырга*) барсақ, сорасақ, «Суға барма, су анасы айағыннан тартар», – диде. Болай су анасын күргәнемез дә йуқ. Аннан су килеп торған wақытта,

йебәрми дәгән иде әниләремез суға төшмәгә. Ул, су анасы су килгән wақытта обезателны кемде дә булса әкитәр тип, йебәрми дәгән иде. Үзебез қурқа торган идек бармаға.

*Сөйләүче: Ибләминова Әҗәр*
*Идрис кызы (1952 елгы).*
*Кызан авылы*

Без берwақыт Румыя дусым мән суға бардық. Анда берәүләр сәпсим күрмим, менә сүз әйтәде, «Дусым, дусым, – дип, – әнә берәүләр батып йатыр». Тиз күләмемез (*күлмәгебез*) мән кереп киттек. Кийемнәремезне алып, анау судан сәпсим китеп бара торган шашләреннән (*чәчләреннән*) сөйрәп-сөйрәп шыгардық. Берәүе З...., берәүе Ф... дусым. Йөрәүә йөремнәре булған, мез шығарып алмасақ, китеп батыр булыр иде. Хәзер әйтәделәр, син шығарып алдын дип. Сөйрәп-сөйрәп шығарып алдық.

*Сөйләүче: Ильясова Халидә*
*Фәрит кызы (1938 елгы).*
*Кызан авылы*

**Тәскирә бәете**

Иләһи wә билләһи,
Җитте қорбан ғәйете.
Без әйтийек, сез тыннағыз,
Тәскирә кыз бәйетен.

Аһ Тәскирә, аһ Тәскирә,
Белмәдем бит уйыңны,
Балықларға азық өчөн
Үстергәнсең буйыңны.

Йәтим үсеп Тәскирә қыз
Қыйынлықта йәшәгән,
Тәскирәнең ғәзиз башын
Қаспий диңгез ашаған.

Астырханнын урамында
Йөри идем қыз булып,
Қаспий диңгез уртасында
Қалдым инде боз булып.

Тиман пароходы йахшы,
Бер дә артта қалмыйбыз.
Мор'аклары усал икән,
Қотқарып та алмыйдыр.

Тәскирә суға батқанда
Қалқып-қалқып бер чыға.
Зинһар, қотқарығыз, дийеп,
Тәскирә қулын суза.

Теш (*төш*) йуратушчыға бардым
Тешемне йуратырға.
Йанымдағы урыс маржа
Қызғанған уйатырға.

Ресторанда эчкән ашым
Ите пешкән изерәп.
Минен суға баткан wақыт
Йасылардан (*кичке намаз*) кичерәк.

Мақаш қала – бик зур қала,
Машина узып бара.
Тәскирә суға батқанда
Дуслары җылап қала.

Тәскирә қыз белмәгәндер
Әҗәленен җиткәнен.
Тәскирә қыз сизми қалды
Су төбөнә киткәнен.

Ул сәүдәгәр қыз булты. Мақаш қалага барып, таwар сатып йөргән.

*Җырлаучы: Ильясова Халидә*
*Фәрит кызы (1938 елгы).*
*Кызан авылы*

## Кыска җырлар

Безем йегетләргә шулай йырладык:

Тәрәзә читен алама,
Алыр булсан, йаучы җибәр,
Алмас булсаң, алдама.

Тәрәзәдән қарама,
Бүрек читең алама.
Алам, алам, дип әйтәсен,
Сиңа чортым барама.

Тәрәзә төбөм қаты бал.
Ашыйсың килсә wатыб ал.
Мине дисән, мине сөйсәң,
Тәрәзәдән тартыб ал.

Тәрәзәдән қарыйсың,
Қарап кемне таныйсын.
Қарап күзен талдырғанчы
Ник шақырып алмыйсын.

*Җырлаучы: Ильясова Халидә*
*Фәрит кызы (1938 елгы).*
*Кызан авылы*

## Мәкаль-әйтемнәр

Алла биргәнгә бирә, тинтәк қайғыдан үлә.

Ата барда бала йәш, аға барда эне йәш.

Бай йарлыға әйләнсә, битен (*йөзен*) салыр җир тапмас;
Йарлы байға әйләнсә, утырыр урын тапмас.

Тайа (*үлчәп, карап*) җисән (*ашасаң*), тай қалыр.
Таймый җисән, ни қалыр.

Сыйласаң минем би (*өлкән атамны*) атымны,
Сыйлармын синең қол атаңны.

Ийене (*җилкә*) қотлы печәден (*хатынның*) ийенләсеп (*тиңләшеп*) ылы (*улы*) үсәр. Ийене қотсыз печәден ийенләсеп қызы үсәр.

Уңган берен бере батыр, дир,
Уңмаған берен бер қутыр, дир.

Киленем бик йахшы, қыйқымын (*чүп-чар*) өйә, йыртығын төйә (*бәйли*) *(бу киленнең уңмаганлыгын аңлата икән).*

Қызым өйдә, холқы төздә (*урамда*).

Иманлы иманын сағыс итәр (*иманына таяныр*),
Имансыз «Мин җиңдем», – дип китәр.

Суқырны алсаң, сау туар,
Тилене алсаң, суй (*нәсел*) қуар.

Кабақбүрәк (*вак кабак бәлеш*) ырлаған – қапқаларын сырлаған,
Җимесбүрәк ырлаған (*урлаган*) – җиңгәләрен сыйлаған.

*Ижбирдиева Зөлхәбирә Фәрит кызының*
*(1929–2011 елларда яшәгән)*
*китабыннан язып алынды.*
*Киләче авылы*

## Шигырьләр

(нигездә, әдәби телдә язылганнар)

### *Сөембикә*

Иркә қызын үгетләде
Нуғай Йосыф мирзасы.
Төрки халқы берләшсен, дип,
Сөйембикә үтәде.

Мең дә биш йөз утыз өчнең
Эссе авгус айында.
Қурчақ ханға Җанғалигә
Сөйми генә хатын да.

Сөйгән Сафагәрәйеннән
Үтәмешгәрәй туды.
Ике йәшлек бала белән
Ханбикә булып қалды.

Мең дә биш йөз илле бердә
Қорбанбикә иттеләр.
Унберенче авгус көнне
Мәскәүгә алып киттеләр.

Йосыфның ақыллы қызы
Нуғай далаларында.
Сөембикә ханлык иткән
Қазан қалаларында.

Баһадир ирләрчә тотқан
Мәмләкәт идарәсен.
Фаҗига аның йазмышы,
Билгесез қабер ташы.

Матур, киң йаланнарның,
Бөйек Нуғай иленең
Балланып үскән чәчкәсе,
Сөйекле Сөйембикәсе.

### ***Яратмый мөмкин түгел***

Әстерхәннең ачык күген
Йаратмый мөмкин түгел.
Тойасың қойаш жылысын,
Шуңа сөйенә күңел.

Су кирәкме, қыр кирәкме,
Табиғәте бай аның.
Бу байлыкта йәшәгәндә
Рәхәт сизәдер жаның.

Бозы да бар, тозы да бар,
Күкерте дә, газы да.
Төрле җәнлек, күлләрендә
Үрдәге дә, қазы да;

Бай ул җиләк-җимешкә дә,
Ите, сөте, дөгесе;
Каспийендә, Иделдә дә –
Балықларның төрлесе;

Қаwын, қарбыз, йәшелчәләр –
Бары да халық қаршында.
Җиренә җитеп пешәләр
Әстерхән қойашында.

Менә шундый байлықларға
Ийәдер Әстерхәнем.
Иренмичә хезмәт кылсаң,
Мул булыр тәстерхәнең.

*Сөйләүче: Гомәрова Мәйсәрә*
*Хәким кызы (1936 елгы).*
*Җәмәле авылы*

### ***Киләче***
*(Авыл тарихыннан)*

Борон-борон заманда,
Әллә легенда, әллә чын.
Әстерхан йанында ғына
Бер қәбилә йәшәгән.

Җирдә қазып йасалған өй,
Булған торақ йортлары.
Тирәсендә үлән үскән,
Терлекчелек кәсебе.

Башлықлары – қарт ақсақал,
Законны ул чығарған.
Ғәйеплеләрне хөкемләп,
Җәзаны да ул биргән.

Ничә буын шулай йәшәп,
Килеп киткән дөнйадан.
Тора-бара қәбиләдә
Кеше саны күбәйгән.

Тыныч йәшәп торған чақта
Чабу килгән аларға:
Уғры килгән, қарақ килгән
Мал-туарын урларға.

Басқынчылар бик күбәйгән,
Йышрақ килеп йөргәннәр.
Кешеләрне үтергәннәр,
Малын алып киткәннәр.

Қәбилә төшкән қайғыға,
Жыйылып киңәш иткән.
Тынычрақ җир эзләргә
Биш-алты атлы киткән.

Эзләүчеләр туқтағаннар
Бер зур йылға йанына,
Ләкин монда урнашырға
Мөмкин түгел тағын да.

Йылғаның арғы йағына
Төзөсәк өйебезне.
Төрле қарақ – йаманнардан
Бу йылға саклар безне.

Шундый қарар чығарып,
Қайтқаннар эзләүчеләр.
Қәбиләнең бер өлөше
Ашығып күчеп киткән.

Йылғаға килеп җиткәннәр,
Саллар йасап кичкәннәр.
Тирә-йак бик киң икән,
Игенгә дә, терлеккә дә
Бик уңайлы җир икән.

Иңкүлекләр суға тулған,
Қамыш-җикән қаплаған.
Түбәләрдә ачық буйақ үскән,
Кеше айағы таптамаған.

Йазғы ташу wақытында
Су кергән болыннарға.
Килгән кешеләр ғәҗәпләнгән
Сарықтай сазаннарға.

Матур җир тапкач үзләре,
«Кил(-ә)че» – дип, чақырған.
Қәбиләдәш туғаннарын
Иделнең арйағыннан.

Монда өйләр күбәйгән,
Аwыл үскән, зурайған.
Килгән кешеләр аwылны
«Киләче» дип атаған.

Аwыл халқы – қәрдәшләр
Дус-тату йәшәгәннәр.
«Киләче» исеме матур бик,
Бер дә үзгәртмәгәннәр.

Беренче булып килгәннәр –
«Ағайлар» дип аталған.
Ә соңыннан аларға
«Морза» исеме қушылған.

«Морза» дип аталуның да
Сәбәпләре бар икән.
Ағайларның бер қыйуwы
Патшаға барған икән.

Мысалбик дигән ақсөйәк
Николай беренче белән
Қара-қаршы утырып сөйләшкән,
Күп мәс'әләләр чишкән.

Үсмер чақта ир балалар
Солдат булып үссеннәр.
Көнйақ чикләребезне
Сақларға өйрәнсеннәр.

Хәзер ул йақлар хәwефле,
Чикләрне нығытырбыз.
Илнең тынычлығы өчөн
Җанны да қызғанмабыз.

Зур иғтибар белән патша
Морзаны тыңлап торған.
Сәйәси йақтан ғыйлемле
Кеше икән, дип уйлаған.

«Князь Урусов» дип йазылған
Алтын тартма тапшырған.
Үзенең дә мақсатларын,
Кирәкләрен йаздырған.

Шуннан бирле Мысалбикнең
Асылы, нәселенә
Кенәз дәрәҗәсе иңгән,
Хәзерге көнгә хәтле
Фамилийә килеп җиткән.

## *Киләче алмалары*

Исеме илгә таралган
Киләче алмалары.
Агачында пешкән чакта
Матур була аллары.

Чыдам була, өзөп сакла,
Кыш киткәндә ашарсың.
Хуш исләре аңкып тора
Иснәп кенә туйарсың.

Сугыш йылларында безне
Ачлыклардан коткарды.
Хәзер дә данга лайыклы
Киләче алмалары.

Җиңү көнөн йакынайтуда
Аларның да өлөше бар.
Безгә түгел, солдатка да
Ризык булдылар алар.

*Ижбирдиева Зөлхәбирә Фәрит кызы*
*(1929–2011 елларда яшәгән)*
*китабыннан алынды.*
*Киләче авылы*

## *Тукай – безнең Тукай*

Татар телен ул wасийәт иткән, бөйөк Тукай,
Йәшлегенә карамастан ул көрәште,
Татар телен йуғалтмаска ул тырышты.

Аның йазган һәрбер хәрефеннән,
Жаны-тәне белән әйткән һәр сүзеннән
Хәзерге көн без укыйбыз рәхмәт аңа,
Шундый бөйөк султан булганына!

Ул күрмәгән йарлы дип йарлыларны,
Ул йараткан йарлы-йәтим балаларны.
Һәрwакыт алар өчен шигер йазган,
Алар өчен wахыт табып бергә булган.

Халкым дип халкы өчен ул көрәшкән.
Чүп-чарларны читкә тибеп,
Йарлы-фәкир булмасын дип, ул тырышкан.

Ләкин аның кәдерен белмәгәннәр,
Аwыруына дару табып күмәк бирмәгәннәр.

Ул андый, дип, ул мондый, дип,
Бай кешеләр төрлесе төрлечә тиргәгәннәр.

Дөнйам, дип дөнйа өчен ул көрәшкән,
Уттан күлмәк кийеп ул тырышқан.
Салқын қышта ишек алдында ачалмыйча,
Сабый чақтан ул аwыруға сабышқан.

Менә ничек зур шағирләр хур булғаннар,
Аwырлыққа, йарлылыққа бит түзгәннәр.
Халқым белән бергә булам, дип баш күтәреп,
Қулға қәләм-дәфтәр алып, хәле килгәнчә
ул көрәшкән.

Йыллар артыннан йыллар үткән,
Йәш җанына саулық килмәгән.
Ул йазуwын һаман дәwам иткән,
Шиғерләре безнең көнгә килеп йиткән.

Без хәзер ғорурланып, Туқай, дибез,
Безнең Туқай Пушкин белән тиң, дибез.
Аның йазған шиғереннән файдаланып,
Татар телем минем бай, дип, шатланабыз.

Үз телеңне йаңадан терелтергә,
Кирәк татар теле мәктәпләр ачарға.
Сабый чақтан қулға туған телне алып,
Өй эчендә йат телләрдән қачарға.

### *Сабыйлар*

Без Қарғалык мәктәбендә
Уқып белем алабыз.
Тормыш йақты булсын, дип,
Йаңа йуллар салабыз.

Йаңа көндә йаңа сүзләр,
Уқығач қына беләбез.
Туған телне Туқай кебек,
Әни кебек сөйәбез.

Үз телеңне онытмасаң,
Алла сине хуш күрер.
Йаман белән буталмасаң,
Әнийең қочақлап үбәр.

Тырыш бул сабый чақта,
Йалқау, дип әйтмәсеннәр.
Үткән-барған синең хақта
Ғәйбәтне сатмасыннар.

Тырыш булсаң – үзең өчен,
Киләчәгең нур булыр.
Зур белемле ғамил *(галим)* булсаң,
Қартлык көнең бай булыр.

Йәшлегеңдә күп уйнасаң,
Ару-талу сизмисең.
Ақ иделдә су қойынып,
Көн узғанын сизмисең.

Йаз көнендә матур айлар
Бушлай ғына узмасын.
Безне уқытқан абыйлар
Безне күреп қуансын.

*Сөйләүче: Асхаров Шамилбек*
*Маликаджар улы (1931 елгы).*
*Каргалык авылы*

### *Теләк*

Хәзергә бергә булсак та,
Мәңгелеккә булмас бергәлек.
Хардәшлек эше қалсын өчөн,
Мин сезгә уқыйым истәлек.

Бәхетле булыйық, дусларым,
Мин сезгә бәхет телийем.
Җир йөзендә йәшәгәндә
Бер аwыры, бер җиңеле –
Аwырлықлар килсә, сабыр итәйек.

Қыр қазлары оча йырақларға,
Қарап қалам алар йағына.
Безнен йәшлек шул қазлардай
Һәр йыл сайын оча қартлықны.

Шулай да тормыш йәмле,
Тик сизәсезме аның кимүен.
Йәшик әле, дусларым,
Тату, тыныч рәхәт,
Беләбез бит ике килмәwен.

*Сөйләүче: Бикбулатова Асия*
*Абдразак кызы (1937 елгы).*
*Ярлы Түбә авылы*

## ӘСТЕРХАН КӨНДӘЛЕГЕ

*Илсөяр Закирова*

Казаннан Әстерханга юл тоттык. Урман, урман-дала, дала – төрле табигый зоналар бер-бер артлы үзгәрә бара. Башта мәһабәт урманнар юкка чыкты, алар урынына чуалып, тузгып үскән куаклык-агачлыклар ешрак күзгә чалына башлады. Инде алар да сирәкләнә бара. Самара, Чапаев, Балаково шәһәрләрен үтәбез. Волгоград шәһәре ерактан ук күренә. Бөек Ватан сугышының иң кайнар нокталарының берсе ул. Хәзер тыныч булса да шул көннәрнең энергетикасын саклый кебек бу шәһәр. Шәһәрнең бер ягыннан икенче читенә барып җиту ике сәгатьләп вакытны ала.

Волгоградның икенче ягында табигать шактый үзгә. Ярым корыган, ярым гарип агачлар очрый. Сирәк кенә чәнечкеле үләннәр күренә, туфрак коңгырт, кызгылт-сары, саргылт төстә. Машина тәрәзәсенә черкиләр өере бәрелә. Ял итәргә, аяк язарга туктаган идек, чәбәләнеп кире машинага кереп качтык. Әлеге черкиләр авызга, күзгә, борынга керә, сулап та булмый.

Алга таба юл алабыз. Юл кырыенда сирәк кенә карбыз-кавын, помидор кишәрлекләре күренеп кала. Алар Иделдән сузылган торбалар ярдәмендә сугарыла.

Ниһаять, Әстерханга җитәбез. Безне – экспедициядә катнашучыларны «Әстерхан татарларының мәдәниятен үстерү һәм саклау ассоциациясе» җитәкчесе Ильмира Үтәлиева каршы ала. Ул безне урнаштыру, кунак итү вазыйфаларын үз өстенә алган. Һәрбер авылның телгә оста, халыкның рухи мәдәниятен яхшы белгән, мәгълүматлы информантларын безнең белән очрашуга барлап куйган. Ильмира безгә һәр адымыбызда ярдәм итеп торды. Яшь, матур бу ханым бөтен яктан сокландыра. Алар ире Ринат Үтәлиев белән

өч ул үстерәләр. Милли рухлы, үз эшләренә бөтен күңелләрен биргән гаилә бу. Кече улларын, татарча камил сөйләшергә өйрәнсен өчен, һәр көн Әстерханнан татар авылына, татар балалар бакчасына йөртәләр. Ринат Үтәлиев – Әстерхан өлкәсенең Приволжский районы җитәкчесе. Эшен яратып, җаны белән бирелеп эшли.

Наилә ханым Потеева белән танышкач, аның тумышы белән Татарстанныкы булуын, лаеклы ялга чыкканчы нейрохирург булып эшләвен белдек. Хәзерге вакытта ул әстерхан татарларының тарихын өйрәнә, рухи мәдәниятен барлый, атаклы шәхесләр, тарихи урыннар турында мәгълүмат туплый. Наилә ханым Әстерхан шәһәренең татар халкы белән бәйле тарихи биналарын, татарлар яшәгән Тиякне, шәһәрнең күп санлы мәчетләрен күрсәтте, аларның һәрберсе турында мәгълүмат бирде. Мәсәлән, Әстерханга килгәндә Габдулла Тукай яшәгән йорт Татар-Базардан ерак түгел урнашкан. Бернинди истәлек тактасы куелмаган. Ике катлы кечкенә генә бу йорт хәзерге вакытта ярым җимерек хәлдә, такталары кылтырап торган верандалар, чарлаклар, пыялалары коелган тәрәзәләр... Шулай да анда берничә гаилә яши.

Наилә ханым авылларны да яхшы белә. Һәрбер авылда аны белеп, яратып каршы алалар. Күпләр аңа доктор буларак та мөрәҗәгать иткән булган. Әлеге өлкәнең хөрмәтле кешеләре белән дә безне Наилә ханым таныштырды. Ул Тиякнең бүгенге хәленә, шунда яшәүче кешеләрнең тарихына битарафлыктан ачына. Кайчандыр Әстерханның кайнап торган татар үзәге булган Тияк бүген ярым җимерек хәлдә. Биредә татарның атаклы шәхесләре тукталган. Шәрекъ клубында Һади Такташ төн буе шигырь укыган. Тиякнең атаклы Яшел мәчете бүген хәрабәгә әйләнгән. Аның нинди булганын диварына эленгән рәсем генә дәлилли.

Әстерхан татарлары төрле этник төркемнәрдән оешкан халык. Алар арасында Алтын Урда нугайларының варислары – юрт татарлары, кундрау татарлары (яки карагашлар), Казан губернасыннан күчкән татарлар һәм башка этник төркемнәр бар.

Хәзерге вакытка кадәр, бер-берсенә якын урнашуга карамастан, бер авылның сөйләме икенчесеннән аерылырга мөмкин.

Халык бай һәм матур яши. Бик зур тырышлык һәм хезмәт белән ирешкәннәр алар моңа. Йорт яны бакчасында помидор, тәмләткеч үләннәр үстерәләр. Помидор үсентекләрен көздән үк үстерә башлыйлар. Аларны теплицаларга күчерәләр. Икенче өлешен соңрак

чәчеп, ул үсентеләрне ачык җиргә утырталар. Һәр көн аларны сугару, чүп үләннәрен утау... – помидор өлгереп базарга чыкканчы куйган хезмәтнең иге-чиге юк. Помидорны биредә мадур диләр. Помидор үстерүнең девизы да бар – «Акша – бакша, товар – базар», диләр авыр хезмәтнең нәтиҗәсе турында. Ягъни, акча – бакча. «Ч» авазы күп сүзләрдә «ш» авазы белән алыштырыла.

Без барганда мадурның беренче уңышы өлгереп килә иде. Суы башкамы, кояшымы – помидорларның тәме бөтенләй башка, гаҗәп тәмле.

Кайчандыр миллионер булган колхозлар беткән. Сугарылган кырлар ташландык хәлдә. Алар уңдырышсыз җирләргә әйләнгән. Җиләк-җимеш бакчалары да корып ята. Йорт яны бакчаларында гына шәфталу, өрек, әстерхан чикләвеге агачлары күренә. Аларны үстерү шактый хезмәт сорый. Салкынга түзмиләр, шуңа күрә һәр агачны кышка киендереп, камыш белән төреп бәйләп калдыралар икән. Иң әрсез агачлар – тут агачлары. Алар бөтен җирдә үсә. Сары яки кара җимешләре коелып утыра. Ишек алларында тут агачы күләгәсенә сәкеләр куеп, ял итү урыннары булдырылган. Җырдагычы, алма белән йөзем дә (виноград) бөтен кешенең бакчасында үстерелә.

Алма бакчасына кереп,
Виноград өләшәм.
Тормышыңда бул бәхетле,
Мин дә теләк теләшәм.

Тәрәзәмнең рамкасы
Виноград агачы.
Виноград гел яфрак,
Син сандугач баласы.

11

Йортлар зур, төрле төсләргә буялган, йорт кыйгачларына пар карлыгач бизәкләре төшерелгән. Күбесе ике катлы. Беренче каты җиргә кертебрәк салынган. Бу – җәйләрдә эсседән котылу өчен шулай эшләнә икән. Ара-тирә камыштан үреп, өстән балчык белән сылап ясалган өйләр – мазанкалар да сакланган. Аларны хәзер кайберәүләр җәйге өй буларак ясыйлар икән. Биредә камыштан өй – мазанкалар салу җырга да кергән:

Өйләр салдым камыштан,
Башым салдым сагыштан.

Моңлы туган дип белмәгез,
Моңлы булдым язмыштан.

Камыш бөтен җирдә үсә. Кеше белән камыш арасында өзлексез көрәш бара. Бераз гына каралмый торса, бакчаларны камыш басып ала. Бер үрчесә, аннан котылу җиңел түгел.

Халык кунакчыл, юмарт, ачык йөзле. Әстерхан татарларының кунакчыллыгы һәм алар әзерләгән ашлар турында аерым китап язарга булыр иде. Милли кухня камыр ризыкларына бай. Нугай бәлеш, пахлава, бадәмгөл, шикәргөл, катланчык, катланчык пәрәмәч, күз бүрәк, лаксалба, бавырсак һәрбер бәйрәм өстәленә куела. Һәрбер бәйрәмгә пылау әзерләнә. Пылауда беренче катлам кабак. Бу ризык шуның белән без белгән пылаудан аерыла.

Әстерхан дигәндә, хәзерге вакытта бөтен кеше бу якның гаять кыйммәтле, затлы ризыгын – кара уылдыкны искә төшерә. Күрдек без аны. Балык базарында саталар. Килосы – аз да түгел, күп тә түгел – нәкъ кырык мең. Дөрес, аны кырык мең түләп тә алып кайтып булмый. Чөнки ул контрабанда санала. Күчтәнәчкә кипкән балык – вобла гына алдык. Аның каравы, гадәттыш бай рухи хәзинәләр туплап кайттык.

**ИДЕЛ БУЕ (ПРИВОЛЖСКИЙ) РАЙОНЫ**
**КИЛӘЧЕ АВЫЛЫ**

12.06.2013

Авылда 900 хуҗалык, 4000 якын кеше (16 милләт) яши.

**Авыл тарихы** Екатерина II заманында башлана. Телдән телгә, буыннан буынга күчеп сакланган истәлекләр буенча авылга нигез салучылар Казачий бугор ягындагы Мошаик авылыннан күчеп килгән.

Императрица Екатерина II вакытында Әстерхан морзасы Абызморза Ямгурчеев Бөтенроссия дворяннары утырышына делегат итеп җибәрелә. Кире Мошаикка кайткач, крестьяннар аннан нәрсә алып кайтуын сорыйлар: Ирекме яки коллыкмы? Абыз-Морза: «Императрица Екатерина II сезнең барыгызны да миңа крепостнойлар итеп бирде», – ди. Бу сүзләрне ишеткән крестьяннар Абыз-Морзаны тотып алып Байган ильмененә батыралар. Шуннан соң, җәзадан куркып, күчеп китәләр һәм хәзерге Киләче авылына нигез салалар.

**Ядгирова Римма Хәмит кызы,** 1939 елгы. Римма апа җырларга ярата. Элек авылда «Яшьлек» дигән халык ансамбле булган. Ул анда җырлаган. «Үтте дә китте яшьлегем», «Олы юлның тузаны» һәм башка җырларны яратып җырлый. Аның рухи хәзинәсеннән түбәндәгеләрне теркәдек:

**Киләче.** Баллы буена бер кеше килеп урнашкан да, халыкны «Киләче, киләче», – дип, ягъни «Килегез әле», дип Баллы буена чакырган. Шуннан авылны Киләче дип атаганнннар.

**Баллы елгасы**на мал төягән баржалар күп килгән. Бер бал төяп килгән баржа крушениегә эләгеп, бал суга тарала. Шуннан бу елга суы баллы булып, елганы да Баллы дип атый башлыйлар. Баллыны ахырда Балду, аннары Балды дип атый башлыйлар.

Авылга Баллы елгасы буйлап иртә-кич пароход килә иде, автобус урынына. Элек күпер юк иде.

**Су анасы.** Су анасы су килгән, су кайткан вакытта күренә. Төнлә чәчен озын итеп чыгарып, чәчен тарарга утыра. Балаларга, барма, Су анасы алыр, диләр. Өйлә вакытында, акшам вакытында чәчен тарый, диләр.

**Өй иясе.** Әйдә-әйдә безнең белән бергә бар, диләр, өй иясенә яңа өйгә күченгән вакытта.

**Әүлияләр.** Әүлияләр күп. Алланың әмере белән килгән кешеләр. Алар күзгә күренми торган кешеләр.

**Кыска җырлар**

Әй, дусларым, җырлыйк әле,
Җырламый тормыйк әле.
Чәчәк кебек яшь гомерне
Бушка уздырмыйк әле.

Әй, дускаем, син үзең лә,
Кашыңдин кара күзең,
Энҗедәйе тешең арасыннан
Сайланып чыга сүзең.

Кулыңдагы гармуныңны
Уйначы тартып-тартып.
Алма – алсу, чия – кызыл,
Син шунардан да артык.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемләре Гөлбостан шул,
Күкрәгемә кадар идем,
Роза чәчәге булсаң.

Кулыңдагы гармуныңның
Бер басмасы уйнамый.
Тышым кояш булган белән,
Эчемниләр уйламый.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Хәдичә.
Уйнар өчен, көләр өчен
Ясалгандыр бу кичә.

**Бәйрәмнәр**

**Мәйдан.** Октябрь бәйрәмендә халык мәйданга чыга, төрле уеннар уйный, ярышларда катнаша.

**Кайтым** булган әниләрнең яшь вакытында. Әниләр-кайнаналар далага чыкканнар. Мал суеп, су-елга буенда өлкүн (зур) бөек казаннарда пешергәннәр. Бөтен кешене сыйлаганнар.

Ул – яңгыр булмаса, корт басса, сәдака бирү, кешеләрне, ятимнәрне сөендерү, илдән дога алу. Ул бәйрәмнәрне кайтым дип әйтәләр. Ураза беткәч тә, корбаннан соң да. Чәчү беткәннән соң, кайтым итик, сәдака бирик, дип сөйләшәләр.

**Вечер.** Элекке аулак өйләрне безнең заманда вечер дип атыйлар иде. Егетләр армиягә киткәндә, авылга берәр кунак кыз яки егет килсә, вечер уйный идек.

**Абдуллаева Зөлхәбирә Әүбәкер кызы дәфтәреннән алынган материаллар** (1929–2012 елларда яшәгән). Зөлхәбирә Әүбәкер кызы үзе ишеткән һәм башкарган җырларны, бәет-мөнәҗәтләрне дәфтәренә теркәп барган. Үзе дә бәетләр, шигырьләр иҗат иткән.

### Сак-Сок бәете

Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,
Сак белән Сокның бәетен ишетәсе.

Халык агыла, китә басуга.
Әти дә китте урак урырга.

Әти киткәчтен утырып уйнадык,
Утырып уйнадык, сугышып җыладык.

Утырып уйнадык, сугышып җыладык,
Әнкәй каргагач, минут тормадык.

Безләр кош булгач, киртәгә кунгач,
Әнкәй җылама, үзең каргагач.

Уң якта канат, сул якта канат,
Очып киткәндә калдылар карап.

Әнкәй каргады, әткәй, сизденме,
Турыңнан уздык, әткәй, күрдеңме?

Әнкәй каргады безне ачудан,
Әткәй дә кайтты арып басудан.

Балалар кайда, дип әткәй сорыйдыр,
Каргадым, диеп әнкәй елыйдыр.

Балам-балам, дип әнкәй җылыйдыр,
Ник каргадың, дип әткәй тиргидер.

Безләр кош булгач, урманга баргач,
Йөрәгем ярылды, зур имән аугач.

Аю үкерә урман эчендә,
Сак-Сок булдык без Кадер кичендә.

Өйгән кибәнне җилләр тарата,
Каушабыз дигәч, хәзер таң ата.

Каргады безне газиз әнкәбез,
Якты дөньяны күрми китәбез.

**Фәрештәләр турында.** Җәбраил – Алламның әмер вә тыюларын пәйгамбәрләргә китерә торган фәрештә. Аллаһ белән пәйгамбәр арасындагы илче. Микаил – табигать эшләре белән җитәкчелек итә итә торган фәрештә. Яңгыр, җил, һәм табигатьтәге ризык эшләре белән җитәкчелек итә торган вазыйфалы фәрештә.

**Якты дөньяны күреп туймадым**
(мөнәҗәт)

Әҗәл ширбәтен бер көн эчәрмен,
Якты дөньядан бер көн кичәрмен.

Әҗәлем җитәр, тыннарым бетәр,
Ясин укырга вакытлар җитәр.

Укый алмамын, бетәр сулышым,
Артымнан калсын дога кылучым.

Газраил килер, җанымны алыр,
Кызыл йөзләрем саргаеп калыр.

Якты дөньяны ташлап китәрмен,
Караңгы гүрдә ни хәл итәрмен.

Караңгы гүрдә калыр бу башым,
Ак фәрештәләр булсын юлдашым.

Мөшкел хәл икән җанны бирүе,
Авыр хәл икән гүргә керүе.

Зифа буемны үлчәп алырлар,
Караңгы гүргә илтеп салырлар.

Зәгыйфь тәнемне каты тотмагыз,
Кире кайталмам, ашыктырмагыз.

Ерак җирләрдән дуслар килгәннәр,
Карап калсыннар якын туганнар.

Йорттан чыкканда, ашыгып чыкмагыз,
Бик елашмагыз, зинһар, чыдагыз.

Тордым дөньяда бераз вакытлар,
Салкын туфрактан безнең ястыклар.

Бу ят җирләргә кемнәр китергән,
Безгә юлларны кемнәр җиткергән.

**Ана васыяте**

Сөйлим әле, балаларым, сүзләремне,
Сүзләремне түгел, моңнарымны.
Мин үлгәчтен, Коръән укытыгыз,
Тәрәзәдән килеп тыңлармын үзегезне.

Зинһар, балаларым, онытмагыз,
Уздырырга минем өчемне,
Белгәннәргә биреп дога кылдырыгыз,
Буш калдырмагыз атна кичләрне.

Зинһар, балам, уздырыгыз җидемне,
Минем рухым кайтыр сезнең янга.
Шушы язуымны калдырамын
Мин үлгәчтен сагынып сөйләргә.

Тар ләхетләр эчендә ятканда
Кырыгымны уздырганны көтәрмен.
Догаларыгыз барса, шатланырмын,
Онытсагыз, нихәл итәрмен.

Балам, илле бер көнемне уздырыгыз,
Минем сезгә актык сүзләрем.
Карчыкларны җыеп укытыгыз,
Якты нурлы булыр гүрләрем.

Тар кабергә илтеп кую белән,
Җавап алу өчен килерләр.
Камил иман белән барган булсам,
Җәннәтләрдә урын бирерләр.

## Егет бәете

(*Бу әсәр тексты алга таба «Гомәр бәете» исеме белән тулысынча бирелә*)

Башыма кигәнем серый фуражка,
Карап булмый нурлы кояшка.

Эх, югалдым мин егет, калтырый куллар,
Үтәдер гомер, үтәдер еллар.

Мәдрәсәдән чыктым имтихан биреп,
Кешелектән чыктым эчеп-исереп.

## Кыска җырлар

Алма бакчасына керсәң,
Алмасын алып аша.
Инде калган гомереңне
Тыныч рәхәт яшә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Бибинур.
Бигрәк матур күренәсең,
Йөзләреңдә нинди нур.

Кошлар канатларын коя,
Тезелеп кагынганда.
Картинкагызга карармын
Өзелеп сагынганда

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр калайлар.
Матур-матур җырлар җырлый,
Менә нинди малайлар.

**Кужамкулов Румиль Мәүлет улы** (1948 елгы). «Яшьлек» ансамбле баянчысы. Ул безне авылда оештырылган рус совет шагыйре Михаил Кузьмич Луконин музее материаллары белән таныштырды, һәм түбәндәгеләрне сөйләде:

**Муса Җәлил турында.** 1933 елда Киләче авылына «Ялкын» журналы редакторы Шакир Мөслим улы Фәтхуллин белән атаклы шагыйрь Муса Җәлил килә. Ул вакытта колхоз рәисе Ибраһим Мәхмүдов була. Мәхмүдовлар өендә шагыйрь йоклаган кровать озак еллар шул урында тора. Хуҗалар анда бер кешене дә утыртмый.

Муса Җәлил авылда 11 көн яши, Киләче халкына уңыш җыярга булыша. Шагыйрь «Җиһан» поэмасын Киләче авылында булганнан соң яза. Поэмада Киләче авылының уңыш җыйган вакыты тасвирлана:

Җил тирбәткән сары җиз башаклар
жиргә яттылар.
Тук бодайлар иркен амбарларга
җырлап актылар.

Бакчаларда торма, кишерләрдән
таулар өелде.
Помидорлар пешеп кызарды һәм
җиргә иелде.
Бакчалардан кайта авылларга
кавын-карбызлар.
Көн буена үтеп тора
тулы обозлар.

Биредә булганнан соң, авылда алган тәэсирләр нәтиҗәсе буларак шулай ук «Күк юрга», «Колхозчы кыз», «Балыкчы кыз җыры» һәм башка әсәрләре языла.

**Алтын кабак.** Көзен октябрь бәйрәмендә мәйданда төрле уеннар оештырыла иде. Ирләр «Алтын кабак» атышалар. Баганага ат кылына тәңкә асыла. Шул тәңкәгә аталар. Элек ул алтын тәңкә булган. Ул, дөресрәге, «Алтынга бак» булырга тиеш.

**Әхмәтова Люция Әбдрәшит кызы** (1960 елгы). Җирле үзидарә башлыгы. Аннан язып алынган мәгълүматлар:

**Киләче авылы Баллы (Балды) суы** буенда урнашкан. Киләче авылы янында Каспий диңгезенә бара торган бал тутырган мичкәләр төягән баржа баткан. Авылда күчмәләр яшәгән. 2012 дә авылга 225 ел булды. Беренче килүчеләр Казачий Бугордан була.

Киләче авылы өч авылдан торган – Аргы, Бирге, Бөгәҗел, ягъни Урта авыл. Авылда 3 мәчет була.

**Әүлияләр.** Авыл түбәсендә 4 әүлия җирләнгән. Нургали ата, Гайшә хан, Фатима әүлия. Берсен белмим. Алар өстендә өй кебек эшләнгән. Өстенә 11 ак байрак куелган. Ул зиратның уртасында урнашкан. Аларны Нәсимә апа ел саен яңартып тора. Гайшә хан, Фатима әүлия – караучы, яки дәвалаучы әүлияләр булган.

Безнең авыл янында таулар – Бэровские бугры урнашкан. Аларны түбә дип атыйлар: Маштак түбә (низкий), Авыс түбә, Биш түбә, Тәмикле, Куян атау, Биш атау, Төркмән атавы.

**Курманова Нәсимә Насыйр кызы** (1939 елгы) – авылның муллабикәсе. Ул сөйләгәннәрдән:

**Шайтан уйнак.** Өермәне шулай атыйбыз. Шайтан уйнак уртасына пычак ташласаң, кан чыга. Уртасындагы пәри-шайтан үлә.

**Аждаһа елан** – усал хатыннарны шулай атыйлар.

## ҖӘМӘЛЕ АВЫЛЫ

13.06.2014

600 ләп хуҗалыкны берләштерә.

Авыл исеменең килеп чыгуын авыл халкы гарәп теленнән кергән дөя дигән сүздән дип тә, гүзәл, матур дигән сүздән дип тә аңлата.

Күпчелек халкы, 20 нче елгы ачлыктан качып, Казан ягыннан күчеп килгәннәрдән. Кавказ, монгол халыклары да күчеп килгән. Төрле халыклар кушылган. Татарлашкан нугайлар да күп.

Җирле үзидарә башлыгы Рамазан Мөхәрәмов милли рухлы кеше. Авылда гына түгел, район, өлкә масштабында үткәрелгән чараларда да башлап йөрүчеләрнең берсе.

**Идиятуллина Румия Усман кызы.** Җырчы, үзенең концертлары була. Халык җырларын башкара, әнисеннән өйрәнгән бәет-мөнәҗәтләрне әйбәт белә. Әтисенең әкиятләр күп белүен сөйли.

Аннан язып алынган **кыска җырлар:**

Алы дисәң, алы бар,
Гөле дисәң, гөле бар.
Совет илен саклап кайткан
Бер мировой яры бар.

Ал дигәнең ал булсын,
Гөл дигәнең гөл булсын.
Байлык баскыч, күңел юаткыч
Җаның сөйгән яр булсын.

Сандугачның балалары
Нигә сигез булмаган?
Бу дөньяның рәхәтләре
Нигә тигез булмаган?

Башыңа япкан ак яулыгың
Яңа яуган кар кебек.
Йөзләрең якты ай кебек
Сүзең сары май кебек.

Тәрәзәнең алларында
Ике банка гөлем бар.
Аның берсе – яшьлек вакыт,
Икенчесе – сөйгән яр.

Өстеңә кигән күлмәгең
Агара торган түгел.
Кая барсаң да, син герой,
Югала торган түгел.

Дусларымның дуслары бар,
Тотып ашарлар иде.
Әле ярый үзем үткен,
Суга ташларлар иде.

Ятлар, ятлар дия-дия,
Күңлен салды ятларга.
Ятлар булмас синең кебек,
Салды янган утларга.

Яна йөрәгем, яна йөрәгем,
Яна йөрәгем ут кебек.
Читтән караган кешегә
Бер кайгым да юк кебек.

Яна йөрәгем, яна йөрәгем,
Янганын үзем беләм.
Тагын шулай янар булсаң,
Ахры, әҗәлсез үләм.

Сандугачлар басып сайрый
Урманда каеннарга.
Син дә сайра, бул сандугач,
Бирешмә кайгыларга.

Эчем пошканга микән,
Чыгыйм тышларга микән,
Эч серемне кемгә сөйлим,
Очкан кошларга микән?

Утырсам, уйга батам,
Кулымда кош уйнатам.
Үзем елыйм, үзем җырлыйм,
Шулай күңелем юатам.

Сандугачның балалары
Сайрыйлар басмаларда.
Күңелемне юаталар,
Кайгымны басмаса да.

Тәрәзә төбем алмагач,
Кистем алма булмагач.
Ни ашасам да, карным ач,
Бәгырькәем булмагач.

Кулъяулыгым кара ефәк,
Агармыйдыр юсам да.
Күз алларымнан китмисең,
Янымда булмасаң да.

Кулъяулыгым суга төште,
Суның читендә дә юк.
Минем күңлем сине уйлый,
Синең исеңдә дә юк.

Иртә торып суга барам,
Өй артында чишмәгә.
Яшьлек чагым кире кайтса,
Белер идем нишләргә.

Су буйларында җырласам,
Тавышым китә су буйлап.
Бөтенесе ятып йоклый,
Мин ятам сине уйлап.

Очып барган кыр казыннан
Яшьлегемне сорадым.
Ул да миңа җавап бирде,
Мин утырып еладым.

Эчем пошса, чыгам тышка,
Карыйм сайраган кошка.
Сайраган кош миңа карап
Сабыр итәргә куша.

Самовар салдым кайнарга
Мәскәүдәге байларга.
Эчем поша, йөрәгем яна,
Никтер, шушы айларда.

Самовар салдым күмерсез,
Кайнап чыгар, күрерсез.
Өстәлегез тулы бит тә,
Утырасыз күңелсез.

Сандугачның баласын
Тотсам, үтермәс идем.
Синең белән бер күрешсәм,
Мәңге үкенмәс идем.

Керләр юам агымда,
Сабыннарым янымда.
Елыймын да, җырлыймын да,
Сабыр итәм тагын да.

Керләр юам агымда,
Сабыннарым янымда.
Елыймын да, күзем сөртәм,
Чиккән кулъяулыгыма.

Керләр юам агымда,
Сабыннарым янымда.
Уйлыймын да, сабыр итәм,
Башымның саулыгына.

Кимим киемем булса да,
Еламыйм күңлем тулса да.
Миңа шулай Ходай язган,
Чыдыйм авыр булса да.

Өйләр салдым камыштан,
Башым салдым сагыштан.
Моңлы туган дип белмәгез,
Моңлы булдым язмыштан.

Сабын савыт нигә кирәк,
Сабын салырга кирәк.
Сагынсаң да, саргайсаң да,
Сабыр итәргә кирәк.

И икегез, икегез,
Икегезнең битегез.
Яшьлек дәртен, мәхәббәтне
Картлыккача илтегез.

Дошманнар безне сөймиләр,
Алай да болай диеп.
Без аларга отвечаем
Замана шулай диеп.

Уф Алла, дигән тавышка
Куян кача камышка.
Йоклаганнар уянсыннар
Без җырлаган тавышка.

**Картка бирелгән кыз бәете**

Татар аулында урам гизгәндә
Очырадым татар туена.
Туй туйлаганда, кыз елаганда
Утырдым да калдым бер уйга.

Ишек ачылды, халык тын калды.
Никахка муллалар керделәр.
Аңладым шунда кызның елавын
Бичараны картка бирәләр.

Әнкәсенә әйтә шушы кыз бала:
«Нигә мине картка бирәсез?
Мин бичараны, яшь кыз баланы
Карт бабайга әрәм итәсез».

«Шуңа бирәмен, кыз балакаем,
Акчасы күп ул карт бабайның.
Акчасын санап, сакалын тарап,
Бабай белән гомер итәрсең.
Яхшы атларда, ефәк фаэтонда
Бабай белән кодрып йөрерсең».

«Бармыйм, әнкәем, бармыйм, бәгырем,
Барасым килмидер бабайга.
Әйдә бир мине, газиз әнкәем,
Теләнеп йөрегән малайга».

Кызның янына җиңгәсе керә:
«Тукта, бер сүз әйтәем.
Син бичараны, яшь кыз баланы
Сөйгәненә алып китәем».

Тиз-тиз киенеп, тизрәк җыенып,
Әйберләрен төенгә бәйләп:
«Эзләмә юкка, калсын карт бабай,
Шул аңарга минем бүләгем».

Кызны алырга карт бабай килә,
Кыз урынына эзләмә юкка.
«Ах, сез аларны, качып киткәннәр.
Акча бирүем чыкты юкка.

Алтын шикелле малларымны мин
Барысын да сатып бетердем.
Көмеш шикелле сакалымны мин
Барысын да йолкып бетердем».

**Мәкальләр:**

Тар урамда ут чыккан, ике хатын тончыккан.

Авырмаган якларына ята бирсеннәр.

**Гомәрова Мәйсәрә Хәким кызы** (1936 елгы). Мәйсәрә апаның җиде буыны да шушы авылдан. Ул үзе күп талантларга ия кеше. Шигырьләр дә яза, ата-бабалардан калган мәдәни һәм рухи мирасны барлап өендә этнография музее булдырган. Аның күңел дәфтәреннән теркәлгән мәгълүматлар:

**Җыен агасы.** Туй булсынмы, аулак өйдәме, алып баручы була, тамада кебек, тамаданы башкача да әйтәләр иде. Җыен агасы, диләр. Күңел ачканда «җыен агасына дүрт кыз» дип әйтәләр. Җыен агасы чыгып уртага баса. Ул яулыклар әзерләп килә. Дүрт кызга икешәр яулык бирә. Дүрт кыз чыгып, уртага дүрт яктан баса. Җыен агасы бии. Аның бии торган үзенең көе була. Бөтен кеше бер көйгә биеми. Уйнаучы белә кемнең нинди көйгә биегәнен. Ул шул көйне уйный. Дүрт кыз шул көйгә такмак әйтәләр. Такмак әйтеп чәпәнәй кагып торалар. Кул сабуны (*чабуны*) бездә чәпәнәй кагу диләр.

Ике кул яулыгыңа,
Башыңның саулыгына,

дип берсе әйтә. Икенчесе әйтә:

Бас идәннең уртасына,
Дошманнан куркасыңмы?

Шулай җыен агасына көч бирәләр. Ул аның саен дәртләнеп бии. Менә шундый такмаклар да бар.

Әйлән түгәрәк,
Син булырсың күбәләк.
Кулъяулыгың читенә,
Гөлләр үссен битенә.

Туйда һәр кешенең якын кешесе була. Шул җыен агасы була инде. Дүрт кыз җыен агасы белән уртада бии. Аннары ул кызлар кулларындагы яулыкларны биреп башкаларны уртага чакыралар. Биергә чакырганнан соң ике яулык бирәләр. Чакырылмаган кеше үзлегеннән чыгып биеми. Уртада һәрвакыт биш кеше була.

## Бишек җыры

Йокла балам, йом күзең, йом күзең,
Йөрәгемнең йолдызы, йолдызы.
Кичтән йокың калыр да,
Еглап үтәр көндезең, көндезең

Арыганда йоклатырга, йоклатырга,
Ал бишеге бар аның, бар аның.
Җырлар җырлап тирбәтергә,
Үз әнкәсе бар аның, бар аның.

Арыганда йоклатырга, йоклатырга,
Тал бишеге бар аның, бар аның.
Елаганда юатырга
Үз эткәсе бар аның, бар аның.

Йоклап торгач уйнарсың-көләрсең,
Җимешем, үсәрсең, пешәрсең
Өемнең түренә, түренә
Син дә бишек эләрсең, эләрсең.

## Кыска җырлар

И, дускаем, килдеңмени,
Күрмәдем килгәнеңне.
Тулган айларгай охшатам
Елмаеп көлгәнеңне.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле
Барыбыз бергә чакта.
Калыр истәлек урнына
Дуслар аерылган чакта.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җыр бит сатып алмаган.
Борынгылар да җырлаган,
Телләрендә калмаган.

Хуш килдегез, кодалар,
Кодалар-кодачалар.
Сездә ничек, бездә шулай,
Җырлап күңел ачалар.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Ризван,
Сөюеңә риза булдым,
Хатымны алып куан.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Марлис икән,
Сөюемнең чынлыгына
Иркәм ышана микән.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Нәфисәме?
Күргән саен күргем килә,
Әллә сихерләдеңме?

Кулымдагы йөземнең
Исемнәре Әминә.
Үз-үзеңне зурга санап,
Миңа ярлар күп димә.

Кулымдагы йөземнең
Исемнәре Хәлимә.
Ятлар белән чуаласың,
Җаным көйдереп йөрмә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Фәризәхан.
Карамыйсың, өзелеп сөям,
Әллә булдың инде хан.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Фрәңгизә.
Очырашалмый интегәмен,
Ул бит илләрне гизә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Миһрбану.
Дәртемә дәрман өстәде,
Синең белән очрашу.

Өстемдәге күлмәгемнең
Клины алты икән
Йөзләреңдә кояш уйный,
Кулларың алтын икән.

Көннәрең дә, төннәрең дә
Яктылыкка бай синең,
Җәйләрең дә, көзләрең дә
Кышларың да май синең.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Галимҗан.
Күргән саен күбрәк сөям,
Белмим синдә нинди җан?

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нурсанә.
Күз өстендә кашың ничек,
Мине шулай күрсәнә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Надия.
Төн йокымнан уянамын,
Җаныем, дия-дия.

### КОЛАКАУ АВЫЛЫ

13.06.2013

**Шамгунова Ажмангул Садыйк кызы** (1930 елгы),
**Гобәйдуллина Гөлсинә Гаяз кызы** (1954 елгы),
**Шабанова Гөлмира Әдһәм кызы** (1968 елгы) сөйләгәннәрдән:

**Кыз ярәшү.** Киләләр яучылар. Мәсәлән, әнисе, ике сестрасы. Китерәләр бүләк – конфет, шоколад бер подноста. Материаллар әнисенә, әтисенә – күлмәк, кызга – алтын йөзек. Шуннан ярәшәләр, бу ярәшү була.

**Әбиләр туе.** Бу туйга хатын-кызлар гына килә. Кызга киемнәр китерәләр. Бу «Тугыз» була. «Тугыз» китерәләр бүләккә. Алтын, киемнәр китерәләр, зур поднос татлылар белән. Шоколад, конфет, шоколад һ.б. Зур бантик бәйлиләр, подносны җыеп бәйләп.

**Сөт хакы.** Сөт хакы – бер куй, 16 килограмм дөге. 5–10 мең акча. Егетнең туганнары кызның ата-анасына бирәләр.

Әбиләр туена пылау пешерәләр. Аракысыз уза. Пәхләвә белән чәй эчәләр.

Саз (*гармун*) уйныйлар, кавал (*бубен*) сугалар. Сазчылар, кавалчылар килә. Уйныйлар, бииләр.

Туйга килгән һәр кешегә бүләк бирәләр. Материал, тастымал, сөлге бирәләр.

Кодагыйлар килә. Егет яктан кыз биткә (*ягына*) бүләкләр китерә. Кыз бит тә бүләк бирә.

Бер мамай (*муллабикә*) дога укый. Аннары теләк телиләр. Бәхетле булсын, кайнана-кайнатасының сүзен тыңласын, диләр.

**Кичен яшьләр туе – кияү сый.** Кияү сыйда кызның әти-әнисе башлап җибәрә. Кияүнең туганнары, дуслары, егетләр авыл читендә машиналардан төшеп, җәяү киләләр. Алар кавыллар кагып, саз уйнап, җырлап-биеп киләләр. Кияү туй шатерына кермәскә тырыша, киреләнә, ялындыра. Аны күтәреп кертәләр.

**Кияү-аракы.** Туй уртасында «кияү-аракы» алалар. Ул аракыны башта өстәл астына яшерәләр. Кыз бит сорый. Кыз ягы җырлыйбии, аларга җырлаган-биегән өчен аракы бүләк итәләр. 12 бутылка. Аннары ул 12 шешәне өстәлгә куялар. Алар кызыл бантиклар белән бизәлгән. Бу аракыны эчеп бетерәләр. Ул ленталарны һәркем алырга тырыша. Үз балаларына да шундый туй насыйп булсын дип, һәркем тизрәк чишеп үзенә алырга тырыша.

Аннары бер атнадан кызга придан бирелә, йорт җиһазлары – диван, башкалар.

Регистрациядән соң шатерда егет ягында туй була. Башта – «Бит күрем». Кыз шатерда, әбиләр туенда һәр мамайның кулын алып чыга. Килен, алдында – егетнең җиңгәсе, артында – кызның җиңгәсе. Мамайлар «Хәерле булсын!» диләр. Шунда акча чәчәләр. Өстәлдә тугызны күрсәтәләр. Җыелган халык акчаны җыя. Йөргән балалар җыя.

**Бишек туе.** Бишек туена бүләкләр алып баралар. Кызның анасы оныгына, кыз бала туса, алтын сырга алып бара.

### Кыска җырлар

Урал сулары булсам,
Уралып агар идем.
Яңгыр тамчылары булсам,
Алдыңа тамар идем.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлсинә.
Өзелеп сөймә, аерылырбыз –
Димәдемме мин сиңа.

**Түбәдә Кыз Әүлия** булган. Ул җирдә ел саен авария була. Егетләр авариягә очрый. Ул кешеләрнең төшенә кергән. Мине казып алыгыз, машиналар аяк-кулларымны таптап йөри, дип бер бабайның төшенә кергән.

**Өлкән сомнарны** (*зур җәен балыгы*) **аждаһа** диләр. Алар кеше ашый диләр.

### ЯРЛЫ ТҮБӘ АВЫЛЫ

14.06.2013

980 хуҗалык. Анда 3500 дән артык кеше яши. Төп халкы – татарлар. Руслар, казакълар, нугайлар да яши. Яшелчә үстерү белән шөгыльләнәләр.

Ярлы Түбә авылы апалары китапханәгә килделәр, бергә җыелып, сөйләшеп утырдык. Җырлап-биеп күрсәттеләр, төрле ышанулар, ырымнар белән таныштырдылар.

**Ярлы Түбә** (дөресрәге Яр Түбә). Яр өстендә, тау өстендә утырган авыл булганга шулай аталган.

**Царев елгасы.** Моннан Петр беренче үткән. Яр буеннан Каспийга үткән. Царев елгасын татарча Ярлы Түбә ягасы дип атаганннар.

### Кыска җырлар

Ал итә-итә-итә,
Гөл итә-итә-итә,
Яннарыңа барыр идем
Ял итә-итә-итә.

Әйдә, дуслар, җырлыйк әле,
Җырлыйк әле сигезне.
Җырламас идем сигезне,
Сез, дусларым, сөйкемле.

**Ышанулар**

Аяк тырнагы белән кул тырнагын бер көндә алу ярамый. Яхшылык белән яманлык бергә килә, диләр иде.

Вторник көнне кер юарга, су түгәргә ярамый. Кабереңә су коярлар, теге дөньяда.

Җомга көн кер юарга ярамый. Әгәр бай булып, байлыгыңны кая куярга белмәсәң, кульяулыгыңны булса да ю, диләр.

Вторник көнне су коярга, кер юарга ярамый. Ул көнне аккан су, кан булып агар, ди. Ул пәйгамбәрнең туган көне икән.

Тырнакны җомга көн төштән соң кисәргә ярый. Ял көннәре ярамый.

Бала янына Коръән, кайчы, пычак саласың, җен-пәри килмәсен, дип.

**Өй иясе.** Яңа йорт салгач, яңа өйгә өй иясен дә күчерәләр. «Мин китәм яңа йортка, әйдә бергә киттек!» – дип, күсәнкәгә утыртып алып китәләр.

**Шайтан.** Бар ул. Ул кызың, улың булып кычкыра, әгәр чыксаң, алыштыра икән. Тыңлап торырга, икенче, өченче тапкыр кычкырганын көтәргә.

**Туй йолалары.** Бездә туйлар берничә этаптан тора. «Кияү сый» – кыз ягында, «Тугыз туй» – егет ягында уза. «Бит күрен»дә кыз күрешә.

Никахта кыз аерым утыра. Аның чәчен тарыйлар. Егет никахка яулык, тарак, пыяла (*көзге*) китерә. Чәчен дуслары тарый. Егет кызга тугыз бирә. Чатырда бер очыннан икенчесенә җеп эләләр. Анда бүләкләр эленә. Егет 16 килограмм дөге, бер куй, конфет һәм башка бүләкләр, кызның әти-әнисенә бүләк бирә. 12 шешә «кияү аракысы» китерәләр.

Кияү чатырга керми, аяк терәп каршы тора. Аны күтәреп кертәләр.

Кияүгә туйда «кием» (*бүләк*) бирелә.

Кияүне ашаткач-сыйлагач, инде безнең сый бетте, хәзер кияү сыен күрик, диләр. Кияү ягы кыз ягына җәза бирә – җырларга-биергә куша. Шуннан аракы бирәләр.

Туй өчен алдан ук балкуас куялар.

**КЫЗАН АВЫЛЫ**

15.06.2013

**Исхакова Баузия Нәҗметдин кызы** (1928 елгы). Баузия апа бик күп җырлар белә. Җырларны кая барса, кайда ишетсә, шунда отып ала, өйрәнә. Казаннан килгән пластинкалардан да бик күп җырлар өйрәнгән. Шушы авылда, шушы якларда җырланган җырларны да башкара. Гомер буе сәхнәдә җырлаган, җыр конкурсларында катнашкан. «Сакмар буе», «Урман кызы» һәм башка җырларны яратып җырлый. Бәетләр-мөнәҗәтләр дә белә. Буш вакытында чигү чигә. Баузия ападан язып алынган җыр-бәетләр һ.б. мәгълүматлар:

**Хушаваз**

Җарлы Түбә, Җәмәле,
Җайлы икән кыдырмага.
Сәмәк белән Кылахау
Бозылып яткан батага.
Сүләнкә дигән сүзле халык
Керешмәсен арага.
Каңга дигән кыңгыз халык
Каңгырып китсен далага.
Каргалык, Майлы күл, Кызаным,
Дан, сәдака Аллага.

**Аманжан**

(Нугай җыры)

Кашыңның карасына, Аманжан,
Кер туган арасына, аман.
Мин сине охшатамын, Аманжан,
Сандугач баласына, аман.

Күзләрең күктер синең, Аманжан,
Күк атның ялы-яме кебек, аман.
Күренәсең күземә, Аманжан,
Дөньяның малы кебек, аман.

Дөнья малын дөньяга, Аманжан,
Дөнья сиңа, син миңа, аман.
Сине бер көн күрмәсәм, Аманжан,
Йөрәгем ярты була, аман.

Син дә, мин дә бер яшьтә, Аманжан,
Икебезнең дә уебыз башта аман.
Синең биргән яулыгың, Аманжан,
Безнең тәрәзә башы, аман.

Сап-сары, сары алтын, Аманжан,
Сапта гына чересен, аман.
Сине миннән аерган, Аманжан,
Сары майда йөресен, аман.

Таудан таулар арасы, Аманжан,
Тауда куян баласы, аман.
Мин сиңа барыр идем, Аманжан,
Син кулакның баласы, аман.

## Нәүруз яки Амил бәйрәме котлаулары

1. Яз килде яппан,
Тегелде кара чапан.
Инде килде яз заман,
Шабдин-шабдин,
Азан-азан,
Инде килде Мүбәрәк.

2. Кара тавык какылдап
Патлык теләп торады.
Яшь чәүкәләр шакылдап
Яулык сорап торады.
Шабдин-шабдин,
Азан-азан,
Инде килде Мүбәрәк.

3. Өй артында күлләр,
Бакылдайды казлар
Безгә яулык бирмәйде,
Киленчәк вә кызлар.
Шабдин-шабдин,
Азан-азан,
Инде килде Мүбәрәк.

4. Тор-тор, анай, тор, анай,
Төлке туның ки, анай.
Безгә яулык бир, анай,
Шабдин-шабдин,
Азан-азан,
Инде килде Мүбәрәк.

## Кыска җырлар

Алсу, алсу, алсу диләр,
Алсуга кызыл тамган.
Былбыллар аерылмый икән,
Былбыл буласым калган.

Ишегем алды бодаемны
Кичке салкын ураем.
Бакчада үскән гөлләр кебек
Аермасын Ходаем.

Якын дустым, белә алмыйм
Ниләр уйлаганыңны.
Поезд китте, күрми калдым
Яулык болгаганыңны.

Шәлләр алдым сигезгә,
Чачаклары тигезгә.
Бир кулыңны, мин дә бирәм,
Яшик әле тигездә.

Син матурым, син гүзәлем,
Син тормыш күбәләгем.
Яшәгез сез бу дөньяда,
Шул гына теләгәнем.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырламый тормыйк әле.
Чәчәк кебек гомерләрне
Бушка уздырмыйк әле.

Айлары урак икән.
Булыр-булмас уйлар уйлап,
Бу башым дурак икән.

Толстовка кесәсендә,
Ислемай шешәсендә.
Эшләп эшкә кулым бармый,
Исемә төшәсең дә.

Уфа тараклары белән
Чәчләрем тараганда.
Үз гүзәлең гүзәл булган
Ятларга караганда.

Кайсы кибеттән алсам да,
Кулъяулыгым ал була.
Сезнең яктан искән җилләр
Йөрәгемә ял була.

Эчим микән, эчмим микән
Суларның салкыннарын.
Эчсәм, алып китәр микән
Эчемнең ялкыннарын?

Исемлесе бер генә.
Шул исемле гөлләр кебек
Исләремдә син генә.

Аклы ситса күлмәгеңә
Каралар тигәләгән.
Кояш синең йөзләреңә
Нурларын сибәләгән.

Уртадагы урындыкка
Утыргансың бер үзең.
Матур үзең, үтә сүзең,
СССРда бер үзең.

Безнең авыл егетләре
Фабрикада станда.
Син син генә, син бер генә
Бөтен Татарстанда.

Фуражкаңны күтәр-күтәр,
Арасыннан җил үтәр.
Бу дөньялар үтәр-китәр,
Кавышканга ни җитәр.

## Егет белән кыз җыры

Стена көзгем ватылды
Ал пудр ягынганда,
Син дип кемнәргә карыйм соң,
Өзелеп сагынганда.

Көзгеләреңне ваттырып
Ал пудр ягынасың.
Ал пудрлар ягынгачтын
Ник мине сагынасың.

Юрган ябынасыңмы?
Одеал ябынасыңмы?
Одеаллар ябынганда
Мине сагынасыңмы?

Одеаллар да юк монда,
Юрганнар да юк монда.
Көне-төне пуля ява,
Синең кайгың юк монда.

## Ямщик җыры

Ком сахрасында кояш нуры көлә,
Шул ком-сахрада яшь ямщик үлә.
Сизәдер ямщик әҗәл җиткәнен,
Чакыра янына якын иптәшен.

Иптәшем, хәзер мин үләм инде,
Ком сахрасына күмәрсең мине.
Минем атымны тапшыр әткәмә,
Актык сәламем әйтче әнкәмә.

Әйт хатыныма, мине көтмәсен.
Үзенә башка юлдаш эзләсен.
Алчы кулымнан алтын йөзегемне,
Хәләл хатыныма сөйлә сүземне.

Өзелде шунда аның сүзләре,
Йомылды аның кара күзләре.
Ком сахрасында вак-вак кар ява,
Ямщикның аты моңаеп бара.

## Мөршидә бәете

Иптәшләр, хәзер җырлыйм мин сезгә,
Туры килер бу эш кемгә дә.
Минем иптәшем зиратларга
Кызын илтте ул үтерергә.

Ата-анасы яхшы тордылар,
Кайгы төште бу матур кызга.
Әнкәсе үлде, калды кыз ятим,
Газап күрергә ул гомеренә.

Көннәрдән бер көн әнкәсе әйтә:
«Шул кызыңнан калмады тормыш.
Я приютка бир, я суга ташла –
Ничек булса да үтер син аны».

Көннәрдән бер көн әткәсе әйтә:
«Әйдә, кызым, барыйк йөрергә.
Кара урманга, зияратларга
Әнкәеңнең каберен күрергә».

«Зиратларда чәчәкләр җыйдым
Әнкәй каберенә куярга.
Бардым мин анда зиратларга
Газиз башкаемны җуярга.

Әткәй кулында ялтырый пычак,
Җыйган чәчәкләрем бер кочак.
Ни эшләсәң дә карышмыйм, әткәй,
Дөньясында бәхетем булмагач.

Зияратларда йөри алмадым,
Ерак икән аның кырлары».
Әнкәсе белми кызын чалганны,
Каберенә ага каннары.

«Чалдым кызымны, сөйгән баламны,
Дөньясында бәхете булмагач.
Чалдым кызымны базардан кайткач,
Яшь хатынымның сүзен тыңлагач.

Иптәшләр, үзем бетерәм сүзем,
Җыр чыгаручымны мактагыз.
Үлсә хатыныгыз, калса балагыз,
Ятим диеп аны какмагыз».

### Галим бәете

Бисмиллаһи вә билләһи, җитте Корбан гаете,
Менә сезгә тыңласагыз, Абдулгалим бәете.

Егерме бишендә слёт булды, концервзавод каршында,
Төнге сәгать тугызларда һәлак итте машина.

Әнкәем өчен сау кайттым Германия сугышларыннан,
Хәйран башым вайран булды Барый машинасыннан.

Төрле уйлар килде миңа ресторанда эчкәндә,
Сулышымны да алалмадым машинадан төшкәндә.

Әрәм буласыга кайтты Барыйның машинасы,
Минем әҗәлгә сынгандыр машина рәшәткәсе.

Ах, дусларым, җыегызчы, кәгазьләрем кулымда,
Минем актык гәүдәм калды аэродром юлында.

Герман осколкасы тиде, башыма түгел, күземә.
Минем өчен елама, әнкәй, сабырлык телә үзеңә.

Сөекле тәтәм, кая бардың, мин сине көткәндә.
Газиз әнкәм җыламасын Ходаем күрсәткәнгә.

Гүзәл Мирбан, миннән теләк: машинада барма калага,
Бәхетсез булдың, дип каргама миннән калган балага.

Сөекле тәтәм, аш бешерсәң, кутарын куй чарага,
Миңа дигән бер аякны бирче ятим балага.

Иртә торып су сип, кызым, Мөнирә гөлләренә,
Гүзәл Мирбан, бәхет телә алдагы көннәреңә.

Минем җаным ак күбәләк, төшкәндер ул таш юлга,
Безне тормышта торырга язган илле беренче елга.

Гүзәл Мирбан, син эшләрсең быелгы иккән бакчаны,
Райкомнан барып алырсың миннән калган акчаны.

Телем булса, сөйләр идем, ничек егылганымны,
Кадерле какам, белмәдеңме таш юлда...

Күз алларым томан булды машинага менгәндә,
Газиз әнкәм еламасын дусларымны күргәндә.

Аэродром юлларында вагон юллары ясар
Ничек үлгәнемне әйтер Муллияминов Абсатар.

Магазиннан бүләк алдым Фәрдәнә сеңелемә,
Кая барсаң да сүз әйтмә, Вәлидә, сеңелеңә.

Гүзәл Мирбан, киемемне кадерсезлектә тотма,
Дусларым килеп әйткәндә, бу бәхетсез, дип әйтмә.

Аягымда ботинкамны алдым мин раймагтан,
Милиционерлар җыелдылар төрлесе төрле яктан.

Мин утырган машинаның колесасы бәйләнгән
Әткәй хәсрәт күрсен диеп, Ходай гомер теләгән.

Кабызган папиросымның спичкасы кулымда,
Газраил җанымны алды аэродром юлында.

Үзем таш юлда үлсәм дә, Кызанда каберем казылыр,
Минем болай үлгәнем газетада язылыр.

Бисмилләһи, дип язу язсам, булмас микән языгы,
Җыйганнарга гыйбрәт булсын, калдырганга – языгы.

Мәрхүм ничә яшендә, серый фуражка башында,
Машинадан егылып үлде егерме сигез яшендә.

Галим үлде ахры мескен Сайфый аркылы,
Үле гәүдәсен китерде Газиз паром аркылы.

Концервзавод каршында салют булган кич-ара,
Галим мескен вафат булды кичима көн кич-ара.

Бәет язсаң, моңлы яз, тыңлаучылар моңлансын,
Машина нинди әҗәл диеп башкалар гыйбрәт алсын.

Галимне ураганнар американский бәз белән,
Галимне искә алырсыз шушы бәете белән.

Сул кулында сәгате, уң кулында шәүләсе,
Телләре юк сөйли белми, фотосында гәүдәсе.

Алмагачны утырталар, булмаса да алмасы.
Гомерлеккә ташлап китте, Мирбан, кара баланңы.

Галимне күзәткәндер балчык суын калаган,
Галимне үлде дигәч, ата-анасы елаган.

Шырналып үскән чәчәкнең сандугач гөлен өзә,
Бу бәетне язучы Хисматуллина Фәризә.

Сандугачлар басып сайрый телеграмм баганасына,
Ходаем сабыр, куәт бирсен калган ата-анасына.

Яткан җире җәннәт булсын, зәм-зәм суларын эчсен,
Дөньяны туеп күрмәде, ахирәтендә күрсен.

Бәет язган каләмемне салган җирен табалмыйм,
Артык яза алмыйм инде, шуның белән тәмамлыйм.

**Гомәр бәете**

Кешелектән чыктым эчкегә бирелеп,
Мәдрәсәдән чыктым имтихан биреп.
Их, югалды яшь егет, калтырый куллар,
Үтәдер яшь гомер, үтәдер еллар.

Әткәемне чалдым, әнкәемне будым,
Кечкенә сеңелемне суга ыргыттым.
Их, югалды яшь егет, калтырый куллар,
Үтәдер яшь гомер, үтәдер еллар.

Бу эшемне сизгәч, килде милиция,
Алып китте мине застав буена.
Их, югалды яшь егет, калтырый куллар,
Үтәдер яшь гомер, үтәдер еллар.

Әткәемне идәндә, әнкәемне түрдә,
Кечкенә сеңлемне су буйларында.
Их, югалды яшь егет, калтырый куллар,
Үтәдер яшь гомер, үтәдер еллар.

Агыйделдә кычкыра первый свисток,
Мине озаталар на Дальный Восток.
Их, югалды яшь егет, калтырый куллар,
Үтәдер яшь гомер, үтәдер еллар.

Берсе судить итте мине атарга,
Берсе судить итте ун ел бирергә.
Их, югалды яшь егет, калтырый куллар,
Үтәдер яшь гомер, үтәдер еллар.

Башыма кигәнем серый фуражка,
Чыгамын да карыймын нурлы кояшка.
Их, югалды яшь егет, калтырый куллар,
Үтәдер яшь гомер, үтәдер еллар.

Төрмәләрдә утырам икмәк-тоз белән,
Күңелемне юатам төрле уй белән.
Их, югалды яшь егет, калтырый куллар,
Үтәдер яшь гомер, үтәдер еллар.

Өстемә кигәнем керләнеп бетте,
Минем яшь гомер төрмәдә үтте.
Их, югалды яшь егет, калтырый куллар,
Үтәдер яшь гомер, үтәдер еллар.

**Амил бәйрәме.** Һәрбер авылда да амил булган. Чит авыллардан арбага утырып, тамакларын төяп килә торган булганнар. Кунакларга кабак бүрәк, куз бүрәк пешергәннәр. Үзләре дә пешереп алып килгәннәр.

**Кызанда** элек дүрт мәчет булган. Мин өчесен хәтерлим әле. Һәрбер байлар үзләре салдырган мәчетне. Курнап, Базар авыл мәчете, Кинәгәч мәчете. Ураза вакытында балалар мәчеттән «Авыз ачылды», дип йөгереп өйләренә кайтып әйтәләр.

**Джуманов Равил Үтәмөхәмәд улы** (1937 елгы). Нугай тарихчысы, халыкның этнографиясен, тарихын, фольклорын яхшы белә. Киң эрудицияле, хөрмәтле шәхесләрдән. Ике хушаваз яздырды.

### Сөннәт туй

Әй, әссаламәгаләйкүм, аманмысыз, муллатай,
Өндәү чакырып туй итепсез, атраптан калдырмай.
Ай, күп халык килепте, атраптан калдырмай.
Җигеп килгән арбасын әүләгә сыйдыралмай.
Уртада бер зат тора, елтыраган алтындай.
Аны барып карасам, ул да икән бажаклай.
Капкадан чыгып китте, тратайка тырылдай.
Астында тимер күчәр, таз тимердәй зыңгырдай.
Ай да хөрмәт итепсез, рәхмәт яусын, муллатай.
Ай да хөрмәт итепсез, рәхмәт яусын, муллатай!

* * *

Айтип-айтип юралар, куймыйсыз мине кыстай.
Мин түгелмен Фәхретдин, янәшәдә Сыдык бай.
Әмма дуслар хакы өчен кыйммәтен җиргә куймай.
Бер-ике авыз әйтәем, шул булып утыр тыннай:
Ярты Түбә, Җәмиле җайлы икән кыдырмага,
Ярты Түбә, Җәмиле җайлы икән кыдырмага.
Кызан, Каргалык, Майлы Күл җыелып килер Кыра Калага.
Сәмигъ авыл, Колакау мисле утырган батага,
Киләчеләр кире халык керешмәсен арага.
Каңга дигән каңгыз калк, кыңгырып китсен далага.
Айрин әйт тә, берин әйт, аспалы күпер, агым су
Җан-Тияктән сәдака.

Бу хушавазда ыру-кабилә, авыллар арасындагы туганлык мөнәсәбәтләре сизелә. Ярты Түбә, Җәмәле кунакка йөрешү, күңел ачу өчен яхшы, Кызан, Каргалык, Майлы Күл бергә җыелып калага килә, алар Татар-базарга товар китерә. Сәмигъ авыл, Колакау ватагага (*балык тота торган судно*) утырган кебек. Киләчеләр кире халык. Нигәдер, аларны өнәп бетермиләр. Анда бик күп милләт яши. Канга күчмәчелекне озак саклаган. Тияк – Царев, Әстерхан шәһәрендә татарлар яшәгән җир. Соңгы татар ханнары шунда яши.

**Кызана**
**(*легенда*)**

Шушы җирдә күчеп йөргән татарлардамы, нугайлардамы бер кыз булган. Үзе ыспае булган. Шул кызны егете алдаган. Ул йөкле булган. Ул вакытта шәригать буенча, халык гадәте буенча андый хатын-кызларны куалар ырудан. Шул мескен баласын табып Түбәгә килгән. Шунда землянка казып, шунда яшәгән. Шунда күчеп йөрергә маллары булмаган ярлы халык килеп урнашкан. Алар кызны Кызана дип атаганнар. Шушы халыктан авыл башланып киткән.

**Мусаев Әмир Дамир улы** (1971 елгы). Кызан мәктәбенең тарих укытучысы. Аның мәгълүматлары:

**Кызан авыл.** Авылның исеме Кызан авыл. Документлар буенча, авылның исеме бу авылга нигез салган сугышчы Йыла Кизан исеменнән килеп чыккан дип санала. Кизан ыру-кабилә атамасы булырга мөмкин. Мангышлакта да Кизан атамасы торак пунктка бирелүе мәгълүм. Төркмәннәрдә Гизан атамасы бар.

Йорт татарларында торак җирләренә нигез салучыларның исеме белән бәйләү еш очрый. Сәмигъ авылга нигезне баһадир Сәмигъ Арслан сала. Күрше Яксатово авылына Яксат исемле кеше нигез сала. Җәмәле авылының килеп чыгуы Җума яки Җуман исеме белән бәйле. Җума яки Җуман табунный голова була. Киләнчи авылына нигез салучы да Киләш исемле табунный голова. Шәһәр янында Мышаек бар, аны татарча Казавыл диләр. Аның исеме Казыйдан (*мөселман башлыгы*) килеп чыккан.

Авыл тарихы белән бәйле легенда бар. Хәзер инде мәрхүм булган Бикмөхәммәт Исаев исемле кеше миңа ул легенданы сөйләгән иде.

**Кызана** – кыз ана, кияүгә чыкмый бала тапкан кыз.

Урта хәлле генә бер гаиләдә бик чибәр кыз үскән. Исеме Өммегөлсем була. Өммегөлсемнең яратып йөргән егете дә була. Кызга бер бай малае да күз төшереп йөри. Кызның ата-анасы бай җибәргән яучыларга кызларын бирергә ризалык бирә. Әмма кыз бу язмыш белән килешергә теләми. Ул бу җаны теләмәгән никахтан ничек котылып буласын озак уйлый. Аннары үзе турында имеш авырлы икән дигән сүз тарата. Бай кодалар, бу сүз килеп ирешүгә кыздан баш тарталар. Кемгә авырлы кәләш кирәк булсын.

Ул заманда кануннар буенча никахсыз балага узган кызларга карата ике төрле чара кулланырга мөмкин булган. Беренчесе – ташлар белән бәреп үтерү, икенчесе – илдән-ырудан куу. Бу очракта икенче юлны сайлыйлар.

Аны шәһәрдән куалар. Ул килеп шушы җирләрдә урнаша. Ашан тау түбәгә, авылга беренче нигез салынган җиргә килеп урнаша. Бу урынны Кызана дип атый башлыйлар. Күпмедер вакыттан бу сүз кыскарып Кызан булып китә.

## МАЙЛЫ КҮЛ АВЫЛЫ

16.06.2013

**Айбекерова Халидә Касим кызы** (1941 елгы),
**Абдулгазизова Фәридә Абдулгалим кызы** (1941 елгы),
**Мохтарова Фәридә Ибраһим кызы** (1948 елгы).

Бу апалар яшь вакытларында өчесе дә үзләренең жыр ансамблендә жырлаган. Конкурсларда катнашканнар. Алар сөйләгәннәрдән:

Майлы Күл авылының исеме җиренең майлы кебек әйбәт булуыннан килеп чыккан. Җирләребез майлы кебек әйбәт, кара туфрак. Яхшы авыл, яхшы авыл дигәннәр. Шуннан Яксатово килеп чыккан.

Мин жырларга яратам,
Биергә дә яратам.
Эчемдәге хәсрәтемне
Жырлап-биеп таратам.

Әйдә дуслар утырыйк,
Өстәл өстен тутырыйк.
Ашап-эчү берни түгел,
Бер жырлашып утырыйк.

Челтәрле күпер астында
Каз канатын төзәтә.
Булма матур, бул бәхетле,
Бәхет күркәм күрсәтә.

Алларым диям сезне,
Гөлләрем, диям сезне.
Ал гөлләрдән, былбыллардан,
Бәй, артык күрәм сезне.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Өммегөлсем.
СССР төзелгән кебек
Тормышыгыз төзелсен.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлбостан.
Күкрәгемә кадар идем
Роза чәчәге булсаң.

Аптекларга йөгереп кердем
Гөлсирин өчен генә.
Януларым-көюләрем
Гел синең өчен генә.

Биек тауның башларында
Резин калош тая ул.
Сагынасыңмы, дип сорыйлар,
Сагынмаган кая ул.

Биек тауның башларында
Кошлар оя ясамый.
Ай булса да, гөл булса да
Туган илгә охшамый.

Ал бидерә, гөл бидерә
Күзләрне чагылдыра.
Бергә чакта берни түгел,
Аерылгач сагындыра.

Миңа бүген җитмеш тулды,
Мин һаман да яшь кебек.
Уйнап-көлеп йөрик әле,
Яшь вакыттагы кебек.

Безнең урам тар иде,
Тар булса да бар иде.
Тар урамны тар-мар итеп
Йөргән чаклар бар иде.

Чәчәк идек илләрдә,
Чәчелдек чит җирләргә.
Тагын да чәчәк булыр идек,
Кайтсак туган илләргә.

Кулыңдагы гармуныңны
Уйначы тартып-тартып.
Алма алсу, чия кызыл,
Сез шулардан да артык.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нурсанә.
Күз өстеңдә кашың ничек,
Мине шулай күрсәнә.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле
Барыбыз бергә чакта.
Калыр истәлек урнына,
Дуслар, аерылган чакта.

Җырлагыз, дуслар, җырлагыз,
Авызыгызны йоммагыз.
Бергә чакта җырлап калыйк,
Һаман бергә булмабыз.

**Авыл бәйрәме** – яңа бәйрәм. Соңгы 5-6 елда уздырыла башлады. Бөтен урожай җыеп алынганнан соң уздырыла. Октябрь башларында, беренче атнасында уздырыла.

Концертлар килә ул көн. Төрле ярышлар уздырыла. «Алтын кабак», ат чабышы, йомырка кабып йөгерү. Җиңүчегә көрәштә куй бирәләр.

**Ураза гаете, Корбан гаете.** Ирләр гаеткә мәчеткә баралар. Алар мәчеттән туры зиратка бара. Анда дога укып кайталар. Алар

кайткач бәйрәм башлана. Аннары туганнарга, күршеләргә кыдырып йөриләр. «Кул алырга» керәләр, «кул алып» чыгалар – өлкәннәр белән күрешәләр. Күчтәнәчләр алып керәләр. Гадәттә өйдән пешкән әйберләр алып керәләр.

Авыл балалары берәм-берәм, икәү-өчәү өйдән өйгә кереп, «Бәйрәм хәерле булсын!» дип, гает белән котлыйлар. Чәй эчерәбез аларга. Аларга күчтәнәчләр әзерләп куябыз, садака бирәбез.

Корбан гаетендә гаеттән соң зиратка баралар ирләр. Кайткач, куй суялар. Сыер булса, биш яки җиде кеше пайга керәләр. Аннары җиде өйгә тараталар. Ярлыракларга, ир баласы булмаганнарга, ялгызларга тараталар.

Кадер кичәсендә мәчеткә баралар.

**Әүлия түбәсе.** Икенче төрле Кыдыр бабай түбәсе дип тә әйтәләр. Анда Кыдыр бабайның кабере бар. Ул үләчәктә арбага утырган да, күрше авылларга чыгып киткән. Бу түбәдә үлгән.

Җыелышып кулъязма белән белән таныша торгач, аның Әстерхан Криуш мәчете имамы Җиһанша Җаббаровның (Җиһанша бине Габдел Җаббар) 1907 елда чыккан «Әстерхан тарихы» китабыннан алынган материал булуы, кириллицага күчерелгән варианты икәне аңлашылды. Әстерханда бу китап сирәк кенә булса да, олы яшьтәгеләрдә сакланып калган әле. Китапта Хаҗитархан (Әстерхан), аның мәчетләре турында шактый материал тупланганган.

«Әстерхан хөкүмәте» кульязмасында: «хөкем сөргән 18 татар ханын биян итәм» диелә:

1. Коерчык хан бине Ырыс хан … 798 (1395)–800 (1397) еллар тирәсендә хан булган.
2. Ул Кытлыг Тимер бән Гали Тимер хан-Тимер Баһадир хан.
3. Мөхәмәд хан.
4. Хәфидә Чуак хан.
5. Мынгышлак хан.
6. Әхмәдхан бән Мөхәмәдхан.
7. Мәхмуд хан. Мәхмуд ханның Әстерхан музейханәсендә сугылмыш акчалары бар. Һәр каюсының өстенә язылмыш: «Әл-Солтан әл-гадел Мәхмуд бән Мөхәмәд бән Тимер».
8. Касим хан 870 (1465) еллар тирәсендә хан булган.
9. Хәйдәр, бән Эби-әл Хир хан.

10. Габделкәрим бән Әхмәд хан. Бу зат 895 сәнәләрдә хан булып, 910 (1504) елга кадәр ханлыгы мәгълүмдер.

11. Җанибек бән Әхмәд хан. Бу затның Хәзәрдә сугылган тәңкәләре күренгәлидер.

12. Хусаин хан 932ел (1517) елда хан булган.

13. Алык хан.

14. Касим сәид Әхмәд хан 938ел (1531) елда чиркас тә, фәсе Әстерханга хөҗүм итеп мәктүл (үтерелә) итделәр.

15. Габделрахман хан 945ел (1535–1539).

16. Шәих Хәйдәр бән шәих Әхмәд хан. Бу зат 944 (1524) елда газел ителеб 961 елда яңгыдан хан итделәр. Өч ел ханлык итеп вафат булды.

17. Ак-Кибәк бән Мортаза хан Бу затны Ямгурчи хан катыл итде (үтерде).

18. Ямгурчи бән Бирдебәк хан мунын заманында Иван Грозный гаскәре килеп Әстерханны зыбат итделәр. Друбишгәли хан-Дәрвешгали хан. Бу затдан соң Әстерханда татар ханнары мәнфираз улды».

Әстерханга 1558 елны нигез салынган, дип исәпләнә, шул турыда шәһәрнең бик күп җирендә язып та куелган. Узган гасырның сиксәненче еллар ахырында татар җәмгыяте төзегәч, без күп тапкырлар «Әстерхан – меңьеллык татар шәһәре» дип язып та, бу проблеманы күтәреп тә карадык. Безгә: «Урыслар килгәнче, иске татар шәһәре Иделнең уң ягында булган», – дип җавап кайтардылар. Әмма халык хәтере башкача сөйли. Руслар килгәнче үк, шәһәр Иделнең ике ягында да була. Олы яшьтәгеләр Иделнең уң ягында – Тинакта, Карантинноеда, Приволжьеда, Стрелецкийда, Сүлә нкәдә иске шәһәр эзләре; хәзерге Әстерханда – Иделнең сул ягында: Кремльдә, Сетевязальная фабрика урынында, Облвоенкомат урынында, Тимерьюл вокзалы тирәсендә, Н. Крупская исемендәге Өлкә китапханәсе урынында хан сарайлары, мәчетләр булуын сөйлиләр. Военкомат урынында элек Девичий монастырь торган, аны исә Дәрвеш Али ханның сарайларын, мәчетләрен сүтеп салганнар. Кремльдә – Карадаут баба-газиз кабере, кенәз Владимир соборы (иске автовокзал) астында, Татар Базар калкулыгында салынган Иван Златоус чиркәве астында безнең әүлияләр ята, татар халкы ул җирләргә әле дә хәер күтәрергә йөри. Рус версиясе буенча, әгәр дөрестән дә алар килгәнче шәһәр сул якта булмаса, хә-

зерге Облвоенкомат урынында булган Дәрвеш хан сараен, Кремльдә яткан Карадаут баба-газиз каберен һ.б. әүлияләр каберен ничек аңлатырга? Шәһәр алынгач, татарларга хөрмәт йөзеннән, үзләре төзегән чиркәүләр астына җиңелгән халыкның әүлияләрен күмеп калдырганнар булып чыгамы?

Г. Тукай иҗатына кереп калган Татар базары турында аерым язып үтәм. Ул Кремль белән гомерлек иске татар бистәсе Тияк арасында, шәһәр уртасында урнашкан. Аның бер ягыннан елга (Иделнең бер тармагы) үтә. Хәзер суны Приволжский Затон дип йөртәләр. Татар Базары тирәсендә – кенәз Владимир соборы, Иван Златоус чиркәве; соңгысының алдында бер түбәдә (Әстерханда түбә дигәнне калкулык, русча – возвышение, дип аңларга кирәк) хәзер иске янгын каланчасы тора. Олы яшьтәгеләр аның урынында да хан мәчетеме, хан сараемы булуын сөйлиләр. Һәм шул тирәдәге иске каберлекләр-зиратлар (сүз монда бер-ике кабер турында гына бармый) Иван Златоус чиркәве территориясендә, кенәз Владимир соборы белән Татар Базар арасында, Татар Базардан чыгып – Кремль белән Приволжский Затон арасында – хәзерге Аккош күле алдында (ул урында замана офисы салып яталар) булган. Әстерханның иске шәһәр өлешендәге түбәләрендә, Кремльдә салынган борынгы чиркәүләр – барысы да Хаҗитархан мәчетләрен сүтеп салынганнар, ягъни ул чиркәүләргә карап «Бисмилла» әйтеп узарга яки яннарында туктап Коръәннән бер сүрә укырга кирәк, дигән фикергә килдем һәм үземнең якыннарымны да шуңа өйрәтәм.

София апа Низаметдинова бер кульязмасында: «Многовековая история Астрахани кастрирована. Астраханский Кремль, построенный на бугре с татарским названием “Шабан-высокий”, это не начало, а продолжение истории. Археологи больше и больше находят доказательств, что старая Астрахань-Хаджитархан занимала гораздо большую площадь, что Шарен бугор. И на левом берегу Волги жили татары: Мошаик (Каз аул), с. Началово, ставка хана Ямгурчи на р. Кутуме, Кара-тюбе возле Пороховых складов. Хочется надеется, что в 2058 году, Алла боерган булса, Астрахань будет отмечать не 500-летний, а 800-летний юбилей. И к этому времени в названиях улиц появятся такие как: Хаджитарханская, Аксарайская, Караванная, Золото-Ординская, Хазарская и т.д.» – дип яза.

«Әстерхан төзелешү хәбәрләре» китабыннан: «Бу шәһәр Идел елгасының Хәзәр диңгезенә койган урынына урнашкан. Борынгы

заманда ул хәзәр ханнарының башкаласы булып, “Ител” шәһәре дип аталган. Соңрак “Әштерхан, Хаҗитархан, Әждерхан” дип йөртелә башланган. Сәмәндәр шәһәре Сәлман бине Рәбигател-Баһили тарафыннан алынгач, ханның Ител шәһәренә чигенүе һәм башкала итеп шуны сайлавы Мәсгуди сүзеннән ачык билгеле. Татарлар килеп чыккач, бу шәһәр озак вакыт алар кул астында кала. Тимер белән Туктамыш хан арасында булган сугышлар һәм авыр фетнәләр нәтиҗәсендә Алтын Урда, Җучи улысы һәм Бәррийятел Бәрәкәт дәүләте таркала, бөтенләй көчсезләнә. Татар шаһзадәләре һәм бикләре арасында үзара көрәш, бүлешү, аерылышу чире көчәя. Шул чакта Алтын Урдадагы бер төркем, Җучи нәселеннән бер шаһзадәне хан итеп, Хаҗитархан шәһәрендә кечкенә, мөстәкыйль бер дәүләт төзиләр».

«Астрахань и ее окрестности» (В.П. Никитин 1982 г.): «Георгий Эдуардович Гибшман астраханский краевед предположил, что Астрахань основывалась, по крайней мере трижды (а то может быть и четырежды?) Первый раз в 13 веке, второй – после сожжения города Тимерланом, которое произошло в1395 г., и третий раз в 1558 году».

«Раскопки старой Астрахани» (Е. Шнайдштейн): «В 13 веке на правом берегу Волги, на высоком бугре (в 12 км выше совр. Астрахани) возник Хаджи-Тархан. Здесь жили ассы (предки сарматов) за боевые заслуги они получили от хана Батыя поощрения – тархан. Некоторые историки предполагают, что Татарская Астрахань возникла не на голой степи, а на месте древнего города Хазарии – Итиля… Город беспрестанно беспокоили соседи-кочевники, Волга подмывала берег, и он часто обрушивался. Все это заставляло жителей переселиться в новую Астрахань, более надежно укрепленную».

А. Штылько «Иллюстрированная Астрахань» китабында болай яза: «Грабили ее (Астрахань) уйшуйники в 1375 г., так же и разорил Тамерлан в 1395 г., нападали в 1522 и 1532 г. крымцы и ногайцы. В 1538 году Иван Грозный вступил в Союз с царем астраханским Абдул-Рахманом. В 1542 году астраханский царевич Едигер приехал служить в Россию. В 1547 году Крымский Саин-Гирей захватывает Астрахань и разоряет. 2 июля 1554 года Астрахань взята русскими, делается данниций Москвы: 40 тыс. алтынъ и 3 тыс. рыб. Власть вручается ставленнику русского царя – Дербышу, который через 2 года изменяет и производит вооруженное восстание против русских. Тогда, в 1556 году Астрахань окончательно присое-

диняется к Московской державе, а еще через 2 года присоединяется с нагорной стороны на остров, безопасной от нашествий и набегов.

…В 1660 году Астрахань чуть было опять не попала в руки татар».

Аннан, Әстерхандагы билгеле бер тарихи фактка тукталып үтәм. 1991–1992 елларда Әстерхан өлкәсенең Кызыл Яр районы, Комсомольск поселогы тирәсендә төзелеш эшләре алып барганда бульдозер көрәгенә затлы агачтан ясалган зур тартмасыман әйбер килеп эләгә. Ул яхшы итеп ябылган, ачканнан соң, эшкәртелгән тире белән тышланган зур-зур, яхшы кәгазьгә язылган китаплар килеп чыга. Язулар гарәпчә булып, китапта таблицалар, диаграммалар, план кебек нәрсәләр күренә. Китапларны караган кешеләр моны Алтын Урда яисә Хаҗитарханда яшәгән бер галименең архивы, кулъязмалары дигән нәтиҗәгә киләләр. Бу хәл XX гасырның 90 нчы еллар башында булып, табылдыклар турында тиешле җиргә хәбәр ителәә. Төрки-татар китаплары икәне билгеле булгач, килгән кешеләр аларның Әстерхан өлкәсеннән чыгып китүен хуп күрәләр. Шулай итеп, китаплар чеченнар кулына килеп керә. Алар бу борынгы китапларны Төркиягә сатканнар. Шул гомердә китапларда әлегә кадәр билгеле булмаган Алтын Урда тарихы, шул исәптән Хаҗитархан тарихы язылганы безгә хәбәр булып кайтты. Тарихчылар арасында, Төркия Әстерхан юбилее алдыннан ул материалларны сатып алырга тәкъдим итә, алар безгә кирәкми, дигән сүзләр йөри.

2006 елда, Әстерханның дәүләт тарафыннан рәсми билгеләнгән юбилее уңаеннан газета битләрендә материаллар күренә башлады. Шулардан «Хрономерт-Астрахань» газетасының «Народный архив» битендә (№ 23 (114), 6 июнь, 2006 ел) «Неправильный юбилей» исемле материал басылган. Әстерхан Техник университетының тарих укытучысы Михаил Сергеевич Сычев сүзен: «В преддвернии 450-летия города историки доказывают, что Астрахани на самом деле на 300 лет больше» дип башлый. Газета материалыннан өзекләр китереп узам:

«– на территории области находят монеты и двухтысячелетней давности;

– по имени ираноязычных племени асов, составляющих значительную часть населения этих мест, и возникло название нового города, появившегося на правом берегу Волги – “Ас-Тархан”, позже видоизменившееся в Астрахань;

– Заячий бугор, где сегодня находится Астраханский Кремль, от постройки которого принято вести отсчет существования города, в то время назывался Шабан-бугром, и там распологалась укрепленная зимняя резеденция золотоординских ханов. С севера, запада и востока окруженный водами Волги и Кутума, а с юга непроходимыми болотами и ильменями, бугор был удобен для оборонительных целей. Поэтому царь Иван Грозный, присоединяя Астраханское ханство, решил заложить новую крепость именно здесь. Строительство кремля началось весной 1557 года, для возведения крепостных стен были сломаны стены старого города, и перенесены с правого берега на левый;

– прошлой осенью астраханские историки обратились к губернатору с просьбой рассмотреть вопрос о праздновании не 450-летия, а 750-летия города. Предложили собрать научную конференцию по этому поводу. Однако в областной админстрации ответили: вопрос о праздновании уже согласован на федеральном уровне и вылезать такими предложениями не следует...»

Әйе, яһүди һәм рус тарихчылары Әстерханга 450 ел гына түгел икәнен яхшы беләләр, кулларында аның Казанга тиң борынгы татар шәһәре икәнен исбатлаучы документлар да аз түгел күрәсең. Тик Әстерханны дөньяга яше белән Казанга тиң татар шәһәре дип таныту бүгенгә җирле тарихчыларга да, Мәскәү һәм Әстерхан хакимнәренә дә кирәк түгел булып чыга. Югарыда күрсәтелеп үтелгән автор материалында, Хаҗитархан-Әстерханның татар шәһәре икәнлеге турында бер сүз дә юк, хәтта татарларның яшәве дә күрсәтелми, гомумән, материалның буеннан буена бер татар дигән сүз табып булмый. Моны – тарихны, ничек кирәк, шулай бозып, яңадан язу, димичә, ни дисең инде.

Казанның 1000 еллык яшен ачыклауда дөньяның төрле почмагындагы тарихчылар, археологлар катнашты. Казанның бу өлкәдә тәҗрибәсе җитәрлек, иншалла, Әстерханны да үги итмәсләр дип ышанып калабыз.

Ә без, Әстерханга ничә яшь дигәндә, болай дип җавап бирәбез: рус Әстерханына – 450, татар Әстерханына 800 елдан артык, ә Түбән Идел буенда урнашкан гомумтөрки дәүләте Итилгә (Камызык районының Самосделка авылы тирәсендә булган) 1270 ел.

* * *

Октябрь инкыйлабына кадәр Әстерханда «Идел», «Мәгариф», «Мизан», «Туп», «Халык», «Борһани тараки» исемле газета-журналлар чыккан. Гомәри нәшер иткән «Идел» газетасы иң абруйлылардан саналган һәм Россиядә чыгып килгән бишлеккә кергән. «Идел» 1907–1914 елларда чыгып, суд карары белән ябылган.

1988 елның азагында татар җәмгыяте «Дуслык»ны төзегәч, көн кадагына газета мәсьәләсе дә килеп басты. «Идел» газетасының 1989 елда, 2 битле булып, берничә саны чыкты. Даими чыга башлавы 1990 елдан. Баштагы ике санны Идел буе районы газетасында редактор булып эшләүче Зөбәрҗәт Закир кызы Моратова тулысынча үз редакциясе базасында эшләп бастырды. Татар газетасын ачып, матди база булдыру, хезмәткәрләр туплауда Патеев Равил Исхак улы зур хезмәт куйды. Газетага Зөбәрҗәттән соң редактор булып Әлфия Дулатова килә. «Идел»не җайга салып җибәрү өчен Әлфиягә, әлбәттә, күп тырышырга туры килде. Әлфия җитәкләгән елларда газета тулысынча халкына хезмәт итүче, милли җанлы, чын татар газетасы иде. Баштагы елларда Хөсәенов Ришат редакторның чын мәгънәсендә уң кулы, ышанычлы кешесе булды. Ул елларны: газетаны халык арасында таныту өчен көне-төне чабарга, тырышырга туры килде. Фатирым «Идел» газетасының филиалына әйләнде, бөтен дөнья газет белән тулды. Казанга, Россиянең башка төбәкләренә җибәрү минем өстә иде. Ул елларда почта аша бандерольләр ясап, ярты тонна газета җибәргәнмен. Зәйнуллина Равия газетада техник хезмәтләрне башкарды; газеталарны базарга илтеп сата иде. Без, «Дуслык» җәмгыяте әгъзалары, ул елларда җәмгыять эшләрен шатланып, булсын дип, үзебез өчен, дип эшли идек. Шуның өчен бөтенебез дә халыкны газетага яздыру, аны тарату, оештыру эшләрендә актив катнаштык. Ул елларда төрле бәйрәмнәр, концертлар еш уза иде. Мин дә сатылмыйча калган газеталарны, халык арасында арзанрак бәягә сата идем. Без ул вакытта яшь, җир җимертеп эшли идек: машина булмаса, газеталарны Әлфия типографиядән зур сумка белән җилкәсенә салып ташый, без халыкны «Идел»гә яздыру өчен үзебезнең хезмәттән соң авылларга чыгып китә идек. Дулатова редактор булганда газета тирәсендә активистлар, булышучылар, мәкалә язучылар күп, редакция умарта оясы кебек гөжләп тора иде. Баштагы мәлне «Дуслык», «Идел» газетасы чын мәгънәсендә татар йорты булып, халык та теләп йөрде. «Идел»не Әстерхан татарлары

көтеп, үз газеталары дипп кабул итә иделәр. Ул елларда тираж 3000 гә җиткән вакытлар да булды. 1990 елдан 1995 кә кадәр материаллар рус телендә генә басылды. «Идел»нең татар бүлеген ачу шрифт булмау сәбәпле зур авырлыклар, кыенлыклар тудырып, гел кичектерелеп килде. Соңгы татар мәктәпләре 1960 елларда ябылган Әстерханда газетада татар бүлеген ачу, аны алып бару, ифрат та авыр, четерекле мәсьәлә иде. Татар бүлеге миңа тапшырылды. Шулай итеп, беренче материал 1995 елның 15 февралендә басылып чыкты. Ул вакытта редактор Рафаэль Ишбердиев иде. Газета эшенә мин үземнең төп табиблык хезмәтемнән соң килә идем. Шул чорда «Идел»дә җаваплы сәркатип булып Ибраһимов Рамазан ага эшләде. Югары даирәләрдә,1995–1996 елларда безнең газетаны ябып, өлкә яһүд газетасы ачу турында озак вакыт сүз барды. 1998 елда бөтен дөньяны тетрәткән дефолт бәласы килеп чыкты. Октябрь-ноябрь айларында редактор Габбаз Булатовтан башкалар бөтенесе дә эштән китте, газета ябылу алдында калды. Мин, Алла ризалыгы өчен, дип, газетага, бушлай эшләргә, әйләнеп кайттым. Габбаз нинди дә булса акча эшләү максатыннан, компьютерны мин белмәгән рус егетләренә, башка җиргә арендага биреп җибәрде. Аларга бары тик компьютер гына кирәк, газетаны ясау турында уйламыйлар да (татар бүлеге турында сүз дә алып барып булмый, газета ясарга килгәч, миңа, комачаулап йөри дип, артык кеше итеп карадылар). Компьютерны алардан алып Габбаз, икенче җиргә – Приволжский Затон тирәсендәге ДОССАФ бинасында урнашкан оешмадагы рус егетләренә бирде. Болар газета халкы, рус материаллары белән эшләсәләр дә, татар материаларын баса алмыйлар, татар алфавитындагы 6 хәрефне өйрәнү, истә калдыру алар өчен шулкадәр авыр, башкара алмаслык хезмәт булды. Аптырагач, яннарына утырып, һәр сүзнең һәр хәрефен аерым әйтеп торам, алар язып баралар. Татар хәрефләре килеп чыккач, компьютерны күтәреп бәрергә әзер иделәр. Газетада күргән авырлыкларны сөйләп тә, язып та бетерерлек түгел. Шулай да мин газетаны калдырып китмәдем, аңлый идем, мин дә йөз чөерсәм, газета ябылып, башка ачылмаска мөмкин иде. Россия бит ул! Андый вакытларда үземнең Татарстан кызы булараk, бу – бетүгә юл алган халыкка, ничек тә булса булышу юлын табарга тиеш икәнемне аңлап эш итә идем. 1999 елның гыйнварында компьютер белән редакциягә кайтып кердек. Шулай итеп эшләр дә үз эзенә төшә башлады. Газетада штатта булсам да (миңа 0,5 ставка

бирә иделәр), бервакытта да хезмәт хакы турында уйламадым. Үзем алып барган татар бүлегендә 1552 елда Казан ханлыгының басып алынуы, чечен җирендә барган сугышлар турында һәм шуның кебек замана сулышын тоеп язган милли хисле материалларым өчен редакторлар мине орыша иде.

1988–1993 елларда Әстерханда татар «Дуслык» җәмгыятен төзеп, аңа нык фундамент салып калдырган милләтпәрвәрләрнең исемнәренә аерым тукталып үтәсем килә.

*Ережепов Мәүлет Хафиз улы* – 1946 елда туган, чыгышы белән Әстерхан татары. Әстерхан татар иҗтимагый үзәге «Дуслык» җәмгыятенең беренче рәисе. 1988 ел ахырында, иске татар телен өйрәнү курсларына йөрүчеләрне туплап (Әлфия Дулатова белән) өлкәдә беренче милли җәмгыятькә нигез салучыларның берсе. Шул елларда «Дуслык» җәмгыятенә нык фундамент салынып, милләт өчен җан атып эшләүче үзәк тупланды. «Дуслык» җәмгыятенә Мәүлет Хафиз улы рәислек иткән елларны Әстерхан татарлары «алтын еллар» дип атыйлар. Ул елларда, Ережепов Мәүлет, Патеев Равил, Измаилов Әхъяр (соңгы икесе инде мәрхүмнәр) еллар буе йөреп, Әстерханның үзәге – Киров урамыннан менә дигән бина алдылар, 1914 елда ябылган «Идел» газетасы яңадан аякка басты, «Ялкын», «Идел», «Умырзая» ансамбльләре төзелде, яшьләр клубы оештырылды. «Дуслык» ның беренче буыны татар телен өйрәтүне беренче урынга куйды, өлкәдә 52 мәктәптә төрле формада ана телен укыта башладык. Мәүләт үзе җәмгыятьтә халыкны җыеп, еллар буе гарәп телен укытты. Яшьләр белән эш һәм милли аңны үстерүгә багышланган чараларга зур әһәмият бирелде. Ул рәислек иткән чорда 120 кешедән торган делегация Казанга «Әстерхан татарлары декадасы»на бардылар. Казан, Саратов, Волгоград һ.б. шәһәрләр белән ныклы элемтә оештырылды. Алтын Урда, Хаҗи-Тархан, төрки-татар тарихын ныклап өйрәнә башладык, шул темаларга багышлап конференцияләр уздырдык, чыгышлар ясарга Казаннан галимнәр чакыра идек.

*Дулатова Әлфия Нәҗип кызы,* 1955 елгы, тумышы белән Пензаның Кутеевка-Кучкару авылыннан, яшьли Әстерханга килеп урнашкан. «Дуслык» җәмгыяте учредителе. Өлкә һәм шәһәр мәктәпләрендә татар телен укытуны гамәлгә куючыларның берсе. Баштагы чорда үзе дә җәмгыятьтә иске татар телен укытты. Өлкә әдәби түгәрәгенә нигез салучылардан. Низаметдинова София апа белән баштагы чорда Өлкә архивында тарихны өйрәнгән шәхес. 1990 елда

яңадан чыга башлаган «Идел» газетасы, ул мөхәррир булган елларда беренче чиратта халыкка хезмәт итте.

*Потеева-Фатыхова Наилә Шакирҗан кызы* 1956 елгы, Татарстан кызы.

*Патеев Равил Исхак улы,* нәсел-ыруы буенча Әстерхан каласы татары. Әстерхан татар җәмгыятенә нигез салуда баш йөрүчеләрнең иң активы, иницитивалысы иде. Җәмгыятьнең милли җанлы, җир җимертеп эшләүче әгъзаларыннан берсе. «Дуслык» җәмгыятенең Уставын төзеп, аны дәүләт органнарында рәсми теркәүгә ирешкән, җәмгыятьне биналы итүдә бик күп юлларны таптаган шәхес иде. 1990 елда Әстерхан татарларының «Идел» газетасын ачуга юл ярып, юридик һәм матди мәсьәләләрне тулысынча диярлек хәл итүче. Казан белән рәсми элемтәгә кереп, Әстерханнан татар, нугай, урыс балаларын Казанның югары уку йортларына урнаштырды. Равил зур мәйданнарда, күп халык җыелган чараларны оештырырга алына һәм матур итеп үткәрә иде. 1995 елда «Ялкын» ансамблен Ленинградка алып барды. 1989 елда Казанда «Уйнагыз гармуннар» фестивалендә катнашып, Әстерхан татарлары лауреат булып кайттылар. 1989–1993 елларда татар телен укыту тулысынча җайга салынды. Равил Патеев белән Зөлхәбирә апа Ижбердиева Н. Крупская исемендәге Өлкә китапханәсендә татар теле курсларын ачтылар, 3 төркемдә 100 дән артык кеше укып чыкты. Хезмәте белән хәрби кеше (полковник) буларак, Россия армиясендә контракт буенча хезмәт итүне дәүләт органнары алдында рәсми куючы һәм документлар төзеп, органнарга тапшыручы да ул булды. Чечен Республикасында атналап-айлап командировкаларда булып, сугышны туктату турында сөйләшүләр алып барды. Әстерхан мэры белән эшлекле мөнәсәбәтләргә кереп, «Мирас-мәгариф» коллективын, «Мәҗлес»нең Әстерхан филиалын төзеде. Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил булып эшләде һәм һәрчак гади хезмәт кешесенең хокукларын яклап йөрде. Кызганыч, замана авыруы аны арабыздан вакытсыз алып китте, рухы шат, урыны җәннәттә булсын.

*Ижбердиева Зөлхәбирә Фәрит кызы* – 1928 елгы, чыгышы белән нугай татары, Идел Буе районы, Киләче авылыннан. Казан ханбикәсе Сөембикәнең ерак карендәше, Урусовлар нәселе кызы. 42 ел укытучылык стажы булып, шуның 15 елы мәктәп директоры вазифасында. Ике китап авторы: «Киләчем минем», «Нәселем эзләреннән».

Зөлхәбирә ханым XX гасырның сиксәненче еллар ахырында Россиядә исә башлаган демократик җилләр тәэсирендә Әстерханда

кузгалган милли хәрәкәтне әйдәп баручылардан булды. Татар иҗтимагый үзәге «Дуслык» җәмгыятенең Уставын төзүдә, аңа нигез салуда мөһим роль уйнады. Туган тел, гореф-гадәтләргә багышланган кичәләрдә катнашты. Ана теленең матурлыгын, нәфислеген яшьләргә иңдерде. З. Ижбердиева 1990 елда татар-нугай йолаларына нигезләнгән «Балага исем кушу» сценарийен язды һәм сәхнәләштерде. Шул көннән башлап, аның тирәсенә каләм тибрәтүчеләр туплана башлады. Һәм ул көчләр өлкә әдәби түгәрәгенә нигез салдылар. З. Ижбердиева Казандагы филологик юнәлештәге югары уку йортларына керергә теләкләре булганнарны татар теле буенча имтиханнарга әзерләде.

«Дуслык» җәмгыятенең иң мөһим бурычы – ана телен өйрәнү, халыкның милли аңын күтәрү, дип чыкты. Өлкә мәгариф бүлеге белән берлектә шәһәрнең татарлар тупланып яшәгән төбәкләрендә, авылларда, désolé pединститутта татар теле дәресләре укытыла башланды. Бу өлкәдә Зөлхәбирә апа иң авыр йөкне үзе тартты. Авылдан йөреп, тулай торакта торып педучилищеда татар телен укытып йөргән чаклары булды. Мәгариф бүлеге белән уртак тел табып иң четерекле мәсьәләләрне чиште. Авылларда татар телен укыту өчен бәрәкәтле җирлек әзерләде.

*Низаметдинова София Латыйф кызы* – 1928 елгы, кала татары. Әтисенең тамырлары Татарстанның Казан арты, Тазлар авылыннан. 1988 ел ахырында 74 нче мәктәпкә иске татар телен укытып йөрде. Әстерхан татар иҗтимагый үзәге «Дуслык» җәмгыятенә нигез салучыларның (учредитель, совет әгъзасы) берсе. Әстерхан татарларының данлы татар бистәсе – Тияктә туып-үскән, меценат Кәримовлар нәселеннән. Бу нәселдән Әстерхан татарларының югары белемле беренче татар хатын-кыз табибы чыга. Шәмсиҗиһан Сафа кызы хатын-кызлар табибы-гинеколог булып эшли, татар телендә гинекология буенча китаплар язып чыгарган. Кәримовларның Тияктә үзләренең өендә мөселман аптекасы булган. София Латыйф кызы да, гаилә традициясен дәвам итеп, гомере буе Идел буе районы хастаханәсендә табибә булып эшләде. Ул бүгенгә Әстерхан татарларының тарихын белүче олы яшьтәгеләрнең берсе. «Дуслык» җәмгыяте төзелгәч, алар Әлфия Дулатова белән Өлкә архивында җирле тарихны өйрәнделәр. Шуның нигезендә София апа «Идел» газетасында тарихи рубрика ачып, «Әстерханда татар исемле урамнар», «Ничә яшь сиңа, Әстерхан?», «Алтын Урда тарихы» исемле материаллар белән чыгышлар ясады.

*Гатауллина София Миңгәрәй кызы* – кала татары, ата-анасының тамырлары Кузнечихадан (Татарстан). Ана теленә мәхәббәт аны 1959 елда Нариман татар театрына алып килә, төп рольләрдә уйный. 1965 елда Әстерхан сәнгать училищесының баян классын тәмамлый. 1964 елдан телевидениедә һәм радиода «Татар сәнгатенең чишмә башында» исемле татар телендә тапшырулар алып бара. «Дуслык» җәмгыяте төзелгәч, беренче сәнгать коллективы – «Ялкын» ансамблен төзеде. 1990 елда бу коллектив Татарстанның 70 еллыгына чакырылды. Казан сәнгать институтыннан өлкән укытучы М.Н. Кашипов белән Әстерхан татарлары фольклоры турында зур күләмле материал җыйдылар. София Миңгәрәй кызы 1990 елда татар коллективларын туплап гарип һәм ятим балалар, караучысыз калган олы яшьтәгеләр фонды өчен ике хәйрия концерты оештырды. 1991 елдан София апа башлап җибәргән, Рамазан аена багышланган концертлар әле дә дәвам итә. 1995 елдан укытучыларның белемен күтәрү институтында татар теле, әдәбияты буенча лекцияләр укыды, шул ук елны Саратовтан килеп, Әстерхан татарларының гореф-гадәтләре турында, аның катнашуында фильм төшерделәр. Яшь талантларны җыеп, «Мирас» коллективын төзеп, хәйрия концертлары бирде. 2000 елдан «Ак калфак», аннан «Сөембикә», «Хаҗи-Тархан» берләшмәсе белән һәр ел Г. Тукай, М. Җәлил, Г. Исхакый, Һ. Такташ һ.б.ларга багышланган кичәләр, очрашулар үткәрә иде.

*Максутова Нурия Гәрәй кызы* – нугай татары. «Дуслык» җәмгыятенең нигез ташларын салган, беренче көннәреннән алып, күп еллар дәвамында җәмгыять советының иң актив, тынгысыз әгъзасы. Идел буе районының Каргалык авылында гомер буе укытучылык итеп, пенсиягә чыкты. Авыл, район күләмендә татар, нугайның милли традицион бәйрәмнәрен үткәрә. Борынгы бәйрәмнәрне (нугай татарларының «Әмил бәйрәме», «Карга боткасы» һ.б.) халыкка кире кайтара. Әстерханның XX гасыр башындагы татар, нугай җәмәгать эшлеклеләре, язучылары, мәгърифәтчеләре турында яңа материаллар туплады. «Идел» һәм Идел буе районы газеталарының штаттан тыш даими хәбәрчесе. Үз авылында татар, нугай халкының язучыларына, шагыйрьләренә багышланган әдәби кичәләр, очрашулар үткәреп килә. Өлкәдә татар телен саклап калуга зур өлеш кертә, район мәктәпләрендә бу проблеманы һәрчак күтәреп һәм яклап чыга. Каргалык авылында балалар бакчасында татар телен өйрәтүне керттерә алды. 2003–2004 елларда Идел буе

районының татар авылларында (Каргалык, Җәмәле, Ярлы Түбә) өйдән өйгә кереп, ана телен фән итеп укыту өчен ата-аналардан гариза җыйды. (Бу эштә башкалар да катнашты, берничә йөз гариза җыелды.) Ул гаризалар «Хаҗи-Тархан» оешмасында анализланып, карарлар чыгарылып, чаралар күрүне таләп китеп, губернаторга, уку-укыту министрына тапшырылды. Шуннан соң, ана телен укыту бераз җайга салынды. Югыйсә, 2002 елга кадәр өлкәдә ана теле бары тик ике авыл мәктәбендә генә фән булып укытуга калган, шәһәрдә бөтенләй беткән иде. Хәзер Нурия апа Ислам институты «Хаҗи-Тархан»да укый, хаҗия. Аның үткән юлы бик күпләргә үрнәк, чын мәгънәсендә үз халкын җаны, тәне белән яратучы зат.

*Хөсәенов Ришат* – 1954 елгы, кала татары, әти-әнисе чыгышы белән Буа (Татарстан) мишәрләре. «Дуслык» җәмгыяте учредителе, җәмгыятьнең нигез ташларын салып, иң актив эшләп киткән ветераннарыбыздан, озак еллар совет әгъзасы. Заманында вакытын да, исәнлеген дә кызганмыйча, бөтен барлыгы белән бирелеп, Әстерхан татарларын юкка чыгудан йолкып калу өчен янып йөргән киң күңелле, һәрчак ачык йөзле, кешегә ярдәм кулы сузырга әзер торган Ришат ул безнең. «Идел» газетасын аякка бастыруда Әлфия Дулатованың һич тынгы белмәс беренче ярдәмчесе, уң кулы булды. Күпсанлы туганнары, танышлары арасында газетага язылуны оештыруда, газетаны танытуда Ришат еллар буе «аяклы реклама» булды. «Идел»не почта аша башка шәһәрләргә җибәрүне яхшы итеп оештырды. Газетаның ул елларда даими штаттан тыш хәбәрчесе булды.

*Каюпов Әхтәм,* Волгоград татары. «Дуслык» җәмгыятенең һәм «Ялкын» ансамбленең беренче баянчысы. Татар җәмгыяте аякка басып килгән елларда табиб Шәфигуллин Надир белән (Татарстанның Азнакай районыннан) бик күп концертларда, бәйрәмнәрдә катнаштылар. Алар башкаруында «Сарман», башка татар халык көйләрен халык сорап-сорап җырлата иде.

*Сираҗетдинов Шамил.* Әстерхан өлкәсенең Яңа Болгар авылында озак гомер тарих укытучысы, аннан мәктәп директоры хезмәтендә булды. Яңа Болгар – Октябрь инкыйлабыннан соңгы авыр елларда Татарстанның Кама Тамагы, Тәтеш районнарыннан күчеп килүче татарлар салган авыл. Авылның йөзе, халыкның тормыш-көнкүреше хәзер дә Татарстан авылларына хас төсмерне саклый. Авыл Әстерханнан ерак, утрауда урнашкан. Шамил әфәнде татар-болгар тарихын яхшы белүче, аны мәктәп балаларына дөрес

итеп җиткерүче, Татарстан тарихчылары, археологлары белән хезмәттәшлек итүче. Туган авылы тарихын өйрәнеп, ике китап бастырып чыгарды. Тарихи темаларга багышланган конференцияләрдә даими чыгышлар ясый, газеталарга материаллар яза. Өендә борынгы чүлмәкләрдән, кувшиннардан торган музей бар.

*Хәйдәров Җиһангир.* Нариман районының Көлдермеш авылыннан. Хатыны Фәридә белән «Дуслык» җәмгыяте учредительләре. Җәмгыятькә нигез салганда зур активлык күрсәттеләр, халыкны тупладылар, без барып җитә алмаган авылларда алар булдылар. Җиһангир авыл халкы арасында абруйлы, сүзе үтә, ә Фәридә исә, үзенең матур, көчле тавышы белән классик җырлар башкарып, халык мәхәббәтен яулады.

*Асанов Рифкат.* Идел буеның Кызан (Татар Башмаковка авылыннан). «Кызан» фольклор ансамбле җитәкчесе. Аны төзеп, милли рух бөркеп, бүгенгә кадәр бердәнбер җитәкчесе. Әстерханда, Казанда төрле бәйгеләрдә катнашып, җиңүләр яулаган коллектив.

*Измайлов Әхъяр Яхъя улы,* каладан. 1925 елда Кашлы Яр авылында туа, беренче татар шагыйрәсе Газизә Сәмитованың карендәше, Бөек Ватан сугышы ветераны. «Дуслык» җәмгыятендә өч рәистәшнең берсе, берара «Идел» газетасында редактор вазифасын үтәде. Ана теленең матурлыгын тәне, җаны белән тоя, пропагандалый иде. Шигырьләрендә – ата-анага, татар хатын-кызына, туган якка, халкына, Казанга, Татарстанга мәдхия. «Родник любви» һәм «Әстерханым – туган ягым» исемле ике китабын чыгардык.

*Фатхуллин Марат Закир улы* – 1949 елгы. Тияктә яши. Нариман районының сәнгать бүлеге мөдире. Районда татар коллективларын, шул исәптән Нариман татар театрын авыр вакытларында саклап, яклап килде, финанс проблемаларын чиште. Районның сәнгать бүлеге мөдире буларак, татар коллективларын үстерүдә, мәдәниятебезне саклап калуда зур ярдәм күрсәтте. «Дуслык» җәмгыятенең беренче буыны белән чын күңеленнән хезмәттәшлек итте. Марат оештырган бик күп концертлар профессиональ югарылыкта уза иде.

Әстерханның «Сөембикә» берләшмәсе үзенең төп юнәлеше итеп ана телен, төрки-татар тарихын өйрәнүне, милли аңны үстерүне билгеләде. Бу максаттан чыгып, 1999–2001 елларда «Әстерхан ак калфагы» кысаларында, ә 2002 елдан бүгенге көнгә кадәр «Төрки-татар дөньясы» исемле программа нигезендә эшләп килә. Һәр дәрес «Яңа гасыр» каналыннан алынган татар дөньясындагы яңа-

лыкларга, Казаннан килгән газет-журналларга күзәтүдән башлана. Мәгърифәтчеләребезгә, милли зыялыларыбызга, әхлак-тәрбия нигезләренә, халкыбызның йолаларына, гореф-гадәтләренә аерым тукталып узабыз. «Казанның татар дөньясы», «Татар әдәбияты һәм шигърияте», «Милли музыка сәнгате», «Әстерханның һәм Россиянең татар газеталары» , «Ерак чит илләрдә һәм БДБ илләрендә яшәүче татарлар» исемле аерым дәресләр каралган. Шушы елларда программа күп тапкыр тулыландырылды, киңәйтелде, югарыда телгә алынган темаларга багышлап папкалар булдырылды. Шулардан кайберләре: «Кол Гали. Кыссаи Йосыф – төрки халкының беренче язма сәнгать әсәре», «Шиһабетдин Мәрҗани. Татарның реформаторы. Җәдитчелек белән укуга нигез салучы», «Кырым татары Исмәгыйль Гаспаралы һәм Зөһрә Акчурина. «Тәрҗеман» газетасы», «2 июль – Әстерханда, 15 октябрь – Татарстанда хәтер көне», «Татар хатынкызының милли хәрәкәттәге роле» һ.б. «Сөембикә» берләшмәсе Гаяз Исхакый иҗатына һәм аны пропагандалауга зур әһәмият бирә.

Әстерханда дүрт тапкыр «Гаяз Исхакый» укулары үткәрелде. Бездә аның «200 елдан соң инкыйраз», «Зөләйха» әсәрләре аеруча популяр. Декада көннәрендә «Зөләйха» спектакле дискын халыкка күпләп тараттык. Яшь буын гына түгел, урта яшьләрнең дә күбесе дә Казан ханлыгы алынгач, XVI–XIX гасырлардагы чукындыру турында бер нәрсә дә белмиләр. Шулай ук берләшмәнең күбесенчә тарихи китаплардан тупланган шәхси китапханәсе бар. Алар да ел әйләнәсендә кулдан-кулга күчеп йөреп укыла. Һәр ел Габдулла Тукай, Муса Җәлил, җирле шагыйрьләр иҗатына багышланган шигырь бәйрәме уздырыла. Укучыларыбызның, гимныбызга әйләнеп баручы «Туган тел» шигырен яттан белүләре мәҗбүри. Төркемгә 10–12 кеше укырга алына. Программа укучы яшьләргә, студентларга, милли зыялыларга, бераз булса да акны карадан аера белүче милләттәшләргә исәпләнгән. Ислам институты шәкертләре (егетләр), ихластан дин юлына баскан зыялылар белән эшләү җиңелрәк тә, аның нәтиҗәләре дә уңышлы. Алар Әстерхан татарлары тарихын яктырткан материаллар туплауда да ярдәм итәләр.

2002 елгы халык санын алу кампаниясендә «Сөембикә» берләшмәсе әгъзалары күпләп катнашып, татар халкын саклап калуда үзләреннән зур өлеш керттеләр.

# СҮЗЛЕКЧӘ

*Наилә Есенбаева*

18 ел Әстерхан өлкәсе, Идел буе районы, Киләче авылы мәктәбендә татар теле укытам. Мәктәптә эшләү дәверендә әстерхан татарларының теле, тарихы, гореф-гадәтләре, татар язучылары һ.б. турында укучыларым белән бик күп материаллар туплаДык, проект эшләре һәм фәнни эзләнү эшләре башкардык. Киләче авылының төп халкы – татарлар. Мәктәбебездә татар теле 2–9 сыйныфларда атнасына берәр сәгать укытыла. Татар әдәби теленә өйрәткәндә бик зур кыенлыклар туа. Беренчедән, сәгатьләр саны аз булу, икенчедән, дәрестә җирле сөйләм теленең аермасына, фонетик, морфологик, мәгънәви үзенчәлекләргә зур игътибар бирергә туры килә. Мәсәлән, әдәби телдәге *мин чигәм* ‘я вышиваю’ сүзе әстерхан сөйләмендә *мин тәмәке тартам* ‘я курю’ дигәнне аңлата. Берничә ел дәвамында укучылар белән шуңа охшаш, ягъни татар әдәби телендәге мәгънәгә туры килми торган гыйбарәләрдән сүзлекчә тупладык. Бу эшне дәвам итәргә уйлыйбыз. Сүзлекчә безнең төбәктәге укытучыларга, укучыларга һәм татар теле белән кызыксынучыларга да кулланма ярдәм булачак.

| **Әстерхан татарлары сөйләшендә** | **Татар әдәби телендә** | **Рус телендә** |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| абый, каха, ага | абый, ага | брат, дядя |
| аждаха, зылым | усал, явыз | злой |
| алдатчык, үтерекче | алдаучы, алдакчы, ялганчы | врун, обманщик |
| алматирәк | алмагач | яблоня |
| алтатар | револьвер | револьвер |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| алыс | ерак | далеко |
| ан як-мон як | анда-монда | там и сям |
| анау | шул | тот |
| армыт | груша | груша |
| ататут | үткер | шустрый |
| аткушар | исем туе | именины |
| ашар | ачкыч | ключ |
| ашарчы | ачкыччы | ключник |
| аяк | касә | пиала |
| аяк–савыт | савыт-саба | посуда |
| әби, мама, әйе | әби, дәү әни | бабушка |
| әкилмәгә | алып килергә | принести |
| әлүнкә | алабуга | окунь |
| әни, әмә | әни | мама |
| әпәй, калач | ипи, икмәк | хлеб |
| әрни | ярый, ярар | хорошо, если ... |
| әүлә | ишегалды | двор |
| баба | бабай, дәү әти | дед |
| бабай түбә | зират | кладбище |
| багай | кадак суыргыч, келәшчә | гвоздодер |
| багу | карау, күз–колак булу | смотреть |
| бадамжан | баклажан | баклажан |
| бай | ир | муж |
| байгыш, кәреп | мескен, ярлы | бедный |
| бакмага | көтәргә, карарга | пасти |
| бакырмага | кычкырырга | орать |
| бала | малай | мальчик |
| балапан | бала | детеныш |
| балга | чүкеч | молоток |
| бармага | барырга | идти |
| барын | барысын да | всех |
| батмак, батпак | пычрак, әшәке, шапшак | грязь, грязный |
| батраш, патраш | бөтнек | мята |
| баяк | күптән түгел, бая гына | недавно |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| бәлдүгән | шөпшә | оса |
| бәлеш, мәлеш | бәлеш | пирог |
| беген | бүген | сегодня |
| бер зәмит | бер минутта | в один момент |
| бибә | эне, сеңел | младший брат, младшая сестра |
| биби | сабый | младенец |
| бидрә | чиләк | ведро |
| бозаубаш | аю чикерткә, бозаубаш | медведка |
| бөлдергән | бөрлегән | ежевика |
| брыс | бүрәнә | бревно |
| бул | тиз | быстро |
| бутка, чүлә | ботка | каша |
| быка | үгез | бык |
| дагырда | сөйләшү | разговор |
| дәптәр | дәфтәр | тетрадь |
| дәрмән | дару | лекарство |
| дубия | фасоль | фасоль |
| дураж | чүпрә | дрожжи |
| духтыр | доктор, табип | Доктор, врач |
| жаучы | яучы | сват, сваха |
| жыбырдак | тиктормас | неугомонный |
| җәбер, зарар | зарар | вред |
| җәнҗәл | гауга, ызгыш | скандал |
| җимпер | джемпер, йон кофта | джемпер |
| җома | җомга | пятница |
| жырламага | җырларга | петь |
| зынгылдамага | такмакларга | трындеть |
| инә | энә | иголка |
| иркәк | ир кеше | мужчина |
| иртән | иртәгә | завтра |
| ишәк матрос | зебра | зебра |
| йөзлек | пәрдә | занавеска |
| каек | көймә | лодка |
| казан өй | җәйге аш өе | летняя кухня |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| кайзамага | кимерергә | грызть |
| кайкана, тилди | запеканка | запеканка |
| кайчанда | күптән | давно |
| как | баш арты | затылок |
| кала | шәһәр | город |
| камыраш | токмач | лапша |
| канә | яле | ну-ка |
| кара торып | торма | редька |
| карт, өлкүн, исле | өлкән, өлкән яшьтәге | пожилой |
| касик | тәрәзә төбе | подоконник |
| каскыр | бүре | волк |
| кәенмә | борчылма | не беспокойся |
| кәмпит | конфет | конфета |
| кәртүп | бәрәңге | картофель |
| кәченмәгә | шуу, тәгәрәү | кататься |
| керпе, керпе чичи | керпе | ежик |
| керт, кыпыл | йозак | замок |
| кече җома | пәнҗешәмбе | четверг |
| киет, саркыт, бүләк | бүләк | подарок |
| киетләү | бүләкләү | одаривать |
| кизәнкә | чолан, кәҗәнкә | чулан |
| киләяк | киләчәк | в будущем |
| кинә | ярый әле | хорошо, что |
| кипрән | мендәр тышы | наперник |
| кирпән | китмән | мотыга |
| кияү бала, җиздә | кияү | зять |
| Коран, Кран | Коръән | Коран |
| куз | чикләвек | орех |
| куй | сарык | баран |
| куймалак | бидон | бидон |
| кураз | этәч | петух |
| куырдак | кыздырган азык, куырган, куырдак | жаркое |
| күзәен, шатлык | шатлык | радость |
| күмәк | булышу | помощь |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| күл | кыр | поле |
| күләк | күлмәк | платье |
| күнтәп | туп | мяч |
| күрпә | матрац | матрац |
| күрше, кунсы | күрше | соседка |
| күрше, кунсы ата | күрше | сосед |
| кыдырмага | йөрергә | гулять |
| кыздырмыш, кумпәш | күзикмәк (*диал.* юка) | лепешка |
| кымбат | кыйбат | дорого |
| кыркылдак | тәртипсезлек | беспорядок |
| кышкалдак | кашкалак | лысуха |
| лакан, шаратабак | ләгән | таз |
| лаксалва, чәкчәк | чәкчәк | чак-чак |
| ләлмик, нәлмик | тәлинкә | тарелка |
| мадур | помидор | помидор |
| маймун | маймыл | обезьяна |
| мата | тукыма | ткань |
| манит | сум, тәңкә | монета, рубль |
| машин | машина | машина |
| маштак, кечкентәй | кечкенә | маленький |
| маштак, кыска | кыска | короткий (невысокий) |
| мәркү | кишер | морковь |
| минга | миңа | мне |
| минҗәрә | коридор | коридор |
| миске | кастрюль | кастрюля |
| монау | бу | этот |
| муллабикә | абыстай | абыстай (супруга духовного лица; старшая среди прихожан мечети) |
| мый | ми | мозг |
| мыр, мырын | борын | нос |
| мышык | песи, мәче | кошка |
| мыя | татлы тамыр, төче тамыр | солодка |
| ни зат? | нәрсә? | что? |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| ни зат итә?<br>ни зат итәде? | нишли? | что делает? |
| онкуна | куна | доска для раскатыва-<br>ния теста |
| өлкүн | зур | большой |
| палас | келәм | ковер |
| пәрәмәчә, кайнары | пәрәмәч | перемечи |
| пычмага | кисәргә | пилить, отрезать |
| пияла | көзге | зеркало |
| саз | гармун | гармонь |
| сандугаш | сандугач, былбыл | соловей |
| саран, арам | саран | жадный |
| сәрен | салкынча | прохладно |
| сарсылган | ватык, китек | колотый, треснутый |
| сасык тургай | чыпчык | воробей |
| саускан | саескан | сорока |
| сәлпитәк | дәртсез, сүлпән | инертный |
| свит | ут | свет |
| селпек | тирес | навоз |
| синәк | сәнәк | вилы |
| синга | сиңа | тебе |
| спае | матур | красиво |
| су кермәгә | су коенырга | купаться |
| суатак | сукбай | бродяга |
| супак | озын | высокий |
| сурамага | сорарга | спросить |
| сыпат//сыйпат | кыяфәт, чырай, килбәт,<br>килеш-килбәт, сыйфат | вид, лицо |
| сыпатсыз | шыксыз, ямьсез | некрасивый |
| сыр | буяу | краска |
| сырламага | буярга | красить |
| сырга | алка | серьги |
| тамак, аш | азык | еда |
| тамаша, кызык | кызык | интересно |
| тактамбит | сәке | нары (лавка) |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| тастымал | сөлге | полотенце |
| тәрәтканә, туалит | бәдрәф | туалет |
| тастархан | өстәл | стол |
| тәвә | дөя | верблюд |
| тәтә, кайти, атабикә | апа | тетя |
| тәтә | апа | сестра |
| тәтле | тәмле | вкусный |
| текпәгә, текмәгә | чигәргә | вышивать |
| тере | көрәк | лопата |
| тинтәк, ангра, тиле, яртыбаш, башы киткән, әләс-мәләс, жилбаш | юләр, тиле, аңгыра | дурак, глупый |
| тирәк | агач | дерево |
| токым | көнбагыш төше | семечки подсолнуха |
| тот//тут | тут агачы | тутник |
| трахтыр | трактор | трактор |
| туган-токым, туганнар | нәсел- нәсәп | родня |
| тустакай, шумакай | чүмеч | половник |
| тымгызмага | сүндерергә | выключить |
| тынчаймага | ял итү | отдыхать |
| тынчаю | ял | отдых |
| тышман | дошман | враг |
| уга | аңа | ему |
| укутучы, апай | укытучы | учитель |
| ут | чүп үләне | сорняк |
| үт, үлән | үлән | трава |
| хас итеп | үч итеп | назло |
| хатын, печә | хатын-кыз | женщина |
| чама | чәй бөртеге, чәй чүбе | чаинка |
| чәйнүк | чәйнек | чайник |
| чәүел | күсе | крыса |
| чигә | тарта | курит |
| чигәргә | үлчәргә | взвесить |
| чиккарын | эчәк-бавыр | требуха |
| шапраш | баскыч | лестница |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| шарлак | чарлак, чорма | чердак |
| шешә | пыяла | стекло |
| шкул | мәктәп | школа |
| шувал | торба, морҗа | труба печная |
| шурпа | аш | суп |
| шык | чык | выходи |
| шыптал | шәфталу | персик |
| шышкан | тычкан | мышь |
| ыйкамага | массаж ясарга | массажировать |
| ылакпа | типтерүче, типтерергә яратучы | гуляка |
| ыргашы | ана | самка |
| ыры | баз | погреб |
| ыспага | ышкырга | тереть |
| ыста | тот | держи |
| яга | елга | речка |
| яз | җәй | лето |
| язык | гөнаһ | грех |
| якмага | элдерергә, кабызырга | включить (лампу) |
| ялпак, җәмпәйгән | яссы | плоский |
| япрак | яфрак | лист |
| ярын | киләчәк ел | в будущий год |
| япалак | ябалак | сова |
| ястык | мендәр | подушка |
| ятсыз, битсез | оятсыз | бессовестный |
| Яхшы кичтә ят! | Тыныч йокы! | Спокойной ночи! |
| Яхшы юл! | Хәерле юл! | Доброго пути! |
| Яхшы кич! | Хәерле кич! | Добрый вечер! |

**Авторлар турында кыскача белешмә**

*Миңнуллин Ким Мөгаллим улы* – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы.

*Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре.

*Әхмәтова Дина Ирек кызы* – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Баязитова Флера Сәет кызы* – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

*Булатова Миңнира Рәхим кызы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге фәнни хезмәткәре.

*Есенбаева Наилә Ислам кызы* – Әстерхан өлкәсе Идел буе районы Киләче урта гомум белем бирү мәктәбенең татар теле укытучысы.

*Закирова Илсөяр Гамил кызы* – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

*Исимбитьева Альбина Ренат кызы* – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре.

*Потеева-Фатыйхова Наилә Шакирҗан кызы* – Әстерхан шәһәрендәге милли хәрәкәт җитәкчеләренең берсе.

*Рамазанова Дария Бәйрәм кызы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты баш фәнни хезмәткәре.

## ЭЧТӘЛЕК

ӘСТЕРХАН ӨЛКӘСЕ ТАТАР ЗИРАТЛАРЫ
ҺӘМ АЛАРДАГЫ КАБЕР ӨСТЕ КУЛЬТУРАСЫ
*Марсель Әхмәтҗанов*
9

ӘСТЕРХАН СӨЙЛӘШЕНЕҢ ЮРТ УРЫНЧЫЛЫГЫ
*Дария Рамазанова*
53

ТАМЫРЛАРЫ ТАРИХКА ТОТАШКАН
*Флера Баязитова*
123

БАЙ ТАРИХЛЫ, ҖЫРЛЫ ТӨБӘК
*Миңнира Булатова*
257

ӘСТЕРХАН КӨНДӘЛЕГЕ
*Илсөяр Закирова*
315

МАТЕРИАЛЬНАЯ И ДУХОВНАЯ КУЛЬТУРА
АСТРАХАНСКИХ ТАТАР
*Дина Ахметова*
353

ТЕПЛО РОДНОГО ДОМА
*Альбина Исимбитьева*
381

ТИЯК – ӘСТЕРХАННЫҢ БОРЫНГЫ ТАТАР БИСТӘСЕ
*Наилә Потеева-Фатыхова*
387

СҮЗЛЕКЧӘ
*Наилә Есенбаева*
410

Научно-популярное издание
*Серия «Из сокровищницы научных экспедиций»*

Одиннадцатая книга

**Национально-культурное наследие**
**АСТРАХАНСКИЕ ТАТАРЫ**

Фәнни-популяр басма
*«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе*

Унберенче китап

**Милли-мәдәни мирасыбыз**
**ӘСТЕРХАН ТАТАРЛАРЫ**

Редакторлар *Я.М. Абдулкадыйрова, Л.Ш. Давлетшина*
Компьютерда биткә салучы *Н.Т. Абдуллина*
Китапта *Д.И. Әхмәтова, М.И. Әхмәтҗанов, М.Р. Булатова, А. Исимбитьева*
фоторәсемнәре файдаланылды

Оригинал-макет
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде

Басарга кул куелды 09.01.2017
Форматы 60×84 $^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе. Times New Roman гарнитурасы.
Офсет басма. Нәшер-хисап табагы 18. Шартлы басма табагы 24,4.
Тиражы 500 д. Заказ 112727